ЭДУАРД
КАСЫЙМОВ

ШИҢМӘСЕН ГӨЛЛӘРЕҢ



ШИҢМӘСЕН ГӨЛЛӘРЕҢ
ЭДУАРД КАСЫЙМОВ

ЭДУАРД ҚАСЫЙМОВ

ШИҢМӘСЕН ГӨЛЛӘРЕҢ

ҖИР БАЛКЫШЫ



Роман

Ике китапта

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1986

ББҠ 84.4(2Р-Тат)
Ҡ30

Касыймов Эдуард.

Ҡ30 Шиңмәсен гөлләрең. Роман — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.— 479 бит.

Кама елгасындагы автогигант бөтен әйләнә-тирәдәге авылларның, анда яшәүче халыкларның тормышын үзгәртеп җибәрә. Авторның геройлары — гади кешеләр: без аларны хезмәттә дә, гаилә тормышында да төрле хәлләрдә, төрле конфликтларда, тышкы һәм эчке, үз характерларындагы каршылыкны җиңү юлында күрәбез.

Ҡ $\frac{4702510000-166}{М132(03)-86}$ 76—86 ББҠ 84.4(2Р-Тат)

© Татарстан китап нәшрияты, 1986

Беренче китап

ДУЛКЫН

БЕРЕНЧЕ ӨЛЕШ

1

Чем-кара туфраклы ифрат киң басуның бер канатында ялгыз трактор, тигез гөрелтәп, чәчү җирен эшкәртеп йөри. Тракторчы Хәнәфи Бариевның җиңнәре сызганулы, куллары идарә рычагларында. Ул бар уен, бар ихтыяр көчен үз эшенә биреп, куәтле тракторын гадәтенчә иpле һәм ыспай йөртергә тырыша иде. Ара-тирә, башын артка каерып, тракторына тагылган зур һәм килбәтсез агрегатына күз ташлап ала: ипле барамы, алай-болай «пеләшләр» калдырмыймы...

Әлеге чәчү җиреннән ерак та түгел, басу түрендә исә бөтенләй бүтән күренеш, дәһшәтле манзара: анда бихисап автоскрепер, бульдозер ише нәрсә җирнең чем-кара, симез туфрагын каезлап, бер тирәдә кайнаша... Анда кара-кучкыл тузан болыты күтәрелә, куәтле гүелдәүләр, ачы ыжгырулар колакны тондыра. Җир катламы вакыт-вакыт авыр ыңгырашып, калтырап-дерелдәп китә шикелле... Анда мәхшәр дигәннәре чын үзе купкандыр кебек!

Гомер-гомергә адәм баласын туендырып килгән үтә игелекле туфракны, тупас һәм авыр пычаклар белән умырттырып алалар да, «аждаһаларны» үкертә-бакырта, ташый бирәләр. Кара-кучкыл сырт калыная, күтәрелә бара. Әүвәле күкрәп игеннәр үскән изге, мәрхәмәтле җир күкрәгендә, менә сиңа рәхим ит, дигәндәй, чем-кара тау калкып чыга!

Басу йөзендә төзәлмәс җәрәхәтләр булып, әрләнбалчык сырлары сузылып китә, тегендә дә, монда да шыксыз шадралар ишәя бара...

Инде мәңге уйнамас монда серкәдә утырган арыш дулкыннары, күз явын алып алтынланмас мул бодайлар...

Ап-аяз күктә май кояшы. Ул бөтенләй гамьсез — планетаның бер ноктасында купкан галәмәткә бөтенләй ис-өн сиздерми. Тик рәхимсез кыздыруын гына белә... Әллә гаҗәпләнүдән, өнсез калып, каш җыерганмы?

Хәнәфи Бариев әлеге хәвефле якка хәтта күз салудан да тайчана. Аның иреннәре кысылган, гәүдәсен вакыт-вакыт сәер дулкын өшетеп алгандай итә, йөнтәс беләкләренә дә җегәр бер кайта, бер китә кебек. Юкса ул совхозның иң әйбәт җирләре зур заводлар астында

каласын күптән ишеткән, моңа җаны белән күптән инде күнгән дә иде шикелле. Ә кичә-бүген, күр син, күңеле белән ихтыярсыздан туарылды да куйды.

Ярыйсы ук киң басу буйлата авыр һәм шома кәтүкләрне әрле-бирле өстерәтеп йөртүләренең хикмәтен, әлбәттә, Мәнди апаең да төшенер бүгенге көндә: җир өсте беркадәр басыла төшеп, ике-өч көн элек кенә чәчелгән кукурузлары дымлы катламда тыгызланыбрак ятсын да, күбенеп, тизрәк шытым бирсен... Әйе, дым барында шытым бирсен, куәт җыеп калсын! Мул уңыш алам дисәң, моннан соң да әле ничәмә-ничә тапкыр эшкәртәсе булыр бу басуны...

Дым, дым...

Бүген иртән совхозның баш агрономы Ризван, имән бармагын янә текә чөйде — ничәмә көннәр инде гелән бер нәрсәне тукый:

— Көне-сәгате кадерле! Китә бит, югала бит дым дигәннәребез... Син дә тырышмасаң, кияү, кем тагы...

Хәнәфи әллә белмиме, аңламыймы? Шөкер, фронттан кайтканнан бирле тракторда, игеп игүдә... Хәер, бик күп аңарчы, юеш танавын сөртештергәләп, ялан тәпиләре белән ат кабыргасына бәргәли-бәргәли, басуда тырма өстерәтеп йөргән чагыннан ук әллә ниләрне күңел түренә сеңдерә башлаган крестьян малае ич ул...

Күктәге явым, җирдәге дым...

Язга чыктың исә, җылы җилләр дә шуны искәртеп, крестьян күңелен сызландыра лабаса. Елның-елында...

Керфекләр авыр. Кул аркасын маңгаена тидереп алса, анда салкын тир...

Шушы кукуруз җиренә ул кичә төштән соң күчкән иде. Ә бүген төшкә тикле аны бетереп тә куймакчы иде. Кая ул! Әнә күктәге кояш инде түбән таба тәгәрәүгә дә юл тотты. Аның эшкәртер җире исә әле хәтсез. Аргы очтан янә биш-алты тапкыр әйләнмичә түгәрәкли дә алмас.

Юк, бу як басуга чыгасы калмаган аңа. Тегендә Калмаш авылы янындагы кукуруз җире дә атнадан артык инде эшкәртүне көтеп ята. Анда калкурак төш, булган хәтле дымын да очыртып бетерә язгандыр инде. Чөгендер җирләре тагы... Ә монда, «мәхшәр купкан басу» тарафына икенче берәүне җибәрттерәсе калган. Тик кемне?

Баягынак аның янына Гарапша сугылды. Гарапша — бүлекчә управляющие, совхозның үзәк авылына хуҗа кеше. Тарантаска җигелгән җирән кашкасын

трактор янына ук китереп туктатты. Хәнәфинең трактор чылбыры төбендә, күләгәдә җиргә аяк сузып тамак ялгап утырган чагы иде. Теге тарантастан авыр гына кубарылып төште дә, йомры, калын гәүдәсен язгандай иттергәч, кояшта янып каралган йөзен ямьшәйтеп төбәлде:

— Бер-бер җире ватылып ятамы инде моның дип, котны алган идең. Болай гына икән, ярый... Ә шулай да акыртынрак кыймылдыйсың түгелме син бүген?

— Бетерербез әле. Ашыгып ашка пешмик.

— Пешәрсең дә! Менә бит ничекләй кыздыра. Моны тизрәк әтмәлләп чыксаң, әнә юлның теге ягында чөгендер чират көтеп ята. Аны шаровкалап чыкмыйча ярамас, дим... «Беларусь»ка кучәрсең.

— Соң, баш агроном Ризван иң әүвәл кукуруз җирләрен бетерергә диде түгелме? Кайсыгызны тыңларга соң? — дип көлемсерәде Хәнәфи, кулында сөтле шешәне селеккәләп.

— Агроном, имеш... Мин әйткәнгә колак сал син, йомры баш! Азаккы сүз минеке булыр.

Гарапша сүзне, бигрәк тә әмер дитәнен, эредән җибәрүчән. Аның бу холкын бик әйбәт белгәнгә күрә, Хәнәфи сүзне капыл өзәргә булды:

— Ярар, аңлашылды... Артыгын боргычламыйк, дим.

— Җук, аңлашылмады әле...— Гарапша моның каршысына чүгәләп утырды, йомры тез капкачында юантык бармакларын биеткәләде.

Хәнәфи, сабырын җыя төшеп, башын кыңгыр салды.

— Таң тишегеннән җабышып, миннән өстә утыручылар кемне боргычларга тотына? — дип тезеп алып китте бүлекчә башлыгы.— Директормы анда, баш агрономмы яисә бүтән берәр «баш»мы... Кемне, дим? Мине түгелме? Ә мин кемне боргычларга тиешле? Аның дөньясы шулайрак корылган шул, каһәре: боргычлау югарыдан түбәнгә таба бара. Киресенчә түгел...

— Анысы хак...

— Хәлләр, хәлләр... Былтыр, өченче елларда, һай, рәхәттә яшәгәнбез икән — прәме сагынырлык! Ә бу язны — тфү! Механизаторларның звенолары таркалып бетте. Әнәтерә бәрәңге утыртырга кеше табып җиткерәсең җук. Ул да түгел, фермада ике савучы кыз, ике җилбәзәк атна буе инде кәҗәләнеп маташа, бу да житмәсә, бүген иртән бер көтүче шалапай... теге кем Исламгәрәй малае сырт йоннарын кабартып килгән — анысына

тикле «ҚамАЗга бетон салмага китәм» дип яный. Эт талагыры!

— Килешәм, хәлләр хәл совхозда,— дип ияк какты Хәнәфи.— Шулай да артыгын уфтанмыйк: бер эзгә төшмичә калмабыз әле... Тукта, әлеге сүзнең җеп очын югалтмыйча сорыйм әле үзеңнән: менә син, әйтик, мине бик шәпләп, үтем сытылганчы боргычладың, ди, ә мин кемнең шөрепләрен борырга тиеш инде, ә? Өйгә кайткач, хатын шөрепләренме? Әллә эчтән генә үз-үзеңне боргычлау да җитәрме? Һич югы, ачу-ярсуны басар өчен, шушы җанкисәгем тракторның тетмәсен тетәргә тотынаймы? Ә бәлкем, бары да җиргә сеңсен дип, шушы шидәй йомшак туфрактан үч алыргадыр? Иң ахыры үзсбезне туендырган изге җирдән, дим...

Гарапша аягүрә күтәрелде, күз кырыйлары белән генә югарыдан түбән таба сөзеп карады. Тракторчы Хәнәфи белән ул бер генә тапкыр сүз көрәштереп карамагандыр, әмма берәр кайчан юньле нәтиҗәгә килгәннәре булдымы икән?

— Җарар, чытырманлыкка кермик...

Моның соңында Гарапша, көрән кепкасын күтәреп, баш түбәсен кашыштырып алды, авыр-авыр сулап куйды.

— Җирләр, җирләр!.. Аллаһы әкбәр дигәндәй, китте безләрдән иң берәгәйлесе, иң һәйбәте... Киләсе елны шушы кукуруз җирең дә яртысыннан күбрәге ф-ю-ют... Азаккысы тапкырында нишләр инде, уңышны мул бирә белерме?

Хәнәфи дә, ризык букчасын күтәреп, аягына торып баскан иде инде. Азмы-күпме тәгам җыеп, берара тын алудан ул гәүдәсенә хәл кергәнлеген аермачык тойган иде. Шуңа күрәдер, тавышы ярыйсы ук көр чыкты:

— Елы-көне килеп, үзебез сынатмасак, ник бирмәсен?

Икесенең дә күз карашы тузан болыты асылынып торган «мәхшәрле басу» ягына төбәлде. Беравык тавышөнсез генә күзәтеп тордылар.

— Дөбер дә шатыр... Әбәткә дә юньләп тукталмадылар кебек. Вәт нишләтә бәндәне симез калҗа исе, ә? — Гарапша юантык гәүдәсен Хәнәфигә таба бора төште.— Синең Айдаш та шунда түгел микән?

— Белмим.

— Ул нәрсәдә, скрепердамы әллә бульдозердамы?

— Бульдозер дигән иде.

— Алайсам, шунда булмый, кайда тагы? Әлегә

ҚамАЗның башы гына бит... Туган авылы кырларында ут уйнатып йөргән егетең бер заман сыпыртсын әле шулай иттереп койрыгын сыртка салып!

— Сүзеңне үлчәп әйт, Гарапша: рөхсәт белән, комсомол путевкасы белән китте лә ул.

— Булса соң! Аны түгел, сине җәлләп әйтүем...— Гарапша янә тракторчы агайга күз төшереп алды, әмма аның йөз-кыяфәтендә кызгану, үз итү чалымы тамчы да беленми иде.— Үзеңә бак син, Хәнәфи дускай, тоташтан икешәр смена кудыра-кудыра элеп киптергәнгә калдың лабаса...

— Әллә зарланганым булдымы сиңа? — Хәнәфи тамак төбенә авыр төер менеп килгәнен аермачык тойды.— Аннары соң, бер улым китсә, икенчесе янда ич... Әллә Вәсимем сынатамы?

— Вәсимеңме? Егет ул! — Гарапша телен шартлатып алды.— Бәрәңге җирендә синең Вәсимең тырышмаса, ай-һай ла!

— Менә-менә, иң әүвәл шулай дип тел тибрәндерерләр.

Шул арада, ни күрсен, Гарапшаның йөзенә янә төксе караңгылык иңеп өлгергән.

— Айдашың исә... Ыһым... Хәл белешергә дә сугылмасын әле! Бульдозерында ыжгырттырып килергә чүп кенә ара югыйсә. Әллә үзе эшләп йөргән әфлисун төсендәге «дытысын» танымас булды микән? Хәер, симез калҗа исе борыныңны кытыклап торса, дөнья төсләре үзгәрүчән бугай...

Моңа Хәнәфи ни дип җавап бирергә дә белмәде. Тик «әфлисун төсендәге» тракторының чылбырына күтәрелгәч кенә, күңел әрнүен яман тавыш белән кысып чыгара алды:

— Атыңны ал, дим, сыбызгы! Йөрисең шунда болай да сызлаган җанны көйдереп!

Гарапша булсын да каныңа тоз салып китмәсен, имеш.

Айдаш... Чынлап та өлкән улы аның шунда, басу түрендә бүтәннәр белән бергә үз «аждаһасын» үкерттереп, кайнаша микәнни? Соңгы мәртәбә Чаллыдан кайтуында, моннан берәр атна әүвәл: «Нинди эштә булыйм? Минеке билгеле инде, җан-фәрманга җир умырттырам»,— диебрәк сөйләнгән иде. ҚамАЗ төзелешен галәмәт зур, диләр, бәлкем, ул бульдозеры белән бөтенләй бүтән төштә эш кыйрата торгандыр? Ә, бәлкем, мәлгунь Гарапша авызыннан хаклы сүз ычкынгандыр: акча сөре-

меннән, житмәсә тагы, шундый кара-кучкыл тузан болыты эчендә, Айдаш та дөнья төсләрен җуя башлагандыр?

Хәнәфи кукуруз басуын гөлдер-келтер иңләп йөрүендә булды, үзе «мәхшәрле тарафка» күз салмаска тырышса да, күңеленнән һаман, менә-менә улы Айдаш бульдозерын үкерттереп аның каршысына килеп чыгар, һич югы, җәяү генә тыпырдатып килеп җитәр дә әтисенең хәлен белешер, дип, көтә иде. Торган саен бүтән төрле ихтимал куыла бара, күңелендә тик шул уй, тик шул теләк кенә көчәя, ныгый бара иде. Әле кайчан гына үзе айкап йөргән һәм шаулап торган игеннәр үстергән туган туфрагы лабаса!

Ниһаять, Хәнәфи кукуруз җирен азакны тапкыр әйләнеп узды. Узды да тирән сулап куйды, кул аркасын янә маңгаена тидереп алды: һаман да салкын тир...

Тракторы ызан буенда калды, үзе әле генә эшкәртеп үткән басуга кереп, җиргә сузылып ятты.

Көн матур, җылы торып, җир дә коры булганда, ул шулай басуда берәр эшне төгәлләсә, берара тын алгаларга гадәтләнгән иде. Күбрәк вакытта, кулларын баш астына салган көйгә чалкан ятар иде. Янында басынкы гына тракторы гүли — ул аңа җанны тынычландыручы рәхәт көй сыман булып кына ишетелә, үзе исә зәңгәр күк гөмбәзендә йөзгән болытларны күзли бирә яисә керфекләрен йома да битен йомшак җил сыйпавын тойган хәлдә, оеп китә. Алар шулай икәүләшеп — хуҗа белән аның корыч айгыры — бүтән эшкә кузгалганчы, бермәл ипле генә хәл җыеп алгалыйлар...

Бүген Хәнәфи җиргә капланып ятты. Куллары белән як-яклардан сыпырып, мендәр сыман иттереп, кара туфракны өйде. Аннары туфрак мендәргә кулларын җәеп салды, аның өстенә салкын тирле маңгаен куйды. Җир катламы бөтенләй гүләп, дерелдәп тора ич: тегендә артык авырттырып каезлыйлар ахры җир тәнен...

Ә туфрак җылы. Исе дә җылы. Мәңге тансык һәм кадерле ис... Киләсе елны моны тау иттереп өячәкләр. Соңыннан, зур заводлар калыккач — алар тирәсенә, Яңа кала салынгач,— аның клумба-газоннарына сибәчәкләр, имеш. Гөл-чәчәкләр үсәр, әмма иген бөртеге инде бүтән шытмас... Шулай буласы, диләр...

Җир җылысы тәнне түгел, җанны җылыта, әчкелтемтатлы исе ачырганган бәгырьне иркәли сыман.

Уйлар оча торды, гәүдәсе авырая барды...

Озак яттымы Хәнәфи, аз яттымы шулай, кинәт үзенең иңбашына кемнеңдер йомшак кына орынуын тойды.

Тавышы да якын һәм үз... Бәй, өлкән улы, зарыгып көткәне Айдаш лабаса!

— Әти дим, бу хәтле үк нитмәсәң иде лә!

— Берни юк, улым, берни... Чак кына... Җир кадере дип кенә...

— Мин бик аңлыйм, әти.

— Юк, аңлап бетермисеңдер... Безнең үзебездә генәме, бөтен Чаллы районында иң һәйбәт басулар иде лә! Теләсә нинди елны да уңышны мул бирер җирләр иде...

— Бик беләм! Шуңа күрә бер карышы, бер учы да әрәмгә китмәсен дип изаланабыз да бит инде.

— Артык кәҗүнни сөйлисең кебек, улым... Ата-бабаларыбызның тире дә, каны да тамган туфрак бит! Читтән-яттан килгән халыкка бар да бер, ә сиңа?

— Әйтәм бит, шуңа күрә күз карасыдай саклап кына...

— Их, әле кайчан гына ярыша-ярыша эшләр идек! Борчак басуында керәшен Әртәми алга чыкса, арыш яки анда арпа белән кукурузда безнең бригад алдырыр иде... Ә былтыр ишелеп уңган бодай соң! Кайсы басуыбыз гына бирә алыр микән тагын шундыйны — уеңа кергәне бармы, улым?

— Ник кермәсен, ди? Шуңа күрә...

— Сез анда дөнья җимерттереп җир каезлыйсыз, ә минем монда бәгырь каезлана... Их, улым, улым!

Хәнәфи үпкәчел, әмма җылы хис белән улының иңбашыннан каккаламакчы булды, әмма уң кулы, һавадагы бушлыкта айкалып алгач, коры туфракка орынды. Шул мәлне, авыр сискәнүдән торып утырды. Торып утырса, янында беркем дә юк.

Төш тә түгел, өн дә түгел, әллә ни... Тәмам исәрләнүеме әллә?

Ах, җир, җир — мәңгелек куаныч, мәңгелек хәсрәт! Син түзәсең, ә мин?

Әртәми... Әртәми Колчерин... Озак еллар буе Хәнәфи белән кырлар киңлегендә алышып-ярышып йөргән дусты да, көндәше дә...

Менә кем бу көнне, бу сәгатьтә Хәнәфинең уй-хисләрен аңлап, аның хәленә керә белер иде. Тик шушындый чалт аяз көндә аны өйдә туры китерүләре генә... Авылы Үтәдем әнә кул сузардай гына җирдә, Шилнә буйлата күккә табан биек тирәкләр тибендереп, җәйрәп ята. Алдагы язмыш тамырына инде балта чабылган чибәр авыл — их, дөньялар!..

Бүтәннәр өйдә югында, аулак сәгатьләрдә Мәтрүнә түти, самовар яңартып, тамак чылаткаларга яратучан булып китте әле.

Хуш исле сөтле чәй йөрәккә сарымай булып куна инде ул, картая төшсәң. Бигрәк тә шушындый сулышны куырырдай кызу көннәрдә.

Ваклап туралган шикәрне тел очына сала-сала, бер чынаяк бушатты, икене, өчне... Ниһаять, сусыны басылып, гәүдәсенә рәхәт җиңеллек һәм җегәр кайтканлыгын тойды, зиһене дә тәмам ачылып киткәндәй булды. Моның соңында, өстәлдәге ризык өстенә чиста тастымал каплады һәм урыныннан кузгалды. Кузгалды да яулык очы белән генә авыз тирәсен сөртештергәләгәч, аш арты догасын әйтә-әйтә, чукынып алды:

— И ходаем, җирдәге дәүләтең белән туйдырып торганга сиңа тау итәбез. Күктәге дәүләтеңнән дә буш калдырма инде...

Инде хәзер эштән кайтасы кешеләр өчен дә аш салып җибәрсә ярый торгандыр. Эмаль кәстрүлне урындыкка куеп, су чүмеченә генә үрелгән иде, капыл бүленеп калды: олы як тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп, капка төпләренә трактор килеп туктады. Бу ни хикмәт икән? Кем икән? Аларның капка төпләрендә трактор гөрелтесе яңгырамаганга бер атна гына түгел бит инде...

Аптыраган түти болдырга чыгып өлгергәнче, капкадан берәү тамак кыргалый-кыргалый кереп тә килә иде инде. Тузанга-майга күмелгән, таушалганрак кием — мондыйларга Мәтрүнә түти әллә кайчан күнеккән инде, тик бу адәмнең йөзе-кыяфәте артык алҗыган да, бер үк вакытта ярсыган да сыман. Болай таныш та кебек үзе, бик таныш кебек... Болдыр төбендә тукталып, Мәтрүнә түти белән җылы гына күреште, саулыгын сорашты, аннары ипле генә елмайды:

— Ходага рәхмәт, димсең алайса... Әйбәт, әйбәт! Ә мин ни... Әртәми Вәсиличны туры китерә алмаммы дип кенә сугылган идем. Ахры, уңмадым бугай...

Менә шунда гына Мәтрүнә түти чәчәкле алъяпкычы өсләтә бот чапты:

— Бәрәч, Әҗердән лә син, үзебезнең Хәнәфи лә син! Әллә артыгын олыгаеп киткәнсеңме, дим... Әйдүк, әйдүк, Хәнәфи энем!

Бусы баскан җирендә таптангалап, үз сүзен кабатлады:

— Мин болай гына, Әртәми Вәсиличны күрә алмаммы дип кенә идем...

— Һе, әллә ишетмәгән иеңме? Әртәми Бәчиличең, савхузны калдырып, төзелешкә җөри бит ул хәзер. Инде икенче атнасын җөри... Оныгым Вәлүдә дә шулай. Анысы кар сулары төшкәнче үк киткән ие. Шулай, Хәнәфи җанкисәгем, аталы-уллы ҚамАЗга җабышты бит безнекеләр!

— Менә сиңа мә, ишетмәсәң, ишет! — дип баш чайкады Хәнәфи һәм шул мизгелдә кисәк тез аслары йомшаруын тойды. Болдыр баскычына утырмый чарасы калмады. Колак артын кашыштырып алгач, капыл исенә төште тагы: беркөннәрдә ишеткән иде шул: имеш, Гәрдәле җирендә борчак чәчтереп йөргән чагында Әртәми Қолчерин, кулында туфрак учлап, ант итеп әйткән, ди: «Үз басуларымнан колак каккач, дөньяның кызыгы бетте миңа. Менә сезгә борчак җирегезне генә бетерешәм дә, үзем дә биштәрне аркага асам але»,— дигән, ди. Тәки үз сүзендә торган икән Үтәдемнең бер асыл ире!

Хәнәфи шулай калын җилкәсен җыергалап утыра бирде, аның баш өстендә Мәтрүнә түти үзләрендәге хикмәтле үзгәрешләрне үзенчә аңлатырга тотынды:

— Соң, безнең авылның җартысы күпты инде. Нишләсен кеше? Чәчкән-урган җирләребез китеп бетте, үзебез авылыбыз белән завод чолганышында калып җатабыз...

— Қая, тамак чылатырга салкын суың юкмы?

— Ниткән су сиңа? Әлсерәсәң, самоварым гөжләп утыра! Әйдә, дим, ризыктан өстен түгелсеңдер әле.

— Бу кыяфәт белән өйгә үтүе дә...

— Һе, синең ише трактористны күрми җәшәгәнме әллә без?

Аш өстәле алты почмаклы иркен генә өйнең алгы өлешендә, кече якта иде. Матур ак самовар, басынкы гына булса да, гөжләп утыруда иде.

Хуҗа карчык көтелмәгән кунак алдына йомшак күмәч телемнәре өйде, шикәрен-маен куйды. Олы гына чынаякка куе иттереп сөтле чәй ясады.

— Син үпкәләмә инде, үзем әләрәк кенә табын артыннан купкан ием. Үрел дим, әйдә, үрел... Ходага рәхмәт, ризыктан өзелдерми бу җылларда...

— Чәйнең бәрәгәйлесе бу! Қулларың сырхауны белмәсен, түти!

— Җарый, җарый, син үз җаеңны кара инде иркенләп... Ә мин аш-суымны караштырыйм әле. Фатирантлар

кайтканчы, ичмаса, ите пешә торсын,— ди-ди, хужа апа чуар чаршау артына, тагы да кечерәк якка кереп, анда савыт-саба кузгаткаларга тотынды.

— Ниткән фатирантлар ул тагы?

— Соң, кем булсын! КамАЗ төзүчеләр инде... Безнең авылга шыплап тутырдылар бит... Әллә кайчан ук. Кеше саен, жорт саен! Ә ник, сезнең авылга барып житмәделәрмени әле?

— Юк кебек... Хәер, мин таң тишегеннән торып китәм, күз бәйләнгәч кенә кайтып керәм, алай искәргәнем дә булмады әле.

— Сезнең Әжер жырактарак шул... Ә безгә ике жегетне куйдылар. Болай иплеләр үзе. Берсе кыргызмы, казахмы шунда, икенчесе сап-сары башлы — әллә урыс, әллә хахул инде. Армиядә чакта ук ахириләр булган, ахрысы.

— Алай икән...— Хәнәфи, күз карашын чуар чаршауга төбәгән хәлдә, уч төбенә генә йөткергәләп алды, аннары сагаюлы тавыш белән эндәште: — Ә ни... Әртәми Вәсилич ниндирәк эштә икән инде?

— Һи, аның эшеләргә дөнжада эш бетәме соң? Аталы-уллы жул салуда алар. Әртәми ниндидер нәрсәкәйдә жулны тыгызлаттыра, ди, ә Вәлүдәбез, шофер кеше, ташын да, комын да китереп аударып торам, ди.

Ике арада бермәлгә тынлык урнашты. Хәнәфи, өстәл читенә таянып, уйга калды. «Әртәми кайда да төшеп кала торганнардан түгел... Бүтәннәр кыздырмаганда да ул үзе кабыныр...»

Тегендә үз эшен түгәрәкләде ахры, Мәтрүнә түти чаршау артыннан бу якка чыкты да:

— Анакай гынам, ни уйга батып утырасың әле?! Жук-жук, бер жомры белән сусын басыламы соң! — ди-ди, табынга үрелеп, чәй яңартырга кереште.— Әллә ниме... күңелең теге нәмәрсәкәйгә кымыржылап торамы, хода бәндәсе?

Хәнәфинең ихтыярсыздан авызы ерылды да китте:

— Тап өстенә бастың, түти! Әртәми дус өйдә булса, кәефләнә белер идек үзе. Пошаманнарны пыран-заран таратып, дигәндәй...

Тракторында бу авылга килгән чагында ук абзаң канын кыздырып куйган иде, хәтта Әртәми дусын өйдә туры китерә калса, инеш буеның аулаграк уентыгына төшеп, кәеф-сафа кору хакында хыялын уйнатып та алган иде. Әмма хыялы сызган шырпы ялкыны гына булып чыкты, чәнчелгере.

— Һи, Әртәми дусың булмаса да, стаканнарны тутырып, көмеш нурлар уйнаттыра-уйнаттыра куяр гына иемдә бит алларыңа... Җук шул, җиңү бәйрәме көнендә үк инде тамчысына тикле сыгып бетерделәр...

— Ә бит сездә өзелмәс иде лә ул көмешкәй.

— Өзелер чаклары җитте, күрәмсең... Чаллыда бит хәзер «корыган закон» диебрәк кысалар, ди. Җиле безнең авыл җиренә дә таралмый калмый инде аның: барыбызны да урап алды, чайкап салды дигәндәй бит бүгенгесе әкәмәт хәлләр...

— Анысы шулай: безнең авылда да кибет шүрлекләрен әллә кайчан корыттылар инде.

— Беркөнне участковый Фәйзрахман кереп үземнең дә котларымны алды. «Зәм-зәм сулары савып ятуларыңны бер генә сизим, этаплар белән Себернең иң зәһәр почмагына озаттырам, Мәтрүнә апаем, чамала»,— ди... Адәм мәсхәрәсенә калыйммы, тоттым да бар нәмәрсәләремне җыеп, келәт чормасына җәшереп куйдым әле.

Түти, бермәл тын торгач, авыр гына көрсенеп алды:

— Шулай да эзләгәнә таба инде аның — тыясың җук. Миндәге җегетләр, ходага рәхмәт, әлегә бик ыспай җөриләр. Әмма күрше-куләндәге фатирантларның төрлесе бар, арада, ай, зәһәр кыланмышлы килмешәкләр дә бар сыман...

Кунагының ничектер иренебрәк кенә чәй йоткалавын Мәтрүнә түти, әлбәттә, үзенчә юрады һәм, ярым пышылдауга күчеп, бөтенләй үз итеп әйтә куйды:

— Чәй чәй инде ул... Җәшермә, дим, күңелең әллә тегеләйрәктәме соң, Хәнәфи? Алайсам ни... Бакча башында Мөкетә картның кара мунчасында бу төнне тычкан күзе бөтенләй дә сүнмәде шикелле. Әйләнимме әллә үзеннән? Хәлгә кермәстәй карт түгел ул безнең...

Хәнәфинең үз гомерендә, хәмер эзләтеп, читкә-ятка кеше чаптырганы булмады, әле хәзер дә кашларын югары чөеп, кискен рәвештә баш селекте:

— Юк, юк, сүз итеп сөйләмә дә, түти... Чәйләрең бик тәмле! Ә иблис суын алай ялгыз башыма чөмереп утырырга яратмыйм да...

Кунагының мондый сүзләренә түти бик канәгать булды, ахры, җыерчыклы йөзе мөлаем нурларда балкып ук китте:

— Үз чамаңны үзең белгәч, әйбәт инде ул. Ә мин үзем ул «корыткан законнарына» бик тә ризамын болай. Соң, безнең Әртәмине әллә кайчаннардан беләсең ич, ул шайтан канын бер имәргә җабышса, әллә нишли: дуа-

маллануның чигенә чыга. Үзе-үземне битәрләү булса да, әйтәм инде: чеп-чи керәшен акылы үзендә — керәле дә чыгалы.

— Ул иблис сөремендә барыбыз да бериш, түти,— дип кыстырды Хәнәфи, тракторчы дусын беркадәр яклапарга ниятләп.

— Җарый әле, бәхетебезгә, тегендә барып орына белде, КамАЗга, дим. Ходага рәхмәт, соңгы араларда исенә дә төшерми... Әүлиянең үземени!

Мәтрүнә түтинең башка авыл кешесе белән менә болай авыз тутырып сөйләшеп утыруны үтә тансыклавы әллә каян беленеп тора иде, һәм ул үз хәлләреннән бәйнә-бәйнә тагын ниләр генә тезмәс иде әле, әмма кунагы, чынаягын каплап, аны читкәрәк этеп куйды да табын артыннан кузгала башлады.

— Кул-аягың сырхауны белмәсен... Галәмәт булды ла бу!

— Рәхмәт инде ипле сүзеңә! Безне онытмыйча керә белүең өчен тагы... Күр, мәйсез-нисез генә дә байлар төсе инде лә үзеңә!

Чын ахры: Хәнәфи кул аркасы белән маңгаен сыпырып караган иде — юеш. Әмма инде хәзер баягыча салкын тир түгел, кайнар, таза тир бәреп чыккан иде.

Гәүдәсенә сеңгән рәхәт җиңеллекне тойган хәлдә, түтигә янә рәхмәтләр яудыра-яудыра чыгып китәргә иде аңа, юк, керәшен дусының чынлап та мул һәм иркен тормышта яшәвенә тагы да ныграк ышанырга теләгәндәй, өйнең түр ягына күз салырга ниятләде. Моны ул керә-керешли үк эшләргә тиешле булгандыр, бәлкем. Ярар, соң булса да уң булсын, дигәндәй...

Юка челтәр каплаулы һәм ак тигез бuяуга буялган пыялалы ишекне киң ачып эчкә үтте. Былтыр ул булып киткәннән соң, байтак нәрсә яңарган шул: түрдә дәү экранлы, нәзек аяклы телевизор кукраеп утыра, бер кырыйда бизәкле-чәчәкле савыт-саба белән тулы ялтыравык сервант урын алган, сул кулда исә саргылт-яшел төстәге диван-карават, аның бер почмагына өр-яңа баян менеп кунаклаган...

— Рәхәтен күреп кенә, гөрләтеп кенә яшәргә насыйп булсын инде! — дип тел чатнатты Хәнәфи, күңеле хушлануын һич яшермичә.

Әлбәттә, бүлмәдә искедән дә күп нәрсә үз урынында саклана иде: кара калайлы түгәрәк мич, аның артындагы матур чәчәкле озын чаршау, тәрәзәдәге гөлләр, тагы әллә ниләр... Иң түр почмакта югарыда исә шактый

тоныкланып, тәссезләнеп калган әүлия сурәте. Ул баш-башлары матур чигүле ак сөлге белән уратып алынган.

Икона алдында нәп-нәзек шәм янып тора иде, хәтта берәү генә дә түгел, берьюлы өчәү.

— Нәрсә, түти, бер-бер бәйрәмме әллә сездә?

— Җук ла...— Түти тотлыгып торды, яулык очын авызына китерде.— Күршедән Варвараттәй кушкач, җандырган ием. Аулак сәгатьләрдә генә булса да дип... соң бит... соң...

Бер тын ара шулай икеле-микеле хәлдә каушабрак торганнан соң, түти серне ачарга булды, кыяфәте моңсу, тавышы сагышлы иде аның:

— Соң, Хәнәфи җаныкаем, шәмнәр җандырып куймый, нишләмәк инде? Бар булган, гомер-гомергә маңгай тирләребез тамган җирләребезне әнәтерә умырттырып, актарып җаталар, җитмәсә тагы: бөтенләй бүтән җиргә күчерәселәр, ди, авылыбызны... Әле ул гынамы, заводларының берсе бер кырые белән, имештер, тап безнең зират өстенә туры килә, ди. Шулай булгач, үзең аңла инде безнең Үтәдем җазмышкайларын...

Хәнәфинең гәүдәсен салкын дулкын кымырҗытып узды:

— Хәлләр, диген...

Ә түти күңелендәге тирән серне менә болай капыл гына ачып салуның гөнаһысын шундук капларга ниятләптер инде, түр почмакка төбәлгән килеш, пышын-пышын чукынырга кереште. Догасы саф татарча, аның аерым сүзләре Хәнәфинең колагын өтеп алгандай итте:

— И Кристос аллабыз, берүк без җазыклыларны җәтим итмә инде! Күңелләрең киңдер... Илләребез... авылларыбыз... таянычыбыз берүк...

Мондый хәлдә тораташтай басып тору килешми иде, Хәнәфи шыпырт кына өйдән чыгып китү җаен карады.

Ләкин болдыр төбендә калдырылган брезент туфлиләрен киеп, апын-төпен капкага таба ун адым атларга өлгермәде — түти, өеннән атылып чыгып, аваз салды:

— Инде китүең дәмени?

Аннары ул, болдырдан төшеп, якын ук килде. Аның җыерчыклы йөзенә янә нурлы мөлаемлык кайткан иде.

— Җомышыңны да әйтмәдең... Әртәми дусыңа ниләр диим соң инде?

Урамда, капка төбендә басынкы гына гөрелдәп тракторы кәтә, монда күзләрен челт-мелт йомгалап түти җавап көтә.

— Ни дип... Күп итеп сәлам ирештерерсең. Аннары ни...— Хәнәфи йодрыгын төйнәп, югары чөйде.— Җимерттереп эшләсен инде ҚамАЗ дигәннәрендә дә! Кәртечкәсен тагын да гәҗитләрдә бастырырдай иттереп!

— И тәмле дә инде телләрең! Үзеңә дә ходай юлдаш булсын берүк!

Тракторның зыңгырдап әйләнгән чылбырында тузан өермәсе бөтерелә.

Ян-якларда иген басулары. Юк, иген үк түгел әле: борын гына төрткән. Урыны-урыны белән ярыйсы гына куерып чыккан — мондый төшләр җәеп салган күгелҗем-яшькелт ашъяулык сыман, урыны-урыны белән ялап алгандай шәрә... Югыйсә, язын дымны һәйбәт каплатканнар иде, чәчүне дә алай сузмадылар, тиз һәм кызу тота белделәр... Их, җирдәге дым, күктәге явым!

Әнә анда ике-өч чакрымга сузылган үр кашында биек тирәкләр астында яшеллеккә күмелеп Чуар авылы утыра. Җыйнак һәм аулак авыл. Кибетчесе дә ипле хатын. Кибетенең бер почмагында бүгенге көн, менә бу сәгатьләр өчен үтә затлы теге нәмәрсәне яшереп калдырмыйча тормагандыр әле. Авылда бригадир булып йөргән Сәгыйть тә хәлгә керүчән, йомшак күңелле бәндә. Бакча артларыннан ук юкә урманы, куе чикләвек куаклары ялганып китә; тәп корып ятардай яшел аланлыклар адым саен анда. Табигатьнең рәхәт куеннары...

Таза, нык куллар идарә рычагларын кысып тотуын белде, әфлисун төсендәге трактор Чуар авылына таба турылайга яман гүелди-дыңгырдый юл яруын белде.

«Ходай юлдаш булсын инде үзеңә дә!» — дип изге теләкләр тели-тели, капка төбендә яулык очын бөтергәләп, йөзендәге бар җыерчыклары белән балкып калган иде Үтәдемнең игелекле бер җаны.

Такыр басу юлы сулга Гәрдәле авылына таба каерылды. Хәнәфи исә һаман турыга тотты. Сөрелеп чәчелгән җир өслтә Чуарга таба кемнәрдер эз салырга өлгергән иде. Ләкин тракторы әллә ни алдыра алмады, үргә таба сулышы капкандай, кинәт тукталып калды.

Басу өсләрендә дым дулкыннары биешә. Көяшны зәңгәр болыт кисәге каплаган. Һава бөркү. Маңгаенда янә бөрчек-бөрчек тир. Бу сөзәк үр битләрендә җир көрәнсу-соргылт төстә. Хәнәфи туфракны учына алып кысып караган иде, кысканы тузанга әверелеп, бармак арасыннан коелды да бетте...

Карашы белән янә дөньяны иңләде. Ужымнар әйбәт сыман үзе: әнә Калмаш белән Буравай тарафларында

яшел хәтфәләре зәңгәр офыкларга тикле сузыла. Бик тә белеп әйткәннәр: яшел төстән җанга рәхәт инә...

Тукта, ни дип бу кадәр тилемсәләнде соң әле ул? Чуар авылы, имеш... Кибетче... Бригадир Сәгыйть... Табигатьнең рәхәт кочагы тагы...

Үз авылы, үз өе барында! Әйе, хатыны Рәсүлә алай кире беткәннәрдән түгел, кар базына төшереп яшергән нәмәрсәкәен чыгармый калмас иде лә бу хәлләрдә... Тик менә кем белән гәпләр корырга да, кайсы белән киңәш-табыш итешеп, каткан җаннарны беркадәр эретеп җибәрергә? Бәлкем, түзәргәдер, берни дә кирәкмәстер?

Сул тарафта бер-ике чакрымда гына тирән чокырга сыенып Гәрдәле авылы утыра. Юк, анда да сугылырга ярамас. Тирән ерганакларны тегә баштан ук әйләнеп үтәсе дә әнә яшел ужым хәтфәләнгән үр сыртына менеп китәсе. Анда менеп чаптырса, үз авылы Әҗер дә уч төбендәге шикелле күренер, «Йолдыз» совхозының үзәк авылы.

Кайтып җиткәч, тракторы тынып калыр, үзе исә... үзе...

Хәнәфи дер-дер калтырап торган корыч айгыры янына килеп, кулын аның кайнар калаена куйды, тузанын сыпырды, сыйпагандай иттерде.

3

Совхоз директоры Таиповның болай да төксе йөзе бөтенләй караңгыланып китте:

— Син нәрсә, берәр котырган эт тешләдеме әллә үзеңне?

— Чынлап әйтәм... Басуда йөрердәй рәтем калмады бүтән. Зинһар, дим, Яхъя Таипыч, җибәр син мине, аер трактордан.— Хәнәфи бик сизә иде: бу минутта директор калын кашларын усал җыерган да коңгырт күзләре белән аны телемнәргә кискәли. Шул сәбәпле тракторчы агай үз карашын ялтыравык шома өстәлгә салган таза кулларыннан аерып алмаска тырышты.— Соң, былтыр ук әле үзең әйткән идең бит: «Механик итеп куярга синнән дә кулай кеше табуы кыен булыр»,— дип...

— Былтыр, имеш, былтыр... Былтыр без колхоз идек, быел совхоз булдык.

— Беләм инде. Унбер авылдан дүрткә калдырдылар. Бөтенләй бәләкәйләндек... И шулай да синең урын алмашынмады, һаман да син «баш» бит безгә, Яхъя Таипыч...

— Ә тракторыңа кемне утыртырга боерасың? Үзем утырыйммы?

— Минем трактор гөрләтеп эшли әле. Иясе тиз табылыр иде. Анда әллә ничә комбайнны ремонтлап бетерәсе бар, ди, бүтәне тагы... Минем бит кул теләсә нинди техникага ябышырдай — үзең беләсең... Ә басуда эш кыйрата алмам инде. Чынлап әйтәм, тәмам җан кыйнала!

— Минем кыйналмыймыни? Ике мең гектардан артык җирләрең китсен дә... Җитмәсә, иң һәйбәт, иң уңдырышлы җирләр!

Хәнәфи, баш калкытып, түргә таба караш ташламыйча булдыра алмады. Юк, директор йөзендә усал ярсыну беленми иде, ул артык алҗыган кыяфәттә күзләрен кыса төшкән дә сөзеп кенә карый сыман иде.

— Ә үзең соң былтыр Казанга актив җыелышына баргач, КамАЗны котлап, ай-һай матур да, шома да сүзләр сөйләгәнсең ич.

— Иштең! Аны гәҗитләр шулай матурлап та, шомартып та язды.— Директорның тавышы капыл чатнап китте, сыкранулы яңгырады.— Мин анда... мин... йөрәгемне уч төбемдә дерелдәтеп сөйләдем... Үзем генә беләм!

Кабинетта бермәлгә урнашкан тынлыкны янә Хәнәфи бозды:

— Анысы, бәлкем, шулайдыр да... Тик мин әллә кая олакмыйм лабаса, үзем өчен дә, совхоз өчен дә кулайрак эшкә күчерүне генә сорыйм бит.

— Кирәк чагында тракторына да утырырсың, җиң сызганып ремонт ишесенә дә тотынырсың. Теләсә нинди техникага! Бүгенге шартларыбыз шулай.

— Ай-һай ла...

— Ай-һайлашмыйк... Ә минем үземә бик ансаттыр, дисеңме? — Таиповның тавышы йомшара төште, ул да үз зарын сиздермичә булдыра алмады.— Бу чәчләр тиккә генә коелып беткәндер дисеңме? Теге чактагы кушылуэреләнүләр, гигант колхозга әверелүләр, инде менә киредән кайтып, кабат бүлешү, кабат вагаюлар... Мең дә бер төрле мәшәкать!

— Мин бик аңлыйм да бит...

— Көн саен диярлек Чаллыга киңәшмәгә чакыртып торалар, сүзләре һаман да бер: «Исемегез «Йолдыз», моңа тикле сынатмадыгыз, инде хәзер шәһәр яны тирәли зонада да...— Таипов чатнатып, нәкъ менә шулай «Шәһәр яны тирәли»,— диде.— Сез иң беренче ялтырап-бал-

кып китәргә тиешлесез», диләр... Менә синең эше үрнәк механизаторларга таянмый, кемгә таяныйм мин бүгенгесе көнне, ә? Шушы коры пеләшем белән генә совхозны балкыттырыйммы?

— Минем үрнәк булырдай чакларым үтте инде, күрәмсең!

— Үтми торсын! Әле тагы да текәрәк сыртлар яулыйсы бар синең дә, минем дә... Барчабызның да! Бусы бер... Аннан килеп, әйт әле. Юк, күземә туры карап әйт: нишләп әле син бар семьяң белән совхоз эшенә аяк чалырга тотындың? Сүз куешып баш күтәрүегезме?

Таипов инде аягүрә баскан һәм, ике кулы белән дә шома өстәл читенә таянган хәлдә, каршысында жилкә жыергалап утырган адәмне үткер күзләре белән чынчынлап бораулаларга керешкән иде. Карашлары очрашкач, Хәнәфинең кара төкләр баскан ач яңагы тартышып куйды.

— Ниткән аяк чалу, ниткән баш күтәрү булсын, ди тагы?

— Иң әүвәл өлкән улың Айдаш баш калкытты. Кирелеген жиңә алмадым. Кыш иде шул... Язын менә мондый дуамал хәлләр туасын сизгән булсаммы? Муенына муенчак элеп, тракторына бәйләп куяр идем, билләһи. Кече улың Рәмзи армия хезмәтендә. Ярар, анысына сүз әйтерлегем юк: кирәкле хезмәттә, изге эштә — ил иминлеген саклый. Ә менә син үзең, моның өстенә Вәсимең тагы?!

— Ә Вәсимгә ни булган? Ул аллага шөкер дигәндәй...

— Шөкер булса ла икән! Менә күр, күзләреңне зур ачып укы! — Директор юка гына папкадан бер бит кәгазь кисәген алып аны тракторчы агайга таба очырды.— Гариза... Иртән кертте...

— Менә сиңа...

— Аның Чаллыдагы комсомолын әйтер идем, каһәре. Вәсимең инде жайлап-майлап та кайткан — анда әшнәләре аз түгел, ахры... Әллә синең белән киңәшмәгән дә идеме?

Таипов аңа кайчан һәм ничек китереп сугасын алдан ук чамалап куйган иде, ахрысы, Хәнәфи бөтенләй бөрешеп калгандай булды, тавышы шыңшынып чыкты:

— Май бәйрәме алдыннан бер жаскынып алган иде үзе, аннан соң ләм-мим...

— Ә хәзер әнә, бәрәңгене генә утыртып бетерим, ди. Куалап чыгардым үзен, артына тибәрдәй булып... Алай-

сам, Хәнәфи туган, мин моны директор булып та, партком члены булып та әйтәм — сиңа партийный поручение шул: ул сыбызгыңны син...

— Мин партийный түгел. Аннары килеп, ул инде...

— Партийный булмасаң, атасы аның — фронтовик, алдынгы механизатор. Җитмәсә, үзеңне әле кайчан гына рабочком члены итеп тә сайлап куйдык.

— Вәсимнең үз акылы үзендә.

— Ни кылсаң кыл, әмма ул егетең моннан ары башны катырып, болай да сызлап торган чи ярага тоз сибеп, быжыкланып йөрмәсен! Ә үз хәлеңне бөтенләй оныт!

— Һай, ансат та соң?

Бу күңелсез тартышу тагын да күпме дәвам итәр иде, Таипов тирән иттереп бер сулыш алды да кырысрак рәвештә кырт кисәргә булды:

— Ярар, аңыштык кебек. Вакытың буш булса, бар әнә, булыш: авылга ике машинада ҚамАЗ төзүчеләр килеп төште, партком Садыйков белән авыл Советы Галимҗан аларны йорт саен таратып, урнаштырып йөри. Рабочком вәкиле буларак, хет аз-маз эш башлап җибәрүең булыр синең дә...

Хәнәфи урындыгын шыгырдатып кузгалган җиреннән теш аралый сыгып кына чыгарды:

— Икесенең дә җилкәләре калын, телләренә шайтан төкергән. Минсез дә җырып чыгарлар әле.

— Әлбәттә, җырып чыгарлар. Тик үзеңә кулайрак квартирантлар сайлап алыр идең, ичмаса. Соңыннан җәфасын күрмәгәең, дим!..

Кабинет ишегенең каты шапылдап ябылуыннан директор сискәнеп куйды: иртәнге якта улы шулай кылланган иде, инде хәзер кичке уңайда — этисе. Ә бит карап торырга үтә юаш һәм күндәм адәм кебек лә үзе... Һай, ишәеп китте әле бу араларда ишекне әнә шулай шапылдатып ябулар!..

4

Урамга чыккач, сулышын җайга салырга теләгәндәй, беравык тукталып торды.

Әнә югары очта бер машина күренә. Түбән очта еракта янә берәү — монысы шул арада Гыйльметдин тыкрыгына борылып күздән дә югалды. «Димәк, иң әүвәл олы урамнан башлаганнар икән».

«Таипов хаклы: безгә дә кертәсе итсәләр, юньлерәк адәмнәрне сайлап алмыйча һич ярамас...»

Ләкин абзаң бу теләк, бу уе белән дә соңгарган булып чыкты.

Урам белән төшеп, үз ихатасына аяк басуга, ни күрсен: ишегалды түрендә, ян бакча баганасына эленгән юынгыч янында ике ят адәм. Берсе — сылу гына гәүдәле, күпереп торган чәчле яшьрәк кенә хатын — җилкә аша сөлге элгән; икенчесе билгә тикле чишенеп аткан да, яртылаш бөгелгән көенчә, таза гәүдәсенә салкын су сиптерә-сиптерә ах-ух килә...

«Менә сиңа, апаем, кайнар пәрәмәч!..»

Ул арада шул ук янбакчадан, бер учма яшь суган кыягы тотып, хатыны Рәсүлә килеп чыкты. Өстендә әйбәткә кия торган эре ак борчаклы яшел күлмәк, үзенең бит урталары янып пешкән. Тегеләр ягына күз атаата, хәлне аңлатмакчы булды:

— Өебез иркен, барыбер читтә калдырмаслар ие... Чаллының үзендә өйләргә шыплап тутырганнар, ди инде. Хәзер авылларга тараталар, ди.

— Беләм: Үтәдемне дә әллә кайчан ҚамАЗ явы басқан әнә.

— Ирле-хатынлы булсын, дидем инде. Хәзерге җәшләрне беләсең бит: арада әллә ниткәннәре бардыр.

— Ярар, үзең сайлап әйбәт иткәнсең. Бездән генә калмас — илебез-җиребез белән күтәрәсе хәлләр бит. Ни... Вәсим кайтмадымы әле?

— Төш турында тамак туйдырып киткәннән соң күренгәне җук әле. Бәрәңгедә үтә дә каты тоталар, ахрысы.

— Тотмыйча ярамыйдыр анысы... Берәр сүз сөйләмәдеме соң?

— Җук... Ә нигә? — Рәсүлә шикле сәерсенү аша иренең күзләренә тутырып карады.

— Болай гына... Ярар, бар, өстәлеңне кара. Юлдан алҗып килгән кешеләрне көттерердәй итмә. Рәмилә өйдә булса, әйт: су салып торырга чыксын. Үземә дә бил тиңентен юынмыйча булмас. Әллә нигә бүген бөтенләй тирләп беттем.

— Көне бигрәкләр дә бөркү шул.

Тегендәгеләр йорт хуҗасының кайтып керүен, әлбәттә, шәйләгәннәр иде инде. Ир дигәне ашык-пошык кына сөртенгәләде дә, майкасын, күлмәгән киеп алгач, хатынын ияртеп, болай таба атлады. Икесе дә кызгылт чырайлы, җитен чәчле, җитмәсә тагы, зәп-зәңгәр күз-

ләләр — тәмам абыйлы-сеңелле диярлегең бар. Каушый төшкәнгәдер инде, уңайсыз гына елмаеп күрештеләр.

— Крутько... Аркадий... Ә бу минем җәмәгатем Мила... Людмила ягъни... Сез, зинһар инде, безне... ни... менә болай көтмәгәндә генә күктән ишелеп төшкән өчен...

— Төшсәгез, бик әйбәт! Сыярбыз. Дөньялар киң безнең! — дип кулларын киң җәеп җибәрде хуҗа кеше.

— Рәхмәт инде сезгә! — дип пышылдады яшь хатын һәм, тагын да мөлаемланыбрак, тигез ак тешләрен елтыратты.

Ә Хәнәфи башын кыңгыр салды да карашы белән аларны янә бер иңләп алды:

— Тәк... кайсы якларның җиле китереп ташлады дип белик инде сезне, дускайлар?

— Белоруссиядән без... Витебск каласы төбеннән, ишеткәнегез бармы?

— Ишетмәгәннәр кая! Сугыш утында үзем үткән яклардан икән лә! Әле сөйләшәсе сүзләребез буласы икән. Ярар, хуҗа апагызны зарыктырмыйк. Юл кешесенең хәлләрен бик беләм мин. «Ризык капмый — җан эреми», дип тә әйтәләр шикелле.

Кунаклар өйгә кереп китүгә, аннан кызы Рәмилә килеп чыкты. Иң төпчекләре. Әмма буй җиткезеп, менә-менә пешеп өлгерәм инде дигән чагы. Ярыйсы гына кыланчык, шактый ук җитез һәм үтә телчән кызый, баскычтан ук сайрый-сайрый төште:

— Әти, дим, әти... Сиңа әнкәй әйтмәгән дә икән әле: бүген Рәмзи абыйдан тагын бер хат килде.

— Шулаймы? Йә, ниләр язган соң солдат абыең? Кайчанрак кайтып төшәм дигән?

— Кайту сиңа! «Бераз вакытка тоткарланырга туры килә әле» дигән.

— Ә? Нишләп икән? Приказ чыкканына әллә кайчан бит инде...— Ата кешенең кашлары капыл җыерылды, аның сулышы ук капты бугай.— Хезмәтендә бер-бер хәл китереп чыгарды микән әллә?

— Ник алай булсын? «Полк командиры үтенде» дигән... Яшь солдатларны бераз өйрәтергә кирәк булгандыр, бәлкем...

— Әһе, бәлкем шулайдыр. Их, бик кирәк чагы иде шул монда үзебездә дә, самый кирәк чагы. Ярар, хәерлегә юрыйк. Минзәләдә кунак булып ятмый, солдат хезмәте диләр шул аны.

Хәнәфи, «ходай китереп ташлаган» кунагы шикелле үк, бил тиңентен чишенеп атты. Калай чапчактагы су әллә ни талыгырга өлгермәгән икән, Рәмилә беренче чүмечне коюга ук Хәнәфинең кызган тәне чымырдап китте:

— Син чамалабрак, кызый...— Тузанга күмелеп, каралып беткән бит-муеннарын сабынлаган гына иде, янә ачуланып эндәште: — Син нәрсә, баскан җиреңдә йокыга киттең мәллә? Сип!

— И, эти! — дип чәрелдәде Рәмилә, тулы бер чүмечне берьюлы коеп.— Әнә урамнан тагын бер машина узды. Җәяүлеләре гитара чирттереп, әллә нинди җыр җырлап китте... Кемнәргә урнаштырырлар микән?

— Эшеңне бел дим, чәтертек!.. Кемгә кертәсен синнән сорамаслар.

Рәмилә этисенең түбән иелгән шәрә гәүдәсенә суны коя торды, үзе һаман сөйләнүендә булды:

— Их, бер генә ел алдан туган булсам икән лә! Һич югы, алты яшьтән үк мәктәпкә барып кергән булсам икән!

— Нишләр идең, сыбызгы?

— Мин дә менә унны бетереп ятар идем. Анда безнең унынчылар бөтенләй шашкан «КамАЗ» дип... Бигрәк тә Чуарныкылар белән Үтәдемнекеләр... Минем дә, дим, ичмаса, дүрт ягым кыйбла булыр иде. Их, бер ел ми черетәселәр бар шул әле!

— Кыйбла сиңа! Тукта, син әледән үк киртә буе сикерергә ябышмадыңмы, кызый?

— Сикерсәм соң?.. Мәктәп ни ул? Теләсәң кая очып китәр өчен старт мәйданы гына... Син, әткәй, теге заманда үлеп, бүген терелгән хәзрәт кебек кыланасың...

— Кыланырсың да сезнең белән... Кая, китер сөлгене!

Рәмилә кулындагы алюмин чүмечне чапчак төбенә шапылдатып төшерде дә, этисенең иңбашына сөлге элгәч, ятьрәк урамга чыгып сызды.

«Дөньяның асты өскә килгән диярсең, билләһи,— дип уйланды Хәнәфи, сөлге белән сөртенә-ышкына.— Чын әгәр: әллә кайчан түгел, былтыр гына үлеп, бүген терелсәң дә, тәмам акылыңнан шашар идең, анңары инде кабаттан җан бирүең ихтимал бүгенгесе хәлләргә...»

— Әтисе дим, бигрәк әкрен кыймылдыйсың ла! Кунакларны бу хәтле көттермәсәң соң...

Рәсүлә кулына зур гына табак белән кашык тоткан көе, ишегалдын кыек кистереп, нәүрәп ягына бара иде. Хәнәфи бауда эленеп торган чиста ак күлмәкне тартып алды да хатынына таба атлады:

— Салкын катык шәп инде ул, энисе. Әмма ни... бер уңайдан аннан теге зәмзәм суын да алып менмисеңме, дим? Коры кашык авыз ерта, беләсең ич.

— Анда өстәл түрендә «биш җолдызлысы» кукраеп утыра, кунагың буш кул белән килмәгән. Сине көтә...— Рәсүлә тукталган җирендә иренә күз чекрәйтеп карады.— Соң үзең «ураза» дигән иең ләбаса... Әллә бозмыйсыңмы, картым?

— Юк, энисе, «ураза»ны бозмыйча һич ярамый миңа мондыен көнне...

5

Кичкә таба көн сүрелә төште. Әмма урам-тыкрыкларга көтү каршыларга чыккан халыкның телендә сүз бер тирәдәрәк әйләнде:

— Боерган булса, җаумый калмас... Бу тикле бөркүләнеп торсын да сиңа...

— Зират өстендәге карга-чәүкә өерен күрегез сез. Тикмәгә түгелдер шашынулары.

— Исен сизәмсез? Әлмәт, Зәй җакларында шәпләп коя да бугай инде.

Әҗер урамнарында, тыкрык чатларында шулай диештеләр. Бер Әҗердә, бер Чаллы төбәгендә генә микән? Җәйгә чыктың исә, шулай инде: йөзләгән-меңләгән авылларда күзләр офык читләрен иңли, игенче җанында өмет чаткылары дөрли...

Көтү куптарган вак тузан җиргә кире куна алмыйча байтак вакыт һавада эленеп торды. Акрынлап абзар-кураларда сыер мөгрәүләре, кәҗә-сарык бәэлдәүләре тына төште.

Ихаталарда яңа сауган сөт исләре таралды.

Һәм менә шул мәлне, кояш кызарып баерга торганда. ниһаять, күренде...

Көньяк-көнбатыш тарафларны бөтенләй иңләп килә. Баштарак өне сизелмәгән дә иде, кичке эңгерне тизрәк куертырга ашыга кебек кенә иде.

Ләкин әнә инде ишелеп-ишелеп дөбердәве буйдан-буйга таралып китте, моңа чатнап-чытырдап алулар ялганды, яшен чыбыркылары ялт та йолт күк читен кискәләде.

Өметләр дөрләгән җаннарга шик-пошаман да инде калмады:

— Һай, берүк бәрәкәте белән генә килә күрсен инде! Бу араларда артыгын кыздырды шул. Давыл булмагае.

— Түгелдер, түгелдер... Җирне туендырырга ашыгуыдыр, дөберди-җәшенли — мул игеннәр, кадерле икмәк булып килүедер...

Хәнәфи болдырның югарыгы баскычында япа-ялгызы утыра иде. Кунаклар хөрмәтенә киеп алган ак күлмәгенең изүе киң ачык, җиңнәре сызганулы, елтыр күзләрен исә актарылып-ишелеп килгән болыттан аерып ала алмассың. Гадәттә ул, бушрак сәгатьләр тия калса, кичләрен бер урам әйләнеп кайтыр, идарә тирәсенә сугылып, эш турында тегесен-бусын белешер иде. Бүген чыкмады. Күңеле тартмады. Яңгыр киләсен тап сизенгәндәй булды. Алар тормышында еш кына шулай бит инде: кичкырын менә дигән иттереп корган эш планнары да, төнен шәп кенә явымлап алса, иртәгесенгә бер тиенгә дә тормый...

Өйдә вак-төяк эшләрен төгәлләп, болдырга хатыны Рәсүлә дә чыгып утырды. Ул яшенле яңгырдан ярыйсы ук курка иде, шул сәбәпле юка толымлы чәч өемен дә, хәтта чигә чәчләрен дә бөтенләй яшереп, ак яулыгын кысыбрак бәйләп куйды.

— Бу КамАЗ төзүчеләрен әйтәм әле: аяклары җиңелдән, ахры. Тик үзләре генә...— Рәсүлә, иренең кабыргасына төртеп, верандага таба ишарә ясады.— Әнә бит тынһары да чыкмый. Бу хәтле дөбер-шатырны ишетмәскә...

Кунакларга урын-җирне верандада әзерләгәннәр иде. Тегеләр аны бик ошатты, шунда төпләнебрәк урнашырга да ниятләре юк түгел икәнлеген аермачык сиздерделәр. Кызлары Рәмилә көннәр җылыну белән ук, бу аулак һәм тыныч почмакны үзенеке итәргә өлгергән иде инде. Әмма кызый, нишләсен, кунаклар хакына күнсә дә күнде, күнмәсә дә күнде.

— Тәмам алҗыганнар, күрәмсең,— диде Хәнәфи.

— Ул Казан аэропортындагы хәлләр, ди. Җарый әле «Метеор»га баш тыга алдык, ди. Чаллыга килеп төшсәләр, кадрлар бүлегендәге тамаша, ди, тагы...

— Шул инде: юл газабы — гүр газабы...

Күк гөмбәзен күзләгән шәйгә Хәнәфи хатыны сүзен әнә шулай җупли торды, үзе күңеленнән улы Вәсимнең өйдән чыгуын көтүдә булды. Табын артында, тамагыннан ризык өзелмәсен дип, сүз кузгатмады кузгатуын.

Дөрес, улына ни әйтәсен ныклап уйлап та бетермәгән, әмма ипләп бер сөйләшмичә дә ярамый иде. Тегеләр абыйлы-сеңелле клубка чыгарга ниятләп маташтылар шикелле. Вәсимгә дә бу араларда аз эләкми, диванга сузылып ятып мәрткә китмәгән булса тагы...

Юк икән, менә күк йөзе чытырдап, бар дөнья ялтырап китүгә икесе дә бусага төбенә чыгып басты.

— Кая инде мондыйда? Күрмисезмени, ничек җабырылып килә? — дип аваз салды әниләре.

— Курыкма, әнкәй, күтәреп алып китмәс әле,— диде кызы гамьсез генә.— Клубта бүген шундый да кызыклы кино, ди.

— Электрын сүндереп куйсалар, булыр сиңа кино... Мондыен дәһшәттә...

— Бер сүндерсәләр, ике яндырырбыз! — диде Вәсим, эре генә тамак кыргалап, һәм шакы-шокы болдырдан төшә дә башлады.

Әмма шул минутта әтисе аның беләгеннән эләктереп алды.

— Сабыр ит әле, улым. Син ни... кыекламый-мыекламый әйт әле...

— Нәрсәне, әти?

— Нәрсәне, имеш... Без сиңа атамы-анамы? Киңәштабышка да ярамый башладыкмы инде әллә? Нигә дип син ул кәгазеңне туп-турылай директор Таипов өстәленә илтеп салдың? Синнән сорыйм?!

— Һе, киңәш-табыш итешергә...— Егет чак кына тотлыгып торды, сүз эзләп азапланды.— Соң... Әнә Айдаш абый сыптырганда бер генә дә җәелеп китмәгән идегез шул.

— Сезгә әйтмәсә дә, минем белән киңәште,— дип сүзгә кушылды Рәмилә.— Тимерне кызуында сукмыйча сиңа... Бик дөрес, абый!

— Кысылма, ичмаса, син, бытбылдык! — Хәнәфи улының беләген кысыбрак тотты.—Туган туфрагың лабаса! Үз совхозың! Аны ниндәен хәлләрдә калдырып китүеңне аз гына абайлыйсыңмы син?

— Таипов сүзләрен сөйлисең, әти. Үзең уйла, бар дөнья купканда, мин генә монда совхозда сөрсеп ятыйммы, ә? Менә бит үзебезнең авылга да кемнәр генә килеп төшмәде инде КамАЗ дип. Яшь чак — җегәрле чак — ике киләме соң?

— Бик дөрес, абый!

Бер тын ара Хәнәфи үзе сүз таба алмый азапланды.

— Ә директор сине кабинетыннан куып ук чыгарган икән. Ул да үзенчә хаклы бит.

Чатнап киткән яшен яктысында Вәсимнең, бер кулы белән күпереп торган чәчен йомарлаган килеш, иреннәрен усал җәеп җибәргәнлеге күренеп алды.

— Куса соң! Муеным сынса сынар, әмма ләкин мин үземнекеннән чигенмәм. Ә син, эти, зинһар, юлларыма киртә куеп азапланма, яме?!

— Син кит, бүтәннәр китсен, совхоз дигәнебез кулсыз-терәүсез калсынмы?

— Туктале, эти...— Вәсим җәһәт кенә чүгәләп, кайнар сулышын этисенә таба өреп җибәрде.— Теге елларны син үзең соң... унҗиде яшь тулар-тулмаста ук военкомат ишеген барып дөбердәткәнсең ич. Ә колхозда хәлләр хәл булган түгелме?

— Чагыштырдың: ул чакта сугыш иде. Ил өстенә афәт килгән заман иде.

— Ә бүген бернинди афәт тә юк, әҗәлгә дә барып керәсе түгел. Киресенчә!

— Ударный төзелеш, ударный! — дип янә чәрелдәде Рәмилә.— Их, мин дә бу елны унынчыда булсам ла икән!

Ата кеше тагын сүзсез калды, ыңгырашкандай авыр сулап куйды:

— Барыгыз, алайсам, барыгыз... Ике дөнья — бер морҗа ла сезгә...

Рәсүлә сүзгә катышмыйча, сулышын кысып кына утырган иде, ире белән икәүдән-икәү калгач, кулын аның иңбашына салды:

— Ул тикле ачыргаланмасана, этисе. Совхозда да хәлләр бер җайга төшми калмас әле. Җазганын күрербез, җазмаганы читләтеп үтәр.

— Анысы алай да бит...

Ә болыт инде болар башы өстендә үк актарыла-бөтерелә иде. Вәсим белән Рәмилә клубка барып җиткәндерме-юкмы, дуамал җил купты. Әллә ниләрне кузгатты, әллә ниләрне шапылдатты.

— Әтисе, дим, әйбәтләп җауса, җаңгыр суларын җыясы булыр. Иртәгә, дим, мунча җакмыйча ярамас. Кунаклар да, бөтен арыганлыкларын бетереп, бер кинәнгәнче чабынып чыгар, ичмаса.

— Җыярбыз. Түбәләрдән тузанны бер кат юып...

Хәнәфи сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, кинәт күк гөмбәзе яман чытырдап, зәһәр яктырып китте дә, шуның арты ук югары очта нидер дәһшәтле гөрселдәп куйды.

— Трансформаторны харап итте, ахры.

Беренче ябырылуы узгач, җил тына төште... Ләкин... давыл болыты кысыр булып чыкты. Болар өстенә килеп җиткәнче коясын коеп бетергән идеме, җиргә тамчы да яңгыр төшмәде...

Өметләр акланмады...

6

Бүген эштән иртәрәк кайттылар.

Рәмилә җиңелчә генә тамак ялгап алды да, җиң сызганып, өй җыештырырга, идән юарга кереште.

Бик тиз арада барын да ялт иттерде! Ишегалдында капкадан болдыр төбенә хәтле сузылып яткан сайгак такталарына тикле саф балавыздай елык-ялык булып калды.

Кайтып керүенә бер мактасын әле әнисе!

Эшен түгәрәкләгәч, мунча казанында калган җылымса су белән коенып чыкты, аның соңында, гәүдәсендә рәхәт җиңеллек тойган хәлдә, өйләренә кереп, олы яктагы трельяж каршысына утырды. Күрче, иреннәре бөтенләй кипшереп, ярылгалап беткән, ә муен-яңаклары исә тәмам чуен төсенә керә язган. Кыздырган кояш астында салам эшләпә генә чүп шул. Әллә кайбер иптәш кызлары шикеле, күз тирәләрен генә ачык калдырып, ак яулыкны бөтенләй урап йөрергә микән?

Тегендә ишегалдына кемдер керде. Атылып чыкса, үз бабасы Туры карт икән. Бабай чал төкләр баскан ияген сыйпаштыргалап, тамак кыргалый-кыргалый иң әүвәл исәнлек-саулык сораштык, аннары ян бакча коймасы кырыендагы эскәмиягә барып утырды. Утырды да кәкре бармакларын кәләпүшенә тидереп алды, боларның ихатасын күз карашы белән иңләп-буйлап чыкты.

— Тәртип! — диде, җыерчыклы йөзенә мөлаем нур йөгерде.— Әниең өйдә җукмы әллә, кызым?

— Юк, бабай, тагын Чаллыга күренергә киткән иде ул. Иртүк...

— Әһе... Җә, ничек ди соң?

— Беренче анализлары болай әйбәт кенә, ди. Соңгылары ни дияр тагы. Бу язны әни радикулитына алай зарланмады бит. Бавыры да рәтләнеп килә кебек.

— Рәтләнә генә күрсен...— Туры карт камзулының бер төймәсен ычкындырып, бик тә авыр сулап куйды.— Шул шикәр чөгендере генә харап итте үзен, шикәр чөгендере генә... Теге җылның авыр көзендә, дим. Болын

хәтле җирне бүлеп биргәннәр ие шул. Эш дигәндә җыртлачрак инде, артыгын җыртлач. Әниең тап үземә охшаган — суйган да куйган...

Бу минутта Рәмилә, ихтыярсыздан көлемсерәп, кулын йөзенә якынайтты.

— Әле ни... «Врачлар инвалидлыктан төшереп калдырсалар, ичмасам, кеше рәтендә эшкә җөрер ием»,— ди, куанычы эченә сыймый әниең.

— Берүк шулай була күрсен! Кеше рәтендә эшкә җөрү — иң беренче дәва инде ул... Ә син, кызым, үзең дә маладис инде: әнәең җугында аулакта әнә ничекләй җалт иттергәнсең ишегалларыгызны, ә?

Саплы ягына салам кыстырудан кызый эреп китә язды:

— Әле бушап калган чиләк-чапчакларны тутырып куясым бар. Анда инде тәмам түгәрәк буласы!

Сүзнең шушы рәвеш алуына бик канәгать булып, Туры карт ирексездән тамак кыргалап алды:

— Алай дигәнеңнән, кызым, ни бит... үземнең дә, самавыр куеп, чәйләр эчәргә чапчактагы тәмле суым корыган бит әле. Колонка суы, дим. Ә киленне, Тәзкия җиңгәңне, беләсең инде: фермасыннан кайта алмый, тәмамлай батты. Җитмәсә, Сабир да әллә кайда олагып йөри, чуерташ!

— Алайсам, хәзер гөрләтәм мин самоварны, бабай!

— И кызым-гөлием, рәхмәт инде тәмле сүзләреңә! Тик мин сиңа, үз өемдә самавыр гөжләтергә суым беткән, дим лә... Фатирант җегетләрем дә үлеп җарата ул колонка суын. Эшләреннән тирләп-пешеп кайтып төшүләренә: «Галәмәт бу!» — дип, чәйне чөмерәләр генә!

Аларның ишегалды почмагында үз коелары бар. Тегенди-мондыйга суны шуннан тоталар. Ә менә самоварга салырга... Һо, чәй өчен колонка суыннан да һәйбәтен, тәмлесен табып кара син бүгенгесе көнне! Бәла тик шунда: бабалары янындагы колонка эшләми. Алар яшәгән түбән урамда җиргә күмеп салынган торбалар, узган кышның зәһәр суыкларына чыдамыйча, шартлаган да куйган. Инде хәзер урамнарын астын-өскә китереп, актарып ташлаганнар, әмма эшләренең очы-кырые күренми кебек әле. Ә «Сабир-чуерташ» дигәне — бабайга гелән дә түшәк җылытучы үз оныгы — сөекле сөяге, тагы да нечкәртебрәк, картның үз теленә кайтарып әйтсәк, «нәсел ботагы», ә чынлыкта исә җилкуар бер җан кисәге. Әлбәттә, ул әллә кайда түгелдер, инеш буенда, су кереп күгелҗемләнгәч, кояшка корсак куеп ятудадыр.

— Траншейларга салырга җүнле торба табалмый җөдиләр шикелле. Аннан килеп, эшләрдәй кешеләре дә ай-һайрак шул,— дип сөйләнүендә булды карт.— Их, аптырамас иem, җегәр дә бөтенләй үк беткән түгел, шөкер, ике кулыма ике чиләк асып, сезнең җаннан балдай тәмле суыгызны үзем апкитәр генә иem дә... ни... кеше сүзеннән шүрлим шул, күгәрченем. Һай, нужаларга төшкән лә бу Туры карт, димәгәйләре...

— Қызгандырыргамы? Мин барындамы? И бабай! — Кыз аяк төбендәге бер таш кисәген тибеп читкә очыртты.— Соң, кыенмыни миңа чиләк-көянтә асып, ике тыкрык аша җил-җил барып кайтулары?

— Теге көндәгесе өчен дә бик рәхмәт инде! Саклап кына тоттым.

— Хәзер үк илтимме, әллә кичкә табанмы?

— Ничек тә җарар... Тукта, ул хәтле кабаланмыйк, кызым! Мин үз туксанымны тукып, әле сорашмадым да бит, тиле баш.— Бабай җыерчыкланып каткан бармакларын тез капкачында биеткәләп алды.— Үз хәлләрең ничекләйрәк соң, үз эшләрең? Тегендә, җәшелчәлектә, дим?

— Әйбәт. Тагы ике-өч көннән суган-кишер җирен әтмәлләп тә чыгарбыз.

— Аннары ни?

— Ялга таралышабыз. Қайсыбыз кая... Тик безнең үз авылдагыларга атна-ун көннән болынга китәсе, ди, әле. Печән җыймага. Бүтәннәр барса барыр, ә мин төкерәм... Әнә Гарапша абый үзе барсын, бик кирәксә!

— Менә сиңа... Болында алай сырт сындырырлык эшләр җуктыр ла!

— Управляющий булган, имеш, ә үзе... адәм мәсхәрәсе! Бүген чәйнәп ташлардай булдым үзен.

— Ник тагы? Олы кешенеме?

— Булса соң! Син, бабай, ишетмәгәч, берни белмисең. Бер заман суган җиренә Гарапша абый әллә каян гына килеп чыкты да безнең җитәкчебез Нургаян абыйны котырта башлады. «Син мине тыңла, туганай, ди. Мин яшелчәлектә эшләп караган кеше, бик әйбәт беләм хатын-кыз холкын, ди. Хатын-кызны аны иң әүвәл үзара яман да иттереп талаштырырга-ызгыштырырга кирәк, ди, аның соңында алар, бер-берсенә ләм-мим сүз катмыйча, көнләшү ачуыннан үлеп тырышырлар, ди. Син, туганай, болар белән дә шуны сынап кара әле — үкенмәссең»,— ди. Мин якындарак кына чүп утап азаплана

идем, барын да ишетеп тордым. Без нәрсә, котырган эт өереме әллә? Үзенең дә тетмәсен теттем аннары...

— Тетәрлеге дә булган шул ләгыйньнең.

Рәмилә башын түбән иде, тавышы кисәк сытылып чыкты:

— Ә ул миңа «ата кәҗә» диде... Авылда кушамат булып китсә...

— «Ата кәҗә» диме? Ах, иблис өшкереп, үте сытылган нәмәрсә! Очрасын гына, мин аны... мин аны...— Туры карт, утырган эскәмиясеннән авыр кубып, кулын кызга таба сузды.— Җарар, кызым, җебемә дә, чәпчемә дә пүчтәккә! Гарапша — бер, ә совхоз бөтенләй икенче нәрсә. Әнәтерә анда эшкә җөрергә кеше җитеп бетми, ди. Җәш чагың — үлмәссең! Ие, җомшарма диюләрем! Тик бүген, гөликәем, көянтә-чиләкләреңне онытa күрмә инде бу хәлләреңдә...

— Онытмам. Текер-текер артыңнан куып та җитәрмен әле, бабай.

Рәмилә, әлбәттә, әйткән сүзендә торды: бер көянтә илтте, икене илтте. Алдагы көннәрдә дә бу хәл кабатланды: кыз тәмле суның тамчысын да коймаска тырышып, зифа буй-сынын сыгылдыра-тирбәлдерә аскы урамга таба ике тыкрыкны буйлый торган булды. Кичке уңайда, көтү кайтып, тузаннар басылгач кына һәм авылга шау-шулы төзүчеләр өере — араларында бабаларындагы өч егетнең, бигрәк тә «шәп мыек»ның кайтуын чамалап кына...

Буйларсың да!

Һай, Туры бабасының өйалдында тулы чиләкләрне эмаль чапчакка «шәп мыек» — молдаван егете — бушатмаган булсачы, бушаткач, чем-кара күзләрен тутырып караган шәйгә, үзенең таза кулын Рәмиләнең иңбашына салмаган булсачы!

Һич көтмәгәндә, сүтелә-сүтелә тәгәрәп кенә китте лә күңел йомгагы!..

7

Учагы дөрли башлады. Төтене әлегә чыкмый, чыкса да туры күтәрелә шикелле. Аның, җиргә сарылып, таралуы соңрак булыр...

Бабасының капка төбендә, буш чиләк-көянтәсен иңнәренә аскан хәлендә, ашык-пошык кына сүз алышулар...

Клубта очрашулар...

Кинода аерым утырсалар да, тын урамнан бергә-бергә кайтулары... Үз өйләренә җитмәс борын, кызның капыл гына йөгереп китүләре һәм, капкадан кергәч, ян бакча баганасына сөялгән килеш, күз йомып торулары...

Шигәю-сагаюлар...

Юк, болар гына түгел. Кызык һәм үтә күңелле хәлләр дә тумый калмады — булды андый хәлләр!

Мондые да молдаван егете Женя Мындага турыдан-туры бәйле.

Беркөнне, өй пәрие юри бозган диярсең, телевизорлары күрсәтмәс булды. Ничек кенә боргычласалар да, ни тавышы чыкмады, ни сурәте калыкмады чәнчелгерененң.

— Берияләшсәң, ансыз бик тә күңелсез икән шул! — дип ухылдады әнисе Рәсүлә.— Бу кадәр сандыкны Чаллының үзенә хәтле үк өстерәргә туры килер микәнни?

Әлбәттә, Рәмзи абыйсы түзеп тә тормас, әллә нинди осталарга ялынып та йөрмәс иде. Җиңнәрен сызганып, үзе ябышыр, актарыныр-сүтәр, бәлкем, кодрәтеннән килсә, рәтли дә алыр иде. Ә мондагыларга — этисе белән ике абыйсына ни? Кая инде телевизор хәтле телевизорга орыну! Аларга машинаның эресе — трактор яисә комбайн, һич югы, мотоцикл ишесе булсын, муеннан майга батардае булсын! Андыен, дөрес, әйбәт өшкерә беләләр — үлгәненә дә җан кертәләр үзе. Ә өйнең иң түрендә кукраеп утырган нәрсәкәй — хикмәтлененң дә хикмәтлесе бит!

Беркөнне кич утырмага килгәч, Туры карт, боларның хәленә керергә теләп:

— Үз түбәм астында оста барында ни пычагыма чит албастыларга җалынырга, ди? «Шәп мыек»ны әйтәм мин. Келәткә утны да үзе кертте, «эһ» тә димәде. Әле коега электр насосы көйләмәкче. «Суга коендырыйм әле үзегезне!» ди, һе-һе... Инде килеп, мондыен да, шәт, булдырып булдырмастай итмәс. Чын әгәр: һөнәр иясе — куллар остасы! — дип гүелдәде.

Баш тарта алмаган егет. Килде ул молдаван сихерчесе.

Хәер, аңа кадәр хәлнең бүтән төрлесе дә булып алды. Өйләренә бер төсле сөрем тараткан кебегрәге...

Ул кичне Чаллыдан, мотоциклга атланып, Айдаш белән Вәсим абыйлары кайтып төшкән иде. Күчтәнәчкә бер букча болгар помидоры алып кайтканнар, бу елны кандай бакча җимешен әле тәмләп караганнары юк иде — табынга куярга бик шәп булды.

Егетләрнең кыяфәтләре ярыйсы ук җитди, сөйләшүләре дә эрегә тартым. Теге кайтуындагы шикелле, бусында да Вәсим үзенең эше турында:

— Әлегә тәртип! «Беларусь» җаныкайның, очып китәргә җыенган сымаграк иттереп, ике тәпиен ике якка җәеп салам да тотына иплe генә җир чокырга. Кирәк икән, күмеп тә, шомартып та китәм,— диде вәкарь белән генә.

Алар икесе дә бер фатирда Чаллыдагы күптәнге танышларында яшәп яталар иде. «Ни әйтәсең? Хуҗалар әйбәт, өйләре иркен — әлегә һич зарланырлык түгел. Ике сыңык егеткә ул хәтле ни кирәк?» Шушы уңайдан сүзгә саранрак Айдаш эчендәге бәләкәй генә серен дә чишмичә булдыра алмады:

— Миңа озакламый тулай торакта урын бирүләре ихтимал, фатирдан китәргә туры килмәгәе,— диде һәм каш астыннан гына барысына да берәм-берәм күз йөртеп чыкты.

Вәсим, башын артка каерып, авызын гына җәйде:

— Китсәң соң, аптыраганнар, ди. Миңа иркенрәк булыр.

— Тот капчыгыңны! Торгыздылар, ди, сине җапа-җалгызыңны, җаныңа бер тинтәген кертмичә,— диде әниләре аш-су әзерләгән җиреннән.

— Кызык та инде бу дөньялар! — дип сүзгә катышты әтиләре Хәнәфи, баш селеккәләп.— Чаллыга килеп төшкәннәрне безнең авыл җиренә китереп шыплыйлар, ә безнекеләр Чаллыга барып оялый. Әрле дә бирле чаптыралар бугай — машинаң чыдасын!

— Чаптырсалар соң... Заманаң өермә куптарса, шулай булмый ни! — диде Вәсим, таза, йөнтәс беләген өстәл читенә куеп.

— Чынлап та, ник үзебездә генә торып җатмаска! — диде әниләре Рәсүлә, мәсьәләне үзенә якынрак рәвештә үтә беркатлы аңлап.— Кул астында мотоциклыгыз бар, җилләр уйнатып кына җөрисе бит инде җугыйсә!

— Әйттең сүз,— диде Айдаш коры һәм саллы тавыш белән.— Көн дә саен авыл халкының күзенә арпа кылчыгы булып кадалыргамы?

— Һич ярамый! — дип нокта куйды Вәсим.

Әнә шулай ярыйсы ук эресымакландылар.

Ләкин, әниләре пешергән ризыктан авыз иткәч, бермәл өнсез тордылар. Аннары, итле бәрәңгене умырттырган чагында, кикрикләре тәмам шәлберәеп, беркадәр зар да сиздерделәр: коры-сары капкалап йөрүнең әллә ни

рәхәте юк икән, ә инде ашханәдә тамак ялгап чыксаң, көне буе сару кайнап үтерә, ди.

— Соң, өйдә ризык беткәнмени? Алып китегез дә үлегез пешереп ашагыз алайса,— диде әниләре.

— И, әни! — диде Вәсим, каш җимереп.— Вакыт бармы безнең? Мәшәкате тагы...

— Алайсам, кайный бирсен саруыгыз,— диде әтиләре.

Табыннан соң, тын алмага түр якка чыктылар. Менә шул чакны гына Айдаш әлегә кадәр яшереп торган хикмәтен күрсәтте: ул урындык артына элеп куйган пиджагының ике як куен кесәсеннән пачкасы-пачкасы белән акча чыгарып өстәлгә салды. Шыгырдап торган җыен унлыклар, егерме бишлекләр — бер өем! Өнсез калдылар.

— Каян бу? Ничек болай? — диде әниләре, ниһаять.

— Узган айныкы... Под расчет бирделәр... Төп-төгәл алты йөз дә алтмыш сум,— диде Айдаш, калын иреннәрен чак кына җәя төшеп.— Ә син кайгырма, әнкәй: авансқа алганыннан фатир өчен дә түләгән идем, әле торып торырга да җитәрлек... Бусы сезгә!

— Һай аллам! Бу тиклем... гомердә күрмәгәнне...— Әниләре утырган җиреннән капыл гына кузгалды да, өстәлгә кояш нурлары төшмәсен, ичмаса, дипме, әллә урамнан кеше күрмәсен дипме, тәрәзә пәрдәләрен тартып куйды.

Вәсимнең күзләре тәмам тасрайган иде, ул кулын күпереп торган чәч өеменә батырды:

— Күр, миңа сиздермәде дә астыртын... Болай булгач, миңа да «Беларусь» белән саубуллашырга туры килер, ахрысы. Әнә автоскреперда эшләргә берме, икеме айлык курс ачмакчылар, ди. Ул эштә дә әкәмәт шәп төшерәләр, ди.

— Котырган акчалардыр ла бу, котырган...— ди-ди, баш чайкаштыргалады әтиләре.— Хөкүмәтне савым сыер иттергәннәр икән алайсам бу зилзиләдә...

— Хәраммы әллә, талап алганмы әллә? Хәләл көчләрне түгеп ләбаса! — Айдаш, үпкә сиздергәндәй, ирен турсайтты.

— Кем көч түкми?

— Соң, улым,— дип ике арага керде әниләре,— бу кадәрене кемнәр... Удмуртиягә җәисә Пермь өлкәсенә калымга киткәннәр генә төшерсә төшерә торгандыр. Өченче җылны әнә Гарапшалар... сөйләгәннәр ие...

— Сурәтләрен гәҗиткә басалар, үзләренә карәп акча өләшәләр — эшләр пулный худта! — диде этиләре теш аралый гына.

— Бик дөрес, эти! — дип урындык шыгырдатты Вәсим.— Сурәтеңне гәҗиттә дә бассыннар, каерып акчасын да ал — вәт булырсың егет бүгенгесе көнне!

— Җыеп куй! — диде Айдаш.

— Кайларга гына куйыйм соң?

— Син, әни, бигрәк инде,— дип шаркылдап көлеп җибәрде Вәсим.— Анда абай тырыша-тырмаша нормалар үтәп йөри. Икене-өчне үти, ә сез монда...

— Әллә нимс... үз исемеңә касса ачтырыйммы, улым? — Тик ни инде... авылда пышын-пышын сүз таралмагае.

Алар соңгы елларда акчага алай интегеп яшәмәгәннәр иде үзе. Ләкин моңа чаклы өйләренә шушы кадәр акчаның берьюлы кайтып кергәне дә юк иде. Үткән айларда Айдаш алган хезмәт хакының зуррак өлешен шушылай әнисенә тоттыргалаган, әмма иң зур дигәне дә, май аендагысы да, өч йөз сумнан артык түгел иде. Әле анысына да исләре киткән иде. Нәкъ менә шул чакны Вәсимнең, күзләре майланып, авылдан таярга җене котыра башлады да инде...

Шыгырдап торган акча өеме өстәл уртасында ята бирде, һәркайсының күз карашы аңа орынып-орынып алгалaса да, кагылучы булмады. Кагылырга сәер геңә түгел, ничектер куркыныч та кебек иде...

Этиләре, майлар сеңүдән каралып беткән юан бармакларын куе төкләр баскан иягеннән кубарып ала алмыйча, һаман да баш чайкавын гына белде:

— Аның нормалары да котыргандыр... котырган башлар куядыр. Соң, мин норма үтәмичә йөримме? Таң тишегеннән ябышып, кояш баеганчы лабаса! Ә шулай да җәйнең җәй буена алганым шушыңарга туламы икән?

— И, эти, сөенер урынга тиккә бәйләнмәсәнә! — диде Вәсим, тавышын шактый корыга борып.— Син җир сөрүдә, иген игүдә... Ә тегендә — зур төзелеш! Җитмәсә, ударный!

— Дәүләт бүтәнме әллә?

— Җиткәндер... Куанырга язган булсын! — диде әниләре.— Әнә ишектә кемдер бар... Рәмилә, дим!

Ана кеше өстәлдәге акчаны ялт кына чуар алъяпкычы итәгенә сыпырып төшерде дә чаршау артына ян бүлмәгә шылды.

Кем дисәләр, ишек төбендә үзләре чакырткан Женя Мында икән. Бусаганы кыюсыз гына атлап үтте дә чак кына көлемсери төшеп исәнләште.

Рәмилә җиңел сулап куйды. Аның йөзе шундук нурга күмелде — күләгәдән кояш яктысына чыктымыни!

Айдаш белән Вәсим дә, егетнең кем икәнлеген аңлап алгач, авыз тутырып елмаештылар.

— Төкле аякларың белән! — диде Хәнәфи үзе, кулларын киң җәеп, һәм яшь останы түр якка үтәргә дәште.

Айдаш белән Вәсимгә Чаллы тарафына китеп барырга вакыт җиткән иде инде. Әниләре ни кыстаса да, алар куныл калырга һич теләмәделәр: иртүк торып вахта машинасына чыгасылары бар, имеш. Алгы өйдә беравык эштер-өштер килгәч, алар әниләре шыплап тутырган букчаны асып, мотоциклларына атланып та алдылар...

Ул арада түр бүлмәдә Женя Мында сандык кадәр нәрсәкәйне, киң кочагына кысып, өстәлгә күчереп утыртырга өлгергән иде инде. Егет иң әүвәл инструкцияне битләп чыкты, схемасына күз текәп торды, аннары чигәсендәге чем-кара чәч бөтеркәсенә орынды:

— Мондыена минем борый тыккан юк иде әле... һм, карап карыйк алайсам...

Ул үзе белән кирәк-ярак коралларын да кыстырып килгән. Берара уйчанланып торгач, тотынды егет сүтәргә, актарынырга... Әллә нине чыж иттерде, пыж иттерде, әллә нине ычкындырды, кабаттан ялгады... Рәмилә, терсәкләренә таянган хәлдә муенын сузып, өстәл янында утыра иде, егет кул хәрәкәте уңаенда кызның иңенә орынып та алгалады, ә бермәлне, янә уйга таргач, ялгышып кына кулын аның йомшак беләгенә салды. Рәмилә шул мизгелдә гәүдәсен кымырҗытып дулкын йөгерүен тойды һәм, артка таба ялт кына күз төшереп алгач, кулын ятьрәк читкә тайпылдырды: әтисе белән әнисе күреп калса тагы... Егет исә, җиңелчә генә сызгырасызгыра, телевизор эченә иелде.

Әнә шулай ашыкмыйча, ипле генә «өшкерә» торгач, яшь оста менә, ниһаять, телевизор шнурын стабилизаторга тоташтырды. Чак кына көтүләренә экран яктырып китте, яман гыжлаган тавыш купты. Егет янә нәрсәгәдер орынган иде, тавыш саф та, тигез дә яңгырый башлады, һәм, син күр дә мин күр, экранда ап-ачык сурәт калыкты.

— һе-һе, урыс әйтмешли, шәп һөнәр иясеннән шүрли инде ул эш! — дип кеткелдәде әтиләре Хәнәфи.— Бик

рәхмәт инде! Болай булгач, фатирантлар белән бергәләп, ниһаять, күз чекрәйтеп утырабыз икән бу кичне.

Ул, мәле килсә, күңелен хушландырган тапшыруларны, аерата «Вакыт» программасын карамыйча калдырмый торган җаннардан иде.

Рәмиләнең күңеле куаныч белән тулды, шуның билгесе рәвешендә бит урталары алсуланып янды.

Ә егет үзе? Кулларын ышкыштырып торган җирендә, аның да какча яңаклары чокырайган иде.

Әниләре шул арада алгы якта җыйнак кына иттереп табын яңартырга да өлгергән икән инде.

Яшь оста, мөлаем елмаеп, кандай кызыл помидорны сайлап алды:

— Тансыкның да тансыгы... Әллә безнең якныкы инде?

— Болгарныкы,— диде Рәмиләнең әнисе.

Чыгып киткән чагында, Женя Мында сизелер-сизелмәс кенә иттереп Рәмиләгә күз кысты. «Күрдеңме инде: син дигәндә аякларым идәндә»,— дию булдымы, әллә: «Бүгенгә хуш, акыллым, әле очрашырбыз»,— дию идеме?

Һәй, күңелле булды Рәмиләгә!..

8

Мәләкәс елгасы аша күперне моңа хәтле Чаллы тирәләрендә булмаган-күренмәгән рәвештә тимер-бетоннан галәмәт киң, хәтәр биек иттереп салып яталар. Соңыннан, Түбән Кама ГЭСы төзелеп беткәч, шушы бәләкәй генә елга үзәнен, шактый эчкәрегә үтеп, су басып китәчәк, ди, күпер астыннан купшы катерлар, елгыр моторкалар выж-выж үтеп йөриячәк, ди...

Бу олы күпер белән байтак изаландылар. Инде азагына якынлашып киләләр төсле: Муса Җәлил проспекты килеп төртелгән башында биек иттереп дамба өелгән, анда бер бульдозер белән бер автогрейдер ком өемен тыгызлап һәм тигезләп дөбер-шатыр килә. Озакламастыр, күпер өстеннән әрле-бирле автомашиналар чабар, дыңгыр-даңгыр трамвай үтеп-сүтеп йөрер...

Түбәндә инеш аркылы җыйнак кына агач күпер салынган. Җиңелрәк автомашиналар вакытлыча шуннан үткәли. Аны ипле генә узгач, «Уазик» каршы яктагы текә генә ярны выжлатып менде дә, инде үрне алдым дигәндә генә, кисәк алгы тәгәрмәчләре белән ком өеменә чумды. Һе, олы күпернең бу башында да дамба өйдерер-

га керешкәннәр икән ләбаса! Якында гына буыла-буыла гүелдәгән бульдозерның кабина ишеге ачылып, аннан усал йөзле бер адәм күренде, һавада кара-кучкыл йодрыгын болгап алгач, бармагы белән чигә тирәсендә бөтергәләде: янәсе, күрмисезмени, кая кердегез, аңгыра башлар!..

— Үзләре, юлның ябылганлыгын күрсәтеп, бер билге дә куймаганнар, тфү! — дип сукранды шофер Дифгат.— Элеватор тавыннан гына китәсе калган, Яхъя абый...

Таипов эндәшмәде. Ниһаять, азаплана торгач, комны ерып чыга алдылар.

Кызыл Чаллы урамы тар, бетон юл белән әллә ни элдертмичә генә киттеләр. Уң кулда тезелешкән йортларның байтагына — йә капкасына, йә бура почмагына: «Өй бик тә ашыгыч сатыла!» — дип язылган фанер такталар кадакланган. Арада нык нигездә, матур кукраеп утырган өйләр бар, аударсаң, нибары утынга гына ярардайлары да юк түгел.

— Утырган нигезләрен ярып трамвай юлы үтәчәк бит, сатмый нишләсен? — диде Дифгат.

— Әйе, ни чарадан бичара,— дип баш какты Таипов.— Әнә ЗЯБ поселогы ягыннан трамвай юлын сузып та киләләр инде.

Орловка авылының ярыйсы ук бормаланып шактый озынга сузылган урамы тагы да таррак. Ләкин монда трамвай керми, шул сәбәпле урам да киңәйтелми, йортлар да сатылмый. Соры тузанга күмелешеп утыралар. Агач-куакларга тикле яшел төсләрен җуя язган.

Соры тузан, үтә вак ачы тузан...

Тар урамда машина ташкыны эчендә кысылган килеш бара торгач, ниһаять, авыл артта калды — киң автострадага чыктылар. Дифгат, күкрәген тутырып, иркен-иркен сулап куйды, слюда козырегын маңгаенда югарырак күтәрә төште. Хәзер инде, теләсәң, сулга каерыл да киң автострада белән Яңа шәһәргә таба элдерт, анда теләмәсәң, уңга борылып һәм әле күптән түгел генә корылган асфальт бөҗрадан әйләнә төшеп, ТЭЦ юлы белән сыптыр — ничек китсәң дә, барыбер «Йолдыз» совхозы тарафларына барып чыгарсың.

Ләкин Таипов, утырган җирендә алга таба тартыла төшеп, капыл гына:

— Бу әкәмәтне кистер дә, үзебезнең иске Минзәлә юлына борып, күпергә кер. Искесенә! — дип боерды.— Тирәкләр астында туктарсың!

Дифгат сәерсенү аша директорга күз ташлап алды, ләкин аны-моны әйтмәде.

Инде шактый таушала төшкән җыйнак кына таш күперне узгач, шундук сулга каерылып, инеш ярында кәпрәеп утырган карт тирәкләр ышыгында тукталдылар.

— Күләгәдә бер тын алыйк, ичмаса! — диде Таипов, җиргә аяк баскач, һәм, чуар кепкасын салып, кулъяулыгы белән такыр баш түбәсен, юан муен артларын сөртештергәләде. Кепкасын үз урынына ябыштырып куйгач, соргылт-зәңгәр күк гөмбәзеннән шәфкатьне белми кыздырган кояшка калын каш асларыннан усал иттереп күз кырыен тидергәләп алды.— Җир йөзен тәмуг итәргә җыена инде әллә?

Аннары ул тирәкләр күләгәсенә таба атлады, әмма кинәт кенә туктап калды һәм, кулларын ян-якларына чапкалап, ухылдап җибәрде:

— Ах, кадалсын да иде! Онытканбыз бит сугылырга, хәерсез...

— Кая, Яхъя абый? — диде Дифгат.

— Иске Чаллы аптегына инде... Бу эсседә баш миләре җебемиме соң! Син, энем, яшь кеше, иренмичә генә әйлән әле, булмаса. Мин шушында көтеп ятармын... Менә рецептлары... Бусы Мәрзия апаңа, кан басымын төшермәгә, ә бусы үземә... Йөрәк нервыларын тынычландырырга әкәмәт шәп нәмәрсә үзе, тик сирәк кайта, эт талагыры... Алай-болай тоткарлык туса, туп-туры мөдирләре Нина Андреевнага кер. «Яхъя Таипычка» дисәң, таптырмый калмас. Ипле хатын ул...

Дифгатнең буйсынмый чарасы юк, кире руль артына кереп утырды һәм менә инде выжлатып китеп тә барды. Таипов яр читенә килде, түбәнгә күз төшерде. «Битнебашны чылатып алганда, зыян итмәс иде»,— дигән уй килгән иде күңеленә, әмма аста карасу кучкыл үлән арасыннан ямьсез яшькелт төстә агар-акмас кына яткан өч бөртек суны күргәч, ниятеннән кире кайтты. Борылып тирәк ышыгына таба атлады. Һәм, кепкасын янә салып, йомшак үләнгә, күләгәгә кырын сузылып ятты.

Бая партиянең шәһәр комитетыннан чыгу белән үк, ул шушы карт тирәкләр ышыгында тын алуны күңеленә беркетеп куйган иде. Секретарь белән авыр һәм ачы гәпләшүдән соң кузгалган уй-хисләрне ничектер бер әрдәнәгә тезәсе, җанны ничектер тынычландырасы иде. Инде менә — хәерсезнең хәере дигәндәй — үз уйлары, үз хисләре белән япа-ялгызы калды...

Еш кына тукталгалар иде ул шушында. Яраткан урыны!

Кайчакларда Чаллыда үткәрелгән озын һәм ялыктыргыч киңәшмәләрдән соң алар, бериш председательләр, кайта-кайтышлый шушы тирәк төпләрендә янә бер тупланышыр иде. Әлбәттә инде, җәйләрен генә һәм көнеҗас килсә генә; әлбәттә инде, Чаллы кибетеннән кыстырып чыккан нәрсәләрен аулак төштә бушатыр өчен, бер кинәнеп-иркенәеп алыр өчен генә... Кызып-кызып бәхәс куертырлар, яисә салмак-ипле генә акыл сатарлар һәм, билгеле инде, киңәшмәдә алганнарын ансат кына җилгә очыртырлар яки, киресенчә, ишеткән киңәш-табыштан май сыгып азапланырлар иде. Аннары, сүзләренең сүрелмәячәген, әмма күк гөмбәзендә шәфәкъ нурларының тәмам сүнә баруын шәйләп, күңелләре ярыйсы ук хушланган хәлдә, һәркайсы үз юлы белән элдертер иде. Фараларның яктылык көлтәсенә төбәлгән килеш, иртәгесен, таң тишегеннән торып, янә җиң сызганырга кирәклеген уйлап... Хәзер монда хәл алмага берәрсе тукталгалый микән? Үткәндә-сүткәндә, күзгә ник бер чалынсалар икән!

Бүген ул япа-ялгызы. Инде колхоз председателе дә түгел... директор!

Ә күпер нәүмиз... Аңарчы килделе-киттеле агач күпер иде, ел саен изаланырлар иде. Ахырда, КамАЗ исе таралганчы биш-алты ел элек, шушысын таштан-бетоннан җиренә җиткереп салдылар.

«Безнең Минзәлә юллары өчен хәйран!» — диделәр. Ә хәзер...

Харап шәп автострада янәшәсендә бөтенләй мескен күренә. Инде машиналар да дыңгырдатмый, тимер култыксалары да кәкрәеп-ямьшәйгән, шул хәлендә мәңгелек йокыга таруыдыр... Күпне күрдең, күпкә чыдадың — рәхмәт сиңа, бәләкәй таш күпер!

Ә тирәкләр? Кәүсәләре тирән җыерчыкларда ермачланып беткән, биек ябалдашлары эчендә шәрә ботаклар да тырпайткан бу тирәкләр? Һай, аларның күргәнишеткәне!

Әүвәл, бик күп әүвәл, бу тирәләр чамасыз куркыныч урыннардан исәпләнгән: имеш, талавыдыр-бүтәнедер булып кына торгалаган. Бу хәтләсен бабайлар гына сөйләр иде. Ә соңга табарак ничектер олаучыларның яраткан урынына әверелеп киткән. Озын юллар йөргәндә агай-энеңне туктап ат эчертергә, үзеңә дә хәл җыярга дәшеп кенә торган купшы тирәкләр һәм алар-

ның тамырын юып аккан көмештәй саф су!.. Таипов үзе дә бик хәтерли: егет чагында, әле сугышка хәтле үк, алар көзгә табан элеваторга ашлык ташыганда, ә язларын, киресенчә, чәчүлек орлык алып кайтканда, олаулары белән туктамыйча һәм монда үзләренчә җенләнеп «сабантуй кормыйча» китәрләр идемени? Ә соңыннан?.. Сугыш чоры олаулары, сугыш беткәч шыгырдаганнары...

Әйе, бик күпне сөйләп бирерләр иде, тик телләре генә юк бу тирәкләрнең. Сүрелмәс моң-сагыш яисә чиксез дәрт-гайрәт сиздереп, шаулый гына беләләр җанлы-җансыз шаһитлар!

Ә хәзер менә бу сәгатьтә бөтенләй өнсез торалар, ник бер яфрак лепердәсен. Бүгенге дөньяның хәйран тамашасына таң калдылар микәнни?

Өнеңне җуймаслык та түгел шул: менә каршыңда гына әкияттәгедәй шоп-шома, тип-тигез һәм киң юлдан бихисап «җен арбалары» — автомобильләр әрле-бирле чабыша, аның белән янәшә шалдырт-шолдырт трамвай рельсларын сузып маташалар, арт тарафта исә, беркадәр ара үтсәң, зәңгәрле-яшелле вагоннар тезелешеп киткән — вакытлы поселок. Исеме матур гына: «Яшьлек»... Вагон өсләрендә сансыз антенна мыек тырпайткан. Айның аенда вагоннар ишәя, поселок киңәя, «мыеклар» тырпая бара... Болай таба чак кына кырыйдарак брезент палаткалар корылган, дөресе, корып бетереп киләләр. Болары инде, әлбәттә, кайнар канлы студентлар өере өчен... Казаннан килеп төшәрләрме, әллә Мәскәү яисә бүтән каладанмы?

Түбәннән, тирәк астыннан күренми, әмма югарыга, ябалдаш эченә үрмәләп менсәң, еракта соры-зәңгәр рәшә эченә күмелеп булса да, завод корпуслары да абайлана торгандыр. Җирдән капыл күтәрелеп, офык читләрен биләгән куе, кара-кучкыл чытырманлык булып шәйләнәдер...

Иң хәйраны, әлбәттә, Яңа кала үзе... Әнә ул чак кына калкынып торган кыр түрендә. Әллә ни ерак та түгел... Әзер йортлары инде дистәгә җиткәндер. Мәһабәт йорт-сарайлар биекләр, ап-аклар, кояш нурларында елык-ялык итәләр. Араларында һәм чит-читләрендә әллә ни-хәтле күтәрү краны озын һәм нәзек «муенын» һавага чөйгән.

Әле кайчан гына шаулап игеннәр үскән аулак басулар иде...

Яңа кала... Күзнең явы ни дә жаның ни — барын да үзенә суырып ала.

Таипов авыр һәм тирән иттереп сулап куйды. Кул аркасын маңгай җыерчыкларына тидереп алды... Шәһәр комитетында Низамов белән ике арада булган авыр гәп нәкъ менә шушы җем-җем иткән өр-яңа калага бәйле рәвештә куерып китте дә бит...

9

Күрешеп, беравык тегесе-бусы хакында сөйләшеп алгач, секретарь аңа:

— Гариза биргәнсез икән, Яхъя Таипыч... Каян сорыйсыз, Яңа каладанмы? — дип төбәлде.— Уңайсыз булмасмы?

— Әйе, Яңа каладан инде, Камил Фәтхиевич... Мөмкин булса,— дип ым какты Таипов, җылы гына елмаеп.— Ә ние уңайсыз булсын ди? Киресенчә, бик тә уңай: Яңа кала безнең совхозга нибары сигез-тугыз чакрым гына бит. Машинада ун минутлык юл. Аның юлларын да безнең тирәләргә табан бетон-асфальттан гына сузып яталар. Эшкә, дим, җил-җил элдертәсең генә...

— Анысына шикләнмим, элдертерсез... Соң, сезнең үз авылыгызда менә дигән, шыңгырдап торган йорт-курагыз бар шикелле — менә шул җәһәттән уңайсыз түгелме, дим? — Низамов аңа, үткен күзләрен кыса төшеп, сүзеп карый иде инде.— Бүген Чаллыда квартир мәсьәләсе ничегрәк икәнен чак кына абайлый торгансыздыр ич?

Таипов куырылды да калды. Дөрес, ул «йорт-кура» хакында һичшиксез сүз кузгалачагын алдан ук чамалаган һәм, әйтергә кирәк, үзенчә җавабын да әзерләп куйган иде. Ләкин секретарьның менә болай сорау бирү рәвеше, җитмәсә тавышының корылыгы, үткен күзләр белән кармалавы... Таипов үзе дә андый кармалауга бик остарганнардан югыйсә, әмма монда, үз башы ут астына эләккәч, сулышына тикле юньгә китерә алмый иза чикте...

Әйе, кайсы авылда кайсы колхоз председателе яки совхоз директоры үзенә шыңгырдап торган йорт өлгертмичә ятар, ди? Аны да булдырмаса, тавык көләр... Ниһаять, Таипов күңелендәгене йолыккалап булса да, яктыга чыгарып салырдай хәлгә килүен тойды:

— Соң, ни бит... Картаюга табан барабыз, Камил Фәтхиевич... Балалар таралышып бетте. Ә карчык инде,

Марзия апаң дигәнем, ничәмә еллар кан басымы белән интегә. Ул инде совхоз эшенә йөрү түгел, өй арасында да әчтем-печтем генә... Мондыен җаваплы чорда совхоз белән үлле-мәлле җитәкчелек итеп йөргәндә... ни шул... йорт тоту мәшәкатьләре тагы... аңлашыладыр ки...

Низамов саран гына елмайды:

— Ярар, Яхъя Таипыч, уйлашырбыз... Яңа кала әле салына гына башлады, алай да инде бик күпләр аңа күзләрен майландырып куйган. Әмма сезне, районда хөрмәт казанган кешене, ничек тә рәнҗетмәбез...

Әнә шулай: «Булды, бирәбез!» — дип тә, «Булмас... көтмәгез!» — дип тә кистермәде. Югыйсә, асылда бары да аның ихтыярына бәйле, аның сүзенә беркем дә колак салмый калмый. Бүгенге әкәмәт хәлләрдә Чаллы хәтле Чаллының, кем әйтмешли, идарә пультына бассын да сиңа!..

Секретарь ул арада сүзне капыл гына икенчегә борып:

— Сезгә шеф итеп ҚамАЗның үзен билгеләргә торабыз, ничек, ризамы соң? — дип сорап куйды.

Таиповның авызы ирексездән кыйшаеп китте, секретарь исә моны үзенчә юрады:

— Нәрсә, кулай түгелме? Ярый, теплицагызны коруда ҚамАЗ СМУы шактый сүлпәнлек күрсәтте — аның әле оешып кына килгән чагы, җитмәсә, үзегез дә шәп кенә абындыгыз, әле һаман эшләрнең очы-кырые күренми кебек, шулаймы? Әмма ҚамАЗ әкияттәге батыр сыман бит: ел үсәсен ай үсә, ай үсәсен көн үсә дигәндәй... Нишләп риза түгел?

— Риза булмаганнар кая?! — диде Таипов, кулларын угалаштырып.— Аңардагы көч-куәт... бүген үк булмаса, иртәгә...

— Әйе, әйе...

Гәп шул рәвешле ипле генә дәвам итәр иде кебек. Әмма Таипов ул минутта йомгакның капыл гына кире сүтелә башлаячагын һич абайламаган, ул аны бөтенләй уена да китермәгән иде.

— Димәк, шартлар ярыйсы, хәтта шәп диярлегең бар бу җәһәттән. Тик менә елның үтә яман килүе генә... Мондый корылыкны, шушылай көйдерүне, ай-һай ла, картлар хәтере сакласа гына...

— Алар бик хәтерли: егерме беренче елны гына шушылай булган. Мин дөньяга килгән елны... Карлар эрүгә бер бөртек яңгыр төшмәгән. Аннары инде ачлык котырган,— диде Таипов.

— Егерме беренче елга тиңлиләр, ә? — Низамовның да киң, ачык маңгаенда җыерчыклар ишәйде, бермәл тын торгач, уфылдап куйды.— Ә без монда шундый хәлләрдә дә сынатырга чамалыйбыз кебек... Әйтегезче, Яхъя Таипыч, нишләп сездә бер генә трактор су сиптерә? Ни хикмәттер, сугарулы көтүлек дигәнегезнең әлегә адәм карарлыгы юк; ни баганалары куелып бетмәгән, ни тимер чыбыклар сузылмаган, ни чәчелгән үләне...

— Шилнә суын ике төштән бәяргә исәп. Тик ПМК траншей казып, торба сузарга тотына алмый һаман...

— Ә ни өчен җир өсләтә генә сузмаска, шушы җәй өчен генә ичмаса, ә? Бүтәннәргә яраган сезгә килешмиме?

— Соң, Камил Фәхтиевич...

— Әллә, дим, былтыргы кәмит кабатланамы? Былтыр шулай землеустроитель белән баш агрономыгызны сугарулы көтүлек өчен басу карап йөргән җирләреннән куып кайтарган идегез ич. Имештер, сездән рөхсәт сорамаганнар, имештер, сезнең абруйны күрәләтә какшаталар... Ә бит барыбер алар күрсәткән басуларны бүлеп алгансыз түгелме? Әллә, дим, тагын мөгез чыгарып ятасызмы?

— Инде кызуларга исәп. Яшелчәлектә шикеллерәк иттереп...

Бүлмәдә галәмәт бөркү иде. Аның кояшы да, баш калкытуына, иң әүвәл секретарь бүлмәсен кыздырырга керешә икән... Таипов маңгаена бәреп чыккан бөрчек-бөрчек тирне кулъяулыгы белән сөртештереп азапланды, ә Низамов бер әләктереп алган кылны йолкуын белде:

— Шикләнәсе юк, кызуларсыз да.. Бу җәйне янә күктәге ходай үзе кисәтеп тора: «Миңа өметләнмәгез, торбаларыгызны ятьрәк сузыгыз да яңгырны үзегез сиптерегез, ди. Көннәрне юри коры тотам, дөньяны юри көйдерәм, сез адәмнәр кыймылдасын өчен!» — ди... Бер авылда бер председатель шулай дигән иде миңа. Төпле председатель! Сез, Яхъя Таипыч, теге атнада «Коммунизм» колхозында оештырылган семинарга нишләптер килмәдегез. Ә бит шәп үтте ул! Сугаруны һәйбәт көйләгәннәр. Көтүлекләре дә чын мәгънәсендә культуралы! Печәне тез тиңентен: куедыр, сусылдыр үзе. Күңелләр чын-чынлап хушланды! Районда бар булган колхоз председательләре, совхоз директорлары килгән иде, бериш бүтән специалистлар тагы. Сездән исә баш агроном Ризван Әүхәдиев кына күренде кебек. Ә үзегез? Файдасы тияр дип курыктыгызмы?

— Соң, ни... терлекләрнең җәйге лагере белән изаланган чак иде шул, Камил Фәтхиевич, бик теләсәм дә...

— Ә культуралы көтүлекләр терлекләр өчен түгелмени? Иртәгәге көнне уйласак, асылда азык проблемасы шул сугаруга килеп төртелә түгелме соң? Юк, Яхъя Таипыч, акланмыйк, зинһар! Сез, минемчә, бу нәрсәкәйгә кырынрак карыйсыз сыман. «Чү, ашыкмыйк, күршеләр бер эшләп күрсәтсен әле, аннары без карап карарбыз!» — дигән шикеллерәк... Хак әйтәмме?

Таиповның тәмам тиргә батып утыруын күреп, Низамов, ниһаять, өстәл түрендәге вентиляторның кнопкасына басты. Вентилятор җиңелчә гүелдәп һәм зәңгәр башын әле тегеләйгә, әле болайга боргалап, җиләс һава өрдерергә тотынды. Сулыш алуы чак кына иркенәйде. Ләкин тирне баса аламы ул? Монда бит тән генәме, җан үзе тир түгә ләбаса!

Низамов шоп-шома кырылган күгелҗем яңакларын сыйпаштыргалап, янә бер тын ара сүз катмыйча утырды, аннары баягыча, гәпне капыл гына бөтенләй бүтән юнәлешкә борып җибәрде:

— Инде менә Яңа поселок кору мәсьәләсе. Ишеттем, беренче казыкны каккансыз икән, шул уңайдан сарыклар суеп, шашлыклар кыздырып яткансыз... Табигать кочагында банкет, ә? «Металлургстрой» төзүчеләре белән чәкешә-чәкешә матур тостлар әйткәнсездер...

— Ырымы шул бит инде аның, Камил Фәтхиевич...

— Ярый, анысын хуп диик. Төзүчеләр вәгъдәләрендә торыр дип ышаныйк. Мин терлекчелек комплексына кагылмыйм әле. Сездә корыласы поселокның кәгазьгә төшкән проекты бармы? Әһә, бар икән. Сезнең шул проектны уртага куеп фикер алышканыгыз булдымы?

— Булмыйча... Кайдамы? Соң үзебездә инде... партком утырышында...

— «Син дә мин — Мөхәммәт Әмин» димәк! Шуннан ни?

— Соң... Әкәмәт, диләр, оҗмахның үзе буласы, диләр. Хөкүмәткә мең рәхмәтләр инде!

— Рәхмәтен рәхмәт... Проект болай минем үземә дә ошады. Ә гади халык ни дияр икән? Кичәге колхозчы крестьянның, бүгенге совхоз эшчесенең фикере, дим? Проектны кем әзерләгән? Гомерләрен шәһәрдә уздыручы кешеләр ләбаса! Алар авылның иркен тормышына күнеккән агай-эненең уй-теләкләрен һәрьяклап исәпкә алып бетерде микән?

— Алайсам ни... тагын фикер алышырга кирәгер... Кайда, клубтамы?

— Анысын инде үзегез карарсыз. Халык фикерен белми, ничек инде?

Таипов бик тә авыр иттереп сулап куйды.

Моңа кадәр ул төрле актив җыелышларында, шәһәр комитеты пленумнарында бер генә тапкыр катнашмады, Низамовны әллә ничә тыңлаганы бар, теле телгә йокмас, теләсә кемне авызына каратып, ышандыра белер, кайчагында кызып китеп, әмма чыгырыннан бик үк чыкмыйча, шәп кенә көйдерә дә белер. Былтыр бугай, әллә өченче ел ук микән, бермәлне шәһәр газетасы редакциясенә кергәч, анда эшләүче болай төпле генә, акыллы гына хатын: «Килер икән безгә дә шундый секретарь! Иплеләр сөйләшүе, әкәмәттер хәлгә керүчәнлеге!» — дип авыз суларын корыткан иде. Әмма Таиповның бериш житәкче агай-энедән: «Һо, аңа эләксәңме? Җаныңны үтәли күргәндәй, айкый да чыга! Йомшак сыйпап катыга да утырта, каты сугып екмыйча да калдыргалый. Кирәк тапса, култык астына кычыткан кыстырып җибәрергә дә күп сорамый...» — дигәнрәк сүзләрне дә ишеткәне булмады түгел. Таипов менә хәзер бер култык астында гынамы, бар гәүдәсе белән кычыткан пешерүен тойган бер хәлдә иң! Сулышыңны аның сулышына кушып утырулары бөтенләй үзгә икән шул!

— Сез бая совхозыгызны районда «күз өстендәге каш» — диебрәк әйткән идегез, хаклыкка якын сүзләр бу. Ләкин ул «каш»ның йолкынган яисә җәрәхәтләнгән булуын бер генә дә күрәсе килми шул. Ихлас! — Низамов зур күзләрен тутырып, янә бер карап алды.— Әллә ниме?

Юк, азакны фикерен әйтеп бетермәде, кинәт кенә өзде. Ул өстәлгә сузып салган сәгатенә әледән-әле күз төшергәли башлаган иде инде, мөгаен, берәр киңәшмәгә чумар вакыты килеп төртелгәндер. Таипов кергән чагында ук, алгы бүлмәдә берничәләп кеше көтеп утыруда иде.

— Ярый, Яхъя Таипыч, каты гына сүзләр байтак әйтелде инде, пожалуйста, рәнҗемичә генә, яме? Нишләмәк кирәк, «кыек сүз сукырайтыр, әмма туры сүзнең күз чыгарганы юк әле»,— диләр шикелле. Дөресме? Сез әле, шөкер, сездә җегәр дә, сәләт тә җитәрлек, без чынчынлап ышанабыз сезгә! Дарыгыз, кем әйтмешли, һаман да коры булсын! Тик, зинһар, мөгез чыгармыйча гына, Яхъя абый!

Низамов инде торып баскан һәм Таиповка табан кулын сузган иде. Аның йөзенә хәтта эчкерсез елмаю чалымы да чыккан сыман иде.

Әнә шул рәвешле элеп алды, селкеп салды. Таиповның моңа чаклы һичбер кайчан андыйга юлыкканы юк иде әле.

Азаккы сүзендә «Яхъя абый» диде — ихтирам күрсәтеп, үз итүеме? Кулны да каты һәм җылы иттереп кысты...

Ләкин аның: «Әллә ниме?» — дию... Нигә әйтеп бетермәде икән? Нигә күңелне шөбһә-пошаманга салды икән соң әле?

Югарыдан җил исеп үтте ахрысы, тирәк ябалдашындагы яфраклар лепердәшеп куйдылар. Ул да түгел, якында гына автомобиль гөрелтесе ишетелгәндәй булды.

Таипов кулларын баш астына куеп, йомшак үләндә чалкан ята иде, торып утырды. Дифгат түгел икән: иске таш күпергә кузовына өстәл-эскәмияләр төягән бер машина кереп бара иде. Брезент палаткаларга таба юл тотты... Озакламастыр, Дифгат тә аптекадан әйләнеп кайтырдыр.

Таипов күз карашын кабат Яңа кала тарафына юнәлдерде. Җем-җем итә йортлары... Ифрат якын да, ифрат ерак та сыман алар. «Рәнҗетмәбез... уйлашырбыз», дигән булды Низамов.

Хатыны Марзияне исенә төшерде: «Абруйлы чагыңда, йоклап йөрмәсәң лә иде... соңыннан үкенмәгәек!» — дип тукып кына тора. Ул да хаклы: дөнья хәлләрен белеп булмый шул...

10

Үтәдем авылында дуңгызлар фермасы гына яшәп калган иде. Бүлекчәнең бар булган бүтән мал-туары Гәрдәле яисә Әҗер фермаларына өченче елны ук инде күчерелгән иде. Иген игәр җирләре — һәйбәт туфрагы, елның елында куандырып килгән басулар — инде хәзер корылып яткан заводлар астында, Үтәдемнең «Йолдыз» совхозына эләгеп торганы нибары шушы дуңгызчылык иде.

Таянычы нык һәм ышанычлы булганга, Таипов бу фермага атнасына бер-ике тапкыр гына сугылып киткәләр иде. Килгән чагында да алай төпченеп һәм нечкәләп маташмый. Бу тармакның бар нечкәлекләрен юньләп белмәгән башың белән ферма мөдире Матвей Асановны яисә зоотехник Галина Алексеевнаны уздырмакчы бу-

лып, нигә дип юкка-барга тыкшынырга? Керәшеннәр гомер буена дуңгыз асраган халык: белеп һәм жирәнә җиткереп карыйлар, хәтта күңелләренә якын күреп, яратып тәрбиялиләр дисәң дә хата булмастыр. Үрчемне тиешенчә алалар икән, аннары җитлеккән хәтлесен һәйбәт симертеп, дәүләткә вакытында тапшыра беләләр икән — куанып яшә!

Бүген Чаллыдан кайтышлый Таипов сугылып китмичә булдыра алмады. Ләкин фермада Асанов юк иде: ниндидер йомыш белән Әжергә төшеп киткән. Ә Галина Алексеевна хакында:

— Әле иң кырыйдагы абзарга дезинфекция җасап бетергәч кенә шушы тирәдә җөри ие, җир җотты мәллә? Ә җук, әйбәтләп җуынмага өенә кайтып киткәндер, анда, бәлкем, самоварын да җаңартып җибәргәндер инде,— диештеләр.

— Иә, ничек, Мария, хәлләр ал да гөлме? — дип сорады Таипов урта яшьләрдәге мөлаем кызгылт йөзле хатыннан. Директор тирәсенә кайсы кулларын алъяпкычына сөртештергәләп, кайсы яулыгын төзәткәләп, дуңгыз караучыларның берничәсе тартыла төшкән иде инде.— «Мырык-мырык бәбиләрең», дим, шәп чиныйлармы? Саутазалармы?

— Мин тагы... үземнең хәлне белешәсең дип торам. Һәйбәтләр, шәп чиныйлар!

Һай, чая һәм четердәвек тә соң бу керәшен хатыннары: җай гына бир — минутында чеметергә торалар! Таипов болар алдында тавышын бик тә көр чыгарырга тырышкан иде, ул аны саклаган хәлдә, шундук хатасын төзәтергә ашыкты:

— Юк ла инде, үз хәлеңне сорашуым. Ә болай, карап карауга, сөбханалла, алмадай күренәсең! Җелекләрне куырган мондыен көнне дә... Ярый әле, дим, сукса тимер өзәрдәй ирең-канатың бар, югыйсә монда... Һе-һе!

Шул җитә калды тагы: Мария, йөзен бөтенләй алсуландырып, җитез генә кул изәп алды:

— И картаеп беткән башың белән, Яхъя абый!

Бу шук сүзләрне бөтенләй үк өнәп бетермәгәне, өлкәнрәк яшьтәге Евдокия-Әүдәки, соры халатының изү төймәсен бөтергәләгән шәйгә, ярыйсы ук коры һәм эшлекле тавыш белән:

— Ә болай Яхъя Таипыч, әйбәт кенә кыймылдап җатабыз! — дип куйды.— Нормальный диярлек! Соң бу эсседә инде... Рационны бозган җук үзе дә бит... Обратың

җитсен дә, тагаракларың корымасын! Чүмерүләрен генә беләләр!

— Үзебез соң, Әүдәки апа! Чәй дә квас, квас тә чәй генә ләбаса бу көннәрдә! Шушындый эссегә чыдауларыңа сөен! — дип кыстырды Мария.— Җитмәсә, үрчемне шәп бирсеннәр дә тизрәк симерсеннәр дип дуылдатып кына торасыз үзләрен!

Төчеләнү, кирәгеннән артык хискә юмартлану Таипов холкына ят нәрсә иде, әмма ул бу сәгатьтә ничектер тыелып кала алмыйча, төчеләнә язып, әйтә салды:

— Менә сез үзегез өч бөртек кенә, ә совхозга сездән дә күбрәк табыш китерүче тагын кем булыр икән? Бүгенгә юк андыйлар, юк! Мең рәхмәтләр дими, уңганнарның да уңганы дими... Валлаһи менә!

— Үзең алай дисең дә... фермабызны тамырыннан корытырга җыенасыз түгелме соң? Бүген булмаса, иртәгә,— диде Мария.

— Юк әле, алай ашыкмабыз. Район җитәкчеләре дә кушмый. «Татарстан» совхозында кайчан әле дуңгызчылык комплексы корылып бетәр, кайчан ходка китәр? Анда бит әле ябыштылар гына. Бүгенгесе хәлләрдә Чаллы тикле Чаллыны ничек итеп иткә туендырмак кирәк?

— Андагы комплекс, имештер, илле дүрт мең баш дуңгызга исәпләнгән, ди. Дөрес булса, ай-һай-ла! — дип тел чәпелдәтте Евдокия.

— Анда, җитмәсә, бар нәрсә машинага, автоматка көйләнгән буласы, ди. Фабрика булмый ни! — дип куәтләде Мария.

— Безнең күк билдән сазга батып изаланасы булмас шул,— дип кинәт кенә баш яулыгын төзәткәләргә тотынды Әүдәки.— Менә кайларда эшләп җатарга рәхәт буласы икән бездәй хатын-кызга!

Гәпнең мондый төс аласын Таипов көтмәгән иде, ашыгып баш чайкады:

— Җә, җә, күрше абзарындагы күркәгә кызыкмыйк әле! Үзебездә соң! Ике мең дә егерме дүрт баш сыерга исәпләнгән ферма корачакбыз ләбаса, ягъни комплекс дигәнем. Өр-яңа, заманча! Дөньяда бер дигәндәй...

Үтәдем фермасы үр кашына ук сыенып утырган, шул сәбәпле моннан совхозның байтак җирләре уч төбендәге шикелле күренә иде. Таипов күз карашы белән зәңгәр рәшә эчендә тибрәнгән басу түрләрен иңләде.

— Әнәтерә, күгелҗемләнеп торган урман артында гына... Яңа поселок та шунда — кем әйтмешли, ошбу

ҫани дөньяның гап оҗмах почмагында, комплекс та урман куенында гына буласы...

Таиповның тавышы күтәренке, үтә көр иде. Җае чыгып торганда, эшчән хатын-кызның күңелен бер кытыклап алудан ни зыян? Дуңгыз караучыларның авызлары ерылган иде, әмма Әүдәки, янә иреннәрен капыл гына җыя төште дә, директорның сүзен бүлеп, кырт кисте:

— Һи, Яхъя абый, син үтереп мактыйсың да... андыена безнең эше дуңгыз караучылар җарармы икән? Андыена аның үзегезнең Әҗер белән Гәрдәле хатыннары да бетеп бетмәс әле. Безнең ишеләргә тагы...

— Безнең ишеләрнең хәлкәйләре... әнә җир белән күк арасында инде бүгенгесе көнне. Кайсы болыт кайсылайга таба апкитәр,— диде хатыннарның берсе, авызын киң ерып.

Шул мәлне дуңгыз караучыларның барысы да диярлек, үзара серле рәвештә ым каккалап, читкә, Яңа кала тарафларына таба күз ташлап алды. Бу сүзләр, бу серле ым кагулар Таиповка совхозның алдагы язмышына кизәнү, һич югы аңа төкереп карау булып тоелды, һәм ул, болай да эссе һавада тамак төбенең тәмам куырылып киткәнлеген тойган хәлдә, ашыгычлык белән үзенекен тезәргә кереште:

— Нишләп? Сездәй уңганнарны читкә кагарга, читкә җибәрергәме? Билләһи, җир йотар! Соңыннан Таипов абый үзе әйткән иде диярсез әле менә: Яңа поселокта дөнья оҗмахында яшәгән шәйләргә, өр-яңа комплекста ап-ак халатлар киеп кенә, үзара ипле генә ярыша-ярыша җирләр җимерттерәчәксез әле, туганкайларым!

— Җарыша-җарыша, имеш... Адәм көлкесенә калакала, диген, ичмасам! — дип, кинәт сызган шырпыдай кабынып китте Мария. Ул директорны янә бер чеметеп алырга җай көтеп торган, ахрысы. Ә бәлкем, сизгер күңелле бу чая хатын, сүзне капыл икенчегә борып, әлеге киеренкелекне бер селтәнүдә тузгытып җибәрергә ниятләгәндер? — Җарыш дигәч тә, җөкләмә дигәч тә... әнәтерә бөтен авыл көлә миннән!

— Менә сиңа, ник көлә, нидән көлә? — дип текәлде Таипов, киң җилкәсен җыерып.

— Көлмәскә... Шул җөкләмәдән инде. Баганаларга фанер такталар кадаклаттырып чыккансыз бит. Арада минеке дә бар. Кызыл өслеккә ак хәрефләр белән шытырдатып язылган, имеш дигән, «Мин, Мария Колчерина, быелгысы җылны һәр ана дуңгыздан унтугыз җарым баш бала алырга җыенам» дигән...

— Соң, йөкләмәң шулай булгач... дөп-дөрес ич! Ул такталарны кадаклап чыгарга үзем куштым мин. Ике багананың беренә. Кем нинди йөкләмә алганлыгын әйттереп... Авыл саен!

— Һай аллам, авыл саен! Аларда да көләләрдер инде... Кирәге жук миңа андый жөкләмәнең!

— Менә хикмәт!.. Соң, үзең үз теләгең белән алдың ич! Аннары ул ак кәгазьгә бик әйбәтләп, өтерге белән дә чокып алмаслык иттереп, язып куелган бит, сеңелкәем,— диде Таипов, баскан җирендә авыр гына таптангалап.— Социалистик йөкләмәләрне кәмит итәргә монда...

— Ак кәгазьдә җараганы баганада җарамый икән шул, абзыкаем! — Мария хәтәр бер хәрәкәт белән янә кул изәп алды.— Хәзер әнәтерә авылга килгән җыен камазчы көлә миннән; «Мария апаем, ди, җыл тәүлегендә бер анадан унтугыз башны алырсың алуын — анысына шикләнмибез, ә менә җарты башлы чучкаңны ничек иттереп алырсың икән — хикмәтнең дә хикмәте булмасмы?» ди. Чәчрәпләр китим, шулай ди...

Таипов әле һаман аңышмыйча тора иде, аптыраганнан ахры, кулъяулыгы белән муен артын, маңгай тирәсен сөртештерде.

— Социалистик җарыш дигәч тә монда... «Кимендә унтугыз баш» дип җазган булсалар, бәйләнепләр торыр иеммени? — дип четердәвен белде Мария.

— Ие, түгәрәклиселәре калган мәнсезләрнең! — дип иптәш хатынына куәт бирергә ашыкты Әүдәки дә.

Ниһаять, директорның авыз тирәсе җәелеп китте:

— Һы, мин тагы... Тукта, түгәрәклисе булгач, нигә «егерме баш чучка баласы» димәскә? Ярый-ярый... күзне шакмакламыйк! Рабочком белән парткомга әйтермен, төзәттерерләр.:. Иртәгә үк дим! — Моның соңында Таипов тәмам эрегән кыяфәт белән баш селеккәләде:—Валлаһи, җәһәннәмгә кисәү булып туп-турылай китүең дә бар сезнең аркада... Ярый, эшегез уң булсын!

— Рәхмәт җылы сүзеңә, Яхъя абый!

Хатыннар, бөерләренә таянып баскан хәлдә, мыштым гына көлешеп калды, Таипов исә, җиргә саллы-саллы басып, үр битендәге юлда көтеп торган машинасына таба атлады.

11

Инде хәзер кая юл тотарга? Әҗергә кайтып, конторда ходайның һәр бирмеш көне тудырып торган очсыз-киксез мәшәкатьләргә чумаргамы? Юк, андагы ыбыр-чы-

бырны тавык та чүпләп бетермәс — контордагылар бер көндә үлмәсләр әле...

Көн болай куырып торганда, борчак басуында шытымнар борын төртүгә үк борча төшмәдеме икән? Хәер, баш агроном Ризван алай җебеп ятучылардан түгел — басуларны әйләнми калмагандыр.

Туп-туры яшелчәлеккә элдертергәме әллә? Анда быел эшләр болай ярыйсы гына көйләнеп китте сыман: утыртуын да шома гына башкара белделәр, инде су сиптерүләр дә ару гына бара. Ә эш көйле җирдә сөйләшүе үк бүтәнчә... Менә бит дуңгыз караучы керәшен хатыннары аңа ничек кенә чытырдап ябышмасын, барыбер чәнечкән энәләре энә булып тоелмады, күңел, киресенчә, ничектер бушанып, йомшарып калды.

Таипов, машина эченә кереп утыргач, ишекне шапылдатып ябып куйды да:

— Гәрдәлегә! — дип боерды. Аннары, машина кузгалып китүгә, бик тә авыр төстә уфылдап җибәрде.— Их, шушы минутларда булса ла иде сап-салкын әйрән яки, киресенчә, кап-кайнар чәй, ә!

— Әйтәсе юк.

Үтәдем авылына сугылмыйча гына, Шилнә суын сайрак төштән кичтеләр дә аръяктагы басу юлына чыктылар.

Сабан игеннәренә күз төшердең исә, җан сыкрый. Арпа белән бодай җирләренең кабарыбрак торган төшләре, күр инде, бөтенләй шәрә диярлек. Ә бит һич соңармыйча, тап үз вакытында чәчкәннәр иде чәчүен. Дымың җилгә очып бетсә, шулай булмый ни! Инде хәзер җирдәге орлыкның үз вакытында шытарга өлгермәгән хәтлесе мондыен эсседә тәмам кибеп, куырылып беткәндер. Ярый әле уҗым басулары әлегә өметле күренә.

Таипов чокыр-чакырлар аша турыга тотарга ым какты. Алда юл дамбасы өчен актарынып ташланган кызыл балчык өемнәре артында, шәп-шәрә басу күкрәгендә, кою заводының вакытлы поселогы көч-дәрман җыеп ята иде.

Кою заводы үзе Үтәдем авылының аргы башында канат җәяргә җыена, анда әлегә күзгә әләгердәе — актарылып ташланган бинаһая җир мәйданы гына. КамАЗның кою заводын дөньяда иң зурлардан буласы диләр бит. Тик ул әлегә юньләп абайланмый да. Дөрес, соңгы бер-ике атна эчендә, менә мин кайда калкачакмын, дигәндәй, буласы корыч фермаларның бетон нигезләргә утыртылган иләмсез юан һәм биек колонналары туп-

туры зәңгәр күккә төбәлде төбәлүен. Әлегә дистәдән артык түгелдер...

Әйе, завод җирдән юньләп баш калкыта алмый әле, әмма аны коручы «Металлургстрой» үзенә вакытлы поселокны — менәтерә, әйдәгез, рәхим итегез! дигәндәй — өлгертеп тә куйды.

Шушы поселок урнашкан басуга гәрдәлеләр азаккы тапкыр борчак чәчкәннәр иде. Сортлы борчак — элита үзе! Харап тә шәп уңган иде! Соңыннан аны күрше-күләндәге хуҗалыклар да: «Зинһар, өлешсез калдырмагыз инде!» — дип, амбарны ялап чыккандай иттереп, алып китеп бетерделәр. Орлыгы бер хәл инде, аның җире дә әкәмәт иде шул! Ә хәзер ипигә ягып ашардай ул туфрак юк инде. Әнә анда кара тау булып укмашкан да өстендә алабута-әрем урманы үстереп ята. Соңыннан янә актарылып, кайларгадыр сибәселәрен көтеп... Ә монда күчеп килгән халык, бу хәлләрне һич уена да китермичә, үзенчә тормыш корып кайнаша...

Бихисап баганалар астында җыйнак кына, бәләкәй генә вагоннар урам-урам булып тезелешкән. Вагоннарның инде исәбенә дә чыгасың юк. Кай арада, диген!

Бериш кешеләр, үз вагонын үстерә төшеп, аңа веранда сыманрак корама тоташтырып куйган, аннары йорт әйләнәсен рәшәткә белән тоткан да ашъяулыгы хәтле генә түтәлләр әтмәлләп, аларга яшелчәдер, чәчәктер утырткан. Җайлаша белә кеше дигәнең!

Вагоннардан чак кына читтәрәк, ачыграк бер төштә бетон панельләрдән киң һәм озын гына бина күтәртеп киләләр — мәктәп буласы, ахры. Аңардан ерак та түгел янә олы гына бер нигез түшәргә керешкәннәр — монысы ашханә булыр микән, әллә клубмы? Таипов төзүчеләр арасында ныклап оялап алган бер сүзне исенә төшереп, ирексездән көлемсерәп куйды: имештер, теләсә нинди зур төзелештә иң озын гомерлесе — вакытлы поселоклар, ди.

Чаллыдан кайсылайга чыгып китсәң дә, тәртеләсең аларга. Инде хәзер вакытлы поселоклар дистәдән дә ашып китте бугай, алай да әле һаман ишәя һәм киңәя баралар. Нишлисең, чарасыздандыр. Моңа кадәр җир йөзе күрмәгән, адәм колагы ишетмәгән олы төзелештәге меңәрләгән халыкка бүтәнчә ничек иттереп берьюлы оя корып бетермәк кирәк?

Вакытлы поселок... Вакыт санап яшәүчеләр... Ә күршеләрендә, әйләнә-тирәләрендә гасырлар буе яшәп килгән авыллар. Әнә Орловка белән Сидоровка инде Яңа кала кочагында — озакламый тәмам йотыласылар. Үтә-

деме дә тулаем завод астына китәсе... Олы мәхшәр купкан җирләрдән шактый читтә утырган Гәрдәле, Чуар, Әҗерләрнең дә язмышлары кыл өстендә эленеп тора — алга таба барыр юлларына куелган киртәләрне әйләнеп үтәсең юк. Мескенләнеп торган урамнар, нәүмиз кыяфәтләрендә утырган иске йортлар... Күпмегә сузылыр әле бу эленке-салынкылык һәм сөремле киеренкелек?

Телгәләнә бәгырь, телгәләнә...

Ә болар? «Вакытлы» дип йөртелсәләр дә, анда яшәүчеләргә төрле уңайлыклар тудыру, тормышларын күркәмрәк итү, ягъни тамырларын Чаллы җиренә тирәнгәрәк җибәртү өчен, ниләр генә эшләнми! Үзләренә хәтта ки матур-матур исемнәр кушып куйганнар: Энтузиастлар поселогы, Яшьлек, Кама, Башакчык, Өмет... Соңгысы аерата хуш яңгырый сыман: адәм баласы, иксез-чиксез илнең әллә нинди почмакларыннан кубарылып, шушында зур заводлар һәм өр-яңа кала салу дәрте белән бергә үз бәхетен дә какшамас нигездә коруга өмет чаткыларын дөрләтеп килмимени?

Таиповның күз алдында янә Низамовның шәүләсе калыккандай булды. Бермәлне бер киңәшмәдә секретарь: «Шулай, туганнар, ышанычы какшаган, өметен җуйган бәндәләрне безнең КамАЗ җире берничек тә сыендыра алмый, андыйлар, әзергә хәзер булып, пешкән бәлеш көтеп йөрмәсен!» — диебрәк, гадәтенчә сүздән яшен чатнаткан иде бит.

Ә менә бүген ул Таиповка азаккы фикерен нишләптер әйтеп бетерергә дә теләмәде. «Әллә ниме?..» — диде дә, кайнар сулышына буылгандай, капыл гына тыелды да калды. Ни әйтергә җыенды икән? «Синең дә, Яхъя Таипыч, дәрт-дәрманың сыегая төшеп, зур эшләргә өметләрең какшабрак киттеме әллә?» — дип өтеп алырга чамаламадымы икән? Булыр да...

Аңарчы исә ул аны консерваторлыкта гаепләгәндәй итте. Булырсың да! Ике дистә елдан артык җитәкчелек иткән дәверендә Таипов, яңалык дип, фәлән дип, югарыдан кушылган бериш нәмәрсәләргә тотынып, азмы авызын пешергәләде? Шөкер, шушы тарафтан да аның алган сабаклары хәттин ашкан лабаса! Инде менә сугару дигәнендә азрак сабыр итмичә, уңга-сулга карангаламыйча, ничек инде илаһи-уптым гына ябышасың, ди?

Их, җаныңа корт ояламасын ла икән!

Юк, фатир сорап гариза бирәсе калмаган үзенә. Вакланмаска иде. Шундыен киеренке заманда хатын сүзе белән йөрсәң монда...

Колак төбендә кинәт:

— Яхъя абый, коеларның атасы бу! — дип яңгыраган тавыштан Таипов айнып киткәндәй булды, әйләнәтирәсенә күз салды. Күр, Гәрдәлегә килеп тә кергәннәр инде.— Суы тешләрне камаштырырдай салкын да, тәмле дә! Тукталмый ярамас, дим, Яхъя абый.

— Әйе, әйе...

Кое шактый тирән икән — чыгыр, Дифгатнең таза беләгенә буйсынып, озак кына шыгыр-шыгыр әйләнүдә булды. Әмма, аның каравы, суы чыннан да әкәмәт икән! Бер-ике йотуга ук әлсерәгән гәүдәгә җиңеллек инде һәм... Таиповның авыр уйлар болытында йөзгән зиһене капыл ачылды да китте. Тукта, ни пычагыма дип килде әле ул Гәрдәлегә? Управляющий Хәкимҗанны ул бүген иртән Кама буендагы болыннарны карап кайтырга җибәргән иде ич! Андагы яшь мал-туарның хәлен дә, печәнлекләрнең торышын да белешергә... Ә Хәкимҗаннан башка бу авылда яшелчәлектә эшләрдәй хатын-кызны эзләдең ни дә эзләмәдең ни... Ярар, яшелчәлектә дә берике көндә үлмәсләр әле...

Таипов, аяк астына төбәлгән хәлдә, беравык уйга батып торды. Дифгат кое чиләгеннән аерылуга аңа калын кашлары астыннан гына карап куйды да:

— Борылыйк, энем... Суыксуга! — дип боерды.

Шофер егет, уң кулын баш артына куеп, челт-мелт күз йомгалады:

— Суыксуга? Кирәгәме?

— Әйе, кирәгә... Чаллы тарафларына, «Коммунизм» колхозына! — Машинага кереп утыргач, директор, тавышын йомшарта төшеп, аңлатырга тиеш тапты:— Иренмик, энем. Авыр юлга бер кузгалып чыккансың икән, аның ахырына җитү хәерле. Аларның культуралы көтүлекләре галәмәт, ди! Бер күз салып кайтмыйча, һич ярамастыр. Югыйсә...

Таипов, сүзен өзеп, тынып калды. Моңарчы аның һичкайчан да күрше хуҗалыкларга баш орып барганы юк иде. Нишлисең, ни чарадан бичара...

«Председательләрнең күзенә чалынмасаң, әйбәтрәк инде әйбәткә... Хәер, Мөнәвир — үз кеше, шәт, гаеп итмәстер. Аның дә кәнфит суырып кына йөргән көннәре түгелдер әле!..»

12

Байтак җирләрне айкап йөргәннән соң, менә инде, ниһаять, кичке уңайда кайтып киләләр. Күпне күрде, күпне ишетте, аннан да бигрәк күпне кичерде — бу көн, мөгаен, Яхъя Таипыч хәтерендә шактый озакка уелып калырдыр. Күкрәгендә оялап алган һәм: «Әллә ниме?..» — дип җанын кимереп торган теге шөбһә корты да инде әллә ни бимазаламый, инде тына төште сыман. Һай, бөтенләйгә тынуы булсачы! Ләкин алдагы көннәрендә, бәлкем, атна-ун көн буена, Таипов шәһәр комитетындагы сөйләшүне, тора кайтып, исенә төшерәчәген, вакыт-вакыт Низамов белән эчтән генә бәхәсләшеп тә куячагын, һәрхәлдә, бөтенләй үк тыныч яшәмәячәген дә бик чамалый иде. Юк, секретарь алай артыгын шөбһәләнеп ятмасын әле анда. Яхъя Таипычның, шөкер, дәрте дә сүрелмәгән, дәрманы да сыекланмаган, ышанып тапшырылган үз хезмәтендә утлар уйнатырлык җегәрләр бар әле аңарда! Бурыч һәм намус дигәнне канында йөртеп, дан-шөһрәт һәм хөрмәт дигәнне җаны белән татып караган, аның татлы тәмен белгән карт гвардия сынатыр диме соң? Әйе, чак кына сабыр итегез, үзен күрсәтә белер әле ул карт гвардия!

Үз көч-сәләтеңә ныклы ышанудан туган якты өметнең бәһасы ни? Мөгаен, аңа бәһа куеп булмый да торгандыр...

Кайтыр юллары Әҗер очына килеп төртелгәч, Таипов Дифгаткә машинаны туктатырга кушты да:

— Ярар, энем, ичмаса, син иркенләбрәк ял итеп ал. Иртәгә таң тишегеннән торасың булыр. Ә мин бераз әйләнеп кайтыйм әле,— дип шофер егетне төшереп калдырды.

Машина урамга кермичә, авылның бакча артларындагы юлына борылды.

Чаллы тарафларына сәфәр тотканда алай кыюлык итмәсә дә, үз авылы тирәсендә, үз басуларында йөргәндә Таипов рульгә еш кына үзе утыргалый иде.

Яшелчәлектә, күр инде, адәм затыннан ник берәү күзгә чалынсын икән. Ни сәбәптәндер су сибүне дә туктатканнар. Нигә болай иртәләделәр икән? Ни булды икән? Иртәнге планеркада бераз пешереп алмыйча ярамас үзләрен...

Аның каравы, яшелчәлек плантацияләренә тоташып киткән сөзәк кенә үр артында һавага нечкәләнеп атылып менгән һәм дугайланып, чуклы-чакланып төшкән су

тасмасы әллә каян шәйләнә. Үзе, җитмәсә, әкрен һәм ипле генә әйләнеп тә тора.

«Хәнәфи Бариев, сменасын тапшырып, китәргә өлгермәгән булса ярый ла...»

Бәхетенә, китмәгән икән әле. Әнә «культуралы көтүлек» дип инде телгә керә башлаган һәм әлегә бер як чите буйлата гына тәбәнәк бетон баганалар тезелеп киткән яшел басу ызаны белән болай таба берәү төшеп килә.

Таипов, машинасын ызан башында калдырып, кәлдин-кәлдин төшеп килүче киң җилкәле адәмнең каршысына таба атлады.

Җылы гына иттереп кул кысыштылар.

— Шөкер, димсең, алайса, Хәнәфи?

— Шөкер...— Тракторчының кояшта, җилдә кипшергән какча йөзендә җиңелчә елмаю чагылып алды.— Сиптерәбез ипле генә. Алны-ялны белми дигәндәй...

— Синең кулалмашчың... теге кемме? Чуардан Минһаҗмы?

— Әйе. Төпле адәм. Төнгелекне дә үзе теләп алды.

— Ә үлән шәп, ә! Менә бит дымга туендыра белсәң, ә! — Таипов, куе, йомшак үлән арасын ерыштырып, әрлебирле йөренгәләп алды.— Сиптерүгә эләккән бу кишәрлек ни чамада?

— Егерме гектарлап.

— Бүлеп алынганның, үләне чәчелгәннең нибары алтыдан бере генә шул. Калган хәтлесе әнәтерә тилмереп ята... Хәлләр диген!

— Әллә тагын бер-ике тракторны куябызмы?

— Бүтән эшләрдә дә җитенкерәми әле ул трактор. Менә син, Хәнәфи, Суыксу белән Мәләкәс көтүлекләрен күреп кайтсаң икән! Аларда трактор белән дә сиптерәләр, хәтсез генә торбалар сузып, боларыннан да коендырып яталар. Үләннәре кайбер кишәрлекләрендә менә болай — тездән югары инде! Сыерларны чамасын белеп кенә кертеп тә чыгаралар, үләнне чабып та ашаталар... Аптырыйсы юк икән, җәйге савымда капыл гына алга ыргылуларның хикмәте әнә нидә икән!

— Соң, безгә дә шушы кишәрлеккә озакламыйча кертергә булыр иде. Тик аңарчы киредән бер кат сиптереп үтмичә ярамастыр. Аннары, шәбәеп үсеп китсә, чабып ашату кулайрак булмас микән?

— Тизрәк үсә генә күрсен, нишләтәсен белер идек әле. Арыш чабып ашату белән генә әллә кая китеп булмый шул. Анысы да бит чиксез түгел, бик чикле...

Таипов иелде дә, бармакларын җәя төшеп, үләнне сыйпаштыргалап алды һәм, шул иелгән хәленнән тураймыйча, авыр гәүдәсе белән җиргә кырынаеп сузылды да ятты. Ул да түгел, чуар кепкасын салып, аны үлән арасына ыргытты, шоп-шома баш түбәсен сыпыргалады. Менә шул мәлне генә Хәнәфи Бариев аның бирегә тиккә генә килеп чыкмавын, директорны зур гына гозерйомыш куып китергәнлеген абайлап алды. Һәм үзе дә янәшәгә тез кочып утырмыйча булдыра алмады.

Директор, нәзек кенә үлән сабагын өзеп алып, аны иреннәре арасына кыстырды.

— Ә бит алдагысы елларны сугарыласы җирләр ничәмә-ничә йөз гектарда буласы. Башлап җибәргәндә генә аның елы бу хәтле яман килмәгән булсачы, хәерсез!

— Ел дигәннән, Яхъя Таипыч, син Чуарның Вәлихан картын әйбәт беләсең бит, сиксәннең теге ягына чыккан менә шул бабай әйтә, ди, әнә: рәттән өч җыл шушылай корытып килер, адәм баласына бик авыр булыр — зур ачлык җәфасын күрмәгәе халык, дип...

Моны ишетүгә Таипның калын кашлары кушыла язды:

— Өч ел рәттән, диген, ә? Акылыннан шашкандыр ла ул!

— Шашкандырмы-юкмы, анысын белмим, әмма ләкин Чуар халкы ул картны бик тә хөрмәт итә. Гыйлем иясе, диләр, үзен. Имеш, Вәлихан бабайның бер кулында коръән булса, икенчесендә төрле сыналмыш язмалар, ди... Аннан килеп, ул әйткәнне Үтәдемнең Варвара карчыгы белән Мөкетә карты да раслаган, ди әле. Монысын минем Рәсүлә Үтәдемнән яшелчәгә эшкә йөргән хатыннардан ишеткән.

— Үтәдем «изгеләре» ничек дигән соң?

— Шул инде: рәттән өч җыл җаман авыр булыр, дигәннәр. Әмма алары нишләптер аны ҚамАЗ төзелешенә төбәбрәк юраган. Олы дәһшәт булып килгән нәмәрсәнең көч-кодрәтен аллаһы тәгалә төрле хәлләрдә сынап карарга теләр, дип әйтеп юраганнар, имеш.

— Менә, сиңа, абзыкай, ишетмәсәң, ишет! Юраганнары юш килмәсә дә икән!

Беравык дәшми-тынмый яткач, Тапиов авыр гына сулап куйды, башын калкыта төшеп, янәшәдә утырган тракторчыга күз сирпеп алды, аннары үзе дә торып утырды һәм зур да, җитди дә нәрсәне түгел, бәлки гадәти бер әйберне хәл иткәндәй генә әйтә салды:

— Сиңа, Хәнәфи, тракторыңнан аерылырга туры килер, ахрысы.

Теге сискәнеп үк куйды:

— Ничек инде ул капыл гына?

— Шулай... Теге чакны үзең дә бик теләгән идең бит. Механик итеп күчер, инде басу иңләп йөрүләрдән туйдым дип, колак итләремне чәйнәп бетерә язган идең ич.

— Анысы бит теге чакны. Ә мин хәзер бу яңа эшемә дә күнегеп киттем әле: суны сиптерә барасың, артыңнан, күз алдында диярлек, ямь-яшел үләннәр дәррәү күтәрелә бара... Җанга рәхәт!

— Әһе, шулай диген! Менә шул сәбәпле мин сине совхозның бар сугару эшләренә баш итеп куярга ниятләдем дә. Тагы да рәхәтрәк булыр.

— Ансат та инде...

Хәнәфи көрсенеп куйды: «Менә нинди гозер белән килгән икән лә бу йомры баш...»

— Үзенә күрә бригада төзеп, ябышсаңмы? Ә аңа кемнәрне тартасын бергәләп уйлашырбыз. Иртәнге планеркага сугылырсың, дим, ишетәмсең? Должность дигәндә исә... механик-гидротехник диярбезме яки анда мелиоратор-механик диярбезме...

Ниһаять, Хәнәфи моңсу гына әйтә куйды:

— Хикмәт исемдә түгел, җисемдә.

— Бик дөрес: җисемдә! Ә җисем дигәнең һавада түгел, кешенең үзендә!

— Инде картаеп барганда гына...

— Һы, урыс ничек ди? Карт алаша буразнаны бозмас, дип әйтәме?

— Урыс әйтә дип монда...

Таипов бер үч үлән йолкып алганлыгын үзе дә сизмәде ахры, менә ул аңа үтә гаҗәпсенеп төбәлеп торды да читкә ыргытты:

— Безгә үгезне мөгезеннән эләктермичә һич ярамый, Хәнәфи! Аннары, дарыны һаман да коры тотуның кирәклеген дә онытмыйк! — Таипов, кем сүзләрен әйтүен исенә төшереп, чак кына көлемсерәп алды, әмма барыбер шуны кабатлады, инде басым беләнрәк кабатлады:— Дарыбыз коры булсын, дим, гелән дә!

— Артыгын коры тотып, шартлап куйсаң бер заман?

— Шартласаң соң! Аптырамыйк: бик әйбәтләп, кире кайтмаслык иттереп җирләрләр.

— Анысы хак: җирнең әле беркемне дә кире кайтар-

ганы юк. Җир куены адәм булганны да сыендыра, ләгыйнь булганны да чыгарып ыргытмый.

Бер-бер нәрсәгә төрттерүе түгел микән дип, Таипов тракторчыга янә күз ташламыйча булдыра алмады. Юк, Хәнәфинең йөз чалымында киная-мазар тамчы да беленми, ул калын иреннәре арасына бәләкәй генә яфрак кыстырган да җитди, уйчан карашын аяк очындагы яшел үләнгә төбәгән иде.

— Ә без ләгыйнь булмадык шикелле, Хәнәфи?

— И булмабыз да, Яхъя Таипыч!

Монысын инде нык бәгырьле, каты беләкле тракторчы Хәнәфи Бариевның ризалашуы дип тә аңларга мөмкин иде. Һәм Таипов, ике күңелнең бер тирәнлектә айкалуын абайлап, аннан да бигрәк, көне буе уйлаганнарына, ниһаять, үзенә күрә сөземтә ясарга җай чыгуына куанып, бер сулыш белән диярлек әйтә куйды:

— Булырга хакыбыз да юк, туган!

13

Алны-ялны белмәстән айга якын эшләгәч, бермәлне Людмила Крутько, вахта машинасын да көтмичә, Чаллыдан иртәрәк кайтып төште. Куанычы эченә сыймагандай күренә — ишегалдына үтүе белән башыннан кызыллы-яшелле яулык кыегын сыпырып төшерде — житен чәчләре тузгып китте:

— Ниһаять, тырмаша торгач, биш катлы йортны ялт иттердек! «Ура!» дигәндәй! Иртәгә ял!

Юынып-сафланып алгач, әмма хуҗа хатыны әзерләгән чәй табыны артына утырмас борын, яшь хатын әле һаман куану дулкынында йөзгән шәйгә, Рәмиләгә төбәлде:

— Рамилечка дим, бу арада син дә эшкә йөрмисең бит. Әйдә, иртәгә җиләккә барабыз! Чаллы базарында без кызлар белән тәмләп карадык инде. Тик шундый кыйбат... Әйбәт җиләклекләр бармы сезнең тирәдә?

Рәмилә муенын эчкә батырды:

— Якында гына юк шул. Җир җиләгенең оясы Кама буенда инде, безнең ерактагы болыннарда.

— Анда тикле ничекләй бармакчы буласың, тилекәй? Аның соңында болын таптаттылар ди сезгә... Әнәтерә печәнен чаба да башлаганнар икән инде,— диде әнисе Рәсүлә.— Берсекөнгә җыймага бармакчылар, ди. Ишетмәдеңмени, алдан ук кисәтеп үттеләр.

Кыз борынын җыерды. Управляющий Гарапша кушкан җиргә аның бер генә дә барасы килми иде. Әмма күңеле бер үк вакытта җилкенеп-кытыкланып та куя иде: яшьләрнең бары бердәй өелешеп, машинада җырлый-җырлый болынга барулары, анда баргач, уен-шуклануларны да онытмыйча, гөрләтеп эшләүләре үзе ни тора!

— Булмаса, иртәгә үзебезнең авыл урманы тирәсенә барырсыз. Анда кырый-кырыйларда элгәре әйбәт кенә җиләклекләр очрар ие. Таба алмасагыз, Калмаш урманы җагына чыксагыз да җарый. Үзем уятырмын,— диде әнисе.

— Ә еракмы соң? Хи, биш-алты чакрымлап кына... Чүп бит ул безгә! Әйеме, Рамилечка? — дип очынып куйды Людмила.

Иртәгесен иртүк торып, юлга чыктылар. Кулларына, «җиләкне куркытмас өчен», өчәр литр сыешлы эмаль бидоннар тотып кына...

Басу юлы бормалы, басу юлы тузанлы. Җитмәсә, кояшы да, терсәк буе күтәрелүенә үк, әйбәт кенә кыздыра башлады. Атлый торгач, ярыйсы гына әлсерәделәр.

Ләкин Әҗер урманы тирәсендәге ачык аланнарда, сай чокыр битләрендә үлән тапталып беткән булып чыкты. Ары сугылдылар, бире килделәр, әмма юньле җиләклеккә юлыга алмадылар. Рәмиләнең ак бидон төбе әле һаман күренеп тора, ә Людмила исә бидонына бер генә бөртек тә җиләк төшермәде: ул очраган берен, вагына тикле, авызына озата бара иде, талымсыз...

— Калмашлар калдырыр ди сиңа! Аларның борын төбендә генә шул! — диде Рамилә, ике-өч чакрымда гына киң уйсулыкта утырган авыл ягына ишарә ясап.— Әнә бала-чагалары чокыр буйлата өер-өер болай таба сузылган да инде.

— Бу хәтле җиргә килеп тә җиләксез кайтырбыз микәнни? — диде Людмила. Аның аксыл йөзе кояшта янып чыккан, ә зәңгәр күзләрендә аптырау катыш әрнү тойгысы аермачык сизелә иде.

— Урман кырыйлатып менеп карыйк әле,— диде Рәмилә.— Бервакыт, моннан өч-дүрт ел элек, без әбкәй мәрхүмә белән, һай, шәп җиләклеккә очраган идек! Әнә теге яктагы Калмаш урманы почмагына кистереп чыкканда юлыккан идек. Минзәлә районы белән ике арадагы межадан әллә ни ерак түгел иде.

Әҗер урманы куе — эченә ерып керәсең юк. Тоташтан яфраклы агачлар: юкәдер, зирек-усактыр, чикләвек куак-

ларыдыр. Кочаклаша-үрелешә үскәннәр. Йөзгә дым бөркелә, борынны юкә чәчәге исе кытыклап-кытыклап ала.

Кырыйлатып шактый күтәрелгәч, сулга каерылдылар. Сөзәк үр битендә өлгереп килгән арыш басуы салмак җилдә кыеклатып кына дулкыннар тәгәрәтеп ята. Аны тар гына ызан белән аркылы кистереп чыктылар.

Ләкин Калмаш урманы борынына таба сузылып төшкән һәм тез тиңентен үлән баскан ерганак-үзәннәрдә дә әллә ни уңмадылар: йә җиләге очрамый, йә, очраса да, җиләк яфракларына тикле тапталып беткән, хәерсез... Шулай да йөри-эзләнә торгач, бер төшкә, бүтәннәрдән ничектер аерылып торган һәм шулай ук сука-тырма тимәгән тар гына, җыйнак кына коры үзәнгә килеп чыктылар. Килеп чыксалар, хәйран аптыраштa калдылар: монда җир җиләгеннән келәм җәйгән кебек иде.

— Менәтерә: тырышкан табар, ди!

Берәр сәгать үттеме икән, юк микән, Рамиләнең бидоны түбәләмә тулды, иптәшенеке исә тула гына язды — яшь хатын, туймас тамак, әле һаман өч җиләкнең берсен авызына озатудан туктала алмый иде. Ниһаять, Рамилә дә булышкач, аның да савыты тулды.

Булды бу!

Бик канәгать йөз белән, җиңел-җиңел баскалап, урман канаты буйлата түбән таба сузылган чокыр ярына төштеләр. Чокыр эчендә күкрәк тиңентен үлән, кычыткан, чәбәләнеп беткән куаклар! Атлый-карана торгач, Рәмилә, ниһаять, чокыр эчендә бәреп яткан салкын чишмәне абайлап алды — бу минутта дөньяның иң кирәклесен...

Сап-салкын чишмә суы тешләрен камаштырды, кулларын куырды. Ләкин шифасын шундук сизделәр: сулыш алулары иркенәйде, буыннарына җиңеллек һәм сафлык кайтты.

Ипле генә өскә, урман куенына таба күтәрелделәр. Агачлар бу тирәдә сирәк иде, җирне куе һәм йомшак үлән каплаган иде. Ялгыз каен күләгәсенә утырдылар.

Монда инде, әлбәттә, бидон тоткаларына бәйләп куелган ризык төенчекләре чишелде. Тамак ялгап алгач, кулларын ян-якларга киң җәеп, чалкан яттылар.

Һавада бихисап шөпшәләр, бал кортлары безелди, салмак кына тилпенеп, иренчәк күбәләкләр очып үтә, чәчәкле үләннәрдән баш әйләндерердәй хуш исләр бөркелә. Төпсез күк зәңгәрлегеннән исә йомшак кына ак болытлар белән бергә купшы каенның яшел ябалдашы да җиңелчә айкала-бөтерелә, үз җаена йөзә сыман...

— Мила апа, безнең яңа поселок шушында булачак инде,— дип пышылдады Рәмилә.

— Шушында?! Кит аннан! — Людмила яткан җиреннән капыл торып утырды, әйләнә-тирәсенә күз йөртеп чыкты.— Әнә теге дулкыннар уйнаткан басу урынындамы?

— Әйе.

— Соң... соң... дөньяның бер оҗмах почмагы ич бу!

— Урынын тикшереп, тишкәләп-нитеп киткәннәр инде. Әле күптән түгел генә, җәй башындарак кына... «Шәп» дигәннәр, имеш.

— Мондагы төзүчеләргә, һай, рәхәт булыр да инде: ике яклап урман, яшел аланнарында чәчәктер, җиләктер... Чылтырап аккан чишмәсе тагын! Ә соңыннан яшәп ятулары?! Күз алдыңа китерәсеңме?

— Китермичә...

Рәмилә дә инде торып утырган һәм салам эшләпәсен тез башына каплап куйган иде. Беравык тын торгач, ул сүз сөрешен ипле генә үз җаена борып җибәрде:

— Мила апа, әйтче: кыенмы штукатур-буяучы булып йөрүләре? Үкендермиме?

— Ниткән үкенү булсын, ди? Дөрес, мин әле остарып бетмәгәннәрдән, шулай да... Көн дә саен синең артыңнан ялт иткән бүлмәләр кала, күңелдә көн дә саен бәйрәм! Ә үзебездә мин, дәүләткә мая туплыйм дия-дия, туеплар да беткән идем...

Тегендә, Витебскида чагында, бу яшь, мөлаем хатын почтада да эшләп караган, госстрах агенты булып та йөргән, ә соңгы ике елында сберкассада утырган икән. Җанына ятмаган, күрәсең.

— Ә төзелештә... ниме... яп-яшь кызлар да күпме?

Рәмилә, тынын кысып, көтә калды. Ул юлда килгәндә дә, җиләк җыйганда да менә болар хакында сорашмакчы булып сүз кузгатырга ниятләгән иде, әмма җаен китерә алмый йөдәгән иде. Инде хәзер, җае чыгып торганда, барын да ник төпченмәскә, ди?

— Күктән яугандай! Әле күптән түгел генә Воронеж ГПТУыннан ике төркем килде. Байтагының борын аслары да юньләп кипмәгән. Беришесенә әнкәсенең җылы куеныннан ычкынуы да ансат булмагандыр. Дөрес, арада ут уйнатканнары да җитәрлек, әмма бер төрлесенә ике дөнья бер морҗа дигәндәйрәк шул.

— Нишләп алай?

— Оеткылары сыек булгангадыр...— Людмила кулларын баш астына салып, янә чалкан ятты, күзләрен йом-

ды. Күкрәге авыр гына күтәрелеп алды.— Их, өйгә кайтып килсәң иде бер! Үлеп тә сагынам җан күбәләгемне — белсәң иде, Рамилечка!

Соңгы вакытларда ул шулай еш кына уфтангалар иде: тегендә әбкәсе тәрбиясендә калган өч яшьлек нәниен юксынуы көчәйгәннән-көчәя бара иде, ахрысы.

— ҚамГЭСка вагоннар күпләп килә башлаган, ди инде. Без дә язылдык язылуын. Тиз генә әләктереп булырмы каһәрне? Электереп булса, әнкәй белән Димочканы монда алдырыр идем, ичмаса.

— Соң, хәзер үк китерегез,— диде Рәмилә.

— Кеше өстенәме, сезне борчыргамы?

— Сыяр идек әле... Ә ниме...— Рәмилә ирен арасына үлән сабагы кыстырган көенчә, сүзен өзеп, чак кына тыелып торды. Кызның, әлбәттә, үз хәсрәте хәсрәт иде, түзмәде, сорап куйды:— Анда, ҚамГЭС, ахры, укытуөйрәтү пунктлары ачкан, ди. Ничә яшьтәгеләрне алалар микән? Уналтыдан ук түгелме икән?

— Уналтыдандыр... Туктале, сеңелем...— Людмила башын калкытты, аннары торып ук утырды да кызның иңбашына орынды.— Син чын-чынлап ниме әллә? Борын төбендә өлгергәнлек аттестаты... Әниең ни әйтер? Әтиең тагы?

— Ни әйтсәләр дә...

Кызның тигез кара кашлары җимерелде. «Бары бериш... Бер сүзне тукыйлар. Женя Мындага тикле... Сабыр ит, унынчыңны бетер, ди... Бар дөнья каршы... Ә күңел?»

Людмила Крутько, сүзнең мондыен артык тирәнәйтүдән өркеп ахры, кинәт кенә кулларын киң иттереп җәеп җибәрде:

— Ә урман искитмәле монда! Үзе гөмбәле дәдер әле, име?

— Гөмбәле... Тик без аны тибеп кенә йөрибез. Җыя белмибез.

— Нишләп? Гөмбә танымыйсызмы әллә?

— Әйе, бездә аны җыючы бик сирәк. Безнең бабай әйтә: урыс кешесе гөмбәне иткә тиңли, ди. Белмәем, әгәренки, ди, гөмбә иткә тиң булса, җыен татар урманга җабырылып җатар ие, ди.

— Кызык икән! — дип, урман яңгыратып көлеп куйды Людмила.— Ярар, яңгырлар явып, гөмбә генә чыксын. Тозлап-маринадлап та күрсәтермен, кыздырып та ашатырмын үзегезгә — телегезне йотардай итәрмен!

Кайтыр юлларына кузгалып, каенлыкны артта калдырганнар гына иде, бер төштә, яшь наратларга табан

сузылган аулак кына куенда, әйбәт кенә җиләклеккә тап булдылар. Рәмилә хәтта үзенең салам эшләпәсен дә тутыра язды. Әйе, өйләренә кайткач, авыз суларын китерердәй тәмле җиләкнең бер өлешен кәгазьгә төрер дә ян бакчаларының урам як почмагына яшереп куяр. Бу кичне дә Женя Мында клубка чыкмыйча калмас әле...

14

Әлбәттә, Рәмиләгә әнисе белән бер утырып сөйләшмичә һич ярамый иде. Һәм, әлбәттә, ибен-җаен китереп кенә...

Әллә ни озак көтәргә туры килмәде.

Бу җәйне врачларга бағылып йөрүенең, ниһаять, көтелгән нәтиҗәсе булды: әнисе ахыргы баруыннан бөтенләй җилкенеп кайтты. «Сәламәтлегең инде ярыйсы ук яхшырды, хәзер инде җиңелрәк эшкә керешсәң дә зыян итмәс»,— дигәннәр ди. Шул хакта әйтеп, кәгазь дә тоттырганнар кулына. Әнисе, билгеле инде, кайта-кайтышлый ук совхоз конторасына сугылып, анда әлеге кәгазьне җилфердәтеп кенә күрсәткән. «Бик шәп, алайсам, дигәннәр контордагылар да, кулларың аш-суга бик оста, механизаторларга аш пешереп торырсың. Булышчыларың итеп җегәрлерәкләрне куярбыз — үзеңә авырга килмәс. Кайсыбер көнне, уптым килеп төшсәләр, КамАЗ төзүчеләрен дә өлешсез итмәссез — өстәп пешерерсез»,— дигәннәр. Җитмәсә, озакламыйча, тап солдатларныкы шикелле, походный кухняга тикле кайтартачаклар икән.

Мондый хәлләрдә күңел үсмиме соң?

Кәефе ал да гөл булып йөргән көнне әнисе, олы мичне ягып, камыр ашыннан ни дә булса пешермичә калмый. Бүген ит бәлеше салырга уйлаган, ә бәлешкә хәтле янып торган мич кызуында, төчегә изеп кенә, коймак чыжлатырга тотынды. Аның шунысы да бар бит әле: ризык пешергәндә, аның тәмен-бәрәкәтен җибәрергә теләмәсәң, һичнинди ызгыш-талаш куптарырга ярамый, ди.

Бусы инде Рәмилә өчен алдан ук майлап куйгандай ич: димәк ки, әнисе аңа дуамал кубып ябырылмаячак.

Рәмилә сүзне ерактанрак, уратыбрак һәм чуалтыбрак башлады: иң әүвәл күрше авыл Гәрдәледән бер-ике кызны телгә алды, аннары үз авылларыннан бер иптәшенең чаялыгы һәм кыюлыгы өчен мактагандай итте, бары шуннан соң гына үз мәелен-теләген сиздерде.

— Чү, акылыңнан җаздыңмы әллә? Чаллы, ди, сиңа! — диде әнисе, капыл кабынып.

— Ә мин нием белән ким?

— Туктале, кызым... Соң син әле кайчан гына, унны бетерәм дә врач булырга китәм, дип, авыз суларыңны корытып йөргәниең. Ак халатлар киеп, үз кулларың белән мине — әниеңне дәваламакчы иең.

— Ә син сәламәтләндең бит инде. Справкаңны тиккә бирделәрме әллә? Аннары, былтыр әнә Рәмзи абый барып караган иде бит, керә алдымы бик? Һавадагы төтен генә бит әле ул безнең ишеләргә институтка барып керүләре...

— Синең башыңда төтен! Имештер, авылдан бер-ике укытучы гына чыккан да бер сыңар агроном. Ә ул, имеш, иң беренче врач булып кайтасы, и чәтнәби!

Рәмилә бәлешкә вак-вак иттереп бәрәңге турап утырган җирендә борын мышкылдатты, әнисенә таба өтәрдәй усал караш ташлап куйгалады. Әнисе мич кызуында таба-табагачлары белән шалтыр-шолтыр итә, коймак чыжлата, үзенең тавышы да чыж да пыж чыга:

— Кемнәр генә котыртты соң сине? Мила апаңмы?

— Нишләп? Котыртырга мин әллә...

— Теге кемең... Женя Мындамы? Молдаван «мыегымы»?

Кыз үткен пәке белән баш бармагын чак кына кисеп җибәрмәде.

— Син, әни, бигрәк инде...

— Бик сизәм мин! Үзенең кемлеген җүнләп белгән жук, ә син инде ул шәп мыек белән... Чамала, кызый!

— Тай типмәгән әле...

— Типкән шул! — Әнисенең кызарган йөзендә ялкын шәүләсе биешә, күзләрендә дә хәтәр очкыннар уйный иде.— Атасы-анасы кемдер... Үзе тагын... Тыштан гына җалтыравы түгелме икән әле ул тәти җегетнең?

— Белмәгән килеш бәйләнмә кешегә! Әтисе дә, әнисе дә эшче, ди. Үзе училище бетергән. Аннары Кишиневтагы механика заводында эшли башлаган... Һөнәр иясе, бик беләсең килсә! Кул осталыгын үзегез күрдегез ич. Сокланыплар туя алмадыгыз!

— Әһә, чынлап та әнә кем иләсләндергән икән лә синең башкаеңны! — Әнисе табагачын шалт иттереп идәнгә терәде.— Ичмаса, унынчыңны бетереп бетерсәң ие, тилекәй!

— Аны эшләгән көйгә дә бик бетереп була,— диде Рәмилә, суган әрчергә керешеп.— Анда, пажалысты гына, ди, әнә...

— Адәм кыяфәтен җуйган җыен сакаллы албасты арасынамы? Шушы җәшеңдәме?

— Миңа октябрьдә унҗиде тула инде... Ә ник бүтәннәр, синең кук, өркеп ятмый? Мәлифә түтиләр, Фәйзрахман абыйлар? Аларның кызлары бик ипле генә китеп барды бит.

— Ипле сиңа! Ни белән бетәсен, белгән җук әле... Бер дә бер көне кайтып керер иең бугай итәгеңә бәби кыстырып...

— Кермәбез... Ә син үзең соң... Унҗидедә... Ә мин кияүгә чыгарга уйламыйм да әле.

— Ышандырдың бик!

— Алай туарылырга кем нәселе соң мин? И әнкәй!..

— Булды, җитте дим! — Әнисе табагачын янә идәнгә шакылдатты.— «Ата кәҗәләнмә», зинһар!

Рәмилә иренен чәйнәде. Управляющий Гарапша авызыннан чыккан бу алама сүз, һәйбәт тиресле туфракка төшеп, инде тамыр җибәреп өлгергән, ләкин, Рәмиләнең бәхетенә, аны очыргаланып йөргән кыска итәкле бүтән кыз-кыркынга да әйткәлиләр икән авылда. Рәмиләнең күз төбенә бөрчек-бөрчек яшь бәреп чыкты, бераздан ул яшьләр аның янып кызарган бите буйлап түбән таба тәгәрәде. Суган әчесеннән генә булдымы икән?

— Кәҗәләнсәм соң...

— Әтиеңә әйтеп, арт сабагыңны бик әйбәтләп укыттырырмын әле менә!

— Укыттырсаң соң...

— Җиттеме-җукмы, дим! Кур, синең арканда монда... Ах, аллам, бер таба коймагым каралып ла көйгән! Бер таба коймак ни әле ул?

Сәерргәге, бөтенләй хикмәтлесе соңрак беленде. Бәләшенең йөзе дә һәйбәт килгән, исе дә бик тәмле таралган иде, әмма табынга куеп, тәмләп карасалар, күзләре шакмакланды: аңа бер бөртек тә тоз салынмаган икән ләбаса! Әтисе хәтта тоткан кашыгын читкә атып бәрде. Шулай булмый ни...

15

Дөнья тып-тын. Тик ара-тирә бик югарыдан, йолдызлар астыннан самолет кына гүелдәп үткәли.

Төн әллә ни караңгы түгел. Их, ул чак кына, ичмаса, караңгырак булсачы!

Рәмилә көтә. Берәүнең ян бакчага кереп ян тәрәзәне чиртүен көтә...

Гәүдәсендә дерелдәү... Килерме икән, юкмы икән?

Бүген күрә алмады: егетләр әле кайтып төшмәгән иде. Ә кичә бабасы Туры картка көянтә-чиләге белән «шифалы су» илткән җирендә, капка төбендә бер-ике сүз алыштылар үзе. Женя Мында әйтте аңа: «Чыгармасалар, килеп чиртермен»,— диде. Әллә Чаллыларыннан бөтенләй кайтмый калдылар микән? Анысы да булгалый бит. Юк, кайткандыр, килердер...

Менә атнадан артык инде чыгармыйлар. Әнисенең сүзе каты, әмере бер: «Җөрмә авылда күз көеге булып!» Әтисе дә трактор маенда каралган юантык бармагын өстәл читенә куеп: «Ыштубы!» — диде. Абыйлары барында рәхәт иде: аларга ияргәндәй генә йөрер иде. Мила апасы да Рәмиләне кызгана шикелле. Ләкин ни эшли ала соң ул мөлаем карашлы яшь хатын? Җилкә тарткалаудан уздыра алмый — чит гаиләгә катышырга хакы юк.

Җитмәсә, әнисе сүзнең әллә нинди ләрен ишетеп тора. Кайсы ләчтит сатучысы ташып өлгерә икән? Имештер, Чуар белән Калмашта да шәп кенә тәпәләшүләр булгалаган, ди; имештер, җыенысы шул «пумалабаш, шәрә сыйраклар» аркасында гына, ди. Ә бер көнне тагы юлда кайтканда, Әҗергә җитеп килгәндә генә, мондагы сакалбайлар да сакал йолкышкан, ди. Әйтерсең элгәрерәк, авылларын КамАЗ явы басканчы, егетләр арасында тәпәләшүләр булмаган да якалашулар ишетелмәгән... Егет-җилкенчәк булсын да, сөзешмичә, йон коймыйча гына йөрсен, ди синә! Чамасыз күпертеп, яман каралтып сөйләүләрен әйт син тагы!..

Чигә тамырлары даң-доң тибә дә тибә...

Гәүдәсендә вакыт-вакыт кузгалгалаган калтырауны да берничек тә баса алмый...

Гыйшык утында янулар шушылай буладыр, ахры...

Караңгы күктә йолдызлар җем-җем күз йомгалый...

Болында печән җыюлары рәхәт үзе. Ни алҗымасыннар, ни сусамасыннар — барыбер рәхәт! Онытылырга да җай... Анда уен-көлке дә ташып тора, сүзнең дә төрлесен ишетәсең. Өлкәнрәкләрнең телендә һаман бер нәрсә: «И хәзерге болынның җәме җәммени? Менә ул без җәшрәк чакларда! Их, кайтмас инде ул заманнар!» имеш. Ә өлкәннәрнең дә өлкәне исә шыңгырдауны гына белә: «Трактор белән кырыкканга чабыннарның хәтере калыр, ди. Чалгы белән җалап алуларга ни җитә инде! Торабара такырая тугайларыбыз»,— ди... Рәмилә мондый гәпләргә катышмый, күп нәрсәне белми дә, аңламый да —

күп нәрсә канына сеңми калган. Аның хәтта шалашта куныл ятуларның да рәхәтен татып караганы юк. Искитмәле, имеш!.. Ләкин шулай да болынга барулары, болыннан кайтулары чиксез күңелле. Иртән машиналарга чикы-чакы төялешеп китәләр, кичен төялешеп кайталар. Моның да иләсләндергеч үз яме бар ич!

Бүген болыннан андагы бар булган печәнне җыеп бетереп, җилләр җилләтеп кайткан чагында, әллә гәүдәсе, әллә җаны өшеп-өшеп куйгалады: бүген кич янә күрешә алырлармы, җае чыгармы? Аннары күкрәге эчендә нидер сулык-сулык итәргә тотынды: алдагы көннәре ничек булыр, кайларга җитеп терәлер?

Теге чакны, җир җиләге җыеп кайткан көннең җылы һәм тыныч кичендә, тыкрыкны байтак буйлап йөрделәр алар. Иркендә азаккы йөрүләре булган икән. Бермәлне, тәмле җиләге бетеп килгәндә, Женя Мында, аның иңбашларыннан кысып алды да кайнар сулышы белән өтә язып: «Инде хәзер җиләктән дә тәмлерәгенә... Йә инде, йә, дим, кара карлыгачым...» — дип, пышылдауга күчте. Рәмилә шул чакны капыл сыгылып төште, башын читкә борды. Бүген килеп тәрәзәне чиртсәме! Бүген Рамилә йөзен читкә бормас та әле, бәлкем...

Әнисе белән әтисе алгы бүлмәдә йоклый. Әнисенең йокысы бик тә сак, уяу — чак кына шылт иткәнеңне дә сизә. Шул сәбәпле Рәмилә көндездән үк, ачканда шыгырдамасын өчен, тәрәзә рамнарының тимерләренә май тамызгалаган иде, гөл чүлмәкләрен дә кая ничек күчерәсен чамалап куйган иде.

Ябынган юрганы калынрак булды ахры, тәне эсселәп бетте.

Күз кабаклары авырайганнан-авырая бара...

Әнә инде ян бакчада, балан төбендә микән, сайрар чикерткә, таң алдының якынлашуын сизеп тер, сызгырүын көчәйтә төште.

Югарыдан, йолдызлар астыннан ук, янә бер самолет гүелдәп үтте. Ни дип гүелди икән ул? «Җебемә! Канатларың шәлберәймәсен, кызый!» — дипме?

Килмәде, чиртмәде егет ян тәрәзәне...

Иртән торып, болдырга чыгып басса, көн янә чалт аяз: җылыдыр, кояшлыдыр. Рәмиләнең бер тын ара хәтта күзләре камашып торды. Ишегалдында әрле-бирле йөргән арада, капкадан әнисе кайтып керде. Кулында озын чыбык. Каз куып кайтышы. Чыбыкны койма буена ыргытты да, түргәрәк үтеп, аяк астында чыр-чу килгән тавык-чебигә җим сибәргә кереште. Әлегә ләм-мим сүз

катмады. Ләкин ул кызы Рәмиләнең юынгыч янынннан читләшүен генә көткән икән. Кыз бауда эленеп торган сөлгегә үрелгән генә иде, әнисе, бер дә искитәрлек нәрсә булмаган шикелле иттереп, тыныч кына әйтә куйды:

— Кичәгенәк Женя Мындаңны да дөмбәсләп ташлаганнар, ди, әнә...

Рәмилә куырылды да калды, хәтта кулындагы сөлгесе җиргә төшеп китте:

— Кемнәр? Кайда? Ни өчен?

— Мин каян белим! Тыкрыкта бугай... Искәртенеп җөрүе булгандыр. Авылда бер син генәмени пумалабаш! — Бусы инде Рәмиләнең бәгыренә туп-турылай хәнҗәр кадаган сыманрак яңгырады.— Җөрмәс үзе дә! Чит авылга килеп, койрык кысып кына утырасы урынга монда... Шәп мыек җибәрдем дигәч тә...

— Кемнәр икән, дим!

— Кем булса да... Беткәнмени авылда сугыш чукмарлары! — диде әнисе. Аннары, бушап калган коштабагын әйләндереп, кулы белән аның төбенә шап-шоп суккалады.— Мындаңның күз төбе бөтенләй күгәреп чыккан, ди, җодрык тикле, ди. Сугышканнарын үзебезнең Сабир күреп торган. Миңа әткәй әйтте...

Кызның күз алдында кояшлы көн капыл сүрелде... Ничекләй сорашырга инде? Әлбәттә, Туры бабасының күзенә күренү ярамас. Сабир, Сабир... Өендәме икән, әллә тырай тибүдәме? Кайда булса да, әнисе монда таутау эш өйгәнче, чыгып сызуың яхшы.

— Туктале, кызым... син кая болай? — дип эндәште әнисе капка тимере шылтырауга.— Җөрмә! Вахта машиналары әллә кайчан китеп барды инде аларның.

— Нишләп? Мин ни... бүген ял бит, берәрсе җиләккә бармас микән дип белешеп кайтмакчы идем... Син бигрәк!

Күршеләрендәге бер кызчыкны Туры бабаларына кертеп чыгарды. Ләкин Сабир әллә кайчан таярга өлгергән икән инде, келәт алдында, иске бишмәткә башын куеп, Туры бабай гына ятып тора, ди. Яшелчәлектә кыяр өлгереп килгән вакыт, Сабир, әлбәттә, шул тирәдә буталып йөри торгандыр. Кайчакны көпә-көндез, әмма каравылчы абзый чәй эчеп, аның ләззәтеннән, изрәп киткән мәлдә, кыяр җиренә кереп чыгуы уңайрак икәнен Рәмилә бик белә — үзенең дә элеккерәк елларда бакча басканы бер генә булмады.

Дөрестән дә, Сабир өч-дүрт малай белән шул тирәдәге чокырларның берсендә үләнгә төтен җибәреп ятуда

иде. Бүтән чак булса, Рәмилә, әлбәттә, аларның кесәләрен актарып, пыран-заран туздырып ташлар, хәтта «чуерташ» энекәшенең янгал чокырына да бер-ике кундырмый калмас иде. Әмма бүген алай итмәде, елтыр күзле «чуерташ»ны читкә дәшеп алды. Сабир алма апасының ник килүен бер сулыштан ук аңлап, ялындыруны бу юлы ничектер бөтенләй кирәксенмичә, төкерекләрен чәчә дә башлады:

— Соң... ничек дип... Киттек без әнә Зөлфәт белән Мында абай артыннан... Качып-посып кына... Нигәме? Соң, кичләрен үзең күренмәгәч, апа, кайсы нечкә биленә кыяләшергә чамалый икән бу, дип. Шуннан, Мында абай сезнең тыкрыкка борылган гына иде, бер заман ике шәүлә әллә каян гына килеп чыкмасынмы! И тотындылар, мин сиңа әйтим, бәйләнергә: «Опыттырырбыз без сиңа бу тыкрыкларны!» — дип...

— Кемнәр, дим? Ник әйтмисең?

— Һе, белми, имеш!.. Соң, авылның Игәч башыннан Әмир инде, тагын аларның кунак егете... Шуннанмы? Шунда Мында абайның ачуын чыгарма икән, Әмир абайга менә болай иттереп берне тамызып җибәргән иде, теге киртә артына ук очып барып төште. Аннары кунак егетен. Бусын читән буендагы кычыткан эченә сеңдерде!.. Вәйт ул самбоны белсәң, ничек икән! Тегеләр әпен-төпен тайдылар тизрәк! Билләһи, үзем дә өйрәнәм әле ул самбога! Мында абайның ирене канап чыккан иде чыгуын, аннары күз төбендә фонарь... и шулай да... ипидер, чәнчелдерде генә үзләрен!

Рәмилә, кичә төн ката йолдыз санап, көтеп ятты, ахырда, үпкәсен басарга теләп, юрган читен чәйнәргә тотынды, ә ул — аның сөйгәне — аларның тыкрык башында, бактың исә, әнә нигә юлыккан икән бит! Сабир-бытбылдыкның сүзе моның белән генә бетмәгән икән әле, менә ул, башын түбән иеп, шыңшынып куйды:

— Ә бүген иртән бабай Мында абайга дапрус ясады...

— Нишләп, анысы ни тагы?

— Соң, мин өйгә кайткач, барын да бабайга текмәтек сөйләп биргән идем, аңышмыйча.... Ә ничек сөйләмисең, ди? — Сабир башын күтәрә төшеп, күз aклары елтырап китте.— Икәвесен берьюлы әнә шулай әпен-чәпен туздырып ташласын да сиңа!

— Ишкәнсең икән, иләк авыз! — Бу минутта Рәмилә үзе дә малайның җилкә тамырына берне кундырмыйча чак кына тыелып калды.— Нинди «дапрус» дим?

— Соң ни... Иртән теге ике абай эшкә барырга дип капкадан чыгып китүгә, бабай Мында абайны тоткарлап калды. Имеш, йомышы бар. Келәткә керергә чакырды. Шуннан, Мында абай келәткә атлап кергән генә иде, бабай ишекне шалт иттереп бикләде дә куйды. Аннары ябыштылар инде.

— Нәрсә дип?

— Нәрсә дип, нәрсә дип... Бабай әйтә: «Син чынлап җөрисеңме, уйнап кынамы? — ди.— Менә хәзер көне буе җат инде уйлап!» — ди. Мында абай башта көлде генә, «Яшьләр эшенә, зинһар, кысылма, бабай!» — ди. Ә бабай үзенекен тукый: «Уйнап кына булса, бел, ди, безнең кызның бер бөртек чәче генә коелсын, ди, аяк-кулларыңны ботарлап, кояшлы Молдавияңә олактырмагаек»,— ди... Ярты сәгатьләп асрагандыр бик астында! Ахырда, Мында абай ишекне дөбердәтә башлады: «Прогул ясаттырсаң, өстеңнән протокол яздыртам, чамала!» — дип. Аннары инде бабай ачты ишекне: «Бәхетеңә, сәвитский карт без, ату...» — дип. Мында абай көчкә-көчкә генә вахта машинасына өлгергән бугай...

— Күр син карт гыйфритне!

— Аннары мин Мында абайны яклап ябышкан идем, бабай минем колакны борды: «Тыкшынма, башың җәш!» — дип. Шундый да авырттырды — өзелеп чыга дип торам. Ярар, үзен дә буш итмәм әле: пинжәк кесәсенә гөберле бака тотып салам әле мин аның, билләһи дим! Үзенә дә тыкшынмаска акыл булыр, име, апа?

Рәмилә, яулык очын авызына капкан көенчә, инеш яры буйлап атлады.

Ул Әмир-бичарага ни калган инде? Авыз тутырып сүзен әйтә алмый югыйсә. Рәмилә аңа ничәмә тапкырлар кырт кискән иде бит инде. Каян килгән кыюлык, каян килгән гайрәт диген ул җебегәнгә? Ә Туры бабасы? Шулхәтле үк кыланмаса соң! Әйтерсең үзенең яшь чагы бөтенләй булмаган...

Көн саен көянтә-чиләкләп колонка суы илтәсе үзенә. Бүген илтә барса, Рәмиләгә дә «дапрус» ясамас микән? Бер үк вакытта илтмичә дә ярамый: тагы әллә нинди шик-шөбһәгә юл ачылуы ихтимал ич...

Әлбәттә, Рәмилә кечке уңайда зифа буен сыгылдыра-бөгелдерә ике тыкрыкны бердән буйлап узды. Бабасы ишегалдында иде, «кһым», дип тамак кына кырды. Ләкин кыз, өйалдындагы эмаль чапчакка суны бушатып, мыштым гына чыгып барган чагында, бабасы аның көянтәсеннән эләктереп алды:

— Әһем... ни, кызым... Моңа чаклы китергән суларында, ипидер бал тәмнәре бар ие. Рәхмәт инде! Әмма ләкин бүген иртән, аннан кире төш турында, самавыр эченә ачуташ салгандай, китергән суың тамагымны бик тә җандырып, бик тә әчеттереп үтте. Болай булса, кое суына күчмәгемнәр...

Әнә шулай гадәтенчә кыек әйтеп туры бәрде Туры карт. Рәмилә ык-мык итеп калды:

— Сон... сон...

— Ипле җөре!

Тыкрыкта йомшак чирәм арасыннан сузылган сукмакка утлы күмер сибеп чыкканнар идемени — аяк табаннарына тикле янды кызның...

16

Бу көнне, бу сәгатьләрне зарыгып көтте Рәмзи.

Ике ел буе көтте...

Инде менә авыр һәм киеренке солдат тормышы артта, бик ерактагы Кавказ итәкләрендә торып калды.

Туган ягы белән күрешкән чагында, егет дулкынланмый калмаячагын бик белә, бик абайлаган иде. Ләкин Чаллы туфрагына аяк баскач, күңеле бу тикле үк чайпаланыр дип һич уйламаган иде.

«Камгэсэнергострой» идарәсенең кадрлар бүлеге инде хәзер әллә ничәү икән. Биш катлы таш йортның үзендә дә бар икән, аның аргы башындагы бушлыкта бер-берсенә сыенышып, тыгызланып утырган яшел һәм зәңгәр вагоннарга да сибелеп беткән икән.

Ләкин иң башта кайсына сугылырга, кем белән киңәш-табыш итешергә соң?

— Әһе, путевкасыз гына, димсең? Алайса, син, солдаткай, комсомол штабына керсәң, хәерлерәк булыр. Иң әүвәл биш катлы таш йортка! — диделәр аңа яшел вагоннарның берсендә.

Керде, чиратка басты.

Коридор тар, кысан, бөркү. Әрле-бирле йөреш, гөжтавыш... Кайберәүләр документларын барлый, икенчеләре бердәнбер өстәл кырыена кысылышып яки тәрәзә төбенә китеп, анкета тутырып азаплана.

Рәмзинең үз ишләре — фуражкалы, яшел киемле егетләр дә аз түгел. Тик иннәрендәге погоннар, күкрәкләрендәге значоклар гына төрледән-төрле. Матрослар да күренгәли. Бүтән халык исә бөтенләй чуар. Ләкин күбесе — аның тиңнәре, яшьләр...

Чират бик акрын бара. Стеналарга төрле игъланнар эленгән. Төзелеш алдынгыларына багышлап чыгарылган плакат-листовкалар тагы... Чү, шул кызыл каймалы матур листовкаларның берсендә аның абыйсы Айдаш түгелме соң? Нәкъ үзе! «Айдаш Хәнәфиевич Бариев» дип кычкырып тора симез хәрефләр! Аның үз бульдозерында кайда, ничек эшләве хакында кыска, әмма бик тә җылы һәм матур итеп язылган.

«Вәт, абый, ничек очрашасы икәнбез, ә?!»

Сурәте болай матур гына: тужурка якасын җилбәгәй салган да, чак кына көлемсери төшеп, туп-туры болай таба караган. Күзләрендә мөлаем нур, үз итеп, якын итеп карау. «Исән-сау кайтып җиттеңме, энекәш?! Әйдә, төкле аякларың белән!» — ди сыман абыйсы...

Ә иң аста эре кызыл хәрефләр ут булып яна:

«КамАЗ төзелеше ударнигына дан!»

«Дан-дан!» — монысы Рәмзи энекәшнең күңелендә даң-доң кыңгырау суккандай булып үтеп керде дә анда бер мизгелдә өермә куптарды.

Юк, чиратта бүтән тора алмады. Сулышы капканлыгын тойган хәлдә, урамга саф һавага чыкты.

Инде шактый күтәрелеп өлгергән кояш иләмсез кыздыруын белә. Аяк астындагы асфальтка тикле йомшара төшкән шикелле.

«Чулпан» кинотеатрының галәмәт зур тәрәзәләрендә фотовитраж. Төзелеш панорамасы... Солдат аны сокланулы карашы белән бердән иңләп чыкты. Ләкин кинәт көлемсерәп куйды: соң ул моны чынлыкта, тормышның үзендә күрергә, барын да айкап-гизеп чыгарга тиеш ич. Аннары инде үзенә дә шул заводларның берсендә җиң сызганасы булыр...

Гидротөзүчеләр урамы шактый ук чибәрләнеп киткән. Урамның ян якларында тротуар буйлата ямь-яшел газоннар сузылган, пөхтәдер, чистадыр үзе.

Солдатка кинәт бик җиңел булып китте. Аяк астындагы җирне тоймыйча диярлек, бер кулында көрәнсу чемоданын селкә-селкә урам белән түбәнгә Муса Җәлил проспектына таба җил-җил атлады. Ләкин бишәр катлы игезәк таш йортлар турысына җитәрәк, адымын әкренәйтә төште. Тегендә ике таш йорт арасындагы скверга аның ишләре — яшел киемлеләрдән тагын бер төркем килеп төшкән, җитмәсә, чуар киемле кызлар да күбәеп киткән сыман, тегеләре боларын, бал кәрәзенә сарылган умарта кортлары шикелле, сарып алган да гөр киләләр.

Иркендә бер рәхәтләнеп, сүз-гәп куертуларны таксыкламас димени солдат!

«Юк, комсомол штабы да, кадрлар бүлеге дә качмас әле. Иң башта туганнар белән күрешмичә, барын да уртага куеп киңәш-табыш итмичә ярамас. Ике абый завод коруда — алар кайда, ничек икәнен белми йөрмәс...»

Солдат кайта!

Иминлек сагын Кавказ төбәгендә калдырып, иңнәреннән җир шарын төшергәндәй бөтенләй бушап-җиңеләеп кайтып килә.

Каршысына тигез асфальт магистраль чаба. Колак төбендә җил ыжгыра...

Юлда машинадыр, машинадыр — выж да выж!

КамАЗ билэмэлэре!

Иңбашларына канатлар үсеп чыкканлыгын тоя сыман солдат...

Моннан берничә еллар элегрәк аның Айдаш белән Вәсим абыйсы да шулай канатланып кайтып килгәндер. Хәер, алар икесе дә Минзәлә юлы чатыннан җәяүләгәннәр шикелле. Рәмзи бик хәтерли: өлкән абыйсы кичен күз бәйләнгәч, бусагадан атлап кергән иде, аның өстебашы ап-ак кар иде, ә Вәсим абыйсы исә язгы чәчү бетәр-бетмәстә әче таң белән өй тәрәзәләрен чирткән иде...

Ә ул менә җәй челләсендә көпә-көндез кайтып килә.

Бик күп еллар әүвәл аның әтисе Хәнәфи дә шушылай җәй уртасында кайтып килгән иде. Аңа да ул чагында тап егерме яшь булган!.. Ләкин ул Чаллының үзеннән үк җәяүләгән кебек. Әйе, туп-турылай басу сукмагы белән атлаган. Аягында кирза итек, башында төсе уңган пилотка, аркасында солдат биштәре...

Ярты Европаны азат итеп кайтышы...

Хәзер дөньялар бүтән... Солдат булып йөргән ир-егетнең туган якларын сагынуы, сөйгәнен юксынуы, кайткан чагында иңнәренә канатлар үсүен тоюлары гына бер төсле дер. Хәер, бөтенләй үк бер төсле микән?

«МАЗ» кабинасында алар икәү...

Орловка авылы очындагы юл боҗрасын дугайлап үтүләренә Кама тарафларында еракка сузылган сөзәк үр кашында биек ак йортлар калкынды. Ак шәһәр... Ул җирдә түгел дә сыман — сыек рәшә эчендә күктә йөзә кебек... Ә каршы тарафта исә җирдән шактый күтәрелергә өлгергән ТЭЦ торбасы күренде, сул кулдарак яшеллеген җуйган һәм көрәнсу-кучкылланып торган бик

тә калын урман-чытырманлык абайланды. Ни икән дисә, болары туып килгән завод корпуслары лабаса!

Солдат тынын кысты.

ТЭЦ торбасы йомшак һәм мул яңгырдан соң капыл күтәрелгән таза саплы гөмбә шикеллерәк. Рәмзи әлегә берни белми, әмма соңыннан чамалар: «гөмбә» эшләпәсе күзгә күренми генә күтәрелә торып — торба аның саен үсә, күтәрелә барыр...

Шофер-сакалбай, газны киметә төшеп, сыңар кулы белән генә сигаретына ут алды да:

— Ике йөз дә илле метрга күтәреләсе, ди. Монысын бетерсәләр, янәшәдә тагын бер торба буласы,— диде.

— Эһе,— дип ияк какты солдат.

ТЭЦ торбасы дәвәеп-сузаеп ярыйсы ук якынлашкач, шофер машинаны капыл гына туктатты да:

— Миңа моннан уңга, стройбазага чаптырасы, ә сиңа, туганкай, тегеләйгә китәсе. РИЗ әнә генә,— диде.

— Аңладым... Бик рәхмәт сиңа, дус кеше!

Юлның ремонт-инструментлар заводы бөжрасын әйләнеп үтүенә, берәр попутныйга янә кул күтәреп ипле генә утырып китәрмен дә бик җәт кайтып җитәрмен болай булгач, дип куанган иде солдат. Ләкин кая ул! РИЗ янында шактыйга тоткарланмыйча һич булдыра алмады.

Чын-чынлап хәйран-тамаша икән лә аның туган як кырларында!

Ул киткән язда монда куәтле экскаваторлар зур чокырны казырга керешкән генә иде әле. Ә сузылып киткән бетон юлның дамбасын өяргә дә тотынмаганнар иде. Нибары әйләнә-тирәнең кара туфрагын гына, дөнья җимертеп, каезларга ябышканнар иде.

Ә хәзер... Актарылып-чокырланып яткан җир күкрәгеннән, син күр дә мин күр, бөп-бөтен завод калкынып чыккан бит инде! Иңлеге дә шактый гына, биеклеге дә шәп, озынлыгы да хәтсез... Инде зәңгәрсу-аксыл панель киемнәрен киенеп, түбәсенә көрәнсу-яшькелт шәльяулыгын да бөркәнеп алырга өлгергән. Көн яктысына көләчләнеп, күз явын алырдай нурлар сибеп карый!

Солдат тирән-тирән сулап куйгалады һәм сулышы белән бергә, каяндыр күкрәк төбеннән, ничектер, үзеннән-үзе соклану һәм дәртсенү авазы бәреп чыкты:

— Хәлләр диген!

Түзмәде, дамба кашыннан түбәнгә төште дә заводның иләмсез зур ишегеннән атлап керде. Юк, әллә ни айкалып-буталып йөрмәде — завод эчен алай тиз генә айкап чыгарлык та түгел икән — күзләрен тасрайтып бер

тирәдән генә әйләнде. Аңа беркем борылып карамады, сүз катмады — һәркем үз эшенә чумган, завод эчендәгеләр гомумән мәш килә иде. Әллә ни төрле, әллә ни хәтле машина-механизмнар! Беришесе туфрак тигезли яисә җир дөмбәсли, икенчеләре чокыр казый яисә бетон җәя. Аргы очтарак тип-тигез шомартылган бетон җирлеккә инде уйдык-уйдык тимер плитәләр тезеп яки агач шакмаклардан идән түшәп киләләр. Ә һавасында зәп-зәңгәр сөрем — аның моңарчы һичкайда да тоймаган ачы исе борыннарны яра, җитмәсә, һава үзе дә әледән-әле дерелдәп, селкенеп китә: даң да доң, дөмберт дә дөмберт!

Кабалану сизелми, әмма бик тә ашыгалар, күрәсең...

Солдатның күкрәгеннән янә ирекле-ирексездән сәер генә аваз сытылып чыкты:

— Монда инде бетереп тә яталар ич! Юк, бусы минеке булмас!

Кире дамба кашына күтәрелгәч, фуражкасын баш түбәсенә үк чөеп, әйләнә-тирәгә янә күз йөртеп чыкты.

Әйе, анык әнә анда тоташтан ялангач урман-чытырмандай булып күренгән көрәнсу-кучкыл корпусларның берсе булыр. Тик аңарчы барын да бер йөреп чыкмыйча, ибен-юнен капшаштырып карамыйча һич ярамас... Җәяүләп, тәпиләп!..

Шушы уен күңеленә киртләп куюына, солдат күз карашын янә РИЗ бинасына төшерде һәм... кинәт телен чәпелдәтеп куйды. Күрче, завод түбәсендә чатыр да чотыр мотороллерлар чабыша лабаса! Һәммәсе дә әрҗәле диярлек! Түбә ябучыларга тегесен-бусын китереп, ташып йөрүләре икән. Атланып алган кешеләре дә әллә кемнәр түгел, яшь-яшь кенә кызлар! Хәвеф-мазар дигәненә дә исләре китмичә, җифырт-мифырт тегеләйгә дә элдертәләр, чатыр-чотыр болай таба да куышалар. Һавада тик алакола яулыклары җилферди дә кайсыберенең чәче тузгына... Менә сиңа шәрә сыйраклы нәзкәй билләр!

Чаллыда кадрлар идарәсе урнашкан биш катлы йорт тирәсендә буталып йөргән чагында Рәмзи солдат чырык-чарык көлешүдән бушый алмаган сыек сеңерлеләргә сәерсенебрәк, хәтта шикләнебрәк тә күз аткалаган иде. Аларның беришесе, әлбәттә, түзә алмыйдыр, як-якларга чәчеләдер, сибеләдер, әмма, бактың исә, аларның мондыйлары, завод түбәләрендә шушылай тыз-быз чабып-очып йөрүчеләре дә, шул ук «чикы-чакы» килүче чибәрләр өереннән күтәрелеп чыга бит!

Һай, җилдертәләр дә соң! Күз тиеп, түбәнгә деңгердәтмәгәйләре тагы!..

Рәмзи күзләрен йомды һәм шул йомудан, томан эченнән калкынып чыккандай рәвештә, күз алдына сөйгәне Язилә килеп басты. Әйе, өзелеп сөйгәне... Ә ул? Кыйгач кашларын югары чөйгән дә кара күзләрен зур ачып, шикләнү, хәтта куркыну аша карый кебек... РИЗ түбәсендәге житез, кыю кызлар шикелле эш җимертә алыр иде микән? Әллә, чыдый алмыйча, ятьрәк койрыкны сыртка салып, читкә элдертү ягын карар иде микән?

«Их, Язилә, Язилә, ник суындың, нигә дип араны өздең син, каһәре... Иң кирәк чагында...»

Солдатның кул күтәрүенә беренче килеп чыккан КрАЗ ук, авыр пошкырып һәм юлда тузан болыты куптарып, капыл гына тукталды.

Кабина ишеген ачып, күтәрмәсенә менеп баскач та, солдат РИЗ түбәсенә тагын бер тапкыр күз төшермичә булдыра алмады: янәсе, бар да иплеме анда, хәлләре ал да гөлме, янәсе, солдат кисәге саулык, хәвефсезлек тели сезгә, күбәләккәйләр!..

Менә инде каршысына туп-туры һәм тип-тигез бетон юл тагын чаба.

Дөньяның иминлек сагыннан туган авылына кайтып килә шулай егет...

Меңнәрдән берәү...

17

Менә инде җәяүләп атлый.

Менә инде Шилнә инеше дә, аның аша салынган яртылаш җимерек иске күпер дә артта калды.

Тыкрык. Балачагында ялан аякларын аз чебиләндермәде бит шушы тыкрыкта. Үз сукмагы! Кырыйларында чирәм әле дә куе.

Читән асларындагы кычытканлыкта чикерткәләр бүген дә сайрый...

Ә бакчаларында, күр инде, бәрәңгенең яфрак-сабаклары, дымга тилмереп, шәлберәеп калган. Шомырт белән карама ябалдашларында да яфраклар шәлберек...

Әмма бәрәңге бакчасының, шомырт агачының әчкелтем-татлы исе — сагынылган, тансык ис! — егет күңелен, тирәннән айкап, кытыклап алды...

Дөнья тып-тын. Һава әлсерәткеч кызу...

Менә инде Ас тыкрыкны да үтте. Менә хәзер Түбән урамга кереп борылса, үз тыкрыклары китә.

Таныш өйләр, каралты-куралар, коймалар... Сагындырган тынлык. Зарыктырган туган авылы һавасы...

Чиксез куанычыннан, дәртле ашкынудан солдат күкрәгендә илаһи бер дулкын купты, егет хәтта сулышы капканлыгын аермачык тойды...

Адымнары нык, адымнары саллы...

Үз тыкрыгы... Ләкин шуңа борылып китәм дигәндә генә, тыкрык чатындагы бәләкәй генә өйнең сыңар капкасы кинәт кенә ачылып та китте һәм аның ачылып киту шаена үк кемдер бер чүмеч салкын суны солдат өстенә тондырып та җибәрде.

— Син нәрсә?!. Син...

Солдат кулъяулыгын чыгарып, битен-муенын сөртештергәләгән арада, су сипкән адәм ак чүмече белән бот шәпелдәтергә тотынды:

— Һай аллам, син икәнсең бит! Үзебезнең күршегенәсе икән бит! Исән-имин кайтуларыңмы?

— Әйбәт... Ә син, җиңгәчәй, шәп каршылыйсың мине, ә! — диде солдат, авызын усал кыйшайтып.

— Соң... ни бит... җаңгыр җаумый бит... Син ни инде, зинһар. ... Үзем тилемсә... Бактың исә, үзебезнең солдат тансыгыбыз икән лә...

— Ярый-ярый, җиңгәчәй, зыяны юк.— Солдат кагынды-сугынды да кинәт көлеп куйды:— Югыйсә, кайта-кайта әлсерәп беткән идем. Аның суы да үзебезнеке бит, җиңгәчәй, име!

— Әйтмә инде! Ә сезнекеләр ни бит әле, өйдә җуклар.— Күрше хатын шул чагында гына, исенә килеп, оек керешенә кыстырылган күлмәк итәген капыл төшереп җибәрде, башындагы алсу чәчәкле яшел яулыгын төзәткәндәй иттерде.— Капка тоткагызга да таяк кыстырмалы.

— Кайда алар?

— Соң кайда булсын,囲 эштә инде. Әниең җәшелчәлектә аш-су пешерүдә, әтиең басудадыр. Анда бит ни... басуга су сиптермәкче булып җәфа чигәләр. Туктале, тукта, әнкәеңнең солдат улкае кайтып җатсын да монда...— Җиңгәчәй кулындагы ак чүмечне, җәһәт кенә селтәнеп, ачык капкадан ихатасына ыргытты.— Иң әүвәлтен текер-текер барып, әниеңнән сөенче апкайтаем әле, күгәрченем!

Инде «текердәтергә» җыенган апаңның күлмәк җиңеннән эләктерәп алды солдат:

— Тукта, сабыр ит, Фәгыйләттәй! Мин үзем иплэп кенә... Югыйсә, әнкәйнең котын алып, йөрәген ярырсың — беләм мин сине...

— Нишләп инде? Җөрәге дигәч тә... Хәер, йомшак инде анысы йомшаклыкка... Айсам...

— Кайгырма, жиңгәчәй, буләктән буш итмәбез! — дип елмайды егет һәм кулындагы чемоданны ихатасының капка почмагына кертеп куйды.

— Бар, айса, күршегенәсе, бар үзең... Әниең теплицадан җырак түгелдер, инеш буенда гынадыр. Син аннан әйләнгәләгәнче үзем самавыр яңарта торырмын... Һай, әттә генәсе, әле кайчан гына киткән иең — үтә лә гомеркәйләр! Берүк җаңгыр апкайтуың булсачы, гөлкәем!

Солдат, билендәге киң каешны ике куллап алдан артка таба сыпырып алды да, урам кырыйлатып, җил-җил түбән очка таба юнәлде.

Атлар җире алай ерак түгел иде.

Менә инде совхозның мастерское, машина-трактор утары, аның арт коймасына тоташып ук диярлек яшелчә бакчалары җәелеп китә. Сул кулда Шилнә буендагы киң генә ачыклыкта янә төрле машина-механизмнар тезелешкән: тырма-сукадыр, культиватор-чәчкечтер. Болары коймасыз-нисез генә — үзе бер табор! Арырак, каршы якта, киртләч-киртләч түбәле һәм һәрьяклап ялтыравык полиэтилен белән ябылмалы киң дә, озын да корама — Фәгыйләттәйнең «теплича» дигәне, әлбәттә, шулдыр. Әле кайчан гына анда сусыл чирәмле зур гына тугайлык иде — кичләрен көтү кайткач, сыер-сарык ише малны бермәл ялмандырып алырга бик тә уңай иде. Бетергәннәр икән...

Болай табарак, һәрьяклап кысылган чирәмлек уртасындарак исә, куе-яшел төстәге вагон кукраеп утыра. Аның түбәсенә кызыл әләм элгәннәр, ләкин ул, җил әсәре булмаганга, әз генә дә җилфердәми — сәлперәеп төшкән. Вагон тирәсендә агач өстәл, эскәмияләр тезелеп киткән — монысы, әлбәттә, дистәләгән кешенең табын урыныдыр. Чак кына кырыйдарак, кара морҗасыннан зәңгәр төтен бөркеп, походный кухня тора, аның күтәрмәсенә берәү менеп баскан. Башында көрәнсу яулык, өстендә кыска җиңле саргылт-яшел күлмәк, ак алъяпкыч... Һе, кем булсын, әлбәттә, әнисе! Әмма ул, яны белән басканга күрә, җил-җил атлап килгән солдатны күрми дә, сизми дә, озын саплы чүмече белән олы казанны болгатуын белә иде. Аңардан ерак та түгел такыр башлы бер абзый, соры эшләпәсен аяк астына чирәмгә генә ыргыткан да, утын ваклап азаплана. Солдат аны шундук танып алды: «Мәттин агай... Ярата да инде җәйләрен казан тирәсендә кочегар булып йөрүләрне...»

Кочегар агай балта чапкан яркасын иңенә күтәреп, җирдәге тумранга шәпләп ормакчы гына иде, кинәт шул хәрәкәтен өзеп, тораташтай катып калды, күзләрен челтмелт йомгаладь, авызын җәйде, һәм аңардан яшелле-зәңгәрле аваз сытылып чыкты:

— Кһы-һы... Кһем!

Әнисе Рәсүлә әллә шул авазны ишетте, әллә күңеле сизенде — ялт кына болай таба борылды. Борылуына, өнсез калды ахры, агач саплы чүмече казан эченә чумды, үзе ике кулын да муен төбенә китерде һәм кисәк, үткен чалгы тиеп үткән болын чәчкәседәй, яшел фуражкалының өстенә ауды:

— Һай, улым!..

Сулышын тиз генә кайтара алмады, кытыршы бармаклары белән егетнең битен-муенын, чәч араларын капшаштырырга тотынды — яшел фуражка җиргә төшеп тәгәрәп китте...

— Һай, улым! Көтә-көтә көтәкләр булдык ла инде, улым! — Ананың кояшта каралган йөзе буйлап яшь бөртекләре тәгәри, тавышы басынкы сулкылдау аша сыныпсынып чыга иде.— Өс киемеңне дә җүешләтеп өлгергәннәр икән...

— Соң, күрше җиңгәчәй Фәгыйләттәй инде...

— Булыр, булыр... Бу эсседә капкасы төбеннән үткәнсүткәнне көннәр буе сагалап кына тора. Җаңгырлар җаумый бит, җаңгырлар! Ә син болай ни... тазарыплар да киткәнсең...

Ана белән улның назлы-иркәле күрешү хәле алай да озакка сузылмады, яннарында, карлыкканрак, әмма бик тә җылы тавыш ишеттеләр:

— Җә, күрешиек әле бер! Инде дә мактап кайтуларың, билләһи, тап пешкән аш өсләренә иңеп төштең лә!.. Исән-имин генә димсең алайса... Җарый-җарый! — Солдат ике куллап күрешкәч, Мәттин агай, кызгылт йөзендәге бар җыерчыклары белән балкып, хан заманыннан калган соры эшләпәсен һавада киң иттереп изәп алды.— Ә дөнҗалар, шөкер, киңдер, матурдыр! Ием, хикмәтледер дөнҗалар бүгенгесе көнне!

Агайның киң селтәнеп күрсәткән «хикмәтле дөнҗасына» солдат иркенләп күз салырга өлгермәде, каяндыр — әллә яшел вагон эченнән чыгып, әллә Шилнә буеннан менеп, аның каршысында ак алъяпкычлы яшь кенә бер кыз пәйда булды:

— Исән-сау кайтып җиттеңме, Рәмзи абый! — Кызыйның тавышы саф, матур яңгыравыклы — якында гына

талир тәңкәләр чылтырап алдымыни? Ә зур коңгырт күзләрендә исә кояш үзе чагылып китте сыман. Менә ул мөлаем елмаюын сүрелдерә төшеп, сул кулы белән ак яулык очына орынды, уңын егеткә сузды һәм кинәт пышылдауга күчеп, әмма тәҗрибәле өлкән апаларча иттереп, әйтә салды:— Инде бәхетле сәгатьләрдә кайтып төшүләрең булсын!

Аның йомшак кулын кыскан чагында, егет бар гәүдәсен эссе дулкын яндырып үткәнлеген тойды. Хәер, бу мизгелдә кызыйның да сөйкемле түгәрәк битендә сирәк сипкелләренә тикле бүртенеп һәм кабынып киткән сыман иде. Солдат тотлыгып калды:

— Рәхмәт җылы сүзләреңә... кем... ни...

— Хәтирә...— дип пышылдады кыз.

— Рәхмәт, Хәтирә! — Солдат аңа янә күз тутырып карады һәм, нәфис чәчкәгә җылы тынын өргән сыман иттереп, бөтенләй үз күреп, әйтә куйды:— Менә инде син дә, сеңелем... Авылыбызның суы да, һавасы да бигрәк шифалы шул!..

Чак кына читтәрәк әнисе Рәсүлә басып тора, аның кояшта янган карасу йөзендәге җыерчыклары язылып киткән, әмма күзләре һаман да дымлы һәм шул дымлы күзләренең сүрелмәс нурлары белән улына карап туя алмый иде. Солдат белән кыз арасындагы җылы һәм мөлаем сөйләшү дә аның колагына бөтенләй эленмәде шикелле. Юк, тыңлап торган, ахры:

— Булышчым...— дип пышылдады ул кинәт, йөзен тагын да балкыта төшеп.— Мактавым булсын: инде дә уңган, инде дә җылгыр — күзләр генә тия күрмәсен!

Бу сүзләрдән кыз тәмам ялкынга уралгандай булды һәм иңнәренә сибелеп төшкән коңгырт чәчен артка таба ыспай гына сирпеде дә текер-текер яшел вагонга кереп китте. Берәр йомышы булдымы анда, юкмы — үзе беләдер. Солдат кесәсеннән шакмаклы кулъяулыгын чыгарып, маңгаен, муен артын сөртештергәләде. Эсселәп, тирләп китүе көн кызуыннан гына булдымы икән?..

Менә ул, капыл гына әнисенә таба борылды да сулышы капкандай, ашкынып сорап куйды:

— Әни дим, әти ерактамы? Кай тирәдәрәк?

Әнисе, кулын кашлары өстенә менгереп, басу ягына төбәлде.

— Әнәтерә, күрәмсең, су сиптерәләр? Җук, җәшелчәлектәгесе түгел, арырак... Культуралы ни нәмәрсәгә инде...

Солдат кинәт кабалана башлады:

— Алайса, әни, су гына эчим дә... Салкыны булса...

Ана кеше таралып киткән зиһенен шул чакны гына җыя алды, һәм, улын да уздырып, кызуланырга тотынды:

— Ниткән су ди сиңа! Сусының бик кузгалган булса, әнә бидон белән компот пешереп куйдым.— Шулай дип ул агач өстәлнең бер очында күләгәдә торган олы ак бидонга ишарә ясады.— Камазчылар бик тә җаратып эчә... Кайта-кайта карыннарың да ачыгып беткәндер инде. Иң әүвәл ныгытып тамак туйдырмаска монда!...

Аны куәтләп Мәттин агай да гүелдәп җибәрде:

— Әтәең белән дә барып күрешерсең әле, дөнҗаң җанмый — ризыктан өстен булырга җарамый.

Рәмзинең эчендә, әлбәттә, күптәннән инде бүреләр улый, әмма аның алай бик үк сынатасы да килми иде.

— Кая, Рәмзи абый, кулларыңны да чайкаштырып алсаң бер...

Чак кына читтәрәк, вагон почмагындарак, чирәмдә Хәтирә көтеп тора икән, аның кулында суы мөлдерәмә тулган ак чүмеч, иңендә ак сөлге.

— Була гына, сеңелем!

Агач өстәл янына кире әйләнеп килүенә, ни күрсен, әнисе эмаль тәлинкәдә куе өйрәле ашны инде китереп тә куйган. Шунда ук чынаяк тәлинкәсендә тоздыр, ипи телемнәредер.

— Әйдүк, улым, әйдүк!.. Үз өебездә булмаса да, барыбер үзем пешергән ризык. Инде тансыклагансыңдыр?

— Тансыкламыйча...

Ләкин, ул да түгел, «җылгыр» Хәтирә — вагоннан алып чыгып, ахры, солдат каршысына бер табак яшел кыяр китереп куйды, пышылдап, әмма балкып әйтте:

— Шундый да тәмле — авыз суларын китерә!

Бу хәлдә Мәттин агай да читтә каңгырап калырга теләмәде, тамагын кыргалап алгач, ятьрәк аныклык кертергә тиеш тапты:

— Кыярны болай май урталарыннан ук өлгертә башладылар үзе, рәхәтләнәбез. КамАЗ төзүчеләренә дә хәтсез генә озаттылар... Май уртасыннан кыяр ашый башла әле! — безнең җакларда хикмәти хәл булмый ни!

Һәм ул коры сүз белән генә дә калмады, пешерү остасыннан рөхсәт-мазар да сорап тормастан, агач өстәл уртасында торган тастымал япмалы олы коштабакны ачып салды, аннан иң әүвәл кайнар бу болыты күтәрелде һәм шуның артыннан ук... Мәттин агайның уң кулында йодрык чаклы симез ит калҗасы күренде.

— Кинән, улым! Аш булып үтсен!..

Солдатның авызы бик киң җәелеп киткән иде, ул аны капыл җыя төште, шулай да көлемсерәвен һич тыя алмыйча, баш селеккәләде:

— Син нәрсә, Мәттин агай? Бу хәтлене... кеше өлешенә кереп...

— Ниткән кеше өлеше булсын?! — Агай өргәләнә-пошкырына үткен пычак белән кайнар ит калҗасын ваграк кисәкләргә тураклап ташлады.— Син кайда булдың? Әһеме, ил сагындамы? Иминлек хакына утка керергә дә, бозлы суга чумарга да әзер булыпмы?.. Кеше өлеше, имеш! Дувай дим, сыпырттыруыңны бел ипле генә!...

Әле алай гынамы, бер юмартланырга тотынгач, беткәнче булсын диптер инде, Мәттин агай кызган канын суындырмыйча, кабаланып, соры пиджагының ян кесәсенә тыгылды һәм аннан кәгазьгә төрелгән бер нәмәрсә тартып чыгарды. Сүтеп җибәрсә, кызыл эшләпәле җыйнак кына, матур гына борыч савыты икән.

— Мәле... Кара борычымны үз кешеләр өчен генә җөртәмен... Сиңа жәл түгел... Сиптер мул иттереп!

Солдатка бик рәхәт, бик күңелле. Алдында куе өйрәле тәмле аш, аңардан кайнар бу белән бергә лавр яфрагы һәм кара борыч исе бөркелә, моңа тагы симез калҗа исе белән җиңелчә төтен әчесе дә өстәлә, һәм, бары бергә кушылгач, борынны гына түгел, күңелнең үзен кытыклый иде. Ә үз итеп, үтә якын күреп сөйләшүләре, төрле кыланышлары?

Менә аның янәшәсендә әнисе басып тора һәм, кояшлы яз куенында матур гөрләгән күгәрчен сыман, үз җаена, ипле генә сөйләшүен белә:

— Кичке уңайда өйгә кайтып, олы мичне җагып, ит бәлеше салып җибәрермен. Аннары тагын тавык суярбыз. Мунча да җагарбыз. Бүген дә шәт абайларың Чаллыда җатып калмас, мотоциклларында выжлатып кына кайтып төшәр. Кич утырырга Туры бабаңнарны да дәшми калмабыз.

Туган ягына кайтып, туган туфрагына аяк баскач, мондый сүзләрне ишетәсең инде анысы. Әмма солдатны моңарчы үз авылында беркайчан да күрмәгәне, күрү түгел, һич уена да китерә алмаганы да көтә икән. Бермәлне башын калкытыбрак күз салса, исләре китте, хәтта авызына китерәсе кашыгы ярты юлда тукталып калды: тегеннән, яшелчә бакчасының коймасындагы киң генә ачыклыктан, төркем-төркем хатын-кыз чыгып килә иде.

Үзләре, җитмәсә, анадан тума диярлек шәрә: өсләрендә нибары трусик та лифчик... Беришесе кием-салымын култык астына кыстырган, беришесе, гәүдәгә тазарагы, купшырак күкрәклесе, дөрес, өске ягын кофта яисә яулык белән каплый төшкән. Ләкин арада зифа сынлылары, яшьрәкләре күбрәк иде.

Мәттин агай инде хәзер авызына кура җиләге кабып, аны суыргандай кыяфәт алды:

— Хур кызлары... Ике автобус бүген... Күр син кәскәс атлауларын, чикы-чакы килүләрен, күр син теге ни...

— Тагын җабыштыңмы, тагынмы? — Солдат энисенең тавышы кинәт усал чәрелдәп яңгырады.— КамАЗның шул шәрә җен-пәриләренә кызыгып чинамасаң соң, өрәк! Туйдырдың инде, валлаһи!

— Тавышыңны саклый күр дим, сеңелкәем! Бу эсседә артыгын алҗыганнар, ахры, сылукайлар... Әйтмә инде, шундыен нечкә билләргә яшелчәлектә чүп утаталар бит! Атна эчендә кара чуен төсләренә кергәннәре дә байтак күренә, энәтерә. Әрәм, әрәм! Беришесен кантурда кәртинкә итеп кенә тотасы җугыйсә... Җитмәсә, син дә, сеңелкәш, чибәркәйләрне шул шәрә көенчә табын янына якын да китермисең, җәл, җәл...

— Китерде ди, табынның җәмен җибәреп монда!

— Их, җәш чаклар бер әйләнеп кайтса ие! Арада шундыйлары буладыр ие, бер җандырып караса — көл буласың, тел әйләндереп берәр сүз әйтсә — җиргә сеңәсең! Сайласа да сайлый белер икән КамАЗ дигәннәре нәзкәй билләрнең кәттиләрен, ә!

— Җиттеме сиңа?! Җугыйсә, менә аш чүмече белән орып, баш пеләшеңне чәрдәклим бит, Әҗер карачкысы!

— Син миңа, сеңелкәем, тимә дә, орынма да! Мин синең белән түгел, солдат улың белән солдат булып сөйләшәм... Җегетләрчә!

— Син дә җегет булдың тагы — үләрсең! Җитмәсә, энисе алдында...

— Эни кешегә җегетләрнең хәлен җакыннан белеп торуның гөнаһысы җук, диләр, энәтерә — исеңдә тот, җәме! — Мәттин агай эшләпәсен кырын салды да, мут елмаеп, солдатка ым какты.

Егет, энисеннән уңайсызланганга, сүз катмый, ул хәтта КамАЗ чибәрләре ягына карамаска да тырыша, ләкин кашыгын иплә генә йөрткән чагында, «гөнаһлы» тарафка күз атмыйча да булдыра алмый иде.

Мәттин агай, бер аягы белән усак түмәркәсенә бас-

кан килеш, кипшергән иреннәрен ялаштыра-майлаштыра һаман да тел тегермәнен тартуында булды:

— Тиккә генәме әллә абзагыз, һәр иртә саен кулына үткен пәкеләр алып, җаңак-иякләрен көзгедәй иттереп җалтыратып җибәрә, ә? Карчыгым, җәгъни сез бик әйбәт белгән Шәмсениса апакаегыз, тәмам шаклар катты инде: «Ниндәен хикмәти хода булды инде ул җәшелчәлек?!» ди...— Мәттин агай кинәт муенын сузды, аягын тумраннан алды һәм үтә зур мәгънә белән баш бармагын һавага чөйде: тегендә хатын-кызлар төркем-төркем үтеп беткән, инде хәзер инеш буасы ягыннан көклеяшелле авазлар яңгырый башлаган иде.— Ишетәмсең: иһаһай да миһаһай — чумалар, кинәнәләр! Әллә, дим, үземә дә кып-кыска трусикны гына киеп җибәреп шул чибәркәйләр арасына барып чумасы инде, ә?..

Хәтирә өстәл башында савыт-саба кыштырдаткан җирендә тыела алмыйча, пырхылдап көлеп җибәрде һәм иелә-сыгыла яшел вагон артына элдертте.

Рәсүлә дә, сынын бөгеп, ике куллап касыгына ябышты:

— Һай, аллам, Мәттин... Мөхәммәттин абай... шакыраеп торган кабыргаларың белән ап-ак өрәк булыпмы? Синнән хатын-кыз түгел, буабыздан бакалар качар бит! Һай, имгә-томга да калмас бит!..

Мондый гына шомлы кисәтүгә сыңар керфеге дә селкенмәде кебек, үзенекен сипли торды:

— Шәмсениса апаегыз бүген иртән әйтә әле, бахыр: «Инде билләрем дә җазылуга табан китте, күкрәкне дә, шөкер, тартыштырмый, әллә ди, үземә дә җәшелчәлегегезгә барып тотыныргамы соң ди, ичмаса бер җәшлектә, бер картлыкта булыр ие», ди. Кһы-һы! Минем карчык көнләшү ачуыннан бер җарсынып җабышсамы?! Аңа ияреп авылның бүтән карт-корткасы тагылсамы? Билләһи, дим, бөтен КамАЗыңны җәшелчәгә күмеп китмәгәйләре!

Мәттин агай солдат янына эскәмиягә килеп утырды, аякларын чәнчеп куйды. Аның сулышы сизелерлек булып авырайган иде. Бермәл тын гына утыргач, терсәге белән солдатның янтыгына орынып алды:

— Анысы да монысы, кайры тунның җылысы дигәндәй, син дә, солдат улым, дускаем, җиңнәреңне сызганып, хәләл көчләреңне түгәр урын эзләми җөрмәссең. Читкә-чатка каерылма диюем! — Агайның йөз чалымында да, тавышында да инде хәзер шаяртуның исе-әсәре дә калмаган, ул кинәт кенә бөтенләй бүтән кешегә әверел-

гән иде: уйчандыр, житдидер кыяфәте...— Бүгенгесе көнне бу дөнҗаның оҗмахы ук димим, әмма ләкин синдәй җегеткә иң кулай урын бер дә әллә кайда түгелдер, тап үзебезнең авылда, авылыбызның да җәшелчәлек дигән басу иңнәрендәдер... Шәт, махы бирмәс иең, ә?

Рәсүлә сагая калды.

Күр моны, шуклана-мутлана торгач, егетне ипле генә кая китереп терәде тел бистәсе карт төлке! Юк, Рәсүлә үзе дә, ире Хәнәфи дә, күңел түрләрендә андый сорауны сакласалар да, төпчек улларына болай ук капыл орынырга җыенмыйлар, бер көн, ике көн, хәтта атна буе сабыр итәрләр иде әле. Ә Мәттин агайга нәрсә — үз улымыни? Аңа дисән, ике дөнья — бер морҗа лабаса!

Ләкин инде сорау-киңәш бирелгән, күкрәккә искәрмәстән очлы сөңге китереп терәлгән сыманрак — боргаланырга һич җай калдырмыйча, бирелгән. Җавабы ни булыр?..

Егет исә ак димәде, кара димәде, кашларын җыерды, әмма шуның арты ук аларны язып та җибәрде, елмайгандай иттерде. Аннары торып басты. Тәмле аш-сый өчен рәхмәтен әйтте. Тагын уйчанланып калды һәм кинәт өстәлдә яткан җыйнак кына бер тастымалга үзеннән артып калган бер-ике ит кисәген салды, өстенә тоз сибеп җибәрде, ит янына тагы ипи телеме белән кыяр кушып куйды.

— Әтигә,— диде.

— Һай, улым! — Ана кеше, капыл исенә килеп, кабаланырга тотынды.— Тукта, алайса, капкачлы банкыга компот та салып җибәрием...

Менә инде илтәсе ризык күн букчага да тутырылды. Солдат китель итәген тартыштыргалап, төзәткәләгәндәй итте дә фуражкасын кырынрак салып, кулына букчаны алды һәм:

— Анда алай озак батып ятмам, әни,— диде. Аннары яшелчә бакчасының коймасындагы ачык арага таба юнәлде.

— Минем сүзгә җавап та кайтармады...— диде Мәттин агай тирән көрсенү аша. Ул тез капкачындагы олы ямаулыкны сыйпаштыра, үзенең кара-кучкыл буынтыклы бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый да сыман иде.— Җарар, җегет кеше үз җаен белми җөрмәс. Нәселе ул түгел...

Солдат анасы Рәсүләнең күзләре янә дымланган иде, аның да күгелҗем иреннәре кыймылдап алды:

— Малай чагын исенә төшергәндер... Заманасында

күн букча тотып, әтисе сызган бурзналарны аз таптамады бит ул.

Бу вакытта Шилнә буасында көлеш-кычкырыш тына төшкән, һәм ул тарафтан өсләренә алды-гөлле киемнәрен киеп алган бер төркем хатын-кыз, дөнья рәхәтендә кинәнүдән соң әле саф тезергә керешмәгән киек казлар шикелле, кәлдин-сәлдин генә атлаштырып, болайга, табын өстәлләренә таба менеп килә иде инде.

18

Авылга көннең-көнендә кемнәрдер килә, кемнәрдер китә — танып та, белеп тә өлгерердәй түгел. Беришеләре: «Без фәлән итүчеләр, без төгән итүчеләр»,— дип, күкрәк каккалап һәм ҚамАЗ сүзен кырыкмаса кырык төрлегә әвәләп, лаф орып йөри-йөри дә бу шаулы-гөрле тормышта капыл гына юкка да чыга. Әллә инде Чаллы каласының үзендә берәр тулай торакка яисә вагон ишесендә үзенә аерым җылы урын хәстәрен шома гына күрә белә, әллә тәртәсен килгән тарафларга таба, ягъни төзелештән мыштым гына сызу җаена таба борып куя. Барын да каян белеп бетерәсең?

Иллә мәгәр Туры картлар йортында оялап алган ике егет — Вятка буенда туып үскән ерык авыз Габделбәр белән Актаныш марие сакалбай Назар — Олы төзелешкә төпле акыл, ныклы ният белән килгәнгә охшый. Дөрес, кай кичләрне алар да төзелештәге төрле чатак-читак якларга ачу сиздереп, теш кайраштыргалыйлар, хәтта моң-зар түккән сәгатьләре дә булмый тормый, әмма «тәртәне кирегә борып, койрыкны сыртка салу» җайларына килгәндә исә, ник бер шыгырдау чыксын үзләреннән!

Тулай торакта үзенә аерым җылы урынга ирешү — әлегә татлы хыял гына. Анда эләгә алсаң, әлбәттә, бик күп төрле мәшәкатьләрдән, аерата баткаклы-сазлы юл йөрү газабыннан, ансат кына котыласың.

Ләкин Габделбәр белән Назарга тулай торак дигәннәре ишеген ачарга алай бик ук ашыкмый икән әле. Чиратлары әллә кайда, койрык очында ук, ди. Шуңа да карамастан, ике егет ирен чәйнәштермәде, алардан уфтану авазы чыкмады, киресенчә:

— Авылда яшәгән көйгә кала салып йөрүләре күңеллерәк тә әле,— дигән булдылар.

Тулай торак хакында сүз купты исә, күз алларына молдаван «мыеккае» Женя Мында килә дә баса. Бер дә

бер көнне тайды ул Туры карт йортыннан... Юк, үзенең кояшлы оҗмахы Молдавиягә сыпыртмады егет: ул нибары иске Чаллы читендә гөмбәдәй калкып чыккан өр-яңа бер йортта шыгырдап торган пружиналы, ялтыравык никельле койкага хуҗа булып алган иде. Бүлмәләрендә бары да энә белән җептән генә чыккан, ди, бары да ялт-йолт итә, хәтта шәп кием шкафы белән шоп-шома тумбочкаларга кадәр куелган, ди. Тик су белән генә элегә җәфалыйлар, әмма анысы да озакламый бер юньгә киләчәк, ди... Боларны ул, бер очрашкач, Назарга сөйләп биргән.

— Электрның чын остасы ич ул! Инде хәзер, безнең «Жилстрой»ны калдырып, турыдан-туры ҚамАЗның үзен коручы идарәгә күчте. Иң беренче заводны салуда да катнашам, иң беренче станокны көйләүгә дә үзем тотынам, ди. Тәки үз дигәнен итәчәк ул! — дип, бердән тезеп салды мари егете.

Моңа җавапка Туры карт чал башын гына селеккәләде:

— Ием, булдырмастай бәндәгә охшамаган... ихлас!

Картның күңелен егет киткәннән бирле: «Шул Рәмилә бәпкәч аркасында келәткә бикләп дапрус җасамаган булсам, бәлкем, ул тикле ашыкмаган булыр ие. Үземдә ипле генә җәшәп җатар ие әле»,— дигән уй бимазалап тора иде.

Женя Мынданың истәлеге булып, келәт белән ак мунчада электр уты янып калды, әмма иң әһәмиятлесе — коедагы насос иде. Монысын молдаван егете китәренә берәр атна калып килгәндә, Чаллыдан үзе табып алып кайтты, үзе үк көйләп куйды. Әкәмәт уңай нәрсә икән: махсус пенопласт «мендәр»-калкавычка беркетелгән җыйнак кына, җиңел генә бу насосны коега төшерәсең дә шнурдагы кнопкага гына басасың — җаның теләгән кадәр суырттыра суны кодрәт иясе! Аннары ишегалды почмагында зур чанда кичкә хәтле талыгып өлгергән суны да шул ук насос ярдәмендә бакчага сиптерәсең. Тамчы да көч түгәсе юк — рәхәтләнә!

Сабир-Чуерташ исә бу шәп нәрсәне бөтенләй уенчыкка әверелдерде: кирәк булганда да сиптерттерә, кирәк булмаганда да дыңгырдаттыра. Ахырда бабасы:

— Бар дөнҗаны сазга әйләндереп бетерер иең бугай, пырдымсыз! — дип онысын бик яман әрләп ташлады.— Әле җәйләр килми калмас, кирәге бик булыр моның... Аннары адәм рәтле берәүнең матур бер истәлеге дә бит әле ул!

Шул ук кичне бабай, электр насосының ычкындырыр төшләрен ычкындырып, аны келәткә алып керде дә монда әле кайчан гына молдаван остасы йоклап яткалаган сәке астына яшереп куйды.

— Кирәге бик килеп чыкканда гына эшләткәләрбез. Ишетсен колагың, малай актыгы! — диде.

Ярый, бу тарафтан өлкән йорт хуҗасының җаны беркадәр тынычлана төште.

Ләкин Туры карт, молдаван егетен әледән-әле яденә китереп, Габделбәр белән Назардан сорашмыйча булдыра алмый иде: Чаллыда алай-болай янә очраганы юкмы, ни хәлләрдә йөри икән, иминме-саумы, дигәндәй? Әлбәттә, картның белергә теләгәне тирәндәрәк, нечкәрәк: «Безнең кызый белән арасын өздеме икән, ары таба инде ниләр кыландырырга чамалый икән ул иблис җегет?» — дигән чамадарак иде. Тик ул монысын егетләрдән туп-туры бәреп сорарга кыенсына иде. Юк икән шул, кабат очратып булмый, ди, тулай торагын эзләп йөрергә вакыт та тими, җае да чыкмый, ди.

Ә Рәмиләнең үзеннән исә... Туры карт үзенең сөекле бәпкәчен андый дорфа сораулар белән җәфалый аламы соң? Бүгенге көндә бөтен нәсел-токымнарында бердәнбер булган асыл зат кызның җанын чыра пычагы белән телгәләү килешер димени? Шул ук чакны Туры карт, күңелендәгене тышка бәреп чыгармаса да, эчтән генә рәнҗеп-сызланып та куйгалый иде: соңгы көннәрдә кызый — кая анда көянтә-чиләкләп тәмле су китерүләр! — бабасының күзенә бөтенләй күренмәскә тырышып йөри иде. «Теге көннәрне катырак орындым, ахры, үзенә. Чын-чынлап үпкәләгән ахрысы балакай» дигән, үзе өчен бик тә күңелсез булган нәтиҗәгә килде карт.

Ә бер кичне, армиядән кайтып төшкән Рәмзи абыйсына ияреп, болар йортына бәпкәче Рәмилә дә аяк баскач, Туры карт күңеле тулудан әллә нишләп китте. Солдат оныгының менә шушылай таза-сау хәлләрдә әйләнеп кайтулары, аның көр тавышын ишетүләр, яшьлек дәрте, көч-гайрәт бөркегән нурлы йөзен күрү бәхетләре Туры картны, әлбәттә, чиксез куандырды. Оныгы белән гөлдер-гөлдер сөйләшкән арада ул, билгеле, күзләрен мөлдерәтеп, бәпкәче Рәмиләгә дә карап куйгалады. Кызыйның да куанычы ташып тора, аның да йөзендә ай да кояш, теленә исә былбыл кунган сыман; чут-чут сайрый, чытыр-чытыр көлеп җибәрә!.. Әйе, аның сөйкемлелеге, мөлаемлылыгы тагын да арта төшкән, кыяфәте дә шактый ук үзгә рәвеш алган: кай ара-

да диген, чәчен кыскартып кистергән дә кабартып куйган, нәзек кашлары биеп кенә тора, ә күзләрендә исә моңарчы күренмәгән очкыннар уйнаклый кебек... Тәмам пешеп өлгергән кура җиләге ни дә, бу ни! Бүген булмаса, иртәгә тот та кияүгә бир үзен! Әүвәлге заманда иртәгә калдырмаслар да иде әле...

Шушы күрешүдән соң: «Түбәсе өстендә карчыгалар бетерелми тормыйдыр. Бер җавызы харап итеп ташламаса җарый инде балакайны!» — дигән пошаманлы уй Туры картның бәгырь төбендә сызылды да калды. Җәрәхәтләп сызылды. Яшьләр барында карт-корыга җан тынычлыгы иңәме соң?

Ә болай үз йортында оялап алган ике егет — Габделбәр белән Назар — мөнәсәбәтенә килгәндә исә, Туры карт алардан бик канәгать, бик разый иде. Ә инде Сабир-Чуерташның фатирант егетләр белән чын-чынлап дуслашып китүе хакында сүз куертып торасы да юк.

Икесе дә авылда туып-үскән крестьян малайлары, икесе дә, вакытлары тисә, кул астына керергә генә торалар. Әле килеп төшкән шәпләренә үк — ул чагында Женя Мында да маңгай тирен җәлләми түкте — капка төпләренә китереп аударылган каен утынын кискәләп-яргалап лапас астына да, урам як койма буена да бик матур әрдәнәләргә өеп куйдылар. Ян бакчадагы умарта ояларын күчерешү, аларның утырган төшләрен чүп-чардан тазарту кебек ваграк эшләрдә дә булышмый калмадылар.

Эш арасында сүз тегермәнен көйләп җибәрергә дә җай чыга бит ул. Эш арасында гынамы, кичләрен табын артыннан кузгалгач та, телләренә богау салмыйлар, хәтта йокы качырган чаклары да булгалый.

Туры карт, серләшә-гәпләшә торгач, ике егетнең дә Чаллы төзелешенә ни сәбәпле кубып килүләрен суырып чыгара белде.

Мари егете Назар әллә ни кыеклап-мыеклап тормады, буразнаны турыдан ярып, үз хәлен бик тиз аңлатып бирде. Аның туган авылы Агыйделдән әллә ни ерак та түгел, киң генә, матур гына күл буенда утырган булган. Ләкин ул авыл хәзер инде юк диярлек икән, нибары өч-дүрт өй генә утырып калган. Ник дигәндә, мондагы Чаллы ГЭСы корылып беткәч, аларның авылын бөтенләйгә су басып китәсе икән. Шул сәбәпле, боларны күрше татар авылына күчерергә тотынганнар. Назарга, әл-

бэттэ, колхозда да эш бетмэгэн булыр иде, эмма ул заман куптарган каты җиллэрдэ күңелен илэслэндереп, КамАЗ төзелешенэ кубарга иткэн.

— Алай икэн...— дип сузды Туры карт, егетне тыңлап бетерүгэ.— Туган-үскэн нигезлэр, җирдэге гүр ияләре — бары берочтан су астында калачак, димсең, алайса? Һай-һай, катырак кизэнгэн шул сезнекелэргэ җазмыш!

— Бер чараң юк, агаем... Чыпчык дулап киртэ җимергэне бармы? Ә мин монда төзелештэ ипле генэ эшли торгач, бер җаена чыгармын эле. Турысын эйткэндэ, соңрак КамАЗның үзенэ күчэргэ ният. Женя Мында шикеллерэк... Тора-бара, бэлкем, техникум ишесен дэ ачмый калмаслар эле минем кебегрэклэргэ...

— Әлбиттэ, телэгең генэ булсын!

Вятка егете Габделбэр исэ күңел түрендэгене яктыга чыгарып салырга алай ашыкмады, уратыбрак-чуалтыбрак кыланды. Ул, тегенди-мондый гына сүз чыкканда да, сыңар кулы белэн киң яңаклы битен сыпыргалап, туган ягын мактарга тотына иде: имеш, тормыш итэр өчен иң уңай почмак алар авылы Түбэн Шөндэдер.

— Безнең колхоз бөтен Киров өлкэсендэ гөрли. Игенчелек буенча дисеңме, яки, эйтик, мал асраучылык буенча дисеңме — байраклар бездэ! Колхоз председателе Таһир абый — Социалистик Хезмэт Герое, бүтэннэр дэ орден-медальлэрне аз такмады инде. Менэ сезнең якта салам түбэле өйлэр эле һаман күренгэли, каралты-кураны эйткэн дэ юк. Ә бездэме? Авылның төзеклеген сөйлэсэмме? Өйлэрнең иркенлеген, чибэрлеген күрсэгез икэн, берсеннэн-берсе уздырган. Тап уенчыклар инде менэ!

Шушылай мактану-һаваланута Туры карт, баш түбэсендэ кэлэпүшен шудыргалап:

— Тукта, нишлэп эле син дөнҗаның андыен гүзэл оҗмахын ташлап китэргэ иттең соң? — дип текэлде.

— Сере бар аның, бабай, сере! — Егетнең коңгырт күзлэре кысыла төште.— Менэ мин карап-карап торам да шаклар катам: сездэ механизаторлар җитми икэн, шоферлар да өч бөртек. Ә бездэме? Ике йортның берендэ шофер яисэ тракторист. Әле күбрэк тэ булмаса... Димэк ки, ул һөнэргэ укуның кызыгы юк минем өчен.

— Ә ни нэрсэ кызык соң алайса?

— Төзелеш, дим, төзелеш! Бездэ болай төзү бригадалары бар барын, эмма алар ферма каралтыларын кору, күпер салу яисэ ремонт эшлэреннэн уздыра ал-

мый. Ник дисеңме? Осталык җитми. Ә шәп клуб, таш мәктәп кебекләрен кемнәр төзи? Әрмәннәр төзи. Кавказ таулары артыннан килеп шулар тотына.

— Безнең үзебездә дә клубны шулар өлгертте — җалт иттерделәр. Бөтен Рәчәй буйлап таралган, диләр, хәзер әрмәнне,— диде туры карт.— Инде дә эшләп күрсәтәләр үзе!

— Умырттырып акчасын да каера! Анысы да хак: кояш белән чыгалар, кояш баегач, кайталар — чыда гына! Үзем эшләп карадым алар янында: комын китереп, ташын-кирпечен әзерләшеп йөрдем — бик беләм! Әмма ләкин алар безнең ишене үз бригадаларына алмый. Колхоз да каршы: син умырттырып акча эшләгәндә, бүтәннәр авыз ачып йөрсенмени? Һич килешми үз колхозчыңны таркату — сәбәбе шул, диләр.

— Ә син акча дип теш кайраган идеңмени әле? — диде Туры карт һәм сынаулы, хәтта мыскыллы карашы белән егетне бердән сөзеп алды.

Мондый чеметтерүгә Габделбәр әллә ни ис җибәрмәде, аның сул кашы гына сизелер-сизелмәс кыймылдап алды:

— Һи, эш акчадамыни? Әрмәннәр кебек чын оста бул, кулыңда утлар уйнасын! Менә нигә кирәк булды миңа сезнең Чаллы! Ике-өч елым җәл түгел, боерган булса, остарып кына җитим! Безнең анда балалар бакчасы, кибетләр саласы булыр, ди, Сасмак авылында культура сарае тагы... Үз осталары булганда, колхозга да файда гына ич!

— Синеке хикмәтлерәк икән шул! — диде карт сузып кына һәм аның йөзендәге һәр җыерчыгы капыл нурга күмелде.— Хуп, улым, бик хуп! Уңарга язган булсын!

Үз серләрен шул рәвешле — берсе кыекламый-мыекламый, икенчесе уратыбрак-чуалтыбрак — ачып салгач, егетләр бабайның үзен дә читтә калдырырга теләмәде. Аларны күптәннән инде кызыксындырып килгән бер нәрсә бар иде: бабайның үз исеме Әүхәди, заманында мулла кушкан матур гына исем, әмма авыл халкы бу исемне бик сирәк әйтә, аңа очраган берсе «Туры бабай» яисә «Туры агай» дип эндәшә иде. Ни сәбәптән икән? Кушамат тиккә генә бирелми ич.

Туры картның ак самоварга кушучлап күмер салып маташкан чагы иде, менә ул, гәүдәсен турайта төшеп, җилкәләрен язып җибәрде:

— Нигә дип... соң... ни... җазмыш инде... Элегрәк мин әллә шушылай бөрешеп, җилкә салындырып җөрер иемме? Гәүдәм гренадерныкыдай, күкрәк киереп, туп-турылай басып җөрер ием җиргә, шуна күрәдер...

Сабир-Чуерташ өстәл читенә таянып, чәй өлгерүен көтеп утыра иде, бабасын шул гына сатты:

— Хәйләләмә, бабай! Күршедәге Бибинур әби үзе әйтте миңа: синең бабаң, диде, сүзнең турысын әйтер, хак сүз әйтер, диде. Әллә нинди нәчәлникләрдән дә куркып тормас, диде. Аның кыек әйтсә дә, туры чыгар, диде... Менә нигә такканнар сиңа андый кушаматны!

Мондый «сатуга» бабай тамчы да үпкәләмәде, киресенчә, бик тә кәефле рәвештә тамак төбе белән генә көткелдәп алды. Аннары, капыл гына тынды да авыр сулап куйды һәм ярым пышылдау аша ирен арасыннан сыгып чыгарды:

— Ә сугышка тикле «Инде Әүхәдие» дип җөртерләр ие, бала-чага исә «Инде абай» дияр ие...

— «Инде абай»? Нишләп алай? — дип текәлде Габделбәр, муенын сузып.

Монысы Сабир өчен дә зур яңалык иде, ул, хәтта авыз ачып сорау да бирә алмыйча, зур күзләрен генә челт-челт йомгалады.

— Тотлыкканга күрә, озынрак сүз әйткәндә дә «инде» дип кыстырганга күрә... «Әйтик, «мото инде цикл» дип төртелеп торулармы җә исә «ата инде каз» дип буылып калулармы — тәмамлар җөдәр ием... Заманасында селеккәннәр ие шул мине...

— «Селеккәннәр иде»? Анысы ни тагы?

— Соң, капчык киертеп инде. Колхоз корган җылны. Әйтсәм дә әйтим инде, оланнар, тарих мең дә тугыз җөз дә утызынчы җылның җазлыгында, сулар киткәч, сәвер аенда. Җаман ачу тотып. «Әртил кормый җарамый безнең ише җарлы-җабагайга» дип бугазны артыграк җыртып җибәргәнмен, күрәмсең. Дөмектермәкче булганнар...

— Ишеткәнем бар: безнең якларда да элекке заманнарда капчык киертеп дөмбәсләүләр булгалаган,— диде Назар, җирән сакалын учлаган килеш.

— Ә мине дөмбәсләмәделәр, селектеләр... Ничекләйме? Безнең валуст Илбактыда ие, шуннан төн уртасында кайтып килгән чагым. Нишләптер арткарак калганмын... Бервакыт Шилнә җары белән ипле генә атлаган җиремдә тал арасыннан килеп чыкмасыннармы! Капчык киерткәннәрен сизми дә калдым...

— Кемнәр, бабай? Каракайлармы? — дип сорады Сабир пышылдап кына. Малайның тамак төбенә кинәт кенә төер менеп кунган, һәм ул аны йотып җибәрә алмыйча интегә иде.

— Җарып кына әйтмәем... Әллә дүртәү, әллә бишәү әзмәвир... Җук, ормадылар, бәрмәделәр капчыкка тыккан көе һавада селектеләр. Ни суккан эзе җук, ни җәрәхәте җук, әмма ләкин эчке әгъзалар урыныннан купкан... Таң аткач, кан косып җаткан җиремнән табып алалар да Чаллы бульнисына илтеп салалар, аннары Казанның үзенә озаталар. Җан дигәнем нык булган, күрәмсең, җата торгач, эчке әгъзаларны рәткә китерә алдылар үзе, тик тотлыгуның гына дәвасы табылмады...

Бу хәлләрне ишетүгә бабайның оныгы Сабир гына түгел, ике квартирант егет тә өнсез калган иде, менә, ниһаять, Габделбәр авыр гына көрсенеп куйгач:

— Ә хәзер тотлыкмыйсың бит инде. Әкренләп үзеннән-үзе беттемени? — дип сорады.

— Бетәр сиңа! Шушы азаккы сугыш чик куйды аңа!

Туры карт бер тотынгач, ярардай хәтлесен яктыга чыгармыйча булмас ахры дип, ясаган чәен бер-ике генә йотты да басынкы тавыш белән язмышының иң саллы гәрәбәләрен ары тезеп китте:

— Башта сугышка алмадылар мине, авылда бригадир булып җөри бирдем. Аннан инде сугышның икенче җылында председатель иттеләр. Авылда җүнле-башлы адәм калмаган, кемне куйсыннар? «Инде абзаң» җарап җарады. Әмма озак тормадым, очырттылар. «Колхоз милкен разбазаривать иткән өчен» дип... Эшләр хөрти, хәлләр дуамал начар чак, Бикләннең чана җасаучылары, тугым бөгүчеләре белән алыш-биреш итеп алган ием шул. Алты-җиде баш җәш үгез малыннан колак кагарга туры килгән ие. Тегеләр акчага сатмый, ә колхозны арба-чанасыз гына өстерәп кара! Хөкемгә тартырга да исәпләре җук түгел ие.

— Соң, колхоз файдасына булган ич! — диде Габделбәр.

— Шулаен шулай да бит... Җарар, колхоз арба-чаналы булып калды, үзем җөрәк җарсуына чыдашмыйча туп-турылай военкоматка киттем. «Ичмаса, обозга булса да җарармын» дип... И тап шуңа охшашлыга җарадым да... Ут эченә ат җигеп кердем, ат җигеп чыктым, дигәндәй. Снарядын-мазарын да ташыдым, җаралыларны да аз апчыкмадым. Гражданнар сугышында, һай,

күп атышырга туры килгән иде, ә монда ник бер атып карасам икән, ник бер фашистны дөмектерә алсам икән. Җугыйсә, арба башына винтовкам да кыстырып куелган ие. Җае чыкмавыннан әйтәм әле. Атка ияреп, җарты Җаврупаны буйласам да...

— Шулай йөргәндә тотлыгудан да котылдыңмы? — дип авызын ерды Габделбәр.

— Ашыкма, дим!.. Герман җиренә барып кергәч булды ул, немечнең җылкылдап торган шәп алашаларын җигә башлагач... Бер заман дуамал дәһшәткә эләгеп, чат минем җанда диярлек бомба шартлады. Җарый әле иптәшләр казып ала белгән. Җаман контузия... Госпитальдә өч ай җарым җатып чыктым. Бер заман терелеп килгәндә, исләрем-акылларым китте: тотлыгуым беткән ләбаса! Валлаһи, дим!

— Менә сиңа хикмәт!

— Авылга кайткач, элеккеге кушаматны тергезеп тормадылар. «Инде абай» булулар эзсез җугалды шулай иттереп... Үземне хәтта киредән председатель итәргә бик тә кызыгып җөргәннәр ие, әмма ул арада улым Ризван кайтып төште. Аның орден-медальләре күкрәк тутырук, ә миндә нибары ике җиз медаль генә... Бик авыр җылларны, бик җәшли көенчә өстерәргә туры килде бәхырьгә. Тик ул да, колхозларны берләштерә башлагач, бер заман очты, дөресе, Казанга укырга озаттылар үзен.

— Агрономлыкка укымага,— дип төшендерергә кирәк тапты Сабир.

— Ие, ми агартмага,— диде Туры карт һәм, чак кына көлемсери төшеп, үзе сөйләгәннәрне түгәрәкләп куярга ашыкты.— Шулай иттереп, сугыш җалмап алды минем теге кушаматны. Җугыйсә, әгәренки үлмәгән булсам, бүгенгесе көнне дә «Инде абай» дип җөртерләр ие, бәлкем. Бер җаманы уатты, икенче җаманы төзәтте, дигәндәйрәк булып чыкты шул...

Аннары ул бик тә авыр сулап куйды:

— Дөнҗа күләсә инде ул, җарый ла хәере беләп әйләнә белсә, дип гомерләр сөрәсең инде шулай әкертенләп...

Моның соңында Туры бабай, башын иеп, тынып калды. Бүтәннәр дә сүз катмас булды. Самовар инде күптән кайнап чыккан, бүлмәдә аның торган саен тоныклана барган гүләве генә ишетелә иде. Ниһаять, Туры карт башын күтәрә төште һәм, беркемгә дә карамый-нитми,

һаман да шул карлыкканрак тавыш белән, әмма һич көтелмәгән тарафтан сорап куйды:

— Теге заманның өермәле җылларында... теге кем... Котовский батыр... милләте белән молдаван булганмы әле?

Сорау егетләрне сискәндереп җибәрде. Алар үтә сәерсенү аша бер-берсенә күз ташлап алдылар. Әлерәк кенә бөтенләй бүтән төрле кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр турында әңгәмә корып утырганнар иде, ә хәзер, күр инде, һич уйга да килмәгән текә борылыш... Туры карт әлеге соравы белән, әлбәттә, үз күңеле төбендә ни ятканын, кемнәр һәм ниләр хакында тынгысыз уйларда ут йотып яшәгәнлеген аермачык сиздерде. Күрәсең, ул, ни тырышмасын, үз эчендә кайнаган пошаманлы уйхисләрне берничек баса да, тыя да алмый иде бугай...

— Ие, бабай, молдаван булган,— дип иң әүвәл сүз катты Сабир.— Киносын үзем караганым бар: зрә дә гаярь, зрә дә үткен кеше булган ул заманасында!

— Алайсам, монда үзебездә дә буласы икән хәлләр! — дип басынкы гына сузды Туры карт һәм чал кашлары астыннан гына егетләрнең берсенә, үзен Вятка татары дип йөрткәненә күз тидергәләп алды.— Каршыларында асыл кошның берәгәйлесе, түш кабартып, канат кагарга торганда, татар булган башлары белән ни җөриләрдер җебеп...

Бу сүзләрдән Габделбәр, янтыгына очлы без кадагандай рәвештә йөзен яман чытып, төкселәнеп китте, әмма егет шунын арты ук коңгырт күзләрендә зәһәр очкыннар да кабындыра белде:

— Син, бабай, үз татарыңны алай ансат кына себереп атарга ашыкма әле бик... Арада ташка басса ут чыгарырдайлары да бетмәгәндер, бәлкем. Үзең әйтмешли, дөнья куләсә — бер көендерә дә, бер сөендерә дә белә бугай ул, ә?!

19

«Түгәрәк кичә...»

Түгел, түгел, буталмыйк: аның дини гореф-гадәтләр белән һич алыш-биреше юк, бер үк вакытта аны халыкның теләсә кем күңеленә бик тә ятышлы булган, әмма инде искерә төшкән берәр йоласының турыдан-туры дәвамы яисә чагылышы дип бәяләү дә хата булырдыр. Шулай ук югарыдан әмер белән кушылган, ягъни астан бау белән тарттырылмыйча өстенә нибары

бастырык кына салынган берәр чара-мероприятие дә түгелдер. Ә ни соң? Болай карап торырга яшьләрнең тоташтан уен-җырга корылган гап-гади кичәсе ул. Ләкин бер хикмәте бар: «түгәрәк кичә» тик солдатларга, аларның да әле армиядән хезмәтләрен тутырып кайтканнарына бәйле.

Солдат-егетләр шушы кичәдә кабаттан күрешү-очрашу шатлыгын татып, аның бер хикмәтләрен үтәгәч кенә, ягъни кичәнең икенче көнендә генә өсләреннән солдат киемнәрен салып, чөйгә элеп куялар. Тик шуннан соң гына алар, үзләре әйтмешли, гражданский тормыш ыгы-зыгысына чумалар. Бергә икән — бергә!.. Ә салып куйган погонлы киемнәре инде бүтән киелми, алар җилле яшьлекнең онытылмас истәлеге булып, кием шкафларында саклана. Әҗердә бүген йорт саен диярлек бар андый киемнәр!

Көзен китеп көзен кайткан егетләр «түгәрәк кичә»не гадәттә кышка кергәч үк клубта үткәрә, язын китеп язын кайтканнар исә Шилнә буена пар тирәк тирәсенә, ягъни табигать кочагына төшә...

Ләкин «түгәрәк кичә»нең мәгънәсен нибары гадәти очрашу-күрешү һәм аның соңында кием алыштыру, ягъни төс-кыяфәт үзгәртү тәртибенә генә кайтарып калдыру аның асылын аңламау булыр иде.

Солдат хезмәтеннән алданрак кайтып төшкән егет аңарчы хәл-әхвәл белешмичә генә йөрер димени? Юк, әлбәттә! Ул инде туган-тумачасы белән дә, авылдашлары белән дә күрешеп, туйганчы хәл-әхвәл белешкән, ул гынамы, исән-сау кайтуының чиксез куанычы төсендә тиешле мәҗлесне үткәргәндә дә махирлык күрсәткән була. Ләкин ул үзе белән бергә киткән, тик әле кайтып өлгермәгән иптәшләрен көтә, аларны юксына, алар соңгысына кадәр кайтмый торып, күңеле түгәрәкләнмәячәген беләә...

Алаен алай да, «түгәрәк кичәнең» иң күрке болары түгел әле, аның иң түрендә янар чәчәк булып балкыганы, кичәгә нур өстенә нур булып коелганы — ул вәгъдәлеләр тантанасы. Нәкъ менә шушы кичәдә вәгъдәлеләр бәйрәм итә дә инде! Алар гадәттә өч-дүрт пар була, кайчагында бер-ике белән генә дә чикләнә. Әмма күпме генә булсалар да, аларны «түгәрәк кичә»ләрнең тоткасы да, җаны белән каны да дип бәяләү һич күпертү булмастыр. Юк, алар «менә без шундыйлар, менә без ил күзе өстендәге каш» дип лаф ормас, киресенчә, бик тә тыйнак, ыспай һәм ипле кыланыр, хәтта үзләрен

күләгәдәрәк калдырырга, «вәгъдә тугрылыгын» әле һаман яшерергә тырышкандай кыланыр. Ләкин кая инде! Бар сагыну-юксынулар, бар шик-шөбһәләр, бар борчылу-өзгәләнүләр инде артта калган, күк гөмбәзләренә менеп елмайган кояшлары ул томаннарны инде капыл таратып өлгергән — шундый чакта бергә кушылып дөрләп киткән һәм тышка ургылып торган ялкыныңны яшереп кара син! Әнә шулай вәгъдәләрен күз карасыдай саклый белеп, бәхетләрен «түгәрәкли» алганнар үзәктә булганга күрә, кичәнең үзенә дә шундый исем бирелгәндер әле...

«Түгәрәк кичә»нең икенче көнендә үк вәгъдәле парларның әле бусы, әле тегесе хакында: «Фәлән солдат белән фәлән кызыйның туйлары озакламас инде»,— дигән юрау хәбәре тарала. Әйтергә кирәк, мондый хәбәрнең моңа кадәр әле бер генә тапкыр да ялганга чыкканы юк: юраганнары гелән дә юш килеп тора!

Аның шунысы да бар бит әле: нәкъ менә «түгәрәк кичә»гә аумый-түнми, абынмый-сөртенми тәгәрәп килә белгәннәр, соңыннан уртак язмышларын тыгыз йомрыга укмаштырып, Әҗер авылының бөтен тормыш-яшәешнең карап туймас күркенә әверелә дә бит инде. Андыйларга үтәсе үрләр дә ансатрак бирелә, диләр!

Рәмзи моны белмиме, аңламыймы әллә? Бик белә, бик аңлый да кана...

Юк, «түгәрәк кичә»дә аңа вәгъдәләр тантанасының куанычын-тәмеп татып карарга насыйп булмаган икән шул. Ә бит хыялланган иде, өметләре җылы гына түгел, кайнар иде. Әле кайчан гына, нибары былтыр, юк, нибары узган кыш урталарында...

«Бәхет» дигәннәре дә, пар канатлы булырга тиеш, күрәсең, сыңар канатың каерылган булса, ниләр кыла аласың инде? Тилпенүен дә тилпенерсең, тик очып кына китә алмассың. Вәгъдәлеләргә сокланып та, кызыгып та, хәтта көнләшүдән җир тырмап та йөрүләреңне белерсен...

Ләкин егет алай да өметен өзми иде әле.

Менә инде шимбә киче дә килеп җитте, менә инде күңелле уен-җырлары, җыен шуклык-мутлыклары белән гөрли-шаулый үтеп тә китте. Әлбәттә, егет солдат дуслары алдында да, кыз-кыркын каршысында да сер бирмәде, матур йола кичәсен артыгын йолкынмыйча, шома гына уздыра белде. «Түгәрәк кичә»дә үз түгәрәгеңнең китек икәнлеген сиздерүдән ни мәгънә?

Түбәндә сыек караңгыда пар тирәк. Аның артында Шилнә...

Уен-җырның шашкынын янә бер тыңлады бүген пар тирәк. Инде хәзер изрәп йокыга китүедер. Ә гармун тавышы әнә инде авыл эчендә ерагаеп бара. Шәп өздерә гармунны Рәмзинең авылдашы — солдат дусы Фәнил. Авыл төн уртасының татлы йокысына чумган дип тә тормый. Өздертмәскә, вәгъдәлеләр бәхетенә ирешкәннәрнең берсе ләбаса ул!

Рәмзи алар төркеменә ияреп китә алмады. Арткарак кала төште, аннары инде, берәр кирәкле нәрсәсен җуйган кеше сыман, түбән караган хәлдә әкрен генә кире Игәч үренә таба атлады. Каршы якларында офык читләре тоташтан ут дингезе булып балкый — КамАЗ һәм Яңа кала балкышы. Ут диңгезе хәтта чак кына дулкынланып та тора сыман. Һава шулай тирбәлгәләп торганга күрә микән? Югарыга менгән тузан катламнары әле һаман таралып һәм җиргә иңеп бетә алмый. Иртәгә тагын тузан болытлары күтәрелер, берсекөнгә тагын... Берәр көнне, ниһаять, чиге булырмы моның?

Егетнең күз карашы янә түбәнгә пар тирәккә төбәлде. Әле кайчан гына ул сабантуйның чуар шәлъяулыкларына, аллы-гөлле чүпрәк-тастымалларына төренеп, көяз һәм купшы кыяфәттә балкып утырган. Әйләнәсендә халык бөтерелгән, көрәш ярсуы кайнаган... Бүген ул тып-тын. Үзән төштә дымга туенып рәхәтләнеп утыра. Аның тирәсендә гомумән рәхәт, хәтта һавасы ук йомшаграк та, җиләсрәк тә кебек. Тиккә генә яшьләр күцелен гелән дә үз тирәсенә тартып торыр димени пар тупыл?

Ярларына тулып торган тымызык Шилнә суында ут диңгезенең бер өлеше чагыла — бу исә пар тирәкнең ян-якларына сибелеп киткән җилпәзәле канатлары сыман булып тоела. Сихри бер күренеш...

Авылда Фәнил-солдат әле һаман туктый алмыйча гармунын сыздыртуын белә. Бәхетле егет! Юк, ул гына түгел, сөйгән кызын мотоциклына атландырып әнә теге җемелдәгән утларга кереп югалган Үтәдем Васясы да, арткы якка, караңгыга, әмма озакламый сызылып таң атар тарафка элдерткән Калмаш Зиннуры да аның сыңары. Бәхетлеләр түбәләре белән күкне сөзәр, ди! Тансык куеннарга көзге хәтле үк керергә ниятлиләр. «КамАЗ кызулый», имеш. Әлбәттә, туйларына бармый ярамас.

Якында тоныкъ кына булып аяк атлаган, үлән кыштырдаган тавыш ишетелде, һәм менә инде сыек төн караңгысында ыспай гына йөзеп килгән сылу шәүлә, үр кашында басып торган егет янына җиткәч, тукталды, тирән иттереп сулап куйды. Рәмилә икән.

— Син, абый, нишләп әле болай? Япа-ялгызың... тегеләрдән бүленеп...

Кызый моны, әлбәттә, ихтыярсыздан гына сорады. Ул абыйсының хәлен бик белә, бик аңлый иде. Хәер, аның үз хәле дә хәл ич: сөйгән яры әллә кайда, дөнья читләрендә, ә ул монда, вакыты белән ут ялкыннар эчендә яна, вакыты белән салкын дәрьялар кочагында ага... Ләкин аның ышанычы әле һич какшамаган, өметләре һич тә киселмәгән. Ә абыйсының? Бигрәкләр дә ай-һай шул. Андый чакта бертуган абыйсының пошаманнарын таркатмага үз иңнәреңне куймыйча ярыймы соң?

Рәмзи бермәл тын торды, баскан җирендә селкенгәләп алды, сеңелесе кебек үк киң һәм тирән иттереп сулап җибәрде, тик шуннан соң гына һич көтмәгәндә бик тә көр тавыш белән әйтә куйды:

— Төн һавасы нинди рәхәт — сулыш алулары ук бөтенләй икенче, ә?

— Ие, бөтенләй бүтән...

Югарыдан, бик биектән, җете кызыл утын йомгалап, бер самолет үтеп китте. Аңа ияреп, Рәмиләнең иреннәре арасыннан ирексездән, ахры, сузынкы пышылдау авазы сытылып чыкты:

— Сабыр төбе — сары ла алтын...

— Нәрсә-ә-әү?

— Юк ла, болай гына... Нишләптер гап-гади бер мәкальне җыр итеп җырлыйсым килеп китте.

Рәмилә бу минутта, пар тирәккә төбәлгән хәлендә, сөйгәне Женя Мынданы уйлаган иде. Йолдызлар астыннан кызыл күзен йомгалап үткән самолет исә аның уй-тойгыларын нечкәртеп җибәрде, хәтта тышка ук бәреп чыгарды... Кыз күңеле сизенә иде шул: аның молдаван «мыеккае» чит бер калага командировкага киткән җирендә бу сәгатьләрдә аэропортта үзенә тиешле рейсны көтеп, төн кыскартырга тиеш. Озакламый алар янә очрашырлар, кайнар хисләре янә чәбәләнеп бетәр... Шуны сизенгәнгәдер ахры, бу минутта Рәмиләнең йөрәге ашкынып-ашкынып тибәргә тотынган иде.

Дөньяда «телепатия» дигәннәре чыннан да бар микән әллә?

Һай, юктыр ла!

Рэмзи-солдат та кич буе, юк, көннәр буе сөйгәне Язиләне уйлаган һәм әле дә аны уйлый иде. Ул аңа — тик аңа гына! — армиядән кайчан һәм ничек кайтасын хәбәр иткән иде бит. Язилә ул чагында Алабугада иде бит әле. Алмый калмагандыр... Ә хәзер кайда икән ул? Кайда булса да, солдат кайткач, авылда матур йола үткәреләсен белә бит. Иҗмаса, берәр хәбәр салса икән!

«Түгәрәк кичә» хакында ишетеп белгәннәр кайтты бит, җыелды бит әнә. Инде хәзер төн уртасы. Авылга орынып ук диярлек сузылган асфальт юлдан автомобильләрнең ут йомрылары да бик сирәк тәгәрәп үтә, Шулай да...

Бәлкем, Язилә юлга соңгарып чыккандыр да төн уртасына калгандыр? Бәлкем, сирәк тәгәрәп килгән әнә шул утларның берсенә утыргандыр яисә утырырга чамалап, тоткарлануыдыр? Ә бәлкем, утырудан өметен өзеп, шома асфальт юлдан яулыгын селкә-селкә, РИЗның үзеннән үк җил-җил җәяүли торгандыр? Әллә каршысына китәргәме? Их, кайдалыгын хәбәр иткән булсамы!

Рәмзи кискен бер хәрәкәт белән маңгаен-битен сыпыргалап алды һәм шуның белән күңелендә тыгызланып өелгән уй-хисләрдән бер селтәнүдә котылырга теләгәндәй, саллы гына тавыш белән:

— Син гади бер мәкальне җыр итеп җырлыйсым килде дисең, сеңелем. Ә миңа тагы КамАЗ төзелешенә җыен шагыйрь җиң сызганып тотынган кебек тоела әле. Шулайрак түгел микән? — диде.

Егет болай дип тиккә генә әйтми иде: соңгы берничә көн эчендә ул, Айдаш белән Вәсим абыйлары аңа кайтуына ук бүләк итеп тоттырган өр-яңа, җете кызыл «Ява» мотоциклына атланып, гигант төзелешнең әллә ниңди почмакларыннан да әйләнеп чыккан һәм күп нәрсәгә хәйран калып йөргән иде инде. Әмма иң хәйран иткәне, җанын айкап салганы: «Главное, ребята, сердцем не стареть!» яисә «Не всем дано так щедро жить — на память людям города дарить!» дигән кебегрәк шигъри юллар булды. Русча язылган андый лозунг-девизлар хәтәр киң автострада читләрендә дә күзнең явын алып кала, биек йортларның маңгайларында да күренә, автозавод төзелешенә барып кергән чагында да һавада тылсым көче белән кабынган хикмәт булып каршылый иде.

Рәмилә абыйсына сыена төште һәм туганнарча якынлык белән йомшак кына иттереп кеткелдәп алды:

— И абый, тап өстенә бастың. Шәмси Әминәсе әйтә: безнең анда шигырь белән җыр һавага ук сеңгән, кислородка кушып сулыйбыз, ди.

Тегендә, авыл эчендә, йөгәнсез гармун кинәт хәтәр-хәтәр иттереп сыздырып алды да тынып калды. Мөгаен, инде хәзер аңа ялганса да беренче әтәчләрнең зыңлы яңгыравык авазлары гына ялганып китәрдер.

— Әнә инде Фәнил дус та арыды бугай.

— Һи, арыды сиңа! Алар бүтәннәр төркеменнән генә аерылды. Кызын озатканда, гармун акыртып барыр димени акылын җуймаган егет?

Рәмзинең уйлары караңгы авыл эченә кереп киткәндәй булды. Төркем-төркем кереп югалды анда яшьләр. Һәр төркемдә ике-өч кызга дүрт-биш егет! Хәер, күбесенең егет диярлекләре дә юк әле. Әмма үзләрен чын, җегәрле бөркетләрчә тоталар: кызларны канат асларына алганнар да якын килгәннәрне «чүкергә» генә торалар. Ә кызлар бөтенләй яшь, бөтенләй сыек — байтагы нибары Хәтирә яшендәгеләр.

Хәтирә... Тыйнак та, мөлаем да, сөйкемле дә кызый. Туган авылы туфрагына аяк баскач, Рәмзинең күңеленә менә кем сәер һәм сихри дулкыннар булып үтеп кергән иде. Аңа ул сокланып та, ымсынып та куйган иде. Әмма, бактың исә, сөйкемле нечкә билең яшь кенә булса да, инде «ияле» икән: янында бөтерелгән бөркете бер дә әллә кем түгел, Рәмзинең тыкрык күршесе Фәрит, алдагы көзне армиягә китәсе егет. Бүтән кызыйларның да хәле шулайрак сыман. Тиккә генә өч-дүрт кызны бер өер егет-җилкенчәк озатып йөрер димени?

Кызлар, кызлар... Бүгенге көндә алтын бәһасыннан да болайрак булган җаннар. Инде «ияле» икәнсез, алдагы көннәрегездә бер-берегезне җуймый гына, таркалмый-каерылмый гына «түгәрәк кичә»ләргә шома иттереп тәгәрәшеп килә белегез!

Ә ул инде...

Егет каршысында офык тутырып балкыган ут дингезен карашы белән бердән иңләп алды. Әйе, нәкъ менә шул утлар дингезе аның бәхет кошын харап итте дә ахры, бүтән ни тагы? КамАЗ, диләр, КамАЗ, ә ул аның өчен, бактың исә... Бу хәлләрдә яман көрсенми, ни кыла аласың тагы? Ә бәлкем... бәлкем... нәкъ менә шушы утлар уйнаган дөньядан килеп чыгар аның фәрештәсе? Юк, Язилә түгел, бөтенләй бүтән... искәрмәстән генә... җилләр уйнатып кына... Утка ут килеп кушылсамы?!

Рәмилә, үр каршындагы сукмакка акрын гына басколап, кайтыр якка таба атлады. Абыйсы аңа иярде.

— Үз ирегеңдә йөрү нинди рәхәт, иеме, абый? Рәхмәт инде, бераз соңгарсаң да, вакытында кайта белдең. Кичләрен өйдә томаланып ятулардан тәмам гарык булган идем.

— Тәмам укмы?

— Ие... Ә син кайткач, синең белән бергә булганда, өйдәгеләр ләм-мим...

Кызый абыйсын култыклап алды, аңа сыена төште. Тагын да назлана төшебрәк, пышылдады:

— Ә хәзер кайтырга да түнәргә... Онытма, миңа иртән иртүк торып Чаллыга китәсе бит. Айдаш абый белән Вәсим абыйга иярермен дигән идем. Йоклап калырга ярамас.

— Чаллыга? Ник тагы? Тагын бер женләнеп кайтыргамы?

— Женләнсәм соң... Үзең уйла: яшьлек ике киләме?

— Ярар, кайгырма: йоклап калсаң, мотоциклда жилжил үзем илтеп куярмын. Үземә дә, янә бер дөнья айкап, жилләп кайту зыян итмәс. Мин бит әле иректә. Мусига камыт кимәгән.

— Әле киярсең... кигезерләр! Тик камытның нинди-се, кайда?

— Ярар, сеңелем, тиккә башыңны катырма, үзем белермен...

Абыйсының авырткан төеренә басты ахры, икесе дә бер мәлгә шым калдылар. Ләкин дәшми-тынмый гына атлавы күңелсез иде, монсуландыра иде, Рәмилә күз карашы белән караңгы авыл өстенә төбәлгән килеш, һич көтмәгән жирдән:

— Ә син, абый, беләсең микән? Бик элгәредә сабантуйларны авылның теге очында, түбән тугайлыкта үткәргәннәр бит. Хәзерге теплица урыннарында,— дип куйды.

— Белмәскә... минем хәтергә әкияттәгедәй матур булып сеңеп калган ул. Бик бәләкәй чагым булса да...

— Шулай да пар тирәк тирәсендә күңеллерәк, име?

— И-ие, күңеллерәк...

Адымнары ирексездән диярлек әкренәйгәннән-әкренәя барды һәм менә инде үр каршындагы сукмакта янә тукталып калдылар.

— Ә син, абый, бу пар тирәкне кем утыртканлыгын беләсеңме?

— Кем?

— Юмай карт.

— Юмай?

— Ие. Башкорт карты. Монда Игәч үрендә элгәрерәк заманда гел башкортлар гына яшәгән бит. Әҗер үзенә аерым, Игәч үзенә аерым. Урталыкта тирән чокыр... Тик колхозлашу елларында гына үзара кушылып, буталышып беткәннәр.

— Ие-ие, минем дә колакка чалынганы бар: үзебезнең Туры бабай авызыннан ишеттемме, әллә бүтән берәүдәнме...

— Ә безгә кубрәге Зөлхәбирә әби сөйләр иде. Аның хәтереме — исләрең китәр! Ә Юмай карт үзе бик тә нечкә, бик тә саф күңелле кеше булган, ди: җырлар дисеңме, бәет дисеңме — барын да шул бабай чыгарган, ди, заманасында. Юмай картның өе дә әнә анда, үр астында, чокыр тамагында булган. Мунча хәтле генә өй... Ә өй артыннан чишмә бәреп яткан.

— Дөрестән дә: Юмай чишмәсе...

— Сугыш башланганда аның өе инде тәмам ишелергә җиткән булган, өстәвенә, бабайның җегәре дә калмаган... Ахырда, Игәчкә кайсыдыр карендәшенә менеп оялаган. Сыендырганнар. «Өем белән лапасым, ичмаса, утынга ярар,— дигән бу.— Сугыш беткәнче ничектер җан асрамага кирәк бит, оланнар,— дигән.— Тик берүк пар тирәккә тия күрмәгез!» — дигән.

— Нигә?

— Нигә, имеш... Соң, шул пар тирәк янына кичләрен яшьләр җыелып, җыр-уен кора торган булганнар. Сугыш алды елларында да, сугыш барган чагында да... Юмай карт әйткән: «Сугыш уты эчендәгеләр иң әүвәл минем ябалдашлары кушылган пар тирәгемне сагынып, шуны җирсеп кайтыр»,— дигән.

Тагын да тын калдылар. Күз карашларын тымызык төн кочагында тын һәм моңсу утырган сихри пар тупылдан аерып ала алмадылар.

— Ә син, абый, пар тирәкнең ябалдашлары ни өчен кушылганлыгын чамалыйсыңмы?

— Ни өчен? — Моны абыйсы аптыраганнан гына сорады, ахрысы.

— Соң, тамырлары бик тирәнгә китеп, үзара кушылып, чәбәләнеп беткәнгә күрә инде. Аннсыз ябалдашлар кушылыр ди сиңа...

Хакыйкатьнең бик тә бәләкәе, кычкырып торганы иде бу, алай да Рәмзи сискәнеп куйды:

— Хикмәт тамырда, димсең?

Игәч үре кашыннан кыйгачланып сузылган тар сукмак белән атлаган чагында, Рәмзи тылсымлы пар тирәк ягына янә каерылып-каерылып карамыйча һич булдыра алмады...

21

Инде менә капка төбендәге эскәмиядә япа-ялгызы утыра.

Күк гөмбәзенең көнбатыш ягында эленгән яктылык элпәсе әкренләп көнчыгыш тарафка авышты.

Авылда сихри бер тынлык. Әмма озакламас, таң ныграк беленә башлау белән, бер купканнан соң әлегә тынып-йокымсырап калган әтәчләр өере, дөньяны тизрәк уятырга җыенып һәм монысында тагын да куәтлерәк авазлар чыгарып, янә җиз быргыларын уйнатырга тотынырлар. Мәңгелек шөгыльләре...

Уйлар, уйлар... Уйлар диңгезендә һәркем үзенчә дулкыннар куптара, һәркем яр-кыяларга үзенчә чайпалып бәрелә...

Солдатның күз алдыннан пар тирәк китми дә китми. Куш ябалдаш — кушма тамырлар... Сеңелесенең шул хакта серле бер гыйбрәт иттереп пышылдаганы әле дә колак төбендә эленеп тора. Әбит, бактың исә, чекрәеп торган гап-гади хакыйкать үзе, ә сере тирәндә...

Моңа өстәлеп, егет күңелендә әтисе әйткән хикмәтле сүз дә җилләр уйнатып ала иде.

Анысымы?

Рәмзи «түгәрәк кичә»гә чыгып китәр алдыннан гына ишетте аны. Алар, өч туган, өч агай-эне, җелекләрне киптерердәй эссе мунчада дөбер-шатыр чабынып чыкканнан соң, бераз хәл җыйгач, табын артына утырышканнар иде. Табында әчедәндер, төчедәндер мул нигъмәт тезелеп киткән, уртада, пыяла йөзенә бөрчек-бөрчек тир чыгарып, «ак башлы» урын алган, кырыйда, кайнар бу болыты бөркеп, ак самовар утыра, тик әтиләре генә күренми дә күренми иде.

Ниһаять, бусагадан атлап керде. Кыяфәтенә карыйсың юк: күз аклары белән тешләре генә елтырый... Авызын киң ерды, әмма шундук җыярга мәҗбүр булды.

— И-и, син дә инде! — дип чәпчергә тотынды әниләре, каш-күз җимереп.— Ичмаса, шимбә көнне малайларың җыелып беткән чагында батып җатмасаң икән, дөнҗаңны онытып...

Әтиләре беравык тотлыгып торды:

— Соң ни бит...— Аннары куе төкләр баскан какча ияк-яңакларын сыпырып узды да бер сулыш белән диярлек күкрәгеннән сыгып чыгарды: — Җир рәнҗемәгәе, дидем инде...

Абыйларына бу сүз ничек тәэсир иткәндер — алар бер-берсенә сәер иттереп күз генә атып алдылар шикелле — ә Рәмзинең исә йөрәген телемнәргә кискәләп үтте гап-гади гыйбарә!

Әниләре дә, кулларын күкрәк өстенә менгереп, бермәлгә сулышын тыеп торды, аннары тавышын капыл гына йомшартып җибәрде:

— Җарый инде, карт, җарый... Җиргә дым дия-дия үзең элеп киптергәнгә калмагаең дип куркудан гына әйтүем...

Рәмзи «түгәрәк кичә»гә чыгып киткәндә, әтисе тәмам арыган сеңер-буыннарын яздырып, пакьләнеп, адәм кыяфәтенә керер өчен, эссе мунчага җыенып калды. Авызыннан ни дәрәҗәдә хикмәтле, ни дәрәҗәдә гыйбрәтле сүз ычкындырганлыгын үзе бар тирәнлеге белән абайладымы икән?

«Җир рәнҗемәгәе...» Хакыйкатьнең иң олысы һәм иң ачысы түгел микән әле бу?

Шуның төбенә төшмәкче булып уйга бирелүенә, егетнең тыны куырылып китә дә, күз алдында әлләниләр булып җанлана: «Җир рәнҗемәгәе...»

Инде ни кылырга?

Таң алдының йомшак салкыны, ниһаять, аның кителе эченә дә үтеп керде, егет бар гәүдәсе белән калтыранып куйды һәм, тәненә җылы йөгертү өчен, аз гына кымшангалап алды. Бу солдат киеме аны өстендә соңгы төнен үткәреп, азаккы таңын каршылый. Көндезен егет аны кием шкафына абыйларыныкы янына, онытылмас бер ядкәр итеп, элеп куяр. Аннары инде бүтән кагылмас... Әмма хикмәт кием алышуда гынамыни?

Әтисенең хәле мөшкел, дөресе, совхоз хәлкәйләре мөшкел: кеше җитми, кеше! Бу кызу җәйдә бигрәк тә... Рәмзи әтисе янында өченче көнне дә, кичә дә булды. Вакыты тигәндә басуда торба салучыларга булышты. Дым, диләр, күктән яумаганда үзебез сиптерик, ансыз азык булмас, азыксыз ни сөте-мае, ни ите өстәлгә менмәс, диләр. Әлбәттә, хак сүз әйтәләр, үз яңгырларын булдырмакчы булып, җиде кат тир түгәләр. Әмма әтисенең булышчылары эчтим-печтим генә. Ә көн, тәмугтагы шикелле, иләмсез кыздыруын белә, су сиптерергә тотынганнар күпме генә эш кыйратып өлгерер микән?

Әтисе аңа: «Менә син дә, улым, арысландай егет башың белән мотоциклда важдырт-выждырт каңгырап йөрүләрдән әле һаман бушана алмыйсың»,— дип орынмый әле орынуын, улы килеп чыкса, эреп кенә киткәндәй итә, әмма кай арада аның солдат улына серле һәм сынаулы караш белән төбәлүендә әлләниләр бар ич!

Хәер, ни әтисе белән әнисе, ни абыйлары белән сеңелесе, хәтта Туры бабай булып Туры бабайсы да аңа кыеклатыпмы, турылапмы бәрелми әле. Мыштым гына көтәләр. «Үзең чамала, иманың кушканын сайла!» — диләр ахры.

Совхоз директоры Таиповка тикле күрешкән чагында: «Әһе, асты өскә актарылган дөньябызга янә бер батыр иңгән ләбаса! Шәп, шәп!» — дип төчеләнүдән артыгын ычкындырмады. Әмма аның да сынаулы күз карашында әллә ниләр чагылып китте шикелле.

Айдаш белән Вәсим абыйсына туган туфрактан кубарылып китүе, мөгаен, җиңелрәк булгандыр. Дөрес, аларга да каршы торучылар, киртә куючылар аз түгел иде шикелле. Ләкин елы-ае белән бөтен ил буйлап җилләр убырылып искән һәм намусыңны да, вөҗданыңны да үз дулкынында тибрәлдереп алып киткән чаклар иде лә...

Хәзер инде һава аз гына тына, тынычлана төшкән сыман. Атлар юлыңа алай дуамалланып киртә куючы да күренми. Әмма әтисе белән әнисенең, Туры бабасының, совхоз директоры Таиповның, бүтәннәрнең күз карашы, тирән-тирән сулыш алуы... Сынау аша аңа туган авылы ук томырылып карыйдыр сыман... Бары да йөрәген уч төбенә салып күрсәтүен көтә...

Айдаш белән Вәсим абыйсы келәттә йоклый. Үзләре белән будильникны бу юлы да алганнардыр. Юкса, ни пычагыма инде будильник! Барыбер әниләре дуылдатмыйча торып кузгала алмаслар. Аннары инде ишегалларында дөбер-шатыр мотоцикл гөрелтесе кубар. Кубар да авыл читендәге шома юлдан еракларга китеп югалыр. Таң атып, кояш күренүгә бер алар ишегалдында гынамыни куба андый дөбер-шатыр? Аннары бер Әҗердә генәме?

Рәмзи дә хыялланган иде, армиядә чагында корылып ятучы завод корпусларын әллә нинди хәлләрдә күреп, интегеп бетәр иде. Ә соңгы өч-дүрт көнендә ул инде төштә түгел, өнендә чын-чынлыкта завод корпусларын аркылыга-буйга айкап чыкты. Җитмеш җиде төрле һөнәрең бар икән, рәхим ит: җитмеш җидесенә дә җегәр салырга урын табылыр. Җир йөзендә һөнәр сөй-

гән адәмгә мондагыдан да форсатлырак урын тагын кайда бар икән? Аерата Чаллының үз төбәгендә яшәүчеләргә мач: күңеленә ошаганны сайлый гына бел!

Мәхәббәттә канаты каерылса да... Тормышта, хезмәттә каерылмаган лабаса! Тирәнгәрәк тамыр гына җибәрәсе...

Рәмзи олы төзелешне гизеп йөрүләренә кичә, ниһаять, сөзмә иттереп, күңеленә ныгытып куйган иде инде: ҚамАЗның кою заводына тотыначак ул. Йөрергә дә якын, заводы да ни җитте генә түгел. Башта бетон түшәр, аннары, тырыша-тырмаша торгач, бәлкем, монтажчылар югарылыгына да үрмәли алыр...

Ләкин менә монда, туган авылында...

Югарыда күк гөмбәзе инде шактый сыекланып, зәңгәрсу төскә керде һәм йолдызлар төпсез зәңгәрлектә эреп югалды. Инде сызылып таң атып килә. Авыл тынлыгын ярып, әтәчләр өере янә купты, зәһәрдер тавышлары.

Ә ул агач эскәмиядән һаман куба алмый. Ләкин озакламый кузгалыр. Печәнлектә аның алдан ук үзе хәстәрләп куйган урыны бар — хуш исләр кочагында! Җәйләрен яраткан ятагы!

Әтисе әйтә: таң алдының уйлары хәтәр тыгыз да, хәтәр саф та, ди...

Бу танда егет керфеген дә какмас...

Түбә ярыкларыннан сөзелеп төшкән кояш нурларын күрер, колагында ишегалдында абыйлары куптарган дөбер-шатыр чыңлап торыр, аннары сеңелесе Рәмиләне Чаллыга выжлатып илтеп куяр...

Соңрак, Чаллыдан кайта кайтышлый ук, туп-туры басуга элдертер. Мотоциклы ызан читендә торып калыр. Үзе исә чишенеп атар. Чишенеп аткач, ялан аяклары белән җир җылысын тоя-тоя, торба сузучыларга кушылыр. Басуга үз яңгырларын сиптермәкче булып тир түккәндә, ара-тирә билен яздырырга теләп, сынын турайтыр, әйләнә-тирәсенә күз салыр. Офык читендә куе рәшәгә күмелгән завод корпуслары абайланыр, мондарак исә күз явын яшел кыр-болыннар алыр. Аерата яшелләлек. Яшелчәлектәге аллы-гөлле чәчәкләр — ҚамАЗ чибәрләре. Күңеле тулып, ихтыярсыздан көлемсерәр: шул матур чәчәкләр арасында аңа дигәне дә атып ятмый микән әле? Мәттин агай юраган юш килмәсме?..

Ә бермәлне, тын алырга туктагач, ул ярыйсы гына юан су торбасына утырган хәлдә, бармаклары аша җылы туфракны или-или пышылдап кына әйтер:

— Әти, ичмаса, шушы зәһәр җәй үткәнче... мин синең янында нитсәм...— дияр. Аннары, тирән сулыш алгач, сорау белән төбәлер: — Гаризаны кем исеменә язасы? Таипов исеменәме?

Әтисенең маңгай җыерчыклары кисәк тирәнәеп һәм ишәеп китәр, какча яңаклары тартышып алыр, һәм, улы кебек үк тирән сулый-сулый, сөялләрдә каткан кулын аның иңбашына салыр:

— Таипов исеменә, улым...

Көн уртасында яшь солдат белән карт солдат арасында әнә шулай гади генә гәп булып алыр. Һәм бу гәп өелеп торган буаны ерып та җибәрер...

Ләкин аңарчы ярты көн бар әле. Авыр һәм киеренке уйлар алда әле.

Нибары ярты, әмма дилбегәдәй озын көн!

Аны атлап үтмичә һич ярамый — солдатның вакыт чаңы суккан иде инде...

Алсуланып аткан таң тынлыгында егетнең таза кулы орынуына капка тимере йомшак кына шалтырап куйды...

22

Рәмиләнең баш өстендә җил сызгыра. Кузовта ул япа-ялгызы...

Тәбәнәк кенә үр каршында сузылып утырган туган авылы Әҗер торган саен ераклаша бара. Игәч түбәсендә ул укыган таш мәктәп. Бу җәйне саргылт-яшел төскә буярга керешкәннәр аны. Ерактан бигрәк матур күренә! Үр астында, инеш буендагы киң тугайда купшы ябалдашлы пар тирәк. Сабантуйларда аларга аллыгөлле сөлге-яулыклар эленә — пар тирәк чәчәк аткандай була. Әле кайчан гына алар әнә шулай бизәнеп, чибәр кыяфәттә балкып утырганнар иде. Тирәндә кушылган тамырлар, югарыда кушылган купшы ябалдашлар... Әлегә сау булып тор, туганым пар тирәк!..

Бик еракта, Шилнә авылы ягындагы каен посадкасы буенда, күзгә чак кына эленеп, эфлисун төсендәге трактор озакламый чәчеләсе арыш җирен эшкәртеп йөри. Артыннан, тәмам кибеп, җилләп беткән җирдән тузан болыты күпереп күтәрелә бара. Хәзер кем йөртә икән ул эфлисун төсендәге тракторны? Авыл артындарак, шулай ук шактый еракта, күккә дугайланып менгән су тасмасы абайлана. Нибары берәү генә... Әмма суны, культуралы көтүлектә дә, яшелчәлектә дә, күп иттереп

җиргә торбалар сузып салган көйгә сиптерәләр. Тик болары ерактан күзгә күренми, абайланмый гына. Анда әтисе белән Рәмзи абыйсы, тагын кемнәрдер тир түгә. Әйе, бу эсседә җиргә дым сеңдергәндә су белән бергә маңгай тирләре дә аз таммый торгандыр... Ә мондарак, инеш яры өстендәге юл белән, артына зур арба тагып, бер «Беларусь» элдертә. Арбасында туракланган яшь люцерна өеме, ахры. Абыйсы Вәсимнән калган «елгыр» түгелме икән? Хәзер кем утыра микән?

Рәмиләнең ике аяк арасында җыйнак кына, матур гына өр-яңа чемодан. Кавказ тарафларында сатып алынган солдат чемоданы... Югыйсә өйләрендә аңа алырдай юньле-башлы чемодан калмаган да иде. Зур, иске күн букча тирәсендә чуалган Рәмиләгә абыйсы Рәмзи үзе тоттырды аны:

— Ал минекен, сеңелем... солдат чемоданы бәхетле булырга тиешле,— диде.

Шыплап тутырылган чемоданда бер алышырлык кием-салым эчендә аның документ кәгазьләре. Нибары икәү алар. Мәктәп секретаре Мәликә апасына бик тә рәхмәт инде: әллә ни карышмады, справканы бирде. Ә менә авыл Советында... Нигә дип ул хәтле кыланчык микән Иннек Саниясе? Йомры иңбашларын тагы да йомрылап, авызын гына кыйшайтты:

— Иң әүвәл Таипов абыең янына кереп, рөхсәт сора, кыйгач кашым! Чаво-то ишәеп киттегез әле сез, сөремлеләр!

Директор Таипов янына керергәме? Ул калын кашлары астыннан бер көйдереп карасамы? Тәтенсез япып, көлгә каласыңны бел дә тор! Ләкин Рәмилә төшеп калган кызларданмы соң? Үзе дә четердәп ябышты:

— Нишләп керим мин аның янына? Күзен, октябрь аенда миңа инде унҗиде тула... Паспортсыз яшимме? Менә нигә кирәк лә миңа синең справкаң! Законны бозарга ни хакың бар?

Иннек Саниясе авыз тирәсен ямьшәйтсә ямьшәйтте, әмма буйсынмыйча, күнмичә булдыра алмады. Бу заманда җибәп калганнарны чебен ашар, ди әнә... Ләкин документ юнәтүе ни әле ул. Иң яманы — өйләрендә туган киеренкелекне атлап үтүләре иде.

Монысында аңа солдат абыйсы Рәмзи ярдәмгә килде. Аның да үз хәле хәл, ул соңгы көннәрдә бөтенләй җитдиләнеп, уйчанланып киткән, әмма ул сеңелесенә теләктәшлек күрсәтеп, тыныч кына:

— Монда, сезнең янда мин үзем калам бит... алай

бик тели икән, бер йөрәген басып, ябагаларын коеп кайтсын, булмаса,— диде.

Моңа тагы квартирантлары Людмила Крутько да кушылды. Алар инде үзләренә аерым вагон алуга ирешкән, иртәгә-берсекөнгә инде бөтенләйгә күченеп китәргә тиешлеләр, әмма, шуңа да карамастан, бу киң күңелле, мөлаем йөзле хатын читтә торып калырга теләмичә, ипле сүзе, йомшак тавышы белән болар гаиләсендә туган киеренке хәлне тәмам йомшартып җибәрде:

— Төзелешкә килсә, без аны үз бригадабызга алырбыз. Мин үзем күз дә, колак та булырмын. Һич тә кимхур булмас кызыгыз,— диде.

Мондый хәлләрдә әнисе, нишләсен, күнсә дә күнде, күнмәсә дә күнде Рәмиләнең китүенә... Әтисенең риза булгандай итүе дә бик ярап куйды. Асылда Рәмилә әтисеннән шүрләп йөргән иде: тагы прәжкәле солдат каешы белән өстәл шапылдатырмы? Кыз бала булгангадыр, аңа сугуын сукмый, әмма хәтәр иттереп шапылдата! Ләкин бу юлы чөйдә эленеп торган каешына үрелмәде дә... Ишек яңагына сөялеп, сулык-сулык иткән кызына — әнисеннән инде бер баш югары калыккан нәфис туйрасына — озак кына текәлеп карап торды да һавада бармагын уйната-уйната:

— Кара аны, кызый, җимерек танау белән тупсага кайтып егыласы булсаң, барып та йөрмә! Матур йөз белән, күкрәк киереп кайтырдай булсаң гына, капканы атлап чык! — диде.

Һай, җиңел түгел икән шул ять-яшь көе туган йортыңнан кубарылып китүләре!

Чаллы төбәгендә бер ул гынамы икән? Аннары бер Чаллы төбәге генәме соң? Йөзләрдер, бәлкем, меңнәрдер шулай...

Менә инде Минзәлә юлына чыктылар. Колак төбендә җил сызгыра...

Әнисе: «Кемнәр генә котыртты, кемнәр генә исәрлеккә салды башкаенны?» — дип, теңкәсенә тигән иде. Дөнья үзе — томырылып искән заман җилләре лә!

Ә Женя Мында, аның «мыекбае»? Егетнең күкрәгендә чын ялкын дөрләсә, ирекә чыккан кошын табар, тапмый калмастыр...

Барып төшкәч, әлбәттә, абыйлары Айдаш белән Вәсим янына сыеныр, әгәренки алар: «Әле син шулаймыни? Ташлап киттеңмени әти белән әнине?» — дип артык каты ябырылсалар, авылдашы-яшьтәше Әминәне эзләп табар. Ә бәлкем, көр күңелле, чая холыклы

Людмила апасы аңа тулай торакта тиз генә урын да юнәтә алыр әле... Бер лачын баласын үз куенында сыендырмасмыни Чаллы тикле Чаллы!

Сыгылса да, сынмас өчен купты лабаса!

Әйе, аумастай каты киртәләргә бәрелеп, авыз-борын канаткалар, тулай торакка күчкәч, мендәр кочып, күз яшьләрен түккән кичләре килер, моңа тоташтан ал куанычка күмелгән көннәре ялганыр һәм янә кара хәсрәте коелыр — бары да алда булыр...

Әлегә исә күп нәрсә билгесез.

Кыз баланың бу көндә, бу сәгатьтә күңелендә нык урнашканы, ап-аныгы бары шул: тәүге хезмәт хакына ул һәйбәт куртка сатып алыр да аның шома аркасына эре ак хәрефләр белән кыйгачлатып: «Әҗер авылыннан» дип язып куяр. Ә нигә, төзүче яшьләргә гелән дә зур шәһәр исемнәрен генә язарга димәгәндер ич?. Аннары бер дә бер көнне туган авылына кайтып төшәр дә урамтыкрыкларны буйлап чыгар. Хәтта чалбар да киеп йөрер! Управляющий Гарапша өе турысыннан юри әллә ничә үтәр: күреп бер сөенсен әле үзенең «ата кәҗәсенә»!..

Таш юллар да бормалы...

Чаллы каласы зәңгәр рәшә эченә күмелгән. Ул әкренләп абайлана бара...

23

Бүген иртән Хәнәфи Бариев, улы Рәмзине ияртеп, үз эшенә сугарулы көтүлеккә килсә, моторист Мөбәрәй эшкә чыкмаган. Бераз сабыр иттеләр, көттеләр. Ләкин юк, килмәде, күренмәде ир уртасы адәм...

Мөбәрәй совхозда уңган механизаторлардан исәпләнә, ул инде үз комбайнын әллә кайчан ремонтлап куйган, аны әзерлек сызыгына бастырган һәм бүтәннәргә булышырга тотынган иде. Ләкин совхоз директоры Яхъя Таипыч аны, уракка төшкәнче болын сугаручыларга ичмаса бер ныгытып ярдәм итешерсең дип, болар янына җибәргән иде. Иple һәм кульдәм холыклы, үтә тырыш бу кешенең, кул араларына кереп, һәрчак төпле һәм эшлекле ярдәм күрсәтә белүе мондагыларга, әлбәттә, бик ярап куйды. Бүтән көннәрдә Мөбәрәй гадәттә кояш белән үк торып эшенә юнәлә һәм, Хәнәфи белән аның улы Рәмзи сугарулы көтүлектә күренгәнче, ул инде анда тегесен караштырып, бусын рәтләштереп, бигрәк тә буа ярындагы насосны майлап-көйләп куйган

була, хезмәттәшләрен исә офык артыннан чыгып килгән кояштай балкып каршы ала торган иде. Ник күренми соң әле ул, ни тоткарлады икән аны бу тып-тыныч иртәдә?

Килмәгән кешене көтеп, көн үткәреп булмый, әнә инде кояш терсәк буе диярлек күтәрелеп тә өлгергән, ул арада сулышлары каба язып ике-өч яшүсмер егет тә килеп житте — болар, бары бер булып, җәһәт кенә эшкә керештеләр. Сугару бөтенләй эләкмәгән кишәрлекләр хәтсез әле. Сузаеп-агарып яткан дюраль торбаларны кичә үк дымга туенып калган өлешләрдән сүтеп-таратып, болынлыкның бөтенләй дым татымаган өлешләренә ташыйсы-күчерәсе дә яңабаштан ялгаштырып-сузып җибәрәсе. Рәтлисен рәтлисе, көйлисен көйлисе. Шактый ук четерекле һәм мәшәкатьле хезмәт. Тегендә иелеп, монда бөгелеп, анысын күтәреп, монысын төшереп әрле-бирле йөри торгач, иртәнге сәгатьтә үк билләр-сыннар калмый. Иң ахырда, кишәрлектә бар нәрсә дә тәмам әзерләнеп беткәч һәм кабаттан тикшерелеп чыккач, буа ярына төшеп, андагы насосны эшкә җигәсе...

Менә, ниһаять, бу четерекле эшләр һәммәсе дә артта калды — магистраль линиягә челтер-челтер су тулды, аңардан ялгаш торбаларга күчте һәм бихисап гидрант краннары бары берьюлы диярлек челт тә пелт иткән тавышлар чыгарып, әрле-бирле хәрәкәтләнергә тотынды — шул чакны ярыйсы ук киң кишәрлек тоташып яуган яңгырга күмелде. Болар һәр иртәдәгечә бары бердәм булып җиңел сулап куйды, кул аркалары белән маңгай тирләрен сыпырып төшерде.

Әмма моның белән генә эш бетмәгән иде әле. Хәнәфи магистраль линиядән бүленеп киткән аерым торба җепсәсен ачып куйды да читтәрәк, икенче бер кишәрлектә тын гына, моң гына көтеп торган тракторга таба юнәлде. Агай әллә ни озак матавыкланмады, тракторны кабызып һәм аны ары табарак күчереп, икенче бер олы гидрантка тоташтырды да насосны көйләп җибәрде — рәхим ит, әнә инде анда да юан гына су бавы югарыга чөелде дә, һавада чуклы-чачаклы киң тасмага әверелеп һәм дугай-дугай сибелеп чәчелеп, түбәнгә, җир өстенә, яңгыр булып коела да башлады.

— Хәзер менә тәмамлый булды дисәк тә ярый, егетләр! — диде Хәнәфи, мондагылар янына кире әйләнеп килгәч, канәгатьләнү аша тамак кыргалап, әмма гадәтенчә саран гына елмаеп.— Бар тырышканнарыбыз куе, сусыл үләннәр булып үссен дә иң азактан, сөт-катык,

май-каймак рәвешендә, кемнәрнеңдер өстәленә менеп, тамакларыннан татлы сый булып үтсен, диик! Инде хәзер үзегез дә бер иркенләп тамак ялгап алсагыз була, ә мин чәйләп килмичә булдыра алмамдыр, ахрысы...

— Бар, әти, бар! Әни сине көтеп утыра торгандыр анда,— диде Рәмзи.

— Бүген, Мөбәрәй югында, зинһар, улым, уяураксаграк бул, үзең дә беләсең: буа насосы да, тракторныкы да чыгымлаучанрак.

— Кайгырма, сынатмабыз! — диде Рәмзи, ак тешләрен елтыратып.

— Беренче көнебезмени? Чәеңне тәмләп эч, Хәнәфи абай! — дип елмаешты әле мыек тибәргә дә өлгермәгән яшүсмер егетләр дә.

Алар — Рәмзи үзе дә, бу ерык авызлар да — инде бая ук өсләреннән салып атканнар, нибары плавкилардан гына калып, ясалма яңгыр астында инде чыланып та өлгергәннәр, шул сәбәпле аларның янып-көеп каракучкылланган таза кулбашларында, тыгыз тәннәрендә елык-ялык кояш нурлары уйный иде.

Хәнәфи аларга бүтән сүз катмады, уң кулы белән биленә таянган килеш, әйләнә-тирәгә, шаулап торган ясалма яңгыр болытына, су сиптерелгән кишәрлекләрдә күпереп күтәрелгән куе яшел үләннәргә, бермәл күз йөрткәләп алды. Хозурлык! Күңел куаныч белән тула... Их, җир өсләтә киңрәк, колачлырак иттереп сузып салырга торбалар җитенкерәми, шуның аркасында инеш насосын бар куәтенә эшләтә дә алмыйлар. Өч-дүрт сәгать сиптереп, бүлеп алынган кишәрлекне дымга тәмам туендыргач, насосны янә туктаталар, торбаларны кабаттан сүтеп-күчереп, кабаттан — инде бүтән кишәрлектә, дымга тилмергәнендә — ялгарга һәм көйләргә керешәләр. Иртәнге кояштан алып кичке эңгергә тикле әллә ничә тапкыр шулай... Бүгенгә бүтән әмәлләре дә юк. Авыр дип, чигенергә дә ярамый. Дөньяда гап-гади «Кирәк!» дигән сүз бар. Шул сүз җигә эшкә, шул сүз өнди адәмне алга табан.

Болынлыкта иртәнге сәгатьтә үк эшне шушылай гаять кызу тотып, байтак тирләр агызгач кына, тамак ялгау исләренә төшә. Рәмзи дә, яшүсмер егетләр дә коры-сары белән, сөт белән канәгатьләнә. Төшкелеккә исә алар чиратлашып кайтып киләләр, әмма яшьләр анда да, ешрак вакытта авыл ягына кырын карап, үзләренең кыр букчалары янында, ризыгын-ныгъмәтен,

уенын-шуклыгын бергә кушып, басуда кала. Хәнәфи, әлбәттә, үзен алай чикли алмый инде. Үз гомерендә ул туган басу-кырларында, коры-сары белән генә тукланып, бик күп йөрде. Аңа хәзер кайнар аш кирәк — ансыз булмый. Иртәнге чәй аерата кадерле. Хатыны инде чәйне кайнатып өлгергән, ике күзен дүрт итеп, иренең кайтуын көтә. Тынып калган өйдә, аулакта алар каракаршы утырышып чәй эчәләр. Ашыкмыйлар. Тегесебусы турында ипле генә гәп куерталар. Кызлары Рәмилә Чаллыга китеп барганнан бирле Рәсүлә үзен кая куярга белми. «Ул гарасатка никләр җибәрдем соң? Аның теге мыекбае да кемдер бит әле, җүнләп белгән җук. Бик җәшләй харап итеп ташламасалар гына җарый инде бердәнбер кызыбызны!» — дип ачыргалана, үкенеп бетә алмый. Иртәнге чәйләре исә күңелләренә кунган яисә кунарга торган ачы юшкын тузанын юа да җибәрә. Рәсүлә үзе әйткәнчә, монын соңында инде ул җаны тәмам тынычлануын, хәтта сөякләре җиңеләюен тойган хәлдә, яшелчәлек бакчасы төбендә торган походный кухнясының казанына су салып, учагына ут тамызырга дип, җәт-җәт чыгып китә. Ие, иртәнге чәй аның хатыны Рәсүлә өчен икеләтә кирәгрәк...

Хәнәфи кайтыр ягына таба атлады. Авылга тикле ара әллә ни ерак түгел: менә шушылай үз җаеңа ашыкмыйча гына атлаганда, нибары ун-унбиш минутлык юл үтәсе. Ләкин Хәнәфи, тез тиңентен күтәрелгән куе һәм сусыл үләнне ерып, алай бик ерак китәргә дә өлгермәде, адымнарын әкренәйтә төште: авыл ягыннан болай таба кемдер килә иде. Үзе кыска җиңле ак күлмәктән, башында салам эшләпә... Бәрәч, Мөбәрәй ләбаса! Ерактан ук авызын ерып килә, атлаулары да кыешмыеш кебегрәк. Салмыш түгелме соң бу?

Мөбәрәй, килеп җитүенә, кулын киң изәп күрешге.

— Син нәрсә, Мөбәрәкша, ни ураза, ни бәйрәм дигәндәй... кызу эш өстендә, ә? — дип төбәлде Хәнәфи, тавышын шактый коры тотып, әмма тегенең исемен тулы әйтеп.— Ә мин тагы монда... Кичәгенәк ишеткән идем: имеш, «Сельхозтехника»га сугару торбалары кайткан, ди, шуны эләктереп калырга управляющий Гарапша үзе барырга ниятләгән, ди. Миңа әйтмичә генә, әллә сине дә үзе белән иярткәнме, дигән идем бу иртәне... Ә син, бактың исә, әнә кайсылайда...

— Барды ди!.. Төкерәм мин Гарапшага! Төкерәм сугару торбаларыгызга! — Мөбәрәй буш сүз әйтмәвен расларга теләп ахры, аягы астына төкереп үк куйды.—

Китәм мин!.. Гаризам директор өстәлендә... секретарена әйтеп калдырдым... ягъни дә бүгеннән башлап дүрт ягым кыйбла!

Хәнәфинең өстенә капыл гына бер чиләк салкын су койгандай булды, гәүдәсе бөрешеп куйды, сулышы буылды, һәм ул Мөбәрәйнең беләгеннән кысып тотты.

— Шаштыңмы әллә син? Бер кешене кырыкка ярырга торганда... Безнең мондагы эшләргә төкерсәң дә, ике-өч көннән штурвалга басасың бар ич!

— Әнәтерә Гарапша үзе бассын! — Мөбәрәй башын кыегайтып, күзләрен ямьсез чекрәйтеп карады, тавышы кисәк сынып китеп, тотлыга ук башлады.— Ә нишләп ул... минем хатын белән малай чабып... киптереп куйган... өч чүмәлә печәнне... машинага төяттереп...

Бераздан Хәнәфи аңлап алды: кичә кичке уңайда болар, ат җигеп, Әҗер урманы янына җыеп-өеп куйган печәннәрен алып кайтырга дип менсәләр, аңардан җилләр искән икән. Куак араларыннан, чокыр-чакырлардан мең җәфа белән чабып-җыеп алган ул печәнне — бер Мөбәрәйнекен генә түгел, тагын берничәләп кешенекен — Гарапша машинага төятеп, ферма янына кайтарып аударткан.

— Син әйт миңа, Хәнәфи абай: шушылай зәһәр корыткан елны совхоз печән-саламнан берәр күтәрәм өлеш чыгара аламы? Тот капчыгыңны! Үзең дә сыер-сарык асрыйсың, аңларга тиешсең! Ә ул?..

— Кемнәр алып кайткан?

— Үзебезнең авыл шоферы тияме соң! Шул Чаллы акайганнары инде, урманга яфрак, ботак-санак ботарларга килүчеләр... Аларга нәрсә: синеке ни, совхозныкы ни...

— Директор беләме?

— Белмәсә, белер... Монда сыер асрыйм, балаларга сөте-катыгы кирәк дип интегеп ятканчы... Әнәтерә Чаллыда мае да, сөте-катыгы да кибет тутырук, ди. Анда аның акчасын да күрәп кенә алалар!

— Җир кешесе бит син! Беткә үч итеп, туныңны утка ташларга булдыңмы?

— Ычкындыр кулны!.. Төкерәм мин синең туныңа! Бүген гүләйт итәм мин! Җәл, үзебезнең кибеттә җилләр уйный. Өйдәге запас та тәк сибә генә иде. Аптырамыйм: әнәтерә Илбакты кибетенә «үгез каны» кайткан, ди. Урак алдыннан азаккысы иттереп... Әйдә, син дә төкер дөньясына, Хәнәфи абай! Ичмаса, бер иркендә сәй-

ран йөреп кайтырбыз, ә! Бармыйсыңмы? Соңыннан үкенмәссеңме?

Хәнәфинең Мөбәрәйне тотып торырлык түгел, авызын ачып, аңа сүз әйтерлек тә хәле калмаган иде шикелле. Мөбәрәй, алпан-тилпән килеп, кишәрлек кырыйлатып, түбәнгә, инеш буена, анда яр өслэтә Илбактыга илтә торган сукмакка таба атлады. Менә инде ул карлыккан, ачы тавыш белән җыр да сузып җибәрде:

Уңга атлап, сулга кит,
Мәскәүләргә барып җит!
Кыз дип алып, хатын булса,
Ат урнына сыер җик!.. Их-ләй!

Ләкин әллә ни ерак китмәде, кисәк чалгы тиеп чабылган рәвештә, түбән чүкте һәм, әйләнә төшеп, җиргә утырды да, башын кочып, тынып калды.

Әле кайчан гына, нибары биш-ун минут элек кенә, Хәнәфи өчен дөнья хозур иде, күңеле куану белән тулган иде. Хәзер исә күктәге кояш та, җир өстендә яңа сауган сөттәй парланып яуган яңгыр да, кишәрлекләрдәге хәтфә үләннәр дә — бары да соры томан эченә кереп күмелгәндәй булды. Ярсудан җаны уттай яна башлады. Әнә анда куллары белән башын кочып утырган сәрхүш адәмне, үзләре су сибеп үстергән үлән арасына егып салып, бер туйганчы изәсе-яргалыйсы килде. Юк, Мөбәрәйне түгел, аны шушы хәлгә төшергән икенче берәүне, куш иякле, каклаган каздай симез йөзле бүтән бәндәне, уңлы-суллы яңаклыйсы килде. Менә хәзер үк, көне-сәгате белән! Халык алдында!.. Ләкин Чаллыдан торбалар төяп кайтып төште микән әле ул ләгыйн?

Әюк, кызмау хәерлерәк. Иң әүвәл чәйләр эчеп, җанны тынычландырырга, акылны җыя төшәргә кирәк. Тик шуннан соң гына берәгәйле иттереп ямыйсы булыр! Сеңерләренә тикле сеңдереп, онытмаслык иттереп!..

Авылга хәтле ике араны Хәнәфи ничек узкәнен дә хәтерләмәде. Әмма өенә кайтып керсә, монда да хәлләр икән...

Хатыны Рәсүлә, әлбәттә, иртәнге чәйне дә кайнатып куйган, аның инде төшкелек өчен, тәмле ис таратып, итле шулпасы да кайнап утыра, әмма ул, алгы бүлмәдә табын әзерләүнең кирәклеген онытып, түр өстәл янында утыра. Алдында ап-ак, чиста кәгазь битләре, кулында авторучка. Ә өстәлнең каршы ягына исә аягоч күршеләре Фәгыйләттәй кереп сыенган — бусы, борынын тарта-тарта, яулык очлары белән күз төпләрен сөртештергәли иде.

Хәнәфи, бу ни әкәмәт бу дисә, Фәгыйләттәй, йорт-курасын сатарга ниятләп, шул хакта игъланнар яздырту өчен, Рәсүлә янына кергән икән. Ир заты, бу хәлгә хәйран аптыраштa калып, ары таба сорашса, сәбәбе һаман да шул бер Гарапша кылган явызлыктан икән.

— Алла боерса, кантур ишегенә дә элеп куям, авыл Советына да ябыштырам, берәрсеннән Чаллы автовокзалына да ябыштырттырам. Җә инде, җазуыңны бел, дим, Рәсүлә җаныкаем! Күрше хакы — алла хакы диләр ләбаса! — дип ялварды Фәгыйләттәй.

— Әнә шул күрше хакы булганга күрә, җаза алмыйм, булмый миннән! — диде Рәсүлә, кулындагы авторучканы өстәлгә куеп, һәм, ярдәм эзләгәндәй рәвештә, дымлы күзләрен иренә төбәде.

Хәнәфинең сулышы янә куырыла язган иде, ул, бая культуралы көтүлектәге шикелле үк, үз тавышына үзе буылып эндәште:

— Акылыңны җый, исеңә кил, Фәгыйләттәй!

Моңа җавапка түти, җиңнәрен сызганып, тамырлары каралып бүселгән ике кулын да Хәнәфигә таба сузды:

— Менә шушы пенсионер кулларым белән чапкан да, җыйган да ием ләсә ул ике чүмәлә печәнне! Ә ул мөртәт? Баермы шуның белән савхуз? Кышка ни белән керим мин?.. Җу-ук, сатам дигәч сатам! Өем белән абзар-кураны да, кәҗә белән сарыкны да! Әнә анда Сталинград төбендә Идел җарында гөрләтеп җәшәп яткан улым белән киленем әледән-әле: «Җатма анда җапа-җалгызың җәфалар чигеп, кил үзебезнең җанга!» — дип чакырып кына торалар. Озакка сузмыйм, кубам булгач, кубам!

— Ул иблис колы Гарапшаны утлы табага бастырып бер биетәбез әле, печәнең дә кире кайтарылыр, исеңә кил, дим, Фәгыйләттәй!

— Искә киләсе җук... Әле рәхмәтләр әйтәм ул мөртәт Гарапшага: моңа тикле ни вакытлар әйле-шәйле, икеле-микеле булып җөргән ием, маладис, ичмаса: култык астыма кычыткан кыстырса да кыстырды, әмма ләкин туган туфрагымнан капыл гына кубарга иттерде! — Фәгыйләттәй, яулык очлары белән күз төпләрен янә бер сөртеп алгач, ялварулы караш белән Хәнәфигә текәлде:— Син инде, күршегенәкәем, алай-болай өй-кураларыма ия чыкмаса, аның тәрәзәләрен, ишек-капкаларын кадаклашырга килерсең әле, җәме?!

— Уйлама да! — дип кырт кисте Хәнәфи.

Мондый җавап ишетүгә, Фәгыйләттәй утырган җиреннән купты да, бер тын ара әле Хәнәфигә, әле Рәсүләгә күз атып торды, аннары, тавышы сынып куйса да, ачусыз гына, йомшак кына иттереп әйтте:

— Син җазмыйсың, ә син теләмисең... Җарый айсам, бигайбә! Авылыбыз зур гына, арадан берәр кулай кеше тапмый калмам әле...

Һәм ул, күлмәгенең киң һәм озын итәген җыя төшеп, үз алдына укына-укына чыгып китте.

— Тәмам җинеләйгән сыман,— диде Рәсүлә, авыр көрсенеп.

— Җинеләерсең дә!..— дип сыкранды Хәнәфи дә, аның хәтта тешләре үк шыгырдап куйды кебек.— Бер селтәнүдә ничәмә кешенең бәгыренә хәнҗәр чәнчегән бит ул нәгъләт!

Хәнәфи чәйләп утырырлык хәлдә түгел иде. Күкрәгендә ярсып дөрләгән ялкынны басарга теләп, голт-голт иттереп бер чүмеч салкын су гына эчте.

Машина-трактор утары янындагы складлар тирәсе буп-буш, анда бер җан иясе дә күренми иде. Әле кайтып төшмәделәр микәнни? Әллә торбаларны туп-туры культуралы көтүлеккә илтергә булып, анда бушатып яталармы?

Ә юк, әнә эчкәредә, аулаграк почмакта койма буенда бер машина туктаган. Аның ачып куелган кузовына исә... сугару торбалары урынына нәп-нәзек водопровод торбалары төялгән иде. Шунда ук шофер егет белән Гарапша да тора: йөкне кая, ничегрәк бушату хакында баш ваталар, ахрысы.

Хәнәфи сәлам биреп тә тормастан, тегеңәргә:

— Ни кылып йөргәннәреңне азрак уйлыйсыңмы син, Гарапша? Авылдашларыңа этлек эшләүләрдән берәр кайчан туктый белерсеңме? — дип кадалды.

Гарапша башын ялт кына болай таба борды, әмма ул кашларын җыерып бермәл генә торды, симез йөзе җәелеп китте, үзе ашыга-кабалана йомшак-төче тавыш белән сипли дә башлады:

— Ә-ә, син икәнсең әле... ни бит... сугару торбалары бу юлысында тәтемәде бит безгә... Ярый әле, Минзәлә дуслар очрады. Алар белән тегеләй кыйландырып, болай әйләндереп, менә боларны юнәтә белдем барган уңайдан... Совхоз өчен әллә ни кирәге дә чыкмас, бәлкем, әмма үзебез өчен үтергән дә куйган инде! Колонкадан чиләнеп сулар ташыганчы, үз өеңдә водопровод

краны, дим, шаулап утыра, ә! Һе, әлбитте, үз кеше итеп, сине дә читкә какмабыз!

Гарапшаның йөз-кыяфәтеннән дә, сүз сөрешеннән дә аларның бу сәфәре төбендә кыек-мыек эшләр ятканлыгын шәйләве әллә ни кыен булмас иде, ләкин бу минутта Хәнәфинең күңелендә торбалар хәсрәте идеме соң?

— Кадалсын ла ул нәрсәләрең! — дип кычкырып куйды Хәнәфи, күзләрендә усал чаткылар чатнатып.— Ни җан белән син авылдашларыңның хәләл көчләр куеп әзерләгән печәнен кичәгенәк ферма янына кайтарып аударттырдың, ә? Ни хакың бар?

— Эһе, әнә ни артыннан йөрисең икән әле син, басудагы эшеңне ташлап...— Гарапшаның авыз тирәсе шундук җыелып, күз алмалары агарып алды — гомумән, аның бар йөзе минуты белән кырыс һәм төксе рәвешкә керде. Әнә койма буендагы соры таш ни дә бу ни.— Хакларым үзем белән — белдеңме? Ә син гәүдәңне сузайтма монда җыен ертлачка терәү булып! Эшләр болай да таркау. Аздырмасыннар халыкны!

— Синең аркада Фәгыйләттәй әнә өен сатып китмәкче, ә Мөбәрәй эшне ташлавы хакында директорга гариза илтеп тоттырган да инде. Ә бит ул алдынгы комбайнчы — озакламый ана штурвалга басасы!

— Печән кемгә кирәкми? Ырвачланмасын, иң әүвәл уртак хезмәт хакында уйласын! Комбайнчы, имеш! Кайгырасы юк: әнә Чаллыда дөнья тутырук механизатор — безгә таба юл күрсәтүчесе тиз табылыр!

Моңа сөйләдең ни, әнә теге бетон баганага аңлаттың ни...

Хәнәфи, бу туң йөрәк белән инде кычкырып сөйләшер тәкате калмаганга, азаккы сүзләрен теш аралый кысып чыгарды:

— Ишетсен колагың, Гарапша: йомшыйсыңмы-йомшамыйсыңмы, әгәренки авылдашларның күңелен күрә белмәсәң и шулай ук Мөбәрәй иртәгә эшкә чыкмаса... мин дә тегендә иртәгә үк яңгыр сиптерүләрне туктатам! Минем дә гариза директор өстәленә Мөбәрәйнеке белән янәшәгә барып ятачак!

— Өркеттең бик! Куркудан менәтерә мыек чолгыйларым тырпайды! Үзең син киртләп куй: моңарчы, совет власте яшәгәндә, колхозның таркалганы булдымы? И совхоз да таркалмас! Ирек бирмәбез!

«Булмаган мыек чолгыйларың ничек кенә тырпаер әле, үзең дә бер тончыкмый калмассың әле! — Монысын Хәнәфи өенә таба атлый-атлый үз алдына тәкрарлады.

Әмма ул кинәт тукталды да, ике уйлап тормастан, кирегә, культуралы болынлыкка таба юл тотты.— Тукта, нишләп иртәгәгә калдырырга соң? Су сиптерүне ник бүген үк туктатмаска ди? Рәмзи белән егетләр аптыраса аптырар. Тик бәгырьне генә, Гарапша кебек үк, ныгытып катырасы да... Ичмаса, аңларлар бүгенге көндә механизаторларның чын кадерен — Гарапша да, аны үз канаты астында асраган Яхъя Таипыч үзе дә...»

24

Түбә кыегыннан тып-тып яңгыр тамчылары тама. Тама да уйларны әллә кайларга алып китә...

Шәп булды әле бу! Рәхмәт инде, әллә ни озак булмаса да, утырыбрак, сеңдеребрәк ява да белде.

Җиргә тансык, җанга тансык... Югыйсә көн урталарына рәхимсез кыздырган кояш эссесеннән җелекләр кибеп, баш миләре кайнар дәрәҗәгә җитә иде. Ачыграк, шәрәрәк төшләрдә җир әллә кайчан яргаланып бетте. Урманнарга тиктомалдан чыгып йөрүләр дә җәй башыннан ук тыелды — Казан радиосы көн туды исә бу хакта кисәтеп кенә тора. Чишмәләр тибәр-типмәс хәлгә җитеп килә, инешләр күзгә күренеп саекты, басуларга чыктың исә, игеннәр белән бергә җаның көя. Дөрес, моңарчы да яңгыр, җаннарга җылы бөркеп, үз исен сиздергәләгән, алай гынамы, бер-ике тапкыр кара-кучкыл болытның күк гөмбәзен иңләп, ишелә-актарыла һәм җир өстен ялт та йолт камчылый-чыбыркылый килгән чаклары да булды, ләкин — ни гаҗәптер — дөньяның яман тузгынуы кысырга булып чыга, җиргә тамчы да яңгыр төшми иде. Күңел кыллары әрнү-сыкранулардан, хәвефле пошаманнардан инде соңгы чикләргә җитеп киерелгән иде. Ичмаса, табигатьнең бу куркыныч зәһәрләнүенә кешеләрнең үз тормышында, үзара мөнәсәбәтләрендә, чи ярага тоз булып, төрле чиктак-чатаклык, ярсу-усалланулар әледән-әле туып һәм өстәлеп тормаса икән...

Җирдәге табигать хәлен, адәмнәр хәлен, ниһаять, аңлады, ахры, күк йөзе. Аңлады да менә бүген, кызарып кояш баеганда, ниһаять, шәфкатькә килде...

Их, чак кына элегрәк, сабантуйларга хәтле, һич югы игенченең шанлы туйлары узгач ук, шушылай бер-ике явып киткән булса соң! Ярый, монысына шөкрана кылып, сөенә бел! Арышка файдасы тимәс инде, аны иртәгә-берсекөннәргә урырга да керешәчәкләр, ә менә

сабан игеннәренә килгәндә исә... тәмам көеп-кибеп беткәнче, боларның дымга сусаулары басыла төшеп, бөртекләре аз булса да тукланыбрак китәр, ичмаса. Ә кукуруз, чөгендер, бигрәк тә бәрәңге ишесенә файдасы ни тиклем? Күзге чәчүгә кадәр тагын шушылай бер-ике явып китсә, табигать үзе дә иркен сулыш алып, рәхәткә чумып ятар, игенче-крестьянның да кителгән күңеле тәмам түгәрәкләнә язар иде.

Аннан килеп, әле җәйгә кергәндә үк Үтәдем һәм Чуар «изгеләренең»: «Өч ел рәттән җәйләр шушылай коры торып, адәм баласына ифрат кыенга туры киләр»,— дип яман юраулары бөтенләй юш килмичә, адәмнәр күңелен алдан ук богаулап алган куркыныч хәвеф-пошаман зынҗырының челпәрәмә җимерелүе түгелме соң әле бу?

Бариевларның өялдылары ярыйсы ук киң дә, иркен дә. Аның бер кырыенда җайлы гына сәке бар. Берүзенә җәелеп, аяк сузып ятардай гына. Хәнәфи бүген менә шунда урнашып алды. Башы йомшак мендәрдә, аста тузгый төшкән түшәк, өстендә иске толып — мондыен йомшак төнне тагын ни кирәк!

Җәйләрен еш кына оялдына чыгып яткалый ул шулай. Төнге дөньяга колак салган килеш рәхәт тә инде оеп китүләре!..

Ә бүген, көндезен ни алҗыган булса да, тиз генә изрәп китә алмый иде. Хәер, турысын әйткәндә, алай оеп китәргә бик үк теләми дә иде.

Инде төн урталары авышкандыр.

Квартирантлары Аркадий Крутько, уянып, ятагыннан купты, һәм, тәмәке кабызып, байтак вакыт ишегалдында югалып торды. Кире әйләнеп кергәч, хатыны Людмила белән ни турындадыр гөлдер-гөлдер сөйләшеп алды, аннары веранда эче янә тынып калды. Алар бу түбә астында азакгы тапкыр төн куна: вакытлы поселокта үзләренә аерым вагонда яшәү өчен, бүген, ниһаять, кулларына ордер алып кайтканнар. Җылы һәм йомшак төн, шифалы төн — алдагы тормышларында иминлек һәм зур куанычлар китерсен инде үзләренә!

Тып-тып тама да тама төнге тамчылар.

Чаллы төбәген һәйбәт чылатып китте лә! Тик бу төнне, менә шушы сәгатьләрдә кайларда һәм кемнәр генә, тамчы моңын тыңлый-тыңлый, уйлар диңгезенә чумып ятмый икән? Мөгаен, бер ул гына түгелдер...

Ә Хәнәфи ни нәрсә уйласа да, күңеленә ни килсә дә, бар уй-хисләре, тора кайтып, хатынының бертуган абый-

сы Ризван-агроном белән булган бәхәсле гәпкә ялгана да китә иде.

Һәм ул сөйләшүне дә бер дә әллә ни түгел, нәкъ менә шушы җылы һәм шифалы яңгыр үзе алып килгәндәй булды...

Хәнәфи, аягына тирән кәвешләр киеп, өстенә кожан элгән килеш, ишегалдында кыштыр-кыштыр яңгыр суларын җыеп йөри иде. Күктән ипле генә явып торганда, мунчадагы олы чапчакны һәм мич казанын йомшак су белән тутырмыйча ярый димени?

Бермәлне, келәт ышыгына посып, чиләк-ләгәннәргә яңгыр суы тулуын көтеп торган чагында, тимере авыр шылтырап, капка ачылып китте һәм ишегалдына калку гәүдәле берәү килеп керде. Тәрәзәдән төшкән яктыга эләгүенә Хәнәфи аның кемлеген шундук абайлап алды һәм:

— Монда кил, кордый! — дип, үзе янына чакырды.

Ризван да өстенә башлыклы плащ киеп алган, аягында резин итекләр. Әллә ни йомышы да юк икән, контoрадан кайтышлый болай хәл белергә генә сугылуы икән. Агроном кеше, билгеле инде, иң әүвәл шушы яңгыр уңае белән чиксез куанычын белдерде:

— Тели торгач, тәки килде бит, ә! Югыйсә, тәмам янып-көеп бетәсе идек.

Әмма, бу юнәлештә сүзне әллә ни тирәнгә җибәрмичә, өйдәгеләр хәленә күчте һәм беренче итеп сеңелесе Рәсүлә турында сүз кузгатты.

— Соң, ничек дип... шулай инде,— диде Хәнәфи, җилкәсен тартыштыргалап.— Рәмилә Чаллыга китеп барганнан бирле, башын кая куярга белми йөди, үрсәләнеп бетә. Аның бит хәбәрен дә юньлесеннән битәр ямьсезен, хәтта куркынычлысын күбрәк ташып торалар.

— Хәлләр, диген.

— Әле ярый, көндезләрен үзенең походный кухнясы тирәсендә кайнаша, халык арасында була — бер онытылып торырга җай... Ә кичләрен... әнә телевизорга төртелеп утыра... ул да булмасамы? Әйдә, керик, хәл-әхвәлен үзең сорашырсың. Бергә-бергә чәйләп тә алырбыз.

— Юк-юк, борчымыйк аны, утыра бирсен. Әле бер иркенләбрәк сугылырмын,— диде Ризван һәм монда, ишегалдында гына калырга ныклы ниятгә булуын аермачык сиздереп, келәт сайгагына җәелеп утырды.— Ипле генә үткәзер әле... Рәмиләгез дә югалып калырдай

кызлардан түгел, энисе Рәсүлә дә чыдам бәгырьлеләрдән.

— Шулай дип юаныйк инде.

— Әле ярый, Рәмзи үз яныгызда торып кала белде — молодец егет. Ә Вәсимегез теге чакны... узган эшкә салават дигәндәй, хәзер әйтсәм дә ярый инде, китәр алдыннан минем янга да киңәш сорап килгән иде.

— Соң?

— Ни әйтәсең инде аңа? Ак димәдем, кара димәдем, үз акылың үзеңдә, егет, әмма иң әүвәл йөрәгең кушканны тыңла, дидем.

— Ишкәнсең икән,— диде Хәнәфи теш аралый гына.— Үзең, җитмәсә, баш агроном тагы, совхоз тоткаларының берсе.

Мондый тәрттерүгә Ризванның тамчы да исе китмәде.

— Үзебезнең егет чакларны искә төшерик, кияү! Егет чакларыбызны! — диде ул, киң бер сулыш белән.— КамАЗ куптарган мондый дулкынга син чыдар идеңме, мин чыдар идемме? Аның дулкыны без күргән-белгән дулкын гынамы... тап «цунами» лабаса!

Хәнәфи кожаны эченнән муенын сузмыйча булдыра алмады:

— «Цунами» диденме? Анысы ни тагы?

— Улмы? Океандагы дулкынның иң хәтәре, иң дәһшәтлесе... Каян була дисәң, сәбәбе шул аның: океаннар төбендә дә, җир өстендәге шикелле үк, зур-зур тау сыртлары тезелешеп киткән, ди, төрле чоңгыллар тагы. Менә шул тау сыртының берәрсе ишелеп төшсә яки анда каты җир тетрәү була калса, «цунами» дулкыны куба. Галәмәт зур тизлектә океаннар буйлата чабуын белә, ди, җир шарын бер генә әйләнеп үтми, ди. Ә инде ярларга килеп бәрелсә, ни барын пыран-заран китереп, җимерә-тузгыта, ди. Дингез ярлары танымаслык булып үзгәрә, ди. Ә болай үзе ерак океан эчендәге кораблар өчен берни түгел, аларны тик тирбәтеп кенә уза, ди...

— Беренче ишетүем... Ә син... ни... КамАЗны шул «цунами» дигән хәтәр дулкынга тиңләмәкчемесең?

— Әллә тиңләмәстәйме? Дулкыны бөтен ил күкрәге буйлата тәгәрәп узды, әллә нинди авыл-калаларны кузгатты, ә ябырылып килеп айкалуы-чайкалуы безнең үзебездә лабаса! Юк, пыран-заран җимерде дә тузгытты димим, киресенчә, дөньябызның, тормышның тамырдан үзгәреп янарасы җаеннан әйтәм.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява торды, Хәнәфи, келәт кые-

гы астында муенын киң җилкәсенә батырган килеш, уйга чумып торуында булды.

Менә шулчакны Ризван тел төбендә саклаган иң әһәмиятле сүзен әйтте дә инде; мөгаен, ул шуның өчен генә кергән дәдер әле:

— Ә без синең белән, яшьти, утны да, суны да кичкән бәндәләр. Тамырларыбыз җиргә тирән киткән безнең. Инде алай-болай авабыз, егылабыз икән, шундук баш калкытырга тиешлебез. Калкытырга да, җиңнәрне сызганып, кабаттан маңгай тирләрен агызырга... Кем әйтмешли, җиребезнең җанлы кыялары сыман...

Хәнәфи монысында тагын да озаграк дәшми торды.

— «Җанлы кыялары» димсең...

— Шулай, кияү... Ә син теге чакны, хәтерлисеңдер, кыр-басуларда бүтән йөрер тәкатем калмады, фәлән дип, төгән дип, Таипов кабинетында вай-вай ла шәлберәеп төшкән идең!

— Соң, актык чиккә җитеп җан кыйналулардан бит.

— Әллә минем йөрәккә кан саумыймы ул каймактай җирләр өчен? Ярый, син шәлберәйдең, мин шәлберәйдем, ди, бүтәннәр тагы... Совхоз ишелеп төшсенме?

— Әллә кайчангыны кузгатмасана, кордый,— дип шыңшып алды Хәнәфи.— Хәзер үз эземдә бит инде мин: басуда яңгыр яудырам, әллә начармы?

— Һе, яудырасың... Ә бүген иртәнге якта ук, тел әрәм итеп, Гарапша беләп әчеләнешүең? Аңа үч итеп, болынлыкта су сиптерүләрне туктатуың?

— Анысымы? Менә шушы күк яңгырының киләсен алдан ук сиздем мин,— диде Хәнәфи, ачы көлемсерәп.

— Ул да җитмәсә, «үзем дә гариза язам, китәм» дип янауларың?

— Ә ник аза, нишләп рәнҗетә ул халыкны? Бер бүген генәмени? Тукта, әллә син дә шул адәм актыгын яклау ягына авыштыңмы?

— Авышты ди... Аның белән ныгытып сөйләшү булды инде. Каты кисәттек. Печәнне дә үз куллары белән кире өләшер. Әлбәттә, Мөбәрәйне дә беркая җибәрү булмас, бүтәннәрнең дә күңелен күрү җайларын уйлаштык.

— Ул кисәтүләр күпме тапкырлар инде? Артына тибеп куасы урынга.

— Кызмасана! Мин сиңа Гарапшамыни? Безнең, дим, үзебезнең җанда корт ояламасын, иң әүвәл без үзебез...

Хәнәфи баскан җирендә таптангалап алды:

— Тукта, сабыр, әнә чиләк тулып чыккан икән, мун-

чага илтеп бушатыйм әле. Җеп очыңны ныгытып төенли тор!

Ләкин Хәнәфи мунчадан әйләнеп килеп, буш чиләк төбенә шалдыр-шылдыр яңгыр саудырырга тотынуга, Ризван — Хәнәфинең сөенеченә, инде хәзер Гарапша исемен бөтенләй телгә дә алмыйча — сүзне һич кителмәгәнчә яңартты:

— Менә син дә пехотада хезмәт иткән солдат, мин дә пехотада. Сугыш дәһшәтен бердәй күрдек, дигәндәй. Аерма тик шунда: төрле фронтларда булдык та син бер елга алданрак кайтып төшкәнсең.

— Старшина погоннарына кызыкмаган булсаң, син дә иртәрәк кайтыр идең.

— Кайтуыңа минем сеңелкәшне эләктереп тә өлгергәнсең. Әкәмәт инде! — дип кеткелдәп алды Ризван.— Мин киткәндә, юньләп буй да җиткерә алмаган унбиш тирәләрендәге кызый гына иде. Кайтып төшсәм, бер әзмәвернең куены астында ана булырга, бәби табарга чамалап йөри сеңелкәш.

— Анысын инде ходай үзе хуплаган, хе-хе...

— Мин дә бит бик хуп дим, кияү!

Ризван аңа әнә шулай «кияү» дип тә, «яшьти» дип тә эндәшә инде. Хәнәфи исә бу эндәшүләрнең үзенчә төсмерен дә чамалый иде: «кияү» дигәндә чак кына вәкарь аша үзенең өстенрәк торганлыгын сиздерә сыман иде; ә инде «яшьти» дисә, монысының төсмере бөтенләй бүтәнчәрәк... Алар, егерме бишенче елда туганнар, авылдан ничәү киткән иде дә тегеннән ничәве генә әйләнеп кайтты? Нибары икесе кайтты — сугышта никадәр тәпәләнеп тә исән калган ике сынык җан... Бүтән «яшьти»ләренең исемнәре генә калды, клуб янындагы һәйкәлдә, кара мәрмәргә алтын белән уелып... Кияүнең аның ниндиен дә табып була — бетмәс алар дөньяда, ә менә «яшьти» дигәнеңне... бар, тергезеп кара тегендә ятып калганнарны...

— Аз гына читкәрәк тайпылдык әле, минем әйтер сүзем ул түгел иде,— диде Ризван, бермәл тын торгач, һәм, капыл җитдирәк тонга күчеп, гәпне янә куертып җибәрде.— Син, яшьти, пехота солдаты булгач, «марш бросок» дигән нәрсәне шәп беләсең инде, аны бер генә татып карамагансыңдыр.

— Татымаганнар кая! Җаннарың чыгар иде!

— Шулай... Бер җиргә килеп егыласың, инде беттем бугай дисең, тамчы да җегәрең калмаган, сулышың капкан... Әмма шулчакны «Вперед в атаку! За Родину!»

дигән команда яңгырый. Нишләмәк кирәк? Капыл куба-сың да үлле-мәлле чабасың, ятып автоматтан сиптерәсең, торып янә йөгерәсең. «Ур-ра!» дип тә акырасың... Каян килә диген шулчакны җегәр, каян килә гайрәт!

— Хәйраннар инде!

— Сугышта күп булды инде алар. Аннан кайткач та, теге авыр елларны, турысын әйткәндә, «марш бросок» ише нәрсәләр баштан бер генә узмады. Егылып борын канаткан чакларыбыз да булгалады.

— Булгалады, яшерәсе юк.

— Инде менә, яшьти, КамАЗ куптарганы... Монысы, бәлкем, синең белән минем ишләргә азаккы «марш бросок» булыр. Ниләр, ничекләр килеп чыгасын, дөресен әйтим, мин үзем дә тулаем күз алдына китерә дә алмыйм, әмма бирешмиек, җебемик, дим. Бүгенгесе көнне үрле-кырлы сикергәләгән яшьләргә кемдер азмы-күпме үрнәк тә күрсәтергә тиештер ич. Хак сөйлимме?

— Хак булмыйча...

Аннары алар капка төбендә дә беравык басып тордылар. Яңгыр инде туктый язган, сирәк-мирәк вак тамчылар гына төшкәли иде. Икесе дә күз карашларын дәшми-тынмый гына еракка, караңгы басу уңаена төбәделәр: анда әллә нихәтле яктылык көлтәләренең яңгыр томаны эчендә әрле-бирле кармалануы аермачык шәйләнә иде. Әле һаман туфракны каезлый бирәләр, өя бирәләр...

— Икенче җаең бит инде: ни көн сиңа, ни төн... Яңгыр димәсләр, ачы җил, зәһәр чиллә димәсләр. Тап фронттагыча! Тик чын асылы белән генә андагының нәкъ кирисе! — дип пышылдады Ризван һәм, «яшьти киявенә» тыныч йокы теләп, аның кулын кысты да лыштыр-лаштыр урам караңгысына кереп югалды.

Ә Хәнәфи исә... түбә улаклары астында тулып ташыган чиләк-ләгәннәргә кул селтәп, өялдына үзенә ятак хәстәрләргә кереште. Яңгыр тамчыларының сихерле тамуын мыштым гына тыңлап ятарга...

Каян сизенгән дә ничекләр керә белгән бу Ризван — әүлия җан. Соңгы араларда үтә пошаманланып торган җанга менә кем белән бер иркенләп сөйләшү кирәк булган икән лә...

Ә «Кара тау»ны тегендә, инде төн уртасы димиләр, җирне изрәтте димиләр, өя бирәләр... Чын-чынлап чиксез куәтледер, ахры, Ризванның «цунами» дигән хикмәтле нәрсәсе...

Бер-бер артлы әнә шул дәһшәтле «цунами» эченә кереп киткән ике улы белән кызы күз алдына килеп басты: Айдаш, Вәсим һәм Рәмилә...

Бу җәй башыннан бирле кичергәннәре дә, әле өзек-төтек булып, әле куерып һәм калкуланып, кабат-кабат узды Хәнәфи күңелсннән. Һәм менә аның күз алдында, зәңгәр томан пәрдәсен ертып килгәндәй рәвештә, Мәтрүнә түти шәүләсе калыкты. Түтинең түр почмагындагы иконасы, анда янып торган шәмнәре... Үтәдем керәшеннәрендә йорт саен икона. Мәтрүнә түти, Варварәттәй кебекләр дә аз түгел шикелле... Өй почмакларында ялкыннарын биеткән нәп-нәзек шәмнәр... Соң, аларның үз авыллары Әҗердә дә карт-кортка җитәрлек мәбаса. Аулак сәгатьләрдә тәсбих тартып аз утыралардырмы? Һәркем үзенчә укына инде. Әлеге «цунами»дан өркеп, илгәкөнгә иминлек теләп...

Ә яшьләргә ни? Тәртәгә ныгытып тибәләр, тибә белеп тибәләр... Инде хәзер яшьләр генәме соң?! Ә өлкәнрәкләр, Мөбәрәй кебекләр? Хәнәфи үзе? Йөгән кимәгән, ияр белмәгән яшь ат кебек, ул да кайчагында чыгымчылап куйгалый башлады түгелме соң?

Ризванның «марш бросок», «җиребезнең җанлы кыялары» диюләре... («Беришләргә үрнәк булулар»...)

Инде озакламый сызылып таң атадыр. Тагы күпме атар әле аларның таңнары? Җаннарына ни иңәр дә иңнәренә ниләр өелер?

Сирәгәйде, әмма әле һаман тып-тып тамгалый иде төнге тамчылар...

ИКЕНЧЕ ӨЛЕШ

1

Кырда эшләр төгәлләнгән, ашлыклар амбарга кергән, орлыкка дигәне, тазартылып һәм калибрланып, сорты сортка бүленгән — агроном кеше, әлбәттә, бер иркен сулап куйгандыр.

Сулавын сулагандыр... Әмма совхозда агрономның эше бетәр димени? Авылда хезмәтнең чиге бармыни?

Барыбер соң гына кайтып керә...

Кайтып керә дә, тамак ялгап алгач, түр якның түр өстәле янына утырып, китап һәм төрле дәфтәр-кәгазьләргә чума. Кайчагында зур колакларын кысып таянган хәлдә тын гына утыра, кайчагында кыштыр-кыштыр нидер язарга тотына.

Аның совхоз конторасында иркен генә үз кабинеты бар. Бүлмәнең ян-як диварларын әллә нихәтле сурәт-плакатлар бизәгән, пыяла ишекле шкафында исә шүрлекләр китап-журнал белән тулган, әмма иң күркәме: зур гына тәрәзә кырыйларында һәм түр почмакларда аерым иген культураларының — арыштыр, бодай-арпадыр, бүтәненнәндер — үрнәкләре көлтә-көлтә бәйләп куелган. Куршы кукуруз бәйләме, идәннән күтәрелеп, түшәмгә төртелеп тора. Бүлмәгә килеп керденме, шундук кипкән иген исе — чак кына бурсыган булса да, җанга татлы ис — борынны кытыкларга тотына... Кабинет хуҗасы игенчеләр белән агро-укуларны, билгеле инде, шунда гына үткәрә.

Ләкин кичләрен анда япа-ялгызына иркенләп утырырлык түгел, ут яктысына әле бусы кереп, әле тегесе сугылып, җыен чүп-чар белән баш катырырга тотына.

Әлбәттә, өйдә җылы, өйдә күп рәхәтрәк! Кай кичләрне ул төн урталары авышканчы утыра — тап аның өстәленә генә төшкән ут көлтәсенең кайчан сүнгәнен бүтәннәр сизми дә кала.

— Улмы? Ни булсын, «Кырлар тарихы»н яза бит ул! — дип аңлатырга тотынды бермәлне Сабир һәм, Назар белән Габделбәрнең аптыраган кыяфәттә каш җимерүләрен күреп, үзе дә күзләрен шакмакландырды.— Ни нәрсәме? Һи, әллә шуны да белмисезме?

Тегеләр чынлап та белми икән. Ишеткәннәре дә юк икән. Үз авылларында берәр агроном тирәсендә ышкылыбрак йөргән булсалар, әлбәттә, колакларына чалын-

мый калмас иде. Ә хәзер менә сәеррәк хәлдә: бәләкәйдән үк туфрак җылысын тоеп, киң басу-кырларда, күкрәп үскән игеннәр арасында дөнья таный башла да белмә, имеш...

— Алайса аңлатам... «Кырлар тарихы» теге ни...— Сабир тамагын кыргалап алды: шушындый җаваплы бер моментта, укытучы апалар сыман, тавышны бераз йомшартып җибәрмичә ярыймыни.— Андамы? Анда кайсы кырның ничек эшкәртелгәне, аңа ни чәчелгәне, аннары соң нинди уңыш алганнары теркәлә... Шулай ук нинди трактор яисә машина-механизмнар кулланганнары тагы... Дөресме, эти?

Болар өйнең олы ягында киң диванга утырышып пышын-пышын гына сөйләшсә дә, түр өстәл янында үзенең китап-дәфтәрләренә чумып утырган Ризван-агроном аларның сүзенә колак шәбәртмичә калмаган иде.

— Бик дөрес, улым! — диде ул, утырган җирендә боларга таба бөтен гәүдәсе белән борылып. Җылы гына иттереп елмайды.— Элеккерәк елларда эшләнгән хәтлесен юньле-башлы теркәмичә зур хата җибәргәләгәнбез. Ә бүгенгесе көнне ансыз һич булмый, һич ярамый...

Ризван өстәл өстендәге өем арасыннан калын гына журнал сыман бер нәрсә табып алды да болар янына килде, пружинасын каты шыгырдатып, диванга утырды. Китергән нәрсәсенең катыргы тышына, эре һәм симез хәрефләр белән сырландырып, чыннан да «Кырлар тарихы» дип язылган иде.

— Әүвәлге елларның нәтиҗәсенә карап, алдагы елында ни кыласын чамалыйсың да инде. Сез икегез дә крестьян малайлары, төптән аңларга тиешсез,— диде агроном, журналдагы кырлы-сырлы язмалар өстендә бармак чиерткәләп.— Чәчү әйләнеше икән — чәчү әйләнеше булсын, бары да фән кушканча истә-исәптә булсын!.. Шулаймы?

Кай арададыр яннарында пәйда булган Туры карт исә:

— Шушы җазганнарына таянып, абзагыз... бүген булмаса, иртәгә совхозга алтын күкәй салып бирмәкче,— дип тамак төбе белән генә хихылдап алды.

— Ярый, көлмичә генә... Алтын күкәйне салып бирербезме-юкмы, алдагы көн күрсәтер,— диде аңа улы агроном, тавышына сизелерлек дәрәҗәдә коры төсмер биреп.— Ә совхозда хәлләр хәл шул әлегә... Текә борылыш алдында торабыз, әмма ул борылыш кына түгел, текә сикереш тә булырга тиеш иң!

— Әлбәттә! — дип куәтләп куйды Назар.

Алар, ике квартирант егет, боларның КамАЗ зонасына кергән совхозында нинди зур үзгәрешләр буласын инде ишеткән, шул уңайдан хәйран калуларын ачык сиздереп телләр дә чәпелдәткәләгән иде.

— Нибары безнең совхозда миллионнар салынасы, миллионнар китәсе бит! Аны ничек инде тизрәк кайтармыйсың ди, шул хакта ничек инде баш ватмыйсың ди? — Ризван-агроном, күзләрен зур ачып, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә караш ташлап алгалады.— Сез авылда үскән егетләр, йөзәрләгән гектарга җәелгән яшелчә плантацияләрен күз алдына әйбәт китерәсез инде. Әмма аны җиренә җиткереп башкарып чыгасы бар бит әле. Мул яшелчә алам дисәң, шәпләп сугарасы бар! Әйтүләре генә ансат шул... Яки, алыйк терлекчелектәге хәтәр дәү комплексны... Бер ябышкач, салынасы нәрсәләр салынмыйча калмас, әлбәттә. Кирәк кадәр нәселле терлеге дә кайтартылыр. Хикмәт анда түгел, хикмәт бүтәндә: каян азык җиткерергә, ни белән туендырырга ул меңләгән мал-туарны? Сөт чишмәсенең башы кайда? Культуралы көтүлекләр, сугарулы болыннар дип бик әйбәт искәртәләр дә искәртүен — монысын да әйтүләре генә җиңел шул... Аннан килеп, шул хәтле мал-туар минем үземә, ягъни кырларыма ни нәрсә бирер? Тирес чыгару җәһәтеннән әйтәм әле. Һәйбәт уңыш көткәндә, бу ягын да исәпкә алмыйча һич ярамый лабаса. Ие, җиңнәрне сызганып, маңгай тирләрен агызасылар күп әле, чын-чынлап көрәшәселәр алда әле!

Шул арада артлы урындыкка утырып алган Туры карт, чал кашлары астыннан улына сөзеп караган шәйгә, авызын кыйшайтты:

— И, улым, ни пычагыма барысы өчен дә нибары сиңа гына ми черетергә ди? Әле өстә утыручылар бар, яндагылары тагы... Хәзергесе заманда аның исәбен-чутын да җаңгыр урынына җаудырып кына торалар бит.

— Яудырсалар соң... Юк, без үз җаебызны онытмыйк, үз исәбебезне белик! Син, әткәй, үз сүзеңне исеңә төшер әле: чигә тамыры ничек дип тибә ди? «Үз акылың үзеңә якын» дипме? «Бүген миең чересә, иртәгә җаның чәчәк атар» дипме?

Бермәлгә тынып калган өйдә нибары кәгазь кыштырдаган тавыш кына ишетелеп торды. Туры карт, әлбәттә, алай тиз генә чигенүче адәмнәрдән түгел, менә инде аның тамак төбеннән чыккан карлыкканрак тавышы янә ишетелде:

— Шулай инде, адәм баласының бар тырышлыклары дөнья көткәндә өстәлендә күпереп торган ипекәй дә, бүтән ризык та булсын дип инде ул. Төптән торып уйлап бактың исә, тарих-бабакай чабатасын үргәндә аны шома гына иттерми, шадра-шадралатып үрә ди. Әүвәлтен дә, хәзер дә... Җәл, дөнья көткәндәгенең, язмыш-бармыш үзе китереп чыгарганнарның бик күп яклары менәтерә синең «Кырлар тарихы»на кермиенчә кала...

Ризван әтисе ягына күз ату түгел, башын да борып тормады, кулларын кушырып, тез капкачы өстенә салды да эре сөякле, таза иңбашларын сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәткә китерде:

— Ярар, әти, читкә тайпылдырма, зинһар!

— Тайпылдырсам да... Сәбәпсезме әллә? Менә син, улым, көрәш дип әйтеп әйтәсең, көрәшми булмый дип әйтеп... Элекке заманнарда әллә көрәшмәгәннәрме?

— Зинһар, дим, күмереңне кабаттан дөрләтмә әле! Куригыңны тартмый тор!

— Жук, тартам! Син әйт менә: тап-такыр, шоп-шома юллардан гына тәгәрәп килгәнме синең бүгенге КамАЗларың, үзең әйткән текә борылышлар, ә?

Бу хакта ата белән ул арасында сүз-бәхәс бер генә купмаган, әлбәттә. Туры картның, гәп корып, тәмләп сөйләшкән чакларда, ике сүзнең берендә «тарих-бабакай»га ишарә итүләре тиккә генә түгел ләбаса!.. Ә бүген, бу сәгатьтә янында, авыз ачкан шәйгә барын да йотарга әзер булып ят шаһитлар утырганда, сүзне нигә тагын бер куертып җибәрмәскә ди? Чыннан да, бу минутларда мари егете Назар гына түгел, хәтта җай чыккан саен туган авылының данын алсу төсләргә манчып таратырга яратучан Вятка егете Габделбәр дә, авызына май капкандай өнсез-тынсыз калган иде.

Ризван-агроном исә, мин инде әйтер сүземне әйттем, иләктә калганын үзегез иләп бетерегез дигәндәй, бүтән ләм-мим дәшмичә, утырган җиреннән авыр гына купты да, идән сайгакларын ыңгыраштырып, түрдәге өстәлгә табан атлады. Менә өстәлдәге лампага ут кабынды, менә өстәл янындагы урындык та шыгырдап алды...

— «Җирем дип, көнем дип», кристиан тирен аз түккәнме элеккеге заманда? Җаны да кыйналган, хәтта, әйтер идем, каны да аз таммаган аның «җир-кыр» дигәнебезгә! Ишетәсеңме? Ашлама гына түгел, каны да дим... Кырлар дәшми, кырлар җавапсыз. Әгәренки, телгә килеп, сөйләп бирсәләр, иеме?

— Бик аңлыйм, бик беләм... Соң, анысы аның социаль тарих була, аның үз галимнәре бар — тикшерәләр, кирәк хәтлесен чамалап китапка язалар. Ә миндә бит коры агрономия!

— Һе, сатсиал тарих, имеш, үз галимнәре кирәк хәтлесен сайлап кына җаза, имеш... Ә син, алайса, коры агроном гына булма, сатсиал агроном да бул! Адәмнәр агрономы да! Ием, үзеңнең агрономия дигәнеңдә дә, адәмнәр тир түкмимени, көрәш дигәнең дә адәмнәр җанын айкап-актарып үтмимени? «Кырлар тарихы»н ни дип ул тикле кыерсытырга инде, ә? — Бу минутта Туры картның тавышы ук сынып куйды һәм аның сынуында бабайның үпкә-рәнҗү тойгысы аермачык беленде.— Ием, әгәренки, төптәнрәк уйлап баксаң, үз тирәбездәге авыл исемнәренә орынуыңа ук исең сизеп сизәрсең чын тарихның. Хәтта ки исемнәреннән үк!..

Улы, зур колакларын дәү куллары белән ике яклап кыскан килеш, башын иеп, мыштым гына утыруын белде. Туры карт ахырда, авызын ямьсез кыйшайтып, улы тарафына кул селтәде: һәй, сиңа сөйләп утырам тагы, картайган башым белән...

2

Женя Мынданың Чехословакиягә киткәненә шактый булды инде. Кайтып төшәр вакытлары бик җитте кебек. Ник күренми әле ул? Нигә, ичмаса, берәр хәбәр салмый, телеграмма сукмый аңа молдаван «мыеккае»?

Юк, сөйгән ярың бүгенге заманда артыгы белән булдыклы да, күндәм дә булмасын икән. Завод җитәкчеләре баштарак бик үк абайламаган, ахры, әмма, сизеп һәм төшенеп алгач, егетне киң туган ил буйлата әле теге тарафка җибәрергә, әле бу тарафка очыртырга тотынмасыннармы!.. Имештер, ул гади электрик кына түгел, имештер, бүгенге заманның иң катлаулы, иң нечкә һәм нәзберек техникасының теләсә кайсына егетнең теше үтә. Тап сихерче, имеш!

КамАЗның РИЗ дип аталган беренче карлыгачына, җитмәсә, дөньяда бар булган станок-җиһазның иң яңасын, иң берәгәйлесен генә туплыйлар, ди. Арада бик тә нечкә, бик тә «акыллы» автоматика, хәтта программалы идарә итүгә корылганнары да әллә никадәр буласы, ди.

Юл йөрүләрдән тәмам туеп, Чаллыга кайткан чакларында егет Рәмилә алдында үзенчә акланып та маташкалар иде:

— Бер мин генәмени? Дистәләгән бит без!.. Соң, ул хикмәтле станок-җиһазларның бар серенә төшенмичә, һәммәсен энә күзе аша үткәрмичә ничек инде? Аларны бит, күз карасыдай саклап, РИЗга кайтарткач та, үзебезгә үк эшкә җигәсе, эшкә җиккәндә, бүтәннәргә дә өйрәтәсе, ди.

Рәмилә, әлбәттә, сөйгән егетенең әнә шулай бүгенге заман техникасын әйбәтләп авызлыклый алуы, аның асыл сихерче булуы белән чын-чынлап горурлана да, аңа куана да, хәтта жае чыкканда, һаваланып куйгаласа да, үзен хаклы дип саный иде, ләкин бер үк вакытта...

Инде менә чит илләргә дә җибәргәли башладылар...

Билләһи, чын әгәр, сөйгән ярың зиһен үткенлеге белән дә, уңганлыгы-күндәмлеге ягыннан да кирәгеннән артык ялтырамасын икән шул. Андыйларга замана йөгәннең дә шәбен, тазасын-чыдамлысын кигерттерә икән лә!

Килдең дә Чаллыма, елмаеп кердең лә
Салкынны-ялкынны белмәгән күңлемә.
Карашың сихерле, сулышың көйдерә...
Чуалды зиһенем, киләлмим ядемә...
Серемне сөйләмим, көемне көйлим мин,
Яшьлегем КамАЗда нишләргә белмим мин...

Әйе, бу аның үз җыры, үз көе... Гел үзенеке генә! Хәер, чын дөресен әйткәндә, ул аның сүзләрен башлангыч хәлендә бүлмәдәше һәм хезмәттәге терсәктәше Фаягөл дәфтәреннән күчереп алган иде. Фаягөл — Туймазы кызы, эшендә үтә елгырлык күрсәтеп, утлар уйната белсә дә, тормышта болай юаш кына, йомшак кына холыклы җан иясе. Бер кичне ул мыштымбикә Рәмиләгә күңелендәге тирән серне ачып салды: теркәлгән шигырьләрнең байтагын ул үзе уйлап чыгарган икән ич. Рәмиләнең исләре китте. Аннары, акылын җыя төшкәч, бик тә төпле киңәш рәвешендә әйтте аңа:

— Соң, апаем, әдәби берләшмә үзебезнең Чаллыда гына бит! Барып бер укып күрсәтсәң, үсеп-тернәкләнеп китәргә үзеңә дә шифалы яңгыр булыр иде, ичмаса...

Фаягөл аңа әйтеп бетерергә дә бирмичә, болай да зур кара күзләрен тагын да зурайта төшеп, өздереп карады:

— Син нәрсә? Мин бит үзем өчен генә... үземә дип кенә! — Аның соңында үпкәләгән рәвештә дымлы иреннәрен турсайтты да авызына чәч тәлгәшен капты.— Шифалы яңгыр, имеш, «Лэйсән», имеш... Бөтен кеше дә анда бара башласа.., бетәр димени Чаллыда минем ише исәрләр?

Ләкин «исәр» кызыйның бер шигыре Рәмиләгә бик тә ярап куйды. Әкренләп, Рәмиләнең үз хиссиятенә ияреп һәм буйсынып, шигырьдәге бик күп сүзләр, сүзләр генәме, юллары да бөтенләй бүтән төсмер һәм рух алды. Шашкын җилләр искәндә Кама-Идел дулкынланмыйшауламый тормас, ди, озакламый, әллә ничек, үзеннәнүзе генә, җырның көе дә табылды. Шулай икән, яшьлегендә тилемсә йөрәгең бер ирексезләнә, бу фани дөньяның шигырь язучысы да, көй чыгаручысы да буласың ла икән!

Их, РИЗ диләр, РИЗ ны тизрәк корып бетерәсе дә сафка бастырасы иде, диләр! Имештер, аны ятьрәк худка җибәрсәләр, автогигантның бүтән заводларын да корып, эшкә җигүе шактый җиңелгә киләчәк, ди.

Шул сәбәпле, анда үтә дә ашыктыралар, кызулыйлар, яналар — мәхшәрнең дә мәхшәре инде!

Ләкин бу дөньяда РИЗның тизрәк корылып, сафка басуын Рәмиләдән дә ныграк теләүче тагын кем бар икән? Бик кирәк, үлеп кирәк аңа бу заводның тизрәк сафка басуы! Ул чагында, ичмаса, сөйгән яры Женя Мында әллә кая җир читләренә китеп, олагып йөрмәс иде, шул йөрүләре белән аны, әллә нинди шик-шөбһәләргә күмеп, тирән сагыш елгаларында агызмас иде. Ул чагында егет гел аның янында, аның канаты астында булыр һәм Рәмилә аны үзенең кайнар хисләре белән ничек уратып аласын бик белер иде... Бик белер иде!

Чит илгә, ят жиргә китәмен, дигәндә,
Буылып яшьләргә, тотмадым җиңеңнән.
Киттең дә югалдың... Ничек лә түзәсең
Саф җилләр искәндә үз туган илеңнән?
　　Серемне сөйләмим, көемне көйлим мин.
　　Яшьлегем КамАЗда бомба мин, бомба мин!..

«Бомба?» Әйе, чынлап торып, шартлап куйсаң, ни булыр иде микән? Чаллыңны да, КамАЗларыңны да сагыш сөреме басып алыр иде микән, әллә бары-бары да ялкынга уралыр иде микән? Бер Рәмилә генә түгел, аның кебек йөзләр, меңнәр шулай бер-бер артлы шартларга тотынса?.. Һай, бу исәр башка нинди генә уйлар керми!

Авылга кайтты исә, Рәмиләгә әнисе әледән-әле исенә төшереп тора: «Берүк!» — ди. Әтисе дә, алай ук еш булмаса да: «Ыштубы!» — дип искәртеп куйгалый. «Берүк! Ыштубы!» Үткен кылыч белән кистереп салгандай рәвештә әйтелгән бу кырыс-кыска сүзләрнең мәгънәсен Рәмилә бик аңлый, бик белә.

Хәер, әтисе белән әнисе әйтмәсә дә... Чаллы кебек мәхшәр купкан җирдә үз кадереңне үзең белеп, итәгеңне җыеп йөрмәскә монда... Әнә шулай тәтенсез янган ут йомрысы булып йөрүләре белән ул чын-чынлап бәхетле дәдер әле. Үзе дә, сөйгәне Женя Мында да! Икәвесе бергә!

Ләкин бүгенгә хәлләре мөшкелрәк әле. Егетләрнең дә, кызларның да... аерата кызларның!

Яшь күңел ireкkә чыгарга иләсләнми торамыни? Киносына-концертына да барасы килә, «парк» дип аталган яшь наратлык та үзенә тартып кына тора, ә инде кичләрен «пятачок» дип аталган нәрсәдә яшьләрнең очкыннар очыртып биюе-җырлавы күңелне ни дәрәҗәдә җилкендереп торуын әйтәсе дә юк! Ләкин анда-монда чыктың исә, әйләнә-тирәңдә әллә нихәтле хәтәр ымсынулы күзләр елтыравын шәйләп аласың, беришесе килеп бәйләнергә дә күп сорамый. Арада бик тупас, бик әшәке телләре дә килеп чыккалый. Андый чакта Рәмиләнең янында, ярый әле, сердәше һәм терсәктәше Фаягөл була, ике кызый, күк күкрәве шикелле үк дөбердәмәсәләр дә, кырт кискәндә, яшен чаткылары шәп кенә чатната беләләр үзе. Ярый әле, кайсыбер вакытта аеруча ябышкак «сыткый сагыз»ларга киртә булып, әллә каян гына кызыл тасма таккан дружинниклар килеп чыга.

Соңгы вакытларда, шөкер дигәндәй, кызлар халкы күзгә күренеп кубәя, ишәя бара. Бу көзгә кергәч, бигрәк тә... Идел буе һәм Урал якларыннан да, Себер булып Себердән дә, тагын әллә кайлардан да профтехучилище бетергән егет-җилкенчәк кенә түгел, хәтта сан ягыннан алардан да уздырып һәм киек казлар шикелле төркем-төркем укмашып, әллә никадәр кыз-кыркын да очып төшкәләде инде. Әле һаман килеп торалар, ди... Әйдә, бик шәп, ишәйсеннәр, иләшсеннәр дә ныгытып тамыр җибәрсеннәр!

Анысы шулай, КамАЗ корпусларын да, Яңа каланың үзен дә, чырай кертеп, нурларга күмәр өчен, меңәрләгән хатын-кыз кулы кирәк булыр инде. Буяу-бизәү эшләре озакламый хәтсез җәелеп китәчәк, ди. Әмма, чынлап торып уйласаң, мондагы хикмәтле дөньяның тышкы ягы, нибары ялтыравыклысы гына ич әле бу. Тормышның күзгә бик үк ташланып тормаган ягы — җан асрау, гыйшык-мыйшык тоту, ярәшү, гаилә кору — дигәне, әчкәредәгесе, тирәндәгесе һәм иң әһәмиятлесе, ансыз һич мөмкин булмаганы бар бит әле аның. Җитәкче агайлар яшәешнең шушы хикмәтлерәк ягын да аңнарында ас-

рыйлар икән, асрау гына түгел, изге уй-ниятләрен озакка сузмыйча тормышка ашыра да беләләр икән, аларны хупламый һәм мактамый ни диярсең инде?

Дөньяның үткән җәйдәге шикелле яман эсседән корышып, дымга тилмереп ятуы кемгә тансык, кемгә кызык? Кояшның да кирәгенчә генә балкып торулары, яңгырның да тиешенчә генә явып китүләре хәерленең дә хәерлесе ич! Әйе, дөньяда ир-егетләр белән кызларның да тәңгәлгә-тәңгәл килеп торуына ни җитә инде! Ичмаса, бер иркенләп сулыш алырлар иде!

Тик бу — әлегә матур теләк, татлы хыял гына шул...

Рәмилә бик еш туган мәктәбен искә ала. Нибары былтыргы хәлен... Аның чын кадерен соңыннан, инде аерылгач кына, аңлыйсың икән шул. Һай, күңелле һәм рәхәт чагы булган ла икән! Укуы да әллә ни кыен түгел иде, уку аңа гомумән ничектер җиңел бирелә иде. Укытучылар да бик әйбәтләр, бик үз иделәр. Ә малайларның, дөресе, инде егет булып өлгереп килгән сабакташларының серле һәм көйдерүле күз карашлары, кайчагында әтәчләнеп куюлары яисә, киресенчә, суга төшкән тавыктай бөрешеп калулары, алар белән хат алышулар, кыскасы, гыйшык-мыйшык утын көйрәтергә тырышып кыйланулары?! Болары да бик рәхәт һәм бик татлы иде жанга...: Әмма анысы әле кызыйның гыйшык өермәсендә бөтерелеп, мәхәббәт ялкынына беткәнче уралып, чынчынлап яна башлавы булмаган икән, нибары... иртәнге йомшак саба җиленең җанын иркәләп һәм назлап сыйпап китүе, нибары күңел кытыклануы гына булган икән...

Инде хәзер... Чаллыда?

Кичке мәктәптә укуы ифрат авыр. Көндезен ыгы-зыгылы, мең четерекле хезмәттән соң алҗыган гәүдәңне, әлсерәгән җаныңны җәт кенә сафландыра-тазарта бел һәм, зиһенеңне җыя төшеп, ачылдырып җибәр, аннан соң, өлгерә алсаң, дәресләреңне аннан-моннан гына булса да караштыргалагандай ит тә тизрәк мәктәпкә йөгер... Русча укыйсы — шунысы аерата читен. Дөрес, математика, физика кебек фәннәрдән аңа һәрчак булышырга әзер торган «башлы» егетләр бераү түгел, әллә ничәү. Ялынасы да юк, үзләренә ым гына как... Ләкин бу дөньяда бер генә нәрсә дә бушка эшләнми, тиккә генә бирелми, ахрысы. «Башлы» егетләр, берсеннән-берсе уздырырга чамалап, кызның күңеленә үк үтеп керергә, аның җанын яулап алырга тырыша иде. Югыйсә, Рәмилә аларга әллә ничә тапкыр инде:

— Күңелем йозакта, ачкычы бүтән бирәүдә! — дип, бик кырыс төстә кистереп тә куйгалаган иде.

Ләкин тегеләрнең мондый гына кисәтүләргә бер генә дә исләре китми:

— Без теләсә нинди йозакка да ачкыч ярата беләбез, сеңелкәш, һич аптырама! — дип, авыз гына ералар иде. Арада үтә дә ач күзләнүчеләр, үтә дә әрсезләнүчеләр дә бар иде.

Әллә кечке укуны ташлап, берәр елга тукталып торырга микән? Ичмаса, җан кыйналулардан котылыр иде...

Ләкин сөйгән яры Женя Мында кызыйның шушындый моң-зарын ишетергә дә теләми, кайтып төшкән һәм назлы-иркәле күрешкән бәхетле сәгатьләрендә ул кыз күңелендә инде пыскый гына башлаган чаткыны минуты белән дөрләтеп җибәрә иде:

— Уйлама да, акыллы акылсызым! Тик торганда бер елны әрәм итәләр димени? Алдагы якты, матур көнебез хакына түзә алмасаң да түз, дим! Менә юл йөрүләрдән бераз бизә төшсәм, яныңда иң ышанычлы таянычың үзем булырмын,— ди.

Егет, әлбәттә, иң әүвәле Рәмиләне өлгергәнлек аттестатына ирештерергә тели, аннары инде үзе дә укуын дәвам иттерергә, техникумда алган белеме өстенә, алга таба, читтән торып булса да, институтка керергә ныклы ният тота иде.

Сөйгән ярының әнә шулай төпле һәм нигезле киңәш бирүләре, йомшак кына, җылы гына әйтеп, тирәнгә сеңдерә белүләре Рәмиләне өзлексез җилкендереп тота да иде, һәм ул, теләсә дә, теләмәсә дә, дәресләренә тотына, кичке мәктәпкә эзен ничек тә суытмаска тырыша иде. Ни кыен булса да!

Бераз тын алырга, азрак җегәр тупларга дип туган авылына кайтса, кызның анда да хәлләре хәл... Яшь күңел өйдә бикләнеп, әти-әнисенең бетмәс үгет-нәсыйхәтен тыңлап утырулардан инде әллә кайчан туйган, телевизорга төртелеп утырулар да куандырмый, җаны һәрчак ирекә, дөньяга, яшьләр арасына ашкына... Шимбә, якшәмбе кичләрендә аларның авыл клубы гөжләп тора. Тегеннән, зур төзелештән әллә нихәтле егет-җилкенчәк кайтып төшкән була. Үз авылдашларына ияреп, әллә нитикле чит-ят егетләр дә бутала. Тик Рәмиләнең үз ишләре, ягъни кыз-кыркын гына чагыштыргысыз аз күренә. Менә шушы хәл, тап Чаллыдагы шикелле үк, җәфалый да инде кыз баланы... Егетләрнең чиксез ымсы-

нып, тәмам көйдереп караган күз карашлары, ягылып-тагылып китәргә тырышкан бәйләнчекләр, суырып-йотып алырга әзер булган төрле әрсезләр... нишләп шулхәтле күп микән алар? Ярый әле, кичләрен клуб тирәсендә сыенырак йөрергә абыйсы Рәмзи бар. Ләкин гелән дә аның канаты астында ышыкланып тормассың бит, бу мөмкин дә түгел. Рәмзинең дә, егет кешенең, кызлар җәһәтеннән үз хәсрәте хәсрәт ич...

Арада иң елгыры, иң кыюы, дөресе, астыртын үткене һәм шул сәбәпле Рәмилә өчен иң куркынычлысы... Туры бабасы өендә оялап алган квартирант Габделбәр. Вятка егете. Чибәрлеккә болай ярыйсы гына, төз һәм таза гәүдәле. Тик авызы гына зуррак кебек, әллә сөйләшкәндә гелән дә елмайганга күрә шулай тоела микән? Туры бабасын ул әллә кайчан ук инде бөтенләй үз итеп бетергән, тегесе бусын мактап бетерә алмый. Ул да түгел, Габделбәр кай арададыр Рәмиләнең абыйсы Рәмзи белән дә якынаеп, дуслашып өлгергән. Хәер, солдатта булып кайткан ике егетнең дуслашып китүенә алай гаҗәпләнерлек тә түгел үзе. Алар бит, җитмәсә, икесе дә бер тарафта — Кавказ төбәгендә хезмәт иткән икән. Тик берсе, Рәмзи, мотопехотада, ә тегесе авиациядә булган да хезмәтен бер елга алданрак тутырып кайткан. Икәвесе дуслашып киткәч, билгеле инде, Габделбәр алар өенә һич тарсынмыйча, бөтенләй үз итеп килеп йөри. Алай гынамы, тегеннән, зур төзелештән кайтып төшеп, вакыты тигән чакларда, Туры бабасы йортында гына түгел, боларда да тегенди-мондый эшләрендә катнашып китә, анысын төзәткәләп, монысын рәтләштерергә керешә. Инде хәзер Рәмиләнең әнисе дә:

— Менә ичмасам, чын эш кешесе! Эш-хезмәт дигәндә, куллары гел дә кычытып тора, ахрысы, бу Вятка җегетенең! — дип, авыз суларын корытырга тотына иде.

Рәмилә бик сизә: әнисе шушындый сокланулы-төрткеле сүзләре белән аңа: «И кызым, җанында әллә ниткән билгесез бер бәндәне асраганчы, күңел күзеңне менә кемгә төбәсәңче!» — дип аермачык киная ясый, хәтта киңәш бирә сыман иде.

Гаҗәп хәл: Рәмилә, бүтән ачкүз егетләргә кырт та пырт кистереп, аларны үзеннән читләштерә белсә дә, Габделбәргә мөнәсәбәттә исә андый катылык һәм кырыслык кыла алмый, күңеле ничектер туарылып китә, хәтта йомшаклык күрсәтә иде... Әле күзгә кергәндә, үз бакчаларында бер төсле өмә сыман нәрсә оештырып, бәрәңге алган чакларында, Рәмилә Вятка егете кузгаткан

шуклыкларга кушылып, шаярды-көлде, аны тәмам үз итә язып, әллә нишләп бетте. Ә октябрь уртасында Рәмиләнең туган көнендә исә тагын да хикмәтлерәк хәл килеп чыкты. Дөрес, җиңел кулдан гына, үз гаилә кешеләре белән генә үткәрелгән ул кичәгә Габделбәр чакырылмаган иде. Әмма егет, дусты Рәмзидән ишетеп ахры, икенче көннең кичендә, Рәмиләне туган көне белән ихлас күңелдән котлап, аңа зур бер бүләк — «Москва» исемле тоттырды. Рәмиләнең андыйны моңа кадәр хыялында да тотканы юк иде, куанычыннан сулышы капты, аннары, кызарынып-бүртенеп, ягъни үтә дә хискә бирелеп, бутала-чуала егеткә рәхмәт сүзләрен әйтте. Егет аның шушындый халәткә төшүеннән үзенчә нәтиҗә ясамагандыр дисеңме?

Әле бик күптән түгел Габделбәр «Урал» мотоциклы сатып алды. Алар авылында андый, үтә дә шәп җегәрле, иркен әрҗәле мотоцикл нибары милиционер Фәйзрахманда гына бар. Ә Габделбәрнең күптәнге хыялы икән. Чаллыда исә аның кебек алдынгы эшчегә аңа ирешүе чүпкә дә тормый икән. Шушы уңайдан бабалары Туры карт:

— Шулай инде: туңган туңкаеп калыр, уңган уңаеп узар! — дип, егетне янә бер мактап алды.

Габделбәр үзе исә: «Вахта машинасын көтә-көтә кайчак көтәк булып бетәсең, килми калган вакытлары да аз түгел, инде хәзер транспорт кайгысы нуль булыр»,— дигән. Аңа бу шәп мотоцикл һич тә жәл түгел, имеш: тели икән хезмәттәше Назар утырып чапсын, тели икән солдат дусты Рәмзи. Сабир-Чуерташка исә, ныгытып өйрәнеп китәр өчен, бөтенләй мач.

Бер иртәне Габделбәр, әлеге шәп мотоциклының әрҗәсенә утыртып, Рәмиләне дә Чаллыга китереп куйды. Әйтәсең юк, бик җилле, әмма бик тә ыспай алып килде. Мотоциклны ул туп-туры Рәмилә яшәгән тулай торак подъезды каршысында туктатты, һәм менә шунда, кызга әрҗәдән төшәргә булышкач, кинәт бер сулыш белән диярлек әйтә салды:

— Син, Рәмиләкәй, бер генә ым как, минуты белән янында булырмын! Турысын әйткәндә, бу мотоциклны да мин синең хакка дип алган идем... Телисең икән, син аның икенче хуҗасы... чын хуҗабикәсе була аласың!

Бу сүзләргә Рәмиләнең исе-өне китте, ул ни дип җавап бирергә белмичә, бермәл ык-мык итеп торды, ахырда, башын тилегә салындырган рәвештәрәк:

— Акылыңнан язмагансыңдыр ич? Әллә ниләр сөйлисең син! — дип, шаркылдап көлеп җибәрде.

Әнә шулай Габделбәр торган саен дәвәеп-зураеп Рәмиләнең күңеленә таба якынлаша бара иде. Әллә аның бу юлына бөтенләй дә киртә торгызып азапланмаска микән? Бериш кызлар кебек кыланыргамы әллә? Бериш кызлар шулай бит: берәүгә күзе төшеп, аның белән мәхәббәт көйрәтеп йөргән була, үзе шул ук чакны икенче берәүне, хәтта өченче егетне үзеннән биздерми, запаста тота... Аннары инде, берсеннән уңмаса, икенчесенә барып сыена, инде монысы белән дә эше пешмәсә, өченчесенә барып сылана... Юк, юк, Рәмилә алай итә аламы соң? Ул андыйларга ишмени? Күкрәгендә аның йөрәк гөле бөреләнеп чәчәк аткан икән, ул тик берәүнеке генә булсын, тик берәү өчен генә шау чәчәктә утырсын! Бүтәнчә булмый, бүтәнчә ярамый...

Габделбәр, сүз дә юк, шәп егет, уңган-булган егет, тырышып эзләсәң дә, аның, бәлкем, бер гаебен дә таба алмассыңдыр, аңа әллә кемең дә кызыгырлык, әмма ул егет моннан ары үз күңелендә өмет чаткыларын дөрләтеп йөрмәсен, моннан ары кыз аңа мөнәсәбәттә үтә кырыс, хәтта усал булырга тырышачак! Һичшиксез шулай! Әнә шул күкрәгендәге бердәнбер гөле хакына...

Әйе, үз әйләнә-тирәсендә бөтерелгән егетләрнең берсеннән дә гаеп эзләргә теләми Рәмилә, бәлкем, алар барысы да бик әйбәтләр, бик шәпләрдер, ләкин шулай да... кызый соңгы вакытларда, Чаллының үзендә торып калса да, туган авылына кайтып төшсә дә, кичке мәлләрдә үзен ачкүзле бүреләр чолганышында калган яшь боландай яисә канаты каерылып, читлеккә томаландырылган ялгыз күгәрчен кебек хис итә, күкрәген нидер кыса башлый, җаны бер көйрәп китә, бер өшеп куя. Мондый хәләтеннән ул тик сөйгән яры ерак сәфәрдән әйләнеп кайткач һәм аның белән кайнарланып күрешкәч кенә котыла. Анда инде бернинди богаулар да, читлекләр дә калмаган, бары да пыран-заран җимерелеп, юкка чыккан, офыклары алсу, күкләре аяз, күңеле исә талгын-талгын дулкыннарда рәхәтләнеп йөзә бирә... Ләкин нишләп соң әле ул, аның сөекле молдаван «мыеккае» шуны читтән торып, еракта торып та эшли алмый? Чехославакия — җәһәннәм арты түгел ләбаса... Нишләп ул, кош теле кадәр генә хат язып булса да, кызны күңелен кысып торган кыршаудан, җанын богаулаган зынҗырдан котылдырырга теләми? Һич югы, телеграмма сукмый? Әллә ниме... карлыгандай күзле кара чәчлекәен

инде оныта башлады микән? Юктыр, юктыр, һич алай түгелдер! Түгелдер!..

ЗАГС Рәмиләләрнең тулай торагыннан бер-ике йорт аша гына урнашкан. Кызлар ул тирәдән күз акларын алмыйлар диярлек. Анда бит көн саен ничәмә-ничә пар, ничәмә-ничә җан «бергә-гомергә!» дип, йөрәк вәгъдәсенә тамга сала...

Шимбә, якшәмбе көннәрендә урамнардан тузаннар туздырып чабучы туй автомобильләренең исәбенә чыгасың юк. Аларның шома борыннарына атланып һәм тыгыз һава дулкынын ярып, чибәр курчаклар чаба. Автомобильләр аллы-гөлле тасмаларга, купшы чәчәк бәйләмнәренә күмелгән була, өсләрендә, тормыш түгәрәклегенә ишарә рәвешендә төрле төсләрдәге шарлар җилферди...

Берзаман Рәмилә белән Женя Мынданың да шундый көне килеп җитәр әле...

Женясы аңа: «Менә РИЗны худка җибәрик тә...» — ди, ә Рәмилә җавапка үзенекен искәрткәндәй була: «Кичке мәктәпне тәмамлыйм инде...» — ди.

Аңарчы күп көтәсе калмады бит инде. Юк, һайлар гынам, күп әле, бик күп әле!

Нихәл итәсең, бүтән әмәлең юк: йөрәгеңне уч төбендә кысасың да түземеңне беләсең!» Сабыр төбе — сары алтын» диләр бит әнә...

Сары алтын... Бүгенгесе көнне аннан да кадерлерәк һәм кыйммәтлерәктер әле сабырлык, тыйнаклык һәм намус сафлыгы!

Ә бит кайберәүләр шуңа төкереп карый, әмма төкерегә җилгә каршы икәнен, кире үз өстенә төшәсен һич уйламый...

Берәүләр хәтта ЗАГС ишеге төбенә дә барып җитә алмый...

Бүлмәдәше Юля исенә төшә Рәмиләнең. Кыланды кызый, һай, кыланды да инде! Күбәләк сыман бер чәчәктән икенчесенә оча-куна йөри торды, тумбочка өстендәге егет сурәтен атна саен диярлек алмаштыра торды. Ахыры ни? Керөп ятты ул бала тудыру йортына, ләкин тудыру өчен түгел, котылу өчен... Аннарымы? Узган айда күп-күмгәк күз төпләре белән кайтып китте ул үзенең Ока буена йөрәк майларын сыгарга...

Ә күрше тулай тороктан икенче берәү? Анысы тудыруын да тудырган, әмма тудыру йортыннан чыккан чагында, бәгырь пәрәсен язмыш дулкынына ташлап, тизрәк сызган, ди, Чаллы каласыннан... Баласы булмаган берәр гаилә куангандыр инде куануын, ә үзе? Тора-бара ни

уйлар, ни кичерер? Соңыннан, сулышы бетеп егылгач? Андыйларга ана исеме әрәм!.. Ә җир ансат кына күтәреп йөртә бит шундыйларны да! Бичаракай, үз җаена гамьсез генә әйләнүен белә, адәм актыкларын ни салкын гүренә тиз генә индерми, ни төпсез космоска ыргытып ташламый! Ә бит йөриячәкләр әле андыйлар гомерләрендә кара үкенечтә каралып...

Тфү, тфү, нишләп әле ямьсез һәм шыксыз уйлар килде күңеленә, нигә дип әллә кемнәргә яман теләкләр тели? Тәүбә, мең тәүбә!

Әнә бит бригадирлары Людмила Крутько — аны, бу үтә тырыш һәм эшчән хатынны, моннан ике ай чамасы элегрәк бригадалары дәвәеп, икегә бүленгәч, кызлар үзләре теләп бригадирлыкка сайлап куйганнар иде — менә шул кирәк чагында бик тә таләпчән, бер үк вакытта мөлаем-йомшак та була белүчән Мила апалары әледән-әле искәртеп тора ла үзләренә:

— Эш эшләгәндә, аеруча безнеке кебегендә, сеңелкәйләрем, күңелнең бик саф, бик матур булуы кирәк! Йорт-биналарга безнең буяу-бизәүләребез белән бергә зур куанычлар, матур теләкләр дә сеңеп калсын! — ди.

Балалар бакчасы белән яшьләр кафесын бизәгәндә дә шулай дигәләр иде, әле менә культура сараена күчкәч, бигрәк тә еш кабатлый андый сүзләрен:

— Кеше шушында күңел көрлеге эзләп килер. Монда матур-матур шигырьләр, җырлар яңгырар. Монда хисләр яңарыр. Ә хис яңартучылардан без — иң беренчеләр, зинһар, сынатмыйк инде, гөлкәйләрем! — ди.

Шулай бермәлне ни мыштым Фаягөл ничектер кыюлана төшеп аңардан:

— Ә моңланырга, сагышланырга ярыймы соң? — дип сорады.

Людмила апалары шулчакны кызыйның башын буяулар сеңгән күкрәк турысына ипле генә китереп кысты да көлеп үк җибәрде:

— Нишләп ярамасын? Сагышлана-моңлана бир! Тик, чибәркәем, уй-хисләрең ак та булсын, пакь тә булсын — нибары шул!

Әнә шундый инде аларның Людмила апалары!

«Юк, Мила апакаем, юк, керсез күңелемә һич кенә дә кер кундырасым килми!..»

Яшьлегем КамАЗда нишләргә-ә-әү...

Ә Юлә шулай да кызганыч... Болай көр күңелле, шук һәм елгыр кыз иде. Их, Юлә, Юлечка!..

3

Кырлар тарихы, авыллар язмышы... Исемнәре... Зур игътибар, зур саклык белән аларга орынып карасаңмы?

Туры карт, мөгаен, хаклыдыр...

Актаныш марие Назарның да, Вятка егете Габделбәрнең дә үз туган авылларының тарихы, хәтта аның исеме белән алай тирәнгә чумып кызыксынганнары юк иде. Хәер, дөньяда андыйлар азмыни?

Мәгәр Ризван-агрономның улы Сабир хакында алай дип әйтеп булмый. Ни дисәң дә, әледән-әле «тарих-бабакай» яисә «җазмыш-бармыш» дип искәрткәләп торган, искәртү генә түгел, үткән заманнарның кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрен, хәтер сандыгыннан актарып алып, сөйләп килгән Туры картның сөекле оныгы ич ул!

Җәйге җылы төннәрдә ак келәткә квартирант дуслары янына кереп кунып калган чакларында, Сабир, билгеле инде, үзе ишеткән-белгән хәтлесеннән төрле «кызыклы әкәмәтләрне» сөйләп биргәли иде. Тегеләр аны бик рәхәтләнеп, хәтта йокыларын качырып тыңларлар иде. Сабир, кызыклы хәлләрне төенләгән чагында, әлбәттә, авыл исемнәрен дә читтә калдырмаган һәм моның белән тегеләрнең күңел кылларын әйбәт кенә чирткәләп тә алган иде.

Әйтик менә, аның туган авылы Әҗер... Каян килгән, ничек туган ул? Чын булса, болай: бик күп заманнар әүвәл, имештер, бериш йомышлы татарга җир бүлеп бирергә булганнар, ди. Патша хәзрәтләренә ниндидер хезмәт күрсәткәннәр, ахрысы... Боларга: «Әҗере шул булыр сезгә» дип, Шилнә буеның, элек-электән татар белән башкорт кушылып яшәгән төшләреннән аулак кына бер почмагын бүлеп тоттырганнар. Җире алай дан түгел, ди, җитмәсә, җыен әрәмә баскан түмгәклекләр, ди. Нишләсеннәр, әрчергә ябышканнар, аннары инде «Әҗер» булып төпләнеп тә утырганнар... Калмаш авылы исеменә килгәндә, дә, шуңа тартымрак хәл. Кама аръягында Бәзәкә дигән зур гына авыл бар. Шул авылдан берәүләр, һәйбәтрәк, тынычрак җир эзләп, бирге якка чыккан, ди, бер дә бер заман. Йөриләр, ди, болар, йөриләр, дә, йөри торгач, кара урман эчләрендә зур гына бер аланга тап булганнар. Бу аланда кыр ягыннан кемнәрдер килеп утырган да аны калдырып киткән, имеш. Кем дигәннәре, әлбәттә, күчмә башкортлар булгандыр... Әнә шул башкортлар ташлап киткән «Калмыш алан» тора-бара Калмашка әверелә дә куя... Ә Үтәдемме? Монысының да ата-

масы ук кычкырып тора: андагы татарлар патша боерганны, урыс чиркәве кушканны үтәгән, ягъни чукынып, урыс диненә күчкәннәр... «Үтәдем» булгач инде, боларга җирнең дә бирәгәйлесен тоттырганнар, үзләренә, җитмәсә, кәсепчелек итәргә — итек басу, кием-салым тегү, пыяла куеп йөрү кебек эшләр белән шөгыльләнергә дә рөхсәт биргәннәр. Диннәрен алыштырганнарга, шул рәвешле, тормыш итүләре, җан асраулары күп җиңелгә килгән...

Әмма иң кызыклысы Гәрдәле исеме. Монысын сөйләгәндә Сабир, иреннәрен ялаштырып, тел чәпелдәтүләрдән дә котыла алмады:

— Шулай берзаман татар агайлар патша башлаган сугышта зур гайрәт күрсәткән, ди. Боларга шуның өчен бүләк иттереп, җир бүлеп биргәннәр, ди. Каян булсын? Безнең Шилнә буеннан инде... Шуннан бу татарлардан берәү юл буйлап барганда, урыс белешен очраткан, ди. Сораган, ди, урыс: «Ну, кнәз-туганкай, хәлләр ничек? Җир бирделәрме?» — дигән, ди. «Хәлләр хәл әле, знакум... Гара дали, гара!» — дип әйткән бу. Боларга шәрә тау битләрен тоттырганнар икән. Бу чабаталы татарның әнә шулай дип әйтүе боларның авылына ябышкан да калган бик әйбәтләп кенә. Аннары инде, тора-бара моның «Гара дали» дигәне әкертенләп Гәрдәлегә әверелгән дә куйган шома гына иттереп!

Назар белән Габделбәр, ихатадагы тынлыкны ярып:

— «Ну, княз! дигән, ә? Үзе княз, үзе чабаталы!

— «Гара дали! дигәне юнылып-ышкылып Гәрдәлегә әйләнсен әле! Кызык булмыйча! — диешә-диешә, бер гөрләтеп көлешеп алган иде ул кичне...

Ә менә Чуар авылына җиткәч, Сабир төртелде дә калды. Монысы хакында аның әлегә кадәр берни дә ишеткәне юк иде. Ә болай бик кызык исем бит! Тик каян килгән, нидән туган икән ул?

Хәзер исә сорашырга-белешергә бик әйбәт җае чыкты кебек: ник дигәндә, әтисе Ризван белән маңгайга-маңгай бәрелешеп, бәхәс куертканда бабасы үзе ук: «Авыл исемнәренә генә орынып кара, тарихның чын исен шундук сизәрсең» дигән сүзне әллә ничә ычкындырды бит. Шушындый форсатны кулдан җибәрергә ярыймыни?

Алар өйнең алгы өлешенә чыгып, кайсы кая утырышып алган иде. Морҗада басынкы гына җил сызгыра, ә тәрәзә өлгеләрен кырпак бозлы вак яңгыр четердәтә иде. Бу исә күңелдә пошаманлы, моңсу уй-хисләрне кузгата иде.

Ләкин Туры карт тышкы кыяфәтенә карагаңда бик тыныч кебек күренсә дә, телен язып җибәрергә ашыкмады. Чал кашларын җыера төшеп, оныгы Сабирга, ике квартирант егеткә берәм-берәм күз йөртеп алды. Гомер сөрмешенең кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрен сөйләгәндә дә тиешле шарты һәм җае кирәк, төрле гыйбрәтләрне тирәнгә сеңдерердәй җаннар булуы кирәк шул. Бу ике «фатирант» егетнең Туры карт өеннән бөтенләйгә чыгып китәренә дә әллә ни күп калмагандыр инде: тулай торакка чиратлары әкренләп булса да, алга таба үрмәли, ди. Инде тәмам ияләшкәннәр иде — сагындырырлар. Хәер, үзләре дә монда яшәгән көннәрен, менә болай кич утыруларны исләренә төшерми калмаслар әле. Әнә җирән сакалбай Назарның туган авылы, туган болын-кырлары бөтенләйгә, тулаем су астына күмелеп юкка чыгачак, ди. Кая барсын кеше? Үзенә юл ярып, бәхет эзләп килгән. Олы төзелештә завод һәм кала җирен үзенчә бизәмәкче, шунда инде бер уңайдан, әлбәттә, үз язмышын да яңартмакчы. Өр-яңа кала җирендә, балга җыелган чебеннәр шикелле, җыен алама имгәкләр дә хәтсез генәдер. Назар кебек асыл җанңар бик кирәк шул анда да! Ә менә Шөн егете Габделбәр исә нәкъ инде шуның киресе сыманрак: шушында, мәхшәр купкан җирдә, үзенә түл җыеп, төпле һөнәр иясе булмакчы, дөресе, төрле эшләрдә болай да оста кулларын тагын да шомартып җибәрмәкче, аннары инде, гөрләтеп яшәп яткан туган авылына кайтып, аны тагын да ямьләндереп җибәрмәкче. Җәл, андыйлар сирәгрәк очрый шул бүгенгесе көнне. Нәкъ менә шуңа күрә, туган туфрагын тагын да баетып җибәрергә ниятләве, җитмәсә, сирәкләрдән булуы белән ул Туры картның күңеленә чагыштыргысыз якын иде. Ә бит тора-бара бу асыл егетнең алар белән бөтенләй якынаеп, хәтта туганлашып ук китүе дә бик ихтимал ич. Теге кызый, аларның бердәнбер чибәр чәчлекәйләре генә, тырт та пырт кыландырмаса инде... Хәер, берни кыландыра алмас, киртә буе сикерсә сикерер, әмма беркая да китә алмас! Егет бер дә җебеп йөрми кебек. Туры карт бик әйбәт сизенә: егетнең шәп әрҗәле менә дигән мотоцикл алып җибәрүе бер генә дә тиккә түгел — бар аның хикмәте! Аннары егетнең соңгы вакытларда артык уйчанланып йөрүләре, бар йөз-кыяфәте белән тартыла төшүләре... тиккә генәдерме?

Әнә ул алгы өйнең олы миче төбенә аяк бөкләп утырган да зур күзләрен мөлдерәмә тутырып, аңа төбәл-

гән. Туры бабасының авызыннан әкияттәгедәй берәр асыл кошның пырхылдап очып чыгуын көтә сыман...

— Чуар турында дидек бит инде.. Ни дип уйга баттың әле, бабай?

Сабирның түземе җитәме соң?

— Кһем... Чуар димсез... Чуар... Соң, үзләре дә чуар, хәлкәйләре дә чуар ие шул аларның... Нигәме?

Туры бабай сыңар кулын өстәлгә сузып салды да кәкре бармакларын кыймылдата-кыймылдата янә бермәлтын утырды, аннары, маңгай җыерчыкларын ишәйтеп, сөйләр сүзенең исенә килгән хәтлесен ашыкмыйча, ипле генә төенләргә кереште:

— Җаман нужадан котылып булмасмы дип, алар килеп утырган Минзәлә җагыннан, кырдан... Сәет, Күгәш, аннары килеп, Сәмәкәй дигән авыллардан, ахрысы. Урман-куак арасыннан җир әрчергә җабышканнар, төпләнә башлаганнар әкертенләп... Әмма ләкин, әйткәнемчә, үзләре дә чуар, хәлкәйләре дә чуар ие: боларга җирнең күпмедер өлешен Гәрдәле басуыннан да кисеп биргәннәр икән. Шуннан ни? Чуарлар көндезен бура бурый, ди, ә гәрдәлеләр төннәрен барып сүтә, ди. Җыларсың да, көләрсең дә... Ә ике арадагы межада тәпәләшүләр! Сансыз инде, сансыз... Хәер, безнең үз авылыбыз Әҗердә соң! Җир бүлгәндә ызгыш-талашлар, хәтта ки кан коешлар! Җәки шундый хәл: үзегез дә күреп торасыз, Шилнә җылгасы безнең авылга орынып ук ага. Буеннан-буена. Ә патша заманында ничек ие? Җылганың теге җак җарыннан ук бүтән авыл җирләре башлана. Урыс җирләре. Шуның аркасында купкан низаг-гаугаларны исәпләп китсәңме? Әйтик, безнең авыл казлары җылгада җөзгәндә арҗак җарга мендеме, тегеләр куалап алып китә, ә инде тегеләрнең дуңгызы алай-болай безнең җиргә керә калса, бөтен Әҗер куба, күсәк-сәнәк күтәреп чабалар: «Нәҗес кергән, җиребезне харап итә лә!» дип... Икмәктер, оланнар! Сез авыз җырасыз, ә теге заманнарда җәшь коешлы ие... Ни дип авыл белән авылны үзара ул тикле җарсытырга кирәк булгандыр инде? Хәзер менә, оланнар, акылга да сыймый, ә теге чакны көн-күрмешнең, җәшәмәкнең фигыле шул рәвешләйрәк ие шул... Безнең тирәдә авыл халкы усал булмый нишләсен?

— Ә сезнең якларда читкә китеп йөрүләр булмаганмыни? Шахта җиренә яки алтын эзләмәгә? — дип төбәлде Габделбәр, мич төбендә идәндә аяк бөкләп утырган килеш чак кына селкенгәләп.

— Алай җыракка китүләр... җук, белмим, булмагандыр. Ә менә Кама аръягында утырган Бондюг заводына баргаларлар ие. Кышларын ат җигеп, завод хуҗасына җыен кирәк-яракны ташымага. Бер кышны, җегет булып килгәндә, мин үзем дә шунда эшләп уздырган ием.

— Ә безнең авылдан бик күпләр киткән шахтыга. Әле дә өй саен диярлек шахты лампасын табып була. Шуңа күрә бездә колхоз оешкач та аңа «Кызыл шахтер» дип исем кушканнар. Шахты җирләрендә әле дә безнекеләр әллә нихәтле... Аннары, алтын эзләүчеләр дә булгалаган. Урал белән Себернең җәһәннәм тишекләрен айкап кайтучылар. Җыен зимагур тагы... Шулай, бервакыт бер йолкышы...— Габделбәр кисәк уч төбенә кеткелдәп алды, башын чайкаштыргалады. Шөн егете булсын да, үз авылына кагылышлы берәр хикмәтле хәлне сөйләп бирмәсен, ди, сиңа!—...өстерәлеп кайткач, Вятка ярына җиткән, ди. Килеп җиткән дә, бугазын ертып, акырырга ябышкан: «Лудкы давай, лудкы давай!» — дип. Көймәче агай берзаман, суны аркылы кистереп, килеп җиткән. Утырткан бу йолкышны. Кичәләр икән инде генә. Шул чагында бу зимагур мактанырга ябышкан: «Галәмәт баеп кайтам бит әле, бәхетләр басты, авылдаш, ходага рәхмәт!» — дип әйтә ди. «Ышанмасаң, менә!» — дип әйтә ди. Шуннан ыштыры эченә чабата киндерәсе белән ныгытып бәйләп куйган янчыгын алып күрсәтә бу. «Менә, ди, алла боерса, агач мәчетне сүттереп, таш мәчетләр салдырам әле — дөньяда бер шаулап алсын әле безнең Түбән Шөннәр! — ди.— Син минем кыяфәткә, минем сәләмәләргә карама, җыен алтын белән якут кына булыр бу янчыкта, билләһи!» — ди. Шулай мактанып-селтәнгәләп барган чагында, моның янчыгы кулыннан ычкынып китә дә суга чулт кына чума... Тап изел уртасында!

— Күр син җебегәнне! — дип шыңшыды Туры карт.— Тәки тәкиләй батырган, ә!

— Батырган... Шуннан ябыша бу, мин сиңа әйтим, акырырга-бакырырга, күз яшьләрен түгәргә. Үзе суга сикермәкче була, ди. Көймәче агай көчкә тотып кала. «Соң, сиңа түләргә сукыр бер тиенем дә юк бит, бар байлыгым шул янчыкта иде!» — ди бу. Шул сәбәпле таш мәчет салынмыйча кала безнең авылда...

Өстәл почмагында борын мышкылдатып утырган Сабир пырхылдап көлеп җибәрде:

— Аның янчыгында алтын белән якут булмаган дадыр әле!

— Менә анысын инде Вятка изеле генә белә!

Шөн егете сөйләгәннәрнең шул рәвешле борылыш алуына үзенең дә хәйран булуын аермачык сиздереп, Туры карт та баш чайкаштыргалады:

— Әә бездә җук, андыен кәмитләр алай бик ишетелмәс ие... Бездәме? Бездә дә булмый тормас ие төрле хикмәтле хәлләр, тик хикмәтләрнең дә һай ачысы, һай канлысы! «Тарих-бабакаебыз»ның үте сытылган чаклары, дигәндәй... Бай бай инде ул — җанын шайтанга саткан бәндә. Әмма ләкин җавызның да җавызы Калмаш баяры булгандыр бу фани дөнҗада...— Бабай авыр иттереп сулап куйды, аның йөзе бөтенләй караңгыланып, чал кашларына тикле кушыла язды.— Урманында чабатага җүкә каезлаганда тотса, үзеңнең җиде кат тиреңне каезлар — син дә адәм баласы бит, димәс... Җавызлыкның чиге бармыни? Авыл кешесе дигәч тә, мескен-бичара дигәч тә... Болар да усаллык күрсәтә белгәннәр үзе! Электә дә баяр җирен басып алулар, байлыгын талаулар булмый тормаган. Мин бәләкәй чакта җәнә бер булды. Безнең Әҗер белән Гәрдәле купты... Шул фетнә башлангачмы, әллә шуны бастыргачмы, патшаның манифесты чыкты да бугай. Анык кына әйтә алмаем... Берзаман авылга килеп тулды кылычлы, мылтыклы солдат, солдат... Прәме мәхшәрнең үзе инде!.. Туктагыз, оланнар, аның бәете дә бар, бәете дә... Озын гына ие үзе...

Туры карт, кәкре бармакларына текәлгән килеш, бермәл тын гына утырды, ниһаять, бәетнең очын хәтеренә китерде булса кирәк, чал башын күтәрә төште, һәм менә инде аның кысык иреннәре арасыннан, морҗадагы җил улавына кушылган рәвештә, өзек-төтек кенә көй сөзелеп чыга башлады:

Әҗер җире әвенле,
Гәрдәледә җалан тау,
Зилзиләләп котырды
Җалмавыздыйн җаман җау...
Шилнә суы нидән болганыр?
Дөнҗа көтүләре, һай, авыр!
Җиде кашык, җәшьле күз —
Сабыйларым каршыймда.
Сыерым таралып пешә
Солдатларның ашыйнда...
Шилнә сулары да бормалы,
Түземнәрең, димсең, бармы әле?..

Бабасына ияреп, Сабир да иреннәрен тибрәндерә: бәетнең ишеткән хәтлесен күңеленә тирәнрәк сеңдерергә

тырыша иде, ахрысы. Ә Туры карт исә, тын алырга тукталган мәлендә, теге замандагы яман хәлләргә аңлатма бирергә дә онытмый иде:

— Соңга таба, герман сугышы барганда, Калмаш баярларын җомшый төшкәннәр дип сөйләрләр ие. Сизенгәннәр, ахрысы. Алты семья ие алар. Калмаш тавы битендә ие утарлары. Шәп утарлар! Октябрьдән соң көл иттеләр. Халык ачуын бер җомшару белән генә басып буламыни?

«Абжур» дигән каманда,
Кызлар кача аранга...
Ачының да ачыйсы—камчыйсы! —
Аркалардыйн кан ага...
  Шилнә суы нигә ашкына?
  Чыдасын ла газиз баш кына!..

— Сәвитне җаклап безнең тирә авыллар күкрәген куйган икән, тиккә генәме әллә? Көрәш тамырлары, айһай ла, җыракларда, ай-һай ла, тирәндә!

Баяр аты тимер күк,
Чабар җире бигрәк күп.
Кибән-кибән игеннәр —
Көле калды күптин-күп!
  Шилнә суларында тегермән,
  Авызым тулы каннар... төкермәм!..
Урал тавы, һай, урау,
Таумыни ул Гәрдәле?
Ник җавыз бу замана.
Ник богаулый бәндәне?
  Шилнә суын буйлар ат кына...
  Җәрәкләрдә, и дуслар, ут кына...

— Дөнҗада бер генә нәмә дә тиктән генә булмый, көрәшсез генә бирелми. Адәмнәрнең тире дә, каны да, һай, күп тамган шул туган җир дигәннәребезгә! Кырбасулар сөйләп кенә бирә алмый. Җо-ок, КамАЗ дигән баһадирыгыз да бер генә дә коры-буш җирләрдә корылмый шул, оланнар!..

Көзге ачы җил морҗада улый, боз катыш яңгыр тәрәзә өлгеләрен зеңгелдәтә...

Түр өйнең түр өстәле янында берәү, башын ут яктысына куйган хәлдә, китап-дәфтәрләргә чумып утыра. Совхозның алдагы язмышын кайгыртып, зур уңышларга иң ышанычлы юллар эзләп...

Ә монда, алгы өйдә?.. Хәер, Туры картның кипшергән иреннәре арасыннан агылган моң-сагыш та бүгенге, иртәгәге көннәрнең сафлыгы һәм тазалыгы хакына куертыла түгелме соң?

4

Вахта автобусыннан төшеп, Аскы урам белән беркадәр баргач, Туры карт йортына якынлашып килгән чагында Габделбәр янәшә атлаган мари дустын кинәт кенә туктатты да:

— Әллә, дим, Назар, бу юлы да тулай торакка чират житкәнлеген әйтми калабызмы? Чиратны тагын берәз вакытка чигендереп торабызмы? — дип текәлде.

Кичке эңгер инде тәмам куерып беткән, шулай да, караңгыда да, Назарның күз аклары елтырап алгандай булды, йонлач бүреген баш артына шудырып жибәреп, бияләйле кулы белән сакалына ябышты:

— Син нәрсә, Рәмилә дия-дия бөтенләй тегеләйгә әверелдеңме әллә? Моннан бер ай чамасы әлгәре үз чиратыбызны бер бирдек бит инде, шул житмәгәнме?

— Ләкин без чиратыбызны үзебезгә караганда күп нужалыракларга биргән идек бит, андыйлар бригадада әле тагын да бар, ә без монда, шөкер, жылыда, рәхәттә, сые-хөрмәте дә муеннан...

— Хы, икебез өчен генә вахта автобусы куарлармы? Кайтканда үзең күрдең ич: бу авылда торып эшләүчеләр нибарысы унлап-уникеләп кенә калган ич инде. Шушы атна азагына аларның һәммәсе дә, кайсы тулай торакка оялап, кайсы вакытлы поселокларга китеп, тәмам таралып бетәчәк бит. Кайтканда сөйләшкәннәре колагыңа эленмәдемени?

— Эленде... Әмма безнең монда, әнә теге капка артындагы ишегалдында, үзебезнең корыч айгыр бар лабаса! — диде Габделбәр, якындагы йортка таба кулын киң изәп.— Вахта көтеп, ми катырганчы, минуты белән утыр да чап, рәхәтлән!

— Әллә никадәр араны ачы суыкта, зәһәр жилләрдә ыжгырттырып бару-кайтулары әкәмәт тә рәхәт инде!.. Тукта, соң син ул корыч айгырыңны Кама белән Вяткада бозлар катып, юлларны көрт басканчы, туган авылыңа әтиеңә кайтарып куймакчы идең түгелме соң? Ә Кама аша машиналар йөри дә башлаган, ди, әнәтерә!

— Кышын безнең авылда мотоциклның хәжәте шул тиклем генә... Монда кирәк ул миңа! Ә тотар урынымы? Кайгырма, анысын да табарбыз!

— Юк инде, рәхмәт! Минем тулай торактан бу юлы колак кагасым килми! Үзебез салган йорт лабаса! Андые кайчан әләгә тагы? Яңа еллар үтеп, язга чыккачмы?.. Аннары, апаем, сиңа да, мондагы тылыңны бик

шәпләп нығытып алгач, һөҗүменне тегендә яшәп яткан көйгә җәелдерергә бик җиткән түгелме?

Габделбәр кинәт көлеп куйды:

— Ярый-ярый, күндерден, җирән сакал! Шулай да тулай торак хакында Туры бабайларга бүген әйтеп тормасак, әйбәтрәк булыр кебек...

— Ник тагы?

— Соң, буш кул белән кайтып киләбез ич. Алай килешерме? Ә тулай торакка берсекөнгә күченәсе әле, димәк иртәгә дә монда кайтып кунасы... Иртәгә көндезен, бер арада кибетләрдә йөреп, истәлеккә әйбәтрәк бүләкләр сатып алырбыз, кабарга-йотарга улсын-бусын тагы... Аннары инде, шул әйберләрне күтәреп кайтып кергәч, куанычыбызны капыл гына әйтеп тә салырбыз... Шәпме?

Ниһаять, җирән сакалбайның да авызы ерылып китте:

— Шулай дисәң генә инде...

— Ә бүген исә берни булмагандай, янә берәр күңелле гәп корып җибәрербез иплә генә иттереп... Төрле кызыклар, төрле гыйбрәтле хәлләргә Туры бабайның хәтер сандыгы төпсез кебек бит.

— Хы, менә анысы булырмы икән? Бүген кич хоккей: үзебезнең ЦСКА уйный...

Туры карт өенә кайтып кергәч, ике егет, әлбәттә, берни сиздермәде: гадәттәгечә, көр тавыш белән хәл-әхвәл белеште, аннары юл киемнәрен салып, аларны мич аралыгындагы чөйләргә элеп куйгач, юынды-чистарынды да әзер табын янына тыйнак кына килеп утырышты. Тик тәмле ризык-нигъмәт белән ачыккан карыннарын туендырып, аны хуш исле чәй белән бастырып куйгач кына, йорт хуҗалары Туры бабай белән Тәзкия апаларына, гадәттәгедән матуррак, җылырак иттереп, рәхмәт сүзләрен әйттеләр.

Хоккей дигәннәренә Габделбәрнең әллә ни исе китми иде. Телевизордан футбол күрсәтсәләр генә, ул дөньясын онытып җибәргәли иде, ник дигәндә, малай чагында үз авылында ул туп артыннан үлле-мәлле аз куышмады, армиядә хезмәт иткәндә дә, полк командасына эләгеп, житәрлек кинәнгәләгән, кыскасы, бу уенны ул үз итә, аның рәтен һәм тәмен белә иде. Ә хоккей булды ни, булмады ни аңа... Менә бу юлы да түр өйдә сыртын йомшак диван артына терәп һәм карашын зәңгәр экранга төбәп, хоккей җене кагылган хезмәттәше Назар һәм Сабир-Чуерташ хакы өчен генә, дәрәҗә саклап кына беравык утырып алды да:

— Клубта берәр кызыклырак кино түгелме икән, әйләнеп кайтыйм әле булмаса,— дип, урыныннан купты.

Тышта дөнья тып-тын, һава ярыйсы ук салкын иде.

Капка төбендә, дөнья тынлыгына колак салган килеш, бераз вакыт басып торды. Егетнең өстендә тик әйбәткә генә, әмма соңгы вакытларда бик сирәк киелә торган киемнәре иде. Менә ул башындагы куян бүреген батырыбрак киде, соры драп пальтосының мутон якасын күтәреп куйды. Аннары акрын гына кузгалды. Ләкин клуб ягына борылып та карамады.

Күңеле тулы моң һәм сагыш иде егетнең. Инде менә ачы юксыну хисе дә оялап алды шикелле... Хезмәттәш дусы Назар хаклы кебек: егет соңгы араларда Рәмиләне уйлый-уйлый, чынлап та, тегеләйгә әверелеп бара, ахрысы. Мактаулы, әмма чиксез авыр хезмәтендә тирләр түгеп эшләгәндә дә күңеленнән ул чибәр кызый китми, юлда барганда-кайтканда да, тамак ялгарга утырса да, йокларга ятса да — күз алдында һаман да шул бер сурәт. Ә монда Әҗергә кайтып төшсәләр, бөтенләй әллә нишләп бетә: кызның төсе-кыяфәте генә түгел, көлүшаярулары, сулыш алулары, хәтта исе үк сеңгән шикелле бу авыл һавасына, урам-тыкрыкларга, йорт-коймалар буйлата сузылган сукмакларга...

Менә шушы тыкрык белән ул, зифа сынын бөгелдерәсыгылдыра, көянтә-чиләкләп Туры бабасына колонка суын китерә торган иде. Зәһәр җәй челләсендә әлсерәп кайткан тәнгә дә, җанга да үтә тәмле һәм шифалы тоелыр иде ул су. Суыклыгыннан тешләр камашыр, ләззәтеннән башлар әйләнер иде... Әмма ләззәтнең тагын да нечкәрәгенә, исәрләндергеч тылсымлысына Габделбәр ирешә алмый калды. Молдаван егете Женя Мында чаярак һәм үткенрәк булып чыкты: кай арада кызыйның чиләгенә үрелде, чиләгеннән беләгенә, беләгеннән йөрәгенә... Ә бит Габделбәр дә бер күрүдә ук аңа кызыгып куйган, шул сәгатьләрдә үк җанында чаткы кабынган иде. Ләкин, юк, иң кирәк чакны чын егетлек күрсәтә белмәде, җебеп калды... Инде хәзер мең үкен!

Шушы тыкрыкта молдаван «мыеккае» шул чибәр нечкәбил хакына, аның данын яулап, авыл егетләре белән бик кайнарланып тәпәләшкән иде. Үзе күз төбенә йодрык кадәр фонарь алса алган, әмма тегеләрнең берсен читән төбенә кычыткан арасына сеңдергән, икенчесен киртә аша чөеп аткан. Габделбәр дә махы бирмәс иде, бер түгел, әллә ничә тапкырлар сугышыр иде, күз төпләренә берне түгел, әллә ничә фонарь алыр иде, әмма

барыбер үзенекен итәр, җиңми калмас иде. Аның үз авылында егетләр белән тәпәләшкәне аз булмады, тәҗрибәсе житәрлек, әмма, аннан да бигрәк, десант гаскәрләрендә хезмәт иткән, чигенүне белмәскә өйрәтелгән солдат лабаса ул!.. Ләкин кайда хәзер ул чибәр кыз, кайда аны күзләп, аны сагалап йөргән авыл егетләре? Эзләре күптән суынган!.. Әнә читән төпләрендәге кычытканнар да әллә кайчан шиңеп, җиргә сыгылган, караңгыда, күцелне сызландырып, читән таяклары һәм киртә казыклары гына тырпаешып тора...

Ә менә тыкрык чаты башында Рәмилә туган өй. Тәрәзәләренә зәңгәр якты сирпелгән. Рәмзи дә хоккей карап утыра, ахры. Әллә сугылып, хәл белешеп чыгаргамы соң? Ә юк, кирәкми, иртәгә саубуллашу мәҗлесе үткәрәчәкләр, менә шунда бик иркенләп, бик тәмләп сөйләшеп алырлар әле...

Җәл, ул үзенең ярыйсы гына уңган һәм булган егет икәнлеген тиз арада гына күрсәтеп, ачып сала белмәде. «Акрын киткән — морадына җиткән», диләр. Дөресме бу тәгъбир бүгенге көндә? Бигрәк тә ҚамАЗ кебек мәхшәр купкан җирдә акланамы икән? Югыйсә ул көнкүрештә, бигрәк тә авылда, крестьян тормышында һава кебек үк кирәк булган әллә никадәр эшләрне эшли белә, һәм ул аларны яратып, җиренә җиткереп башкара. Тик торуларны өнәмәү, кулының һаман да берәр эшкә кычытып торуы, кешегә ярдәм итешү, аңа һич рияланмыйча, шулай кирәк, шулай тиешле дип тотыну һәм моңардан тәм табу — аның канына күптән инде сеңгән сыйфатлар иде. Мондагылар да, егетнең холык-табигатендәге менә бу якларын, акрынлап булса да, бик әйбәт сизеп алдылар шикелле. Әнә бит, беркем әйтеп тә, үтенеп тә түгел, шулай ук кемгә дә булса алай бик ярарга тырышып та түгел, нибары тик тора белмәгәннән һәм кыек-шыекларны күрүдән җаны әрнегәненнән генә, булмаган вакытын бар итеп, Туры картларның болдырын сүтеп-таратып һәм өр-яңадан корып, аңа менә дигән шома култыксалар ясап куйды. Ул да түгел, какшаган ишекләрен төзәтеп бирде, арт һәм ян тәрәзәләренең рамнарын ныгытып, аларга өлешчә өр-яңа, чиста пыялалар куеп чыкты. Йорт хуҗалары аңа ничек дип рәхмәт әйтергә белмәделәр.

Әнә Рәмзиләрнең өй морҗасыннан төтен ургылып чыга, югарыга тигез һәм матур булып күтәрелә. Әнисе Рәсүлә, өйләре төнгә җылы булсынга, мич ягып җибәргән, күрәсең... Ә бит ул төтеннең шушылай ургылып,

матур булып бөркелүенең төп сәбәпчесе Галделбәр ләбаса... Һай, күңелле хезмәт булган иде лә ул, аннан да битәр, инде эш төгәлләнгәч, куерткан гәпләре матур һәм мәгънәле булган иде! Тик, жәл, ул ялда шушы йортта туып үскән нечкәбил ни сәбәптәндер кайтып төшмәгән иде, шунлыктан чибәр кызый берни күрмичә, берни ишетмичә калды...

Инде суыклар башлангач беленде: Рәмзиләрнең морҗалары юньләп тартмый, шул сәбәпле, мич авызыннан төтен чыгып, бөтен өйләрен тутыра икән, инде тәмам йөдәп беткәннәр. Якшәмбе иртәсе иде, Габделбәр тиктән генә аларга барып кергәч, казалы хәлне аңлап, мичне тегеләй караштырып, болай караштырып чыкты һәм, колак артын кашыган көйгә, әйтеп салды:

— Безнең Түбән очта Мәсгут исемле мич остасы яши. Инде дә салып күрсәтә үзе мичләрне! Чират тезеп, колхоз эшеннән бушаганын гына көтәләр. Чын шөһрәт иясе!.. Бер җәйне, әле армиягә хәтле үк, мин аның кул арасына кереп, булышкалап йөргән идем. Кеше эштән курыкмасын, эш кешедән курыксын дигәндәй, булмаса, керешеп карыйк әле моңа!

Тәвәккәлләп тотынды ул. Әйбәт киемнәрен салып атып, иске-москы сорап алды. Иң әүвәл мичнең югарыгы өлеше белән морҗасын бөтенләе белән сүтеп ташлады. Аннары, мичнең исән калган өлешендәге бар төтен юлларын бик әйбәтләп тазартып чыккач, сүтелгән кадәресен яңабаштан салырга керешге. Ул, билгеле, һәммәсен үзенчә иттерде, үзенчә кыландырды. Әйе, кулларында чын-чынлап ут уйнатып күрсәтә белде егет ул көнне! Измә изүдә, иске кирпечләрне кырып, чистартып, әзер хәтлесен югарыга биреп тору кебек эшләрдә аңа дусы Рәмзи булышты. Кичке эңгер куерганчы эшләрен түгәрәкләп тә өлгерделәр.

Түгәрәкләп куйгач, билгеле, яңартылган мичнең сәләтен көне-сәгате белән үк сынап карыйсылары килде. Мичкә яртылаш кына, артыгын кызып, каты куырып куймаслык иттереп кенә, утын тутырдылар да чырасына ут тамыздылар. Мич галәмәт шәп суырта иде, коры утын минуты белән ялкынга уралды һәм дөрләп-гүләп яна да башлады.

Менә шул чагында йорт хуҗабикәсе Рәсүлә мич янында идәндә аяк бөкләп, җәйрәп утырган, куллары, битейөзе корымга, тузанга буялып беткән Вятка егетенә, үз куанычын бертөсле сорау рәвешенә төребрәк, әйтте дә инде:

— Әфсенең бик әйбәт беләсең икән, сырхаулар күрмиенчә меңнәр җәшә, улым! Тик ни... Шул Мәсгут абыең җанында остарганнан-остара барып, үз авылыңда шәһәрткә күмелеп җәшисе урынга ниләр эзләп килдең соң син мондагы Чаллы мәхшәренә?

Моңа Габделбәр гадәтенчә киң һәм мөлаем елмаеп җавап кайтарды:

— Ә безнең Мәсгут абый әле илленче еллар башында ук, ягъни мин дөньяга килергә җыенган гына мәлләрдә, Мәскәү каласының Ленин тауларында өр-яңа университет бинасын коруда катнашкан, аннары аны, иң шәп ташчылар рәтендә, Варшава каласына галәмәт дәү культура сарае салышырга җибәргәннәр. Яшьлегенең әнә шул матур елларын ул бик сагынып, бик горурланып әледән-әле исенә төшереп тора, аны тыңлаулары ук күңелле!

Моның соңында шунда мич каршысында ук тез чүгеп утырган дусы Рәмзигә күз орындырып алды:

— Син, Рәмзи, Чаллы юлларыннан аз йөрмисең бит. Олы юл белән выжлатып үтеп барган чакларыңда, бер кырыйда зур хәрефләр белән буйдан-буйга галәмәт сузайтып: «Не всем дано так щедро жить — на память людям города дарить!» дип язылган плакат күзеңә чалынганы бармы?

— Чалынмыйча... Андый плакат КамГЭС поселогының бер йорт маңгаена да беркетеп куелган, кичләрен ут булып яна! — дип җүпләп куйды Рәмзи.

— Менә шул-шул... Минем дә, дим, соңыннан горурланып, хәттә мактанып сөйләрлек бер эшем калсын үз гомеремдә!

Рәсүлә бу сүзләргә бик канәгать, бик риза кыяфәттә баш каккалап алды. Ләкин аның әйтер сүзе әле бетмәгән икән, ул инде хәзер тавышына тагын да серлерәк, мәгънәлерәк төсмер бирергә тырышып, егеткә төбәлде:

— Ә бәлкем... соңыннан кала салган җиреңдә урнашып та калырсың, туган авылыңа бөтенләй дә кайтып тормассың? Ә бәлкем, шушы данлы-шаулы тирәнең берәр авылында төпләнеп калырга ниятләрең туар, ә?

Габделбәр менә монысына инде җавап бирергә ашыкмады. Аның авыз тирәсе бер җыела төште, бер җәелеп китте, маңгае җыерчыкланып сырланды, ахырда, тирән сулап куйгач, сүзен турыдан бәрмичә, читләтебрәк, әмма шулай ук үзенчә тирән мәгънәгә төрендереп, әйтә салды:

— Язмыш китабын актарып караган юк бит әле...

Бәлкем, аның алдагы битләрендә шулай дип язылгандадыр, Рәсүлә апа!

Дөрләп янган мич каршысында, йөзләрендә ялкын шәүләләре уйната-уйната, бик матур, бик мәгънәле сөйләшү булды ул тымызык кичне, һәм менә шуннан соң алар үзара бик якынаеп, тәмам үз кешеләр булып китләр дә шикелле.

Ә Туры бабай өендә, төп йортларында кич утырып, «Кырлар тарихы» тирәсендә матур һәм серле гәп корулар? Аңа сеңгән кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар, авыллар язмышы, адәмнәр көрәше? Ә авыл исемнәре? Аларның асыл мәгънәләре, аларга төренгән серле һәм хикмәтле хәлләр? Менә болар һәммәсе дә Габделбәрнең күңеленә тирән уелып керде, һәм ул, туган ягы Вятка буйларына кайтып төшсә, бу җәһәттән барын да тирәннән өйрәнеп-белеп алырга ниятләп куйды — моңа аның иманы камил иде. Димәк, бу тарафтан Туры карт үз максатына иреште дисәң дә була иде. Ләкин нечкә күңелле хәйләкәррәк зиһенле бабайның теләге моның белән генә чикләндеме икән? Ул үзе сөйләгән кызыклы вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр белән тыңлаучыларында, бигрәк тә Габделбәр күңелендә, бу тарафларга, үзенең туган якларына олы ихтирам һәм хөрмәт хисләре уятырга, шуның белән аларны тагын да якынайта төшәргә, ахыр килеп, бөтенләй үз кеше итеп куярга теләде шикелле. Габделбәргә мөнәсәбәттә ул монысына да иреште диярга мөмкин иде. Алай гынамы, егет күңелендә әлеге күркәм тойгылар гыйшык хисләре белән дә үрелеп, кушылып киткән, ягъни тагын да нечкәрәк, нәфисрәк һәм кайнаррак рәвеш алган иде. Әйе, егет кичләрен серле һәм хикмәтле гәп корып җибәргән чакларында үзе янында чибәр кызның да утырганын, хотта аның сулыш алуларын тоя кебек, «Кырлар тарихы»на, аларга сеңгән кызыклы вакыйгаларга, хикмәтле язмышларга ияреп, күңеле һәм уе белән бик-бик еракларга китеп бара, җанын тәмам иләсләндергән кызның аны тарихның гыйбрәтле язмышлары тудырып үстергәнен һәм бүгенге көнгәчә китереп, соклангыч матур гөлгә әверелдерүен бик әйбәт аңлый — бу исә егетне чиксез куандыра да иде...

Әнә ул кырлар-басулар. Юка кар астында туңыпөшеп яталар. Инде сап-салкыннар...— Бу минутларда егет, тыкрык белән акрын гына атлап, авыл читенә үк чыгып җитә язган иде...— Ә юк, әнә шул туңып-бөрешеп тын гына яткан мәлләрендә дә, сап-салкыннан да туфрак исе, киләсе яз һәм җәйнең җылысы бөркелә сыман.

Күзләреңне йомдың исә, күз алдында ямь-яшел басулар, гөрләп үскән игеннәр шәйләнә, хәттә аларның шавын колагың белән дә ишетәсең кебек... Алай гынамы, шул яшьлек дөньясыннан, шул игеннәр арасыннан болай таба, аңа таба, җилдә чәчләрен туздырып, кулында зәңгәр яулык болгый-болгый көләч йөзле кызый килә сыман, ул йөгерә-ашкына, бер оча, бер куна, торган саен якыная килә, менә инде кайнарланып кочагыңа керер, менә инде ялкынлы күкрәгеңә сыеныр кебек — нәкъ инде кинодагы шикелле... Ләкин бу — нибары җанлы-җансыз сурәт кенә, нибары мираж гына, аны кочагыңа алыйм дисәң, кочагыңда коры һәм салкын бушлык кына... Назар әйтмешли, әллә чынлап та хыялыйга әверелеп бара инде ул соңгы араларда?

. Ә совхозларында бүген хәлләр хәл... Ризван-агроном, Хәнәфи Бариев белән аның улы Рәмзи кебекләр, бүтәннәр, тырышмыйлар түгел, бик тырышалар, көне-төне баш ваталар, тирләр түгәләр, болай кыландырмакчы, тегеләй итмәкче булалар, әмма атлап үтәсе кыенлыклары хәтсез шул әле. Тегесе җитми, бусы җитми, бигрәк тә төрле һөнәр ияләренә зур кытлык. Ә бит, турысын әйткәндә, Габделбәрнең күкрәк кесәсендә трактор йөртергә таныклыгы бар — моны ул урта мәктәпне тәмамлаганда ук алган иде, шоферлыкка да хокукы бар — монысын армиядә чакта үзләштерде, ягъни хезмәтнең бу төрләреннән дә сынатырлык егет түгел иде. Тик ул боларын әлегә әйтмичә тора, туган ягы Вятка буйларын искә төшергәндә тегеләй дә авыз суларын корытып сөйли, белгән-өйрәнгән һөнәрләре җәһәтеннән кәпрәергә бер дә теләми иде. Яисә, әйтик, кирәге чыкса, дусы Рәмзи белән бергәләп, җәен болыннар сугаруда тир түгеп, кышын ремонт эшләренә ике куллап ябыша алмас идемени? Күңел сала белсәң, совхозда үз сәләтеңне беткәнче күрсәтердәй эшләр азмыни? Шулай, Габделбәр менә бу кыр-басуларда үз буразналарын бик теләп сызар иде. «Кырлар тарихы»ның алдагы сәхифәләренә үз исемен җуелмаслык иттереп, матур иттереп яздыра белер иде. Ләкин моның өчен ике җанның бергә кушылып чәчәк атуы, аларның бер-берсенә тиң булып, кулга-кул тотынышып яшәп китүләре, ягъни кырлар тарихына, авыл язмышына иң матур сыйфатларда сеңеп китүләре кирәк ләбаса! Егетнең бердәнбер шарты шул... Әйе, бер Бариевлар гаиләсе өчен генә түгел, шушы авыл, шушы кыр-басулар өчен дә иң кирәк кеше бит инде ул югыйсә... Нигә менә моны аңламый икән ул кызый?

Кырлар эндәшми, кырлар җавапсыз. Ә юк, алар тын гына хәл җыеп, җегәр туплап яткан мәлләрендә дә, сапсалкыннан да әнә:

— Алдагы матур һәм якты көннәрең хакына, безнең дә алга таба бәрәкәтле һәм хозур булуыбыз хакына, саф намусың белән чын-чынлап кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәт инде, егет! — дип, кайнар пышылдап, киңәш бирәләр сыман...

Кыш башының тымызык бу кичендә Әҗер урамнарын һәм тыкрыкларын байтак буйлап йөрде Вятка егете...

Кайтып керсә, хоккей инде тәмамланган, өйдәгеләр бары бер булып, «Вакыт» программасын карап утыралар иде. Арада, диван почмагына чумып, Ризван-агроном үзе дә утыра иде.

— Нәрсә, клублары бик суыкмы әллә, җүнләп җакмыйлармы әллә? — дип төбәлде Туры карт, алгы өйдә утны яндырып һәм егетнең кызарып янган йөзенә игътибар итеп.

— Суык...— дип көлемсерәде бусы һәм түр якта кәнәфигә чумып утырган хезмәттәше Назарга гына күз төшереп алды да, һәммәсе ишетерлек иттереп, бер сулыш белән диярлек әйтә салды:— Кайткач та әйтергә онытканбыз... Тулай торакка чират җитте бит безнең! Иртәгә сезгә азаккы көн кайтабыз!

Тегендә Назар башын ялт кына болай таба борды, беравык иптәшенә күз тасрайтып карап торды, аннары, үзе дә авызын киң җәеп, җирән сакалын селеккәләп алды:

— Ие, ничектер онытып җибәргәнбез... Берсекөнгә күченәсе!

Югыйсә мондый көн киләсен беләләр иде, аны көтәләр дә иде. Шулай да, хәбәр капыл гына әйтелгәнгәме, Туры бабайның чал төкләр баскан, тирән җыерчыклы үз йөзе дә кинәт кенә куе кызарынып китте.

— Менә бит, ә! Инде көне җитте, диген, ә! Һай, тиз үтә дә соң гомеркәйләр! — дип, карлыккан тавыш белән сөйләнеп куйды карт һәм Ризван улы белән килене Тәзкиягә эндәште:— Ишеттегезме?.. Син инде, улым, иртәгә кичен кантурыңнан вакыт чамасын җуймый кайта бел! Ә син, килеп мунча җагып җибәрерсең, мичкә итле бәлеш салырсың... Берәгәйле иттереп кенә бер мәҗлес корып утырмыйча, һич җарамас, диюем!

— Ярый, эткәй, шулай итәрбез! — дип җавап кай-

тарды Тәзкия һәм, менә хәзер үк эшкә керешергә җыенгандай, утырган урыныннан ук купты.

Ризван да, ачык елмаеп, очлы няген каккалады:

— Андый кичне кантурда батып яталармы соң! Әлбәттә, коры-буш көйгә генә үткәрмәбез аны! Мәҗлескә Рәсүлә сеңел белән Хәнәфи кияүне дә дәшеп алырбыз, уллары Рәмзине дә...

Тик Сабир гына:

— Инде саубуллашасы да икән,— дип куйды моңсу гына. Аңа инде тәмам үз булып беткән абыйлары белән генә түгел, бер уңайдан аларның харап та шәп мотоциклы белән дә хушлашырга туры киләчәк иде.

Ниһаять, ут сүнде, өй эче тынып калды. Бу кичне Ризван-агроном да озаклап утырырга теләмәде, хәер, ул соңгы вакытларда кич озайтуларын сирәгәйтә төшкән иде: яше дә бәләкәй түгел, өстәвенә, эштән чыгып алҗый да торгандыр. Ләкин бу төн аны да, бүтәннәрне дә йокы тиз генә җиңә алмады.

Назар белән Габделбәр гадәттәгечә алгы өйнең бер өлешендә урнашкан чаршау төшермәле киң караватка ятты. Башлары уртак ястыкта... Бермәл тын гына яткач, Назар пышылдап кына, әмма үпкәсен аермачык сиздереп, әйтә куйды:

— Бүгенгә тишелмичә торабыз дип сүз куешкан идек, ә син, сыбызгы?

— Син гафу ит инде. Мин капыл гына киресен уйладым. Никме? Тылның чыннан да ныкмы икәнен беләсем килде. Әйбәт икән! Үзең күрдең ич ниләр кыландырмакчылар!

— Оста да син...

— Ә син, Назар, хаклы: миңа хәзер Чаллыда яшәгәк килеш җиһләр истерергә бик вакыт. Теге мыекбай дусның ныклыгын бик шәпләп сынап карамыйча ярамас! Рәмилә аның ялтыравык укасына гына кызыгып, җенләнмиме икән? Бик яшьләй үз укасы коелмагае кызыйның!

Назар молдаван егете Женя Мынданы да чит күрми, аны якын итә, ә Габделбәр хакында әйтеп торасы да юк. Ул аларның маңгайга-маңгай бәрелешүен һич теләми иде. Ләкин, нихәл итәсең, мәхәббәт юллары кисешми тормас, ди: берәү җиңә, икенче берәү чигә яисә җиңелә... Назар авыр сулап куйды:

— Бик тә кызганыч: мәхәббәтнең күзләре сукыр, диләр шул...

— Аныса аның алай да... Әнә шул мәхәббәтнең сукыр күзләрен ачтыру — асыл егетләр шөгыле түгелме соң, дускай?

5

Таиповның кулында келәшчә-чүкечтер, өтергедер, ян сәкедә вак кадак белән калайдыр, олы кайчыдыр, алдында исә күпне күргән иске әрҗә.

Хатыны Мәрзия аңа: «Зинһар, шуны адәм карар кыяфәткә кертеп, рәтли күр инде, картым»,— диде. Үтенече түрдән. Ә үзе ул Яңа калага куна китте.

Бүген Таипов болын хәтле өендә япа-ялгызы матавыклана.

Аларга өр-яңа квартираны унике катлы мәһабәт йортның бишенче катыннан бирделәр. Өлкәнрәк яшьтәгеләр өчен бераз югарырак инде югарылыкка, әмма алай зыяны булмастыр, шәт: лифт дигәннәре өзелми эшләп торачак, имеш. Ә болай квартирлары әллә кемең кызыгырлык: шоп-шома линолеумлы, ялтырап торган өч бүлмә, ике балкон, берсен, урам якка караганын, «лоджия» диләр икән. Кафель диварлы бик пөхтә кухня. Ни дисәң дә, чын осталар салган «мәскәүский» йорт шул. Әмма иң әһәмиятлесе: суның салкыны да, кайнары да килеп тора, өзеклемый газны да үткәрәселәр, ди. «Мичкә утын ягып, сулар ташып иза чигәсе булмас, бер рәхәтләнер көннәр килер икән безгә дә...» — ди карчыгы. Бу да түгел, якында, кул астында гына диярлек, кибете-мазары, урам аша гына иләмсез дәү поликлиника корылып ята. Картаймыш көннәреңә оҗмахның үзе буласы инде. Карчыгының куанычы күлмәге эченә сыймагандай күренә. Бүгенге хәле шулай, алдагысы ни күрсәтер тагы?

Ике бөртек җан дигәч тә, алдагы көннәрдә, мөгаен, алай калмаслардыр, ишәерләрдер. Шулайрак абайлана. Әнә Идел ярында җәйрәп утырган Козьмодемьянск каласында үзләренә оя кормак булып тырмашкан кызлары Әлфинур белән кияүләре Вазыйх азаккы хатларында бу якларга тартылырга ниятләре барлыгын аермачык сиздереп яздылар. Көннәрнең бераз йомшарта төшүен генә көтәләр. Нәниләре бар, әле тагын булырдыр. Ярый, хуп, кайтсыннар, төпләнсеннәр. ҚамАЗ өчен әзер механик бик тә ярап куяр, кызлары врач та эшне тиз табар, читкә кагылмас. Гаилә тормышлары да картлар янында, ичмаса, түгәрәкләнә төшәр. Әйе, бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Яңа квартирага, әлбәттә, мебельнең өр-яңасын, күзнең явын алып торганын кертерләр. Заманчасын! Мәрзиянең күптәнге хыялы. Яңа квартирага савыт-сабаның, урын-җирнең бер кадәресе күчерелде дә инде. Әмма Мәрзия — әкәмәт җан, Яңа калага иң башлап гөлләрне, аларның да иң купшысын, иң матур чәчәклесен илтте. «Изге сәгатьләрдә туры килсен дә алдагы көннәребез, картлык җәфасын әллә ни күрми-нитми генә, гөлдәй балкып торсын!» — диде.

Ә мондагы, иске йорттагы байтак нәрсә — шактый таушалган өстәл-урындыклар, тимер караватлар, шкаф-комодлар — үз урыннарында калыр: әйдә, үз җайларына әкрен генә туза бирсеннәр. Хәер, алай онытырлык итмәсләр: ике арада җепләр барыбер өзелмәс, туган авылларына эзләрен барыбер суытмаслар...

Бу иске әрҗәне исә үзләре белән алырлар. «Яңа фатирда елтыр-ялтыр мебель арасында аңа гына урын табылыр, сыйдырырбыз»,— диде карчыгы.

Шулай димәскә, иске әрҗә — аның иң кадерле истәлеге. Бирнә әрҗәсе!

Үл көннәрне онытырлыкмы соң? Кышка кергәннәр иде инде. Сугыш беткәннең беренче йомшак карында беренче чана эзләре төшкән чак иде. Кошовкага иңне-иңгә терәшеп утырган шәйгә, туй атының аллы-гөлле сөлгетасмаларын җилфердәтеп һәм җиз шөлдерләрне матур чыңлатып, Әҗер урамнарыннан әллә ничә тапкыр гөрләтеп уздылар. Иң ахырдан, кояш тарафыннан әйләнә килеп, аларның шушы нигез капкалары төбендә тукталдылар. Кошовка артына исә шушы әрҗә бәйләп куелган иде...

Рәхәт һәм татлы көннәре иде...

Егерме сигез ел әүвәл...

Инде хәзер Яңа калага карчыгы әрҗәгәниләрен тутырып алып китәр микән? Иң кадерле савыт-сабасынмы? Әллә элек-электән сакланып килгән китап-журналларнымы? Арада гарәп хәрефләре белән бастырылганнары бар, латин шрифтындагылар да бар.

Ә бәлкем, шушы әрҗәсенә янә кием-салым, чүпрәкчапрак тутырып алып китәр? Теге замандагы иң олы байлыгы булган бирнәсенең үзенчә бер төсе һәм рәвеше иттереп?

Беркөнне карчыгы комодның иң астагы тартмасын актарырга тотынды. Бу әрҗә ул чакны әле келәтнең бер почмагында, ягъни тыныч аккан еллар куйнында, әкрен генә искергәннән-искерә барып, тузан җыеп ятуда иде.

Мәрзия комод тартмасыннан байтак нәрсә тартып чыгарды: үзенең кыз чагында яратып кигән, матур-матур бизәкле күлмәкләрен, яулык-кыекларын, килен булып йөргәндәге киң күкрәкчәле, каймалы алъяпкычларын, бүтәнен... Барының да төсе уңган, бары да тузган, тик тотып карарлык кына. Шунда, и хикмәти хода дигәндәй, тартма эченнән җилкә башлары тәмам уңып, хәтта агарып беткән ертык якалы гимнастерка белән кыршылган пилотка килеп чыкты. Яхъя Таипыч хатынының мондый хәстәрлегенә исләре китеп карап торды. Әмма хикмәтнең дә хикмәте бу түгел икән әле...

Берзаман чүпрәк-чапрак арасында пергамент кәгазьгә бик пөхтәләп төрелгән дүрт кырлы төргәк күренде. Мөгаен, карчыгының шуны эзләве булган дадыр әле... Тапкач, тегеләй әйләндереп, болай боргалап карады, аннары һичбер ашыкмыйча-кабаланмыйча, сакланып кына сүтеп җибәрде. Яхъя Таипыч шул минутта аһлар итте: төргәктә тип-тигезләп өсте-өстенә салынган кулъяулыклар иде! Дистәдән артыктыр!.. Шомалар, чип-чисталар! Бәс-батист чүпрәкләр, дөрес, чак кына саргая төшкән, әмма чигүле чәчәкләре, билләһи, менә шул сәгатьтә генә бакчадан өзеп алып кергән сыман!.. Фронтовик егет булып йөргән чагында аз бүләк иттемени ул аңа шундый кулъяулыкларны? Соңыннан, бергә кушылып, җан юлдашлар булып бер сукмактан атлап киткәч, күрәмсең, барын да кире җыеп алган да, хәстәрен күреп, саклауга куйган...

Мәрзия ул кечне кулъяулыкларның һәркайсын диярлек җәеп җибәреп, аларга дымлы күзләрен төбәгән хәлдә, озак кына уйчанланып утырды, аларны иснәп-иснәп тә куйгалады, ахырда берсен иренә дә сузды:

— Мәле, иснәп карале! — диде.

Чын әгәр, зур роза чәчкәле батист кулъяулыктан әле һаман хушбуй исләре килә иде!

Карчыгы бар булган истәлекләрен, әлбәттә, иң яхшыларын, иң кадерлеләрен, Яңа калага шушы әрҗәгә төяп алып китәргә җыенадыр...

Өлкән ир затының кулында келәшчә-чүкеч уйный, олы кайчы ялтыравык калайны телемнәргә телгәли, аның ихтыярына буйсынып, иске әрҗә торган саен ныгый бара, яшәрә бара иде.

Гомер юлдашының олы гозерен җиренә җиткереп үтәү аның үз йөрәгенә дә ял бирә сыман иде...

Кинәт абзый чүкечен күтәргән хәлдә, сагаеп калды: тышта кемдер болдыр баскычына каты-каты иттереп

аяк бәргәләп алган кебек тоелды. Кайсы йөри икән тагы эш бүлдереп?

Теге озак көттермәде, ишекне киң ачып һәм үзе белән бер болыт салкын ияртеп, бусагадан атлап та керде. Хәнәфи Бариев икән лә.

Хуҗа кеше аңа үтә сәерсенеп төбәлде: Хәнәфинең өстендә гадәттә кия торган кайры тун, башында колакчын читләре шактый ук кыршылган күн бүрек, әмма аягында... бик озын кунычлы резин итекләр иде. Менә сиңа — бу җилдә, бу суыкта!

Хәнәфи ипле генә исәнләште, аннары бияләенең кыры белән генә куе төкләр баскан какча яңагын сыпырып узгач, ярыйсы ук каушаган тавыш белән әйтә куйды:

— Ни... Яхъя Таипыч, кодаң Гайнан Кама уртасында бозда батып калган бит әле. Машинасы-ние белән...

Таипов әрҗә янына чүгәләгән җирендә, кисәк буыннары йомшап, лып иттереп идәнгә утырды, хәтта кулындагы чүкече дә аяк арасына төшеп китте:

— Нәрсә-әү?

— Син, зинһар, алай ук бик нитмә әле, Яхъя Таипыч: үзе исән ул, исән! Акмаган да, нитмәгән дә... Машинасы гына ике боз арасында кысылып калган, ди. Аның бозы да, кадалгыры, ике катлам булып каткан бит бу елның кышында...

— Ник алай?

— Шул инде, югарыдагы ГЭС хикмәтләре: кыш уртасы җиткәндә боз өслэтә шаулатып су агызып ятмасалар соң. Инде хәзер аста да боз, өстә дә боз, ә ике арада су, ди... Кемме? Үзем сөйләштем. Рабочкомда утырган чагым иде, телефон төбендә... Алабугада куна калган булган ул.

— Уф, рабочком, бу хәтле котны алмасаң соң. Җүнләп аңлата да белмисең, иблис! — Таипов идәннән авыр гына кубарылып күтәрелде дә ян эскәмиягә утырды. Аның сулыш алуы, ниһаять, җайлана төште сыман. Атнаун көннәр элек колакка чалынган иде шул: ни Алабугага, ни Менделеевскига чыгып булмый, елга өслэтә шаулап су ага дип... Гыйнвар азагында, чатнама суыкта, ә! Бу Каманың рәтен тәмам бетерделәр: ни җәй сиңа, ни кыш... Ә Гайнан ни пычагыма дип күрәләтә барып кергән соң? Һе, легковойлар уза дигәч тә... ГАИ посты да булмаганмы? Шулхәтле акай-чукайланмаса соң!

— Чукайланмаска... Аның Алабугада бер нефтьче әшнәсе бар икән. Менә шул бәндә берничәләп баллон

кислород ышандырган булган. Ремонтның самый кызган чагы бит. Кислородсыз гына, бар, җүн чыгарып кара!

— Кислород күгәрчен сөте түгел лә. КамАЗ төзелешендә аны су урынына эчәләр дигәч тә, үзебезнең Чаллыда тапмаска... Ярый, хуп, миннән ни?

— Ни дип... Төнгә каршы кешене машинасы-ние белән Кама уртасында калдырмассың бит инде.

— Дөрес, ярамый... Әмма ләкин мин бит инде үзең бик беләсең...— Таиповның товышы кисәк сынып китеп, карлыгуга күчте:— ...власть түгел бит инде, власть түгел!.. Акбашев беләме? Кем булсын, мине алыштырган яңа директор!

Хәнәфи бияләй кыры белән янә какча яңагын сыпырып узды, авыр гына көрсенеп куйды:

— Миңа, Яхъя Таипыч, власть кирәк түгел, миңа... трос кирәк иде.

— Трос? Нинди трос?

— Соң, тарттырмага инде. Мастерской лапасы төбендә рулонда берәү бар иде. Инде җилләр искән. Күргән-белгән кеше дә юк. Әллә, дим, сез...

— Һы, мин каян белим, каравылда утырдыммыни?

— Әллә дим, Гарапша кодаң чагында ук... бер-бер җиргә...

— Гарапша? Тагын шулмы? Тфү, әйтмә миңа бүтән ул исемне! — Таипов ян эскәмиядән капыл гына кубып, алгы өенең идән сайгакларын шыгырдата-шыгырдата ишекле-түрле йөренергә тотынды. Аның калын кашлары кушыла язып, йөзе үтә ачулы, хәтта куркыныч төс алган иде.— Әйтмә!.. Кода, имеш! Тегесе дә, бусы да... бөтенесе дә! Ә бит Гарапшаның артына тибеп авылдан озатканыма өченче ай китте түгелме? Югын да, барын да бер төшкә аударырга... Һы, таптыгыз ташландык коены!

Хәнәфи челт-мелт күзләрен йомгалады: «Менә исәр...» Авызыннан да юньле-башлы сүз чыга алмады:

— Соң бит мин... әллә, дим...

— «Әллә»... «әллә»! Ә бәлкем, ул тросны печән-салам тарттырганда ук тураклап бетергәннәрдер? Ә син миннән таптырасың. Менә хәзер, директорлыктан киткәч...

— Нишләп? Кирәге чыкмаса идеме? Бик исем китте, ди... Соң анда Кама уртасында берәү интегеп ята лабаса! Җитмәсә, тышта җәяүле буран...

— Сез үзегез җәяүле буран!.. Дөнья мәшәкатьләреннән котылып, инде үз җаема әкрен генә кыймылдап ятыйм әле дисәм, ургылып кына ла керәсез!

Хәнәфинең дә тавышы кинәт каяндыр, бөере янынннан ук күтәрелеп, калын ирен араларыннан сытылып кына чыкты:

— Ярый алайсам, үзең әйтмешли, «хуп»... Бер-бер әмәлен тапмый калмабыз әле...

Таипов бүлмәдә йөренгән җирендә капыл тукталды һәм кинәт айнып киткән, аптыраган кыяфәт белән Хәнәфигә баштанаяк сөзеп карады — теге инде уң кулы белән ишек токтасына ябышкан иде.

— Тукта, җен орган!.. Тукта! Кама уртасында, димсең... Тфү, анысы да кода!.. Әзер машинаң бармы?

— Булмаска. Мастерской ишегалдында гына...

— Әһе, бар алайса, ул машинаң белән кил син кантур янына.— Таипов бер кулы белән такыр баш түбәсен кашыштырды, икенчесе белән чөйдә эленеп торган билле тунына үрелде.— Менә сиңа аяклы казалар...

Әлбәттә, аңа — кичәге директорга — бүтән берәү өчен проблема рәвешен алган нәмәрсәне хәл итүе чүпкә дә тормады: телефоннан гына шылтыратып, төенне чишеп җибәрергә бик тиз әмәлен тапты.

Ул совхоз конторыннан урамга чыкканда, «МАЗ» кабинасы янында, җилгә аркан басып, Хәнәфи көтеп тора иде инде.

— Әһе, рульгә үзең утырмакчысың, ярый, хуп... Менә болай, Хәнәфи туган, син туп-туры Чаллыга «Сельхозтехника»га чаптыр. Анда Газизов үзе дә белә, баш инженеры Андрей Матвеич та. Шимбә булса да, үз эшләрендә алар... Тросы да табылыр, әгәренки үз «МАЗ»ың белән генә өстерәргә чамаң булмаса, өстәп, машина да сорарсың. Ул Гайнан, оешмаган алла колы, шуны да абайламаска, Чаллысы борын төбендә генә бит югыйсә...— Таипов сукрангандай иттерсә дә, аның йөзенә елмаю иңгән, гомумән, абзыйның төс-кыяфәтеннән, егетлек безнең тирәдән әле качмаган, дигәнрәк чалым аермачык сизелә иде.— Дөньяда дусларың бетмәсен!

— Власть тирәсенәрәк укмаша бит аның дус дигәне дә, Яхъя Таипыч,— дип төрттереп алды Хәнәфи, тыныч кына көлемсерәп.

— Адәм булсаң, власть беткәч тә югалмас чын дуслар!.. Ярый, хуп, тиккә чәнчешмик әле. Карале, ни... Хәнәфи...— Таипов инде кабина күтәрмәсенә басарга итенгән Хәнәфинең җиңеннән эләктереп алды, тавышы ничектер бөтенләй йомшарып, хәтта пышылдауга күчеп куйды.— Син... ни... кайткач, миңа киләлмәс идеңме, ә? Хатын да өйдә юк: япа-ялгызым утырам... Сулышны-су-

лышка кушып дигәндәй, бер сөйләшеп утырырга, ә? Иренмәсәң, кәнишне... Аерылышасы бит, ичмаса, бушаныр идек бер, ә?

Хәнәфи, сәерсенеп һәм соң дәрәҗәдә житдиләнә китеп, Таиповка күз төбәми булдыра алмады: тегенең каратут йөзенә шул арада моң-сагыш та, инәлү дә, хәтта нәүмизлек тә иңеп өлгергән иде.

— Ярый, Яхъя Таипыч... Тегендә батып ятмасам...

«МАЗ» вак кар көртләренә зәңгәр төтен бөркеп һәм бар гәүдәсе белән шалтырый-дыңгырдый китеп тә барды.

Җил карны шәп себерә иде. Таипов зәһәр җилгә бер тын ара йөз тотып торгач, тун якасын күтәреп һәм олтанлы киез итекләре белән шыгыр-шагыр кар изеп, урам белән югарыга үз өенә таба юнәлде. Анда аны хатыны үтенгән һәм көтмәгәндә бүленеп калган олы бер эше көтә ич... Ләкин бу минутта Яхъя Таипычның уйхисләре иске әрҗәне яңарту-яшәртүләрдән бик-бик еракта иде.

6

Бүген төшке ялга тукталгач, Рәмилә иптәшләре белән бергә ашханәдә тиз-тиз генә тамак ялгап алды да җәһәт кенә тулай торагына йөгерде. Җил-җил барып керәп, вахтер өстәленә күз салса, ни күрсен, аның исеменә телеграмма ята. Сөйгән яры Женя Мындадан!

«Алдагы якшәмбедә Мәскәүдән кичке рейс белән кайтып төшәрмен, көт, үбеп синең Женяң»,— дигән.

«Алдагы якшәмбедә»?.. Димәк, иртәгә!..

Күктән көтмәгәндә шушындый куаныч ишелеп төшсә, ни була?

Аякларың җирне тоямы? Очар кошка әвереләсеңме?

Рәмилә бүген очар кош булып та, җырланасы җыр булып та күкләргә менде! Әйе, җыр булып та!

Үз җырының моңа кадәр җырланмыйча, тыелып торган өлеше, күңелендә менә шушы көн, шушы сәгать өчен генә сакланган хәтлесе, кинәт күкрәгеннән өр-яңа төсмерләргә уралып, тышка ургылып чыкты, кешеләр ишетмәсә дә, дөньяга дулкын-дулкын булып таралып китте:

Зәңгәрсу күгемдә самолет күренде,
Сәламләп һавадан канаты тибрәнде.
Кояшым елмайды, күзләрем нурланды,
Ак лачын, бәгырем, ул синдер, ул синдер!
    Серемне дә сөйлим, көемне дә көйлим,
    Яшьлегем КамАЗда иртәнге чәчкә мин!..

Рәмиләнең хәлен Фаягөл шундук аңлап алды:

— Утларда янып йөргән иден, әйттем бит мин сиңа,— диде ул, сердәше өчен чиксез сөенеп.

Күңелең тулы куаныч булганда, кулыңда ут уйнамыймыни? Диварларга матур буяулар белән бергә синең якты һәм саф хисләрең дә сибелмимени, бүлмәләр кояш нурларына күмелмимени!

Ике кыз, шатлыклы тойгылар дулкынында айкалачайкала, көлеп-елмаеп эшли торгач, берзаман ни күрсеннәр, культура сараеның кече залына караган интерьерын инде очлап та чыкканнар. Менә бит, сизелмәде дә диярлек!.. Буяу-бизәү әйберләрен коридорга чыгарып куйдылар да өс-башларын аз-маз төзәткәләргә тотындылар. Смена бетәргә шактый вакыт бар иде әле, бригадир Людмила апалары аларны нинди эшкә кушар икән: спортзалындагы измә сылаучыларга булышмага җибәрерме, әллә «кафе-бар» дигәненә бүгеннән үк бизәү төшерә башларга диярме?

Алар шулай икеле-микеле баш ватып торган арада, бригадир Людмила Крутько яннарына килеп тә басты, чакырып-дәшеп тә йөрисе булмады үзен. Сынаулы карашы белән интерьерны буйлап та, иңләп тә чыкты, аннары ике яңагын да чокырайтып елмайды да тел шартлатып алды: димәк ки, мактавы...

— Кипкәч ни әйтер бит әле,— дигән булды Рәмилә.

— Әйбәт дияр! Булдыргансыз! Инде хәзер нишләтергә икән сезне? Күкләргә чөеп мактаргамы, әллә... кабып кына йотаргамы?

— Кабып йотарга!

— Чәйнәмичә генә...

Бер рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Моның соңында Людмила Крутько, маңгаена төшкән сары чәч тәлгәшен төзәтеп куйды да гөлдәй балкып торган Рәмиләгә текәлде:

— Сиңа, чибәрем, кичке мәктәпкә барасы бит әле, аңарчы дәресләреңне дә караштырып куярга кирәктер, иеме?

— Бүген шимбә бит — кичке уку юк... Мин, Мила апа, авылга әни янына кайтып килермен дигән идем. Инде ике атна кайтып күренгән юк.

— Авылга? Бик әйбәт, кайта гына күр. Сиңа алай озак күренмичә тору килешми дә, ярамый да, кызый! Кайткач, әниең белән әтиеңә миннән күп сәлам ирештер... матур теләкләрдә калды, диген! Алайса...

Бригадир мәсьәләне шактый кызу тотты. Алар тирә-

сенә янә бер-ике кыз тартыла төшкән иде, Людмила апалары һәммәсен бер караш белән иңләп алды:

— Рәмиләбез бүген туган авылына кайтып китмәкче икән. Ә тышта буран кубарга җыена сыман... Иртәрәк кайтып китсенме? Җибәрәбезме, кызлар?

Бу минутта: «Женя Мынданың телеграммасы хакында белми әле. Их, аны да белсә идеме!» — дигән уй Рәмиләнең күңелен кымырҗытып узды.

Иптәш кызлары исә, дәррәү кубып җавап кайтарды:

— Җибәрмичә... Кайткач, солдат абыең иңнәренә тау-тау сәламнәр аудар, яме!

— Бер килеп күренсен әле, ичмаса!

И рәхмәт яугырлары!

Рәмилә тулай торагына таба очты. Бер сулыш белән диярлек үзенең бишенче катына йөгереп менде. Бүлмәсенә кергәч, эш киемнәрен салып атты да аларны стенадагы шкафка урнаштырды, моның соңында душ бүлмәсенә сугылып, краннарны боргалап карады: и боларына да мең рәхмәтләр инде, соңгы араларда суның ни кайнарыннан, ни суыгыннан өзмиләр. Туйганчы кинән!

Тиз генә юынып, чистарынып чыгар да өстенә җылырак киемнәрен кияр. Башына, әлбәттә, мамык шәлен урар. Тик былтыр сатып алган кышкы пальтосы гына шәптән түгел инде, күкрәк тирәләре, иңбашлары кыса, якасы да кыршылганрак. Әнисе аңа: «Унынчыңны бетергәнче җитсен ыштубы!» — дигән иде. Ә кызлар монда хәйран шәп киенә, авылдан килгәннәре дә мода җәһәтеннән әлләниләр кыландыра, кала кызларыннан һич калышмый торганнардыр. Кибетләрдә менә дигән модный пальтолар исәпсез. Рәмиләнең әллә ничә тапкыр киемнәр кибетенә кереп караштырып йөргәне булды инде. Туплаган акчасы да җитәрлек. Ләкин сабыр, сабыр, Женя Мындасы кайтсын әле, бергә-бергә карап йөрерләр, бергәләп сайлап алырлар. Пальтоның иң һәйбәтен, иң модныен, иң шәп мехлысын! Якасына карап, иң модный хатын-кыз бүреге тагы! Сатып аласы әйбере иң әүвәл аның күңеленә ошасын! Ә бүгенгә юл йөргәндә аның бусы да бик яраган...

Әллә абыйлары Айдаш белән Вәсимнең сменадан кайтуларын көтәргә микән? Алар бу атнаны нишләмәкчеләр икән, авылга кайтырга исәпләре бармы икән? Ә юк, бу суыкта, бу ачы җилдә мотоциклда ыжгырттырып кайтканчы монда... Олы юлга чыкса, шушындый көнне берәр сакалбай-шофер Рәмиләне туган авылына хәтле үк илтеп куймасмыни? Кайткач, әлбәттә, әнисе-

этисе, Рәмзи абыйсы белән күрешер-сөйләшер дә Туры бабаларына барып килер, аннары клубка чыгып, бер кинәнеп кайтыр. Әнисе бүген үк мунча ягып куйган булса, бүген кич керер, өлгермәгән булса, иртәгә иртүк үзе ягып керер, парланып, җиңеләеп һәм сафланып чыгар. Ә төш тирәләрендә инде кире Чаллыга кайтыр да кич булганын көтә башлар. Анда инде аэропортка элдертер... Моңа кадәр Рәмиләнең сөйгәне Женяны ерак сәфәргә ике тапкыр озатып җибәргәне генә булды. Каршы алганы әлегә кадәр юк иде. Хәер, моңа чаклы егетнең телеграмма сукканы да булмады ич. Ә бу юлы суккан! Димәк, сагынган, бик-бик сагынган ул да! Рәмиләсен тизрәк күрәсе килгән!..

Менә инде өстенә душтан су коела. Җылымса, рәхәт!

Кызыйның бите-муеннары, бар тыгыз, зифа гәүдәсе буйлап су чишмәләре ага, үзе, тончыгып-пошкырынып булса да, җыр сузудан тыела алмый:

Сер...емне дә сөй...лим, кө...емне дә көй...лим,
Яшь... ле... гем... Кам...АЗ...дау...

Менә инде юынгач-сөртенгәч, иң әүвәл киясен генә киеп алды да, башына сөлгесен урап, душ бүлмәсеннән чыкты.

Гәүдәсендә илаһи бер җиңеллек!

Авылга әле бик күптән түгел генә тектереп алган, алсу өслектә күксел яшеннәр яшьнәгән, саргылт-яшел йолдызлар җемелдәшкән күлмәген киеп, башына да мамык астыннан шундый ук яулык кыегын ябып кайтыргамы әллә? Монда аны бер киеп күрсәтүенә бүлмәдәш кызлары һуштан егыла язды. Тегендә туганнарының да исе китмичә калмас, ә инде клубка чыгып, берәр җиллерәк биюдә шул күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, бөтерелеп күрсәтсәме! Ә юк, юк, аны иң әүвәл Женя үзе күрергә тиешле! Бу затлы материяне ул бик ерак бер сәфәреннән алып кайтты, Рәмиләгә унҗиде яшь тулу уңае белән октябрь уртасында бүләк иткән иде — зәвыгы хәйран аның, сөйгән ярының күңеле ни теләгәнен, аңа ни килешәсен бик белә! Яңа елга күп калмады инде — нибары бер атнадан чак кына артыграк. Менә кайчан киячәк ул аны! Женясы аңарчы, әлбәттә, беркая да китеп югалмас, бергәләп берәр мәҗлес-фәләндә катнашырлар, һич югы тулай торакның кызыл почмагына төшәрләр. Әнә шулчакны инде Женясы да, бүтәннәр дә

энчеле-йолдызлы «кырлар чәчкәсенә» бер сокланып куйсыннар әле! Әйе, иң әүвәл үзе сөенсен, үзе!..

Ә хәзер исә Рәмилә кичке эңгер куерып киткән бүлмәнең түренә үтеп, тәрәзә каршысына басты. Тышта, болай таба кыекланып торган йортларның байтак тәрәзәләренә ут кабынган инде, ә шактый арырак, сыек буранлы рәшә эчендә, басу түрен кисеп үткән олы юлда автомобильләрнең фара яктылары чабыша — елга булып ут агыла диярсең...

Тәрәзәдән бөркелгән салкынча, әмма йомшак һава дулкыны аның кайнар гәүдәсен бик тә иркәле кочып алды. Кыз, шуның рәхәтен тойган хәлдә, ике кулын да күтәреп тыгыз күкрәкләре өстенә салды да күзләрен йомды.

Инде әллә ни күп көтәсе калмады... Әйе, вакыты җиткәч, әйтер ул аңа:

— Менә, бәгърем, тәнемне дә, җанымны да синең өчен саф көе, керсез көе саклап килдем. Инде теләсәң нишләт мине,— дияр.

Бәлкем, РИЗны худка җибәрүләрен дә, Рәмиләнең кичке мәктәпне тәмамлавын да көтмәсләрдер әле... Үзе ни дия бит?

> Киң дәрья буенда ак кала салабыз,
> Чаллыда ялкынсыз янучы бер минме?
> Җил-давыл уйнатып яныма килерсең,
> Шашынып үбәрмен үземнең тиңемне!..
> Яшьлегем КамАЗда таңдай саф чәчкә мин,
> Дөньяны балкытып, ал нурлар сибәм мин,
> ал нурлар сибәм мин!..

Беркадәр вакыт үтүгә, «кырлар чәчкәсе» җәен-җәй буена көязләнергә бик тырышып та, кышка кергәнче көязләнеп бетә алмаган Муса Җәлил проспекты буйлап, инде шактый көчәеп киткән җәяүле буран эчендә, әмма үзе дә чокыр-чакырлар аша бик тә җилле сикерә-атлый, зур күзләре караган тарафка элдертә иде инде...

7

— Син, Хәнәфи энем, турысын гына әйт әле: үзебезнең Әҗердә сиңа авыз тутырып, күбәүләрме «җизни» янсә «кода» дип эндәшә? Бик күпләрме, дим?

Яхъя Таипыч табынны болындай иркен өенең түр ягына әзерләгән, әмма ул табада бәлеш төбе кыздырырга яки чәй куймага алгы өенә, газ плитәсе янына да чыкмыйча булдыра алмый һәм кергән-күренгән арада

диванда җәйрәп утырган кунагы Хәнәфигә әнә шулайрак дип төбәлә иде.

— Соң, алай әллә ни күп түгел түгелен, әмма дәшми йөрмиләр,— ди монысы.

— Дәшсәләр, эреплә дә китәсеңме?

— Эремичә... Хәер, төрле чак була: кәеф ничек бит, шарты тагы...

— Менә-менә: хикмәт кәеф белән шарт дигәнендә! Яшьрәк чакта минем дә шартлар шәптән иде: авылда өч кенә бөртек кеше миңа шулай дәшә торган иде. Һы, тансык булмый ни! Ә хәзер? Ыру-тамыр, туган-тумача, һай, ишәйде, һай, җәелде. Инде куян шулпасының шулпасы гына да түгел — күл, диңгез!

Хуҗа, иңе аша салынган чуар башлы сөлгегә кулларын сөртештереп, янә алгы өенә чыгып китә, ә Хәнәфи шоп-шома итеп кырылган какча яңакларын учы белән сыпыргалый-сыйпаштыра утырып кала.

Монда килгәнче, өендә мыштым гына кырынып, көязләнеп маташкан чагында, хатыны Рәсүлә аңа: «Син нәрсә, көндезләр беткәнмени сиңа? Әллә кызлар жанына төп ката аулак өйдә утырмага жыенасыңмы соң, картлач?» — дип күз чекрәйткән иде. «Әйе, аулак өйгә — тап өстенә бастың, карчык!» — дип, ярыйсы ук эресымакланып җавап кайтарды аңа Хәнәфи. Әмма сер йомгагының җеп очын хатынының кулына абайламыйча тоттыргансың икән, йомгакны аз гына булса да тәгәрәтеп җибәрмичә котыла аласыңмыни? — Булмаган эш. Аңлатып бирүенә хатыны ботлар чапты: «Кит аннан! Әстәгъфирулла дими, Таипов була торып Таиповмы?!» Рәсүләнең авызында сүз тормаучанрак, түзмәгәндер, күршеләрнең берәрсенә кереп: «Шулай-шулай бит әле, безнеке Яхъя Таипычка аулак өйгә әчләр бушатышырга китте бит әле, әкәмәт!» — дип, төрле имеш-мимешне күпертергә оеткы салып чыккандыр инде. Әй, салса соң, имеш-мимеш таралса соң? Директор булып эшләде дигәч тә, Таипов кеше түгелмени?

Ниһаять, табынга олы табада бәлеш төбе килде, өстәл читендәрәк кайнар буын бөркеп, эмаль чәйнек тә урын алды. Табын әзерләүнең ни икәнен юньләп белмәгән хуҗага хатыны югында ризык-нигъмәт хәстәрләве җиңел булмады, ахры: Таиповның җәенкерәк борыны һәм маңгай жыерчыклары өстенә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан иде.

— Әйдә, Хәнәфи, энем, гаеп итештән булмасын, җиңел кулдан гына инде,— ди-ди, ул табын күрке бәлешне

кунагына таба этебрәк куйды, аннары уртада җем-җем итеп торган җыйнак кына графинга үрелде, рюмкалар чыңлатып алды — Кабарга менә тозлы кыярдыр, кәбестәдер... Әйдә, исәнлеккә-саулыкка! Менә шулай... Эһе, йөгердеме? Тегендә, Кама өсләрендә дим, чынлап та ай-һай булгандыр шул, ә?

— Әйтәсе юк. Анда тәгәрмәч төпләреннән, ягъни боз арасыннан фонтан булып су бәреп ята! Нефтьчеләрнең ике машинасы чумган, арырак тагы бер «Волга»...

— Волга?

— Әйе, нәчәлниге, күрәсең, корыга чыгып, Чаллының үзенә шылган җәтрәк. Ә шоферы, мескенкәй, нибары курткадан, ботинкадан гына. Төнгә каласы булса, машинасы да, үзе дә Кама уртасында шакыраеп катасы иде. Өстерәп чыгардык аны да...

— Заманалар диген...

Хәнәфи, ни әйтсен, калын җилкәсен генә тартыштыргалады. Итле бәлеш галәмәт тәмле иде, тозлы кыяр белән кәбестә дә бик һәйбәт — кабуга эреп кенә китә... Таипов елтыр графинга янә үрелгән чагында, ниһаять, сүз дилбегәсен баягы тарафка тартыбрак куйды:

— Шулай, туган, җыен баҗалар, кода-кодагыйлар, кодача-кайнешләр үзебезнең Әҗердә ярты авыл, инде хәзер Гәрдәле белән Чуарда да әллә нихәтле. И яшьрәк чакта рәхәт кенә булган шул! «Кода» дип әйтүләренә алай бик таралып төшмәсәм дә, «җизни» дип җибәрсәләр, ипидер, эреп кенә китәр идем. Андыйларга учыучы белән көнбагыш өләшер идем. Кесәмә юри тутырып йөрер идем. Ә хәзерме? Өләшәм дисәң, җилкәнә биштәр асып йөрергә кирәк, билләһи!

— Алай ук түгелдер лә,— диде Хәнәфи, көлемсерәп.

— Һы, эш башында утырып карале, Хәнәфи туган! Синең дә нәсел-нәсәп тамырларың шактыйга җәелгән кебек, һәммәкие дә бик тиз сиздерер үзен менә шул чагында... Һы-һы! Әле без синең белән, Хәнәфи, чынлап торып, нечкәләп, тамыр очларын тикшереп караганыбыз юк, шөкер, хатыннар да җитенне бик үк талкыштырмаган. Бәлкем, без икәвебез дә үзаралашлый кода-мазардыр, ә? Һы-һы, ярый, булмавыбыз, дөрес, аны белмәвебез хуп... Җәле, шуның хакына берне сеңдереп куйыйк әле булмаса. Ягъни дә гап-гади авылдашлар булуыбыз хакына!..

Хәнәфи, утлы суны аударып куйгач, чак кына йөз җыерып торды да, үзенчә тирән мәгънә салып, баш каккалап алды:

— Анысы шулайрак инде, Яхъя Таипыч, адәм баласы ничек тә власть тирәсенә, түрәләргә сырпаланучан...

— Ә син менә үзең ник сырпаланмыйсың? Нигә һич югы «кода» дигәнен актарып чыгармадың, ник җебеп йөрдең, ә? Югыйсә түтәлләр янәшә бит, нәсел-нәсәп орлыклары кучми калмагандыр... Димәген ки, хикмәт адәмнең үзендә. Тамырларында типкән каннары һәммәкиенең дә кызыл төстә, әмма ләкин тибү җайлары төрлечәрәк, күрәмсең...

«Эһе, керә башлады бу чытырманлыкка...» — дип уйлап куйды Хәнәфи, ләкин үз сүзен итәгатьле һәм сабыр рәвештә әйтте:

— Шуңа күрә дөнья диләр аны...

— Шулай, адәмнең төрлесе бар, әмма ләкин үз туган авылында яшәсәң яшә, тик баш булып йөрмә икән! Гап-гади механизатор булып йөрүләреңә куанып яшә, Хәнәфи туган!

— Анысы хак: күктән алай йолдыз чүпләргә үрелгән юк үзе,— диде Хәнәфи, ипле генә ым кагып.— Шулай ук адәмнәр арасында ерганак ерып азапланганым да булмады шикелле.

— Шуңа, дим, куанып яшә, мең яшә! Ярый, хуп... Ә ул миңа нәрсә ди?

— Кем?

— Һы, кем... Соң, Акбашев инде, яңа директор. Мин аңа, минем монда үз туган авылымда хәлләр шулайрак бит әле, бик тә хикмәтле, дип төшендерергә тотынган идем, авызын ерып көлде генә! Минем дә, ди, үз туган авылымда байтак кына вакытлар колхоз җитәкләгәнем булды, нәсел-нәсәп тә ярыйсы ук ишле иде, әмма ләкин туган-тумачаның алай басынкы иткәнен тоймадым, ди.

— Шулай диме? — Хәнәфи, яңа директор турында сүз купкач, ак күлмәгенең изү төймәсен ычкындырып, муенын суза төште, терсәгенә таянды.

— Шулай димичә: яшьрәк чагы бит, кардәш-ыруы, күрәмсең, ишәеп, тармак җәяргә өлгермәгән. Бәлкем, аяк арасында буталучыларны үзе баштук тибәрә белгәндер. Мактавым булсын: үтә дә җилле кеше! Әле сизәрсез...

— Җилле, димсең, алайса?

— Җилле дә, җегәрле дә. Мин Чаллыга гариза илтеп тоттыргач, ике айга якын минем урынга кандидатура эзләп азапландылар. Бөтен республика буйлап! Һич күпертмим, өлкә комитеты булып өлкә комитеты үзе шөгыльләнде шикелле. Шулай булмый ни: совхозыбыз КамАЗга орынып тора лабаса! Күз өстендәге каш кебек... Акба-

шевны күргәч, исләрем китте: вакантный урынга эзли торгач, тәки тапканнар бит нәкъ тиешлесен!

«Яңа директорны күкләргә чөюе белән үз абруеның да аңарчы түбән булмаганлыгына, күр, ничек оста ишарә ясый, ә!» — дигән уйдан Хәнәфинең авызы җәелә төште, алай да, бу хакта сүз катмыйча, ыспай гына колак торгызып тыңлавын белде. Яхъя Таипыч исә кинәт авыр сулап куйды һәм әйтер сүзенә дә гер элгәндәй иттерде:

— Ә минем монда аяк-куллар тәмам чәбәләнгән инде. Башны кемнәр ашады дисәң, шул инде, кардәш-ыру, туган-тумача, аерата Гарапша кода кебекләр!..

Хәнәфинең күңелендә: «Бар абыну-чәбәләнүләреңне нибары туган-тумачаңа аудару дөрес булырмы икән? Кардәш-ыруыңны бөтенләе белән эт эчәгесенә тиңләп, хаклыкка хилаф кылмыйсыңмы, Яхъя Таипыч?» — дигән сорау купкан иде кубуын, ләкин аның Гарапша турында да уй-фикере күптән өлгергән, күптәннән анык — иң әүвәл соңгысын ярып салырга итте:

— Гарапшаны белмәскә... Аның ише болганчык суда балык сөзәргә яратучыларны эзләп табасы әле. Ата комбанатор!

— Шулай! Иң атасы... Ни җитми кешегә? Урыны җылы, элекке кыланмышларын да кичергән идек югыйсә. Ә ул һаман үз юлында... Соң, җәен сугаруга торбалар китерткәндә, минзәләлеләр белән алыш-биреш итешүләре, ә? Имеш, совхозга файда китерә, ә бактың исә... Күпме буталдык, очына чыга алдыкмы? Ә халыкка җәфа күрсәтүләре? Ярый әле, болыннан печән ташырга тотынгач, койрыгына баскандай иттек, алай да шушындый кытлык елны никадәр печәнне сулга шылдырган — чуртым белә... Андыйларга бит дөнья никадәр болганып торса, шулхәтле шәп!

— Характеристика да сорап тормады бугай...

— Сорар сиңа: имеш, гөнаһсызга рәнҗетелгән... Тфү, бакыр елан! Шул инде, чыбык очың тул-туры Каракай башкисәрләренең берсенә барып тоташсын да сиңа, бүтәнчә булсын ди.

— Каракай дидеңме?

Авыл халкы телендә бер төсле батыр сыманрак йөртелгән кеше турында Хәнәфи алай ук ямьсез уйларга гадәтләнмәгән иде, аның хәтта гәүдәсен нидер кымыржытып узгандай булды.

— Һы, шуларга барып тоташмый сиңа! Авылда итәк астыннан ут уйнатып, дөньяны төтенгә сасытып ятулар

Әҗердә кайчан тамыр җәйгән дип беләсең? Шул заманда булмый сиңа, кайчан тагы? — Яхъя Таипыч, йөрәгенә түзә алмады, ахры, утырган җиреннән капыл кубып, шыгыр-шагыр бүлмә буйлап йөренеп алды.— Каракайлардан калган тамырлар берәр кайчан корып бетәрме безнең авылда, юкмы? Ник дәшмисең, Хәнәфи? Каракайлык берәр көнне бетәрме, дим?

Монысы аптырашта калды: авылдашлары хакында шушылай киң һәм күңелсез нәтиҗәләр ясарга аның һич уена да килгәне юк иде. Ни дип җавап кайтарырга белмәстән, сүзне, авыз кыйшайтып кына, икенче тарафкарак борды:

— Ә Гарапша, Чаллыга киткәч, Камснаб хәтле Камснабның үзенә борын тыккан, ди, әнәтерә.

— Тыгар да... Әшнә өстенә әшнә өелгән бит аның Чаллысында да, атын алгыры!

— Чуртанны олы күлгә җибәргән кебегрәк булды шул.

— Үзебез җибегәнгә, үзебез!.. Их, тылның нык булуы кирәк шул, тылның! Ниятләрең ни изге булмасын, обозың какшаса, алырсың яңадан-яңа үрләрне!

— Анысы, бәлкем, шулайдыр, какшагандыр. Әмма гаеп бер обозда гына микән, Яхъя Таипыч?

Таипов ишеккә таба атлаган җирендә тукталып, болайга таба борылды һәм табын янына килеп, Хәнәфи белән янәшә үк утырды, өстәл читенә таянды. Аның күз карашын, юк, аптырау-каушау да, рәнҗү-үпкә дә түгел, тәмам алҗу-хәлсезләнүдән туган сәер бер томан каплаган сыман иде. Хәнәфинең аңарда мондыйны беренче тапкыр күрүе иде.

— Катырак орындың түгелме, Хәнәфи энем? — Моны пышылдап кына кысып чыгаргач, карашын читкә күчерде, уфылдап куйды.— Хәер, катырак булса соң, чын дөреслеккә тарттым лабаса... Йомшарган агачны ни баса, ди? Кортмы? Мин менә шушы кулым белән Гарапшаның гаризасына имза салсам, шул ук көнне, дөресе, шул ук кичне шушы ук кулым белән үзем дә гариза яздым... китүем хакында... Әмма ләкин шәһәр комитетына илтергә ашыкмадым, гаризамны менә монда күкрәк кесәмдә, йөрәк янында ай буе диярлек асрап йөрттем. Шундук ерткалап ташларга нишләптер йөрәгем җитмәде... Бер какшасаң, шулай икән шул, их, чәнчелсен лә иде!

Таиповның күз карашы гына түгел, бөтен төс-кыяфәте хәтәр үзгәреш кичергән иде: ул кушыла язган калын кашларын әйтәсе дә юк, аның тирән җыерчыклы маңгае

һәм аңа ялганып киткән баш шомасына да тимгел-тимгел булып кызыллык иңгән иде. Югыйсә әллә ни күп тә эчмәделәр — аның рюмкалары да нибары уймак хәтле генә, сыйдырган эчемлеге кече телне чылатырлык кына — Яхъя Таипычка хәмер ярамаганлыгы әллә каян беленә иде. Ә бәлкем, аның чуалчык уй-хисләре әнә шул рәвештә тәненә үк бәреп чыккандыр? Хәнәфинең күңелен кинәт кызгану хисе эсселәтеп җибәрде.

— Саулык булсын, Яхъя Таипыч...

— Дөрес, саулык булсын. Әмма, кызганыч, анысы да соңгы вакытларда ташкүлчимгә генә калды шул... «КамАЗ — это прежде всего нервы» дип тиккә генәме телгә дә кереп оялады, ә? Төзелештә, хәтәр темпларга чыдамыйча, аз тәгәрәдеме бүгенге көндә төрле-төрле башлыклар? Шул-шул: КамАЗ сайлый да белә адәмне, сайлап алгач, җегәрен дә сыга белә... Ә без КамАЗ кырында гына, без аның көйдереп торган фокусында лабаса! Янма да, җебемә дә — чыда!

— Ә мин сине, Яхъя Таипыч, алай бик үк җебеп төшкән димәс идем. Бар әле синдә дилбегәләр кагарлык кына җегәрләр!

Таипов кунагына төбәлеп карады:

— Син моны ихлас күңелдәнме?

— Ихластан!

Хуҗа дәшми-тынмый гына графинга үрелде. Аның йөзенә бераз нур кайтты сыман, иреннәре җаелә төште, калын кашлары да җай гына селкенгәләп алды. Тик маңгай өсләрендәге кызыл тимгелләр генә әле һаман таралып-сеңеп бетә алмый иде.

Рюмкаларга агызып чыкты, ләкин кунагын кыстарга ашыкмады, ияген учлаган хәлдә, уйчанланып калды.

— Шулай да кыен әле. Бер хәлдән икенче хәлгә атлап чыгулары, дим... Һай, кыен, белсәң иде, Хәнәфи! Әйе, хушлашу көне килеп җитә икән лә шулай берзаман. Җитмәсә, совхозны да авыррак хәлләрдә тапшырам шул. Аз гына түзсәм, шушындый кыен елны гына уздырып җибәрсәм соң? Булмады, сабырым җитмәде, җен оргыры... Ә бит баштарак, алланың кашка тәкәседәй, һич аны-моны уйламыйча йөргән буласың. Ә көне килеп җитә барыбер! Дөньяда бер мин генәме соң шулай? Юк, күпләрдер, бик күпләрдер!

— Өметсез шайтан булмыйк сана, Яхъя Таипыч!

— Рәхмәт, Хәнәфи энем, җылы сүзләреңә! — Таипов шулай дип, уң кулын кунагының иңбашына салды.— Синнән яшерә дә алмыйм, яшерәсем дә килми, ә хәл-

кәйләрем шушылайрак: бер аягым белән тыпп иттереп кала җиренә китереп бассам да, ягъни үземә менә дигән фатир тоттырсалар да, икенче аягым белән бот төбеннән үк туган туфракта бит әле — суырып аласы бар. Суырып алалсам да сыңар итегем туфрак кочагында ятып калыр кебек. Ятып калыр да сыңар аягым белән ялантәпиләп китеп барырмын кебек...

Хәнәфинең күз алдына бу күренеш бар бөтенлеге, бар чалымнары белән килеп баскандай булды, һәм ул аны куып таратырга теләп, хәтта баш чайкаштырып алды:

— Син алай ук чайпалма, зинһар, Яхъя Таипыч. Сыңар итекләрне суырып алырлык кына көч-кодрәт бар әле синдә. Хәтта күбрәк тә! Дөнья белән алыш-биреш итәселәребез әле бетмәгән, диюем...

— Әллә сүз куешкансыз инде: шәһәр комитетында да шулайрак дигәннәр иде киңәш-табыш итешкәндә...

— Кем?

— Кем, кем... соң Низамов инде, беренче үзе! Чын әгәр, үтәли күрә чукынган! Аның белән бер гәп корып җибәрсәң...

Әнә шулай үз хәлләрен авыл хәлләренә ялгап, авылныкын дөньяныкы белән талкыштырып, байтак сөйләшеп утырды бу кичне сугыш утында да янган, хезмәт ялкынында да көйгән ике ветеран.

Өйдә җылыда һәм тынычта утырган чакларында җәяүле буран инде алай гамь сиздереп азапланмый сыман иде: ни тәрәзә өлгеләренә каты-каты орынып китми, ни югарыда чорма моржасында шомландырып уламый иде.

Әмма, юк икән әле, җил бөтенләй үк тынмаган икән: кунагын капка төбенә кадәр озата чыккач, Таипов тун якасын күтәрмичә булдыра алмады. Аның өе олы урамнан чак кына эчкәре кереп торган, тар гына тупый уенты-аралыкта урнашкан иде, әмма җил монда да әле теге яктан, әле бу яктан килеп, әйбәт-әйбәт кагылып уза иде.

Капка төбендә, җилгә арканрак басарга тырышкан хәлдә, беравык дәшми-тынмый тордылар. Клуб моннан әллә ни еракта түгел иде, ул яктан тонык кына булып музыка ишетелә, яшьләрнең көлешкән авазлары яңгырап куйгалый иде. Әнә олы урам белән, җәяүле буранны тагын да көчәйтеп җибәрергә җыенган сыман, выж гына иттереп, әрҗәле мотоцикл узып китте. «Иж-планета» булдымы ул, әллә «Урал» идеме — Хәнәфи абайламыйча калды. Бу ачы җилдә кайсы исәре юл чыгарга

исәп итте икән? Хәер, исәргән башлар азмыни бүгенгесе көнне?

Яхъя Таипыч, ыжгыртып узып киткән әрҗәле мотоциклны әллә күрмичә калды, әллә күреп тә, аңа бөтенләй ис-өн җибәрмәде, ул капыл гына Кама бозында бәлагә тарганнарны исенә төшерде.

— Казага юлыкканнарга вакытында ярдәм кулы сузу — аңардан да саваплырак эш бармы икән, Хәнәфи туган?

— Савабы саваптыр, әмма, адәм үзе дә шундый чакта сынала.

— Хак сүз... Ә җәяүле буранны минем җенем сөйми.

— Нишләп?.. Котырма буран әллә шәбрәкме?

— Анысында аның, ичмаса, кеше ни буласын чамалый, тыелып тора. Ә җәяүле буранмы? Авылда ул әллә ни түгел кебек, әмма кырга-яланга чыксаң... Шул инде адәмне саташтыра да, адаштыра да!

Бер-берсенә хәерле кич, тыныч йокылар теләп, куллар кысышкач, Хәнәфи урам буйлап шыгыр-шагыр үз тарафына атлады, ә Таипов борылып ихатасына керде. Кергәч, болдырга таба атларга ашыкмыйча, капка баганасына сөялде. Күзләрен йомды.

Аның күңеле ярыйсы ук тынычланган, җаны әллә ни айкалмый иде.

Ләкин күзләрен ачып җибәрүенә, кинәт бар гәүдәсен өшетеп, салкын дулкын йөгерде: ихатаны әйләндереп алган шәп-шәп каралты-куралар, аерата ни гомер инде сыер-тана мөгрәүләре, сарык бәэлдәүләре, ә үткән көздән бирле каз кыйгылдаулары, тавык кытаклаулары ишетелмәгән җылы абзарлар үтә дә шомлы булып күренде аңа төн караңгысында...

Өенә кергәч, шул көе — өстеннән ни билле тунын, башыннан ни йонлач бүреген салмаган көе — ян сәкегә килеп утырды. Аяк очында идәндә иске әрҗә, инде хәзер ярыйсы ук ныгыган һәм яшәргән әрҗә. Түр өйнең ишек пыяласы аша сөзелеп төшкән яктыда әрҗәнең бериш калае, тонык кына булса да ялтырагандай итә. Үрелеп әрҗәнең капкачын ачып карады, тагын ябып куйды. Аннары, тирән-тирән сулап алгалагач, әрҗәгә төбәлгән хәлдә, әмма күз алдында хатыны Мәрзияне тотып, акрын гына ирен кыймылдатты:

— Бөтенесен дә сыйдыра алыр микән, карчык, бу әрҗәң? Ә бит, һай, күп алар, иң кадерле һәм иң якты истәлекләр! Күпмесе кала әле! Әнә түшәмдә сиртмә бәҗрасы — балаларның һәркайсын бишектә тирбәлдереп

тоткан затлы тимер, ә менә монда олы мич — нихәтле тәмле-томлы ризык пешермәдең син аңарда! Бары, бары да кала! Әле сагынырсың! Сагындырыр арт бакчадагы миләш белән куралар да, капка төбендәге чирәм дә, күрше-күлән белән кичләрен гәп корып утыруларың да... Ә картың, ә үзем? Язын беренче ярган буразнадан килгән туфрак исен яисә серкә очырганда тирбәлгән арыш-бодай дулкыннарын әйтмим дә, хәтта авылдашларга акыл өйрәтәм дип, ызгышуларымны да искә төшергән саен зар-интизар булырмындыр... Үткән юлларны, узган гомерне бер әрҗәгә генә сыйдырып буламыни? Тормышны яңартабыз дип, купкандай кыланабыз. Ә бит аякны туган туфрактан суырып аласы бар әле. Суырып аласы бар...

8

Юлга канатланып-очынып чыккан Рәмиләне, туган авылына кайтып төшсә, бик күңелсез яңалык көтә икән: әле җәй башында ук, аны да чиксез кызыктырып һәм иләсләндереп, зур төзелешкә китеп барган чая-үткен сабакташы Шәмси Әминәсе тулай торакта яшәп яткан җирендә кеше әйтеп ышанмаслык тәртипсезлек эшләгән, ди, аның яман хәбәрен ишетүгә, ни юаш, ни сабыр әтисе, йөрәгенә чыдый алмыйча, Чаллыга барган һәм кызын эшеннән дә, торагыннан да чыгартып, үз өенә алып кайткан, ди.

Бу ямьсез хәлне Рәмиләгә әнисе Рәсүлә, өстәлгә табын әзерләргә керешкәч, гадәтенә сеңгәнне дә онытып, ягъни кызының хәл-әхвәлләрен юньләп белешеп тә тормастан, бердән тезеп салды.

— Мактарлыгы булса, мактарлар ие, ә җаман хәбәр ябалак канатларына атланып кайта да, бөтен авылны бетереп, кычкырып җөри ул, олан...

Рәмиләнең йөрәге жу итеп куйган, күз аллары караңгыланып киткән иде. Аның: «Юк, юк, булмагандыр андый хәл!» — дип кычкырып җибәрәсе килде, ләкин кычкыра алмады, тавышы сынып, әнисенә пышылдап кына төбәлде:

— Ә ни кылган соң Әминә ул кадәр?

Ләкин әнисе кызының агарынып киткән йөзенә дә, сынып-сытылып чыккан тавышына да игътибар итмәстән, һаман да шул зәһәрле рәвештә үзенекен дәвам иттерде:

— Иреккә ирештем дигәч тә, үз-үзеңне белми кыйланып җөрсәң, шулай булмый ни!

— Ни булган, ни кылган, дим!

— Мин алар белән тулай торакта бергә иемме әллә? Ике җегетне болар ике бүлмәдәш кыз ничектер балкон ашамы, әллә вахтерларына сиздермиенчә генә бүтәнчәме, эчкәрегә үткәргәннәр дә бүлмәләрендә мыштым гына мәҗлес корып җатканнар. Ул ике җегетне кундырып ук калдырмакчы булганнар, ахры, әмма берсе исергән баштан төн уртасы авышканда акырып җырлап җибәргән бугай — шундук өсләренә басканнар... Кызлар торагында андый хәл өчен баштан сыйпамый торганнардыр, үзең миннән шәбрәк тә белә торгансыңдыр әле?

— Белмичә...

— Беренче кыланмышлары гына булмаган, ахрысы: җыелыш җыеп, бик хәтәр тузынып, тулай торакларыннан сөрергә үк җыенганнар, ди, әмма әтисе, вакытында барып җитеп, бу ахыргы хурлыгыннан җолып калырга өлгергән...

Авылда олы төзелешкә китеп эшләүче яшьләр әллә нихәтле — кырык-илледән дә ким түгелдер. Һәммәсе җимерттереп эшли, һич берсенең әлегәчә ямьсезлек кылганы юк, моңарчы бу җәһәттән шылт иткән аваз да ишетелгәне булмады, инде макталып телгә кергән кызлар-егетләр дә аз түгел. Әмма макталганның даны нибары үзе һәм иң якын кешеләре өчен генә кебек, ә менә яманлык кылганның хурлыгы бик күпләргә зур күләгә булып төшә, син дә керсез күңелең, якты омтылышларың белән аның яманатын үз иңнәреңдә күтәреп йөртергә тиешлесең... Дөньяның нинди гаделсезлеге бу?

— Инде әнәтерә: ни укуда түгел хәзер, ни эштә... Урамга чыгып йөз күрсәтерлеге дә калмаган, өендә томаланып ята, ди. Ә сабакташ кызлары исә, берниндн хәсрәт-кайгы белмиенчә, җөреп җаталар мәктәпләренә...

Рәмиләнең әлгәрегә кайтуларында да әнисе, Чаллы төзелешеннән күңелсезрәк, яманрак хәбәрләр ишетеп, аларны чәйнәштергән чагында, үзенең сүзен әнә шулай: «Анда интегепләр эшләп тә, укып та җәфаланганчы, кайта гына күр үзеңнең иркен өеңә, үзеңнең җәшьлек рәхәтлекләреңә!» — дигән рәвештәрәк, ап-ачык үгет-чакыру белән төгәлли, җәен үзенең йомшаклык кылып, бердәнбер кызын зилзилә җилләре уйнаган мәхшәрле тарафка очыртып җибәрүгә риза булуларына кат-кат үкенә иде. Ә хәзер, Шәмси Әминәсе китереп чыгарган хәлдән соң, ул инде мәктәп директоры белән дә барып

сөйләшкән, теге исә Рәмиләне мәктәпкә кире алырга ике куллап риза булган икән.

— Укуында азрак аерма туган икән, анысын гына тиз бетерер, башлы кыз ул, ди, аның каравы, русчасы шомара төшкәндер — монысы аерата әйбәт, ди...

Әнисенең тавышында хәзер ачы зәһәрлек сизелми иде инде.

— Кичкедә дә минем уку начар бармый, соңгы вакытларда икеле алганым да юк. Эшем дә әйбәт... хәйран шәп безнең бригада!

— Кичке уку... икеләләр алмау... әйбәт, хәйран бригада, имеш! — Әнисенең тавышы капыл гына янә кырысланып китте.— Ә тормышның бүтән җаклары, ә? Ахыры җитеп, үзең дә чоңгылга бер төшеп киткәнеңне күтәсеңме? Әтиең җә абыйларың сине дә җилтерәтеп апкайтсынмы?

Карыны шактый ачыгып кайткан булса да, Рәмиләнең ризык кабарлыгы калмаган иде. Ул бер-ике чынаяк кайнар чәй генә эчеп куйды. Әнисе кузгаткан юнәлештәге ары таба сүзне һич кенә дә куертасы килми иде аның. Куертасылары әле алда булыр — һич шикләнмәскә мөмкин... Борын мышкылдатып, бермәл тын гына утыргач, кыз кыюсыз гына:

— Әти кайда соң? — дип сорап куйды.— Рәмзи абый да күренми...

— Әтиең Яхъя Таипычка кич утырмага дип менеп киткән ие... Ә Рәмзи абыеңмы? Соң ул сине алырга дип мотоциклда Чаллыга очкан иде ләбаса, әле әйтмәдеммени? Юлда аймыл булгансыз, күрәмсең... Ул тегендә Айдаш абыең белән Вәсим абыеңнарга да сугылмыйча калмас, бары бер булып кайтып төшәрләр әле.

Менә шул чагында гына ана кешенең, җыен күңелсез һәм шыксыз сүз-хәбәрләр аркасында миңгерәүләнеп торган зиһене, ниһаять, ачылып китте сыман. Йөзенә мөлаемрак, җылырак нур кайтты, тавышы да йомшаруга таба үзгәрде:

— Теге атнаны да мунчаны кыздырып көткән иек жугыйсә... Арадан ник берегез кайтып төшсен!

— Соң, ел азагы бит, тегендә яман да куыралар, аңларга тиешсең, әни,— диде Рәмилә, саран гына елмаеп.

— Ә бүген, ичмаса, берегез булса да өйдә инде!.. Бар әле, кызым, бар, иренмичә генә эшкә тотын әле. Мин инде, алай-болай кайтып төшсәләр, кер уарга-нитәргә туры килмәгәе дип, мунча казанында суны җылытып куйган иием. Син инде теге миченә дә ут тамызып җи-

бәр, утыны инде тутырылган да... Аннары, бар булган савытлар, бидоннар туларлык иттереп су ташып куярсың. Сырхаулы әниеңә барына да җитешергә бер генә дә җиңел түгел шул. Их, үз өеңдә, үз җаннарымда җәшәгән көйгә генә укып җатсаң, җорт эшләрендә кул арасына кергәләр иең, ичмаса!

Рәмилә шундук, бик теләп, бик рәхәтләнеп урыныннан купты: монда әнисе белән яман хәлләрне әвәләштереп, сүз чәйнәп һәм бәхәс куертып утырудан ул тәмам туйган иде. Әнисенең искерәк киемнәрен киеп алды да йортка саф һавага чыкты. Мунча миченең утыны тутырылганына, туз яндырып, ут салды, кисәүләре инде пыскып кына яткан казан астындагысына да, утын өстәп, ялкын тергезде. Аннары иңнәренә көянтә-чиләк элде.

Тышта шактый ук караңгы иде, җилләп-буранлап тора, әмма, бәхетләренә, су колонкасы аларның тыкрык чаты башында гына. Эш белән мавыкканда, ичмаса, күңеле бераз тынычлана төшеп куяр кебек иде. Ләкин, юк, күз алдыннан һаман да сабакташы Әминә китмәде...

Мәктәптә чагында ук шаянрак, егет-җилкенчәккә сырпаланучанрак иде шул. Әмма кайчагында, кинәт кенә айнып киткәндәй, шуклану-сырпалануларын кырт кына кисеп, ара да саклый белә иде. Тегендә, КамГЭС поселогында аларның тулай тораклары берсенең бер башта, икенчесенең икенче очта иде, шул сәбәпле анда очрашканнары булмады диярлек. Әминә дә, Рәмилә шикелле үк, кичке мәктәпкә укырга кергән, әмма озакламый, аның авырлыгына чыдый алмыйча, ташлаган иде. Авылга да ул Рәмиләгә караганда сирәгрәк кайта, менә шул чагында гына алар, йә юлда попутный көткәндә, яисә кичен авыл клубында күрешеп куйгалар иде. Соңгысында моннан бер ай чамасы элегрәк, Әминә гадәтенчә шукланып-көләчләнеп, хәтта артыгын кыландырып һәм, билгеле, күбрәге егет-җилкенчәк хакында сөйләнеп, авызыннан саесканнар очырткан иде. Аңардан берни сизәрлек тә түгел, бу кызый озакламый зур бәлагә тарыр дип уйларлык та түгел иде... Бәлкем, ул кадәр куркыныч, яман төсләргә манчып сөйләүләрнең ышандырырлык җирлеге юктыр да, барысы да, ачы оеткылар куша-куша, чамасыз күпертү генәдер? Менә боларны тәгаенләми торып, Рәмиләнең җаны тынычлана алмастыр, ахры...

Әйе, мунчага су гына ташып бетерсен дә — аның миче яна торыр, ташы кыза торыр — ә ул, өстен-башын

алыштырып һәм, әлбәттә, әнисеннән рөхсәт сорап, тиз арада гына клубка барып килер. Анда инде танцы башланган булыр, Рәмилә аңа катнашып китәрме-юкмы, әмма ул анда Әминәнең чын әхвәлләрен төгәлрәк һәм эчкәртенрәк белгән берәр кемсәне очратмый калмастыр әле...

Ока кызы Юлия, авылдашы Әминә шикеллеләр тегендә уппап бер, юк, йөздән бер генәдер, бәлкем, әмма син монда бер гөнаһсыз башың белән әнә шундыйлар куптарган ачы тузанны йотып йөр инде менә, күрәсең булса. Аны хәтта ачы җилле җәяүле буран да таратып, себереп ташлый алмый, киресенчә, күңелдәге ачысын тик көчәйтә генә сыман...

Клубка яшьләр әллә ни күп җыелмаган иде. Ел азагы икәнлеге үзен монда да нык сиздерә иде.

Ләкин, сабыр, сабыр, Яңа елга инде бөтенләй күп калмады, ул чагында шушы киң фойе хәтәр купшы бизәлгән булыр, шыгрым тулып, шаулап-гөрләп торыр...

Җыелганнарның күбрәге, әлбәттә, егет-җилкенчәк, әмма арада кызлар да — мондагылары да, тегеннән кайтып төшкәннәре дә күренгәли иде.

Музыка мул булып һәм төрләләнеп яңгырый: әле радиоланы борып җибәрәләр, әле магнитофонны әйләндерергә тотыналар.

Бер кырыйга мыштым гына баскан килеш, үзенчә күзәткән булып тик тору уңайсыз иде, Рәмилә моңа күнекмәгән дә иде, ул шундук биюгә катнашып китте. Аның өстендә «мәктәп пальтосы», башында кызгылт-көрән берет, аякларында исә шәп күннән тегелгән, каты үкчәле модный сапожкилар. Ритмны тиз тапты... Клубта ярыйсы ук салкын, күбесе пальтодан, әмма арада инде кызып өлгергән һәм өс киемнәрен салып атканнар да бар иде.

Менә Рәмилә каршысына басып, чандыр гәүдәле, кылычрак борынлы бер егет тез бөккәләргә, бил сындыргаларга керешге. Рәмиләнең аны моңарчы күргәне юк иде, егет ара-тирә авызын киң җәеп, елмаеп җибәрә, нидер әйтеп тә куя, ләкин ул әйткәннәр кызның аңына барып җитми иде. «Калмаштан»,— диде, ахрысы. Армиядә хезмәт итеп тә кайтуына бәхетен «түгәрәкли» алмаганнардан шикелле. Хәзер әнә, болар клубына килгән дә, тырыша егет, бик тырыша! Хәер, мондый хәлләргә Рәмилә инде күнегеп, иләшеп бетә язган иде. Ул, гамьсез бер кыяфәт сакларга тырышып һәм карашын

әле тегеләйгә, әле болайга юнәлдереп, залны күзәтүен белә иде.

Ниһаять, ишектән управляющий Гарапша кызы Фәрханә килеп керде. Рәмиләнең әүвәлге сабакташы. Яшел пальтодан, башына шакмаклы шарф ураган. Тукталды. Ян-якларына карангалап алды. Укытучылардан шүрли торгандыр әле...

Фәрханә болай ярыйсы гына кыз кебек. Укуы да әйбәт кенә, әмма астыртынрак, яклырак холыклы, укытучылар алдында юхаланучан — менә шул ягы күпләрнең җен ачуын чыгара иде. Ярый, кадалмый анысы, Фәрханә Әминәләр күршесендә генә яши, тегеләрнең хәлен тикшерми-белми ятмагандыр әле.

Музыка тынуга, Рәмилә Фәрханә янына килде һәм, әллә ни таралмыйча гына хәл-әхвәл белешеп алгач, ыекламый-мыекламый Әминә турында сорашырга керешге. Әйе, булган шул, ди, тулай торакларында әкәмәт ямьсезлекне чынлап та кылганнар, ди, инде хәзер авылда кеше күзенә күренерлеге калмагач, бүген иртән әнисе аны Зәйдә яшәп яткан олы кызы белән киявенә алып китте, ди. Барын да белә Фәрханә.

Элегрәк ул Рәмилә, Әминә кебекләрнең тәвәккәллегенә кызыгыр, алардан көнләшеп тә куйгалар иде, ә хәзер исә үзенең өстенлеген ярыйсы ук вәкарь аша, хәтта мәсхәрә белән аермачык сиздереп сөйләнде.

— Унсигезне тутырып килгәндә, әнисе, сабый бала кебек, җитәкләп йөртсен әле... Кызык бит, иеме?

— Ә ние кызык аның?

— Соң ни... анда Чаллы күгендә ач тилгәннәр өзлексез баш өстендә очып йөри, кызларны, бәбкә-чеби урынына куймыйча, тибеп-чокып кына тора бугай... Әминәне «төпсез чуманга утырып» калмагандыр дисеңме? Әнисе аны Зәйгә тиккә генә алып киткәнме әллә? Котылырга итсә, анда бит этем дә сизми калачак...

Атасы Гарапша ни, кызы Фәрханә ни — боларга дөньяны тагын да болгатыбрак, сасытыбрак җибәрергә генә булсын... Рәмилә үзе дә түзмәде, шулай ук ачы мыскыл белән кысык иреннәре аша сытып чыгарды:

— Көтеп карыйк әле: син үзең, саескан, «төпсез чуманга утырып» калмагаең...

Аннары, кырт-кырт баскалап, бер читкә китеп барды. Аңа клубтан бөтенләй чыгып китәргә ярамый иде әле. Шуны гына белешергә килгән икән, бусының да канына тоз салып җибәрдем, дип куанмасын әле, ичмаса, шул Гарапша токымы!

Юк, күңеленә җиңеллек килмәде, җан тырналулары кимемәде, киресенчә, көчәйде генә кебек...

Янә музыка яңгырап, бию башлануга, Рәмилә каршысында кабаттан Калмаш егете пәйда булды. Ул инде хәзер тагын да дәртләнебрәк, тагын да тырышыбрак кыйландырырга тотынды. Рәмилә хәтта ихтыярсыздан көлемсерәп куйды. Егет исә җавапка бар кыяфәте белән балкып елмайды... Тукта, ни дип, авызына ачуташ капкандай, чырай җимереп караңгылыкка бирешергә ди? Нигә бер иркенәеп-рәхәтләнеп, «җенләнеп» алмаска ди? Ичмаса, иңнәреннән тузаннар коелыр, рухы ачылып китәр! Ул арада гына мунчаларына ут капмас әле, кирәксә, энисе үзе дә чыгып карый ала, ә ул монда... Әйе, һавадагы сөрем, күңелдәге әчелек таралсын, ә Фәрхәнә кебекләрнең йөрәге янсын!.. Тырыш әйдә, егет, кыйландыр, егет! Әнә шулай, әнә шулай! Җителгән бәхетең бүген булмаса, иртәгә түгәрәкләнер әле! Ахыр заман җитмәгән, галәм сүнмәгән, дөньяда олы һәм саф хисләр бар, дөньяда чын мәхәббәт бар! Үз ярым түгелсең, алай да... әнә шул матурлыкны раслап, бер ут булып яныйк, бер гөл булып балкыйк әле, егеткәй!

— Рәмилә апа!.. Алмапа, дим!

Рәмилә инде тәмам кызып киткән, инде чын-чынлап ут булып кабыныр чиккә җиткән, ул инде өстендәге пальтосын, башындагы беретын салып атарга ниятли башлаган иде. Кулбашына кат-кат орынудан, ул, аңына килеп, борылып карады. Борылып караса, янәшәдә туганнан туган энесе Сабир басып тора. Бүрек колакчыннары җилбәгәй, кашлары җимерек...

— Ни булды, Сабир?

— Чыгыйк әле...

Бу кичне, ниһаять, бәхетен түгәрәкләүгә күңелендә өмет чаткылары кабызган һәм шул сәбәпле үтә тырышып, үтә дәртләнеп биегән Калмаш егете, сынын турайтты да торараштай катып калды, күзләрен челт-челт йомгалады: күр инде, әле мыек та типмәгән бер нәрсәкәй аның балкып, күтәрелеп килгән алтын кояшын, бүрегенә томалагандай иттереп кенә, алып чыгып китсен әле!..

— Ни бар, ник дәштең, Сабир?

— Сине алырга мендем мин. Өйдәгеләр кушты. «Ныгытып бер сөйләшәсе бар, кайтсын әле!» — диделәр... Аннан инде, бер сөйләшеп алгач, клубка кабаттан менсәң дә булырдыр... Әйдә, утырасыңмы?

Урамда, клуб баскычы төбендә, сүндерелмәгән көеп-

чә, тоныК кына гүелдәп, мотоцикл тора иде. Габделбәр мотоциклы — «Урал» лабаса!

— Нәрсә, Габделбәр дә шундамыни?

— Шунда... Рәмзи абый белән Вәсим абый да кайтып төшкән. Шулар җибәрде дә инде... Ә Габделбәр абый иң башта безгә сугылды, анда Туры бабай белән бергәләп чәй эчкәч кенә, икәүләп сезгә килдек... Мотоцикл ачкычын бу юлы үзем сорарга да өлгермәдем: «Барыбер тынгылык бирмәссең, мә, тагын бер кинән инде алайса!» — дип, кулыма тоттырды.

Габделбәр... Ул хәзер инде Чаллыда яши, әмма әледән-әле алар авылына килеп төшкәли икән. Сизенепбелеп килгәнме, әллә болай очраклы рәвештә генәме?.. Димәк, ныгытып сөйләшмәкчеләр... Бүген үк! Аз гына сабыр итәргә, чак кына кичектерергә ярамады микәнни?

— Нәрсә, алмапа, утырмыйсыңмыни?

— Утырмыйм, рәхмәт, энем!

Сабир кабат ялынып тормады, мотоциклын бик яман иттереп гүелдәтеп алды да, җәһәт кенә кубып, ыжгырттырып, урам белән түбән таба төшеп тә китте. Ачы җил димәс, кызлар ташып кинәнер әле бу кичне дә...

Рәмиләнең алай ашыгыр җире юк иде. Салкын җил үтеп, тирләгән аркасын шул арада чиркандыра да башлады. Таралган зиһенен ничек итеп җыеп бетерәсе дә ничек иттереп сабырлык һәм түземлек саклый беләсе? Адымнары акрынайганнан-акрыная барды...

Әтисе әле кайтып кермәгән икән.

— Тегендә аулак өендә Яхъя Таипыч бушанасын бушатып бетерә алмый торгандыр, ахрысы,— дип аңлатты аңа әнисе.

— Айдаш абый да күренми.

Монысына түрдә, телевизор төбендәрәк утырган Вәсим, калын кашларын җимереп һәм авыр көрсенү аша җавап кайтарды:

— Ел азагы лабаса — үзең дә бик әйбәт беләсең... Туфракның туңы тирәнгә киткәнче, актарасын актарып, каезламый-өйми булмый шул, сеңелкәш. Бәлкем, төн урталарында кайтып төшәр әле. Аннан иртүк кузгаласы булыр. Минем үземә дә иртүк торып китәсе. Ял дип исәпләшеп торыр чакмыни?

«Эһе, әнә ни өчен монда да кызуларга кайткансың икән. Уптым әйләндереп салырга дигәндә, сиңа бир инде...» — дип уйлап куйды Рәмилә.

— Ә нишләп Туры бабайны дәшеп алмадыгыз?

— Олы кешенеме? Тик торганда аны да борчыргамы? Юк, сеңелкәш, кирәкле эшне бик әйбәтләп, тиешенчә иттереп без монда үзебез генә дә хәл итә белербез!

— Соң, Туры бабайның кызының кызы ич мин, нәсел-нәсәбендә бердәнбере...— диде Рәмилә, килешергә теләмичә.— Әмма, ул монда килеп, минем язмышны хәл итәргә тотынсагыз, минем файдага түгел, сезнең файдага касрачак ла... Шулай булгач, ник дәшмәскә ди?

— Тукта, ни лыгырдыйсың син? — дип, капыл кабынып, сүзгә кушылып китте энисе.— Синең файда — безнең файда, безнең файда — синең файдаң түгелмени? Һай, кызым!

— Алай микән?

Әле алгы бүлмәгә чыга кыз, әле түр якка үтә, әлеге сүзләрен дә ул энә шулай кераеле-чыгалы йөргәндә ычкындыргалый иде. Аның бит урталары уттай яна, гәүдәсе клубтагыдан болайрак кайнарланып киткән иде. Менә өстендәге саргылт-яшел кофтасын салып, аны урындык артына элде, инде хәзер миләүшә төсендәге күлмәктән генә калды. Кара чәч өемен төзәткәндәй иттергәләде, әмма болай да күперенке чәче аның саен таралып кына китә иде. Шул рәвешле йөренгән, кылангырган арада, ул бер читтә кәнәфигә сенеп утырган Габделбәр ягына күз атып алгалый иде. Габделбәр терсәкләрен кәнәфи култыксаларына куйган, аның өстендә көрән төстәге һәйбәт йон костюм, ак күлмәк, көрәнле-кызыллы матур гына галстук. Ул чип-чиста иттереп кырынган, чәче бераз кабарып тора. Бары да һәйбәт, бары да килешле!.. Әмма егет, кызның күз карашын эләктерүгә, уңайсызланып китә, аның да киң маңгае, яңаклары, эчке хәләтен аермачык сиздереп, ялкынланып янып чыккан иде...

Габделбәр бүген дә Рәмилә яшәгән тулай тораккa сугылып чыкты. Дөрес, моңарчы да анда кагылып үткәләгәне булмады түгел, әмма кызны һич туры китерә алганы гына юк. Бүген исә вахтер хатын аңа кызның үз туган авылына кайтып киткәнлеген төп-төгәл иттереп, ышандырып әйтте, һәм ул күңеле төшкән нечкәбилне үз өендә очратасына ышанып һәм ашкынып килде. Тик егет бу кичне Рәмилә белән туганнары арасында бик тә мөһим, кичектергесез сөйләшү буласын гына белмәгән иде. Монысын аңа, күрешеп беркадәр утыргач, дусы Рәмзи чиште. Әлбәттә, Рәмилә киредән үз авылына кайтып, шушында урнашып калса һәм үз мәктәбенә укырга йөрсә, Габделбәр өчен күк капусы яртылаш ачы-

лып киткән кебек була да бит... Анда инде, туасы һәм балкыйсы бәхетен тизрәк тудырыр, ныграк балкытыр өчен, бөтен уңайлыклар, бар киңлекләр аңа атап яратылган ич!.. Менә моны аңлау, шуңа өметләнү егетне эчтән генә чамасыз куандыра, әмма шул ук чакны шушы куанычлы тойгыны тышка чыгармаска тырышу, моның өстенә, гаилә эчендәге үтә дә әһәмиятле, үтә дә үз булган эшне уртага куеп сөйләшкәндә аның монда катнашырга һич хакы юклыгын белү аны шактый ук кыен һәм четерекле хәлгә куя иде. Рәмиләнең ара-тирә усал иттереп, яндырып карап куюлары исә аны бөтенләй әллә нишләтеп җибәрә иде. Ахырда түзмәде;

— Ярый, хәлләрегезне белдем, әйбәт кенә ятасыз икән. Ара якын түгел, кайтыр вакыт җитте кебек инде,— дип, утырган урыныннан тора башлады.

Әмма шулчакны, моңа кадәр диван почмагына посып, каш-күз җимеребрәк мыштым гына утырган Рәмзи дә капыл гына кузгалып куйды:

— Уйлама да! Әле өлгерерсең! Менә хәзер тамак ялгап алырбыз. Аннары, без сөйләшкәндә, син чит кешемени? Алай бик яшерен сүзебез дә булмаячак, курыкма!

— Әйе, утыруыңны бел! — дип куәт өстәп куйды Вәсим дә.— Әнә кабарга-йотарга бар, безнең белән бергә булганда бер дә харамга китмәс! Аннары, мин сөйләгәнне, ичмаса, җүпләп-ныгытып куйгаларсың. Чаллыдагы хәлләрне син дә миннән ким белмисең ич.

Моңа Рәмилә ак та димәде, кара да димәде, янә бер тапкыр — монысында инде ике абыйсына берьюлы — усал һәм яндыргыч караш ташлап алды. Шул карашы белән үк бер уңайдан өстәлне дә иңләп үтте: анда кабарга тегесе-бусы куелган, инде рюмкалар да әзер, уртада исә «акбашлы» кукраеп утыра иде. Башта ук күзенә чалынып та күңеле белән игътибар итмәде микәнни? Әллә соңгы вакытларда, Чаллыдан абыйсы Вәсим кайткан саен, бу күренеш инде гадәткә керә барганлыктан, аңа ис җибәрмәгәнгәме?

Рәмилә үрелеп шешәне ять кенә кулына алды да:

— Минем язмышны хәл иткәндә, ичмаса, бу катнашмасын! — дип, аны шкафка илтеп куйды.

— Кагылма! Кире китереп куй урынына! — дип аваз салды Вәсим, ярсый язып.— Синең язылмаган ахмак язмышың өчен җир тишегеннән табып алдыкмыни без аны? Йөрәк янганнарын басарга дип табылган дәва бит ул!

— Синең йөрәкнең сүреләсе булмастыр да... бу дәваңнан, киресенчә, тагын да ныграк ярсып кына китәр! Ә минем... ә минем... чәй эчеп кенә сөйләшәсем килә! Электр чәйнегеннән дә түгел... самовардан! Самовар моңын тыңлый-тыңлый!

— Моң тыңлый-тыңлый... Син әйт әле менә иң башта: тегендә Чаллыда алга таба ни майтарып ятмакчы буласың, кызый?

Рәмзи кискен бер хәрәкәт ясап, кулы белән абыйсының авызын томаларга теләгәндәй иттерде:

— Соңрак, абый, соңрак.. Сабыр ит бу хакта!

Ул сөйләшәсе сүзнең менә болай бик текә һәм тупас төстә башланып китүен теләми иде.

Әниләре дә мич янындагы урындыкта кулларын тез капкачлары өстенә куеп утырган җиреннән купты:

— Дөрестән дә, кызым... Байтактан инде самовар куеп, чәйләр эчкән җук. Бер тәмләп-баллап кына эчеп алыйк әле, алайсам. Самовар чәе ул күңелләрне җомшартып җибәрүчән. Ул кайнап чыккан арада, бәлкем, әтиегез дә кайтып төшәр.

Тупаслык һәм усаллык белән юньгә ирешә алмаячакларын ана күңеле бик әйбәт сизә иде. Җәен кырысрак булырга тырышып карадылар, җиңә алдылармы? Үзләре үк чигенде, хәтта җебеп калды ич...

Әнисе белән сеңелесе алгы өйгә чыгып китүгә, Вәсим, ачык мәсхәрә сиздереп, авызын ямьшәйтте:

— Күр кыланмышларын, күр түш кабартуларын! Хан кызымыни!.. Ярый-ярый, азрак сабыр итик: әле сыгылу түгел, сынып та куячаксың, кызый!

Әнисе, самоварга су салган арада, Рәмилә эленгеч янына килде дә өстенә, бая колонкадан су ташыгандагы шикелле, иске плюш жикетны киеп алды, башына иске мамык шәлне япты.

— Син кая, кызым?

— Мунчага утлы күмер алырга... Монда чыра белән азапланганчы...

— Ие-ие, бик әйбәт булыр, кызым. Анда утлы күмер гөждер әле. Аннары мунчаны томалап та куярбыз.

Рәмилә кулына озын аяклы, юан бүксәле тимер савытны тотып чыгып барган чагында, әнисе, чүмеч белән чапчактан су алган җиреннән тукталып, кызы артыннан карап калды. Кызының клубтан кайтып кергәч тә тырт-пырт йөрүе, сырт кабартулары аңа һич ошамаган, тик ачыну хисе, шик-шөбһә генә кузгаткан иде, инде эш самоварга килеп төртелгәч, монысы аңа кызының

йомшаруга, күнүгә таба авыша баруына аермачык ишарә булып күренде — бу исә ана кешенең күңелендә җылы һәм өметле тойгыларны кузгатып җибәрде.

Җиз самоварны мич янына үз урынына күчереп куйгач, Рәсүлә ян сәкегә утырды да кулларын тез өстендә кушырган көе, кызын көтә калды. Ләкин теге тиз генә әйләнеп кайта белмәде. Ахырда, көтеп тә җиткерә алмагач, Рәсүлә үзе дә китте.

Мунчага барып керсә, тимер савытка утлы күмер инде тутырып куелган, әмма мунча миченә янәдән утын өстәлеп, яндырып җибәрелгән иде. Рәмилә исә мич каршына бәләкәй эскәмиягә утырган да карашын ялкынга төбәгән. Үзе балавыз да сыга кебек...

— Һай кызым! Ни кыланмышларың бу? Инде томаларга дигәндә генә, ник тагын?

— Янсын...

Ана кеше тавышын кабаттан йомшартуга, хәтта бераз төчеләнүгә таба борды:

— Әллә ниме... иң башта үзең кермәкче буласыңмы?

— Минем кайчан беренче мунчага кергәнем бар? Иң азактан!..

— Җарый-җарый... Иң әүвәл абыйларың керер. Теге кунак җегет тә мунча җанлылардан, җыйнаулашып, чабынып чыгарлар. Тик үзеңнең генә менә төн урталарына калуларың... курыкмассыңмы, кызым?

— Мунча җеннәре үзебезнеке әле, ят итмәсләрдер...

— Һай кызым, әллә ниләр сөйләнәсең син... Җарый алайса, утыра бир, күз төпләреңне киптерә тор, самовар чыгуга, дәшеп алырмын.

Әнисе утлы күмер тутырылган тимер савытны күтәреп чыгып китте, ә Рәмилә, мичтә биешкән ялкын телләренә дымлы күзләрен төбәгән килеш, утырып калды.

Мунча ишеге шыгырдап китүгә, Рәмилә, шул арада самовары кайнап чыкты да микәнни, дип, эчке калтырану аша, башын күтәреп карады. Әмма ачылган ишектә әнисе түгел, туганнан туган энесе Сабир пәйда булды. Бөтен мунча эченә саф һава тутырып керде һәм шунда, бусага төбендә үк, идәнгә чүгеп утырды. Утыруына бүреген арткарак этеп куйды, пальто изүен чишеп җибәрде. Куллары күн перчаткада, уң кулының имән бармагында мотоцикл ачкычы селкенә.

— Нәрсә, бүген кызлар катать итмисеңмени, Сабир? — дип сорады Рәмилә, ирексездән елмаеп.

— Һе, бу ачы җилдәме? Кайсы чыксын ди?

— Ә сине монда... мине сакларга дип җибәрделәрме әллә?

Сабир утырган җирендә кымшангалап алды, көлеп куйды:

— Сакладылар ди... Менә син авылга кайтып, үз мәктәбеңә кередән йөри башласаң, ул чагында инде... Берәрсе синең данны сатарга ниятләп, авызын гына ачып карасын, миң аны!.. Йодрыклар нык минем, алмапа, курыкма!

— Ә син андый хәл булыр дип уйлыйсыңмы?

— Булса-булмаса... синең ирекккә балта чабалар бит инде. Әнә анда өйдә Вәсим абый: «Аны моннан ары Чаллыга җибәрмәскә кирәк, бүгеннән өйдә томалап калдырырга кирәк, калган хәтлесен тегендә үзем хәл итеп бетерермен»,— дип сөйләнеп утыра... Усал кизәнә ул, иеме?

Рәмиләнең бөтен гәүдәсен кымырҗытып, салкын дулкын йөгереп үтте. Димәк, инде хәл итеп тә куйганнар. Аңа ни кала инде? Еларга-сыктарга, бәргәләнергә-чәбәләнергә генәме?

Бермәл тын гына утыргач, Сабир кинәт бик тирән иттереп сулап куйды.

— Ә Женя абый Мында синең бу хәлләрне белми дә торгандыр, иеме? Ул кайда хәзер? Үзебездәме, әллә берәр чит илдәме?

— Чехословакиядә иде, ә хәзер Мәскәүдәдер инде. Иртәгә кайтып төшәргә тиеш ул. Телеграммасы бар.

— Иртәгә үк?!

Рәмилә ым какты. Аның бите инде кибә язган иде, әмма менә хәзер күз төпләренә янә яшь бәреп чыкты. Ләкин ул аларга бармак тидермәде, дым элпәсе аша мичтәге ялкынга төбәлеп утыруын белде.

— Ә синең аны күрәсең бик киләме инде?

— Килмичә...

Сабир да күз карашын мич ялкынына текәгән иде, менә ул янә тирән иттереп тын алды да кисәк ярып салды:

— Соң алайса... әйдә качабыз, алмапа!

Рәмилә башын ялт кына болай таба борды, дымлы күзләрен челт-челт йомгалады.

— Син уйнапмы, уйлапмы, энем?

— Уйнады ди... РИЗга тикле илтәм дә куям, ә теге ягын автобуста элдертерсең....

Кызның хәтта сулыш юллары кысылып куйды: аның

күк капусы ачылып китәргә җыена түгелме соң? Аның ачкычы да әнә энекәшенең имән бармагында гына ич...

— Женя абый белән күрешкәч-сөйләшкәч, калган хәтлесен, каласыңмы-кайтасыңмы, үзең карарсың инде анда, иеме?

— Ие, Сабир, ие...

Кабаланып өстен-башын капшалап чыкты: иске плюш жакет, иске мамык шәл, ярый әле аякларындагы модный сапожкиларын моңарчы салмыйча йөргән...

— Өйгә кереп өс алыштырсаң, сизәрләр, алмапа... Өйалдыгызда иске толып эленеп тора — үзем орынып үттем...

Рәмилә утырган җиреннән җәһәт кенә калкынды да туганнан туган энесен кайнарланып кочагына кысты:

— Их, Сабир, жаныкаем минем! Их, бәгырь кисәгем минем!

Бу минутта өйдәгеләр, әлбәттә, берни белми дә, сизми дә, алар дөньяда Сабир исемле, инде егет булырга җыенган малай яшәвен гомумән оныткан, исләренә төшерсә дә, аның үз күңеле, үз холкы-фигыле барлыгын, кирәк дигәндә, кыю һәм тәвәккәл була белүен бөтенләй уйламый да иде...

Әнә инде самовар кайнап 'та чыкты, менә инде ул өстәлгә табын күрке булып менеп тә утырды. Ләкин шул мәлне капка төбендә пытырт иттереп мотоцикл моторы кабынган тавыш колакларына чалынды.

Вәсим, урыныннан җәһәт кенә кубып һәм гәүдәсен янтайтып, түр тәрәзәгә күз салуына, шәрран ярып кычкырып җибәрде:

— Ах, нәгълэтләр! Толыпка төренеп утырганы Рәмилә!.. Сызмакчылар!

Урындык-конәфиләр читкә тибәрелде, ишекләр каерылып ачылды. Атылышып урамга чыктылар.

— Рәмиләү! Рәмиләү!..

Әнә анда, урам белән югарыга таба, инде шактый арада, җәяүле буран пәрдәсен фара яктысы ялаштырып бара, ул тарафтан тонык кына булып гөрелте ишетелә, әмма күз ачып йомган арада фара яктысы юкка чыкты, гөрелте дә ишетелмәс булды...

— Күр син мәртәтне! Күр хыянәтчене! — дип чамасыз авыртыну аша сукранды Габделбәр, ул хәтта кулындагы куян бүреген җиргә атып бәрде.

Ләкин хыянәт идеме соң бу? Чынлыкта гаделлек һәм тугрылык галәмәте иде түгелме?

Әмма иң ярсыганы Вәсим булды. Ул бер җиргә типте, бер изүләрен ертырга итенде:

— Күрәләтә адәм мәсхәрәсенә калдырып тайсыннар әле! Юк, болай калдыраммы соң! РИЗдан ары китә алмаслар... Кая, Рәмзи, синең «Ява»ң куәтлерәк тә, елдамрак та... куып җитеп, якаларыннан эләктерим әле!

— Үзең генәме? Юк, син анда куып җитеп, әллә ниләр кыландыруың бар... Мин үз «Ява»ма атланам, син үзеңнекенә атлан!

Алар, агалы-энеле, өсләренә җылы киемнәрен киеп алыр өчен апын-төпен өйгә кереп киттеләр. Монда капка төпләрендә әниләре Рәсүлә:

— Менә күрәселәрең булса, менә әкәмәтләр! — дип шыңгырдап, еламсырап торуында булды.

Ул арада җиргә саллы-саллы басып, йорт хуҗасы Хәнәфи кайтып җитте. Аңа хәлне аңлатырга тотындылар, әмма ул, тыңлап та бетермәстән, бу икене — хатыны Рәсүлә белән Вятка егете Габделбәрне:

— Тормагыз монда ахылдый-ухылдый! — дип, ихатага куып кертте.

Ишегалдында Вәсим белән Рәмзи мотоциклларына атланып өлгергән, анда галәмәт дөбер-шатыр купкан, алар кул изәп, капканы киңрәк ачып куярга кушалар иде. Ләкин этиләре капканы киңрәк ачу түгел, аны шапылдатып ябып куйды һәм болар янына килеп, мотоциклларын бер-бер артлы үз кулы белән сүндереп чыкты. Аннары:

— Акылыгыздамы сез? Явыз бәдбәхетләр урлап качканмы әллә сеңелегезне? — дип гүелдәде ул ачы тавыш белән.— Качсалар соң... Үз энекәшенә утырып лабаса! Сез нәрсә... Шәмси кызыныкы кебек, яманаты бөтен авылга таралсын, дисезме? Тыныгыз чыкмасын — шым булыгыз! Юллары таныш... киткән икән, кайта да белер!..

9

Инде берничә сәгатьләр Бигеш аэропорты ябылып тора. Тышта буран котыра.

Көндезен җил алай ук түгел иде. Самолетлар очкан, Мәскәү рейслары да булган. Әмма кичке эңгер куера башлаганда, җил капыл гына көчәеп китте. Тышта буранның инде җәяүлесе түгел, җир белән күкне тоташтырганы, тәмам котырмасы — җеннәр туе...

Тегендә, Мәскәү төбендәге аэропортта, очып китә

алмыйча Ул тилмерә торгандыр, монда исә, ничек көтеп җиткерергә белмичә, Рәмилә тилмерә...

Вокзал эче халык белән шыгрым тулган. Утыру түгел, иркенләбрәк басып торырга да җай юк. Кысылып-буталып йөргәндә тирләп-пешеп бетәсең. Урамга чыксаң, ачы җилдә тыннар буыла.

Рәмилә, тамагы кибүдән йөдәп, инде ике-өч тапкыр буфетта кара кофе эчеп чыкты. Сусыны беркадәр басылган кебек тоелса да, ул әчкелтем нәрсәдән саруы гына кайный башлады.

Аңа, әлбәттә, тулай торагына кайтып китсә дә булыр иде. Бүлмәдәшләре ипле холыклы, ятар ястыгы йомшактыр, җылыдыр — тынычта рәхәтләнеп йоклый бир. Сөйгәне Женя Мында да, мөгаен, сүз әйтмәс иде: моңарчы аны каршы алганы булмады, ул әле андыйга ияләшмәгән, тик өметләнә генә торгандыр, аның өметенә җавап йөзеннән килде бит менә, аэровокзалда җәфа чигеп йөри бит менә, аннары кире кайтып киткән тәкъдирендә дә, сине көтә-көтә хәлләрдән тайдым, дип акланырга җитди сәбәбе дә бар ич. Ләкин ул алай итсә, егете аңа үпкәләр, хәтта рәнҗеп куяр, тиктән шик-пошаманнарга чумып сызланыр, дип хафалана иде. Бу хафасы өстенә, шушы кичендә тулай торакта янә берәр көтелмәгән борчу-бимаза тумагае дип тә шүрли иде. Бигрәк тә анда абыйларының килеп керү ихтималы куркыта иде.

Кичә авылдан качу галәмәте дә әледән-әле исенә төшә аның. Юк, үкенү хисе кичерми, алай да җаны берөзлексез сызланып тора, тамак төбенә кунган ачы төерне ни йотып җибәрә алмый, ни үзе таралмый төер...

Тора-бара туганнары, бәлкем, аны аңларлар, зур дуамаллыгын кичерерләр, елга, язгы ташу вакыты үткәч, үз ярларына кайткан шикелле, аларның тормышы да әүвәлгечә тыныч кына, үз җайлары белән агуын дәвам иттерер. Ләкин кайчан булыр әле ул?

Ә хәзер исә Рәмиләгә сөйгән яры Женя Мынданы көтеп җиткерергә кирәк. Күктән кар урынына таш яуса да, иң әүвәл аның йөзен күрергә, аның сулышын тоярга тиешле! Ул аңа, әлбәттә, барын да сөйләп бирер, һәм егетенең аңа мөнәсәбәтен, аны ни дәрәҗәдә яратуын сүз сөрешеннән битәр күз карашыннан ук аңлап алыр...

Элегрәк аның чит милләт булуына басым ясарлар иде, соңгы вакытларда исә, йөри-йөри шомарып беткән эт каешыдыр әле, диебрәк шик белдерәләр. Бигрәк тә әнисе... Рәмилә бик аңлый: үз сукмагыннан җил-җил

атлаган мәлендә, чоңгылга төшеп, зур бәхетсезлеккә юлыкмагае бу кызый дип, туганнары аның өчен хафалана. Шул сәбәпле аны, кире авылга кайтарып, үз яннарында, үзләренең күз карашы астында тотасылары килә. Әмма бер киселгән ипи телеме кире ябышамы соң? Аннары, Рәмилә үзе сайлаган сукмагының нинди икәнен белмимени? Аңардан ул уңны-сулны абайламый атлап барамыни? Рәмиләнең ышанычлы таянычы, тайпылмас терәге булган Женя Мында турында да дөрес уйда түгелләр. Кеше үзенең чын асылда кем икәнен раслар өчен, күкрәген ярып һәм йөрәген учына алып күрсәтергә тиешме инде? Ә Рәмилә сөйгән ярына ышана, ихлас күңелдән, бик-бик ышана! Ансыз чын мәхәббәт була димени?

Төнге унберләр киткәндә, ниһаять, буран күзгә күренеп басыла төште. Бетон полосаларны өзлексез чистартып тордылармы, әллә буран аларга кар көртләрен өя алмаган идеме, озакламый самолетлар оча да башлады. Әле бу тарафтан, әле теге тарафтан төшеп кунганнары турында да игълан тавышлары яңгырарга тотынды. Аэропорт хәрәкәткә килде, ул бертуктаусыз гүләп тора иде инде.

Рәмилә җиңел сулап куйды. Ләкин ул иртәрәк куанган икән...

Инде менә төн урталары авышты. Аэропорттан соңгы рейс автобуслары да китеп бетте. Вокзал каршындагы мәйданда берничәләп такси «Волга»сы һәм шәхси автомобильләр генә торып калды. Әмма Мәскәү самолеты әле һаман очып төшә белмәде. Рәмилә хафага калды. «Әллә анда да бер-бер хәл микән?» дип, пошаманга чумып, справочныйдан барып белешмәкче генә иде, шул мәлне баш өстендәге куәтле динамиктан Мәскәү самолетының төшеп кунуын хәбәр иттеләр... А н ы ң рейсы!

Рәмиләнең йөрәге ашкынып тибәргә тотынды, ул ялт кына чыгару капкасы төбенә барып басты. Буран басыла төшсә дә, җил үзен әле һаман ярыйсы ук сиздерә иде. Рәмиләнең өстендә үзенеке кебек үк мутон якалы соры пальто, әмма ул аңарда капчык шикелле булып эленеп тора — бүлмәдәше Фаягөл гәүдәгә Рәмиләгә карый карсаграк булса да, аның иңбашлары, күкрәкләре күпкә тулырак шул. Башында исә ак куян мамыгыннан бәйләнгән яулык — бусы Светаныкы... Женя Мында, аны бу кыяфәттә күреп, мөгаен, аптыраушта калыр әле. Калса калыр, ярый әле, бүлмәдәш кызлары киендерә белде. Рәмиләнең бу минутта бите-йөзе кызып, янып

тора, ә гәүдәсе исә, бизгәк тоткандагы шикелле, тынгысыз калтыраудан туктала алмый иде...

Менә инде Мәскәү самолетында очып төшкән пассажирлар бер-бер артлы капкадан чыга да башлады. Рәмилә ике күзен дүрт иттереп әчкәрегә төбәлде һәм бер мизгелдән күреп тә алды: әнә ярымкараңгыда, урталыкта, җиргә нык-нык басып, Ул атлый. Башында козыреклы кара бүрек, өстендә тар якалы кыска пальто. Бер иңенә сумка аскан, икенче кулында дипломатка... Аның да әнә купшы мыек тирәсе җәелеп, ак тешләре елтырап китте. Капкадан чыгуына, кулындагы әйберләрен капыл җиргә төшерде дә, колачын киң җәеп, Рәмиләне кочып та алды.

— Ә мин инде сабыры җитмәгәндер, каршыларга килсә дә, инде кайтып киткәндер, дип уйлаган идем...

Рәмилә сүзен әйтә алмый, аның тыны кысылган иде.

— Ә мин... ә син...

— Күр, бөтен гәүдәң белән калтыранасың ла син... бик тундыңмы әллә?

— Нишләп?

Егет кызны аз гына читкә тайпылдыра төште, аннары янә күкрәгенә ныгытып кысты. Рәмилә аның болай итүен үзенчә юрап, үз хәлен аңлатып бирмәкче булды, әмма тавышы өзек-төтек булып чыкты:

— Син инде аптырыйсың бугай... мин бит... минеке түгел бу киемем... минекеләр тегендә калды... мин бит авылдан толып киеп качтым.

— Ни сөйлисең син?!

— Башыңа төшсә...

Кыз, егетнең күкрәгенә капланган көенчә, сулкылдап елап җибәрде.

— Менә сиңа әкәмәт... Ни сәбәптән, дим? — Кыз җавап кайтара алмагач, егет башын боргалап, әйләнә-тирәсенә күз салгалады.— Тормыйк монда, әйдә, кайтыйк алайса... Юлда сөйләрсең.

— Юлда? Чит кешеләр янындамы? Тукта, аз гына сабыр итик, ашыкмыйк әле.

Хәер, ашыгырга бик теләсәләр дә, берни барып чыкмаячак иде: такси «Волга»лары да, шәхси автомашиналар да инде китеп беткән — аэровокзал мәйданы бөтенләй бушап калган иде.

— Һе, менә сиңа кирәк булса... Ярый, монда бөрешеп торганчы, җылыга керик, ичмаса.

Вокзал эче инде бөтенләй диярлек бушап һәм иркенәеп калган иде. Иң кырыйдагы диванга бер-берсенә

сыенышып утырдылар. Женя Мында аклы-зәңгәрле сумкасыннан Рәмиләгә кызгылт йөзле алма алып тоттырды. Кыз аны керт-керт кимерергә кереште. Бераздан, алманың яртысын гына ашаудан да, ул үзенең тынычланып китүен тойды һәм сөйгән ярына соңгы вакытларда үз башыннан кичергәннәрне бәйнә-бәйнә сөйләргә тотынды. Женя Мында аны, һич бүлмичә, сабыр гына тыңлап утырды. Аның да йөз-кыяфәте үтә җитдиләнгән иде. Сүзенең ахырына таба Рәмилә Вятка егете Габделбәр турында да әйтмичә булдыра алмады. Аның исемен ишетүгә, Женяның маңгае җыерчыкланып, куп-шы мыегының бер чите сәер генә кыймылдап алды.

— Габ-дел-бәр... Мәнә көтмәгән идем! — Женя кинәт уч төбенә көлеп куйды.

— Ә син көлмә! Яман булса, йөзенә төкереп, тибәреп кенә атар идең, ә ул... Аның уенда гел яхшылык, гел изгелек кылу кебек... шул ягы белән ул куркыныч та! Әнә безнекеләрне үз ягына тәмам аударып куя язган бит!

— Яхшылык белән изгелек куркыныч, дисең, ә? Кызык шул! Ә без әллә начарлык кылырга җыенабызмы?

— Аннары ул астыртын да кебек... хәйләкәр дә сыман. Әллә нинди планнар корып йөрүе бар.

— Астыртын? Мәнә монысы шәп түгел... Ә хәйлә дигәнең... Мәнә монысы, бәлкем, безгә дә зыян итмәстер, ә? Уйлашмый ярамас, шулаймы, кара күзем?

Егет Рәмиләне янә күкрәгенә кысып алды һәм бармаклары белән аның башыннан, иңнәреннән сыйпаштырырга кереште. Рәмиләнең хәзер инде тамак төбендә бернинди төер дә юк, җаны да тап балавыздай эреп куйган, ул хәзер илаһи бер җиңеллек кичерә иде. Ә сөйгән егете исә аны сыйпавын-иркәләвен белде, аның йомшак бәрхет тавышында чиксез моң белән сүрелмәс дәрт бергә кушылган сыман иде:

— Без дә яманлыкка бармабыз, без дә гел яхшылык, гел изгелек кылу ягын карарбыз... дөрес бит?... Ие-ие... Мәнә инде болытлар таралып, күк йөзе аяза башлады, мәнә инде елмаеп, матур нурланып кояш та күренде, мәнә инде Рәмилә-каракүзнең үз йөзе дә...

Әйе, бу — У л, аның Женя Мындасы чын үзе иде...

10

Вахтерша хатын Рәмзине сынаулы караш белән баштанаяк сөзеп чыкты да, иңнәренә салган йон яулыкны төзәткәләп, ачы көлемсерәп куйды:

— Абыйсы, димсең, алайса? Һе, кызык, өченче көнне дә шулай бер майлы күзлесе килгән иде, ул да «абыйсы» дигән иде. Ни теләнсә дә, үткәзмәдем мин аны: үзенең документы да юк, үзе, җитмәсә, салмышрак та иде... Ә синең документың бармы соң?

Рәмзинең күцелен: «Вәсим тәки кергән икән, юньсез,— дигән уй көйдереп узды.— Ярый әле үткәрмәгәннәр...»

— Бар минем документ. Әмма мин аның бүлмәсенә үтәргә уйламыйм да. Аны монда чакырып төшерергә кирәк.

— Бер Рәмилә булмады инде. Теге атнада шулай менә синең кебек башына чүлмәк кигән бер егет тә кергән иде. Дөрес, «абыйсы» димәде, киңрәк йөзле, зуррак авызлы, үзе болай матур гына, йомшартып кына сөйләште...

«Анысы, әлбәттә, Габделбәр булгандыр...» — дип уйлап алды Рәмзи.

— Әмма ул мөлаем егетнең дә юлы уңмады: ул кичне чакырып төшерергә Рәмилә үзе юк иде... Инде хәзер, әнәтерә, аның кайдадыр югалып торган үз «мыекбае» да кайтып төшкән югыйсә: кабаттан күренгәли башлады. Чем-кара күзле, сумала кашлысы... кайсы халыктыр үзе...

Рәмзи кулындагы төргәкне өстәл читенә куйды, тавышын кырысландыра төште:

— Аның мыекбаенда да, халыгында да эшем юк, апа. Миңа шушы төенчекне генә тапшырасы да азрак сөйләшеп аласы... нибары шул!

— Алайсам... соң хәзер...

Вахтерша алтын балдаклы бармакларын өстәл читендә бисткәләргә тотынды. Әмма ул як-ягына карангалаганчы, Рәмзи артыннан йомры гына, таза бер кыз калкынып чыкты — ул аларның сүз куертуын тыңлап торган, күрәсең.

— Мин хәзер чакырам аны, абый! Кичке мәктәбенә әле китеп өлгермәгәндер, җыена гына торгандыр...— Йомры кыз шундук баскыч буйлап югарыга элдертә башлады.

— Мин аны тышкы якта көтәрмен. Анда минем мотоцикл тора, — дип кычкырып калды Рәмзи.

Тышта биек баганага эленгән лампа яктысында кар чебеннәре бөтерелгәли. Җил юк үзе, суыгы да алай бик куркытырлык түгел. Рәмзи кулындагы төенчекне селкештергәләп һәм җылы эчле күнитекләре белән шыгыр-

шагыр кар изештереп, мотоцикл тирәсендә әрле-бирле йөренергә тотынды.

Абыйсы Вәсим исенә төшеп, ул ирексездән тешләрен шыгырдатып куйды...

Рәмилә качкан кичне аларның бик яман ачуы чыккан, әмма барыннан да битәр Вәсим ярсыган иде. Сабир, алмапасын РИЗга тикле илтеп куйгач, мотоциклны да, аның әрҗәсенә төреп салынган толыпны да боларның капка төпләрендә калдырып, ятьрәк үз өенә тайган иде. Вәсим иң башта әнә шул малай актыгына каныкты, аны үз өенә барып бик әйбәтләп ярмакчы булып тузынды, әмма мондагылар аны анда җибәрмәде, иң әүвәл Рәмзи үзе абыйсының чыгар юлына киртә булып басты. Үз өендә Сабир, әлбәттә, Туры бабасына булган хәлне һич яшермичә сөйләп биргән. Бабасы аны, билгеле, астыртын, хәйләле эш кылганы өчен мактамагандыр, киресенчә, бик каты тиргәп ташлагандыр, әмма шул ук чакны үзенең сөекле оныгын икенче оныгыннан, инде тәмам озмавергә әверелгәненнән, рәнҗетергә юл куяр идеме соң?

Вәсим, Сабирга кул суза алмаячагын төшенгәч, Габделбәргә ябырылды. Дөрес, егетнең монысы да бу кичне боларда бернинди дә эш пешмәячәген аңлап алган һәм шул сәбәпле, озак та тормый мотоциклына атланып, үзенә бик таныш булган юл белән кайтып киткән иде. Үзе юк дип тормады, Вәсим Габделбәрне җебегәнлектә гаепләде:

— Азрак үткенрәк булып, кыюрак кыланса, бу кыска акыллы чәчлекәйләре, ичмаса, әллә ниткән мыекбай аркасында җенләнеп йөрмәс, киртә буе сикермәс иде,— диде һәм:— Алга таба араларына үземә чын-чынлап кысылмыйча булмас, ахрысы,— дип тә өстәде.

Бераз соңрак, кызу мунча кереп, анда ах-ух киләкилә чабынып чыгулары Вәсимне дә ярыйсы гына йомшартып җибәргән сыман иде. Әмма мунчадан соң, бер стакан зәмзәм суын бүленмичә, тоташтан эчеп, гәүдәсенә сеңдереп куйгач, Вәсим кабаттан зәһәрләнеп китте.

— Тулай торагына барып, бүлмәдәш кызлары алдында бисмилласын бик әйбәтләп укытам әле мин аның! Күрмәгәннәрен күрсен! — дип усал янарга керешге ул.

Әтисе-әнисе болай да акылларын җыя алмыйча иза чигә иде, аның шушылай яман янавына аларның өнкотлары бөтенләй югалды.

— Барып кына кара! Аның соңында шушында, үз

туган йортыңа атлап керәсе булмассың! — дип кисәтте әтиләре, каш-күз җимереп.

— Синең гөрбиянлегең, синең шушындый тупас кыланмышларыңнан өркеп качты да инде сеңелкәшең үз туган йортыннан,— дип кушылды аңа әниләре дә.— Син булмасаң, син кысылмасаң, иплэп кенә, җайлап кына, бәлкем, көндерә дә алыр иек үзен...

Рәмзи дә әтисе белән әнисе ягына авышкан иде.

— Буталып кына йөре! Анда инде тиреңне миннән алырсың! — дип кисәтеп һәм янап куйды ул да...

Ахырда Вәсим чигенде, болар әйткәнгә күнде сыман, ул хәтта сеңелесе яшәгән тулай торакта бөтенләй күренмәскә дип сүз дә биргән иде. Ләкин барыбер килгән бит, җитмәсә әле салган баштан килгән. Ярый әле, эчкәре үткәрмәгәннәр. Югыйсә, кыландырып күрсәтер иде ул фиргавен! Алай да, бертуган абыйсының кызмача хәлдә килүен Рәмиләгә җиткерми калмаганнардыр, бу исә аның күңел җәрәхәтен тагын да тирәнәйтеп җибәрмәгәндерме?

Ана күңеле күп нәрсәне алдан ук сизенә, күрәсең. Капка төпләрендә әлеге төенчекне мотоцикл багажнигына бәйләп маташкан чагында, әнисе Рәсүлә кайта-кайта әйтте аңа:

— Үпкә-рәнҗүләребезне аермачык сиздер, улым, әмма берүк илаһи уптым кубып бәреләсе итмә! Аңа да җиңел түгелдер... Сырт уңаена сыпыргалап, җомшаграк иттереп кенә... алай әйбәтрәк сеңүчән була бит.

Бу хәтлесен Рәмзи үзе дә бик белә, бик аңлый. Аның да күңелендәге ачуы эреп юкка чыкмаган, сеңдерәсен сеңдерә белер. Әмма шул ук чакны Рәмилә ят кыз түгел, аның сөекле сеңелесе лабаса!

Ләкин алар үз авылларында тегеләй дип, болай дип уфтанышып һәм башлар катырып яткан чакларында, монда янә бер күңелсез һәм ямьсез вакыйга булып алган икән. Шулай, чүп өстенә чүмәлә өелүчән инде ул!

Монысын Рәмзи моннан ярты сәгать чамасы элегрәк кенә белде.

Ул шушы тулай торакка килеп кергәнче дусты Габделбәр белән күрешеп өлгерде. Әлбәттә, Габделбәр яшәгән торакны эзләп йөрмәде, мотоциклын урам белән туп-туры төзелеп яткан йортлар тирәсенә юнәлдерде. Рәмзи аларның кай төштә өр-яңа йортлар торгызуын белә иде. Кичке эңгер инде тәмам куерып беткән, әмма куәтле прожекторлар яктысында югарыга шактый ук калкып өлгергән таш йорт тирәсендәге бар нәрсә, көн-

дезге кебек үк, бик әйбәт күренә иде. Рәмзи биектә ике тәрәзә арасына ак кирпечтән тигез һәм матур иттереп дивар торгызып матавыкланган Габделбәрне бик тиз абайлап алды. Теге дә, түбәндә кәтмәгәндә мотоцикл гөрелтесе ишетеп, игътибар белән күз салды һәм, аның иясен танызгач, мастерогын югары чөйгән хәлдә, каты гүелдәп, аваз салды:

— Чак кына сабыр ит, дускай! Менә сменаны гына түгәрәклик тә яныңа төшәрмен!

Биш-ун минуттан алар, асларына күн тышлы бияләйләрен салып, кирпеч өемнәрендә кара-каршы утырышканнар иде инде. Рәмзинең Габделбәрне бу киемнәрендә күргәне юк иде әле: өстендә сырган чалбар-куртка, бүрек колакчыннарын артка чыгарып бәйләп куйган, аякларында исә тирән галошлар кигезелгән киез итекләр... Ләкин иң гаҗәбе шул иде: Габделбәрнең суыкта кызарган йөзе бик ямьсез булып җәрәхәтләнгән иде — уң күз төбендә йодрык кадәр фонарь күгәреп тора, борыны ямьшәеп шешеп чыккан, ияк тирәсе дә сыдырылып киткән...

— Нәрсә, абайламый егылдыңмы әллә? — дип сорады Рәмзи, үтә сәерсенү аша.

— Егылды ди... Теге кем... молдаван дус «мыеккай» белән «по-джентльменски» сөйләшүнең җимеше,— диде Габделбәр, ачы көлемсерәп, һәм черт иттереп аяк астына төкереп куйды.— Дөресе: чәчкәсе әле... җимеше соңрак өлгерер! Ә болай чәпәләшү ару гына булды безнең!

— Кит моннан!

— Китмичә торыйм...

Габделбәр башыннан кичергәнне яшермичә сөйләп тә бирде. Өченче көннең элеккеге көнендә ул, кинодан соң, Рәмилә белән Женя Мында артыннан ияреп киткән. Әлбәттә, читтән генә күзәтеп барган. Тегеләр Рәмилә яшәгән тулай торак төбендә озак кына сөйләшеп торсалар да, түзгән, егетнең кыздан аерылып киткәнен көткән. Женя Мында, ниһаять, кайтыр ягына борылып, урамга чыгуга, Габделбәр, аның юлын кисеп: «Синең белән, туган, джентльменнарча бер бик әйбәтләп сөйләшәсе бар»,— дип, тегене туктаткан. Менә шуйда инде ул, ничектер чыгырыннан чыгып, үзенең кайсы авыл егете икәнлеген күрсәткән: молдаван «дускаеның» изүеннән ныгытып эләктереп тоткан, ә тегесе мондый тупаслыкны өнәмичә, Вятка егетен этеп җибәргән. Шуннан киткән инде, киткән... Әмма болар шулай бик тәмләп һәм бик кызып тәпәләшкән арада, өсләренә дружиначылар

килеп чыгып, ике этәчне ять кенә аерганнар. Габделбәр үзе дә ара-тирә тәртип саклауда катнашкалаган кеше, әлеге дружиначылар арасында аның таныш егетләре дә була, артык җәфаламыйча, икесен ике якка борып җибәрәләр. Югыйсә, штабларына алып китеп, эшне тирәнгә җибәрү мөмкинлекләре дә бар ич әле аларның...

— Йодрык белән генә какшатырлык түгел, нык тора, чукынган! Тик жәл, йөзен артыграк бизәдем, ахры... Бусына өстәп, үземә фонарьлар кундырса кундырыр, әмма аңа кирәкмәс иде алай ук ямарга...

— Ник тагы? — дип текәлде Рәмзи, мондый текә борылышка хәйран калып.

— Соң, аны җимерелгән йөз белән чит илгә, һич югы үзебездәге берәр калага җибәрерләр, дисеңме? Ә миңа бу араларда аның югалып торуы кирәк... монда булмавы кирәк!.. Кичәгенәк синең Вәсим абыеңны очраткан идем, ул да шулай ди: «Йөзен бизәсең калмаган, чәнчелгере»,— ди.

— Вәсим?

— Эһе... Соң, син Женя Мынданың кылларын чиртеп карау шушының белән беткәндер, дисеңме? Бетмәгән әле! Сынауның икенче төрлесе алда әле. Тик инде хәзер уйлабрак, нечкәрәк итеп эш йөртәсе булыр.

— Ничек, ничек?

— Әлегә сорашма син. Ни кыласын мин үзем дә уйлап бстермәдем әле. Ә син курыкма: сеңелкәшеңнең бер бөртек чәче дә коелмас. Ул молдаван дусны кабаттан, инде бүтәнчәрәк иттереп сынап карамыйча да ярамый. Соңыннан үкенечкә калмасын, дим, аңа да, миңа да, сезгә дә!..

Рәмзи ары таба сүз куерта алмады. Габделбәрне бер төркем иптәшләре, ашханәгә барырга дәшеп, аваз салып тора иде. Вятка егете утырган җиреннән җәһәт кенә купты да:

— Өеңә кайткач, алай-болай мине сорашсалар, бик әйбәт ята, диген! Үзләренә миннән тау-тау сәламнәр ирештер! — дип, гадәтенчә киң һәм дустанә елмаеп, Рәмзигә ым какты.

Рәмзи исә, мотоциклына атланып алды да, аны ничек кабызырга оныткан шикелле, бермәл уйга тарып калды. Нинди планнар белән ни эш кырырга чамалый икән бу Вятка егете? «Сеңелкәшеңнең бер бөртек чәче дә коелмас»,— диде дә диюен... Аның Вәсим белән якынаеп китүе юньлегәме соң? Сеңелкәшләренең баш өстендә көтелмәгән берәр кара болыт куерырга җыенмыймы

икән? Әллә абыйсы Айдаш белән киңәшеп алыргамы икән? Айдаш, ел азагы — җир каезлаудан план үтим дия-дия, көнне төнгә ялгап эшли, бу араларда аның дөньяда бүтән гаме юк та сыман. Ул авыррак кубучан, әмма эшне һәрчак диярлек төптән уйлап, башын-ахырын беткәнче исәпләп башкарырга ярата. Яңа елга инде күп калмады, анда инде Айдаш та бушый төшәр, Рәмзи үзе дә шушында «Сельхозтехника»га ремонт эшенә килергә тиешле. Ике туган, ике фикердәш бу четерекле хәлләрдә ни дә булса уйлап табарлар әле. Мөгаен, ул молдаван «мысккае»ның чын ныклыгын бер дә әллә кем түгел, үзләре сынап карарга тиешледер. Чын ирләрчә иттереп...

Бу уй-ниятләрен, шик-шөбһәләрен Рәмзи әти-әнисенә, әлбәттә, сиздермәячәк. Гомумән, ул Чаллыда абыйсы Вәсимнең салган баштан тулай торакка килүен дә, Габделбәр сөйләгән ямьсез хәлне дә әйтмәячәк. Аларның болай да хафалы башларына нигә дип күңелсез уй-исәпләр өстәргә ди?

Югарыда, бетон баганага эленгән лампа яктысында, кар чебеннәр уйный. Рәмзи мотоциклы тирәсендә әрле-бирле йөренүдән туктала алмый. Аның бер кулында төенчек...

Тулай торакка керүчеләр, аннан чыгучылар өзелми. Төркем-төркем укмашып чыкканнары да булгалый. Кызларның шат һәм күңелле көлешкән авазлары суык һавада чыңлап яңгырап куйгалый. Ләкин аның сеңелкәше нишләп чыкмый соң әле? Кичке мәктәпкә шултикле озак җыеналармы инде? Әллә бөтенләй күренмәскә исәп иткәнме? Санга сукмавымы? Рәмзинең күкрәгендә йокымсырап торган ачуы кинәт күперә башлады. Иң әүвәл үзенә — җәй көне йомшаклык кылганы өчен... аның соңында кабаттан сеңелесенә. Шул бер иләс-миләс чәчлекәй ничәмә кешенең канына тоз салып, ничәмә кешенең башын катырсын әле!

Ниһаять, ишек ачылып китте, һәм аннан яңа-ялгызы гына бер кыз килеп чыкты. Өстендә шәп мехлы модный пальто, башында шундый ук мехтан йомры бүрек. Баскычтан төште дә модный сапожкилары белән кырт-кырт баскалап атлый да башлады. Рәмзи аңа бер генә күз тидереп алды да карашын читкә борды. Әмма шундук янәдән күз салды: кызның атлау рәвеше аңа бик тә таныш кебек тоелды. Үзе, җитмәсә, туп-туры болай таба килә. Бер кулында төенчек, икенчесенең беләгендә дүрт почмаклы, чем-кара төстәге ридикюль сыман нәрсә

эленгән... Рәмзи кинәт өнсез калды: чү, бу аның сеңелесе Рәмилә түгелме соң?

Кыз аның янына бөтенләй якынлашкач, туктап калды, күзләрен мөлдерәмә тутырып карады да ап-ак тешләрен балкытып елмайды:

— Исәнме, абый! Әти белән әни ниһәлдә калды?

— И-исәнме, Рәмилә.. ә-әйбәт... э-элеккечә...— Рәмзинең капыл каушап китүе, әлбәттә, аның телен дә тотлыктырды. Егет бу халәтеннән тизрәк котылу нияте белән, кулындагы төенчекне селеккәләп күрсәтте.— Ә мин сиңа... теге киемнәреңне... бишмәтең белән яңа мамык шәлеңне алып килгән идем. Ә син монда, бактың исә... һе, таныйсың юк!

— Мәктәп пальтосынмы? — Кыз җиңелчә кеткелдәп куйды.— Аның хәзер кирәге шултиклем генә инде... Өйдә ярап торыр, һич югы, баш астына салгаларбыз... салгаларбыз. Бер истәлек булыр. Ә мамык шәл әйбәт әле, әни үзе ябып туздырыр...— Моны әйткәч, Рәмилә үз кулындагы төенчекне селкеткәләп алды.— Син абый, минә бусын да алып китәрсең. Плюш жакет белән иске шәл... теге кичнеке...

Бу төенчек тә Рәмзи кулына күчте. Егет, ниһаять, сеңелесенә игътибар беләнрәк, җентекләбрәк күз тидергәләп алды. Рәмиләнең өстендәге искитмәле һәйбәт киеменә тиң-тәңгәл төстә йөзе дә нык үзгәргән сыман: иреннәре, бит алмалары, әллә иннек якканга, алсуланып яна, күз төпләрендә исә әз генә, тонык кына күләгәләр, әмма, аның каравы, чем-кара күз төймәләрендә куанычлы, шаян чаткылар биешә...

Рәмилә абыйсына нинди тәэсир ясаганлыгын бик әйбәт сизенә, ләкин ул аның кабат-кабат тутырып каравыннан ничектер уңайсызланыбрак киткән иде, кисәк акылына килгән рәвештә, кабаланып, пальтосының шәп мехлы җиң очын чак кына кайтарды да сәгатенә күз салды.

— Нәрсә, кичке мәктәбеңә ашыгасыңмы? Илтеп куйыйммы?

— Һе, минә шушы биш катлы йортлар артында гына бит ул безнең мәктәп — нибары өч-дүрт минутлык юл. Бүген соңгы кичебез, иртәгәдән каникул.

Янәшә атлап киттеләр. Рәмзи аңардан: «Яңа елга өйгә кайтасыңмы соң?» — дип сорамакчы булды, әмма нигәдер авызы ачылмады. Ә сеңелесе, аның ни уйлаганын белгән төсле, әйтә куйды:

— Иртәгә без сәфәр тотабыз.

— Нинди сәфәр? Кая?

— Соң, туристик экскурсия инде... Уисигез көнлек. Мәскәү, Ленинград, Киевларда буласы. Юл уңаенда тагын ниндидер калаларда тукталасы, ди. Ә поезд Казанда оеша. Иртәгә шунда очасы.

— Мәскәү, Ленинградларга-ау? — Рәмзинең хәтта сулышы куырылды.

— Ие... Бригададан без Света белән икәү китәбез. Ул да әйбәт эшләве өстенә кичкедә дә болай ару гына укый... Шулай инде, кайберәүләр безне санга сукмагандай иттерсә дә, бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икәнбез, бәһане белүчеләр бар икән.— Кызның тавышы аз гына чатнап куйса да, аңарда ярыйсы ук вәкарьһавалану һәм моңардан битәр нечкә төрттерү аермачык сизелде. Әмма кыз үз хатасын шундук төзәтү ягын карады.— Ә Яңа елны без Мәскәүдә каршы алачакбыз...

— Мәскәүдә, димсең?..

Рәмзи барган җирендә тукталды да сеңелесенә янә сөзеп карады. Егет күңелендә инде хәзер бернинди дә ачу-ярсулар, үпкә-рәнҗүләр калмаган, алар инде өн дә сиздерми — каядыр таралып, бөтенләй юкка чыккан иде. Хәзер аның күкрәгендә нибары гаҗәпләнү һәм соклану, болар өстенә чиксез үз итү, чын туганнарча ярату хисләре генә ташып тора иде. Их, нигә бу кыз бала аның сеңелесе булып туды микән? Юкса, аны үз җаные — гомерлек юлдашы итәр өчен ниләр бирмәс, ниләр кыландырмас иде бу дөньяда!

— Ярый, абый... Кайткач, әти белән әниләргә, Туры бабайларга күп иттереп сәлам әйт, яме!.. Ие, бу төенчектә азрак күчтәнәчләр дә бар: чәйдер-конфеттыр шунда, аннары әти белән икегезгә бер шешә коньяк... Яңа елны әйбәт каршылагыз! Сау булып тор!

— Сау бул, сеңелем! Хәерле юллар сиңа!

Рәмзи басып калды. Аның ике кулына ике төенчек — сеңелесенең үткәне, артта калган язмышы эленгән иде. Рәмилә хәйран затлы пальтосы эченнән зифа сынын бөгелдерә-сыгылдыра, йөгерә-атлый үзенең кичке мәктәбенә — моннан күренмәгән, әмма зур, якты тәрәзәле үз бинасына таба юнәлде һәм, кышның сыек караңгысында биш катлы йорт артына борылып, күздән дә югалды...

11

Директор кабинетында шактый ук салкын иде, шул сәбәпле Мөслим Акбашев өстәл артында киң якалы тышлы тунын иңнәренә салган көенчә утыра иде. Менә ул, аз гына кымшангалап алгач, сынаулы караш белән Хәнәфигә төбәлде:

— Сез, Хәнәфи Бариевич, шәп механизатор булуыгыз өстенә, ялгышмасам, рабочком да әле? Чуарга, дим, әллә икәү китәбезме?

Хәнәфи, юантык бармакларын өстәл шомасында шудыргалап, ачыклык кертергә ашыкты:

— Алай рабочком ук түгел түгелен, нибары урынбасары гына... Зиннур үзе, инде ишеткәнсездер, укуда бит. Кем әйтмешли, хәсрәт заочник...

— Кайда укый?

— Соң, Мәскәүдә инде. Профсоюзларның иң югары курсындамы шунда, әллә мәктәбендәме, ди.

— Бәлкем, институттадыр?

— Чуртым белә... Инде диплом якламага китте шикелле. Тик кайчан тәмамлап кайтасын аермачык белгән кеше генә юк... Шул инде, үзе булмагач, «рабочкомны» аз-маз өстерәгәндәй кыландырасың.

Хәнәфи тыелып калды: Зиннур хакында аның фикере бик үк әйбәт түгел иде. Теге, имеш, дипломын яклагач, кире совхозга кайтып эшләргә һич уйламый да, ди, КамАЗга таярга ниятли, ди. Булыр да: шома егет, тәмам каешланып беткән адәм. Тиккә генә КамАЗ профсоюзы тирәсендә кирәктә дә, кирәкмәгәндә дә ышкынып йөрмәгәндер ич?.. Ләкин яңа директорның боларны әлегә белмичәрәк торуы хәерле булыр, ичмаса, ул икеле-микеле уйларда йөрмәс, һич югы алдан ук кәефе кырылмас.

— Тәк, Чуарга, дим, нишлибез?

Хәнәфи уфтангандай иттерде:

— Ә нигә партком Садыйков янсә баш агроном Ризван янә иптәш була алмыйммыни сезгә? Алар абруе янында минеке чагыштырырлыкмы соң?

Акбашев инде хәл-әхвәл белешкәләп Үтәдемдә дә, Гәрдәледә дә булып кайткан һәм берсенә барганда үзе белән партком секретаре Садыйковны, икенчесенә чыкканда баш агроном һәм берүк вакытта директор урынбасары булган Ризван Әүхәдиевне иярткән иде.

— Абруй, абруй... Онытмыйк: рабочком сез! Рабо-чий коми-тет, проф-со-юза дип аталасыз, Хәнәфи

Бариевич! — Директорның тавышы шактый ук югарыга менеп яңгырады, әмма аның саргылт-кара йөзендә ачулану яисә зәһәрләнүнең эзе дә сизелми иде. Әллә эчтән генә көлеп утыра инде? Менә ул, урындыгын шыгырдатып, урыныннан купты һәм, иңбашына тышлы тунын элгән көенчә, бүлмәдәге озынча өстәлне әйләнә үтеп, мич янына килеп басты, кулларын аның акшарына тидергәләп алды.— Ә Садыйков чирли икән, ангина, ди. Аны ничек кузгатасың инде? Ризван-агроном да әнә: «Кырыкка ярыла алмыйм, бүген кич агроукулар»,— ди. Анысын да өзәргә ярамый, минем дә көнне әрәм итәсем килми. Нишлибез соң? Әллә рабочком баш тартты дип, үзем генә барып кайтырга инде, ә?

Хәнәфинең моңа кадәр күрше авылларның берәрсенә барып җыелыш уздырып йөргәне булдымы соң? Юк, әлбәттә. Әле үз авылларында уздыра торганнарына бара белсә, таманга килә иде. Рабочкомга башны тыктылар дигәч тә, күңеле белән ул җәмәгать эшенә тиешеннән артык суыртылуга һич риза түгел иде.

Акбашевның исә, уч төпләрен җылы мичкә тидергәләп алгач, тавышы тагын да йомшарып китте сыман:

— Ниткән җыелыш булсын ди. Барып, кешеләр белән сөйләшәбез, Чуардагы хәл-әхвәл белән танышабыз — нибары шул! Рабочкомга да бер җилләп кайту, шәт, зыян итмәстер, ә?

«Кылларны чирткәләп, ныклыкны юри сынап карады... Юк, Яхъя Таипыч түгел бу: кырт та пырт кистерми, каты игәү белән йомшак иттереп игәүли...» Чыннан да Акбашевның тавышында гына түгел, күз карашында да кырыслык яисә катгыйлык тамчы да сизелми иде. Киресенчә, аның җиңелчә елмаю аша үз итеп, якын күреп каравыннан ук җанны эретүчән һәм ихтыярыңны буйсындыручан нур агыла сыман иде.

Хәнәфинең холкына ярарга тырышу яки риялану кебек нәрсә бөтенләй ят иде, алай да, тирән сулап куйгач, урындыгын шыгырдатып, урыныннан купмыйча булдыра алмады:

— Мастерскойда ремонтны самый кыздырып җибәргән чак иде. Ярар инде алайсам, барсак барырбыз...

— Менә бу егетләр сүзе, ичмасам! Кичке савымга ничек тә өлгерергә кирәк безгә!

12

Мастерскойда төшкелеккә тукталгач, Хәнәфи өенә кайтып керде дә, авызын җәйгән шәйгә, хатынына бүген кичке уңайда кем белән кая барасын әйтеп салды. Рәсүләсе, бу хәбәрне ничек сеңдерергә белмичә, беравык күз йомгалап торды:

— Чуаргамы? Җаңа директор беләнме? Күр сине... Куып ук җатмассыздыр бит? Айсам, җарый, җарый, бик әйбәт...— Шулай дип аяк каккалагач, ул кинәт иренең иңбашына төртеп алды.— Туктале, дим, син нишләп соң җаңа директорыңны үзебезгә төшке ашка дәшмәдең? Әнә ит белән бәрәңге плитәдә буларын бөркеп утыра! Аны бит төзүчеләр ашханәсендә генә тамак җалгаштыргалап җөри диләр. Семьясыз кешенең...

Хәнәфинең өстеннән туның, бүреген салып маташкан чагы иде, күзләрен шакмакландырып хатынына карады:

— Син нәрсә? Шундый олы кешене... капыл гына...

— Әҗер карачкысы булма, бар, дим! Үзең рабочком тагы... кеше турында кайгыртмаска монда. Ичмаса, бер җүнле ризык кабар авызына.

Күнмичә мөмкин түгел иде, Хәнәфигә киредән күн бүреген башына батырып кияргә туры килде.

Бәхетенә, Акбашев «Автозаводстрой» ашханәсенә китеп бармаган икән әле, әмма ул, елмаеп кына зур рәхмәтләр әйтсә дә, Хәнәфинең тәкъдимен кискен рәвештә кире какты: имеш, ярамый, уңайсыз, килешми... Мондый чакта Хәнәфи дә төшеп калганнардан түгел:

— Мин бит сез әйткәнгә күндем — Чуарга барудан баш тартмадым, ә сез киреләнәсез... Анда хатын да, дуамал кубып, буран кузгатты. Ризыктан өстен булырга ярамый бит инде,— дип ныклык күрсәтте һәм шул ныклыгы белән тегене аударып та куйды.

Алар кайтып кергәндә, Рәсүлә өйләренең түр ягына табын әзерләргә керешкән иде инде. Әмма Хәнәфи аптыраудан тамак кыргаламыйча булдыра алмады: түр якта Рәсүләгә табын әзерләшеп, каенатасы Туры карт та үзенчә эш кыйратып матавыклана иде. Кай арада килеп кергән, диген! Бая Хәнәфи өенә сугылган чагында ук аларда булып, түр якта күзгә чалынмыйча утырып калды микәнни? Юктыр, Рәсүлә аңа ять кенә хәбәр салгандыр. Килеп җитәргә ара еракмыни?

Хәер, Туры картның монда булуына алай бик аптырарлык та түгел иде: соңгы араларда ул әледән-әле

аларга килеп керә дә: «Теге бәпкәчтән андый-мондый хәбәр җукмы?» — дип сөекле сөяге хакында сорашырга тотына иде. Кызлары Рәмиләнең һич уйламаганда зур һәм бик тә мактаулы сәяхәткә чыгып китүе һәммәсен дә чиксез дулкынландырган һәм куандырган иде. Көнелләрендә «Ерак җирләрдән әйләнеп, дөнья күреп йөргән мәлләрендә, бәлкем, җенләнүләре коелып, азрак акылга килмәсме? Читкә китсәң, җыен ыбыр-чыбыр, вак-төяк юкка чыгып, күзгә күренмәс була, аның каравы, тормыш өчен иң хаҗәте һәм әһәмиятлесе, бигрәк тә туганлык-кардәшлек хисләре дәррәү үсеп, кабарып китә. Бу кызый белән дә шулай булуы бик тә ихтимал» дигән өмет ялкыннары дөрләп куйгалый иде. Әмма шул ук чакны шик-шөбһәгә чумган вакытлары да булмый калмый иде: ә шуның нәкъ киресе килеп чыкса? Кызый әнә шундый данлы җирләрдә булудан бөтенләй масаеп һәм һаваланып кайтса? Үҗәтләнүләре күпереп кенә китмәсме?

Рәмиләнең кайтыр вакытлары инде узып бара, әмма аңардан моңа тикле ни хат, ни хәбәр килгәне булмады. Бу исә мондагыларның пошаманлы уй-исәпләрен көннән-көн көчәйтеп тора иде...

Туры картның боларда булуының Хәнәфи бик үк абайламаган икенче сәбәбе дә бар иде: бабай, яңа директорны урамда очраткалап, аңа итагать һәм әдәп белән баш селеккәләп киткәләгән булса да, аның белән күзгә-күз иркенләп сөйләшергә җай көтебрәк йөрүдә иде. Менә хәзер дә, картларча, әкрен, әмма эре кыйланып табын әзерләшкән җирендә дә, кипшергән иреннәрен ялаштырып куйгалаулары ризык тәмле күренгәнгә генә түгел, билгеле...

Әмма ул өстәл артында үзе белгән тәртипкә һич хилаф кылмады, ягъни гәпкә капыл гына керешмәде. Тозлы кәбестәне кетертләткән шәйгә яисә ит белән бәрәңгенең үтә кайнар шулпасын болгаткалый-суыткалый, бер үк вакытта кунагын да ныклап кыстарга онытмыйча, әкертенләп һәм иплән кенә тегенең кылларын чирткәләргә тотынды... Акбашевның армиядә хезмәт итүче улы, җитеп килгән кызы барлыгын һәм болар өстенә хатынының да фельдшер булып эшләвен ишеткәч, «Тормыш җаклары, айсам, эздә икән, рәхмәт, энем!» — дип авыз шәпелдәтте дә шуның арты ук кунагын тынычландырырга ашыкты:

— Ә син, энем, һич кенә дә хафа җотып җөрмә: тулай торакта алай озак чиләнеп җатмассың, чакыртыр-

сың үзеңнекеләрне... Җаңа калада өр-җаңа фатирны тоттырырлар сиңа да! Әнә бит Таип Яхъясы, ай-һай, өлгерлек күрсәтте! Ә нигә, әллә лаек түгелме? Әйтерлегең җук: бик тә лаек!

Таиповның директорлыктан китү сәбәбен авылда төрле кеше төрлечә аңлата иде. Шулай булмый ни, күчәр башында дилбегә тотып, ни гомерләр утырсын да, күпләр һич уйламаганда, капыл гына арбадан төшеп калсын әле сиңа — хикмәтле хәлнең дә хикмәтлесе түгелмени? Мәгәр Туры карт, элгәреге елларда Таипов белән никадәр еш, никадәр каты чәнчешкәләгән чаклары булмасын, аның хәлен аңлау, хәтта яклау ягына авышкан иде:

— ҚамАЗ шартларына җараплар бетмәде, борчак пешерә белмәде — иң чын дөресе шул! Җугыйсә бер искән җилгә генә авардай имән иемени? Җарар, пошынмыйк, үз җаен белми кыланмас... Ә болай бик тә заслуженный инде, үз иңнәрендә азнымы өстерәгән адәм!

Ярыйсы ук күтәренке тавыш белән сиптерелгән шушы сүзләрдән соң Туры бабай, кинәт өн-аңына килгән рәвештә, табын артындагыларга берәм-берәм күз йөртеп чыкты, кашыгын кулына алды, ләкин тәгамне бер-ике кабып куйгач та, кире кайтып, әмма йомшаграк, ягымлырак тавыш белән Акбашевның үз хәлләрен төпченергә керешге:

— Эһе, җыракта Ык буенда тир түгәргә туры килде, димсең айса! Орунбур белән Башкортстан почмагында ук? Эһе, мондагы күк савхуз икән, җарый-җарый... Ә тумышың белән кайсы җакныкы диик инде? Эһе, Әлмәт тирәсе, Зәй буе — димәген ки, нефте бәргән төшләр... Ә элекке заманда ничек диярләр ие, җәгъни кайсы өяз, кайсы губерна дигәнем?

Туры карт булсын да, тарихны чокымый торсын ди сиңа! Акбашев аптыраудан ахры, кашыган авызына китергән чагында ярты юлда тукталыбрак калды.

— Элеккедәме? Самара губернасы Бөгелмә өязе исәпләнгәнбез. Ә нигә?

— Болай гына... Без үзебез, әйтик, элекке заманда Минзәлә өязе булганбыз, димәген ки, Өфе губернасы. Бүгенгесе көнне ҚамАЗ дигәнебез, җәгъни дә эчкәртенрәк китеп әйләндереп карасак, әүвәл-әүвәлтеннән татар белән башкорт кушылып җәшәгән җирләрдә укмашып җата, энем.— Бу минутта Туры карт ашаудан бөтенләй тукталган һәм маңгай буразналарын тирән сыздырып, кунагына төбәлгән иде:— Ә фамилияң синең әкәмәт сәер.

— Нишләп?

— Үзең Акбашев, үзеңнең башың чем-кара! Сәер булмый ни! Җолкып өшкермәгә, ичмасам, чәчең арасында көмеш сукканы бер генә бөртек күренсә икән!

Менә бит, кешенең чәченә бәйләнмәсә соң... Кияве Хәнәфи ,дә, кызы Рәсүлә дә аңа, кунагыңа бу тикле ябырылмасаң иде лә дигән мәгънәдә, каш җимереп ым кагалар, әмма Туры карт алар ягына күз салып та тормый иде. Ул үз ышнасына үзе хуҗа, җилпучын үзе теләгәнчә һәм торган саен кыюлана төшеп, селкүен белә иде:

— Ничә җәшьләрдә дип белик инде үзеңне, энем?

— Егерме бишенче елгы.

Менә шул чагында инде Хәнәфи:

— Соң, яшьтиләр икән лә без! — дип кычкырып куйды.— Авылда алайса хәзер өчәү булдык: Ризван белән мин дә... инде менә син!

Бу хәбәр Туры картка да көтелмәгәнчәрәк булды, ахры, ул хәтта тотлыгып калды:

— Һы, менә сиңа хикмәт... карап торырга шактый ук җәшьтер дисәм... Айса, сугыш утларында да җөрми калмагансыңдыр әле?

— Йөрмичә...

Яшьти, яшьти!.. Бу дөньяда Хәнәфи кебек сугыш ветераны өчен аннан да кадерлерәк адәм бармы икән бүгенгесе көнне?!

13

Басу юлына килеп кергәч тә, чана түренә оялап алып, сыртын үрәчә башына кырын салган Хәнәфи, бүрек колакчыннарын тарта төшеп, кайры тун якасын күтәреп куймыйча булдыра алмады. Аңа шундук диярлек юлдашы да иярде. Шөкер, аңарда да тун иде — кышын, аерата юл йөргәндә, иң кулае, иң ышанычлысы. Тик аякларда гына аермалы: Хәнәфидә йомшак киез итек, ә тегеңәрдә, «җылы» дип макталып әйтелсә дә, нибары ботинка гына иде. Шуңа күрә Акбашев аякларын йомшак саламга тыгыбрак утырды.

Чуарга кадәр җиде-сигез чакрымнар. Юл чокыр-чакырларны, куак-әрәмәләрне әйләнә-чолгый үтә. Кышын, әлбәттә, машинада борын төртәсең юк. Нибары трактор юлы да, чана юлы... Ян-якларда анда-санда, әмма бөтен юл озынлыгына, чыбыклар төртеп чыкканнар.

Туры алаша — ышанычлы һәм тугрылыклы кодрәт иясе, юл тигезләнеп, шомарып китсә, дилбегә какканны да көтмичә, юыртуга күчә, ә инде салулырак өлешкә керсә, атларга тотына, әмма шул чагында да, кызулыгын чак кына да җуярга теләмичә, адымнарын тибеш-тибеш сала иде.

Хәнәфинең күптәннән инде, менә болай чана түренә оялап, кышкы юлларны гизгәне юк иде, һай, тансыклаган икән — күңеле әллә нинди рәхәт дулкыннарда тирбәлүгә күчте:

— Һай, малкай гынасы ла!

Бүген тагын, күр инде, җәяүле буран кубарга чамалый сыман. Тик зәһәр җилнең искән тарафы гына бу юлы беркадәр үзгәреш кичергән шикелле: салкын һава дулкыны, бөтерелеп-айкалып, инде тап котып ягыннан түгел, бәлки кояш чыгышы тарафыннанрак агыла иде.

Бу кышны җир йөзенә болай да юка кунган кар инде хәзер үзәнкел төшләргә, чокыр-ерганакларга себерелеп бетә дә язды. Ак, йомшак юрганнарыннан мәхрүм калган басулар, аерата чалкыерак өлешләре, имансыз туңудан кара шадралы йөзләрен чытып, һавага, күккә рәнҗеп яталар шикелле. Кыш уртасында бит!

Ел, җәйгә чыккач, тагын яманга әйләнеп китәр микәнни? Әүлия җанлы ил картларының былтыр чиксез уфтану аша: «Өч ел рәттән шушылай корылык булыр»,— дип, юраганы юш килер микәнни?

Акбашев үрәчә буйлатыбрак кырын яткан җиреннән капыл гына тез өсләренә калкынды да:

— Ә Үтәдем хатыннары чая да соң! Телләренә шайтан үзе төкергәнмени! — дип һич көтелмәгән тарафтан сүз башлап җибәрде. Күр моны, кемнәр хакында уйлап бара икән! — Аларның мунча ташлары элек тә шулай кызу идеме, әллә ҚамАЗ кыздырып җибәрдеме?

— Икесе дә булгандыр, Мөслим Гайнаныч. Ҡерәшендә мунча ташының, әйтергә кирәк, суынганы да юк, һаман да «жәрле» яшиләр! Аерата хатын-кыз...

Күңелле генә көлешеп алдылар.

— Тик, жәл, совхозга ябышып торганнары нибары шул дуңгыз фермасы гына икән. Әле анысын да бу елны бетерергә ниятләгәнсез икән.

— Соң, безмени? Тресттагы агайлар тырыша инде.

— Тресттагы?

— Әйе, нибары сөтчелек белән яшелчәлек кенә булсын, диләр бит.

— Алай бик ашыкмаганда да ярар иде... Юк, бер-

бер эмәлен тапмый булмастыр. Дөньяда бер трест кына түгел, бүтәннәр дә бар. Аңлаучылар, дигәнем...

Хәнәфи юлдашына текәлебрәк күз атып алды: «Күрче, совхоз дилбегәсен кулына ныклап тотканы юк әле, инде шәпләп кизәнергә дә җыена түгелме соң бу?..»

Ләкин Акбашев шушы юнәлештә сүзне артык куертырга теләмәде, ахры, көлемсери төшеп, янә баягы эзенә кайтты:

— Ә гәрдәлеләр сабыррак күренә.

— Алар җиргә ябышканрак... Һәйт, малкай!

Ярыйсы ук салулы юлдан ат авыр-авыр атлауга күчкән иде, Акбашев янә үрәчә уңаена кырын ятты, әмма бермәлдән кабат калкынды:

— Ә партком секретаре Садыйков акбур белән кара тактаны сагына башлаган, ди, чын булса...

— Кара тактаны? Ә, әйе... сагынмаска, партком булганчы, математика укыткан кеше бит.

— М-м-да,— дип сузды Акбашев, бу икеле-микеле ымлыкка үзенчә мәгънә салып.

Инде күз бәйләнергә тора, юл читендәге маяк чыбыклары да тоныкабайлана иде. Йомры алаша янә юыртуга күчкәч, Акбашев гәүдәсен тагын кырын салды һәм бүтән калыкмады да инде. Ул, йөзен тун якасы белән каплый төшеп, хәтта күзләрен үк йомды шикелле. Йокымсырап китүеме? Әллә бар белгән-ишеткәннәрен тизрәк сеңдермәкче булып, тирән уйларга таруы гынамы? Ни әйтсәң дә, үзе өчен бөтенләй ят җиргә, өр-яңа тарафка күчеп килүе бит...

Чуарга нибары җиде-сигез чакрымлык юл. Нибары... Буран һаман җәяүли бирә, ә Хәнәфи, чана түренә елышкан хәлендә, күңеле белән уйлар диңгезенең әллә нинди дулкыннарында чайпалуын белә...

Күз алдына Яхъя Таипыч килеп басты. Ә бит чынлыкта бабасы Туры карт хаклы: тиз генә бирешердәй имән түгел кебек иде — тамырлары тирән, һич какшамас сыман иде. Әмма үткәндәге кырысрак заман өчен... Ә бусына, яңасына чыдамады. ҚамАЗ бөтерелмәсе аударды аны. Ризван-яшьтиенең «цунами» дигәне... Аумас, бирешмәс өчен җайларын таба алмады, әмәлләрен белмәде. Ярый әле, вакытында үз хәлен аңлап, дилбегәне икенче кулларга тапшыру ягын кайгырта алды. Ышанычлырак кулларга... Аның бу хәтлесе дә чын егетлек түгелмени!

Ә бу кара башлы Акбашев ниләр җимертер икән? Җимертә алырмы? Ә болай үзе дуамал кубучаннардан

түгел шикелле. Үткен акыллы, хәлне аңлаучан кебегрәк...

Кичке эңгер шактый ук куера төште. Юл инде начар абайлана иде. Әмма туры алаша, рәхмәт яугыры, кай төштә юыртып китәсен, кай төштә саллы-саллы атлауга күчәсен үзе дә бик әйбәт чамалый иде.

— Һәйт, малкай гына ла!

Инде күп калмады: әнә сөзәк үр каршындагы куаклар артында Чуар утлары җемелдәшә. Үзәнлектәге чокыр-чакырларны әйләнә төшеп үтсәләр, үргә күтәреләләр дә...

Тик нигә соң әле аның юлдашы-яшьтие өн-тын сиздермичә мәрткә китеп ята? Мондый юлда гәп коруның никадәр тансык һәм татлы икәнен аңламый микәнни? Һич югы сугыш истәлекләрен янә бер селеккәләп алсалар да, зыян итмәс иде.

Акбашев түрдә дилбегә тотып утыручының ни теләгәнен күңеле белән сизенде, ахры, менә ул кырын яткан җирендә башта кымшангалап алды, аннары, ат тигез юлдан җиңелчә юыртып китүгә, торып утырды, әмма сүз итеп Хәнәфи көткәнне түгел, бөтенләй бүтәнне башлап җибәрде:

— Чуарда хәлләр ничегрәктер инде, Хәнәфи Бариеч, ә?

— Чуардамы? Безнең Туры бабай әйтмешли, үзләре дә чуар, хәлкәйләре дә чуар, һе-һе...

Хәнәфи бу авыл турында тәмләп сөйләмиме соң! Әмма ул, кеткелдәвен басып, бер тын ара сүз башламыйчарак торды. Ни турында сөйләргә икән? Юк, производство хәлләре, фермасы-бүтәне торып торсын әле — качмас, баргач барын да үз күзләре белән күрер. Ә менә авылның үзе турында, аның сәеррәк халкы, аеруча уңган кызлары һәм киленнәре, бу бәләкәй генә авылдан чыккан укымышлы кешеләр хакында җәелебрәк сөйләсәң дә, шәт, гөнаһ булмастыр.

— Хәзер анда, кәнишне, күз явын алырлык берни дә юк,— дип тотынды ул, ниһаять, дилбегәне җиңелчә каккалаган шәйгә.— Ә менә җәйләрен... билләһи, исләр китәрлек! Курорттай урын инде! Яшеллек эчендә күмелеп утыралар. Урам дигәннәре бәрәү — болын хәтле! Шулай булмаска, алар бит элгәредә Минзәлә өязенең төрле авылларыннан килеп укмашкан, янәсе, һәркайсы үз тирәсенә елыша... Урамның бер ягыннан икенче ягына чыкканчы утлы кисәү сүнә, бер якның әтәч кычкыр-

ганын теге яктагысы ишетми, ди. Чуарлар үзләре әйтә, һе-һе...

— Телгә җор димсең алайса.

— Бар инде, бар... Алар бит сабантуйны да авыл уртасында урамда гына үткәрә.

— Кит аннан!

— Китмичә торыйм: мин белгәннән бирле шулай, ипидер!.. Соң, рәхәт булмый ни! Телисең икән, алышкөрәшне өендә ачык тәрәзә янында чәй-мәй капкалаган шәпкә генә күзәтәсең; телисең икән, өй түбәсенә яисә тирәк ботагына кунаклап карыйсың; ә инде урамдагы хәтфә чирәмдә кырын яткан шәйгә карауларның уңайлыгын әйтәсе дә юк...

— Идиллия икән.

Бу сүзнең асыл мәгънәсен Хәнәфи, әлбәттә, белми иде, алай да, аны матурга юрап, ияк каккалады:

— Үзе инде... Аннары, Мөслим Гайнаныч, шунысын да әйтим әле: менә безнең совхоз «Йолдыз» исемен йөртәме? Йөртә. Ә бит заманасында бу матур исемне безгә Чуарлар биргән.

— Ничек?

— Ничек дип... күптән инде. Колхозлашу елларында ук. Дөрес, Чуарда да бөтенесе дә алай шома гына бармаган. Иң башта әртил кормага ир-ат тотынган. Корганар да. Коргач, «Кызыл Ләпәй» дип атаганнар. Ә «Ләпәй» дигәнеме? Анысы аның урман исеме — теге як басуларына тоташып китә... Ярар, коруын корганнар болар әртилне, әмма озак яши алмаганнар: ике-өч ай үтүгә үк, язгы чәчүгә чыккач, ат-арбаларын, сука-тырмаларын киредән бүлешә-бүлешә ызгышып, канга батышып беткәннәр. Таралган боларның әртиле. Шуннан соңмы? Шуннан соң хатын-кыз тотынган. «И мескенкәйләр, сездән буламы соң!» дип... Җилле аларда хатын-кыз, бигрәк тә яшь киленнәр, кызлар. Арада берсе, комсомолка Гайшә дигәне, баш булып йөри. «Ләпәй дә булсын исем, ди, юк, безнең әртил Чаллы-Минзәлә төбәгендә йолдыз булып янарга тиешле»,— ди. Хатын-кыз ике уйлап тормый, моны әртилләренә председатель итеп сайлап та куя. Ир-атның, билгеле, буйсынасы килми, ат бирми интектерә. Ә болар югалып калмый, сыер жигеп булса да, уртак җирләрен сөрә дә, тырмалап чәчә дә!

Юк, заманасында даны яңгыраган комсомолка-председатель турында җәелебрәк сөйләргә язмаган икән Хәнәфигә: туры алаша, әйбәт кенә юыртып барган шәпкә,

ярыйсы ук тирән чокырга төшеп, чанасы-ние белән муеннан тирән карга батты. Бер тилпенде малкае, ике тилпенде, әмма аның саен карга тирәнгәрәк чума барды. Камыт-дугалары әллә кая менде.

— Тфү, кадалгыры! — дип сукранды Хәнәфи.— Шулай инде ул, яшьти, сүз тәменә чумсаң, юл җаен онытасың!

— Ярар, уфтанмыйк! Хәерле каза булсын, арт ягы таза булсын, диик, яшьти! Туармыйча гына котыла алмабыздыр...

Атны туарып, чананы тирән кардан өстерәп чыгарганда да, кабаттан җиккәндә дә Хәнәфи юлдашының кул-беләкләрендәге җегәргә сокланмыйча булдыра алмады — Алып батырлар нәселеннәндер бу, рас!

— Булды гына бу! Әйдә, утырышыйк, яшьти Хәнәфи!

Чуарга барып керүләренә, кичке савымга шактый ук соңгарган булып чыктылар.

14

Клуб бәләкәй генә иде: нибары кырык-илле кешегә генә исәпләнгән зал, түрдә идәннән ярты метр чамасында гына күтәрелеп торган сәхнә, анда җыйнак кына өстәл, трибуна. Шоп-шома диварларда исә сурәт-плакатлар, лозунглар, схема-диаграммалар, тагы әллә ниләр — Чуарлар үз клубларын артыгы белән чуарлап җибәргән лә, дияргә булыр иде хәтта. Артлы урындыкларны исә урталыкка түгел, ян-якларга диварлар буйлата тезеп чыкканнар. Күрәсең, монда күбрәге күңел ачарга, уенҗыр корырга җыела торганнардыр.

Ишек янындарак тигез акшарланган мичнең залга караган ышыгында бәләкәй генә биллиард булып, шуның янында ике бәләкәч малай, бүрек-бишмәтләрен салып атып, үлле-мәлле шар сугып ятуда иде. Ике абый тупсадан атлап керүгә, алар, кызыклы уеннарыннан шып тукталып, күз тасрайткан иде.

Әйе, монда бары да үтә җыйнак һәм үтә бәләкәй иде. Зур культура сарайларына күнеккән күзләргә беренче карауга монда бары да уенчык кына булып күренүе дә ихтимал. Әмма нибары кырык-кырык биш хуҗалыктан торган авылга моннан да артыгы ни булыр иде икән тагы?

Акбашев канәгатьләнү аша тамак кыргалап алды:

— Ярыйсы гына икән бу... Әйбәт бу!

Алар инде фермада кичке савымның азаккы өлешен генә булса да күзәтеп өлгергәннәр иде. Анда йөргәндә дә Акбашев савым эшләренә тыкшынмыйча, тик хәл-әхвәл генә белешкәләп һәм менә шушылай канәгатьләнү аша тамак кыргалап йөргән иде. Хәнәфи үзе дә кеше мәш килеп эшләп ятканда тыкшынырга яратучылардан түгел иде — яңа директорның бу гадәтен күңеле белән бик ошатып куйды.

— Йә, ник тукталдыгыз? — диде Акбашев, биллиард янында күз тасрайтып өнсез калган ике малайга.— Авызыгызны ябыгыз, дим, югыйсә чыпчык очып керә бит! Ие, менә шулай, тотыгыз җәһәт кенә... Егет дигән затларга кул шомартып, күз үткенәйтүләр бер генә дә зыянга булмас!

Аннары алар, уң тарафтагы ян ишекне ачып, клубның бүлемте өлешенә керделәр. Монысында уку залы, дөресе, бәләкәй генә китапханә икән.

Бүлмә карар күзгә тагын да пөхтәрәк һәм җыйнаграк күренә иде. Диварлардагы төрле язучыларның сурәтләрен, китап сөяргә өндәгән плакатларны яисә бер кырыйда ачык шүрлекләрдә тыгыз итеп тезелгән китапларны әйтәсе дә юк, түрдә биек кенә тумбочкалар өстендә урта зурлыктагы экранлы телевизор һәм радиоалгыч белән магнитофон да күз яуларын алып утыра иде. Әйтерең юк, бай гына яшиләр икән ләбаса!

Бүлмә уртасындагы озынча өстәл янында дүрт-биш кызчык китап-журнал актарып утыра иде. Алар, әлбәттә, көтелмәгән кунакларны күреп, каушап калдылар, әмма, каушасалар да, матур гына иттереп исәнләшә белделәр.

— Гыйлем сендереп утырабыз, димсез инде алайса? Шәп, шәп! — дип эндәште аларга Хәнәфи, җылы гына иттереп.— «Избач» апагыз кайда соң?

Кызлар, бер-берсенә күз аткалап, шыпырт кына көлешеп алдылар, бер-икесе хәтта муенын җилкәсенә батырып куйды. «Избач» дигән сүзне үзләре өчен хикмәтле дип таптылар, ахры. Ниһаять, берсе, бүтәннәрдән чак кына калкурак күренгәне,— сирәк сипкелле йөзе бүртенеп кызарса кызарды,— әмма кыюлык күрсәтте:

— Зәйтүнә апамы? Ул өй борынча почта өләшеп йөри әле.

— Алайса, ул югында сез хуҗа монда?

— Шулай инде.

Хәнәфи хәлне Акбашевка аңлатып бирмичә булдыра алмады:

— Зәйтүнә апалары теге ни... бер үк вакытта клуб

мөдире дә, китапханәче дә, өстәвенә почтальон да! Мактавым булсын, Чуарның иң уңган киленнәреннән.

— Күренә,— дип ым какты Акбашев, бүлмәгә янә күз йөртә-йөртә.

Сораша торгач, белделәр: авылда шушы кызлардан өлкәнрәк булган җиде-сигез малай белән кыз Әҗер урта мәктәбенең интернатында яшәп укый икән, ә болар Гәрдәледәге башлангыч мәктәпкә көн саен төшеп йөриләр икән.

— Кыен түгелме соң?

— Нишләп? Күңелле генә... Ат җигеп, төшереп куялар, уку беткәч, алып кайталар. Умартачы Рәҗәп бабайны белмисезме әллә? Җәйлектә совхоз умартасын карый, ә кышлыкта безне йөртә.

— Белмәскә... әйбәт абзый! — диде Хәнәфи һәм янә Акбашевка аңлатып бирде.— Боларның үз авылларында да элгәрерәк мәктәп бар иде, дөресе, мәктәпчек: барын бергә, ягъни дүрт классны берьюлы бер укытучы укытыр иде. Уптым! Соңрак авыл халкы үзе үк андый тәртипне өнәми башлады.

— Хәлләрен бик аңлыйм,— дип елмайды Акбашев.— Үзем дә Зәй буеның шушындый ук бер бәләкәй авылында туып үскән малай. Йөреп укуларның кадерен бик беләм...

Аннары ул киң бер хәрәкәт белән бүлмә һавасында кул изәп алды:

— Бу кадәр китап кочагында утырулар рәхәттер шул, ә!

Кызкайларның күзләрендә шундук чаткы-йолдызлар ялтыр-йолтыр җемелдәшергә тотынды.

— Рәхәт булмыйча! — дип күтәреп алды кара кашлы кыз, авызын киң җәеп.— Без, берәр кызыклы тапшыру булса, телевизор да карыйбыз, кайчакларда, кирәк дисәк, музыка да тыңлыйбыз әле. Зәйтүнә апа шундый да әйбәт ул безнең!

— Бик күңелле яшисез икән!

— Аның әле бөтенләй күңеллесе атна азагында була. Шимбә белән якшәмбе кичләрендә. Анда инде Әҗердә укып ятучылар да, КамАЗ төзүче егетләр белән кызлар да кайткан була. Безнең клубка бер кичне килеп карасагызмы! Зрә дә әкәмәт инде! — Сирәк сипкелле кызый, ялгышып артыгын ычкындырдым, ахры, дип шүрләп куйдымы, кинәт тыелып калды һәм, башын кыңгыр салды да, ике абыйсына да җәт кенә күз атып, әмма

басынкы гына тавыш белән сорау бирергә итте.— Бүген кич безнең клубта җыелыш буламы әллә, абыйлар?

— Әйе, кызларым,— дип җылы гына иттереп ым какты Хәнәфи.— Бер сөйләшеп алырга дип килгән идек әле менә.

— Ә безнең әнәйләр белә микән соң?

— Белгән хәтлесе беләдер, ә белмәгәне... Туктале, нишләп «әнәйләр» генә? «Әтәйләрнең дә» булуы бик хаҗәт бит, кызым!

Шул сүз җитә калды: бүлмәдә кинәт кискен җил исеп куйдымыни, кызлар, бары бердәм кубып, өстәл артыннан себерелеп чыктылар. Аларның шәл-бишмәтләре почмактагы урындыкка тигезләп, өс-өсләтеп өеп куелган иде, ашык-пошык киенергә тотындылар.

Бер минут үтүгә китапханә бүлмәсендә аларның исе дә юк иде инде. Бу шулхәтле тиз булды, Хәнифи Бариев белән Мөслим Акбашев кызларга сүз катарга да өлгермичә калдылар.

Бүлмә бик якты булуы өстенә шактый ук җылы да иде, болар да өсләреннән туннарын салып, кызлардан бушап калган урындыкка өеп куймыйча булдыра алмадылар.

— Әнә шулай итеп, алар, Мөслим Гайнаныч,— диде Хәнәфи, өстәл янына утырып һәм кулына беренче эләккән журналны алып, әмма аны битләп карарга ашыкмыйча,— «әтәй» димиләр, иң әүвәл «әнәй» диләр. Хәтта ки җыелышка дәшәргә дигәндә дә...

— Нигә икән?

— Соң, аңлаттым шикелле бит инде, бу авылда элек-электән үк хатын-кыз баш бит. Гайшә апа председатель булып йөргән заманнардан ук... Ие, сугышка хәтле дә, сугыштан соңгы елларда да председатель үзе генә түгел, бригадир яисә завферма белән кладовщик ишесе дә нибары хатын-кыздан булды. Ә бит үзләренә, әртилгә баш булулары өстенә, семья карыйсы, бала-чага үстерәсе дә бар.

— Бертөсле «матриархат» сыманрак икән алайса,— дип көлемсерәде Акбашев.

Хәнәфи «матриархат» сүзенең асыл мәгънәсен исенә төшерергә тырышып, маңгай җыерчыкларын ишәйтте, аннары, зиһене ачылып китеп, иреннәрен җәеп җибәрде:

— Әйе, шуна охшаш... Тагы шуны да әйтим әле: шушы карап торырга караңгы гына кебек тоелган авылдан укымышлы халыкның ниндие генә чыкмаган: укытучы белән врач дисеңме, инженер яки анда геолог

дигәннәреме... хәтта ки, полковник белән прокурорга кадәр бар! Әллә кемнәр... Безнең Әжер белән Гәрдәлене, аларга өстәп Үтәдемне кушсак та, укымышлылар ул кадәр үк җыелмастыр, чын әгәр...

Бермәл тын гына журнал актарып утырдылар. Ләкин бу хәл алай озакка сузылмады. Хәнәфи бер кызык сөйләргә тотынгач, ахырына җитик инде дигән сыман, җиңелчә көлемсерәү аша, ары алып китте:

— Хикмәтнең дә хикмәте болар түгел әле, Мөслим Гайнаныч... Сез үзегез дә Зәй буеның бәләкәй генә бер авылыннан, дисез. Бәлкем, сездә дә хәл шулайрактыр: шушы Чуар авылында, аңлашыладыр шәт, үз араларыннан кыз алыш, кыз биреш, ягъни өйләнешү күптәннән юк инде. Ник дисәң, болар күптәннән үк инде үзара туган-тумачаланып беткәннәр. Шул сәбәпле, үз кызларын чит авылларга очырталар, үзләренә киленне бүтән җирләрдән төшертәләр. Болай гап-гади хәл кебек, әмма иң кызыгы шул, әле бик күптән түгел Чуардан берәү, энәсеннән җебенә кадәр җитеп, тикшереп караган: боларга төшкән киленнәрдән, әлбәттә, уртачага куеп исәпләгәндә, өч баланың берсе малай булып туа, ди, калган икесе кыз була, ди. Ә бүтән авылларга киткән үз кызлары исә тегендә тупырдатып малай тудырып ята, ди... Ягъни тегендәгеләрнең ыру канын яңартып, нәсел-нәсәп ботакларын ныгытып...

— Үз авылымда минем мондыйны ишеткәнем дә, искәргәнем дә булмады. Менә бу, ичмасам, феномен дисәң дә феномен! — дип тел шартлатты Акбашев.

— Үзе инде... Ә ни сәбәпле? Имештер, Чуарның карт тирәк төпләреннән бәреп яткан көмештәй саф чишмә суының шифалыгыннан, аннары тагы юкә урманының аланнарында пешеп өлгергән җиләкләрнең куәтеннән килә, ди, гел малай тудырып ятмага сәләт, һе-һе... Авыл уртасында үтә торган сабантуйларына да егет-җилкенчәк, ярыштан битәррәк, әнә шул кызлар җәһәтеннәнрәк җыела да инде. Тагы әйтерем булсын...

Хәнәфи инде сөйләгән хәтлесенә тагы ни өстәргә җыенгандыр, әмма аңа ары ялгап алып китәргә әлегә насыйп булмады: тегендә, клубның зал өлешендә ишек ачылган, идән сайгакларын кыштырдаткан тавышлар ишетелде, һәм менә инде китапханә бүлмәсенең дә ишеге төбенә кадәр ачылып китте.

Иң алдан башына кырпулы бүрек кигән, сызылып киткән тар мыеклы абзый килеп керде — бусы совхозның умартачысы һәм ат җигеп балаларны мәктәпкә йөр-

түче Рәҗәп карт иде. Аның артыннан ак мамык шапкалы, көләч кенә йөзле хатын — клуб мөдире дә, китапханәче дә, бер үк вакытта почтальон да булган Зәйтүнә һәм киң, калын җилкәле, әмма ябыграк чырайлы бригадир Сәгыйть атлап үтте.

Болар тыйнак кына исәнләшеп, хәл-әхвәл белешергә өлгермәде, тегендә янә аяк кыштырдаган тавыш ишетелде һәм китапханәгә, тыштан әллә никадәр саф, салкын һава ияртеп, бары да диярлек мамык шәлләргә төренгән җиде-сигез хатын-кыз килеп керде. Болары ферма эшчеләре — башлыча, сыер савучылар иде.

15

— Юк ла инде, җыелыш та, утырыш та түгел, без менә Хәнәфи Бариевич белән сезнең янга бераз гәпләшеп алыр өчен, ягъни хәл-әхвәл белешү нияте беләнрәк килгән идек.

Акбашев бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты. Халык әллә ни күп җыелмаганлыктан, алар, клубның зал өлешенә күчмичә, шушында, китапханә бүлмәсендә генә, утырышып калганнар иде. Хатын-кызлар мамык шәлләрен иңнәренә шудырып төшергән яисә пальто, плюш жакет эчләреннән суырып алып, урындык артларына элеп куйган, һәм барысы да диярлек, изү төймәләрен ычкындыра төшеп, бик иркен сулыш алуда иде. Акбашев аларның байтагын фермада кичке савым вакытында күреп өлгергән, хәтта кайберләре белән аз-маз сөйләшеп тә алгалаган, тик ул һичберенең исемен белми иде.

— Гәпләшергә икән гәпләшергә... Без әзер! — дип елмайды нәкъ Акбашев каршысында, өстәлнең икенче ягында урнашып алган ярыйсы ук өлкән яшьләрдәге хатын. Ул коңгырт чәчен шома иттереп тарап, баш артында бәләкәй генә төенгә укмаштырган һәм аңа ярыйсы ук зур тарак та кадап куйган иде. Елмайган чагында аның тигез кара кашлары югары чөелеп, маңгаенда байтак кына сырлар хасыйл булды, әмма иң күркәме — ике яңагы да матур булып чокыраеп куйган иде. Бригадир хатыны Рәхилә иде бу. Рәхилә, шул арада елмаюын сүрелдереп һәм гәүдәсен чак кына бора төшеп, иренә эндәште: — И син дә инде, Сәгыйть, җүнләп дәшә белмәгәнсең. Өебез иркен, өстәлдә самовар гөжләп калды, бергә-бергә чәй җоткалап кына гәпләшеп утыруларга ни җитәр ие!

Ишек төбендә Рәҗәп карт белән янәшәдә калын сырмасын җилбәгәй җибәреп утырган Сәгыйть, какча йөзен чытып, үзенчә аклангандай иттерде:

— Соң ни бит... Фермада җөргән чагында ук әйткән ием дә бит... үзләре инде...

— Сөйләшү өчен монда да бик әйбәт,— дип үз сүзен кыстырды Хәнәфи.— Ә тегесе аның соңыннан да качмас әле...

Шулмәлне Рәхилә янында утырган зур, алтынсу алкалы хатын, күршесенең колагына таба иелә төшеп, шыпыртлап кына әйтә куйды:

— Көн тәртипләре дә жук икән... болай хәл-әхвәл белешү генә булгач, тегеләрне дә, дим, телевизор төбеннән кубарып алып, үзебезгә ияртәсе калган, Рәхилә апа!

Монысы кулы белән борын төбеннән чебен-черкине кугандай гына иттерде:

— Таптың: аларның тегесе теге җакта, бусы бу җакта ич. Җүнле сүз чыгарып, уңайга сукаларлар дип беләсеңме әллә?

Ике хатын, үзара шыпыртлап кына сөйләшсә дә, аларның сүзен барысы да диярлек ишетеп алды. Бу исә Мөслим Акбашевка, сүз очын эләктереп алып, йомгакны тәгәрәтеп җибәрергә бик әйбәт булды.

— Килми калганнарга үпкә тотмыйк, вакыты житкәч, алар белән дә сөйләшенелер... әле бер генә дә түгел,— диде ул, мөлаем гына көлемсерәп.— Сез көн тәртибе дисез инде. Бу юлга җыелыш ук түгел түгеллеккә, әмма, шулай да, бәлкем, сез хаклыдыр: бәләкәй генә булса да, көн көтүебезгә караган нәмәрсә кирәктер. Алайса, һем... фермагыздагы хәлләр хакында чакчак кына...

Һәммәсе дә сагайган бер кыяфәттә директорга төбәлде. Ләкин Акбашев фермадагы эшләренә бәйләнүнитү түгел, киресенчә, боларның сырт йоннарын уңайга таба сыпыргандай иттерде: ферма каралтыларының төзеклеген, мал-туарның ярыйсы ук көр булуын мактап алды, азыкка шушындый кытлык елны әрәм-шәрәм итүләргә юл куелмавын аерата хуплады, ул да түгел, ел тәүлегенең бу айлары өчен савымның да әйбәт кенә булуы куанычлы күренеш икәнлеген әйтте. Ахырда, бар күзәтүләренә нәтиҗә ясагандай, Чуар авылында чынчынлап уңган куллар эшләгәнлегенә беренче килүендә үк тәмам ышана язганлыгын сиздерде.

Мондый сүзләрдән бүлмәдә утыручыларның һәркай-

сының йөзенә җылы һәм якты нур иңде, авызлар ихтыярсыздан җәелеп китте. Рәхилә дә рәхәт елмаюда эреп киткән иде, әмма ул, иң беренчеләрдән булып, уч төбенә йөткергәләп алды да үткен күзләре белән Акбашевка текәлде:

— Салпы ягыбызга салам кыстыруыгыз гына түгел микән... кем, Мөслим Гайнаныч, ә?

— Нишләп? Уйлаганымны ихлас күңелдән әйттем,— диде Акбашев, шаяртырга һич уй-исәбе юклыгын аермачык сиздереп.— Ә теге фермаларда исә... Совхозның ай-һай ла икән хәлләре! Бигрәк тә Әҗердә.

— Бу кышны һәркайда да кытлык,— диде алтынсу алкалы хатын, карашын чебен күзләгәндәй һавада йөртеп, янәсе, яңа директорның сүзләрендә аның өчен ис китәрдәй һич кенә дә яңалык юк.

— Килешәм,— дип ияк какты Акбашев.— Әмма сездә азык ягы мулрак, ә фермагыз иркенрәк күренде әле миңа... Әллә, дим, симертәсе малларның беркадәресен Әҗер фермасыннан сезгә күчерергә микән? Бер илле-алтмыш башны, ә? Менә шул хакта...

Акбашев әйтер сүзен әйтеп бетермәде, кисәк, сулышы киселгәндәй, бүленеп калды: бүлмәдәгеләрнең һәммәсе дә шул арада йөзләренә караңгылык иңдереп, кашкүз җимереп өлгергән иде.

Иң әүвәл өстәлнең түр башындарак утырган бәләкәй генә, йомры гына хатын чәчрәп купты:

— Әҗердәнме? Шулхәтле малнымы? Үзләре анда азыкны әрәм-шәрәм итеп җатсын да...

— Көзгелектә ни караганнар? Анда бит малны азыкка карабрак булганнар ие,— дип күтәреп алды алтынсу алкалы да. Аның күз карашы, һавада «чебен күзләүдән» капыл түбән иңеп, төкселәнеп, директор йөзенә төбәлгән иде.— Жу-ук, азык җәһәтеннән безнең үзебездә дә хәлкәйләр хәл әле, җаманның да җаманы!

Тәрәзә төбендә, читтәрәк утырган янә бер хатын, урыныннан кубып, һавада кул селтәргә кереште:

— Һаман да шул бер Әҗер! Җәшелчәлекләренә барып булышмага да, урманда җәшел җафрак-ботак җыйганда да, бүтәнендә дә җәрдәмгә безләр. Һаман да шулар чоңгылда! Иманнары кайда икән?

Акбашев аптыраган, хәтта каушаганрак кыяфәттә калган иде. Бу хәлдә Хәнәфи өлгерлек күрсәтергә ният итте:

— Инде дә корыган чытырман үзегез: шырпы тидермәс борын чытыр-чатыр кабынырга гына торасыз! —

дип гүелдәде ул калын, күкрәк тавышы белән.— Соң, монда мал китертү турында болай гына, киңәш-табыш итешү төсендә генә әйтелде ләбаса! Сынап карау өчен, дигәндәй...

Рәхиләнең тигез, кара кашлары шундук маңгай сырлары өстенә менеп китте:

— Сынап карау өчен? И Хәнәфи туганкай, безне сыныйсы җук, без инде күптән сыналган! — Менә ул, өстәлгә таянган хәлендә, учын җәеп җибәреп, бүтәннәргә тыелып торырга ишарә итте, үзе исә күзләре белән кемнедер эзләштерде.— Әһе, зоотехник Заһидә Гәрдәлесенә кайтып киткән инде, ну, җарый.— Моның соңында борылып, бригадир иренә төбәлде: — Сәгыйть, дим, ул тиклем өстәмә малны сыйдырып булырмы? Ни уйлыйсың?

Тегесе малахай бүреген бөтәрләгән шәйгә җилкә тартыштырды:

— Соң, бик тырышсак, бик кысынкылансак кына инде... Аннары, өстәмә фураж биреп, бардасыннан-мазарыннан җитәрлек өлеш чыгарсалар гына...

— Анысы, әлбәттә, тиешенчә бирелер,— диде Акбашев.

— Ярар, ничек тә сыйдырырбыз, Мөслим Гайнаныч,— диде Рәхилә.

— Менә бит,— дип елмайды Акбашев.

Шулмәлне Хәнәфи, Әҗер кешесе буларак, үз әрнүен сиздермичә түзә алмады:

— Шулхәтле дә каныгырсыз икән безнең Әҗергә! Тетмәсен тетү генә түгел, җир йөзеннән себереп үк ташлар идегез бугай!

Болай дию белән ул, әлбәттә, сөйләшүне бөтенләй бүтән тарафка борып җибәрде, ләкин инде хәзер гәп дулкыннары, баягыча чал сыртланып, әпен-төпен чайпалмыйча, йомшак һәм ыспай гына тирбәлү җаен алды.

— Бик тә хәҗәте бар ие! — диде тәрәзә төбендәге хатын көр генә тавыш белән: аның йөзенә караганда, ул менә-менә көлеп тә җибәрер иде шикелле.— И Хәнәфи гөлием, инде оныттың дамыни теге чакларны? Сугышлар бетеп, дим, беренче корган сабан туебызны? Тырыйк-тырыйк, һай, кыйландырган да иең соң җаралы аякларың белән кичке уенда! Җаныңда көмеш җәшьләрен җылтыратып Рәсүләң бөтерелмәсә иеме? Мин үзем ни, тол солдатка башым белән, суырып кыйнайлар алырдай хәлләрдә ием! Ә безнең кызлар соң?.. Кая анда каныгу-кыерсытулар! Үзеңә дә, Хәнәфи дус-

каем, ыру-тамырыңны җаңартмага безнең авылныкы бик кенә дә җарап куйган булыр ие җугыйсә...

Хатын-кыз, бары бердәм булып, шау-гөр көлешеп алды. Хәнәфи дә бирешергә теләмәде:

— Һе, минем Рәсүлә сынаттымы әллә? — дип күкрәк киерде.— Тупырдатып өч малай, бер кыз табып бирде!

— Хут анысы җарый... шәп, булдырган! Рәхмәт үзенә!

— Ә каныгу-кыерсыту дигәннән... сез үзегез! — дип үз сүзен кыстырды алтынсу алкалы хатын, Хәнәфине авырттырыбрак чеметергә чамалап.— Соң, теге заманны хәтсез авылларны кушып колхозны эреләндерергә тотынгач, безнең Чуарны төбе-тамыры белән җотарга аз тырыштыгызмы?

— Безмени? Бөтен Әҗермени? Яхъя Таипыч бит... Ул да югарыдан кушкангарак кына,— дип төшендермәкче булды Хәнәфи.— Ә соңыннан чигенмәдеме, буйсынмадымы сезгә? Менә бит культура учагыгызны ничекләй яңарттырды! Телевизор белән магнитофонга тикле бар, бүтәнен әйткән дә юк!

— Хе-хе, җаңарттырды! — дип көлеп җибәрде Рәхилә.— Председатель булуы өстенә үзен Татарстан депутаты итеп сайлагач бит инде болары!

Бу минутта һәммәсе дә күз карашы белән Акбашевның күкрәгендәге депутатлык значогын да, аның үзен дә кармалап, сыйпаштырып алгандай итте, янәсе: «Менә инде син дә депутат икәнсең, ни яхшылыклар кылырсың безләргә?..»

Шулмәлне Рәҗәп карт, сүзгә катышмыйча утыруына, ниһаять, чик куеп, тамагын кыргалый-кыргалый, күңелендәгене әйтергә булды:

— Син... кем... иптәш... Мөслим энем, безнең авылның күчереләсе хакында беләсеңдер инде, име? Әһе, беләсең. Мин ни... әгәренки-мәгәренки, алтын алмам тәгәренки дигәндәй, безнең Чуар шушында утырган җирендә утырып калса, ничек булыр ие, дим? Җәгъни дә бөтенләйгә күчерелмиенчә, куптарылмыенча, ә?

Үтәдем белән Гәрдәледәме, Чуардамы яки Әҗернең үзендәме берәр җыелыш-мазар булса, һич югы менә болай гап-гади гәп корып җибәрсә дә, халык бу хакта сүз кузгатмый калмый иде. Бүтәннәр белән бергә, әлбәттә, Хәнәфи дә колак торгызды. Әмма яңа директор да һичнинди яңа сүз әйтә алмады, нибары:

— КамАЗның санитарный зонасына эләккәч, ни

хәлләр кыласың инде,— дип муенын эчкә батыру беләп генә чикләнде.

— Зона диләр шул, зона... Безгә ким дигәндә бер унике җыллар кагылмыенча түзсәләр икән хет.

— Нишләп тап унике ел?

— Соң, минем дә дөнҗада җәшәр чамам шулхәтле калды... Минем бабай да, әтәй дә җитмеш дүртне тутырып, җитмеш бишенчегә чыккач, вафат булган. Аларныкыннан һич уздырасым килми. Бу фани дөнҗада артык мәшәкатьләр тудырып җөргәнче, тегендә мәңгелек җалга, дим, барып җатуларың рәхәтрәк булырдыр...

— И җәшәрсең әле, Рәҗәп агай, җәшәрсең! Әле кияү җегетләредәй күренәсең, сөбханалла!

— Инде әгәренки, ходай әмер биреп, артыгын җәшәргә насыйп була икән, ул чагында... Һо, жук, барыбер ни Җаңа поселокка, ни хәттә Җаңа каланың таш капчыгына башымны тыгасым килми!

Бу сүзләре белән Рәҗәп карт бүлмәдәгеләрне бер көлдереп алмакчы иде бугай, ләкин һичкем иренен дә кыймылдатмады.

Ул арада өстәлнең түр башында:

— Ә ҚамАЗны без чакырып алганмыни, аның зонасына без үзебез теләп кергәнмени? — дип чытырдап алды йомры хатын.— Бик кирәксә, әнәтерә, үзе чигенсен! Без, ичмаса, зона дигәннәренең читендәрәк калыр иек...

— Хе-хе, син нәрсә, ҚамАЗны арба җәисә чана, һич жугы паравыз дип белдеңме әллә! — дип, башын артка таба чайпалдырып, гүелдәп көлеп җибәрде бригадир Сәгыйть.

Ләкин аның шаркылдавына да кушылып китүче булмады.

Моннан ары инде, әле бу тарафтан, әле теге яктан, кайсы моң-зарын ачык сиздереп, кайсы моң-зарга ачы юмор да катнаштырып түгелергә тотынды:

— Күченәсе булгач, җорт бурасын түгел, хәтта ки мунчаныкын да бураттырмыйлар. Авыл Советы тыкшынырга күз тозырайтып кына җөри!

— Их, үзебезнең прокурор Зөфәр әллә кайда Қазагыстанның Күкчәтавында законнар саклап җата. Монда бер кайтып, актарынып караса, безне җаклардай берәр нәмәрсә китереп чыгармас ие микән?

— Ә сез законның үзенә орынмыйчарак кыйланыгыз, кайчагында, үзенә каты кагылмасаң, күз йомып та калгалый бугай ул...

— И Хәнәфи, сиңа шулай сөйләнергә җиңел шул: сезнең Әҗер КамАЗга сигез-тугыз чакрымнарда ук, ә безгә?

— Мунча дигәннән... Шимбә-якшәмбеләрдә авылыбыз төтенгә күмелә. КамАЗны «нервы тегермәне» диләр әнәтерә. Безнең мунчаларда аны коручыларның ничәмә җөзе җан җаңартып, дәрт-дәрман җыеп китмәгәндер инде, ә? Ичмасам, шунысын аңласыннар ие!..

— КамАЗ анысы хөкүмәткә кирәклеккә бик кирәктер инде. И шулай да... без дә хөкүмәтнеке түгелмени?

— Хөкүмәтнеке булганга күрә, кайгырта да бит инде: зонага бикләнеп, черешә күрмәсеннәр, сау-сәламәт яшәсеннәр, терекле булсыннар, ди.

— Әнәтерә Казан каласының үзендә әллә нихәтле завод-фабрик. Арада әллә ниндиләре бар. Берәрсенең әйләнә-тирәсеннән берәр кайчан берәр кемсәне читкә себергәннәре булдымы икән? Рәхәтләнеп җәшәп җата халык, аны-моны уйламый да...

— Ием, җәшьләр ни кылса кылыр, Җаңа поселокка күчәме җәисә Җаңа калага китәме, үзләре белер ие. Ә безгә туган туфрагыбыздан кубарылмаенча гына Чуарыбыз белән бергә-бергә картаясы ие шул...

— Карт имән кебек, тәмам корыганчы диген...

Рәхилә, үзенчә дәрәҗә саклагандай кыланыпмы, әллә болар түгеләсен түгеп бетерсен дә яңа директор Чуарның бар булган нечкә якларын миенә сеңдереп калсын дипме, моңа кадәр дәшми-тынмый гына утырган иде, менә инде ул да кымшангалап алды һәм:

— Унике-унбиш җыллар безгә тимиенчә түзә алсалар икән шул, җаннарыбыз тынычланыбрак торыр ие, ичмаса,— дип, бик тә авыр көрсенеп куйды.

Шундук аңа янәшәсендә утырган алтынсу алкалы үзенекен кушылдырып җибәрде:

— Казан вокзалында поезд көтеп, чемодан өсләрендә утыргандай җәшәп җатулары бер генә рәхәт түгел шул...

Бу минутта һәммәсе дә күтәрелеп яңа директорга күз төбәде. Акбашев ике кулын да өстәлгә салган көенчә, керфек тә селкетмичә, бер ноктага төбәлеп, үтә җитди кыяфәттә уйчанланып калган иде. Ямьле Зәй буенда утырган үз туган авылын исенә төшереп, онытылып китүе булды микән? Бераздан ул да, ниһаять, тирән иттереп көрсенеп алды:

— Ярар, ничек тә сез теләгәнчә итәргә тырышырбыз...

Бүлмәдәгеләр бары бердән җиңел сулап куйды.

16

Икенче көнне иртәнге планеркада яңа директор Хәнәфигә бөтенләй бүтән кеше булып тоелды. Юк, әлбәттә, Акбашев алай карап торырга һичнинди дә үзгәреш кичермәгән, шул ук мөлаем-ачык чалымнар, тавышын күтәрмәс, кубарылып орынмас, әмма аның сүз сөреше, китереп чыгарган хикмәтләре...

Утырышка җыелырга тиешле кешеләр җыелып беткәч, Акбашев бер тын ара үз эченә бикләнеп, уйчанлапып утыргач, кинәт барысына берьюлы күз йөртеп чыкты да сәер генә көлемсерәү аша әйтә салды:

— Заманында үз туган авылымда, аннары ахыргы совхозда менә шушылай ук баш булып тотынгач, беренче елның язында сыерларга түбә саламнарын төшереп ашаткан идек. Анда ферма түбәләре гел диярлек салам иде. Ә сездә ферма каралтылары шәп, түбәләре тоташтан шифер, нәселле мал-туар... Ул нәсел сыерларына шифер ашатып була микән?

Бу һәммәсен дә сискәндереп җибәрде. Иреннәр капыл кысылды. Ә директор тавышын тамчы да үзгәртмичә, янә сорау белән төбәлде:

— Совхозда малга ашатырлык силостыр, печән-саламдыр, тәгаен күпме калды икән, кем әйтә ала?

— Кара исәп белән исәпләгәндә...— дип тотынган иде баш зоотехник Гомәр, әмма аны Акбашев капыл бүлдерде:

— Юк, ак исәп белән... Эһе, белмисез? Бер айга микән, әллә ай ярымга ук микән? Тәк, тәк... Ә бит җәйгә чыкканчы, ай-һай, күп яшисе әле! Былтыр күз, ишетүемчә, сезнең Чаллы тирәсендәге кайбер хуҗалыклар Украина, Кубань якларына барып, салам пресслатып алып кайткан, о сез пишләптер... кһем... да...

— Үзебезнеке җитәр дә кышны-язны ничек тә ерып чыга алырбыз әле диебрәк уйланылган иде шул,— дип аңлатмакчы булды Гомәр.

— Басу хәлләренә арт белән борылып, күктәге болытка карап уйланылды микәнни?

Җавап кайтаручы булмады. Байтагының йөзендә кырыс-уйчан да, хафалы да чалым. Хәтта моң-сагыш төсмере дә бар сыман. Ә Акбашев һаман да шул бер тон белән һәм әйтер фикерен һаман да шулай сорау рәвешенә төребрәк, ут тамызгалауда булды:

— Ары таба да төрле эрәм-шәрәм итүләргә, бигрәк тә Әҗер фермасында, күз йомып йөрүләр килешерме

бу хәлләрдә? Азыкның бөртеге дә кадерле чакны, кыенлыкны ходайга сылтап, бер үк вакытта сан-исәпне бар дип белмичә, борын салындырып яшәү килешәме? Һәркемнең дә персональ җаваплылыгын онытып торыйкмы? — Кинәт ул бик тә авыр сулап куйды.— Мал-туарны җәйге чорга күтәрәм хәлендә чыгаруның ни мактанырлыгы бар? Сау-сәламәт булсын ул! Җитмәсә, әнә КамАЗ төзүчеләре дә сөт-май, ит дип, аның да һәйбәт сыйфатлысы дип, сорап ята түгелме?

Янә дә тынлык. Йөзләрдәге күләгә куера гына төште кебек.

Акбашев өстәлгә сузып салган кул сәгатенә карап алды:

— Нәкъ сәгать тугызда Чаллыда киңәшмә... Төш турыларына әйләнеп кайтырмындыр. Аңарчы алты-җиде автомашина әзерләп булырмы? Әлбәттә, ышанычлы, шәп кузовлыларны!

— Булмаса... булырдыр,— диде Әҗер управляющие Мөхлис.

— «Дыр-дыр»...

— Булыр! — дип кырт кисте баш инженер Рәкыйп.

— Сәфәр озын гына, дөрес, юлы әйбәт, асфальт юл. Монысында үзем дә китәрмен. Ә шоферларны кисәтерсез: бу юлында куна калырга туры килер. Машиналарның икесенә печән оны, ягъни яшь маллар өчен витамин төясәк, калган хәтлесенә прессланган салам. Анда безнең совхозның...— Акбашев кисәк бүленеп калды, әмма сүзен шундук төзәтеп куйды:— ...андагыларның ким дигәндә бер ел-ел ярымлык резервлары бар әле. Бөлмәсләр! Әле бер генә дә барасы булмас... нишлисең...

Кабинеттагыларның йөзенә чак кына яктылык нуры инде шикелле. Күбесе җиңел сулап куйды, ә беришесе сизелер-сизелмәс кенә үзара күз атышып алды: янәсе, «сизденме, тегендәгеләрне нинди рәхәттә калдырган...»

Монда түр өстәл артында утырган директорның да калынча кара кашлары язылыбрак китте шикелле.

— Ә болай совхоз авылларында халыкның күңеле көр диярлек. Дөрес, ыңгыр-шыңгыр йөрүчеләр дә, пыскып кына җан асраучылар да бөтенләй үк юк түгел икән... Бер җыелышып сөйләшеп алганда зыян итмәс.

— Нәрсә, совхоз активы җыябызмы? — дип сорады партком секретаре Садыйков.

— Актив? Нишләп? Иң әүвәл үзебезгә шушында дирекция белән парткомда ныгытып сөйләшәсе булыр.

Әлбәттә, рабочком белән комсомолны да тартып... Хәер, совхозда бер җыелыш уздырмыйча да ярамас, тик ул тантаналы булыр.

— Тантаналы?

— Әйе. Соң, ничек инде Яхъя Таипычны озатмыйча гына ярасын ди? Бу кышны без сезнең... бер безнең совхозда гынамыни, бүтәннәрдә дә хәлләр хәл бит — анысын инде ходайга сылтыйк... Ә Яхъя Таипычның үткәндәге кылган хезмәтләре, яулашкан үрләре? Үкенечкә калмасын, дим... Үзенә бик әйбәтләп бүләк тоттырып, җылы сүзләр әйтеп вә һәм шәп концерт биреп, ә!

— Әле чирләбрәк киткән ул: йөрәк, ди, кан басымы, ди, аннары нервы, ди, тагы... Санаторийга дигән путевкасын да кире тапшырмакчы бугай. Больницкә салмагайлары үзен...— дип күпләр өчен күңелсез яңалыкны әйтеп салды Мөхлис.

— Шулаймы? Менә бит... Димәк ки, тантаналы кичәне һич кичектерергә ярамас. Бәлкем, аның шифасы да тияр: йөрәге дә үз оясына тынычлап кереп утырыр, нервысы да үз эзенә басар, ә?

Йөзләр, ниһаять, тәмам ук нурланып китте.

Ләкин Акбашев, өстәлдә яткан сәгатенә янә күз төшереп алгач, шундук кире кайтып, көндәлек мәшәкатьләр сукмагына басты:

— Ә партком утырышында... кһем... әйе, безгә, мөгаен, шулай ук һич кичекмәстән, белгечләрне генә түгел, аерым коммунистларны да иң җаваплы участокларга беркетмичә ярамас. Фермалардагы хәлләр хакында көннекен-көнгә менә шушында исәп тотардай иттереп! — Моны әйткәч, ул башын партком секретарена таба борды.— Менә шул беренче утырышта ук, Әхсән Садыйкович, сезнең «акбур белән кара тактаны сагынуларыгыз» турында да ачыграк сөйләшмичә булмас. Директор иң әүвәл парткомга таянмыйча, кемгә таяна ала инде, ә?

Садыйков ык-мык итеп калды, маңгаендагы күзлеге кулына күчте.

— И шулай ук рабочком... Берәүнең гыйлем сеңдереп, укып йөрүләре, ярый, бик әйбәт диик... Ләкин рабочкомны айлар буена иясез тотулар шәпме? Яман түгелме? Ә бит бар сездә рабочкомны уртага җигелеп тартырдай кеше. Бар! Хезмәт юлы зур, халык алдында абруйлы, сүзе үтемле.— Соңгы сүзләрен әйтеп бетергәндә, Акбашев күз кырые белән генә, әмма тирән мәгънә салып, Хәнәфигә карап алды.

Бу мизгелдә Хәнәфинең йөрәге жу итеп, бар гәүдәсен салкын дулкын кымырҗытып узды...

Биш-ун минут үтүгә яңа директор, куе яшел «уазик»ка утырып, Чаллы тарафларына китеп тә барды.

Конторада эш бүлмәләре булган белгечләр, маңгай җыерчыкларын сырландыра-сырландыра, колак артын кашып утырыр өчен, әкрен-әкрен генә үз урыннарына таралышты. Калган халык урамга, саф һавага, чыкты.

Шунда ни турында сүз кузгатырга белмичә аптырабрак торган төркем эченнән берәү папиросын бик тырышып суырды-суырды да:

— Борчакны ныгыттырып куырырга чамалый бу! — дип, һәркайсының уртак уен ярып салды.

Хәнәфи, башын түбән игән көенчә, тыгыз карны изә-изә мастерскоена таба атлады.

Көн тып-тыныч иде. Җәяүле буран алар Чуарга барган төнне тукталып, әлегә зәһәр шаярудан тыелып тора иде.

Юл-сукмак кырыйларында кар бөртекләре җем-җем итә. Табигатьнең җәяүле бураны тынган да тынуын... Хәнәфинең үз күңелендә зилзилә бураны кубарга җыена — иңнәренә күтәрә алмаслык йөк булып, коточкыч кыя-тау аварга тора сыман иде.

«Менә сиңа яшьти!.. Чуарга бармаска кырт кисәсе калган да бит... Барган тәкъдирдә дә артыгын белдекле булып кыланмаска, тиккә тыкшынмаска итәсе икән... Димәк ки, Чуарга баруларында аны сынавы булган. Инде менә Хәнәфинең үз хәлләре дә чуарланып китте. Бөтен дөньясы чуар!.. Их, яшьти, яшьти, минем башны тыгарга итмәсәң, рабочкомлыкка бүтәннәр беткәнмени совхозда?..»

17

Хәнәфи көне буе шул хакта уйлады. Мастерскойда, азрак онытылырга тырышып, теге эшкә тотынып, бу эшкә ябышып карады, әмма күңелендә инде хәсрәт булып ояларга өлгергән нәрсәне тарату мөмкинлекләрен таба алмады. Кулыннан эш бармады. Әлбәттә, озакка сузмаслар, рабочком утырышын шушы көннәрдә җыярлар да... Зиннур барыбер китәсе кеше — болар совхозыннан шулай ансат кына котылуына чамасыз сөенер инде. Ә Хәнәфи? Моңа кадәр гелән дә бүтәннәр ышыгында яшәргә күнеккән җаны белән ул андый йөкне тарта алырмы? Берзаман юк кына нәрсәгә дә сөрлегеп,

авыз-борын канатмасмы? Кичә Акбашевка ияреп Чуарга барганына кайта-кайта үкенде Хәнәфи.

Көндез төшкелеккә кайткач, Хәнәфи башына төшкән хәсрәтне хатыны Рәсүләгә сөйләп биргән иде, тегесе, бермәл күзләрен челт-челт йомгалап торгач, гадәтенчә кулларын күкрәге өстендә кушырды да:

— Җаңа директор әйтте, дисеңме? Һай гынам, андыен җөкне сиңамы соң өстерисе! — дип ухылдап куйды. Бүтән сүз әйтмәде дә.

Аның ухылдап куюы исә Хәнәфинең пошаманын көчәйтеп кенә җибәрде.

Хәер, хатыны Рәсүлә әллә ни төпле киңәш-табыш бирердәй хәлдә дә түгел иде: аның күңелен дә, зиһенен дә бүтән төрле хафа — һаман шул бер кызлары Рәмилә турындагы уй-исәп — янә биләп алган иде. Һәм ул ачы нәрсә, әлбәттә, Хәнәфинең үзен дә читләтеп үтмәде. Шулай инде: сөремгә сөрем кушылучан...

Кичә кич инде шактый соңарып, Чуардан кайтып килгән чагында, Хәнәфинең кәефе болай ярыйсы гына көр һәм күтәренке иде. Әмма өенә кайтып керсә, аны кызлары Рәмилә турында һич тә матур булмаган хәбәр көтә иде. Бу күңелсез яңалыкны аларга Чаллы Сельхозтехникасында куна-төнә эшләп яткан уллары Рәмзи алып кайткан иде. Аның сөйләгәне шул: тегеннән, дөнья бетереп әйләнгән туристик экскурсияләреннән, чаллылар һәммәсе дә кайтып төшкән, әмма алар арасында Рәмилә генә юк, ди. Моны Рәмзигә Чаллыда барын да күзәтеп һәм белеп яшәгән Габделбәр әйткән. Рәмзи, билгеле, өнсез калган һәм, йөрәгенә түзә алмыйча, сеңелесенең юлдашы булган Светаны эзләп киткән. Тапкан ул аны: шул ук тулай торакта, күрше бүлмәләрнең берсендә яши икән. Ул кызый баштарак: «Мәскәүдә бер төркем Казан яшьләре белән төшеп калды ул. Мәскәүне тагын да әйбәтләбрәк йөреп чыгарга, бар булган музейларын карап бетерергә дип... Озакламас, кайтып та төшәр»,— дигән. Әмма Рәмзи: «Нинди яшьләр, кемнәр ул?» — дип төпченебрәк, кырысланыбрак сорашырга тотынгач, Света чын-дөресен әйтеп салган: «Рәмиләне аны... теге мыеклы егете моннан бер атна элек үк Киев каласында алып калды. Анда аның ниндидер туганнары яши икән, әнә шуларда кунак булып ятарга, киногa, театрларга йөрергә дип...» Менә шул: сер дигәне хикмәт, хикмәт дигәне михнәт... Кыз башы белән бөтенләй уйламаган-белмәгән ят кешеләрдә

ниткән кунак булулар ул? Инде атнадан артык бит! Кайда монда әдәп һәм намус, кайда, һич югы, оят?

— Ул бит әле эштәге кеше исәпләнә,— диде Хәнәфи, бу ямьсез яңалыкны ни рәвешле сеңдерергә белмәстән.— Ичмаса, әнә шунысын җайлау хакында... теге кем... үзебездә яшәгән белорус марҗасына берәр үтенеч хәбәре салгандыр, бәлкем, мутлак җан?

— Анысы шулай инде: җыен җахшылык белән изгелекне аңа Мила апасы эшләп тора. Син, улым, зинһар, аның үзен табып, барын да төпченеп белеш әле! — дип үтенде Рәсүлә, җанлана төшеп, әмма ул шуның артыннан ук тирән көрсенеп куйды.— Аңа, ул ипле җанга да бөтенесенә бер җулы күз-колак булулары бер генә дә җиңел түгелдер инде. Аның канаты астында бер безнең Рәмилә генәмени? Ике дистәләп бугай бит алар, ул җенлеләр...

Рәмзи, бүген Людмила Крутьконы күреп, аңардан берәр нәрсә ачыклый алса, кайтып төшәргә тиешле иде. Инде берни дә белешә алмаса, ул, озын юллар үтеп, кайтып йөрмәячәген кисәтеп куйды. Әмма бүген аның өйгә кайтып төшүе этисе Хәнәфи өчен үлеп кирәк иде. Бу төпчек улы инде хәзер хезмәттәге уң кулы гына түгел, гаиләсендә иң ышанычлы һәм төпле терәгенә әверелеп куйган иде. Рәмзи белән киңәш-табыш итәсе бик-бик килә иде аның: көтмәгәндә курыныч рәвештә калкынып чыккан әлеге «рабочком» мәсьәләсендә ул ни әйтер икән?

Кичке караңгыда мастерскоеннан кайтып килгән мәлендә, үз урамына кергәч, Хәнәфи өйләренең бар тәрәзәләре дә балкып торуын күреп алды. Рәмзиләре өйдә булганда шулай ялт иттерә инде ул бар өйне... Бүтән ихтималны исәпкә кертмәстән, Хәнәфинең эченә җылы йөгерде, җилкенеп китте: берәр юньле хәбәр алып кайткандырмы-юкмы, әмма бүген алар төпчек улы белән әйбәтләп киңәш-табыш итәчәк, димәк...

Шул уй белән капкадан керде, шул җылы өмет белән өй ишеген каерып ачып, бусагадан атлап үтте...

Атлап үтте дә, кисәк тораташтай катып калды... Алгы өйнең ян элгечендә һәйбәт мех якалы ике пальто эленеп тора: берсе хатын-кызныкы, икенчесе ирләрнеке — кыска итәкле, элгеч өстендә шундый ук шәп мехтан тегелгән ике бүрек, берсе йомры, күперенке, икенчесе кыскарак йонлы, козыреклы... Элгеч астында идәндә исә модный сапожкилар белән янәшәдә җылы эчле,

шәп күнле ирләр ботинкасы... «Димәк, димәк... менә сиңа пәрәмәч икән лә!..»

Кабаланып өстеннән сырмасын, башыннан бүреген салды, әмма аларны элгечкә элеп тормыйча, алгы өйнең ишек төбе сәкесенә генә атты. Аның соңында киез итекләрендәге галошларны ычкындырды.

Хәнәфи, какча яңакларын кыймылдаткалап, түр якка тупса аша атлап үткәндә, тегеләр — кызы Рәмилә белән молдаван мыеккае Женя Мында — утырган җирләреннән кубып, аңа каршы киләләр иде инде.

— Исәнме, әтәй! Сау-сәламәт кенә эшләп йөрисеңме?

— Әлегә шөкер диярлек... Үзең соң? Үзегез... Күрәм-күрәм: буш кул селтәп кенә кайтмагансың, үзеңә сыңар да иярткәнсең икән...

— Соң, әтәй...

Күрешүләре болай җылы гына булды. Женя аның кулын аерата нык итеп кысты:

— Сез, зинһар, кичерегез инде безне!

Утырыштылар. Хәнәфи гадәтенчә диван почмагына сеңде. Күр инде, табын өстәле бөтенләй балкып тора лабаса: озын аяклы вазаларга иртәнге алтын кояш төсле эре-эре әфлисуннар, алсу йөзле алмалар тутырылган; мае, шикәре-вареньесы куелган. Өстәл башында кукраеп һәм тигез гөжләп көмеш самовар утыра. Теге кичне Рәмилә моннан качып киткән сәгатьтә дә ул шулай моңлы җырын сузып утырган иде. Ул, гомумән, урыныннан кузгатылмаган һәм бүгенгәчә үз җырын өзмичә саклап килгән, тик шушы кич өчен табынны гына бөтенләй бүтән рәвештә үзгәртергә мәҗбүр иткән сыман иде... Ләкин табып янына утырышырга дәшүче булмады, бүлмәдә кинәт кенә авыр һәм киеренке тынлык урнашып алды.

Хәнәфи күз карашын кызы Рәмиләгә күчерде. Кызының өстендә бик тә килешле тегелгән, әмма әкәмәт сәер бизәкле — алсу өслектә зәңгәр яшеннәр чатнаган, яшькелт йолдызлар җемелдәгән — күлмәк, үзе колак яфракларына алтынсу бөҗралар элгән, чәч өемен дулкын-дулкын иттереп күпертеп куйган, иреннәре һәм бит алмалары да, күлмәге төсенә кереп, пешеп-янып тора. Тик күз карашында гына сизелерлек җанлану белән бергә азрак инәлү-ялвару катыш өркү дә оялап алган сыман... Әйе, әле кайчан гына, нибары бер ай элгәре генә, бөтенләй бүтән кыяфәттә иде лә бу! Инде хәзер аның кызы Рәмилә дә кебек, ул түгел дә кебек...

— Ишетмәсәң ишет, этисе: өйләнешергә рөхсәт сорарга дип кайткан болар...— Рәсүләнең тавышы кисәк чатнап китеп, еламсырауга күчте.

Хәнәфи түр урындыкта тез өсләрендә кул кушырып утырган хатынына ялт кына карап куйды. Башта ул аңа игътибар итмәгән икән: хатынының кыяфәте үтә моңсу, күз төпләре дымлы, йөзенә тимгел-тимгел кызыл чыккан.

— Нәрсәү?

— Соң, эти,аның ни гаебе бар? Безнең бүтәнчә әмәлебез калмады. Сез инде...

— Аның Киевта менә бусының туганнарында кунак булып ятабыз дигәне дә күзгә төтен җибәрү генә булган икән.

— Соң, әни, анысы бит бүтәннәр өчен... вагонда калганнарга... Чит-ят халыкка барын берьюлы ничек әйтеп саласың, ди? Ә сиңа мин чын-дөресләп һәммәсен сөйләдем дә бирдем. Алайса, син дә, эти...

Рәмилә ашыга-кабалана этисенә дә сөйләп бирде: Киевта чынлап та Женя Мынданың бернинди туганнары да юк, алар анда театрга-мазарга йөрергә уйламаганнар да, Рәмилә иптәшләреннән аерылуга, Женя белән икесе, самолетка утырып, Одессага очканнар. Аннан алар шул ук Одесса өлкәсенең Молдавия белән чиктәш бер районына юл тотканнар — шунда зур гына поселокта егетнең әнисе, туганнары яшәп ята икән.

— Алар бик ошатты мине, хәтта ки яраттылар дияргә дә була!

— Башларың тәмамлай әйләнгән икән, и кызым! — диде Рәсүлә, ачы иттереп.— Әллә инде туй хикмәтләрен дә хәл итеп куйгансыз?

— Ансыз ничек инде, әнәй? Аның бәләкәен, җиңелчәсен тегендә уздырырга исәп, ә зурысын үзебездә, ягъни Чаллыда үзебез салган берәр кафе-мазарда...

— Үзләре рөхсәт сорарга кайттык дип кыланган була, үзләре әнә ниләренә тикле хәл итеп куйганнар инде! — дип уфылдап җибәрде Рәсүлә.

Женя Мынданың йөзе кызарып яна, ул, әлбәттә, татарча белми, әмма сүзнең ни турында куертылуын бик әйбәт чамалый һәм, баш каккалап, русчалатып, үз сүзен кыстырырга тырыша иде:

— Сез гафу итегез инде, без бер-беребезне югалтмаска уйладык...

— Соң, кызым, сиңа унсигез дә тулмаган бит әле...

— Ә син үзең кияүгә чыкканда, унсигезне тутырган

иденме соң? — дип, күзләре белән яндырып алды Рәмилә.— Авыл Советына язылышырга Айдаш абый тугач кына баргансыз түгелме соң?

Мондый сорауның биреләсен ана кеше бик абайлый иде: кайчакларда шулай аналар язмышы балалар язмышына да әверелеп куя, күрәсең... Рәсүләнең тавышы кисәк пышылдауга күчә язды:

— Ул чакны заманасы нинди ие соң, кызым?

— Хәзер дә замана кимен куймый, бик әйбәт куыра белә. Кайчагында башыңны кая куярга белми йөдисең.

— Без, ичмаса, авыл Советына барганчы, үзебезчә, мөселманча иттереп никаһланып алган иек... Ә сез? Моның белән чиркәүгә барырга җыенасыңмы әллә?

— Чиркәүгә? Һе, бардылар, ди... Сез, әнәй, әтәй, бер дә хафаланмагыз, без инде... без...— Рәмилә түш кабарта төшеп, әти-әнисенә бик тә серле-мәгънәле рәвештә караш ташлап алды һәм моңа тикле саклап килгәнен кисәк кенә ярып салды.— Без инде тегендә поселок Советларына язылышуга гариза биреп кайттык...

Бу сүзләр ата белән анага өсләренә салкын су койгандай тәэсир итте:

— Ничек, ничек?! — дип төбәлде Хәнәфи, муенын сузып һәм кашларын югары чөеп.

— Һай гыналарым, ни сөйлисең син, кызым! — дип кычкырып куйды Рәсүлә. Аның куллары ирексездән муены төбенә менде.

— Алар республикасында, әнә бит, закон тәртипләре йомшаграк икән: кызларга унҗидедә үк кияүгә чыгу рөхсәт ителә икән. Безнең рәсәфәсәрда гына ул...

— Нәрсә, анда дуңгыз итләре ашап, аны йөзем ширбәтләре белән бастырып куйганга кызлар иртәрәк өлгерәме? — дип авызын кыйшайтты Хәнәфи.— Ә безнең мондагы итләр-майлар, җиләк-җимешләр, һавасы-нисе ярап бетмиме, тоткарландырамы әллә?

— Белмим, бәлкем, шулайдыр... Әмма безнең ише аптыраганнарга анда барып сыенырга бер җай, ичмаса.

— Тапкансың икән барып сыенырга оҗмах! — Рәсүлә яндырып-яндырып молдаван егетенә карап куйгалады. Ул аның урынында бөтенләй бүтән берәүнең утыруына зур өметләр баглаган иде шул.

— Соң, әни, бик теләмәсәгез... каршы торсагыз... анда бармаска, гаризадан баш тартырга да була ич...— Рәмилә шулай диде, әмма аның тавышыннан да, үзүзен тотышыннан да алай итәргә һич теләмәве аермачык сизелә иде.

— Сез гафу итегез инде: без бүтәнчә булдыра алмыйбыз шул! — Бусын, янә кайнар пышылдап, Женя Мында әйтте.

— Гафу, гафу... безне, борылырга да җай калдырмыенча, почмакка китереп терәгез дә... Ә без монда бердәнберебезне... Белмим инде, мондыен хәлләрдә...

Рәсүлә әйтәсе сүзен капыл өзде. Ана бәгыренең катылана баруын ничектер туктатырга, ничектер сабыр җыя белергә кирәк иде. Ул усал иттереп ире Хәнәфигә карап куйды.

Хәнәфи исә бу минутта кияү булырга тиешле егеткә төбәлеп, аны күзли иде. Егетнең өстендә карасу-көрән һәйбәт костюм, кардай ак күлмәк, тимгел-тимгел кызыл төшкән көрән галстук. Чәчләре коңгырт-кара. Үзенең бөтен йөзе бурлаттай янып тора. Әйтерең юк, чибәр генә үзе... Әмма нишләп соң әле аның сул кашы өстендә һәм түбәндә, купшы мыегыннан иягенә таба, ниндидер җөй эзләре беленә? Уң күз төбе дә күгәренке... Җәен, аларга телевизор рәтләргә килгәч, андый нәрсәләр беленмәгән кебек иде ич. Ни хикмәт икән бу?.. Ниһаять, Хәнәфи егетнең күз карашын эләктереп алды: аңардан инәлүялварудан битәр мөлаем өмет һәм тәвәккәллек нурлары бөркелә сыман иде... Ата кеше тирән сулап куйды:

— Алай икән...

Рәсүлә иренең сүз куертуга юньләп катнашмавына, нибары ара-тирә юк-бар сораулар гына биреп утыруына ачулы иде. Ул, әлбәттә, иренең бүген нинди пошаманга чумып йөргәнлеген бик аңлый, әмма шул ук чакны... Рәсүлә түзмәде, ирен бераз айнытып куярга ниятләп, хәтта аны сискәндереп җибәрерлек дәрәҗәдә зәһәр иттереп, иреннәре арасыннан кысып чыгарды:

— Син, атасы, рабочком, димсең, озакламый рабочкомлыкка сайлап куюлары ихтимал, димсең... Белмим инде, белмим. Үз гаиләңә баш була алмаганны совхоз тикле совхозда ниләр генә җимерттерерсең икән, рабочком?!

Икенче китап

ШИҢМӘСЕН ГӨЛЛӘРЕҢ

БЕРЕНЧЕ ӨЛЕШ

1

Төпчек уллары Рәмзинең үзләре белән бер түбә астында яшәве әти-әнисенә бик күңелле дә, бик уңай да иде. Ни әйтсәң дә, егет гелән дә күз алларында, аның һәр адымын ук булмаса да, күп кыланышларын күреп һәм белеп торалар. Йорт тотып көн итмештә аның кул арасына кереп булышулары янсә, иң киме, тымызык кичләрдә ирле-хатынлы боегып-сәлперәеп утыруларга ирек куймавын әйткән дә юк инде.

Егет үзе дә төп йортта торып калуына бик риза, бик канәгать иде шикелле.

Ә хезмәт дигәнендә шактый гына кызыклы килеп чыкты аның. Армиядән кайтып төшкән елының җәендә һәм көзендә ул әтисе белән бергә совхозның культуралы болынында сугару эшләрен җайга салу белән мәшгуль булды. Шактый иза чикте алар ул чакны: тегесе җитми, бусы җитми, үзләре дә өч бөртек кенә, өстәвенә, хезмәтләре дә аңарчы белмәгән, күнегелмәгән нәрсә, алай да байтак эш майтарып ташлый алды тагы — ясалма яңгырлар бәрәкәте белән хәтфә болынлыкта күкрәп үскән печәннәр ул галәмәт коры, афәтле елны совхозның эре мал-туарын туендырмага ярыйсы гына терәк булды, аннан да бигрәк, алар тырышлыгы белән юктан бар ителгән ул чибәр болын алдагы елларны бу тарафта тагын да киңрәк колач белән җәелеп китү өчен ышанычлы җирлеккә әверелде.

Көзен, болынлыкта эшләр түгәрәкләнгәч, Рәмзи мастерскойда ремонт эшенә кереште. Беләк-кулбашлар нык, күкрәктә гайрәт ташып тора: дың да доң, шалт та шолт! Ләкин бу хәл алай озакка бармады, егетнең йөзкыяфәтенә акрынлап бер төсле сагышлы-күләгәле чырай иңеп алды. Ахырда чыдамады:

— КамАЗ корылмаларына үземә тиешле өлешнең азын гына булса да кертмичә, дөньям түгәрәкләнмәстер, китек калырдыр,— дип күңелендә төенләнгәнне чишеп салды.

Ләкин ул абыйлары Айдаш, бигрәк тә Вәсим кебек, илаһи-уптым кубып, дуамалланып кыланмады, иң әүвәл өйдәгеләре — әтисе-әнисе, шулай ук Ризван абыйсы, Туры бабасы белән бик әйбәтләп киңәш-табыш итеште, аннары, үзенчә рөхсәт-фатиха алырга ниятләп, ди-

ректор Акбашев янына сугылды. Теге үҗәтләнеп каршы килер дип көткән иде, ләкин, юк, киресенчә, бик йомшак, бик иплe генә тегесен-бусын сораштырган да, азактан:

— Өлеш кертми булмый, хыялыма хыянәт итә алмыйм, димсең инде, ә? Ярый, акыл-киңәш сорап килүең өчен рәхмәт инде, энем!.. Язга тикле димсең инде, ә? Яхшы, җибәрергә ризамын, ҚамАЗ коручыларга үз өлешеңә тиешле бетонны коеп бир инде алайса! Әмма ләкин хыял хыял белән, ә тормыш җүне җүн белән, энем: җәй башында сине үз басуыбызда күрәсем килә, синең кебек асыл егетләрдән башка совхозда, бөтенен әйтмим, ясалма яңгыр яудыртулар турында уйлыйсы да юк, егет сүзе бер булсын! — дип, җылы фатихасын һич җәлләмиенчә, егетнең кулын кыскан.

Шулай иттереп, Рәмзи Бариев кыш урталарында «Металлургстрой» трестына барып эшкә урнашты һәм, җиңнәрен сызганып, якын киләчәктә дөньяда иң куәтлеләрдән булырга тиешле кою заводы нигезләренә бетон салу эшенә тотынды. Тотынды да тотынуын... шул тотынуы аркасында «Металлургстрой»да баткан да булып чыкты. Ирекле-ирексездән...

Хикмәт шунда ки, дөньяда иң куәтле буласы кою заводын салырга алынган нәкъ менә шул ук «Металлургстрой», төп вазифасына өстәп, аларның «Йолдыз» совхозында өр-яңа поселок һәм эре мөгезле терлекләр өчен галәмәт дәү комплекс кору эшләре белән дә мәшгуль иде.

Ул елны язын, карлар эреп, дөнья ачылгач, Рәмзи аптыраішта калды: аңа инде үз совхозына әйләнеп кайтып, сугару эшләренә җиң сызганып ябышыр вакыт җиткән, әмма тегендәгеләр, егетнең асыл ниятен сизеп, аны «Металлургстрой»да калырга үтереп димләргә тотынган, дөресе, бу трестның кою заводында җан-фәрманга эш майтарып яткан СМУыннан бөтененә — нәкъ менә аларның «Йолдыз» совхозына Яңа поселок һәм терлекчелек комплексы корырга керешкәненә күчәргә котырта иде: имеш, андагылар бик тә акрын кыймылдый, төзү эшләре тәмам койрыкта сөйрәлә, төп сәбәбе — эшче куллар, шәп осталар җитешми, ди.

Рәмзине димләүче бер дә әллә кем түгел, кою заводында бергәләп бетон салган звено башлыклары Петя Кувалдин иде. Петя төп һөнәре белән сантехник икән, ул үзе инде Яңа поселокка күчеп эшләргә ризалык бирү генә түгел, сантехниклар бригадасы туплауны да үз

өстенә алган икән, аңа инде, өр-яңа бригадага, билгеле, егетләрнең иң ышанычлыларын, иң җегәрлеләрен һәм осталарын туплау хәҗәт... Өр-яңа эшкә тотынганда шулай итми ни!

Идел буеның Тәтеш дигән бәләкәй генә, күркәм генә каласында туып үскән ул таза, калынча гәүдәле, кызгылтрак йөзле егет бер дә бер кичне боларның өенә килеп утырды. Шома һәм ыспай сөйләшә. Рәмзи колак артын кашудан бушый алмады:

— Хет икегә ярыл...

— Вәгъдә — иман, улым. Директорга әйткән сүзеңне онытма, егет бул! — дип кисәтте аны шул чакны әтисе Хәнәфи, артык шыңгырдамыйча гына, әмма бик тә тирән сулыш алып.

Кабаттан китте шулай Рәмзи совхоз конторына киңәш-табыш итмәгә, фатиха алмага... Мөслим Акбашев, егетнең гозерен тыңлагач, бармакларын өстәл шомасында биеткәләп һәм киң маңгаен тирән уйларда сырландырып озак кына утырганнан соң, мәсьәләне кәтмәгәндә үзенчә әйләндереп салды:

— Шулай инде: безнең Чаллы төбендә егет кешенең икегә түгел, кырыкка ярылырдай чагы. Бик кирәк, үлеп кирәк эшче куллар һәр җәһәттә дә! Ә үзебездә аерата оператор-мелиораторлар! Бу елны ук культуралы болынлыкларны биш-алты йөз гектарга җиткерергә исәп, алдагы елны янә шул чамага үстерергә ният. Ансыз терлекчелектә, ай-һай, ул текә тауга үрмәләүләре! Әйе, әллә нихәтле яңгыр установкалары, насослар, торбалар кайтасы... Шулай да син, энем, төпле, ышанычлы бригада корырга ниятләгәннәр икән, булмаса, шунда гына укмашып кал инде! Ә монда сугаруда ничек тә ермачлап чыгарбыз әле, булышучылар, шәт, табылмый калмас... Тегендә исә, Яңа поселокта ягъни, үз кешебезнең, үз таянычыбызның булуы бик тә кирәк! Әле сантехник белән генә дә чикләнергә ярамастыр, үзебезнекеләрдән таш белән бетон эшенә дә, бүтәненә дә ышанычлы кешеләрне табып җибәрми булмастыр... Алайса давай, энем, болай карап торырга да, нәсел-токымың белән дә адәм итеп изгәндә ут-яшен чаткылары кушып тугылаганнардан шикелле, Яңа поселок корылышында да очкыннар уйнатып күрсәт инде бер, яме! — диде.

Шул рәвешле, Рәмзи Бариев язның бер көнендә монтажчы-сантехникка әверелде дә куйды...

Иртәнге сәгатьтә ул җете кызыл «Ява»сына атланып ала да, туган авылы Әҗер урамнарын бер мәлгә

мотоцикл шытырдавына күмелдереп, эшенә чыгып китә. Авылның Игәч башыннан ялан кырга атылып килеп чыккач, сулга каерылып, салынып яткан асфальт юл белән Яңа поселок тарафына, туп-туры кояш чыгышына таба элдертә. Ике кышын һәм ике җәен әнә шул юлда үткәрде егет.

2

«И балалар, бәләкәй чакта, үскәндә бер хәсрәт булсагыз, дәвәеп кеше арасына кергәч китергән көенечләрегез мең шул сезнең!..» — Рәсүлә шулай дип, адәм дигән зат дөньяда җан иңдереп җир йөзе буйлата сибелергә тотынганнан бирле әйтелеп килгән һәм мәңге әйтеләчәк гап-гади хакыйкатьне күңеленнән өзми диярлек кабатлый иде. Миллионлаган аналар телендә булганны...

Ә гомер дигәннәре, чәнчелгере, бармак араларыннан тоткарланмый шуып төшкән ком сыман, агыла да тора. Эзе дә калмый... Хәер, калмыйммы? Шул ук уч төпләрендә сөялләр катыланганнан катылана, йөз-тәннәрендә җыерчык өстенә җыерчыклар өстәлә бара, гомер көзенең кырау җепләре торган саен күбрәк һәм ешрак укалана төшә. Берни эшләр хәлең юк: беркавым чигенделә алса да, кемнең әле гомер көзеннән кача алганы бар?

Ләкин көз — бер үк вакытта дөньяда шаулы-гөрле язлар бар һәм булачак дигән сүз дә бит әле!

Төпчекләре Рәмилә абыйларын кызык итте: тегеләрнең борынына бик шәп чиртеп, үз куышын иң әүвәл корырга тотынды. Тегеләре исә дөнья көтүнең бормалы-сырмалы сукмакларында, дуадак казлар сыман, үзләренә иш таба алмыйча, әле һаман каңгырап йөрүләрендә...

Ә боларга кияүләре Женя Мынданың тырышлыгы аркасында гына, билгеле, Яңа каланың мәскәүлеләр салган хәтәр биек, галәмәт шәп йортыннан бер бүлмә — «малосемейка» бирделәр, ягъни ике бүлмәле, әмма бер балконлы һәм бер кухнялы квартирада икенче берәүләр белән «коммуна» булып яшиләр. Ярый, тормыш башлаганда аның мондые да бик әйбәт! Үзләре болай онытмыйлар, атна саен ук булмаса да, аена бер-ике тапкыр кайтып, кунак булып китәләр. Кунак булу гынамы, йорт арасында тегесенә-бусына катышып, байтак кына эш тә майтарып куйгалыйлар. Монысы инде,

әлбәттә, йорт хуҗалары ата белән ананың йөрәгенә сары май булып куна иде. Ләкин Рәмилә кайчакларны, әнисе белән генә калган аулаграк минутларда, ыңгыр-шыңгыр килеп, зар түгүдән дә тартынып тормый иде:

— РИЗны полный худка җибәргәннәренә инде әллә кайчан. Ә Женяны һаман әле тегендә очырталар, әле монда куалар... Чехословакия белән ГДРда булып кайтуларын инде әйтмим дә, әле күптән түгел Франция белән Италияләрдә дә батып ятты ич. Инде хәзер дөнья читенә, Япониянең үзенә үк җибәрмәкчеләр бугай, ди.

Рәсүлә, аны үзенчә тынычландырмакчы булып:

— И кызым, түземеңне җыя бел! Бер утырмый, бер төпләнми калмас әле. Андыен оста кулны гелән дә читтә очыртып йөртмәсләр, монда да кирәге бик чыгар! — дип кирәкмәгән чәчелүләрдән тыярга тырыша иде.— Инде алай бик җуксынасың икән, үзебезгә җышрак кайтып җөре, туган җортында ничек тә тынычрак булыр...

Шушы киңәш ярап куйды шикелле: Рәмилә, ире ераграк сәфәргә киткән мәлләрдә, кышын да, язын да авылга әтисе-әнисе янына бер генә түгел, хәтта икешәр-өчәр тапкыр кайтып китүчән булды. Рәсүлә кызы кайткан саен, тормыш итешнең яшертенрәк яклары турында туп-турылай сорашырга базмый базуын, әмма тәҗрибәле, үткен күз карашы белән аның буй-сынын, бик җентекләп, әмма бер үк вакытта үзенә сиздермәскә тырышып кына капшап-кармалап чыгулардан туктала алмас иде. Ләкин юк, Рәмиләдә һаман да шул кыз чагындагы шикелле үк сылу билдер, матур төртелеп торган җыйнак күкрәктер, тик күз төпләренә генә куе күгәренкелек иңгән сыман — гәүдәсендә генәме, үз-үзен тотышында да ана булырга җыенуның һичбер чамасы беленми иде аңарда. Бу ни хикмәт бу? Бала-нарасый булдыру хакында уйламаска монда!

Шушылай пошаманлы уй-хисләргә бирелгән чакларында Рәсүләнең күз алдына кияве Женя килә дә баса. Чит милләт кешесе булуы сәбәпле, элегрәк, кызлары Рәмилә белән гыйшык-мыйшык тотып, әвеш-тәвеш йөргән вакытларда ук әле, бу чибәр егетнең шаяртулары түгелме, кызыйның атар-атмас нәфис чәчкәсен вакытыннан иртә өзеп-изеп ташламасмы, дигән кебегрәк шикшөбһәләре, бетмәс хафалары белән аз яндырдымы ул Рәсүләнең йөрәген? Кистереп һәм өздереп кенә: «Олы мәхәббәт! — диләр.— Бар җиһанны гүзәл нурларда балкытып, аның учагында дөрлибез!» — диләр... Иләһи

балкыш, сихри нурланыш!.. Рәсүлә дә, ире Хәнәфи дә еш кына үз яшьлеген исенә төшергәләде — күңел түрләрендәге мәңге җуелмас татлы һәм матур көннәрен... Шул сәбәпле кызлары Рәмиләгә соңга табарак алай бик каты орынып, үзе сайлаган юлына киртә торгызып азапланмадылар да... Ни мәгънә? Төрле шик-шөбһәләрдән ут йотып яшәсә яшәделәр, мәгәр сабыр иттеләр, азагын көттеләр. Ниһаять, көткән көннәре килде — теләгеләр морадына иреште. Ата белән ана да җиңел сулап куйды. Ләкин шик-пошаманнар бөтенләй үк таралып һәм сибелеп беттеме соң?

Әйе, карар күзгә кияүдән уңдылар сыман: йомшактыр, күндәм һәм итагатьледер холкы-фигыле, бер үк вакытта тырыштыр, елдамдыр. Женя Мынданың чем-кара мыек астыннан эре ак тешләрен балкытып эчкерсез елмаюында, коңгырт күзләрен мөлдерәмә ачып, нурландырып карауларында ук асыл ирләрнең чын сафлыгы да, сөйкемле гадилеге дә, тагы әллә ниләре — бары берьюлы ташып түгеләдер кебек. Күрше-күлән дә бик ошатты һәм яратты үзен. Ярый, бик әйбәт, бик хуп. Ләкин нишләп соң әле ул, макталмыш кияүләре ҚамАЗ хакына күктәге бөркет сыман җирнең бер читеннән икенче читенә очып-кунып йөри, ә менә үз оясына җан иңдерү, аны нурландыру хакында алгысып уйламый? Нидән ул пошмас сүлпәнлек? Әллә алар халкында бу җәһәттән ашыкмаучанлык һәм сүлпәнлек хуп күрелә микән? Һай, юктыр, юктыр! Татар ни дә, молдаван ни, бүтән халык ни — һәркайда да, һәркемгә дә иң әүвәл бала-нарасый тансык һәм кадерле! Төн җимеше генә түгел, мәхәббәт җимеше, җан җимеше — иң бөек һәм газиз зат! Ул синең бүгенге юанычың һәм куанычың гына түгел, ул синең иртәгәге көнең, туачак таңнарың! Пар килгән, тиң булган ике җанны да нәкъ менә бала ныгытып төенләндерә, яшь ата белән ананың алдагы язмыш йөгәне дә нәкъ менә шул дөнья яме булган сабыйның йомшак, нәни кулларында ласа!.. Менә шуларны аңламыймы, белмиме әллә аларның кияүләре? Ә бәлкем, төп гаеп боларның үз кызларындадыр? Әлегә тикле җифырт та мифырт кылануларыннан котыла алмаган шушы чәчлекәйдәдер? Асылда, балага узу, бала булдыру иң әүвәл хатын-кыз ихтыярында ласа. Яшьлегендә таза-саф көенчә, күңелең илаһи дулкыннарда тирбәлгән чакларда ана булуның шатлыгы ни тиклем дә, матурлыгы нихәтле! Хатын-кызга чын бәхет менә кайчан һәм ничек тулаем яралып иңә ич!

Рәсүлә, үз кызы, үз җимеше булган Рәмиләгә менә шушы иң изге, иң гүзәл уй-хисләрне вакытында тиешенчә төшендерә һәм сеңдерә алмаганы өчен, кай араларда үз-үзен битәрләргә тотына иде. Бәлкем, җанына сеңдерергә бөтенләй ук соң да түгелдер әле?

Кызы Рәмиләнең бер кайтуында түзәр хәле калмавын тойды Рәсүлә — тышта карлар эреп, яз исе борынны гына түгел, җанны айкаган чак иде, кызының зифа сынына, бигрәк тә аның нечкә биле тирәсенә ым кагып һәм, әлбәттә, йомшак, җылы тавыш белән сорарга кыюлык итте:

— Нишләп соң әле, кызым... теге ни... тазарыбрак, тулышыбрак китәргә һичбер чамаң күренми синең?

Ана кеше моны бик тә җаен китереп, сыйпагандай иттереп кенә сораса да, кызы җавап бирергә ашыкмады. Рәмиләнең диванда үзенә урын-җир хәстәрләп матавыкланган чагы иде, күз кырые белән генә әнисенә орынып алды, аннары, сынын турайтып, чәчләрен тузгытып җибәрде һәм, борыла төшеп, трюмога күз ташлады, моның соңында мамык мендәрне каккаларга-суккаларга тотынды.

— И әни...

— Аптырама... Әзрәк хәлкәеңне белергә теләүдән генә төпченәм, кызым. Шушындый сөлектәй гәүдәләрең белән, таза-саф көенчә... сөбханаллалар... җәшлегең җәмендә... тансык та җан бала-нарасый хакында... уйисәпләрең ничекләйрәк диюдән...

Бу сөйләшү, ана белән кыз арасында гына булудан битәр, тәҗрибәле, сизгер күңелле өлкән хатын белән гаилә тормышының ни асыл мәгънәсен, ни тәмен юньләп белмәгән яшь хатын арасында иде. Моны һәр икесе дә бик әйбәт аңлый, тиккә чәчәләнү яисә чытлыклануларны бөтенләй кирәксенми иде, әмма, шулай да, яшьлекнең тәҗрибәсезлеге, суга батырылган бөке сыман, пырт иттереп өскә калкынды:

— Без сабыр итәргә булдык әле, әни,— диде Рәмилә, ниһаять, шактый ук коры рәвештә, гүя сүз бөтенләй әһәмияте булмаган, чүп кенә нәрсә турында кузгатылган иде.

Кызы әйткән сүзләрнең мәгънәсеннән дә битәррәк, аның тавышындагы корылыгы һәм шыксыз гамьсезлеге Рәсүләнең капыл хәлен алды да бугай...

— Сабыр итәргә? Сакланырга? Беренче баладанмы? Әстәгъфирулла! — дип, басып торган җирендә лып иттереп урындыкка утырды ул.— Син нәрсә, кызым, пеш-

кән алмадай гомеркәйләреңне кысыр чәчкә булып уздырырга җыендыңмы әллә?

— Җыенмасам да... Анда күршенеке генә дә колакларны тондырып бетерә әле. «Малосемейка»ның ни икәнен син аз гына чамалыйсыңмы соң? Үз җаен үзебез белербез әле!

— «Малосемейка», имеш... Булсын гына — үзем багармын! Билләһи менә, шушы кулларымнан төшермәм. Әтиеңә дә, миңа да тансык кына булыр ул!

— Син бигрәк инде...

Сүз үтә интим һәм нечкә нәрсә турында кузгатылган иде, һәм Рәсүлә көченнән килгәнчә йомшаграк, сабыррак һәм итагатьлерәк сөйләшергә тырышкан да иде. Ләкин булмады, барып чыкмады: ихтыярсыздан диярлек үз тавышы да күтәрелеп китте, сүзләре дә чатнап-калтыранып сибелергә тотынды:

— И бәгырькәем, ниләр генә уйлыйсың син, акылларың кайда? Табигатькә каршы торыпмы, җола-гадәтләрне бозыпмы, ә? Элек-электән бәбине — донҗа күрке, мәхәббәт җимеше, дигәннәр, шуны да белмәскә! Безне уйларга сала-сала ни пычагыма дип чыктың айса кияүгә?

Рәмилә, диванга сузылып яткан җирендә, башын юрганы белән томалап ук куйды.

— Күр моны, ай-һаенда да җук!

Рәмилә үпкәсенең бәләкәй түгел икәнен ныграк сиздерергә уйлаптыр инде, айдан артык, ире Япониядән әйләнеп кайтканчы, туган йортының бусагасыннан атлап кереп, әти-әнисенә йөз күрсәтергә теләмәде, Чаллысында бөрешеп ята бирде. Ярар, бу хәтлесе аның үз намусында...

Ә Рәсүлә үзе үпкәләмәдеме, рәнҗемәдеме ул пумала башның дорфалыгына? Кая инде! Йөрәк парәсеннән кубып, якты дөньяга аяк баскан һәм анда чын адәм булырга тиешле үз сыныгы ич!.. Аннары килеп, Рәсүлә аларның бәбиләрен көтеп, озак эзләнү-сайлаулардан соң, ул туачак нарасыйга үз күңеленә иң ошаган, иң матур күренгән исем дә табып куйган иде инде: малай туа калса, «Вил» дип, кыз булса, «Ләйлә» дип тәкъдим итмәкче иде. Ә нигә, үзебезнең татар теле өчен үтә дә ятышлы һәм күркәм булуы хакында әйтәсе дә юк, русча да бик шома һәм шәп яңгырый, мөгаен, молдаван теленә дә алай ят күренмәстер — хуш килердер. Инде алай-болай кызы белән киявенә бу исемнәр бик ошап

бетмәсә, рәхим генә итсеннәр: Рәсүләнең төрле исемнәр теркәлгән дәфтәре калын гына...

Яңа туган балага исем кушу җәһәтеннән үз авылында Рәсүләнең абруе бәләкәйдән түгел иде. Әле байтак кына еллар әүвәл, бөтен Әҗер үк димик, мәгәр авылның түбән очында яшәгән хатын-кыз, дөньяга яңа җан иясе индерү бәхетенә ирешсә, бераз хәлләнүенә үк, Рәсүлә янына йөгереп килеп җитәр иде. Килеп җитәр иде дә:

— И Рәсүлә җаныкаем (яисә апаем), син үз балаларыңа инде дә күркәм исемнәр кушкансың, зинһар, безнең яңа туган нәнечебезгә дә берәр матуррак исем табып бирче,— дип куанычын да, үтенечен дә берьюлы түгеп салыр иде.

Табышмыйлармы соң, кешенең куанычына нур өстәргә тырышмыйлармы соң!

— Җарый, айсам... тик менә эзләргә-уйланырга берике көн бирерсез инде, җәме,— дияр иде Рәсүлә.

Уйлар иде, кайчакларда төн йокылары качар иде, әмма бәхетле ата-ана күңеленә хуш килердәй исемне әзерләп куяр иде. Берне генә дә әзерләмәс — кәгазьгә өч исем теркәлгән булыр, янәсе үзләренә дә уйларга-сайларга мөмкинлек бар — рәхим итегез!..

Ул кушкан исемнәрне йөртүче авылдашлары әллә ничә дистәдер инде: егетләрнең армия сафларында булганнары һәм аннан инде әйләнеп кайтканнары да, кызларның исә кияүгә китеп, үз нәниләрен үстерергә тотынганнары да, әле өлгереп кенә килә торганнары да, мәктәп яшендәгеләре дә байтак кына.

Әлбәттә, ул исемнәрнең төрледән-төрле булуын тели, гөлбакчада чәчәкләр гелән дә бер төсле булса, ямьлемени, күңеллемени? Ичмаса, Әҗер бүтән авыллардан шул ягы белән, ягъни исемнәрнең күплеге, төрлелеге һәм матурлыгы белән аерылып торсын, ди. Ә дәфтәргә ул исемнәрне саташмас-буталмас һәм кабатланмас өчен теркәп бара. Анда шулай ук Әҗердә әле моңа кадәр беркемгә дә кушылмаган исемнәр «маясы» да зур гына. Рәсүлә сөйләшкәндә колагына чалынган яисә берәр әдәби әсәр укыганда күзенә күренгән һәм күңеленә хуш килгән бер генә исемне дә дәфтәренә теркәми калдырмый иде.

Исемнәр, исемнәр... дөньяда кешене бизәргә тиешле илаһи чәчкәләр! Ә менә уйлаган-тапкан исемеңне кушарга җисемең булмаса? Кысыр калса? Ул чагында, исем-чәчкәнең күркәм булуында ни мәгънә?

Әйе, соңгы елларда дөнья көткәннең сикәлтәле сукмакларыннан болай таба атлап килгән саен, Рәсүләнең гөлбакчасыннан матур чәчкә сорап килүчеләр кимегәннән-кими барды һәм менә инде былтыр-быелларда бөтенләйгә тукталып калды. Шулай булмаска, аның үз кызы, йөрәге төбеннән өзелеп төшкән үз сөеклесе, баладан — җитмәсә, беренчесеннән үк! — сакланып, аңардан өркеп йөрсен дә сиңа, бүтәннәрдән ни көтәсең?

Инде хәзер яшел тышлы калын дәфтәр шифоньер өстендә ачылмыенча тузанга күмелеп ята бирә...

Аны кем һәм кайчан ачтырыр? Дәфтәргә матур-матур исемнәр янә өстәлерме? Өстәлгәннәренә җисемнәр табылырмы?

«И авылдашлар, и яшь киленнәр, моның җан әрнетүләре нихәтле — белсәгез лә икән!..»

3

Ә уллары?

Шөкер, таза-саулар, эшчәннәр, чибәрләр — ил күзендә каш кебекләр...

Әйе, моңа кадәр алар өчен гел диярлек куанып яшәделәр.

Кечесе Рәмзи иртән торып тамак ялгавына мотоциклына атлана да үзе сайлап алган, күңеленә яраган эшенә чаба, кичләрен, авыз ерып, әйләнеп кайта. Хафамазар тудырмый, тудырырга, мөгаен, иртәрәк тәдер әле, һәрхәлдә, аның өчен бүгенгә җаннары тыныч...

Ә тегеләре, Айдаш белән Вәсим? Моңарчы алар да абыну-сөрлегүләргә һич юлыкмады шикелле: икесе дә бөтен дөньяны шаулаткан төзелештә җимерттереп эшли, үзләренә тоттырган бүләк һәм грамоталарның санисәбенә дә чыгасың юк. Алай гынамы, аларны — бигрәк өлкәне Айдашны — ничәмә гәзитләрдә мактап яздылар, Казан радиосы да ике туган — хезмәт батырлары исемен ай саен диярлек бик зурлап телгә ала.

Әмма ике бертуганны уңган, тырыш хезмәтләре өчен әнә шулай янәшә куеп күкләргә чөйсәләр дә, асылда аларның хезмәт итмеш һәм көн күрмеш җайларында күзгә төртелеп торган аерымлыклар да бар иде.

Айдашы Чаллыга барып ни эшкә тотынган булса, нибары шуны гына белде: бульдозерында җир актарды, җир каезлады — бүтәненә хиресләнмәде. Әле һаман да шул авыр эшендә. Ләкин ул, аның каравы, торган-яшәгән тулай торагын ошатып бетерми иде: КамГЭС посе-

логында берне алыштырды, икене, инде менә күптән түгел, язга чыккач, кем беләндер алыш-тилеш итешеп, Яңа каланың үзенә күченеп куйган. Ни сәбәпле? Үзе юньләп аңлатып тормый: «Шулай инде, кирәккә күрә»,— ди.

Әмма иң кызыгы һәм хәйран аптырашта калдырганы бумы соң әле! КамАЗ коручылар арасында гайрәтлеләрнең дә гайрәтлесенә әверелгәч, Айдаш көтмәгәндә дөнья гизәргә яратучан булып китте — көз азагында тиешле ялга чыгуына кулына путевка ала да җәтрәк чит илгә шыла. Үз җаны исәрләнүдәнме, әллә булачак кияве молдаван «мыеккае» Женя Мынданың шаукымы тиеп һәм аңардан астыртын гына көнләшеп, без кай ягыбыз белән ким, диюдәнме? Мөгаен, икесе дә бардыр. Өченче елны ул шулай «круиз» дигән нәмәрсәкәйгә чыгып, ярты Европаны урап, океаннар гизеп, бетмәс айһайларга чумып кайткан иде, ә бу елны, җаен чыгара алса, Һиндстанның үзенә сәфәр тотмакчы. Аның ул ерак сәфәрләрдә янчык-янчык акча туздыруларына каты орынып сүз әйтерлегең юк: акчаны ул күрәп-күрәп кенә ала диярлек, ләкин кайчан соң әле егет асылы, акылына килеп, үзенә гомер итмәгә җан юлдашы табар да кайчан чын адәмнәрчә үз оясы хакында хәсрәтләнә башлар?

Чаллыдан кайтып төшкән чакларында, менә болар хакында сүз бер генә тапкыр куптарылмады инде — булгалады андый хәлләр — соңгы араларда әтисе Хәнәфи дә аңа теш аралый сыгып кына чәнчеп-чәнчеп орынгалады, ләкин теге һаман бер төслерәк калкан белән капланырга итенә иде:

— Һе, ирек барында бер рәхәтләнеп дөнья күреп калмаска монда... Соңыннан сезнең «җаный» дигәнегез бер заман өскә җәтмә ыргытса, ирекә бик омтылырсың да, тыпырчынудан артыгын булдыра алмассың... Пошынмыйк, җәтмә астында калырга өлгерербез әле,— ди иде.

Бер көнне әтисе, аны авырттырыбрак чәнчергә ниятләп:

— Үзең арысландай егет, үзең әнә нидән өркәсең — механизаторлар арасыннан да шушындый адәм көеге чыгар икән! — дип кадалды.— Әллә ниме... Үзеңә җанаш итеп... берәр нечкә билле француз кызын яки, әйтик, Һиндстан кәттиен апкайтырга ниятме? Патшалар, ханнар шикелле, ә?

Моңа Айдаш бер рәхәтләнеп көлде генә:

— Һай, тоҗырдың да соң, әти! Курыкма, чыкырдап торган татар кызы булыр! Бер дә әллә кайда түгелдер, тап үзебезнең Чаллы тирәсендә муенга элмәк салмагс кылдан аркан ишеп азапланадыр...

Әнә шулай тешләрен генә агарта өлкәне...

Бу исә уртанчылары Вәсимгә җил-яңгырдан сакланырга үзенчә ышык кына: янәсе, абыйсыннан уздырып оя корып йөрүләр чын егет булган кешегә һич килешми, һич ярамый. Сеңелесе Рәмиләнең кыланмышына, ягъни кияүгә чыгып, үз сукмагыннан тиз атлап китүенә тамчы да аптырамый. Бу хәлгә абыйлы-энеле, киресенчә, куангандай булып: «Кыз кешенең, җәтрәк канат чыгарып, парланып оча башлавы әйбәт кенә. Бүгенге заманда бигрәк тә!» — дип кенә җибәрәләр.

Ә болай Вәсимнең тормыш итеше бөтенләй бүтәнчә. Бу макталмышлары Чаллыга барып эшкә урнашкач та яшәү өчен кая кереп оялаган булса, шунда төпләнеп тә калды: имеш, йорт хуҗалары үтә ипле, моның өстенә, ишегалларында мотоцикл тотар өчен дә уңай. Тулай торакка күченүләрне уена да китермәде. Аның каравы, олы төзелешнең механизация тармагында Вәсим тотынып карамаган берәр хезмәт калдымы икән? «Беларусь»-җаныкаен»да җир умырттырып, туфрак тигезләштереп тә йөрде; галәмәт зур кранга утырып, аның да чын куәтен сынап карады; инде менә соңгы бер-ике елында, ничектер төпләнә төшебрәк, юл төзелешендә автогрейдерда эш кыйрата. Бер дә бер көнне Туры бабасы, аның хезмәттәге кыланмышларына үзенчә бәя биреп:

— Безнең Вәсимме? Аңа артыгын авырга да килмәсен, шул ук чакны тегермән мөшкәсеннән онның тазасы, шәбе агудан да тукталмасын... Җитмәсә, дан-шөһрәт дигәне дә таманчадан уздырыбрак җавып торсын! — дип тел шәбәрткән иде, һәм ул мөһерне гадәтенчә тап өстенә туры китереп басты шикелле...

Вәсимнең дә үзенчә хикмәтлерәк ягы бар иде: аңа машина җене кагылган иде. Байтактан бирле инде ул елык-ялык итеп торган «Жигули»га ия булу хакында хыяллана иде. «Абый кук тиленәр өереннән түгел без... Их, дөнья күргәндә, үз машинаңа утырып, рульгә сыланган көйгә җил-җил очыртуларга ни җитә! — ди, үзе шул мәлне, биш бармагын да батырып, баш пумаласын бутарга тотына һәм, кисәк аңына килеп, өстәп куя: — Билгеле инде, сезне дә утыртып...» — ди.

Бер мәлне атасы аның хәлен аңлагандай булып кыланса да:

— Анысы, улым, шулай инде: рульгә сыланып, җил-җил элдертүләре әкәмәт инде! Тик ни... синең өйләнүең дә шул машинага булып, шуны кочып ятарсың микәнни? — дип төрттерүдән һич тыелып кала алмады.

Моңа җавапка Вәсим, пумала башын артка ташлап, тешләрен генә агартты:

— Нишләп? Бусының да рәхәтен белербез, тегесе дә качмас! Җебегәннәр без түгел, әти, белеп тор!

— Түгел микән? — дип күзләрен чекрәйтте әтисе.— Аннары дим, йөри торгач, оя кормага хәләл җефетне тапсаң да, ул синең үзеңә түгел, елык-ялык итеп торган машинаңа кияүгә чыккан булмасмы?

Бу яман сүз улы Вәсимнән битәр Рәсүләнең үзен өркетте, һәм ул шундук:

— Тфү, тфү, җурый күрмә, зинһар! Әйттем исә кайттым, диген! Сәгате туры килеп, җилкәсендәге фәрештәләр җазып куймагае тагы! — дип ян якларына төкерергә тотынды.

4

«Саулыкка туеп, кеше арасында хезмәткә җөрүләргә ни җитә инде! Бәхетнең дә иң зурысы, мөгаен, шулдыр әле...» — Рәсүлә еш кына шулай уйлый һәм, уйлаган саен, күңеле тулып, гәүдәсенә бер төсле рәхәтлек иңгәнлеген тоя иде.

Ә бит әле кайчан гына — ничә ел элек кенә — ул, авыр сырхаудан интегеп, тәмам гаҗиз булган чакларында, авылдашларының шаулашып эшкә баруларын, гөрләшеп эштән кайтуларын тәрәзәдән генә, хәленнән килсә, капка төбенә чыгып кына карап утыргалар иде. Ул яман чаклары кире әйләнеп кайта гына күрмәсен инде!

Әнә шундый үзәккә үткеч каты сыналудан соң, уртак һәм күмәк хезмәткә катыша алуларның кадерен дә, тәмен дә бик аңлый, бик белә Рәсүлә!

Хезмәтнең төрлесе бар инде аның. Ул китергән куаныч-юанычларның да төсмерләре бихисаптыр.

Үз ихатаң, үз абзар-кураң тирәсендә генә казыну, ягъни үз мәеңне белеп кенә кайнашу да хезмәттер. Бу да кызыклы һәм файдалыдыр, хәтта мондыеның табышны күбрәк китерүе дә ихтималдыр, шатлык-куаныч дигәнен дә аз бирмәстер, хәтта кайберәүләрдә бусы чиксез-чамасыз күпереп тә китәдер. Әмма бу ише куанычшатлыклар нибары бакыр яисә җиз ялтыравына гына

охшап калмыймы икән? Адәм баласы гомер итмешен нибары шуның белән генә чикләсә, әйбәт микән соң? Гелән дә ышкып-ялтыратып тормасаң, бакыр белән җиз-гә күгәрек бик тиз куна лабаса...

Ә тегесе, күмәк хезмәттә катышулар китергәне? Анысының яме? Анысы тоныклану-күгәрүләрне белмәстер, аңарда алтын-якутлар балкышыдыр. Мондые адәмне гомере буена сөендереп барырдыр, хәле бетеп егылгач та, хәтта әле теге дөньяга китеп баргачтын да, бүтәннәрнеке белән кушылып, бүтәннәрнеке дәвамында нурланып торырдыр...

Рәсүләнең түккән хезмәте болай бер дә әллә ни түгел югыйсә: язын, ләйсән яңгырлары үтеп җир кибә башлауга, походный кухнясының учагына ут тамыза да, аның нәзек морҗасыннан зәңгәр төтеннәр бөрки-бөрки, туган авылының басу-кырларында тир түгүче эшчәннәрне кайнар аш белән туендырып йөри. Аларга иң кирәк сәгатьләрдә көч өсти, җегәр кертә.

Иртә яздан башлап ачы көзгәчә.

Хезмәтенең авырлыгын да, җиңеллеген дә үзе белә...

Ә басу-кырлар елның елында үзгәрә, байый, көзнең явын алырдай булып матурлана бара. Хәтсез киң кырларда күкрәп үскән игеннәрнең яисә йөзәрләгән гектар җир биләп, куе яшеллектә хәтфәләнеп утырган кукуруз һәм чөгендер басуларының ямьлелеген әйтәсе дә юк. Ләкин боларына күзләр дә, күңелләр дә әллә кайчаннан ук күнеккән инде. Ә хәзергесе, бүгенгесе?

Әнә бит авылларына тоташып ук киткән яшелчә бакчалары инде хәзер күз күреме җитмәс җирләрдә җәйрәп ята. Калмаш белән Илбакты авылларына таба сузылган тигезлекләрдә сөзәк үр битләрен биләп алган культуралы көтүлекләр, купшы болыннар тагы? Болары да инде меңгектарларга якынлашып килә, ди, лабаса! Хәер, бу чикне узып киткән булулары да ихтимал инде... Алардагы үләннең куелыгы, шәплеге! Өлгереп килгән чакларында ул болыннарда да, нәкъ инде күкрәп үскән иген кырларындагы шикелле үк, шәбәреп искән җилләрдә тыгыз, көмешсу дулкыннар тәгәрәп-уйнап тора. Һәм менә шул басу-кырларда, юк, яшелчә басуы белән культуралы болын-тугайларда гына түгел, хәтта чөгендер һәм өлешчә кукуруз җирләрендә дә — яңгырның күктән яуганын көтмичә, җирдән генә сиптереп яталар. Кайвакытларда, көн матур, кояшлы булып торганда, басуларның шактый-шактый өлешләре тоташтан яңа сауган сөт сыман томан белән өртелгән

була — тап инде игелекле җир өстенә яңгыр болыты үзе иңгәндәй... Моңа кадәр андыйны кырлар тарихы күргәнмени, белгәнмени? Игенче-крестьян гасырлар буена нибары татлы хыялында гына асрый алган тылсымлы бер хәл инде — әкәмәт булмый сиңа!..

Яшелчә бакчасын кистереп сузылган юл белән алар көн саен диярлек үткәлиләр. Арбаларына походный кухня тагылган була, арбаның үзенә исә ягарга утындыр, бидоннарда судыр, сөттер, әрҗәләрдә ризык-нигъмәтнең бүтәнедер төялгән була. Аяк селкештереп, шылтыр-шалтыр барган чакларында, Рәсүләнең төп булышчысы Мәттин агай (хатын-кыз булышчылары гелән дә алмашынып тора) тибеш-тибеш атлап барган кәрән алашаны капыл гына туктата да, күз карашы белән басу киңлекләрен иңли-иңли, күкрәк төбеннән бер сулыш белән диярлек кысып чыгара:

— Кичә үлгән булсаң, күрмиенчә китәсе икәнсең... Хәйран да тамашалар шул бүгенгесе көннәрдә!

Рәсүләнең дә соклануы чикләрне белми. Кайбер көннәрдә ул, арбада ипле генә селкенеп барган чагында, күңеле артык иләсләнеп китүдән төшеп калырдай да була. Төшеп калып, яшелчә басуына сибелешкән һәм ерактан караганда аллы-гөлле чәчәкләр булып күренгән хатын-кыз арасына кереп, аларга кушылып китәсе килә аның. Эшләре ни авыр булмасын, бакча җимешен — кыяры белән суганын да, кишер белән помидорын да, бүтәнен дә — үстереп йөрүләре галәмәт күңелле. Соңыннан, өлгергән хәтлесен җыеп тапшыра барулары бигрәк тә!.. Җәйнең икенче яртысында алар авылы Әҗердән Чаллы тарафларына әрҗәләргә яшелчәнең төрлесен төягән автомашиналар бер-бер артлы китеп кенә тора — андый чакта күңел айкалмас җиреннән айкалыр шул!

5

Былтыр ире Хәнәфи һич уйламаганда рабочкомга баш итеп сайлап куелгач, Рәсүлә аңа юри шаяртып кына:

— Болай булгач, минем эшләр дә җиңелгә табан китәр инде. Ичмаса, без дә түрә хатыны булып кына бер җәшәп карыек әле! — дигән сүз белән орынып алган иде.

Теге исә:

— Һы, киресенчә, авыраеп китмәгәе,— дип кенә кистерде.

Тап өстенә баскандай, рас сүз әйткән икән.

Ни өчеңме?

Соңгы бер-ике елда, аерата җәйге айларда, алар совхозында кунак-төшем күбәеп китте әле. «Кунак-төшем» дигәч тә, эшем кешеләре түгел, эш кешеләре иде, билгеле: әле алар совхозында яшелчә үстерүләргә яисә һәйбәт сенаж әзерләү, шәпләп силос салу җайларына багышлап хуҗалыкара семинар уздырырга тотыналар, әле төзелеп яткан яңа поселок белән андагы терлекчелек комплексына төрле белгечләр киңәш-табыш итәргә җыелыша. Тик алар Чаллының үзеннән яки үз төбәгеннән генә җыелсалар ла икән! Казаннан да, хәтта Мәскәү тикле Мәскәүдән дә килеп төшкәлиләр бит. Арада карар күзгә яшь кенә күренгән, әмма зур-зур дәрәҗәле агай-эне дә, чаларган чәчле олы-олы абзыйлар да булгалый.

Кунак-төшем ишле булганда, рабочком, әлбәттә, уртада кайнаша, күп нәрсә шуның җилкәсенә ава иде. Авуын ава да... ире Хәнәфигә ни кылырга кала? Менә дигән иркен һәм пөхтә җыештырылмалы өе, өстәвенә, туган авылында аш-су, ризык-нигъмәт әзерләүдә иң осталардан исәпләнгән хатыны барында, үз йортына дәшми, авыл буенча баш орып ялынып йөрсенме? Шөкер, андыйлардан түгел — кеше хакына үз җәймәсен бик һәйбәтләп җәя белүчеләрдән!

Әмма гелән дә алар өендә бикләнеп калмаслар иде: көн матур һәм җылы булып, совхозларында «эш кунакларының» дәрәҗәлерәкләре, олыраклары өелешеп тә йөрсә, казанны Калмаш каенлыгының яисә Әҗер карамалыгының аулаграк аланына илтеп асарлар иде. Ул матурдыр, купшыдыр алан, якында гына чишмә чылтыраидыр, һавасы сафтыр, дөнья тынычтыр — туйганчы кинән!

Тора-бара Рәсүлә дә бу хәлләргә күнегеп, ияләшеп китте. Ияләшү генәме, ни дәрәҗәле, ни олы кунаклар булмасын, табын артында купкан гәпкә ул да һич битараф калмас, үзе ишеткән-белгәннәрне кыюсыз гына булса да ара-тирә кыстыргалап җибәрер иде. Үзе бер үк вакытта тегеләр — бигрәк Казан һәм Мәскәүдән килгән олы адәмнәр — әйткәнне дә колак шәбәртеп тыңлар, моның белән үзенчә гыйлем сеңдергәндәй булыр, хәтта җан офыклары да киңәеп киткәндәй тоелыр иде.

Рәсүлә әзерләгән ризыкларны һаман да үтереп мактаучы директор Мөслим Акбашев, аның шушы хәләтен бик әйбәт сизеп алганга күрәдер ахры, кайчакларда гәп кызып китмәс борын ук, кинәт кенә кыбырсып:

— Кая әле безнең Рәсүлә ханым? — дип, күзләре белән эзләштерергә тотына.— Эһе, монда гына икән... Синнән дә уздыручы булмас, Рәсүлә ханым: шома телең белән авылдагы тормыш җайларын, совхоз хәлләрен аңлатып бирче кунакларга! — ди. Аннары табынга җыелганнарның күңеленә чаткы салу өчендер, ахры, төшендерергә тиеш таба: — Совхозыбызның кырлар хуҗабикәсе булыр бу, аның белмәгәне юк,— ди.

Андый чакта Рәсүлә, билгеле инде, уңайсызланып китә, сыңар кулы муены төбенә бер менә, бер төшә. Әмма ул үзенә төбәлгән сагаюлы яисә ымсынулы йөз-күзләрдән посар әмәл дә таба алмый, нишләсен — кыюлана төшәргә туры килә — тегеләрнең сорашканы гына аның күңеленә ятышып китәрдәй булсын...

6

Бер кичне Хәнәфи бик соңгарып, төн урталары җиткәндә генә кайтып керде. Партком белән рабочкомның берләштерелгән утырышын уздырганнар икән. Борын төбендә генә уракка чыгар көннәре, менә шуңа хәзерлекне кабаттан, инде бик тә җентекләп тикшергәннәр, әмма иң кызыгы, әле беренче тапкыр диярлек уртага салып, ныгытып, Яңа поселокны һәм андагы комплексны коручыларга булышу җайларын сөйләшкәннәр. Иренең шушылай төрле утырыш-киңәшмәләрдә батып калуларына Рәсүлә инде күнегеп бара иде, шул сәбәпле монысына да әллә ни исе китмичә, гадәти бер хәл дип карады. Ләкин Хәнәфинең азаккы сүзләре аны сискәндереп җибәрде:

— Акбашев әйтә әле анда, Яңа поселокка бүгеннән үк исем табу хакында уйлашканда да зыянга килмәс, бәлкем, совхоз буенча конкурс игълан итәргә кирәк булыр — халык тапкан исем матуррак яңгыравы бик ихтимал, ди...

— Исемме? Җаңа поселоккамы? Бүгеннән үкме?

Рәсүлә, күңеле әллә нишләп куйганга, утырган кәнәфиендә утырып кала алмыйча, бүлмә буйлап йөренеп китте. Әллә нәрсәгә барып орынды, әллә нине килеп алды...

Бер тукталганда, күз карашы үзеннән-үзе шифоньер

өстендәге тузан җыеп яткан яшел тышлы дәфтәренә төбәлде.

Менә шул төндә кузгалды да инде аның җан өянәге...

Яшел тышлы дәфтәрне кат-кат актарудан файда чыкмады: анда, бихисап булса да, нибары адәм баласына тиешле исемнәр генә теркәлгән иде. Бетмәс китап укыган чакларында, исем-атамаларның бүтән төрлесенә игътибар итмәвенә, андыйларын да җыеп-теркәп бармавына кабат-кабат үкенде.

Ләкин ул исем кушуда бөтен Әҗердә «атаулы» булган башы белән җебеп-өшеп калырга тиеш идеме соң? Исемнең иң матурын, иң нурлысын ул табарга тиеш, нибары ул!..

Монда бит күрше-күләндә туган берәр нәнигә исем табу гына түгел, поселок тикле поселок — дөньяда булмаган хәл ләбаса!

Кайчан, кем язмышына тигән, ди, мондый форсат?

Басу юлы белән дыңгыр-даңгыр эшенә барган чагында да, үз ихатасында тузан туздырырга тотынса да, Шилнә буена каз-үрдәк эзләргә төшкән җирендә дә уенда гел шул булды.

Кичә тапканын бүген ошатмый, бүгенгесен иртәгә юкка чыгара — бәла икән лә бу дөньяда исемнең асылын табулары!

Тәмам җан тынычлыгын җуйды...

Үзенең «кырлар хуҗабикәсен» әллә нишләтте лә бу яңа директор...

7

Кайсы гына хатын-кыз, ирек иңгәндә, тәмләп тел тегермәнен тарттырудан тайчаныр да бизәр, ди?

Кышларын, әлбәттә, вакыт тигәнлерәк. Тышта сулышларны куырырлык чатнама суык була яисә күз ачкысыз буран үзенең «җен туенда» котырына, ә син җылыда, рәхәттә тустаганыңда әчкелтем миләш яки карлыган кагын җебетеп һәм бер үк вакытта үтәдән тәмле кура җиләге вареньесын да капкалый-капкалый, ягъни ләззәт чишмәсенә тәмамлый чумып һәм моның өчен «күршегенәкәеңә» мең рәхмәтләр әйтә-әйтә, көмеш самоварны сыгарга тотынасың. Сыга бирәсең — «көмеш буксә» әкренләп бушый бара, аның саен, гәүдәңә никадәр сеңдерсәң дә, күкрәкләрең киңәеп, җаныңа җиңеллек һәм хозурлык күбрәк иңгәндәй тоела бара. Дөрес, кайчагында иләкләрендә сүзнең әчкелтеме мулрак иләнгәндә, кү-

җелгә юшкыны да утырмый калмый — беркая китәсең юк, көн күрмештә андые да булмый тормый...

Җәен, билгеле инде, вакыт күпкә кысанрак: тегесенә өлгер, бусына җитеш!..

Ләкин, бик теләгәндә, хатын-кыз җаен табалмый йөдәрмени соң? Гадәттә кичләрен, кояш баеп килгәндәрәк, берәрсенең капкасы төбенә җыелышып, андагы эскәмиягә җәйрәп утырышалар. Авыл инде тынып калган, урамнарда тузан басылып, һавада мал-туар исе, яңа сауган сөт исе таралган була.

Өзелми, авызларга сүзнең төрлесе — миләш кагыдай әчесе дә, кура җиләге вареньесыдай тәмлесе дә килә... Бүгенге дөньяда, бигрәген дә әйләнә-тирәндә ҚамАЗ зил-зиләсе бөтерелгәндә, күтәрел алып, селкеп салырдай хәл-хәбәрләр бетәр димени? Шулай да, сүз инешен ипле генә агызып яткан мәлләрендә, чын елга агымының текә ярларга орынып, айкалып-чоңгылланып торган урыннары булган шикелле, боларның да көннең көнендә диярлек, әйләнә-бөтерелә килеп, туглаган нәрсәләре була: тозлап-борычлап бүгенге яшьләрнең тетмәсен тетәләр, соңгы елларда һава хәлләренең яман тотрыксыз, алама булуының сәбәбен космоска очыртулардан күреп, монысын бик зәһәр каһәрлиләр, аннары уфтана-уфтана... үткәндәге тормышның иплерәк, матуррак булуын искә төшерергә тотыналар. Кеше күңеле шулайдыр инде: вакыт җиле сыйпаштыргалаган саен, үткәндәге хәлләр шомарак һәм күркәмрәк булып күренә торгандыр. Һәм әнә шул шома, күркәм күренешләр арасында ни сәбәптәндер аерата ямьлесе булып, күз алларында авыллары Әҗерне ҚамАЗ төзүчеләре явы баскан көннәр калкына. Алай озак та яшәмәделәр — иң күп дигәне дә ике елын да тутыра алмагандыр — вакытлы поселоклар һәм Яңа Чаллы каласы шактый тиз кире суырып алды үзләрен, тап инде ай күреп, кояш алгандай булды, әмма ул яуның авыл язмышында, кешеләр күңелендә калдырган эзе? Яман кысанлыкта интеккән, уйламаган кыенлыклар ашаган чаклары да аз булмады шикелле, тик инде хәзер болары кайдадыр ерак рәшә эчләрендә эреп югалган, инде беленми дә сыман. Шулай димәскә, әнә бит киң эскәмиядә җәйрәп утырган җирләрендә тирән-тирән сулап куйгалыйлар да:

— Исән-имин хәлләрдә җөриләрме икән, бахырлар? ҚамАЗ зил-зиләсендә кайларда, ниләр җимерттерәләр икән инде? — дип, кичке эңгердә билгесезлеккә сорау белән төбәләләр.

Һәм шуның арты ук:

— Уттай-җалкыннан туган халык, шәт, сынатмыйлардыр. Берүк, бәхеткәйләр җылмайсын ие инде һәммәкиенә! — дип, күк гөмбәзендәге алсу шәфәкъ нурларына күз төшергәли-төшергәли, изге һәм матур теләкләрен Чаллы тарафларына очырталар...

Үткәннәрне сагынып искә төшергәндә яисә бүгенгенең кайбер якларын ачынып тиргәштергәндә, сүз-хәбәрнең кызыклысы, өр-яңасы, теге чакларда бөтенләй уйга да килмәстәе, шул сәбәпле гәпне капыл җанландырып җибәрердәе дә сөзелеп чыккалый.

— Әле кичәгенәк Чаллыга барып кайткан ием,— дип куя арадан берсе шулай.— Исләрем-акылларым китте: урамда җөргәндә ник бер сакалбай очрасын ла икән! Әкәмәт булмый ни: кайларга олагып бетте икән ул албасты сакалбайлар?

— Олагыр, ди, сиңа! — дип шундук төзәтергә ашыга икенчесе.— Сакал пумаласының мудасы беткәнгә генә ул!

— Аннары, дим, Чаллы урамында очраган һәр өч хатынның берсе көмәнле! Билләһидер! Ис-акылларың китмәскә, автобуска ни утырасың, ни төшәсең җук — һаман да шулар!

— Сөбханалла диген!

— Андагылар хет булдыра, андагылар һәммәкие дә, күзләр тия күрмәсен, уттан-җалкыннан туган нәмәрсәләр! Ә безнекеләр? Безнең Әҗер киленнәре? Шул тиклем җебегән җаннар туры килсә дә килер икән... Әллә инде ниме дим, аптырагач... җәп-җәш көенчә ирләре белән җокларга да шүрлиләр микән, дим? Тфү, тфү, эфсен-төфсен!

— Әйтмә, Фәгыйләттәй!

Кичке тынлыкны ярып, рәхәтләнеп бер көлешеп алалар да тирән сулый-сулый беравык дәшми-тынмый утыралар, хәл җыялар. Моның соңында арада берсе, сулышын алданрак рәтли алганы, сүнә төшкән учакка үз йомычкасын җәтрәк салырга ашыгып, аңа өреп җибәргәндәй иттерә:

— Тик читкә-чатка киткән кызларыбыз сынатмасын гына инде. Ә болай Әҗеребез кияүләрнең ниндиен генә эләктереп калмады, ә?

— Әйтерең җук: менәтерә Рәсүләнең молдаван кияве берүзе генә дә ни! Аның мыегын әйтмәем — мыектыек песидә дә бар,— килеш-килбәте дим, холкы-фигы-

ле, дим. Бүтән милләттән, бүтән деннән булса соң... Адәмлеге ни тора бит аның, адәмлеге!

— Ә Игәчтән Мөршидә кияве? Аты кем әле... теге ни... Дагстанның Махач-каласыннан — күргәнегез бар инде. Борыны кылыч булса соң, сөлектәй буй-сын, үткер күзләр, гөлдер-гөлдер сөйләшүләре...

ҚамАЗ төзелешенә читтән очып килеп, Әҗер кызларын эләктергән бөркетләр арасында ике-өч татар, берике башкорт егете дә бар барын, әмма аларны сирәк телгә алалар, чөнки моның алай искитәрлеген һич тапмыйлар — күптәннән күнегелгән хәл дип саныйлар. Ә менә молдаван белән дагстанлы кияүләрен тел уртасына салып, бик рәхәтләнеп әвәләштерәләр — бусы, күрәсең, кызыклырак та, тәмлерәк тә...

— Бәхетләрен сүрелдермиенчә тигезлек белән җәши күрсеннәр инде.

— Дөрес, Фәгыйләттәй, дөнҗада иң әүвәл тигезлек кирәк!

Шушылай кич утыруларның уртасында гадәттә Рәсүләнең аягоч күршесе Фәгыйләттәй була. Иренми, кич саен диярлек тыкрыкның теге чат башыннан болар янына килеп җитә. Мондагылар белән гәп корулары аңа рәхәтрәк һәм татлырак, күрәсең. Хәер, аны Түбән очта якын һәм үз итмәгән кеше юктыр да...

Фәгыйләттәй тол хатын: яшьли сөйгән ире сугыштан әйләнеп кайтмады. Бердәнбер улын үстереп һәм аны көченнәнчә укытып кеше иткәч, инде хәзер япаялгызы яшәп ята. Нибары бер-ике сарык асрый, кошкортны да әллә ни күп тотмый, шул сәбәпле җиңгәчәйнең ишегалдында күпереп торган яшел чирәм — тәгәрә дә ауна!

Шактый эре сөякле, калынча гәүдәле, чак кына җәенке, карасу йөзен мул иттереп җыерчыклар бизәгән бу хатын ничәмә дистә еллар колхоз фермасында сыер савып, тырыш, уңган хезмәте белән заманасында үз исемен ярыйсы ук шәп шаулата белгәннәр токымыннан иде. Пенсиягә ул әле бик күптән түгел, хуҗалыклары совхозга әверелгәч кенә, чыкты. Шул уңайдан җиңгәчәй баштарак, аны-моны уйламыйча:

— Минеке калхуз тоттырган крестиянский җегерме тәңкә түгел. Шөкер, кесә тутырып рабучий пенсиясе алып җатабыз,— дип, бүтәннәр алдында ярыйсы ук һаваланып та куйгалый иде.

Пенсиягә аңардан алданрак чыкканнар, ягъни өлкәнрәкләр, нибары «крестиянский җегерме тәңкә»не төсиләүчеләр моңа җавапка:

— Әллә әртилгә без кимрәк өлеш кerтkәнме? Эш дигәнендә без дә аз кыйландырганмы, җөрәк майларын аз суырдырганмы әллә? Кайларга качып җөри торгандыр ул гаделлек дигәннәре? Җугыйсә бит без дә савхуздан китмәгән, без дә аның корткалары,— дип, каш-күз җимереп, үпкә-рәнҗүләрен шундук сиздерерләр иде.

— Соң, гаеп миндәмени? Крестиян белән рабучий арасындагы аермалыктан бит ул, калхуз белән савхуз аермасыннан...— дип үзенчә акланып маташкалар иде Фәгыйләттәй.

Мондый сөйләшүләрнең юньлегә илтмәячәген ул бик тиз аңлап алды. Һәм соңгы вакытларда үзенең «кесә тутырып алган рабучий пенсиясе» хакында бөтенләй сүз катмас булды.

Әмма, аның каравы, туган авылы Әҗернең алдагы язмышын кайгыртып, бүгенге яшьләрне, аерата «сыксаң майлары тамарлык» киленнәрне уртага салып, аларның тетмәсен теткәндә, арада Фәгыйләттәйне уздыручы булмас иде. Монда ул ни тозын, ни борычын җәлләмәс иде...

8

Дәрт-гайрәте ташып торган, йөрәгендә кайнар кан типкән егет кеше кыз-кыркынга күз салмыйча, битараф кына йөрер диме соң!

Дөрес, бу тарафтан өлкән уллары Айдашның бер заман авызы бик яман пешкән иде инде. Армиядә хезмәт иткән чагында ул Югары очтан бер кызый белән матур гына иттереп мәхәббәт җепләрен төенләп маташкан иде. Ләкин теге иләс-миләс чәчлекәй Айдашның армиядән кайтып төшәр вакытлары җитеп килгәндә генә, тотты да җәһәт кенә күрше авыл Калмашка кияүгә китеп барды һәм шул вәгъдәсезлеге белән егет җанын бөтенләй өшетеп куйды сыман. Хәзер инде, бер тапкыр кәкре каенга терәтелгәч, Айдашлары һич ашыкмый-кабаланмый, зур саклык һәм аек акыл белән эш итәргә чамалый кебек.

Вәсим исә бөтенләй бүтәнчә кыланды: армиягә алынганчы тегесе белән йөрештерде, бусы белән чуалды,

солдат хезмәтеннән дә төрлесенә-төрле хатлар язгалап, монда авылдагы чибәркәйләрне буталдырып, хәтта үзара ызгыштырып бетерде.

Тегендә, мәхшәр оясында да, Вәсим әле һаман да үз холкының колы, имеш: әле тегендие белән, әле мондые белән гыйшык-мыйшык уйнаштыра, ди.

Уртанчы улының шушылай җилкуарланып, йөгәнсезләнеп йөрүләре әнисе Рәсүләнең җанын әрнетә, аны тирән пошаманга сала иде.

Бервакыт, төрле күңелсез уйлардан гаҗиз булгач, ул кызы Рәмиләдән тегендә абыйларына күз-колак булыбрак, тегесен-бусын белешкәләп торуын үтенгән иде. Әмма Рәмилә, йөзен җыерып:

— Авылда чакта да абыйлар хакына шпион булып йөрүләрдән туеп беткән идем инде. Хәзер мин үзем ир хатыны. Вакытым да юк, шпионлык итүләр хәзер миңа килешми дә,— дип кырт кисте.

Яшь хатынның өлкән абыйларыннан, бигрәк тә Вәсимнән, җаны тәмам бизгән иде, ахрысы.

Ниһаять, кибеткә барган җирендә Рәсүләнең колагына өр-яңа хәбәр иреште: имештер, Вәсимнәре соңгы арада Чуар кызы Фәүзиягә кармак салырга керешкән, ди, имештер, ниятләре зурдан, ди... Бу хәбәрне ишетүгә, Рәсүлә аңгы-миңгеләнеп китте, сулышы капты, эченә салкын йөгерде. Югыйсә аңа, уртанчы улы дуамалланудан арынып, акылына килә башлаган дип, куанырга гына иде, әмма юк, булдыра алмады: кызый ул һич теләмәгән авылдан иде.

Күңелдә авыр пошаманны озак саклап йөрүдә мәгънә юк иде, бер тымызык кичне, аулак сәгатьтә ул аны ире Хәнәфигә сиздерде.

— Кем кызы? — дип текәлде ире, калын кашларын югары чөеп һәм авызын киң ерып.

— И, җәймәсәнә авызыңны!.. Чуар кызы, ди, шул сихер оясыннан, ди... Фәүзия атлы, ди.

— Атасы-анасы бардыр ич?

— Булмыйча... Әнисе теге кем... Нәфисә инде. Гәрәбә аскан тутырган тавык. Үзе югыйсә нибары сыер савучы гына, ә һаваланулары күктин ашкан: районда атаклылардан, имеш.

Хәнәфи шундук чамалап алды ул хатынны: чынлап та, һавалы да, җилле дә нәрсә...

— Әтисе, дим, кем? — Монысын инде Хәнәфи ничектер ихтыярсыздан гына төпченгәндәй иттерде.

— Сораган буласың тагы... Шофер Шәйхулла.

КамАЗ башлану белән үз совхозыннан тайган адәмнәрдән.

— Тайган? Хаталанма! Үзебезнең Айдаш белән бер вакытта Яхъя Таипыч рөхсәте белән китте ул төзелешкә. Ипле кеше, чын адәми затлардан! Инде озакламый кире кайтырга да җыена бугай.

— Ипле сиңа! Хатынының олтырагы астында изелгәннәрдән... Үз малаең Вәсим дә шундый җазмышка дучар булсын дисеңме әллә?

— Ә син безнең Вәсимне ансат кына бирешер дисеңме? Ул үзе карчыга!.. Ә бит алар, җитмәсә, борын төбендә генә, нибары алты-җиде чакрымда гына утыралар.

Хәнәфинең тавышында куанычлы дулкынлануы аермачык сизелде — моны хатыны бөтенләй ошатмады, аның ярсуы көчәя генә төште сыман:

— Сиңа әвеш-түеш килеп җөрергә генә булсын! Ә мин ул бичура белән кодагый булырга уйламыйм да, аңа ул матур сүз белән эндәшергә җыенмыйм да...

— Анысы үз ихтыярыңда. Куркасы да юк: кодагыйкодачалар дөнья тутырук. Ә менә кода дигәнең... кода...— Хәнәфи бу минутта хәтта бик тә авыр сулап куйды.— Бу чын асыл затларны табулары кыенрак шул бүгенгесе көнне...

— Чуар белән кодаланырга алай бик ашыкма әле — пешүең бар! Җук-җук, тәгаенләмичә һич булмый.

Кода, кодалар... Хәнәфинең уфтануы бер дә тикмәгә түгел иде. Кызлары Рәмиләне әнә кияүгә бирделәр, зурлап туй үткәрделәр, әмма ул үз этисен «кодалы» итә алдымы соң? Юк. Кияүләре Женя Мынданың этисе, Хәнәфи өчен бик тә кадерле, бик тә тансык кеше, ике ел элек гүр иясе булган икән. Шулай инде, сугыш уты аша үткән асыл ирләр берәм-берәм китә баралар.

Чаллының иркен һәм якты кафесында шаулап-гөрләп узган туйга тегеннән, молдаван ягыннан, егетнең әнисе белән бертуган апасы һәм җизнәсе килгән иде. Болай җор холыклы, ачык чырайлы кешеләр икән, туйның үзендә дә, соңыннан да һич сынатмадылар, яшьләр тантанасына нур өстенә нур булып кундылар. Ләкин туй мәҗлесе нихәтле генә күркәм һәм түгәрәк үтмәсен, Хәнәфи анда үз тиңе кодасы булмаудан бушлык һәм нәүмизлек ачысын нык тойды.

Ә тегендә баргач, бу җан ачысы тагын да көчәеп китте сыман. Әйе, молдаван кодагые һәм аның кызы белән кияве боларны бик гозерләп кунакка чакырдылар. Кызлары Рәмилә белән кияүләре Женяның алдагы тор-

мышы матур һәм нык төенләнүен теләгәндә, аларның дәшүен һич читкә кагарга ярамый иде. Әмма барасы юллары ерак, бик ерак иде. Ә Рәсүләнең — кая аңа андый сәфәрләр! — Чаллы, Алабуга, Зәй тирәләреннән арырак китеп, юл йөргәне дә юк иде. Курыкты, бик курыкты. Алай да үз-үзен җиңде, вөҗданына хилаф кылмады. Озаклап һәм бик әйбәтләп әзерләнгәннән соң, былтыр җәй башында, язгы чәчү эшләре түгәрәкләнгәч, ниһаять, тәвәкәлләделәр һәм, Бигештә самолетка утырып, Одесса тарафларына сәфәр тоттылар.

Авыллары зур гына икән. Боргаланып-сыргаланып аккан мул гына сулы инеш буена җәелеп утырган. Үзе, җитмәсә, тоташтан яшеллек эченә күмелгән — хәйран калырлык. Хуҗалар үзләре дә әкәмәт кыланды: төрле сыйларның, аннан да битәр, кадер-хөрмәтнең чиге булмастыр кебек тоелды. Дөрес, агач-куак җимешләре — алмадыр, чия-йөземдер — әле өлгермәгән чак, әмма, аның каравы, бакчаларындагы озын-озын түтәлләрне кып-кызыл, сусыл җир җиләге — виктория баскан иде. Туйганчы рәхәтләнделәр, ичмаса! Рәсүлә дә алай бик төшеп калганнардан түгел: үзләре белән алып барган күчтәнәч нигъмәте — чәкчәк, катлама-бавырсаклар — белән сыйлагач, ул тегендәгеләргә бу татлы-тотлы ризыкны пешерү әмәлләрен дә өйрәтте. Әнә шулай, русча белүе такы-токы гына булса да (хәер, бу җәһәттән молдаван кодагый-кодачаларының осталыгы әллә нидән түгел иде), Рәсүлә теге як белән бик тиз арада уртак тел таба белде, араларында эреде дә бетте диярлек. Ә Хәнәфи? Аның русчасы начар түгел, хәтта әйбәт дияргә мөмкин иде — ни әйтсәң дә, өч елга якын фронтларда йөреп ярыйсы гына шомарган солдат — ул һич сер бирергә теләмәде, көләч йөз, көр тавыш сакларга тырышып, молдаван дусларының әле бусы, әле тегесе белән булдырганча гәп корып җибәргәләде. Ләкин шулай да... Олы бүлмәләренең акшарлы стенасында иң түрдә дүрт почмаклы җыйнак кына портрет эленеп тора иде: ак чырайлы, купшы кара мыеклы, ягымлы, әмма үткен карашлы хуҗа сурәте иде ул. (Кияүләре Женя суйган да куйган этисе икән!) Хәнәфи җансыз сурәтнең җанлы карашы һаман да үзенә төбәлгәнен тоя, күзләре очрашканда, аның күңеле әллә нишләп китә иде... Менә кем кирәк иде аңа, бик кирәк иде! Ул да бит бик күпне кичергән, диләр: сугышның беренче көнендә үк ут эченә кергән, партизан булып йөргән, әллә ничә тапкыр яраланган, ахырда, инде гаскәри частьта Будапешт өчен

барган сугышта яман контузия алган. Аларның, Хәнәфи белән икесенең, сугышып йөргән мәлләрендә, юллары кисешкән урыннар да, бәлкем, булгандыр. Булмаса да... Күз нурларын һәм җылы сулышларын кушылдырып, искә төшерер нәрсәләре, сөйләшер сүзләре күп булыр, һай, күп булыр иде лә. Әмма үлгән кешене терелтеп, җансыз сурәтне җанландырып булмый шул! Тыныч тормышта, саулыгы бераз рәтләнә төшкәч тә, тынгылык белмәгән, ди: авылларын төзеклəндерүдә күп тирләр түккән, аңа электр кертүдә башлап йөргән, кешеләргә җылылык һәм яктылык биреп торган, ахырда егылган... Алай да аңардан сукрану-сыктану авазы чыкмаган, тормышта көр һәм саф күңел белән яшп белгән — туганнары аны бик тә хөрмәтләп искә алалар... Их, һич югы шушы көләч йөзле, матур көннәргә тикле яши алган булсачы! Баһадир улының шанлы туен, аның зур тантанасын күрер, кем белән туганлашуын, кемнәр аңа кода-кодагый булганлыгын белеп китәр иде, ичмаса, якты дөньядан... Күз карашлары очрашу белән Хәнәфи күкрәк читлегендә йөрәк тамырларының әчетеп-әчетеп тырналуын тоя, җанын авыр хис өтеп ала, гүя ул молдаван кодасының да өлешенә кереп яши, гүя кодасының вакытыннан иртә гүр иясе булуында аның да күпмедер гаебе бар сыман... Анарчы Хәнәфинең андый халәтне беркайчан да кичергәне юк иде әле.

Кайтыр сәфәрләренә кузгалыр алдыннан алар азаккы көннәрен Одессада үткәрделәр. Бу данлы каланың яр буйларын гизделәр, диңгезне күзәттеләр, дулкыннар шавын тыңладылар, ә кайткан чакларында, Мәскәү тирәсендә бер аэропорттан икенчесенә күчкән мәлләрендә, шулай ук шактый гына вакыт бүлеп, башкаланың бөтен дөньяга билгеле булган урыннарын тамаша кылып йөрделәр.

Заманында ярты Европаны айкап үткән булса да, аңарчы Хәнәфинең ни диңгезне күргәне, ни дулкыннар шавын ишеткәне, ни башкала урамнарын гизеп йөргәне булмаган иде — бу җәһәттән аның күңеле бөтенләй түгәрәкләнеп һәм хозурланып кайтты. Ә Рәсүлә хакында әйтеп торасы да юк. Аның җаны менә инде янә хиресләнә башлады кебек. «Инде бу җулысында ничек тә җайларын китереп бакча җимешләре өлгергән чакка туры китеребрәк барасы булыр, иеме?» — ди. Хәнәфи бу хакта әлегә бер сүз дә әйтә алмый. Ерак сәфәрләрдә йөреп, күз күргән дөнья ямьнәре, сусыл бакча җимеш-

ләренең татлы тәме аның күңелендәге бушлыкны тутырып, йөрәк чәнчүләрен баса алырмы икән?

Ә Чуар авылы кул сузарлык җирдә генә... Их, Вәсимнәре җылы колак булып, җебеп йөрмәсә лә икән, эләктерә алса ла икән ул нечкә билне! Кызның әнисе, Рәсүлә әйткән «гәрәбә аскан тутырган тавык» Нәфисә чая инде чаялыкка, ләкин аны һич кенә дә чиктән ашкан усал яисә явыз дип әйтә алмассың — телең корыр. Әтисе Шәйхулла сугыш ветераны түгел түгелен — сугыш алар буынын ялмап алырга өлгермичә калды. Дөресе, Хәнәфиләр буыны саклап калды аларны. Дөньяда күп андыйлар, бик күп — тоташ диярлек. Әмма Шәйхулла шул күпләр арасында болай ярыйсылардан шикелле: тырыш та, күндәм дә кеше, тиккә сүз боткасы әвәләргә яратучылардан түгел, аның белән борчаклары бик пешәр сыман. Хәл-әхвәл белешкәләп, кунакка йөрешүләр дисеңме, иңне иңгә терәп, ярдәмләшүләр дисеңме — кодакода булып яшәүнең чын рәхәтен татырлар иде, ичмаса! Ләкин... Рәсүләнең күңелендә инде әллә кайчан дөмегергә тиешле көнләшү җене янә котыра башлады, ахры. Аның үз хасияте — хасият...

Рәсүлә «тәгаенләмичә» түзә аламы соң? Икенче көнне үк ул совхоз яшелчәлегенә эшкә йөргән Чуар хатыннарыннан тегеләйрәк иттереп, болайрак кыландырып, малае хәлен ачыкларга керешкән. Чуар хатыннары кыеклап-мыеклап торуны һич өнәми, ул бәләкәй генә авылда теләсә нәрсә көн күзендә бар яклары, бөтен төсләре белән калкынып һәм нурланып тора, Рәсүләгә «чын турысын» ярып салганнар. Шулай, ди, йөрештерә, кай көннәрдә мотоциклга атланышып җалт кына кайтып төшәләр, ди, ләкин ул җегет күптән инде кармак салулардан узган, әле үткән якшәмбедә генә Нәфисәнең түрендә кадерле кунак булып сыйланып китте, ди.

— Әнә ничек бит! Әйтәм җирле, узган атнада күзләре бик майлы күренгән иде, өйдә дә сәгатьтән артык булмады, җәтрәк шылды,— дип чәчелергә керешге Рәсүлә, кичен ире белән янә аулакта калгач.— Тегендә, кызыйның Чаллыдагы тулай торагында ни кыландыра торганнардыр, ә монда... шул бичураның түрендә кияү җегет булып сыйланып утырсын әле малаең!

— Вакыты җиткән, күрәмсең,— диде Хәнәфи, тынычрак булырга тырышып. Үзе күңеленнән: «Ни өчен безнең авыл хатыннары шул тикле күралмый Чуарныкыларны? Тегеләрнең уңганлыгы-булганлыгы өченме? Бөтен авыллары белән ирләренә баш булып яшәгәннәренә

күрәме? Бу Рәсүлә бигрәк тә...» — дип ачынып уйлап куйды.

— Житкәнме, житмәгәнме, ул Чуар тарафларына борылып карыйсым да килми.

— Сәбәбен әйт, ник әйтмисең! Бер мәлне, диген, ирем-канатым шул гәрәбәле бичураларның берәвесен, мотоцикл әржәсенә утыртып, Чаллыдан ук алып кайтты, диген. Кайтканда посадка кырыенда, ак җәймәләр җәеп, сыйланышып, бик тә хозур утырдылар, аннан соң, ул тутый кошны Чуарына хәтле ук менгереп куйды, диген. Ә ул нәфис җанның исеме... Нәфисә ие, диген.

— Ә ник, әйтермен дә...

— Тагы да шуны исеңә төшер...— Хәнәфи, авызын кыйшайтып, мәсхәрәле көлү аша хатынының элек бәйләнгәннәрен җепкә тезде дә тезде: — Икенче бер тапкырында, бәйрәм тантанасында, зур клуб сәхнәсендә үтәдән ашкан Чуар чибәренең иңбашларына затлы кашемир шәле элгәч, сыртыннан бик озак иркәләп сыйпаштырып торды, диген... Хәер, анысының аты бөтенләй бүтән иде бугай...

— Булмаган, кеше күрмәгән хәлме әллә?

— Мин дә бит дөрес, дим... Ә узган кышны җыелышка менгән җирендә, ачы буран сылтавы белән куна калгач, бер зәһәр дә купшысы үзенең йомшак түшәгендә йоклатып чыгарды, диген. Бусының исеме Миңлебикә ие, диген.

— И мыскыл итүләрең...

— Нишләп? Үзең әйткәннәрне, үзең төрттергәннәрне генә исеңә төшерәм ич. Бик тәмсез мәллә? Малаеңа да тезеп сал — йөрәгенә май булып кунсын!

— Тезәрмен дә...

— Көлкегә каласың килсә...

— Миннән түгел, синнән көләрләр. Әүлия булып кыланган буласың, чын дөресеңне белерләр, ичмаса!

Рәсүләнең зиһене тәмам чуалган, аңарда нибары ачы хисләр өермәсе бөтерелә шикелле. Хәер, Хәнәфи үзе дә шул ук өермәдә бөтерелә түгелме соң? Шушылай үзара чәнчешүләрен дәвам иттерсәләр, ахырда кая җитеп төртелерләр? Ие, Хәнәфигә хатынының зиһенен ничектер чатнатып җибәрергә кирәк иде, ниһаять, әмәлен тапты сыман:

— Белмиенчә җилләр өрдереп, ялкыннарын көчәйтеп җибәрүең генә ихтимал... Рәмиләгә киртәләр куеп азапланган идең, җиңә алдыңмы? Түреңә кияү булып үзең теләгән кеше менеп утырдымы соң? Ә Вәсимнең

үҗәтлеге Рәмиләгә карый биш битәр артыграк — чамала!

Рәсүлә капыл сүзсез калды, уң кулы муены төбенә менде. Диванда кулына газета тотып, әмма аны укырга керешә алмыйча утырган иренә каш астыннан зәһәрле караш ташлады да, алгы өйгә чыгып, савыт-саба шалтыратырга тотынды. Ләкин анда да озак матавыкланмады, җанын язып җибәрер өчен генә, кичке урамга берәрсенең капка төбен сакларга чыгып китте.

9

Былтыр да, бу елны да, кыш язга таба авышып, кояш елмаебрак карарга тотынгач, Рәсүлә белән аның аягоч күршесе Фәгыйләттәй берара совхоз теплицасында эшләп алганнар иде. Ачыклап әйткәндә, икәвесе бер звенога укмашып, совхозга, дөресе, КамАЗ төзүчеләренә, байтак кына яшел суган үстереп бирде алар.

Теплицаның артыгы белән җылы һәм бөркү һавасына чыдый алмыйча, хатын-кыз өс киемнәренең калынрагын салып атып, бик юкадан гына калып эшли. Бер ишеләре, Мәймүнә, Гөлсем һәм читтән килеп алар авылында утырып калган Лида Уханова кебек, кыяр үстерергә тотынган яшь хатыннар, анадан тума диярлек кыяфәттә йөри бирә. Әйтерсең су буендагы пляжга килгәннәр. Алай ук кыланмасалар да булыр иде, югыйсә. Дөрес, андый чакта теплицаның ишекләрен эчке яктан ныгытып бикләп куялар, эчкәрегә ир-атның әллә кемен түгел, хәтта җылыткыч генераторларының хуҗасы — машинист-оператор Сергей Ухановны да хатыны янына кертмичә йөдәтәләр. Янәсе, авызын ачып, тиккә майландырмасын күзләрен...

Звенолар үз түтәлләрендә генә эш кыйратканда, сүз чәйнәми тормыйлар. Ә инде звенолар бер-берсенә булышмага тотынып, кушылыбрак китсәләрме? Ул чагында чыда гына — сүз измәсен тегеләйгә дә туглыйлар, болайга да изәләр! Әнә шулай дөнья һәм тормыш хәлләрен бик тәмләп әвәләгән сәгатьләрендә, яше белән бүтәннәрдән шактый өлкән булган, гомер итештә тәҗрибәсе дә хәттин ашкан Фәгыйләттәй сүзе гадәттә һәрчакны диярлек өстен чыга. Ләкин шулай да, бик сирәк булса да, Фәгыйләттәйгә дә кайчагында сүз көрәштерешнең ачуташ тәмендәгесен дә тәмләп карарга туры килгәли...

Бер көнне шулай, кыяр үстерүчеләргә булышмага чыгып, алар бүлемтеләрендәге буйдан-буйга сузылган тимер чыбыкларга, яшь үсентеләр югарыга таба ипле

генә үрелеп-күтәрелеп китсен өчен, сүс баулар бәйләп маташкан чаклары иде. Менә шул мең мәшәкатьле эш белән матавыкланып, бер үк вакытта сүз боткасына май тамызгалап болгаткалаган чакларында, кайсыдыр ычкындырды бит: имеш, авыл Советында секретарь булып утыручы Иннек Саниясе әйткән ди:

— Безнең Әҗердә,— дигән, ди,— шушы елны мәктәпкә җиде бала барып керсә, киләсе елны дүртәү, ә тагы биш елдан соң нибары берәү генә булыр, ахрысы...— дигән, ди.

Бу сүзгә һәммәсенең дә исе-акылы китте.

— Ә нигә, алай ук түгелдер, дисезме? Иннек Саниясе җалгышмас: җазма документка таянып әйтер әйтсә дә...

— Эшләр алайга киткәчтен, кысарлар да, җабарлар да инде бездәге мәктәпнең башлангычтагы сыйныфларын,— диде Фәгыйләттәй, уфтанып.— Каф тау артларыннан килеп, әрмәннәр салып биргән менә дигән таш мәктәбебез, көне җиткәч, бушап каласы алайсам.

Моны әйткәч Фәгыйләттәй, тимер чыбыкка бау бәйләү эшеннән тукталып, бер кулын биленә салды да икенчесен һавада болгый-болгый бүлемтедәге яшь хатыннарга ук булып кадалды:

— Барысына да сез генә гаепле, сезнең ишләр генә!

— Менә әкәмәт: нишләп без булыйк, ди? Менә сиңа иске авыздан яңа сүз! — дип, шәп-шәрә иңбашларын селкеткәләп алды Мәймүнә.

— Сезнең ишләр булмый тагы... Бер бөртек бала табып, бүтәне хакында уегызга да китермиенчә, җөргән буласыз шунда тән-гәүдә шәбәртеп кенә, адәм көекләре!

Теплицада яртылаш шәрә йөргән хатыннар арасында иң чибәрләрдән исәпләнгән Гөлсемнең сумаладай кара чәч бөтерклсе арасыннан көмеш алкасы шундук елыкялык итеп алды:

— Бу тиклем дә бәйләнерсең икән, Фәгыйләттәй! Тозга манчымый-нитмиенчә генә кабыплар җотар иең бугай.

— Җотмабыз... Синең күкләрне җотып, соңыннан гомерең буйларына яман укшытулардан азап чигәргәме?

Монысының авызын томалагандай иткәч, Фәгыйләттәй кызуын тамчы да киметмиенчә, аңардан ике-өч түтәл аша бил-сын бөгеп азапланган Лида Ухановага төбәлде. Бу яшь кенә хатын күпереп торган чәченең сарылыгы белән дә, тәненең аклыгы белән дә, җыен карга-чәүкә арасына эләккән ак күгәрчен сыман, бүтәннәрдән шактый ук аерылып тора иде.

— Зачим и у тибе нит малутке, Лида? Үзең сөлектәй, үзең шундый да красивая,— диде Фәгыйләттәй, русчасын, татарчасын бергә бутап.— Што, мужик не хочет, али твоя не может?

Хатын-кыз чырык-чарык көлешеп алды. Лиданың чабата төбе әллә кайчаннан тишек иде, шул сәбәпле ул болар арасындагы гәп кай тирәдәрәк чуалачагын бик тиз абайлап алган иде, әмма яшь хатын үзенә дә ук булып кадалырлар дип һич көтмәгән иде, ахры: каушап калды, сирәк сипкелле аксыл йөзенә, хәер йөзенә генәме, шоп-шома муенына, хәтта купшы күкрәк өсләренә дә җете кызыллык йөгерде.

— Фагиле-эттей, зачем ты так сразу... кисэк кнэ,— диде ул, шулай ук ике телне бергә бутап.— Вот дадут новую квартиру в Новом поселке, тогда уж, может... А хазэр, пока что, булмый, кирэк тигел, значит...

— Зачим булмый, зачим кирэк түгел? А крыша есть? Мужик есть?.. Больше ничава ни надо! Ты уж, давай, Лида сеңелкэем, спи да знай — скорей нам малутке делай! А ту вечэ уж наше деревне умирать собирался...

Моңа тагын да шәбрәк көлешү белән җавап кайтардылар. Әмма Фәгыйләттәйнең тукталырга һич исәбендә дә юк иде. Ул инде хәзер биленә ике куллап ук таянып алды:

— Ичмаса, дим, үзебезнекеләр булдыра алмагач, урыс марҗасы булышмага килмәсме. Җугыйсә, җен оргырлары, Чаллыга да барып җөриләр, күзләренә бер генә дә төртелми микәнни: анда бит өч-дүрт хатынның берсе әнәтерә кибәндәй көмәнле, диләр... Дәүләт белән хөкүмәтебезне баету хакында уйламыенча туң җөрәк белән: «Мин — мин микән, мин кем икән?» диеп, түш кабартып кына җөреп җатырга монда — әллә кемнәр диярсең...

— Чаллы, Чаллы, һаман да бер Чаллы — чәйнәп туймадыгызмы инде?! — дип чәрелдәп җибәрде Гөлсем.— Сез, селкәсе итсәгез, ичмаса, зуррак кала җирен селектерегез! Қазан җәки, әйтик, Мәскәү хатыннары хөкүмәтне баету хакында кайгырталармы бик? Исләре дә китми! Үз рәхәтләрен белеп, төкерепләр генә җөрепме җөриләр, билләһидер!

— Их, җәш чаклар бер әйләнеп кайтса иеме? Җук шул инде, әйләнепләр кайтса да, заманасы тамыркайларыбызга балта чапкан ие шул инде: ир-җаныкайларыбызны сугыш утлары җалмап кына алды ла, ил хакына җан биреп көл булган туфракларын да белмәй-

без лә...— дип кинәт сыкрануга керешеп китте Фәгыйләттәй.— Их, җәш чагым кайтып, менә сезнең күк чиртсәң каннар тамардай хәлләрдә булса иемме? Һич ирекмәс ием, бала-чагага, дим, ишегаллары тутырып ук җатар ием. Ипидер!

— Андый заманнар үткән шул инде, түтикәем! Җегерменче гасырның соңгы чирегенә керергә җыенабыз! — дип янә чәрелдәде Гөлсем.

— Культурный заманнар! — дип аңа куәт өстәргә ашыкты ахирәте Мәймүнә, шәрә иңбашларын янә матур уйнатып.— Җактылык нуры һәркая да җарып кергән көннәр!

— Их сезне, кысыраеп барган культурный чәчкәләр! Ичмаса, картаймыш көннәрегез хакында да уйласагыз икән бер... Җук, моннан ары булышмага димәгез дә, килмәем дә...— дип, ике куллап күлмәк итәген күтәреп алды да түтәл араларыннан үз бүлемтеләренә таба атлады Фәгыйләттәй.

Бераздан Рәсүлә дә аңа иярде.

Рәсүлә үз бүлемтеләренә килеп кергәндә, Фәгыйләттәй суган түтәле кырыена каплап куелган чиләк төбенә утырган көенчә уйга тарып калган иде.

— Үзем тилекәй: пенсионер башым белән шушында эш кырмага җөргән булам бит,— диде ул, авыртыну аша баш селеккәләп һәм шул ук вакытта ак яулыгы читеннән бүселеп чыккан чәч тәлгәшен төзәтергә дә азапланып. Аның чәч тәлгәше яртылаш диярлек бәсәргән иде.— Шушы җазны гына уздырыем. Аннан ары мондагы иблис токымнары җанына аяк басаммы соң! Тепличалары ник убылып төшми!

Рәсүлә аның үз өендә бикләнеп ятарга яратмаганлыгын, эшкә — теплицага булмаса, бүтән төрлесенә — сирәк булса да, барыбер йөрмячәген бик белә иде. Шул сәбәпле бу хакта ләм-мим сүз катмыйча, түтәй янына җиргә чүгәләде. Фәгыйләттәйнең болай да басынкы һәм моңсу тавышы кисәк сулкылдауга күчеп куйды:

— Ир белән җәшәүнең кадерен белмиләр шул, их, белмиләр! Ачуларың купмаслыкмыни? Ә бит мин ничәмә җыллар төшләремдә күреп интегер ием: имештер, ирем, Зәйнуллам, исән-сау кайткан да бер өер бала-чага үстереп җатабыз. Арада кызлар да бар, малайлар да җитәрлек. Менә инде, имеш, үсеп киләләр, менә инде, урам күрке булып, мәктәпкә баралар. Өлкәнрәкләренең менә инде, имеш, армиягә китәр чаклары да җитеп килә. Кайчакларда туйлар итеп тә җөргән булабыз... Төшлә-

ремдә шулай җуаныч та куаныч, ә уянып китсәм... өнем-дә? Үзләре түгел, шәүләләре дә юк...

Рәсүлә ни күрсен: Фәгыйләттәйнең җыерчыклы бите буйлап мөлдер-мөлдер яшь бөртекләре ага. Аягоч күршесен мондый хәлдә беркайчан да күргәне юк иде әле аның...

— Ул заманның бердәнбер сөендергәне шул: бер генә бөртек булса да малайлы булып калдым. Сугыш җалмап алганчы, Зәйнуллам, ичмаса, анысын булдырырга өлгерде, бәгырькәй... Бәхетемә...

— Җә инде, Фәгыйләттәй, бу хәтле үк өзгәләнмәсәнә!

— Аңламыйлар шул ир белән җәшәп, бала-чага үстерүләрнең кадерен дә, тәмен дә... Һай, аңламыйлар! Бер генә җылга, юк, бер генә айга минем хәлкәйләргә куеп карыйсы ие үзләрен!.. Менә, әйтик, син үзең, Рәсүлә сеңелкәем, ирсез көе олы малаең Айдаш белән генә утырып калдың, ди... бүтәннәре юк, ди, тумаганнар да, ди... тфү, тфү, әфсен-төфсен... Кайларга куяр иең газиз башкаеңны?..

Бу сүзләрдән Рәсүләнең йөрәге жу итеп куйды. Юк, андый хәлне күз алдына китерә дә алмый, китерергә теләми дә иде ул.

Шуннан соң алар теплицада әллә ни озак эшләмәделәр инде. Түтәлләрендә кыяклы суганның өлгергән хәтлесен генә җыеп тапшырдылар да аны яңабаштан үстерергә тотынмадылар. Анда инде совхоз механизаторларының язгы чәчүгә чыгар вакыты җиткән, димәк ки, Рәсүлә аларны кайнар аш белән туендыру хакында кайгырта башларга тиеш иде. Пенсионер хатын Фәгыйләттәйгә дә җәйгә керер алдыннан үз ихатасы һәм бакчасы тирәсендә кайнашыр чаклар бик җитеп килә — аңа япа-ялгыз башына йорт тотып ятулары бер генә дә җиңел түгел иде...

Әмма хезмәттә һәм тормыш итештә юллары янә аерылып китсә дә, вакыт тигәндә, аягоч күршесен күз кырыеннан ычкындырмаска тырыша иде Рәсүлә: алай-болай, теплицадагы шикелле, язмышы тоттырган гомер йөгәнен бушандырып җибәрмиме, шул сәбәпле уйламаганда сыгылып төшеп, җебеп калуларга юл куймыймы тагы дип...

Юк, Фәгыйләттәй һич сынатмый, бернинди абынусөрлегүләре булмагандай рәвештә, һаман да көр күңел белән һәм ярыйсы ук җилле төстә үз көнен күреп яшә-

нен белә иде. Мөгаен, тормыш үз агышында, дуамал әйкалып-буталып киткән чакларында да, ургылу-чайпалулардан соң тына төшеп, иңле генә агарга тотынганда да, иң әүвәл нәкъ менә Фәгыйләттәй шикелле, саф һәм нечкә бәгырьле дә, чыдам буынлы да, ихтыяри кодрәтле дә була белгән хатын-кызга таяна торгандыр?

Кайчандыр, әле сугышка хәтле үк, колхозлары чәчәккә күмелеп яшәгән чакларында, ул яшь, чибәр ире белән кулга-кул тотышып төрле спектакль-концертларда аз катнашмаган, гомумән, үз ишләре арасында иң гаярь, иң җиллеләрдән исәпләнгән. Өлкәнрәк яшьтәгеләр, ул матур елларны сагынып искә төшерергә тотынсалар, һәм онытылмас хатирәләренә Фәгыйлә дигән исем дә килеп керсә, тәмләп тел чарлаулардан бушана алмас иде.

Иреннән ул, әйткәнебезчә, бер малай белән утырып кала. Авылдагы бик күпләр кебек үк, аны кеше итәр өчен саулыгын да, көч-җегәрен дә җәлләми. Ләкин улы, белем һәм һөнәр алып, инде тәмам кеше булгач, нишләптер туган авылларында калырга теләмәде, армия хезмәтеннән соң Волгоград каласында — кайчандыр этисен ут йотып алган Идел ярында төпләнеп калды. Автомеханик... Гадәттә, ул җәйләрен, әлбәттә, гаиләсе белән, туган авылына кайтып төшә. Галәмәт күңелле була — шау да гөр киләләр. Менә шул чакны инде Фәгыйлә түти бар йөз-кыяфәте белән бөтенләй ачылып, нурлар сибеп йөрүчәнгә әверелә. Тап инде Әҗер авылының Түбән оч өлешендә үзенә бер төсле кояш кабынып, текертекер урам-тыкрыкларны балкытып йөрергә тотынгандай була...

Аның азаплана-азаплана йорт-кура, бакча тотулары да, шулай ук каз-үрдәк һәм сарык асраулары да, әлбәттә, сагынып көткән кадерле кунаклары өчен, башлыча елның ямьле җәй тәүлеге өлешләндергән әнә шул шаулы-гөрле көннәр өчен иде.

Кышларын Фәгыйлә түти ике-өч айга Волгоградка улы янына китеп бара һәм туган авылына яз кояшы тутырып елмаерга керешкәч кенә кайтып төшә иде. Менә шул вакытта ул ялгыз өен карарга авылдашларыннан берәрсен, әлбәттә, киң һәм йомшак күңеллесен, калдырып торгалар иде. Әмма, әйтергә кирәк, Фәгыйлә түтинең үтенече-шарты бәләкәйдән түгел иде: «Берүк, акшарлы мичемә боз салкыннары иңеп, өемнең җылысы сүрелә күрмәсен! Идән астында бәрәңгем бар — өшүе ихтимал, өй тутырып гөлләр үстерәм — шиңеп, әрәм булулары ихтимал. Берүк, көннекен-көнгә җагып, җы-

лытып торыгыз инде!» — дип үтенә. Аның җылы абзарында кош-кортын, ике баш сарыгын карауны авылдашлары, әлбәттә, чүпкә дә санамый. Түтинең төп өлеш бәрәңгесе дә бакча базында җиргә бик әйбәтләп томаланган хәлендә калын кар астында саклана. «И Фәгыйләттәй, диләр әкәмәт тә җан соң үзең: кышның зыкы суыкларында җалгыз өеңә җагып ул тиклем утыннар әрәм иттергәнче... андагы өч бөртек бәрәңгеңне дә, шәп гөлләреңне дә үзебезгә генә күчереп куйыйкчы! Үзеңнең дә киткән җиреңдә җаның тыныч җөрер, безгә дә мәшәкате кимрәк булыр»,— диләр. Арада түтинең мәелен аңлап, аны җиренә җиткереп башкарырга теләүчеләрдән бигрәк, аның сәер кыланышларына: «Картаюның җинеләйтүләре шушыдыр инде ахры»,— дип шөбһәләнү аша баш чайкаштыручылар, хәтта ачы көлемсерәүләрен яшермәгәннәре дә була иде. Фәгыйлә түти, дөрес, андыйлар белән сүзне артыгын куертып тормый, шул ук вакытта үпкә-рәнҗүен дә сиздерми, ары эзләп китә. Эзли торгач, таба, күндерә, хәтта җылы өен саклауның әҗерен дә алдан ук биреп куйгалый. Билгеле, алучысы булса...

Бер кышны аның өен сакларга — әлбәттә, бернинди дә әҗер өчен түгел, болай күңел йомшаклыгы белән — Рәсүлә калган иде. Аягоч күршесенең мәелен үтәү йөзеннән бик әйбәтләп, җиренә җиткереп саклады да,-карады да ул аның өен. Карарсың да!

Башта ук, Фәгыйлә түти үзенең олы гозер-үтенечен әйтергә килгәч ук, ачылды аның хикмәтле сере. Рәсүлә, миңгерәү ми, аңа җавап сүзендә, бүтән кайбер кешеләр кебек ук: «И-и, җиңгә-чәй, өйләребез иркен, ул әйберләреңне үзебезгә күчереп куйсак соң»,— дип тотынган гына иде, аягоч күршесе болай да җыерчыклы йөзен тәмам ватып-яньчелдереп һәм күзләрен мөлдерәмә тутырып аңа төбәгән хәлдә, моңлы-рәнҗүле төстә баш селеккәләргә кереште: «И-и, Рәсүлә сеңелкәем, ни тикле җомшак күңелләрең белән син дә шулай димсең, син дә аңламыйсың. Хикмәт бер бәрәңгем белән гөлләремдә генәмени? Сине күңелемә үтә дә җакын күрә генә газиз серкәйләремне ачыйм инде алайса үзеңә... Утыз җыл... утыз җыллар да ашып китте бит инде...— Бу минутта җиңгәчәйнең мөлдерәмә тулы күзләреннән исәпсез җыерчыклары өсләтә бөрчек-бөрчек яшь тәгәрәргә тотынды.— Зәйнуллаем-тулган аем Сталинград төпләрендә ил азатлыгы өчен мәңгегә шәһит булып киткәнче, монда үз җанымда... ие, шушылай ук чатнама суык кыш ие, өебезнең

җылысын, ичмаса, сеңерләремә сеңдереп китием әле, дигән ие лә мәрхүмем... Инде утыз җылдан да әүвәлтенрәк... Аның төсе, аның җылысы итеп, моңа тиклем газизләп саклаганымны... ничекләй иттереп, өем нигезенә суык индерим, ди?..»

Әле бу да түгел, Фәгыйлә түти, ил азатлыгы хакына ире Зәйнулланың «мәңге шәһит киткәнлеге» турында кара мөһер басылган кәгазь кулында булса да һәм үзе дә бу яман ачы хакыйкатькә инде тәмам ышанып алса да, әле сугыш арты елларында, ягъни яшьрәк һәм җиллерәк чагында, менә дигән адәмнәрне дә борып-борып җибәргәләгән. Һаман да шул күңелендәге һәм өендәге җылыны бүлешәсе, таратасы, тузгытасы килмиенчә!..

Әле һаман саклый, сипми-таратмый...

Утыз елдан да артык...

Менә шушы хәлне белүдән һәм аңлаудан Рәсүлә ул мәлне сулышы куырылып, өнен-исен җуя язган иде.

Кеше күңелен диңгез диләр шул, ә диңгез тикле диңгездә нинди генә култык-уентык, нинди генә чоңгыллар юктыр, димсең?

Рәсүлә аның урынына үзен куеп карый, аның язмыш юлларына үзен кертеп җибәргәндәй иттерә: андыйны булдыра алыр идеме, түземе калыр идеме? Утыз елдан артык бит инде!.. Җавабын таба алмый, җавабы тик калтырата һәм өркетә генә...

Теге үтә эссе һәм коры җәйне дуамал кубып. йортын-нигезен ташлап китәргә йөргән көннәрен исенә төшерүләрне Фәгыйлә түти һич өнәми иде. Берәрсе шул хәлне телгә алырга тотынса, аның йөзе капыл агарып китә, кашы-күзе җимерелә — тәмам өнсез кала диярлек иде... Ул чакны түти инде кәҗәсен-сарыгын да сатып өлгергән, инде өенә дә хак бирергә теләүчеләр килгәли башлаган иде. Ахырда берсе белән килешенеп, өстәленә акча өеме чыгарып салынгач, түти: «Әллә нишләдем әле мин... әллә нишләдем,— дип беравык кына баш селеккәләп утырган да: — Шул бәдбәхет Гарапша аркасында гына шушылай зур гөнаһларга керүләрем лә... Күктәге алла кичерсә дә, үзе кичермәс... үз җаным кичермәс лә!» — дия-дия, ишек яңакларын коча-коча, илереп еларга керешкән. Ул көнне Рәсүлә басуда иде — күрә дә, катыша да алмады, түтине күршеләре көч-хәл белән генә тынычландыра алганнар... Аның соңында Фәгыйләттәй авыл Советы ишегенә, клуб баганасына, хәтта Чаллыга барып, андагы автовокзал диварына да ябыштырган игълан кәгазьләрен, авылдашы Гарапшаны каһәрли-ка-

һәрли, үз куллары белән йолкып-ертып йөрде, диделәр. Түтинең: «Күктәге ходай кичерсә дә, үзе кичермәс.. үз җаным кичермәс бу зур гөнаһымны!» — дип ачыргаланып әйткән сүзләрен Рәсүлә бөтен йөрәге белән аңлый хәзер.

— Җир йөзендә бар адәм дә җалгыз тол хатынның хәлкәйләрен аңлап бетерәмени? Тиккә авыз җыручылар да аз түгел, зинһар, җан серемне саклый күр инде, Рәсүлә сеңелкәем! — диде күршесе.

Авызда сер саклауның кыенлыгын Рәсүлә бик белә — бу тарафтан үз холкы үтә дә йомшаклардан иде, шулай да, ни читен булса да, аягоч күршесенә ныгытып сүз бирде. Әмма бер генә адәмнән — ире Хәнәфидән генә яшерә алмады, ачып салды хикмәтле серне: аңа ышанмыйча булмый — Рәсүләнең белүенчә, иң шәп, иң таза йозак аның ире авызында иде. Хәнәфи уйчанланып китте, моң-сагышка батты, аннары тирән уфтану аша әйтә салды:

— Зәйнулла абый сугышка киткәнче, ахыргы җәендә, мин аңарда плугарь булып йөргән идем. Хыялым аның күк тракторчы булу иде. Йөрәк җылысын мәңге саклардай адәмнәрдән иде шул мәрхүм...

Һәм ул, Фәгыйлә түти срак сәфәренә чыгып киткән көнне үк, аягоч күршесенең капкасы төбенә, үз ихатасыннан төяп, бер «Беларусь» арбасы шыкырдап торган коры утын илтеп аудартты.

— Мәңгелек һәйкәл утларында Зәйнулла абый өчен дә ялкын телләре дөрлидер дөрләвен, әмма монда үз өендә дә сүнмәсен, уты һәйбәт дөрләсен инде алайса...— диде.

10

Бариевлар өендә кай кичләрне бары да җыйнала. Гадәттә ул ял алдыннан шимбә көннәрендә була.

Чаллыдан алгысып Айдаш белән Вәсим кайтып төшә. Алай бик еш булмаса да, кай көннәрдә аларга кызлары Рәмилә белән кияүләре Женя да нярләли.

Кунаклар рәхәтләнеп, туйганчы, тәмам камыр булганчы мунча кереп, аннан тән һәм җан җебетеп чыгалар. Чыгуларына, әлбәттә, түгәрәк табын өстәле. Атаананың сые мулдан, хөрмәте чиксез.

Дөньяларын онытып, зәңгәр экранга төртелеп калмаган булсалар, әлбәттә, тегесе-бусы хакында гәп тергезмичә дә тормыйлар.

Сүз оеткысын гадәттә Чаллы кунаклары сала. Ни дисәң дә, алар галәмәт дәү завод һәм зур Ак кала салуда хәләл көчләре белән турыдан-туры катыша, ә бөтен дөньяга шаулаган гигант төзелештә, сөзеп алып тәмләп сөйләр өчен, яңалыклар аз туып торадырмы?

Аерата Вәсим эресымаклана иде: имеш, аның гигант төзелештә тотынмаганы-актармаганы инде бик аз калган, әле, исән-сау булып, ходай кушса, тагы берничәләп һөнәр-кәсепне сынап караганда да һич зыян итмәс. Инде гәп хезмәт хакы тирәсендәрәк чуалырга тотынса, Вәсим сүзне каяндыр төптән, бавыр яныннан ук куптарып, сизелерлек вәкарь аша гына ычкындыргалый, алай гынамы, бүтәннәргә акыл өйрәтү рәвешенә керүдән дә тартынып тормый — мондый чакта, аның сүзе-тавышы гына түгел, башын чайкалдырып җибәргәләгән мәлләрендә, болай да кабарынкы чәч пумаласы тагын да күпереп китә сыман иде. Кайчакларда ул, кинәт йомшый-кылтыйлана китеп, энесе Рәмзине дә:

— Егет башың белән җебеп, йомылып йөрисең... Әйдә, сиңа биреп торырлык кына акча бетмәгән бездә, язып давай машинага! Яшьлегеңдә бер кинәнеп калырсың, ичмаса! — дип котыртырга тотына иде.

Рәмзи, әтисе Хәнәфи шикелле үк, сүзгә сирәк катыша, нибары ияк каккалап кына утыра, яисә, гәҗит-журнал караштырырга тотынып, «мәрткә» киткән була. Тик инде абыйсы Вәсимнең шушылай кылтыйлануына игътибар итмичә дә ярамый. Машинаны ул үзенең хәләл көче белән тапканына, нибары шуңа гына сатып алачак! Егет кешегә мескенләнү килешәме? Мәгәр шул ук вакытта Рәмзинең үз горурлыгы һәм мактанычы бар: дөньяда иң зур заводларның берсен коруда ул да хәленнән килгәнчә бетон салышмый калмады; бәлкем, җае чыкса, тагын салышыр әле; ул үз совхозлары җирендә балкып торачак Яңа поселок һәм терлекчелек комплексы төзелешендә тир түгә ләбаса — андый комплекс бөтен республикада моңа тикле булмаган да, ди, бит әле! Инде бу да җитмәсә, вакыты тигәнчә, туган авылы басуларында яңгыр яудырып, салават күперләре нурландырып йөрүчеләрнең кул арасына кереп, аз эш майтарамы?..

Бүлмә түрендә йомшак кәнәфигә чумып, кәпрәеп утырган абыйсына менә боларны, тигез кашлары астыннан ачык һәм үткен карашын төбәгән шәйгә, авыз тутырып әйтмичә булдыра алмый иде егет.

— Имеш, салават күперләре! Хе-хе! — дип каһкаһәләп көлеп җибәрә шул мәлне абыйсы.— Үзе бушка, үзе туйганчымы? Муеннар кәкрәеп, уч төпләренә каннар саркып чыкканчымы? Яңгыр урынына үзең сибелмәсәң соң!

Бу хәтлесен инде Рәмзи үзе генә түгел, бүтәннәр дә өнәми, ни сабыр әтиләре Хәнәфи диван почмагында оеп утырган җирендә капыл кыбырсылап куя да, ык-мык итеп торгач, кызу-кайнарланып:

— Бушка булса соң... туган туфрагында ич! Алай үз кулларың белән яңгыр яудырып, салават күперләре балкытып йөрүләр бар кешегә дә тәтеми әле ул, бик беләсең килсә, чүбек баш! — дип, Вәсимнең ерык авызына ямаулык салырга ашыга иде.

Рәмзинең тагын бер өстенлеге бар иде: әкәмәт йорт җанлы булып чыкты ул. Абыйлары, хәтта әтиләре Хәнәфи, ни майтара соң әле? Кая анда яңаны торгызу ясә кәкре казыкны турайтып кагулар, ихаталарында аркылы ятканны буйга китереп салуны да юньләп белмиләр. Йорт тоту дигән җәһәттән нишләптер җаннары тунрак булды инде аларның.

Төпчек уллары алай кыланмады. Ни арада абзаркураларны, ак мунчаның тишек-тошыкларын ямаштырып, түбәләрен яңартып алды, ни арада тәмам таушалган урам капкасы белән өй каршындагы рәшәткәне адәм карар кыяфәткә китереп, матурлап җибәрде.

Әмма, анысы аның алай да... Менә шул чибәр йортны тагын да бизәп, күбәләктәй җилпенеп йөрүче, сөлектәй гәүдәле, пешкән алмадай йөзле яшь хуҗабикә күренми бит әле, тавык-чебешләрне өркетеп, алар янында тибенеп ятучы җан татысы нарасый юк бит әле!

Йорттагы өлкән адәмнәрнең, бигрәк тә сыгылма җан Рәсүләнең, моңа бик яман эче поша, эчләр пошу гынамы, вакыт-вакыт күңелендә «кысыр улларына» карата ачы үпкә-рәнҗүләргә тикле кузгала иде.

Чаллы кунаклары китеп баргач, йортлары бөтенләй тынып һәм бушап кала, юк, алай гынамы! Чибәр йорт тәмам ямансулап һәм нәүмизләнеп кала...

Чибәр йортның яшь, елгыр хуҗабикәне күрәсе килә, яшь нарасый авазларына тулып, гөрләп торасы килә! Чибәр йорт юксына! Сагына! Көтә!..

Йортның үтә көязлеге бу ачы хисләрне тагын да көчәйтеп һәм куертып кына җибәрә иде...

11

Җәйлектә Түбән очның елгыррак хатын-кызы — эшкә фермага мал-туар янына йөриме ул яисә яшелчәлектә бил бөгәме — иртәнге яктан нәнечен җитәкләгән шәйгә Фәгыйләттәй капкасы төбендә тукталып: «Өемдә аяк-кул арасына керердәй кешем калмады, зинһарлар өчен, авырсынмыйча гына минекен дә апкала күр инде, җиңгәчәй!» — дип ялвара. Бусы капкасын шундук җилбәгәй ачып җибәрә дә: «Әйдә, әйдә, калдыра гына күр, фәлән-фәлән гөликәем!» — дип иң әүвәл үзе балавыздай эреп китә. Теге килен, куанычыннан күкрәк тирәләрен сыйпаштыра-сыйпаштыра, эшенә чаба, бу исә нәнечнең башларыннан сөя-сөя аны яшел чирәмле ишегалдына иркенгә җибәрә яисә чиста һәм пөхтә җыештырылган өенә кертеп куя. Әлбәттә, бүтән сабыйлар янына... Мондый минутларда түтәйнең карасу йөзенә кояшы да, ае да берьюлы иңгәндәй була.

Хәер, авыл җирендә шушындый гадәт, ягъни йортта утырып калган өлкән яшьтәге хатыннарның, карт-корт-каның күрше-күләндәге бала-чаганы үз канатлары астына алып, аларга күз-колак булып ятулары элек-электән килгән һәм инде йола рәвешен ала язган бик тә күркәм бер чара инде ул: бүтәнен әйтәсе юк, авылда ут-күз чыгармау җәһәтеннән дә уңай, авыр хезмәт чилләсендә тир түгүчеләрнең дә җаннары тыныч...

Фәгыйләттәй әнә шулай бар кыяфәте белән матур нурлар бөркеп йөргән көннәренең берендә, кичке уңайда, кызыклы гына сөйләшү булып алды, һәм бу сөйләшү соңыннан һич уйламаганда түтәйнең көнкүрешен тагын да кызыклырак һәм ямьлерәк сукмакка борды да җибәрде.

Ул тымызык кичне Рәсүлә урам аша чыгып килгәндә, тегендә, шомарып беткән киң эскәмиядә Рәсүләнең маңгай күршесе Мәрфуга белән Фәгыйләттәй ни турындадыр җылы гына гәпләшеп утыра иде инде. Мәрфуга совхоз эшләреннән бөтенләй үк читләшми, җәйләрен басуга яшелчәлеккә йөрештергәли, әмма анда үз җаен белеп кенә эшли. Ә инде атнаның бер-ике көнендә ире шофер янына кабинага җәйрәп утыра да машинада җилләр уйната-уйната Чаллы юлларындагы чакрымнарны санарга чыгып китә. Чаллыдан ул галәмәт дәү букчасына ризык-нәгъмәтнең әллә ниндиләрен тутырып алып кайта, аннан да бигрәк сүз-хәбәрнең дә өр-яңасын төенчегенә шәп төйнәгән була. Бөтен Әҗер үк булмаса

да, авылның түбән очына олы төзелештәге җыен яңалыкны нәкъ менә шушы елгыр хатын ташып тора да инде.

Рәсүлә алар янына эскәмиягә килеп утыруга: «Җә, бу барышында сүз капчыгына ниләр тутырып апкайтты икән җылдам җан кисәге?» — дип, колакларын тырпайтты. Юк, әллә ни төйни алмаган икән, төзелештә тир түккән малае белән киленнән ризасызлык белгертеп, моң-зар түгеп утыра икән. Болар өчен моның һич искитәрлеге юк: инде күптән күнегелеп беткән гап-гади сүз ачыткысы иде бу. Әмма игътибар салыбрак тыңласалар, аның зары «мактауга лаек» зар булып чыкты: тегендә кыбырсык килене нәниен имидән аерган да, аны олан багучыга тоттырып, төзелештә үз эшенә кабаттан керешкән икән.

— Соң, тиле баш, куанырга гына ие сиңа! — дип көлемсерәп куйды Фәгыйләттәй.— Куллары бушап, үзе җараткан шөгыленә, буяу-сылау эшенә тотынган, дисең ич!

— Ә миңа калдырып китсә бәбиен, бага алмас иемме? Атнасына бер кайтып, иркәләп-назлап киткәләсәләр, җитмәгәнме? — дип күз акларын агартып алды Мәрфуга.— Ә ул бала караучы кортка күпме каерадыр дисез үзләреннән?

— Күпме? — дип муенын сузды Рәсүлә.

— Аена шыгырдап торган кырык биш тәңкә! Ә бит аңарда бер безнекеләрнең генә оланымыни? Берьюлы өчне бага бит ул кортка! Аена күпме чыга, ә?

«Ах» иттеләр.

— Монда җәшелчәлектә көннәр буена бил бөгеп тә ул тиклемне кесәгә салулары ай-һай ла! — дип баш селеккәләде Рәсүлә.

— Форсаттан файдаланып, терелә туныйлар инде, терелә! — диде Мәрфуга, шыңшынып.

— Аның каравы, ничәмә-ничә тап-таза хатын, куллары бушап, төзелештә катнаша ала,— дип үзенчә төзәтмә кертергә тиеш тапты Фәгыйләттәй.— Шуңа күрә анда Җәсли-детсадларны җаман да ашыктыралар, ди, бит әнә.

— Безнең кортка ни әле — андыйлар Чаллыда хәтсез, диләр. Үз колагым белән ишеткәнем булды: берәү бар, ди, анда, заманасында медсестра булып эшләгән, ди, инде хәзер икенче группа җанвалид, ди, шул сәбәпле казна эшеннән азат, ди. Әмма, аның каравы, бала багуда, ай-һай, маһирлык күрсәтә, ди! — Мәрфуга, сүз-

нең искитмәлесен әйтергә җыенып, хәтта күгелҗем иреннәрен ялаштырып алды.— Кайчакларда аңарда уңлап-уникеләп бала җыелып җата, ди! Җә, исәпләп карагызчы, ай буена ничә тәңкәне суга инде ул хатын, ә?

Бу юлы хәтта «ах» итә дә алмадылар: сулышлары куырылды...

— Һы, зур кала җирләрендәге атаулы профессорларныкыннан ким түгелдер айса, вәйран шул! — дип ухылдап куйды Фәгыйләттәй.

— Нибары нәниләрне карап...— диде Рәсүлә, хәйран кыяфәттә янә баш селеккәләп.

— Тегендә берәү ипләп кенә профессорлар сукканны сугып җата, ә син, Фәгыйләттәй, монда туже ничәмә бала карап...

— Бүгенге көнне алтау...— дип ачыклык кертергә кирәк тапты Фәгыйләттәй.

— Алтау... Болай нәнечләргә капкаларга ризыкны китерәләрдер инде китерүен, и шулай да... буш сүзгә, коры рәхмәткә генә ич. Акчасын да аз-маз тамызгалап, дим, торсалар, кесәләренне, Фәгыйләттәй, бер генә дә...

— Син, нәрсә, акча корты дип белденме әллә мине? — Фәгыйләттәйнең тавышы кинәт чәрелдәп һәм калтыранып яңгырады.— Авызыңнан җилләр алсын! Авылдашларымның рәхмәтеннән дә кыйбатлырак тагын нәмә бар бу дөнҗада?!

Мәрфуга шундук шым булды. Рәсүлә дә сулышын кысты. Моннан соң алар ни турында сөйләшкәннәрдер, Рәсүлә хәтеренә сеңдерә алмады. Ләкин ул күңеленә уелып кергән хәтлесен шул кичне үк ире Хәнәфигә текмә-тек сөйләп бирде. Теге аны-моны әйтмәде, мыштым гына тыңлап торды, ләкин икенче көнне, шулай ук кичке уңайда, кинәт ярып салды:

— Син анда Фәгыйләттәйгә әйт: үз канаты астына алган сабыйларны әгәренки унбер-уникегә җиткерә ала икән, без аңа совхоздан тиеш кадәренчә хезмәт хакы түләп торачакбыз!

Рәсүлә, иренең бу сүзләренә ышаныргамы-ышанмаскамы белмәстән, беравык челт-челт күз йомгалап торды:

— Син уйлапмы, уйнапмы?

— Уйнадылар, ди! Акбашевның үзе белән киңәштем. Хупламыйча сиңа! Яңа поселокта өр-яңа детсад-ясленe кайчан өлгертәләр бит әле...— Моны әйткәч, иренең авыз тирәсе кисәк кыйшаеп китте.— Кантурда сөйләшкәндә директор бик яман иттереп төрттереп тә алды: мин, ди, бүгенгесе көнне теләсә кайсы совхозның яки колхозның

хәл-әхвәлен культура ягыннан да, бүтән җәһәттән дә нәкъ менә балалар бакчасы булу-булмавына карап бәялим, ди. Хәзер инде таш мәктәпләр, культура сарайлары белән генә шаккатырыр заманнар үтеп бара, әмма иң әүвәл тегесе, детсад-ясле дигәне хаҗәт шул авылларга, ди. Элегрәк үзе эшләгән җирләрдә ул шулайрак кыландырган, күрәмсең.

— Ни әйтәсең, без генә монда гомер-гомергә караңгылы-җактылыда сөрсеп җаткач та... күзенә төртелгәнбездер,— диде Рәсүлә моңсу гына.

— Шулайдыр, төртелгәнбездер, ахры... Ярар, карчык, син болары хакында авызыңнан алай бик саескан очыртырга ашыкма, бар, иң башта Фәгыйләттәйне күндерү ягын кара — булдыра алсаң, бик хуп! Яшелчәлектә эшләрнең яман да кызган чагы, анда иркенләбрәк эш кырмага ничәмә хатын-кызның кул-аягы бушар иде, ичмаса! Алай-болай түтәйне күндерә алсаң, өстәп әйт үзенә: рабочком бер генә дә читләшмәс, һәр җәһәттә дә булышмага әзер торыр, диген!

Шундый да күңелле һәм куанычлы хәбәрне минутысәгате белән үк түтәйнең үзенә җиткермиләрме, аны күндерергә тырышмыйлармы соң!

Рәсүләнең тезеп һәм өзеп салуына, Фәгыйләттәй болдыры төбендә бер тын ара аңгы-миңге хәлдә тораташтай катып торды, аннары җиңнәрен сызгангандай иттерде, тиктомалга башындагы яулык очларын бер чишеп җибәрде, бер бәйләп куйды, тик шуннан соң гына:

— Айсам, минем бу хезмәтемне дә җаратканнар икән, менә бит, һе-һе! — дип, тәмам эрегән кыяфәттә көлеп җибәрде.— Андый чакта, шушылай хөрмәт итеп торганда, риза булмыйлармы соң!

Шуннан куптылар да инде.

— Түбән очта бала-чага бөтенләй үк корымаган икән әле, эзләштерә торгач, рабочком Хәнәфи әйткәннән дә уздырып, унбишләп нәни җыеласы билгеле булды. Хәер, аларның бер өлеше төп Әҗернеке түгел иде: үзләре дә Чаллыда туып, әти-әниләре дә олы төзелештә эшләүче, монда әбкәйләре яисә дәү апалары янына җәйгелеккә генә китереп аударылган нарасыйлар иде. Ләкин эш кузгатып йөрүчеләр вакланып тормады: барыбер кемнәрнеңдер куллары бушый, кемнәрдер иркенләп кала, эшкә чыга ала. Сабыйларның бергә-бергә уйнап, бергә үсүләренең чиксез ямьлелеген әйтеп торасы да юк инде...

Ә Фәгыйләттәй үзе соң? Тегеләй дә җилле генә, җегәрле генә хатын тәмам җенләнеп китте шикелле:

бер-ике көн эчендә болай да пөхтә һәм чиста булган өен, кырырдаен кырып, юардаен юып, бөтенләй ялт иттерде, ихатасында капка-коймаларны, абзар-кураларны төзәттерде — аның кыланмышлары әкәмәт иде!

Хезмәттәгене хөрмәт итмәсләр димени соң?

Дөрес, Фәгыйләттәйнең хезмәт хакына чыкканы тегендә, Чаллыда «атаулы профессорлар гына» сукканны кесәсенә ипле генә салып ятучы хатынныкына карый чирек, юк, сигездән бер өлешләр генәдер, ләкин игътибар-хөрмәт дигәне? Монысы инде аңа, әлбәттә, йөз өлешләр күбрәк ява иде.

Әмма Фәгыйләттәй абруй-дәрәҗәнең олысын соңыннан, эшләр төгәлләнгәч татыр әле. Ул чагында аның канаты астындагы нәниләр инде таралышып, үз әниләре куенына сыенган булыр. Әмма авыл эшчәннәре көзен клубта үз бәйрәмнәрен шаулатып бәйрәм иткәндә, аны да онытмаслар: совхозның иң алдынгылары рәтендә аңа да Мактау грамотасы тоттырырлар, иңнәренә гаҗәп матур шәл салырлар. Һәм моны бер дә әллә кем түгел, директор Акбашев белән рабочком Хәнәфи Бариев эшләр. Түтәеңә дә шул чакта шаулатып кул чабарлар, түтәең куанычыннан авызын җыя алмыйча йөдәр... Аның өендә бер дивары Мактау грамоталары белән тула язган диярлек, Фәгыйләттәй бу яңасын да, матур рамга урнаштырып, элеккеләре янына элеп куяр, матур шәлен дә кышын-кыш буена диярлек иңнәреннән салмыенча йөртер...

Әмма кызыкның да кызыгы бу да булмас әле — анысы соңыннан, кыш янә язга таба авышып, күктәге кояш ягымлы елмаерга тотынгач килер. Йөрәкләренә чыдый алмыйча, алар, Рәсүлә белән икәү, янә теплицага барырлар, җәй җитеп үз мәшәкатьләренә чумганчы, совхозга янә байтак кына яшел суган үстереп бирерләр. Ә кызыклы хәл алар эшкә керешкәндә үк туар: күршедәге кыяр бүлемтеләрендә эш кыйратучылар арасында теге өч чибәр хатын — Мәймүнә белән Гөлсем дә, Лида Уханова да булыр. Ләкин алар элеккеге елдагы шикелле сылу гәүдәләрен шәрәләндереп, иһаһай да миһаһай кылана алмаслар инде: өчесенең дә киң күлмәк-халатлары тиешле төшләрендә, матур бүселеп, чүмәләдәй күпереп торыр. Балага узмага үзара сүз куешканнар, диярсең!

Менә шул чакны инде Фәгыйләттәй бүтәнен — Яңа поселокта озакламый квартир өләшәчәкләрен дә, анда балалар бакчасының өлгереп килүен дә, хәтта үткән җәйдә Әҗердә нәниләргә мөнәсәбәттә үзе куптарган

җылы һәм күңелле дулкыннарны да — исенә төшермичә, Рәсүләгә күз кыскалап, һәммәсе дә ишетерлек иттереп, әйтә салыр:

— Күр инде, Рәсүлә-гөликәем, тегеләрне: сөбханаллалар, димиенчә, ә! Былтыр үзебез дуылдатканнарның җимеше лә! — дияр.

Шул мизгелдә теплицада, кисәк шар ярылгандай, көлеш яңгырап китәр...

Ләкин аңарчы, ул матур көлеш яңгыраганчы, байтак гомер — өшәндергеч көзне дә, салкын кышны да — үткәрәселәре бар шул әле...

Ә хәзер исә тышта җәй уртасы.

Иртәнге якта, урамда көтү күренгәнче үк, Фәгыйләттәйнең капкасыннан бер оя бәбкә белән ана үрдәге килеп чыга. Килеп чыга да, койма буйлата сузылган сукмактан, ян-якларына сибелешкән бәбкәләре арасында ава-түнә, инешкә таба элдертә.

Соңрак, көн җылынып, кояш ярыйсы ук күтәрелгәч, бер өер бала-чага белән Фәгыйләттәй үзе күренә. Урам-тыкрыкларны буйлап Шилнә ярларына, тугайларга төшкәндә, эре сөякле, йомры гәүдәле түтәй дә шулай, нәниләр сафының әле алдына чыгыбрак, әле уртаданрак, әле артка калыбрак, кәс-кәс атлавын белә. Үзенең өстендәге күлмәге дә, башындагы яулыгы да көн саен диярлек алышынган була — сандыгында байтак хәзинә саклаңган, күрәмсең. Өс киемен шулай бик еш алыштырып торса да, киң түшенең сул канатында авыр хезмәттә яулап алган ордены белән медале тагылган була. Туган туфрагының аулаграк төшләреннән атлаган чагында, ул аларга кытыршы бармак битләре белән орынып-орынып та алгалый: янәсе, үз урыннарындамы, тагарга онытмаганмы... Өстән кояш елмаеп караганда, аның орден-медальләрендә елык-ялык нурлар уйный — иясе күрми, дөнья күрә...

12

Кияве Женя Мында Япониядән әйләнеп кайткач булды ул искитмәле хәл.

Чит илдән гадәтенчә төрле-төрле сувенир нәрсәләр төяп алып кайткан: күз явын алырдай нәфис япмадыр, яулыктыр, елык-ялык иткән тартмаларда сәгатькә охшашлы хикмәтле нәмәрсәләрдер, арада авызына сигарет кабып, бер кулына көзге, икенчесенә зажигалка тоткан маймылга тикле бар. «Әкәмәт инде, күр инде!» — дип

авыз шәпелдәткәләсә дә, Рәсүлә аның сувенир әйберләренә алай бик өн катырмады — моңа ул инде күнегә язган иде.

Әлбәттә, иң сөендергәне Женя Мында үзе булды. Аның өстендә соргылт төстәге һәйбәт костюм, зәңгәр бизәкле ак күлмәк, чуар галстук, үзенең чем-кара купшы мыегы астында авызы, тигез ак тешләрен күрсәтеп, җәелә дә тора, җәелә дә тора...

Әмма иң кызыклысы һәм күңеллесе алдагы атнаның шимбә көнендә булды.

Анысында алар, кияве белән кызы, Чаллыдан берьюлы ике йөк автомашинасына утырып кайтты. Машиналарның икесенә дә баулар белән тарттырып, тау кадәр агач материал төялгән иде: шәп-шәп такталар, калын-калын сайгаклардыр, арада җепсә-өрлеккә ярардай, юнылган бүрәнә сыманраклары да күренә иде. Бу ни әкәмәт бу дисәләр, ҚамАЗ хикмәте икән. Болар Чаллыга барган-кайткан чакларында төзелеп яткан автогигант тирәсендә, аның тимер чыбыклар белән урап алмалы хәтәр зур складларында өстенә өелгән дәү әрҗә-ящикларны күреп узгаларлар иде. Ул складларда әрҗәләрнең мунча кадәр генәме, хәтта авыл өе зурлыгындагылары да күзләренә чалынгалар иде. Инде хәзер автомобильләр комплексының һәр заводында да диярлек киң колач белән җан-фәрманга монтаж эшенә керешкәннәр икән: әрҗәләрнең тиеш кадәрен, завод корпусына алып килеп, сүтәләр-ваталар да икән, эчләреннән килеп чыккан чын алтын бәясе торырдай станокларны монтажлыйсы урынына куәтле краннар белән җәтрәк илтеп утырту ягын карыйлар икән... Ә сүтелгән әрҗә агачларын, менә дигән төзү материалын нишләтәләр, ди? Нишләтсеннәр инде — ҚамАЗның агач дип хәсрәтләнер чагымыни, аңа аптырагынмыни ул, әмма андагыларның алай да әрәмшәрәм итәселәре килми, әйләнә-тирәгә таратырга ниятлиләр. Рәхим итеп, алырга ия генә чыксын, имеш!

Йөкнең берсен боларның капкасы төбенә аудардылар, икенчесен Женя Туры бабайлар йортына алып китте. Ни дисәң дә, ул аны үтә якын күрә иде.

Булышмага алай-болай кирәгем чыкмагае дип, Рәсүлә дә этисе йортына, төп пуҗымга төшеп китте.

Шушындый байлыкны күрүдән Туры картның түбәсе күккә тия язган, ул хәтсез җыерчыклар, чал төкләр бизәгән авыз тирәсен һич җыеп бетерә алмый, үзе тагы күлмәк җиңнәрен сызганып, бер үк вакытта баш түбәсендәге кәләпүшен дә шудырмаска тырышып, йөкне буша-

тучыларның кул арасына керергә итенә, кыскасы, тыз-быз кылана иде. Әлбәттә, кияүләре Женя Мында үзенең ике шофер дусты һәм аларга килеп кушылган Сабир-Чуерташ белән ни Туры бабайга, ни Рәсүләгә кул да тидертмәделәр, йөкне ялт иткән арада бушатып та, урам як койма буена тигезләп өеп тә куйдылар.

— Әкәмәтнең үзе булмый ни бу! Урманнан китерелеп, үзебезнең савхуз пиларамында җардырылганын көткәнебез, күр инде, ходай рәхмәте, кияү тырышлыгы белән КамАЗ дигән албастының үз ихатасында төялеп, келтер-келтер капка төбенә китереп аударсыннар әле! — Туры карт шулай дип, кияве Женя Мынданың таза иңбашларына орынып-орынып алгалады.

Теге исә кул аркасы белән маңгай тирләрен сыпыргалый, үзе ләммим дәшми, тыенкы гына көлемсери иде. Аның иптәшләре дә, ни җилләр уйнатып эшләсә дә, моны гап-гади нәрсәгә санап ахры, һавалану әсәре сиздермичә, үтә тыйнак һәм сабыр кыяфәттә капка төбендәге эскәмиягә утырышып, сигарет пыскытырга керешкән иде. Туры карт, туктала алмыйча, куанычлы сайравын белде:

— Галәмәт булды әле бу: келәт-абзар түбәләрен сипләтергә дә, бүтәнгә дә... Әмма иң кызыктырганы менә шушы урам җак рәшәткәне бөтенләе белән җаңартасы килә. Туры бабагызның өе каршындагы бакчасы бөтен тыкрыкка җәм биреп, нурлар сибеп торсын әле бер заман, ә!

Үз капкалары төбенә китереп аударылган такта-мазардан Рәсүләнекеләр исә бакчаларына тыкрык буйлата койма тотарга булдылар. Хәтта кешедән уңайсыз иде: тыкрык якларындагы текмә читән, киртә-койма бөтенләй таушалып беткән, менә җимереләм, менә авам дип тора иде.

Җыйнаулашып тотынсаң, утлар уйнамыймы соң! Аерата кияве Женя белән улы Рәмзине күзәтүе күңелле иде: икесе дә майкадан гына, икесендә дә җегәр ташып тора — кулбашлары нык һәм тыгыз, тәннәре көрәнсу, икесендә дә күпереп тузгыган чем-кара чәч, аерма тик шунда: берсендә купшы мыек, икенчесенең борын асты шоп-шома, үстерми, хәер, үстереп җибәрергә итсә дә, тегенеке шикелле үк купшы булыр иде микән — нәселе ул түгел...

Менә шул чакны хикмәтле хәлне күзәтте дә инде Рәсүлә...

Женя Мында үзенең җилдәй елгыр, күбәләктәй ыспай хатынына һич эшләргә ирек бирми, Рәмилә үҗәтләнеп эшнең чак кына авыррагына, кыенрагына тотынуга, теге: «Тукта, сабыр! Үзем!» — дип җенләнеп килеп җитә иде. Тыкрыктагы иске киртә-читәнне туздырып ташлаганда да, капка төбендәге яңа әрдәнәне актарганда да, чокыр казырга кулларына көрәк алгач та, шулай кыланды, кая алары, юка гына такталарны кискәләргә керешкәч, хәтта пычкы да тоттырмады үзенә!

Тикмәгә түгел икән...

Бер заман Рәсүлә кызының буй-сынына иплэбрәк, төпченебрәк күз салса, кинәт тамагы төбенә ниндидер дулкын ябырылып менүдән: «Бәрәкалла!» — дип кенә куйды да аяк астындагы кискәгә лып иттереп утырды: кызының нечкә биле бөтенләй беленми дә диярлек, кигән күлмәгенең «ул төше» инде ярыйсы ук кабарып тора иде. «Сөбханалла, кимендә өч айлык, җук, дүрт үк тә булырдыр...»

Ана кешенең күңелен үтә җылы һәм рәхәт хисләр биләп алды, авыз тирәсе үзлегеннән җәелгәннән-җәелә барды...

Ә бит әле кайчан гына, карлар эреп дөнья җәйгә керергә җыенганда гына, алар, ана белән кыз, баланарасый булдыру-булдырмау, аның кирәклеге һәм кадере хакында дуамалрак сүз куптарып, үзара ярыйсы ук әчеләнешеп алганнар иде. «Бәлкем, шул көннәрдә үк узган булгандыр? Их, аны-моны абайламый, катырак орындым бугай үзенә... Ә, җук-җук, катырак булса да, файдагадыр. Кем белә бит аны: бәлкем, ул көмәнгә узганлыгын чамалагандыр да котылырга ниятләгән булгандыр? Тиккә генә ул көннәрдә үтә дорфаланып, укасөмсерен коярга тотынмагандыр ла...»

Ә хәзер күзләренңне тутырып һәм мөлаем нурландырып бак үзенә, рәхмәтләр яугырыга! Эшләгәндә юрамалый авыррагына тотынулары белән дә әнисе күңелен кытыклап кына азаплана ич — күр чәчбине!

Ире, әлбәттә, андый нечкәлекләрне уена да китерми, күз ачып йомган арада теге чытлавык янына килеп тә өлгерә: «Тукта, үзем!.. Чамала!» — ди. Шул хәтле үк өрекмәсә соң!

Менә бит хәлкәйләр! Менә бит сөенечләр! Һай, кыландыра белә дә соң бүгенге җәшләр! Без андыйны белгәнмени? Ире, «мыеккае» тагы...

Көне буе Рәсүлә авызын җыя алмыйча йөрде. Тимер худ арбада келтер-келтер басу юлы белән элдерткәндә

дә, механизаторларның тамакларын туйдырган чагында да, шактый ук алҗып кайтып килгән мәлендә дә, уң кулы гел авыз тирәсендә булды...

Ул кайтуга мондагылар тыкрык коймасын ялт иттереп торгызып та куйган, ул да түгел, су ташып, мунча миченә ут салырга да өлгергән иде инде.

Кичен, эреп-изрәп мунчалар кергәннән соң, җыйнаулашып табынга утырыштылар, әлбәттә, шау-гөр килделәр. Менә шул чакны да Рәсүлә үзенең нурлы күз карашын тегеләрдән аерып ала алмады. Кияү белән кызының авызы бер җәелеп куйса, әби булырга исәп тоткан ана кешенең ике җәелеп китә иде...

Инде төн уртасы. Йортларына йокы тынлыгы иңгән. Арыган буыннар ял сорый.

Кызы белән кияве верандада. Рәмзи бу төнгә печәнлеккә хуш исләр кочагына менеп китте.

Өйдә болар икәү генә.

Рәсүлә, йомшак мендәргә башын салган көенчә, күз карашы белән шифоньер өстен кармалый, анда — матур-матур исемнәр язылган кадерле яшел дәфтәр, аңардан төн караңгысында да нурлар бөркелә сыман...

Түзмәде, терсәге белән иренең янтыгына орынып алды. Бүген үк, бу төнне үк көндез күзәткәннәрен тәфсилләп сөйләмичә, зур сөенечне уртаклашмыйча калырга ярыймыни?!

Ире инде йокымсырап киткән иде бугай, колак торгызса да, кибеп житмәгән борчак кузагы чытырдаган шикеллерәк тавыш белән: «Эһе... кһем, алай икән»,— дип кенә куйгалады, әмма азакта, йокыдан инде тәмам айныганлыгын аермачык белгертеп, кисәк кенә:

— Әйтәм, җир йөзендә хан-солтаннар торган саен азая бара, тиккә түгел икән! Үзебезнекеләр монда, Чаллы төбендә дөньяга хан-солтанның берәгәйлесен тудырып бирмәкче икән! Хе-хе! — дип, куанычыннан төн караңгысын ярып, шаркылдап көлеп җибәрде.

13

Бирим дигән колына чыгарып салыр юлына, ди.

Рәсүләнең ян бакчада кура җиләге җыярга керешкән чагы иде. Басуда үз эшен төгәлләгәннән соң, өенә кайтып беравык хәл җыйгач: «Тукта, тәмле ризык белән янә бер сыйлыйм әле үзләрен»,— дип тотынган иде ул.

Җиләк сусылдыр, татлыдыр — авызга салуыңа эри дә китә. Тешләрне камаштырырдай салкын сөткә салып

ашасаң, әкәмәт инде. Ире Хәнәфи белән улы Рәмзи шушындый кызу көнне тир түгүләрдән соң, кичке уңайда янә бер кинәнеп алсыннар әле!

Рәсүлә әнә шулай уйлап, бакчадагы кура сабакларын актара-күтәрә бирде, кызарып пешкән тәмле җиләкләрне эмаль табагына ашыкмыйча гына сава торды.

Әлеге күңелле һәм кызыклы эше белән бик тә мавыгып киткән мәлендә, урамда капка төпләренә машина килеп туктаган тавыш ишетеп, сагаймыйча булдыра алмады. Тегендә менә инде, тимере шылтырап, капка ачылып китте, менә инде кемдер тамак кыргалап алды.

Рәсүлә, эшеннән бүленеп, бакча коймасы янына килде дә дәшми-тынмый гына муенын сузып карады. Ишегалларына килеп кергән юантыграк базык гәүдәле адәмнең өстендә җиңнәре сызганулы, зәңгәр сызыклы модный ак күлмәк, аның каравы, башында кәрәнсу төстәге гап-гади чүпрәк кепка, йөнтәс беләгендә исә, көмеш нурланып, зур гына сәгать елтырый иде. Рәсүлә аны шундук танып алды: партиянең шәһәр комитеты секретаре Камил Низамов ич бу! Басуга ул үзенең машинасында сирәк булса да килеп чыккалар иде. Һәм бервакытны, былтыр бугай, язгы чәчүдә иртәнге бөртеклеләрнең эшен төгәлләп, кукурузга тотынгач, кыр станында Рәсүләнең аш-суы белән дә сыйланып киткәне булган иде. Аның ризыгын Низамов үтереп мактаган иде ул чакны...

— Әйдүк... әйдүк, кем... Камил энем! — дип, ян бакчадан атылып килеп чыкты Рәсүлә.— Әйдә, түкле аякларың белән!

Теге Рәсүләне дә онытмаган, бик хәтерле икән: исемен әйтеп җылы гына кул биреп күреште һәм, хуҗа хатын сузган табактан ике-өч бөртек җиләкне кабып җибәргәч, күзләрен йомып, авыз бөрештереп алды.

— Хәйран... җанны эретерлек! Өегезне эзләп йөрүем тиккә булмаган шул!

Ул инде бодай басуында ашлык урган комбайннар янында да, Шилнә инеше артындагы ындыр табагында да булып өлгергән, авылда совхоз конторасына да сугылып чыккан, әмма беркайда да ни директорны, ни партком секретарен очрата алмаган, ахырда, урам белән Хәнәфи Бариев йортын эзләп төшкән икән.

— Хәнәфи Бариечың өйдә җук шул, энем. Шушындый кызу көнне өйдә җатарга... Ә нигә?

— Бер уңайдан су сиптерүләре белән төптәнрәк танышырмын дигән идем. «Фрегат»лары кайсы басуда яудыра икән, яшелчәлектәме, әллә культуралы болын-

лыктамы? Хәйран диләр үзен! Ә Хәнәфи Бариеч, ни дисәң дә, сездә ясалма яңгырның атасы ич.

— Анда «Фрегат»ларга баш булып Мөбәрәй җөри хәзер.

— Мөбәрәй?

— Исем... җәгъни тулы исеме Мөбәрәкша. Былтыр ук әле Украинага барып, укып-өйрәнеп кайтты. «Фрегат»лар заводының үзенә... Тукта, кая болай? Җук-җук, капкабыздан атлап кергән синдәй олы кешене коры-буш кына борып чыгарырга монда...

— Рәхмәт, Рәсүлә апа! Ашыгам мин.

— Дөнҗаларың җанмыйдыр әле. Менә бит кызарып пешкән сусыл җиләк кулымда, сап-салкын сөткә салып, тәмле ризык белән сыйламыйча соң!

Низамов шоп-шома итеп кырылган булса да, күгелҗемләнеп торган ияк-яңагын сыйпаштыргалап алды, үзенең бер үк вакытта күзләрендә елтыр чаткы да күренгәндәй булды, ниһаять, авызы ерылып китте:

— Баш өсте алайса...

Олы кунакка табынны Рәсүлә, әлбәттә, өенең түр ягында әзерләде. Тиз кулдан гына, аннан-моннан гына. Кухня өлешендә улы Айдаш бүләк иткән көмеш йөзле электр самоварын розеткага тоташтырды, суыткычыннан сөт белән катык алып, савытларының иң матурына — кияве Чехословакиядән алып кайткан фарфор касәләргә салды. Күпереп торган күмәч икмәгенең дә иң елмаеп торганын турады.

— Әйдә, энем Камил... кем ни... Фәтхиевич бит әле, име? Әйдә, аш булып сеңсен... Сөте үз мүкләгемнеке. Мактыйлар. Мүкләкнеке шулайрак инде ул...

Олы кунак ашыкмыйча гына тәмле ризыкны капкаларга кереште. Бүлмәдә тынлык урнашты. Ләкин бу әллә ни озакка сузылмады.

— Әле бер көнне, җәйгә кергәчтен, безнең совхозга сугару министры килеп чыккан ие,— дип янә сүз яңартты Рәсүлә, үзе дә фарфор касәдән генә чәй эчәргә керешеп.— Минзәләдән кайтышы икән. Әкәмәт җор, әкәмәт күңелле кеше икән үзе! Ипи белән катыкка җабырылды инде, туясын да белмәде сыман. «Күптән инде мондый тәмлене ашап караган җук ие, галәмәт!» — ди... Мич шәп минем, күрше-күлән дә хәйран аптыраашта: «Бигрәген дә уңа шул синдә ипекәй, Рәсүлә!» — дигән булалар. Ә пешерүнең сер дигәнен уйларына да китереп бакмыйлар!

— Сере дә бармыни?

— Булмыйча... Ә ул сугару министры, өстәвенә, үтә дә мунча җанлы адәм икән. Шимбә көн ие, мунчаны харап та кызу иттереп җаккан ием. Җибәрдем мин бу министрны бер җулдашы белән мунчага. Киттеләр болар. Киттеләр дә баттылар. Уза бер сәгать, уза ике сәгать, кайтмыйлар гына бит. Шуннан, китүләренә өч сәгать тулды дигәндә, тәмам аптыраудан гаҗиз булгач, җибәрдем Хәнәфине: бар әле, алай-болай ис тидереп, харап булып җатмыйлармы, министр да кеше бит, дип... Барса, тегеләрнең уенда да җук, ди, мунча ташының бар кызуын сыгып бетергәнче чабынып ятулары икән. Мең рәхмәтләр әйтте, кайткач! Ә мин бер бөтен күмәч ипиен тоттырып җибәрдем үзенә...

— Бер бөтен икмәк дисеңме?

— Ие, жәлмени бүгенгесе көнне? Семьяң белән бер утырып ашарсыз, шул хәтле дә тансык булгач, дидем. Аннары соң бер мәлне Мәскәү кунакларына да берәр-берәр ипекәй тоттырып җибәрдем. Анысында халык казанышы күргәзмәсеннән ике профессор белән бер министр, җук, министрның урынбасары ие бугай. Алары да: «Шушындый ипине беренче ашавыбыз, хәйран»,— дип мактадылар. Министр урынбасарына хәтта ике ипи тоттырдым: берсен өеңдә гаиләң белән түгәрәкләнеп ашарсыз дип, икенчесен РСФСРның Министрлар Советында җыенысына да авыз иттерерсең, дип...

— Хе-хе, Министрлар Советында ипиеңне тәмләп караганнардыр дисеңме?

— Карамыйча... Ипидән өстен түгелдер әле берсе дә...

— Ай-һай, оста да икәнсең, Рәсүлә апа: күр, министр хәтле министрларны ничек иттереп кенә җайлап-майлап ятасың икән лә син монда! Хәтта үзләренә күмәч ипиләре тоттырып, ә? Әйтәм, республика Авыл хуҗалыгы министрлыгы сезнең совхозны бу тирәдә үзе өчен базовый хуҗалык итәргә чамалый — бер дә тиккә түгел икән ләбаса!

— Бардыр инде, энем... кем... Камил Фәтхиевич, бардыр.

Ниһаять, олы кунак алдына шундый ук матур касәдә сөтле чәй килде, май һәм варенье салынган савытлар да аңа таба этебрәк куелды. Ләкин Низамов көтмәгәндә чәйдән баш тартты: янәсе, сап-салкыннан соң кайнарны йотуы бик үк килешеп бетмәс, аннан да бигрәк, авызына сеңгән җиләкле сөт тәмен һич бозарга теләми, аны Чаллыга ук алып кайтып җиткерәсе килә... Алай да, ризык кабудан тукталса да, олы кунак табын артыннан куз-

галырга ашыкмады, утыра бирде, күрәсең, аңа гап-гади авыл хатыны белән гәп корып утыруның тәме җиләкле сөт тәменнән ким булмагандыр, ахры.

Дөрес, гәпне куертып торыр өчен икесенең дә алдан уйлап, әзерләп куйган оеткысы юк иде, шул сәбәпле сүз сөрешләре бик табигый рәвештә әле тегеләйгә орынып, әле болайга борылыбрак бер җай белән агылуда булды. Хәер, Рәсүләнең күңеле түрендә секретарь белән киңәшер әйбере бар иде, бик бар иде, ул нәрсә вакыт-вакыт, түбәннән күтәрелеп, тел очына ук менеп җитә сыман иде, әмма Рәсүлә аны ычкындырудан тыелып, хәтта шүрләп-шөбһәләнеп тә кала иде: ярый ла секретарь аңласа... ә аңламаса?

Шулай да бер арада, секретарь авыл әхвәлләрен сорашып, аларның гаилә хәлләрен белешергә тотынгач, Рәсүлә тел очыннан ул кадерле нәрсәне ничектер үзеннән-үзе бик тә урынлы, бик тә ыспай рәвештә ычкындырды да куйды:

— Кече улым Рәмзиме? Анысы «Ватан»да эшли. Монтажник-сантехник булып... Вакыт тигәндә, совхозның сугару эшенә дә катышкалый... Ә «Ватан»ны харап та шәп, дөнҗада бер буласы диләр бит!

Низамовның соргылт кашлары сикергәләп алды:

— Тукта, нинди «Ватан»?

— Нинди булсын, җәшел түгел инде... Без Җаңа поселокны шулай дибез хәзер. Без, түбән очтагылар, хәер, бөтен Әҗер үк диярлек...

Бусы, әлбәттә, чамадан тыш күпертү иде: корылып яткан Яңа поселокны «Ватан» дип атау бөтен Әҗергә таралу түгел, аны хәтта Рәсүләнең үз өендә дә белмиләр, ул көннәр-төннәр буе эзләп-уйлап тапкан исемне нибары түбән очта иң якын күргән ахирәтләре белән генә уртаклашып өлгергән иде... Менә ул, муен төбенә менгән кулын аерып ала алмыйча, секретарьга ымсынулы караш белән төбәлгән килеш, аңа совхозда игълан ителгән конкурс хакында әйтте дә янә тынын кысты:

— «Ватан»... Җәмсез җаңгырыймы әллә?

— Ямьсез димим... Соң, конкурсыгыз тәмамланмаган ич әле. Бүтән авылларыгызда, бәлкем, бүтәнен әйтерләр? Аннары андый исем кайбер колхоз-совхозларда бар да бугай инде, хәтта кайдадыр бер газетаның исеме дә шулай атала шикелле...

— Аталса соң...— Бу минутта Рәсүләнең бар гәүдәсен эсселәтеп ниндидер дулкын купты, кайнар кан йөзенә йөгерде, һәм ул, эсседән җаны гына түгел, зиһене дә

кабынып киткәнлеген тойган хәлдә, бер сулыш белән диярлек тезеп алып китте: — Аларныкы, бәлкем, ул исем җисеменә бик үк туры да килми торгандыр, ием, чат шулайдыр әле! Ә бездә? Соң, өр-яңа җирдә яп-яңа поселок төзелә — халыкка Ватанның чын бүләге ич! Үзе тагы оҗмахтай буласы, ди. Җитмәсә, русча да бик матур, бик җиңел әйтелә, бүтән телләрдә дә шулай. Ә яңгырашы: Ва-тан! Чат инде алсу таң шикелле нурланып, балкып яңгырый!.. Син инде, энем... кем, Камил Фәтхиевич, бу матур исемне раслау алай-болай сиңа килеп төртелсә, зинһар өчен, берүк яклый күр, җәме!

Низамов, ниһаять, табын артыннан кузгалырга итте һәм, хуҗа хатынга мөлаем карашын төбәп, җылы гына елмаеп куйды:

— Миңа килеп төртелсәме? Якламыйча соң... әлбәттә, әлбәттә! Тәк, теге кем... «Фрегат»лар атасы Мөбәрәй... Мөбәрәкша диденме әле?

Бу йортның киң күңелле, алтын куллы хуҗабикәсенә изгелекләр теләп, зур рәхмәтләр әйтә-әйтә чыгып барган олы кунагына Рәсүлә үзе дә иярмәкче иде, әмма ул бусага төбендә кисәк тукталып калды. Тукталып калды да, чак кына уйланып торгач, кухня өстәлендәге чүпрәк япмалы өемгә күз салды...

Ул капкадан атылып чыкканда, Низамов, чем-кара «Волга»сына кереп утырган, әмма кузгалып китәргә өлгермәгән иде әле.

— Нәрсәңне оныттың, Рәсүлә апа? — диде ул, автомобиль ишеген ачып.

— Онытмадым... Мәле, энем, мә! Аш булып үтсен!— дия-дия Рәсүлә аңа кулындагы төргәкне тоттырды.— Җә инде, үзең дә ипекәйдән өстен түгелсеңдер әле! Ихлас күңелдән дип бит!

— Син бигрәк инде... Бу хәтле үк... Зур рәхмәт инде!

— Исәнлеккә, энем!

Елык-ялык иткән чибәр «Волга» урам белән Түбән очка элдертте һәм анда, мастерскойга җитәрәк, уңга басу юлына таба борылды. Аңарда җәйрәп утырган секретарь Низамов күңеленә ни төяп алып киткәндер, монда урам уртасында басып калган Рәсүлә исә, йөрәгенең атлыгып типкәнен тойган хәлдә, ян-якларына күз төшергәләде: бу сәгатьтә, шушы минутта ук зур яңалыгын ахирәткәйләре белән уртаклашу теләге купкан иде аның күңелендә.

Ә, юк, сабыр, сабыр... Кич житсен әле, авыл сихри бер тынлыкка чумсын әле. Анда инде кичке сәрендә маңгай күршесенең капка төбендәге киң эскәмиягә чыгып утырыр да:

— Шулай-шулай бит әле, үзебез тапкан теге матур исемне Низамов булып Низамов ошатты сыман. Аны иплән кенә үз җаебызга аударып куя җаздым,— дип, зур куанычын уртаклашыр...

Күкрәген тутырып тирән-тирән сулап куйды...

Рәсүләнең үз гомерендә иң җилкенгән көннәренең берсе иде бу.

14

Бер дә бер көнне Хәнәфи Бариев Яңа поселокны да, андагы комплексны да, үз аяклары белән йөреп-айкап, төзелештәге хәл-әхвәлләр белән күзгә-күз танышып кайтты.

Аңарчы да Яңа поселоктагы хәлләрдән бөтенләй үк бүленеп яшәмәгән, вакыты тигәндә, аның ул тарафлардан әйләнеп кайткан чаклары булгалаган иде.

Монысында рабочком абзаң, күзәтеп-белешеп йөрүләр белән генә чикләнмичә, кайбер нәмәрсәләренә, ярыйсы ук тирәнгә чумып, тыкшынгалап та алган.

Кәефе шәптән түгел иде.

Тегендә, совхоз конторасында ни әйткән яисә ни әйтәседер әле, монда өйләрендә хатыны Рәсүләгә кипшереп ярылгалаган иреннәре арасыннан кысып чыгара-чыгара, бар зарын тулае белән түкте дә салды.

Комплекстагы хәлләр аерата ошамаган аңа:

— Кыландырган әллә нихәтле эшләре тагын кыеккыеккка чыккан. Экспериментал дигәч тә, республикада мондые әле беренче дигәч тә, чиге булыр микән кабаттан үзгәртү-төзәтүләрнең? Проектларында, имештер, чиле-пешле нәмәрсәләр әледән-әле чыгып кына тора. Югыйсә, аның анысын да галим дип исәпләнгән йомры башлар төзегән бит, ни уйлап әвәләштерделәр микән? Мастеры белән дә, участок башлыгы белән дә якалашып алдым әле. Тәгаен кайчан өлгертәселәрен үзләре дә ярып кына әйтә алмый. Ә безнекеләр монда совхозга җәһәннәм артларыннан нәселле терлек кайтарту җайларын эзләп юл таптый, яныл-көеп йөри. Мең бәла белән кайтартылган ул мал-туар тора-торып үзебезнең иске фермаларга гына сыеп бетәрме? Ә бит һәммәкие дә алтын бәһасенә төшә, һәммәкие шул комплексның тиз

араларда корылып бетүенә чамалана... Ә алар? Их, шәп айгырга атландырабыз дигәннәре кәҗә тәкәсе сыртына булмаса гына ярый ла!

Сәгате туры килеп, Яңа поселок корылышында да бавырына тиярдәенә юлыккан:

— Ташчылары болай ярыйсы гына кыландыра үзе. Карап торырга күңелле. Рәт-рәт тезелешеп киткән мансардалы йортлар да, ике катлылары да байтак инде. Әмма алар нибары таш каплар гына бит! Адәмне ничек кертәсең андыйга? Ә сылау-бизәү эшләре исә? Бер ишесе, дөрес, эш майтарып кылангандай иттерә, алай да алынкы-салынкы гына маташтыра, ә инде җәш-җилкенчәге... җәй кызуында кояш нурларын әрәмгә җибәрмик дип ахры, шәп-шәрәләнеп, йорт түбәләренә, веранда өсләренә сырт-корсак кыздырырга яткан. Көн биргәндә җиде кат тирләр түгәсе урынга! Шундыйларын: «Болай кылансагыз, тамаклык та эш кыйрата алмассыз, ни уйлыйсыз, үтә чибәр аналар тудырган үтә матур сылукайлар?» — дип оялтырга ниятләп тел орырга өлгермәдем, чытыр-чатыр үземә ябыштылар: «Бәйләнмәсәнә, абзыкай, кеше тамак өчен генә яшимени?!» — дип тә сиптерәләр, бер төсле чытлаклары хәтта ки: «И абзыкай, карчыгың үз янында йоклатмыйча куып төшердеме әллә? Күз майландырып йөрмә ичмаса безнең тирәдә!» — дип үк җибәрде. Баскан җиреңдә хет эреп ак, хет таш булып кат, билләһи!

Рәсүлә моңа ни дип җавап кайтарырга да белмәстән:

— Шулайрак инде, карткынаем, бүгенгесе көндә җәш-җилкенчәктән бериш чәчлекәйләр оят-намус дигәннәрен уч төпләреннән өф иттереп җилгә очыртып җибәрүләрне бер тиенгә дә куймый, ыштыр битләр! — дип, ахыр чигенә җитеп аптыраган кыяфәттә, баш чайкап кына куйгалады.

Рабочком алай да, күз үткенләндереп йөри торгач, күңеленә хуш килердәенә дә тап булган. Монысы студентлар хезмәтенә, аларның үтә тырышлыгына бәйле иде. Әҗер урманы кырыендагы киң тугайлыкта дәү-дәү брезент палаткалар корылган, шунда җәй буена яшәп, җәй буена төзелештә хәлләреннән һәм кулларыннан килгән кадәренчә, көч түгеп йөрүдән бүтәнне белми дә кебек иде ул студент халкы. Өченче елны һәм былтыр Казан студентлары иде, бу елны мәскәүлеләр, ди. Химиклар, ахрысы...

— Ичмаса, тәртип аларда! Тиккә генә үзләрен «сугышчы-боецлар» дип атамаганнар шул! Төзегән нәрсә-

ләре, дөрес, әллә ни чүтерекледән түгел, гараж салалар да юлга бетон түшиләр, тагын шуның ише нәмәрсәләр. Әмма аның алары да галәмәт кирәк бит!

Шулай һәр нәрсә белән дә кызыксынып йөргән мәлендә, рабочком абзаң читләтеп үтмәгән, улы Рәмзи эшләгән бригадага да барып чыккан. Һәм менә шунда, күзләре дә, күңеле дә янә беркавым ял итеп алган.

— Үзләре шабыр тиргә баткан, чүмеч белән чиләктән салкын су чөмерәләр дә янәдән юан-юан торбаларга җан җегәрләре белән ябышалар... Күз алдымда тирән генә траншеяда кызыл балчык өсләтә сузган торбалары соры-агарып әллә ни тиклем үрчеп куйды — менә, ичмасам, чын егетләрчә!

Әмма шул чакны һәм шул ук җирдә ул күз агына арпа кылчыгыдай кадалып, җен ачуларын куптаргынына да тарыган... Хәер, бу азаккысын Хәнәфи хатыны алдында чәчеп салырга ашыкмады. Улын көтте. Ә Рәмзи бу вакытта, Яңа поселоктан инде кайтып төшкән булса да, совхоз басуында ясалма яңгыр сиптерүчеләр арасында эш кыйратып йөри иде. Ниһаять, өс-башы чыланып ул да кайтып керде. Ишегалдында бил тиңентен чишенеп, ах-ухлап юынып алгач, өстенә корысын, тазасын киеп җибәрде. Аннары алгы бүлмәдә әнисе әзерләгән табынга утырды. Әтисе шул чакны да сүз кузгатырга ымсыну сиздермәде, көтте.

Рәмзи кичен урам йөреп кайтырга җыенып, ак күлмәк өсләтә костюмын киеп алгач һәм яка кайтарырга тотынгач кына, ниһаять, әтисе Хәнәфи диван почмагында тез чәнчеп утырган җиреннән, кулындагы гәҗитне читкә куеп, тамак кыргаларга тотынды:

— Сезнең анда, улым... юк, ни... бер генә дә чөй кыстырасым килми, шәп җимерттерәсез икән, маладцы! — диде ул, йомшак һәм чак кына күперенке тавыш белән, тик үзенең шул чакны какча яңаклары тартышып та алгалады.— Ие, чөй кагып йөрүләр минем эш түгел... Әмма ләкин нишләп әле сез экскаваторчы адәмегезне әзрәк тыенкылатмыйсыз, нишләп ул кысыр хәсрәтнең намусына катырак орынмыйсыз? — Шулай дип улына кадалгач, Хәнәфи хатыны Рәсүләгә хәлне аңлатып бирергә кирәк тапты: — Берәүләр анда траншея эчләрендә манма тиргә батып, тир тозлары ялый, ә икенче берәү... экскаваторы белән әзрәк кенә траншей казып куйган да, бу эшен калдырып, ерак та түгел бер төштә үз бәрәңгесенең төбен өяргә керешкән — кызу эш вакытында бит! Шундук елык-ялык итеп торган «Москвич»ы тагы...

Кем җире? Совхоз җире. Сорап алганмы? Юк... Шәп бит, ә!

Өйләрендә шушындыйрак сүз кубасын Рәмзи көткән иде булса кирәк, көзге каршысында басып торган җиреннән ялт кына әтисенә таба борылды, коңгырт күзләре зәһәр елтырап алды:

— Зяб поселогының нахальный өлешендә хан сараедай йорт-кура җиткезеп, дөньяның артына тибеп яши дип-тә өстә инде, ник өстәмисең?

— Өстәрмен дә... Ул тиклем ертлачланса да ертлачланыр икән кеше! Хет җирен сорап алган булса икән. Ә экскаваторы ни дип тик тора? Аның бит һәр сәгате...

— Үзебез кушканга! Ары казып китсә, траншеяга су җыелмасынга!

— Тамчы да су күрмәдем... Ә «торбач» дигәнегез ни дип гәүдәсен кырын салган, анысы да су җыелмасын дипме? — Хәнәфи янә хатыны ягына күз ташлап алды.— «Торбач» дигәнем... шул инде... «бульдозер-трубоукладчик» ягъни... дөресе, шуның иясе... Бульдозеры күләгәсендә сыртын җиргә кырын салган да рәхәтләнеп тәмәке көйрәтүен белә. Курортка килгәнмени! Бусының да «Москвич»ы якында гына. Вәт аксөякләр! Югыйсә, траншейга торбаларны шул имгәк салдыра барырга тиеш түгелме соң? Ә сез арканнар белән! Элмәк кигезеп! Кулбашларда җегәрләр ташып тора дисәгез дә...

— Их, белмәгән көйгә кысылмасаң иде, ичмаса! Ничек уңай, ничек тиз, шулай иттерәбез! Ул безгә торбалар ташый, җир каезлый, траншея күмдерә — җитмәгәнме? Тиккә тыкшынмасаң икән! Имеш, син генә барына да белдекле, син генә остарып беткән механизатор!

Тегендә хәсрәт бульдозерчы-торбач, читкеше алдында оятына көч килеп, ахры, гәүдәсен кырын салган җиреннән кубып, кирәккәдерме-түгелдерме, бульдозерында җир умырттырырга тотынган икән. Әмма каушап киткәнгә күрәдер инде, юньләп эшләтә алмаган, кырт та пырт кыландырган. Ә Хәнәфи шул мәлне, чыгырыннан чыгып, тегене бульдозерыннан куып төшергән дә: «Казнаның тимер-томыры дигәч тә, вакытыннан иртә харапка чыгарасың лабаса, эт еккыры!» — дип, үзе менеп утырган. Әлбәттә, бульдозер аның оста кулларында биеп-уйнаклап кына торган. «Тимернең дә җанын аңлый белергә кирәк, энекәш!» — дигән... Шул рәвешле, әрләп кенә калмыйча, хәсрәт механизаторыңа бик шәпләп сабак та биргән абзаң. Төзелештә йөреп-күреп җыйган

бар әрнүләрен шул бичара «торбач» өстенә аударган, күрәмсең...

— Ичмаса, анда сине минем әти дип белмәгән булсалар икән,— дип йөз чытты Рәмзи.

— Белсәләр соң... Ә син үпкәләмә дә, рәнҗемә дә, улым. Мин синең әтиең яисә ата механизатор гына түгел, мин бер үк вакытта «рабочком» да әле! — Хәнәфи бу минутта карлыкканрак төс алган тавышына йомшаграк рәвеш бирергә тырышты шикелле.— Җәй азагына кырыклап фатирны тапшырмакчылар. Өлгертерләрме? Иң әүвәл «рабочком» кайгыртмый, кем кайгыртсын! Ә сездә, Яңа поселок төзелешендә? Тегендә бериш чибәрләре сырт-корсакларын кояшта кыздырып ятсын, монда типсә тимер өзәрдәе кызу эш өстендә үз бәрәңге җирендә — житмәсә, незаконный җирендә! — чокчынып маташсын яки авызыннан төтен бөрки-бөрки күктә болыт агызырга тотынсын — барыр, ди, синң эшләр җүнгә таба тәгәрәп!

— Без үзебезнекен үзебез белербез! Безнеке какшамас та, аксамас та!

Ләкин улының соңгы әйткән сүзләренә атасы колак салып торуны кирәксенмәде бугай, башын артка таба каерып, ачулы-җитди карашын түшәмгә төбәгән шәйгә, моңа кадәр бар әйткәннәренә сөземтә ясарга җыенгандай иттереп, бик тә тирән сулыш белән әйтә куйды:

— Их, механизаторларны бүгенгесе көнне дөньяның кендеге дип лаф орган булабыз. Авыл хуҗалыгында дисеңме яки, әйтик, төзелешнең үзендә дисеңме! Ә бактың исә... Арада бар икән шул әле казна имчәген иплән кенә авыз тутырып имеп ятучылар. Җайлашканнар! Көненә өч-дүрт сәгать эш кыйратма, өстеңә тәңкә-тәңкә акча яуганын көтеп ят! Азу-кинәнүләрнең дә аръягында...

— Бар кешене дә үзең күк әүлия дип белдеңме әллә, сантый,— диде Рәсүлә, бәхәсләре янә куера төшеп, тирәнгә китә калса, үзенең һичшиксез улы Рәмзи ягына авышачагын тавышы белән үк аермачык сиздереп.

Ләкин ана кешегә алай авышып мәшәкатьләнергә язмаган икән, шул мәлне Рәмзи кулы белән дулкын-дулкын чәчләрен төзәткәләгәндәй иттерде дә:

— Шулай, кешенеке күренә инде. Ә монда үзебезнең Вәсим абый?..— дип ярып салды.— Ул да белешкәләп-испәштереп йөри ич инде. Тәңкә-тәңкә акча яуган тынычрак төшләрне чамалап... Инде туйдырды, тын алмый булмый, имеш...

Абайламый кайнар шулпа капкандагы шикелле, этисе белән әнисе икесе бер тиңнән ис-өнсез калды.

— Вәсимме? — дип пышылдады, ниһаять, этисе, әле һаман күзләрен шакмакландырган көенчә.

— Кем тагы? Анын да бит «Жигули»е инде борын төбендә генә: иртәгә булмаса, берсекөнгә...

— Кая таймакчы, Жаңа поселоккамы? — дип муенын сузды әнисе. Ул мәсьәләне бар житдилеге һәм тирәнлеге белән зиһененә сеңдереп бетерә алмаган иде әле.

— Һы, нишләп? Чаллы төзелешләре галәмәт бит, беткәндер дисезме «казна имчәген» җай гына имеп ятарга аулак төшләр! Куршенеке куренер, ә уз борынын астындагы беленмәс, ди... Выт тәк!

Менә инде Рәмзи артыннан өй ишеге дыңгырдап алды, әнә инде ихаталарында капка тимере дә шалтырап куйды...

Өйләре тып-тын калды. Ата белән ана, бер-берсенә күтәрелеп карарга да уңайсызланып, моңсу һәм нәүмиз кыяфәттә утыра бирде. Алар сулыш алырга кирәклеген дә оныттылар шикелле...

15

Якында гына гөрелте ишетелде һәм, бер-ике тапкыр төчкереп алгач, тынып калды. Рәсүлә походный кухнясы тирәсендә, тегесен җыештырып, бусын рәткә китереп матавыкланган җирендә, бу хәтле соңарып кайсы икән инде тагы, дип борылып караса, мотоциклыннан төшеп, болай таба ире Хәнәфи килә иде. Башындагы чүпрәк кәпәчен сгетләрчә кырын салган, йөзе каралганянган, сыек яшел күлмәгенең җиңнәре сызганулы, изүләре киң ачык, үзе җиргә саллы-саллы басып атлый.

— Кая, эчәргә берәр нәрсәң юкмы?

— Булмыйча... Тамагыңа капмыйсыңмыни? Монда бераз бар әле.

— Рәхмәт, әлегә бөртек тә кабасым килми. Эчәргә, дим...

— Бигрәкләр дә кыздыра шул.

— Куерак итеп яса... Юк, шикәрсез генә...

Хәнәфи чүпрәк кәпәчен агач өстәл читенә куйгач, аяк өсли генә эмаль кружкадан чәй эчәргә тотынды. Чәй әле суынып өлгермәгән, ярыйсы ук кайнар иде, шуның белән сусынын беравык баскач, Хәнәфи, бар йөзе белән балкып, басу буйлата авыл ягына ым какты:

— Күрәмсең, юл белән кыяр җире читеннән берәү төшеп бара?.. Кем дип уйлыйсың?

Рәсүлә уң кулын җәт кенә кашлары өстенә менгерде.

— Кайда?

— Әнә, иплә6рәк кара! Инде шактый ерагайган. Аксыл күлмәкле.

Авыл ягында, сул кулдарак, хәтсезләргә җәелгән кыяр плантациясендә төрле төсләрдәге җанлы чәчәкләр сыман, хатын-кыз сибелешкән, уң тарафта, киң тугайларда, салават күперләре балкытып, «Фрегат»лар яңгыр яудыра. Ике арадан сузылган тар юлда исә... Рәсүлә керфек очлары белән, ниһаять, элеп алды:

— Бер кулы белән хәтәр иттереп селтәнә, икенчесенең култык астына нидер кыстырган... шулмы?

— Шул... Кем дип беләсең?

— Кем?

— Шөн Габделбәре!

— Вәтке җегетеме? Үзебезнең... теге җылдагымы? — Рәсүләнең тез аслары йомшап китте, ахры: лып иттереп өстәл буйлата сузылган эскәмиягә утырды.— Ник килгән ул монда? Нишләп җөри?

Бу минутта Хәнәфинең күзләрендә шаян чаткылар биешә, авызы читендә исә көлемсерәү чалымы хасил булган иде, әмма хатыны аңардагы мондый халәтне бөтенләй абайламады.

— Бик тә зур эш белән килгән ул: шушында күчәнеп, безнең совхозда төпләнеп калырга ниятли икән.

— Соң... соң... ул бит төзелештә кирәк хәтлесен генә өйрәнеп алам да, Вәтке буена туган авылыма кайтып, төзү эшенә керешәм, дигән ие. Анда чын һөнәр остасы булып, ике куллап зур эшләргә тотынмакчы ие... Шундый да матур ниятеннән ваз кичкәнмени?

— Ә безгә күчсә, начармы, матур ният түгелме? Бездә дә егет кешегә ике куллап ябышырга зур-зур эшләр азмы әллә?

— Аз димим... соң бит... соң...— Рәсүлә, күзләрен чепиләндереп, ләкин бу юлы кулын маңгаена куймыйча гына, әлеге шомлы тарафка төбәлде. Аның күз карашына хәзер салават күперләре уйнатып яңгыр яудырган «Фрегат»лар да, кыяр җирләренә сибелгән җанлы чәчкәләр дә элеимәде — болар һәммәсе дә куе томан белән өртелгән сыман иде, тик авылга табан сузылган тар юлда бәләкәй генә аксыл төртке шәйләнә, ләкин ул шикле төртке кинәт кенә ерагая да юкка чыга, аннары капыл гына терелә һәм, тирбәлә-тирбәлә якыная килеп,

Рәсүләнең күз алдын бөтенләй томалап ала иде.— Һай-гыналарым! Җүнлегә булыр микән?

— Ә нишләп куркасың әле син? Рәмиләң инде кияүдә, үзе ир хатыны. Түреңә Шөн егетенең кияү булып кереп утырасылары юк бит инде. Хәер, белмәссең сине: теге чакны өрмәгән җиргә дә утыртмаган идең. Әллә, дим, киредән кайтып...

Рәсүләнең төсе качкан, иреннәре хәтта күгелҗемләнеп киткән иде, ул йөзе алдыннан чебенне куган шикелле иттереп, кул селтәп алгалады:

— Ни лыгырдыйсың син? Теф-теф, диген! Ниткән кире кайтулар, ди? Кызың белән киявең шундый матур тормыш корып җибәрсеннәр дә...— Әйе, Рәсүлә кызы белән киявенең матур язмышы хакына теләсә нинди хәвеф-хәтәр алдында калкан булып басарга, яшен булып чатнарга әзер иде. Тирән сулап куйды.— Алаен алай да... гыйшык белән җенләнгәннәр әллә ниләр китереп чыгаргалый, тормышта әллә нинди әкәмәтләр булып куйгалый — бер ходай сакласын!

Хәнәфи, күзләрендә шул очкыннарны сүндермичә, хатынының һәр сүзенә колак сала, аның һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтә иде, менә ул кинәт бик күңелле рәвештә кеткелдәп җибәрде:

— Соң, мин бит боларны юри генә, сине сынар өчен генә сайрадым лабаса!

— Мине сынар өчен генә? Й шылтыравык! — Рәсүлә кулын бугазы төбенә менгерде, күзләрен челт-челт йомгалады.— Ә теге адәм... Габделбәр түгелмени?

— Габделбәр — чат үзе! Ләкин аның безгә күчәргә уенда да юк! Бу җәй азагына туган авылына кайтып китәргә җыена икән. «Бәби генә исән-сау тусын», ди.

— Нинди бәби?

— Нинди булсын — үзенеке! Өйләнеп җибәргән бит ул. Безнекеләр кук, «малосемейка»да яшиләр икән.

— Өйләнгән алайсам...— Рәсүлә киң иттереп сулап җибәрде, кипшергән иреннәрен ялаштырды, күзләрен кинәт дым басты.— Хатыны кем ди соң?

— Болай әйбәт кенә, ди, күндәм, ди. Көмәне инде шактыйланды, инде озакламастыр, ди. Хәзер декретта икән... Эшеме? Трамвай йөрткән иде, ди. Шул уңайдан үзе бераз зарлангандай иттерде хәтта ки...— Хәнәфигә менә боларны сөйләве күңелле дә, рәхәт тә иде, ул җиңелчә кеткелди-кеткелди ары тезеп китте:— Баштарак ул аны авылга таба һич карата алмаган. «Авылда трамвай юк бит, ни эшләрмен мин анда?» — дип киреләнгән

теге. Ахырда, Габделбәр моны туган авылына алып кайтып таныштыргач, Вятка буенда чынлап та оҗмах кебек икәнне үз күзе белән күргәч, хатыны күнгән тагы... Аннары, шунысы да бар: колхозларында хатын-кыз кышын мастерскойда тегү тегә, ә җәен яшелчәлектә эшли икән. Каладагы ниндидер фабрика белән договор төзегәннәр икән.

— Күрче, әмәлен тапканнар анда хатын-кыз көен көйләргә...

— Ә без аңа бер капрон капчык кыяр тутырып җибәрдек. Кыярның иң һәйбәтен, иң матурларын! Ризванъяшьти дә шунда иде. Йөкле хатынына да, туасы баланa да бик тә шифалы булыр бу, туганкай, дидек. Куанычыннан авызын җыя алмады Габделбәрең.

— Менә монысын булдыргансыз, ичмасам!

— Ә монда безнең басуны гизеп йөрүләре исә... Ул бит соңгы араларда сугару эшләре белән яман да кызыксына башлаган икән. Барын да күреп, белеп китим, ди. Кайткач та иң әүвәл шуңа тотынырга туры килмәгәе, ди.

— Күрче, күр, һәр җәһәттән дә чын һөнәр иясе булып кайтмакчы икән.

— Шулай итмәскә, ул бит каны-җаны белән җир кешесе ләбаса!

Рәсүләнең йөзенә кабаттан төс иңгән, бит урталарына хәтта җиңелчә кызыллык та йөгергән иде. Ул ачылып, нурланып киткән күз карашы белән янә баягы тарафка төбәлде, ләкин яшеллек эченнән авылга таба сузылган тар басу юлында теге ак төртке — хәзер инде бик тә кадерле һәм хөрмәтле төртке!—күренми иде инде.

— Тукта әле, тукта, нишләп соң син аны монда алып килмәдең? Үз өемдә булмаса да, үзем пешергән ризык белән сыйлап җибәрер идем... басу түрендә!

— Дәштем мин аны. Уңайсыз, дигән була. Сиңа сәлам әйтте... Мине тегендә Туры бабай, самоварлар куеп, көтеп торырмын дип әйткән иде, ди. Мотоциклын да шунда калдырган икән... Әнә кем сыйлап җибәрмәкче аны!

— Һе-һе, барыбер үзебезнең кеше ич! — дип авызын ерды Рәсүлә.— Әткәй белән борчаклары пешә ие шул аларның. Берүк, түгәрәк бәхетләренә матур иттереп тәгәрәп бара күрсеннәр инде шулай! Габделбәрне әйтәм.

Бу кояшлы, ямьле көнне басу күкрәгендә ир белән хатын арасында әнә шулай матур гына гәп булып алды. Икесенең дә йөзләре көләч иде, нурлы иде.

Рәсүлә иренең баштагы усал шаяртуын ипле генә йотып җибәргән, ул аны инде онытa да язган иде. Ләкин аның күңеле тыныч түгел иде: эчтә йөрәге тырналып тора иде. Бүтән кеше, бөтенләй ят кеше бәхете өчен куанышып утырганда, җан сызлануы көчәя генә бара сыман иде... Менә хәзер иренә әйтергәме, юкмы? Бәлкем, шушындый матур көннең куанычлы сәгатенә күләгә төшермәскә, сабыр итәргә кирәктер? Бит бу сиңа шаярушуклану түгел, ачы хәл, ире Хәнәфи өчен аерата аянычхәл... Бәлкем, киресенчә, шушылай күңелләре киңәеп, иркенәеп киткән мәлдә, аңа аны сеңдерүе җиңелрәк булыр? Иртәме, соңмы, ире ул ямьсез хәлне барыбер беләчәк бит...

Күңеленнән ныклы бер карарга килеп, Рәсүлә тирән иттереп сулыш алды да басынкы тавыш белән сүз башлады:

— Кичәгенәк өйдә үзебезнең Рәмилә әйткән ие... тегени... Вәсим хакында...

Хәнәфи хатынының көрсенеп куюыннан да, шомлы тавышыннан да сагая калды һәм, кашларын җыерып, аңа текәлеп карады:

— Ни тагы?

— Соң ни... Вәсим Чуардан эзен суыткан, ди.

— Ничек суыткан?

— Шулай... Фәүзия үзе йөз чөергән, ди.

— Әйтәм кичә, миннән сер яшереп, Рәмилә белән пышын-пышын килгән идегез. Әнә нинди йөк аударырга кайткан икән ул чәтнәби! — Хәнәфи, башын кыегайта төшеп, хатынына янә сынаулы караш ташлап алды.— Ә син шаяртмыйсыңмы, кызый? Ә бәлкем, үз кыланмышларың, үз сихерең аркасындадыр?

— Ниткән кылану, нинди сихер булсын? Мин инде үзем дә ул Чуар тарафына күңелемне күндерә башлаган ием,— диде Рәсүлә, авыртыну аша, һәм ул моны, чыннан да, ихластан әйтте.— Алар арасын Гарапша кызы буташтырган, ахрысы. Ул да бит күпмедер вакыт безнең Вәсимгә күз атып җөргән, диләр. Үчен кайтарган, күрәмсең.

— Гарапша кызы? Тфү, нәселләре белән бөтен авылга җан көеге булдылар инде!.. Юк, монда малай актыгы үзе гаепле: теге итәк артыннан чап, бусы артыннан йөгер — шулай булмый ни!

Хәнәфи, торып, зур чәйнектән эмаль кружкага чәй агызырга тотынды. Агызуын агызды, әмма эчәргә керешмәде: чәй булып чәй үтәрлек түгел иде тамагыннан...

Иренең кара көйгән йөзен, авыр кылаңышын күреп утырган Рәсүләнең күңелен: «Бу араларда хафаны болай да аз җотып йөрми, сабыр итәсе калган, кадалгыры»,— дигән үкенү хисе өтеп алды.

Хәнәфигә бу минутта, чыннан да, ачы, бик ачы иде. Бу кояшлы, матур көнне капыл гына тоташтан соры төсләр басып киткән кебек, хәтта агач эскәмиядә боегып утырган хатынына тикле бичура булып күренә иде аңа. Шулай күренмәскә, аның чуарлар белән якынаюына һәм туганлашуына тоткан бар якты өметләрен челпәрәмә китереп җимерсен әле малай актыгы — иблис җан!

Хатыны янына агач эскәмиягә утырды да, гәүдәсен авыр гына селкеткәләгән шәйгә, каяндыр күкрәк төбеннән кысып чыгарды:

— Чынлап та, акыллы кыз булгандыр. Язмыш ул алтын кызны безнең Вәсимгә әрәм дигән, күрәмсең... Бик тә жәл...

16

Бригадаларында барын да оештырып, әйдәп йөрүчеләре, билгеле, бригадирлары Петя Кувалдин. Рәмзине үз янына эшкә дәшеп килгәннән соң да ул Бариевлар өендә берничә мәртәбә кадерле кунак булып сыйланып киткәләде. Идел буенда туып үскән саргылт чәчле, тормышның кырыс җилләреннән һаман да коры-кызгылтланып торган йөзле бу адәм килеш-килбәте, үз-үзен тотышы һәм ипле дә, төпле дә сөйләшә белүе белән теләсә кемдә ихтирам уятырлык иде. Фамилиясе ни дә, үзе ни тагы: кувалда — зур чүкеч!

Бариевларда бер Петя Кувалдин гына түгел, Рәмзинең бүтән терсәктәшләре дә кунак булып, сый-хөрмәтне туйганчы татып киткәли иде.

Аларның һәркайсының да килеш-килбәтендә генәме, холык-фигыльләрендә дә, язмыш һәм кыланмышларында да үз хасиятләре булгандыр, билгеле, әмма өлкән Бариевларның — Хәнәфи белән Рәсүләнең — хәтеренә аерата сеңеп урнашканы арадан икәвесе булды. Берсе — бәләкәй генә шакмак мыеклы, әмма Алыптай таза, калын гәүдәле, сөйләшкәндә тимер мичкәдән чыккандай гүелдәү белән сөйләшүче Саша Юрченко иде. Таза, нык адәмнәргә хас булганча, сабыр холыклы, авырдан кыймылдаучы. Ләкин, Рәмзи әйтүенә караганда, акрын җигеп, каты юрттыручылар токымыннан икән, тегендә, эшләгән җирләрендә, бигрәк тә авыр торбаларны траншея-

га төшереп, сузып матавыкланган мәлләрендә, аның ниләмсез көч-куәткә ия булуы артыгы белән ярап куя, ди.
Юрченко хатыны һәм бердәнбер нәни кызы белән Литейный поселогында үзенә аерым вагонда, Яңа каладан фатир биргәннәрен көтеп ята икән. Ярый, аның бу хәтлесендә — ни эшендә, ни яшәү җаендa — алай бик искитәрлек нәрсә юк, болары бик тә гадәти хәл, өлкән Бариевларны шаккатырганы шул булды: Юрченко эшенә чыгып киткәнче иртән иртүк торып, аннары эшеннән кайткач, кичке эңгер куерганчы, үзе яшәгән вагон түбәсендә күгәрчен очыртып гомер үткәрә, ди. Күгәрченнәре ике дистәдән дә артык икән инде, шулар зәңгәр күк гөмбәзендә тилпенә-атына очкан чагында, дөньяларын тәмам оныта, ди, бу. Шулар өчен вагон түбәсенә әллә ничә бүлемтәле оялар, очырткыч күперчекләр ясап куйган, шулар хакына ни акчасын, ни вакытын жәлләми, ди. Алыптай гәүдәле, типсә тимер өзәрдәй адәмнең балачага сыман әнә шулай күгәрчен дип җан атып кылanulары Бариевларга гаҗәп кызык та, галәмәт сәер дә булып тоелды. Болар гынамы, бөтен Литейный поселогы хәйран аптырашта, ди, моңа!.. Ә бер көнне Саша Юрченконың туган ягы Таганрогтан ук бик саклап, бик кадерләп алып килгән иң матур, иң зиһенле ике күгәрчене — ап-агы белән көрән-чуары — әллә һава шартлары килешмәгәнгә, әллә бүтән берәр сәбәптән, кинәт кенә җан тәслим кылган, ди. Бу хәлләрдә Алыптай ир заты чиксез олы хәсрәттән атна-ун көн буена кара коелып йөргән, эшләгәне эш булып чыкмаган, ашаганы аш булып үтмәгән...

Булса да булыр икән җир йөзендә әкәмәт җаннар!— дип тик баш кына селки алды моңа өлкән Бариевлар...

Күңелләренә уелып кергән икенче адәмнең исеме Вася иде. Бусы тегесенең тап киресе иде: гәүдәгә бәләкәй, чандыр, йөзе ябык, сөйләшкәндә чытыр-чатыр сиптерә генә, сиптергәндә берөзлексез елмаюдан һәм бертуктаусыз колак артын кашудан бушый алмый.

Вася да шул ук Литейный поселогында аерым вагонда гаиләсе белән укмашып яшәп ята, ул да шулай ук яңа каладан фатир бирүләрен көтеп йөри икән. Тик инде кая аңа күршесе шикелле түш киереп, зәңгәр күк гөмбәзенә күгәрчен очыртып ятулар! Өй тутырып үз күгәрченнәре гөрләшә, хатыны инде бишенчесенә көмәнгә узып өлгергән, ди. Юаш кына холыклы, чандыр гына ул хатын, үз бәбкәләрем — алтын, күршенеке — кыркын, дип кылануларны бөтенләй белмичә, канаты астына күр-

ше-күләннекеләрне дә сыйдырып, Литейный поселогының басуга караган бер почмагында мәш килеп яшиди, шулай. Тамак ялгамага күрше-күләннәр керткәннәр дә өстәлгәч, уртак табыннары мулланып та, нурланып та китәдер, әлбәттә! Ире Вася гигант төзелештә тегесенә кагылып, монысына ымсынып тыйтаклап йөрмәгән булса, андый ишле гаиләгә яңа квартираны әллә кайчан тоттырган булырлар иде, югыйсә. Инде хәзер Вася, акылы куерып, бүрегенә төртә башлагач, ниһаять, бер оешмада, ягъни «Металлургстрой» СМУында, утырыбрак эш кыйратып карарга ният иткән...

— Шулайрак инде ул, һе-һе,— дип көлеп куйды Хәнәфи, бу сүз-хәбәрләрне ипле генә тыңлап утырган чагында.— Әзмәвердәй адәмең мышный-мышный боргаланып кыланган арада, бүлтерек бәндәң, аны-моны уйлап тормастан, нәселен үрчетеп тә өлгерә!

Уллары Рәмзи исә ни көлмәде, ни елмаймады, шулай ук йөзенә ни кырыслык чалымы кертмәде, тик:

— Ә бит ул әле утызны да тутырмаган. Безнең Айдаш абай яшьләрендә генә,— дип, тирән сулап куйды.

Ләкин егетнең сулыш алу рәвешендә дә, тавышында да үпкәчел төсмер аермачык беленде — әнисе Рәсүлә моны шундук сизеп алды. Ачынуы бүлтерек Васяга түгел, үз хәлләренә, үз абыйлары Айдаш белән Вәсимгә иде, әлбәттә!.. Моңарчы һаман да шуларга ым кагып: «Хәләл җефет кайгыларын иң әүвәл әнә кемнәр кайгыртсын!» — дип кырт кистереп кенә яшәде дә бит... Күрәмсең, бу хәлгә төпчек уллары Рәмзинең дә, ниһаять, эче пошып, күңеле кымырҗый башлаган. Бәлкем, күкрәгендә ялкын ук дөрләргә тотынгандыр? Дөрләсә, җан атканы кем икән, кайсылайда икән? Ичмаса, бу төпчек уллары чиле-пешле кәлҗемә булып чыкмаса ла икән!..

Ул арада Рәмзи:

— Вася ни бүлтерек дисәң дә, эштә утлар уйната белә үзе! — дип әйтә салды, үзенекен дәвам иттереп. Болай диюе белән ул хезмәттәшенең бәһасен күтәреп җибәрергә ниятләде, ахры.— Нығытып эшләгәндә, бездә дә төшем начар булмый бит. Ә Вася, монгол аты шикелле, ару-талуны белми, һәммәбезне дуылдаттырып кына тора!

— Дуылдаттырмаска... Сезгә нәрсә? Ә аны кайтып керүенә, җим көткән кош балалары сыман, өй тутырык сабыйлары күз мөлдерәтеп каршы ала ич! — диде әнисе.

Шушындый сөйләшүләрдән, шушылай нечкәләүләрдән

соң, Рәсүләнең күңел бакчасында янә бер гөл матур чәчәк аттырды...

Ризыкка, шөкер, бик мул һәм иркен яшиләр. Рәсүлә әледән-әле камыр ашлары пешереп тора. Һәм ул соңгы араларда күңелендә чиксез җилкенү-сөенү тойган хәлдә, тәмле-томлының иң һәйбәт килгәннәрен сайлап алып, аларны шулай ук матур төенчеккә төйнәп, улы Рәмзи аша бүлтерек Васяның гаиләсенә: «Җирдән көткәннәре күктән төшкәндәй булсын әле!» — дип, күчтәнәч җибәреп торгалаучы юмарт бер җанга әверелде дә куйды.

Ул пешергән ризыкны Әҗердә авыз итеп карамаган кеше, мөгаен, бик аздыр инде. Унган кулларын гелән дә мактыйлар, кыланмышларын гелән дә хуплыйлар... Ә мамыктай күпереп пешкән, хуш исләр бөркеп торган ак күмәчләре? Болар инде үз авылында гына да торып калмады. Министр булып министрлар «ашап-ашап та туеп булмаслык ла» ди, әллә кайларга алып киткәләде — Казангадыр, Мәскәүнең үзенәдер...

Министр кабинетларына үз гомерендә барып кергәне булмады Рәсүләнең. Кабинетларына түгел, торганяшәгән өйләренең тупсаларыннан да атлап үткәне юк. Шул сәбәпле, бөтен тулылыгы, бар нечкәлекләре белән күз алдына китерә дә алмый: кайда, ни эшләтә торганнардыр инде ул тоттырып җибәргән ак күмәч-ипекәйләрне? Тик бераз чамалый гына: әлбәттә, әрәм итмиләрдер...

Ә монда?

Дөрес, Рәсүләгә бүлтерек Васяның ни җәмәгатен, ни бала-чагасын үз күзләре белән күрергә бу көнгә хәтле насыйп булганы юк. Ул аларның кыяфәт-чалымнарын үзенчә төсмерли генә. Андагылар да шулайдыр: дөньяда бер юмарт җанлы түти барлыгын белеп, аның төскыяфәтен һәркайсы үз күңелендә үзенчә сурәтләндерәгенәдер... Әйдә, була бирсен!

Әмма Рәсүлә үзе дә ана кеше, бер оя бала-чага үстергән җан, тегендә кысан вагондагылар, бүлтерек этиләре бер төенчек күчтәнәч күтәреп кайтып кергәч, ни әкәмәт кылануларын бик әйбәт күз алдына китерә иде.

— Әйдә, саулыкларына байлык булсын, көр-сәламәт үсә күрсеннәр! Җаннарына да бер нур булып сеңеп калсын! — дип сөенә-сөенә күн букчага ризык тутыргалый иде.— Ием, соңыннан, Җаңа калада бәхетләре җылмайгач, вакытлы поселокта кыен ашап җаткан чакларын искә төшереп сөйләгәннәрендә, тәмләп тел тибрәндермәгә урыс марҗасына, ичмаса, бер матур хатирә булыр...

Улы Рәмзи баштарак әлеге күн букчаны алып китәргә бик үк теләмәс иде, алган тәкъдирдә дә бүлтерек Вася дустына тапшырырга нигәдер уңайсызланыр иде. Әмма ул соңгы вакытларда әнисеннән ризык-нигъмәтнең төрләрәген һәм тәмлерәген сорап, аны күн букчага үзе үк тутыручан булып китте әле.

Бер кичне ул, дусты Васяга ияреп, вакытлы поселокка барып чыккан да анда күн букчадагы бар тәмле-томлыны тегенең бала-чагасына үз куллары белән өләшкән иде. Аннан ул күңеле үтә хушланып кайтып керде һәм, эчендә өермәләнгән куанычын һич яшермичә, бер сулыш белән әйтә салды:

— Рәхмәт, әни! Меңнәр яшә!

Әнисе җавап кайтармады. Тик күзләрен мөлдерәмә тутырып улына төбәлде.

Әти-әнисенә ипле һәм итагатьле, туган туфрагына тугрылыклы һәм игелекле булулары өстенә, күр инде, кече күңеллелеген, кеше хәленә керә белүчәнлеген, шуңардан рәхәт тоюын... Кешеләрне, бигрәк тә бөтенләй ят адәмнәрне, куандырудан һәм шуңардан тәм таба белүдән дә кадерлерәк тагын ни бар икән бу дөньяда?

Рәсүләнең уң кулы күкрәге өстенә менде, һәм ул, җан җылысы белән күңел хозурлыгын бергә кушып:

— Үзеңә дә рәхмәтнең зурысы, улым,— диде, пышылдап кына...

— Нәрсә, әти?

— Соң, шул инде: «Татарстан»га, дим, баруым хакында...

Туры карт, муенын кыйшайтып һәм күзләрен чепиләндереп, улы Ризванга текәлде. Теге җиңел машинасының ишек тоткасына кулын салып өлгергән иде инде. Автомобиль эченә чумып, выжлатып китеп барырмы, әллә, карт әтисенең сүзенә колак салып, тоткарланып калырмы?

— Син баягынак табыннан купканда да нишләптер кистереп кенә әйтмәдең, улым.

Ризван әтисе янына килде, әмма, өй рәшәткәсе төбендәге эскәмиягә утырмыйча, җиргә чүкте. Сыңар кулы белән тузгып киткән чәчен сыпырып алды, аннары иягеп учлады. Аның да күрәнсу чәчендә көмеш җепләр бихисап күренә иде. Кояшта каралып, кучкылланып беткән киң маңгаенда тирән буразналар сырланды.

— Кордашың Кузьмич белән күрешмәгә күңел тагын кымырҗып тора, димсең инде син, иеме?

— Ие инде... Теге атнада дәшү хәбәрен тагын җиткерделәр. Бу җылны «Татарстан»да алмалар харап та шәп, ди, улым.

— Алма үзебездә дә начар түгел, әнә өй артына гына чыгасы да өзәсе... Нәрсә, сине шушы машинада илтеп куеп, аннары кире барып аласымы?

Туры картның йөзендәге сансыз җыерчыклары кыймылдашып алгандай булды, күзләреннән дә өмет нуры сирпелеп куйды, ул, башындагы кәләпүшен шудыргалап, хәтта кеткелдәп тә җибәрде:

— Һе-һе... җук ла инде, нишләп сине мәшәкатьләп маташыйм, ди, улым. Туры алашаны тимер худлы җиңел арбага җигәм дә элдертәм! Мәттин ике куллап риза бирергә...

— Япа-ялгызың гынамы?

— Ә нигә? Шөкер, беләктә ат җигеп, ат тотарлык кына җегәрләр бар әле — курыкма бер дә! Җулдашка Сабирны алыр ием дә, ул бит Айдаш белән комбайнда умырттыра. Һай бу җылның ашлыккынасы — сөбханаллалар булмыенча! Маладис инде үзегез дә — үстерә белдегез! — Туры карт шушылай кинәт кенә шапырынуга күчүе белән, әлбәттә, баш агрономның кырыс җанына беравык сары май тамызгаларга тырыша иде.— Сабирны андыен важный эшеннән аерырга җарар димени соң?

Моңа җавапка улы Ризван эреп китү түгел, киресенчә, күзләрен кыса төшебрәк карады, тамак кыргалап алды:

— Хикмәт Сабирдамыни? Хикмәт синең үзеңдә, эти! Кузьмич кордашың белән янә очрашкач, ни буласын мин белмимме әллә? Өченче елдагы күк тагын типтереп ятар идегезме?

— Әллә кайчандагы чүпне актарып маташмасаң ла ие, улым. Аңа инде ничәмә карлар җавып, ничәмә тапкырлар эрегән ич. Үзең әле генә, машинада илтеп куяргамы, дип тә әйттең бит, ир сүзе итеп...

— Юри сынар өчен генә әйттем бит мин аны...— Ризван, чүгәләгән җиреннән авыр гына калкынып, аягүрә басты, соры пиджагының чабуларын аерып җибәреп, ике кулын да чалбар кесәсенә тыкты.— Ярар, эти, чүбек әвәләп утырыр чак түгел, әнә күктә болытлар куерырга тора, хәтсез ашлык теземнәрдә... Ә син Кузьмич кордашыңны уеңнан чыгарып ат та йөр шунда үз көеңне көйләп кенә, үз өең дә оҗмах кебек!

— Оҗмах сиңа...

— Күңеленне, дим, бастырыклап куй иплэп кенэ!

— Бастырыкламыйча торсыннар эле... Их, кемнэн туыпсыңдыр шушындый!

Саргылт-яшел «Газик», тыкрыктагы хэтфэ чирэмгэ зэңгэр төтен сыландырып, чаттан борылды да олы урамга менеп китте.

Монда Туры картның сөмсере капылт коелды да калды. Ачудан кэкре башлы таягы белэн аяк астындагы бер гаепсез туфракны төйгэлэп алды...

Биреште шул, артыгын биреште. Их, дүрт-биш ел эүвэлтендэге хэле эйлэнеп кайтса идеме, бу «таш бэгырьдэн» рөхсэт сорап, аңа ялынып торыр идеме соң? Шулайрак икэн шул: картаюың басыбрак киткэч, тормыш дилбегэсе искэрмэстэн генэ синең кулыңнан ычкына да үзең берэүнең ихтыярына бэйле булып каласың икэн. Тап инде сабый бала сыман... Эллэ ниме, нэкъ менэ сэхрага-иреккэ җаскынган сабый бала кебек, сорамый-нитми генэ, шыпыртын гына элдертергэме? Таң тишегеннэн торып, туры алашаны барып җигэсең дэ... Э юк, хэерлегэ булмас, яманга эйлэнеп китүе бар: улы Ризван, ике уйлап тормас, сары-яшел «пэриенэ» утырыр да артыңнан куа ук чыгар. Туфаннар куптарыр...

Тик нишлэп соң эле бу хэтле үк аңа үчекте? Бер-бер рэнҗүе бармы, зур ачу тотамы?

Яшерэсе юк, аталы-уллы сүз көрэштермичэ генэ яши белмэделэр инде анысы... Лэкин тиктомалдан, буш-корыдан гынамыни? Бары да гомер сөрмеш, эш кылмышлар китереп чыгарган нэрсэлэр лэбаса! Заманасында Туры карт колхозда сыйфат комиссиясе председателе булып аз йөрмэде, пенсиягэ чыккач та эле байтак вакытлар өстерэде ул авыр һэм мэшэкатьле эшне. Димэк, һэр нэрсэгэ үзенчэ «ревизия» кылып йөрүлэр аның канына сеңгэн, миенэ укмашкан. Инде совхозга эверелгэч, җыен кыек-мыекларга, төрле эрэм-шэрэм итүлэргэ күз йомып кына йөрсенме?Алайса, күз нигэ бирелгэн, җан нигэ индерелгэн? Совхоз директоры эллэ кайда, һэр чакны аңа барып «аһ» итүлэр сэер дэ, э монда аның улы Ризван совхозның баш агрономы гына түгел, халык контроле житэкчесе дэ ич! Шөкер, бер шатрун түбэ астында яшилэр, бар уй-хислэрең белэн иң эүвэл аңа килеп түгелми, кемгэ түгелэсең, ди? Шулай булгач, ара-тирэ үзара бэхэс куптаргалап, хэтта чэнчешкэлэп алалар икэн, бик тэ табигыйдыр ки...

Э бит Туры карт кыек-шыек якларны гына түгел, уңай белэн матурын да бик эйбэт күрэ белэ ич. Эйтик,

яшелчәлектә суган, кыяр, кишерләрнең уңуына сокланып тел тибрәтүләре, аерата кукуруз белән чөгендернең хәйран шәплеген мактаулары аз булдымы? Ә инде бу елны ишелеп уңган игеннәргә сөенгәне!..

Иле-көне белән әнә шулай куанып йөргән көннәрнең берендә Чаллыдан чемоданын күтәреп Айдаш кайтып төште. Юк, бөтенләйгә түгел, урып-җыю чорында авылдашларына булышырга кайткан икән. ҚамАЗ төзүчеләре арасыннан авылда туып үскән бериш оста механизаторларны шулай елның-елында иң киеренке чорларда җибәргәләп торалар иде. Өченче елны һәм былтыр Айдаш күрше колхозларның берсендә эшләп йөргән, ә бу елны тир түгәргә туган туфрагына кайткан иде. Үзе үтенгән. Бу инде нур өстенә нур иде. Қоңгырт күзләрендә очкыннар елтыр, колагына тикле җәелгән авызында тигез тешләре елтыр егетнең...

— Бөтенләйгә кайтулар һай-һай әле... ҚамАЗның беренче чиратын аякка бастырмыйча, ничек инде? Мин китим, бүтәннәр таралсын, аны кем очлап куяр? — ди, бахыр.

17

Барыннан битәр комбайнны сагынган икән. Ие, заманасында анысында да маһы бирмәс иде егетнең асылы... Ләкин совхозда, хәерлегәме, хәерсезгәме, дигәндәй, ремонтланган комбайннарның бүленәсе бүленгән, ягъни һәркайсына да ия табылган, ул гына да түгел, комбайнчылар дөнья умырттырып арыш белән борчакны теземнәргә салырга керешкәннәр иде инде. Алай да мастерской утарында берәү калган икән әле: ярты-йорты ремонтлаганнар да, ахырда, кырга чыгарырга рәтен тапмагач, өметсезләнеп, кул селтәгәннәр, имеш. Бик тә «кәлдер-келдер генә» ди. Әнә шундый «кәлдер-келдер»не бәхет дияргә яраса, бәхете елмайды Айдашның! Үзенә булышырга Сабир-Чуерташны дәшеп алды. Сабир аңарчы яшелчәлектә җан-фәрманга су сиптереп йөргән иде, әмма аның эше инде җиңеләюгә, хәтта түгәрәкләнүгә таба бара иде. Абыйсы дәшүгә түбәләре түшәмгә тия язды. Тәки үз дигәннәрен иттеләр тагы: ничәмә көн буена җәфа чигүдән соң, «Сибиряк»лары Әҗер урамыннан даңгыр-доңгыр үтеп, басу юлына чыкты. Әлбәттә, аларның комбайны дан түгел, кырда үзенең «кәлдер-келдер»леген өзлексез сиздергәләр: бер көн эшләсәләр, ярты көн уалып ятарлар иде. Алай да, ни иза чиксәләр дә,

сынатырга теләмәсләр, бүтәннәр артыннан җегәрләре җиткәнче үз үрләрен яуларга тырышырлар иде. Ватылып яткан чакларында ни кичерә торганнардыр — бу хәтлесен Туры бабаларының төпченгәне булмады, мәгәр аларның кыр күкрәгендә җилдертеп эшләүләренә сокланмыйча мөмкин түгел иде: комбайннары теземнәрне җыеп суктырганда җирдә мул уңышның берәр башагы түгел, бөртеген дә калдырмыйча, камылларны аждаһадай себереп-ялап бара сыман иде. Ул көнне Туры бабалары оныклары яныннан, басу түреннән күкрәк тутырып олы хис, зур куанычлар алып кайткан иде...

Өстәвенә, нәкъ менә шул көннең кичендә аңа «Татарстан» совхозында яшәп яткан кордашы һәм дусты Кузьмичның кунакка дәшүен җиткерделәр дә... Бу исә аны бөтенләй җилкендереп җибәрде. Шулай икән: бала күңеле далада, диләр, әмма картаймышта да бер дә бер заман күңел сәхрага-иреккә алгысый ла икән! Дөньяларда ниләр бар икән, дип, бүтән төшләрдә халыкның хәл-әхвәлләре ничекләр икән, дип...

Шуны да аңламый бит, чукынгыры! Үз улы, үзеннән бүленгән нәсел ботагы, берәгәйле ботак, ни җитте түгел — баш агроном! Әмма нишләп инде ул әтисе чыгып китәр юлга яман чытырмандай чәнечкеләрен тырпайтып, кабарынып баса? Аны ничек атлап үтәргә инде? Әллә кияве Хәнәфи янына зар түгеп барыргамы? Холкы белән ул үтә киң күңелле, хәлгә керүчән... Тик аларга барган җирендә Рәсүлә дә белеп алса? Әтисе сүзенә колак салырмы, эреп китәрме? Аныкын беләсең юк. Абыйсы Ризван ягына авышып куюы да бар. Ие, «җапа-җалгызыңмы? Үз хәлеңне үзең белмиенчәме?!» — дип, чытырдап ябышмагае...

Иң әйбәте шул булырдыр: таң тишегеннән торасы да, шыпыртын гына туры алашаны барып җигәсе. Анда инде сәхра синеке! Ләкин моның өчен тимер худлы арбаны да, сбруй-мазарны да алдан ук хәстәрләп кую кирәк ләбаса!

Күңелендә ныгып алган бу мут уе картны капыл утырган җиреннән куптарды, һәм ул, өе каршындагы зәңгәр буяулы, матур рәшәткәне артта калдырып, аягындагы җиңел чүәкләрне кыштырдата-кыштырдата тыкрык сукмагы белән атлады. Әмма чат башына җиткәч, кәкре башлы таягына таянып, кинәт тукталып калды.

Ерактан, кыр түреннән күңелне хушландырып, тонык гөрелте ишетелә иде. Исенә төште: ат караучы Мәттин, әлбәттә, шундадыр, басудадыр — урак өстендә механи-

заторларны кичке уңайда да ашаталар лабаса. Кәнүшнигә барып йөрүнең әлегә мәгънәсе булмас, кояш баегандарак сугылыр ул анда...

Кулын каш өстенә куеп, Шилнә аръягына күз салды.

Анда, яшел тугайда, чирәм кимергәләп, бер төркем тышаулы атлар утлап йөри. Арада, әлбәттә, йомры санлы туры алаша да бардыр, малкай. «Әйдә, кипәнә бир, иртәгә таң тишегеннән үк тимер худ арбага җигеләсең булыр, рәхмәт җаугыры...» Картның нурлы күз карашы, тышаулы атлар төркемен иркәле сыйпаштырып алгач, әкренләп Шилнә буенда күпереп утырган купшы ябалдашлы чибәр тирәкләргә күчте.

Күз алдына, купшы тирәкләр тарафыннан калкынып, кордашы Кузьмич килеп баскандай булды. Башында соргылт-кара картуздыр, сыңар аягы агачтыр, чаларып беткән куе каш-сакалдыр. Үзе тагы түгәрәк сакалын сыйпаштыра-сыйпаштыра ягымлы да, хәйләкәр дә иттереп көлемсери дә кебек...

— Бабай, ни дип болай тораташтай катып торасың әле?

Борылып караса, эндәшүче — оныгы Сабир-Чуерташ икән. Егетнең күлмәк җиңнәре сызганулы, бармаклары гына түгел, беләкләренә кадәр тоташтан майга буялган, йөзендә дә күзләре белән тешләре генә елтырый.

— Нәрсә, улым, комбайныгыз тагын уалдымы әллә?

— Уалмыйча... Бусында моторы ук янып чыкты. Алыштырмыйча булмый. Чаллыда «Сельхозтехника»да яңасы бар, ди. Исламов абый шуны алмага элдертте.

— Соң... Басу корсагында җатарсызмы шуны рәтләп?

— Нишләп? Трактор белән өстерәтеп мастерской янына алып кайттылар. Комбайнның алыштырмаган нәрсәсе калмады да диярлек инде, нәләт. Алай да чигенергә исәп юк. Айдаш абай көлә: «Урак беткәндәрәк, өр-яңа булмагае бу комбайн», ди. Хи-хи-химе?

— Хи-хи... инде бик... Ә өйдә ни йомыш?

— Тамакка капкаларга берәр нәрсә алырга иде исәп. Безгә мастерскойда кич караңгыга тикле ятасы булырдыр...

Оныгына ияреп, Туры карт та кузгалды. Әмма өенә таба кыштыр-кыштыр атлаган мәлендә, кисәк адымын әкренәйтә төште: тукта, боларның янә казага таруы аның өчен күк капусы ачылган шикеллерәк була түгелме соң? Ул мотор дигәннәрен алыштырып-көйләп мастерской төбендә кимендә бер-ике көн ятачаклар. Айдаш, этисе

Хәнәфи кебек үк, киң күңелле, күндәм егет, шул арада Сабирны эштән бушатып торуы бик ихтимал. Һич югы бер көнгә!..

Кичен шактый соң үз өендә табын артында чәй эчәргә утыргач, Туры карт алдындагы сөтле чәй агызылган җәйләүгә кәкре бармаклары белән орынырга ашыкмыйча, байтак вакыт бер ноктага төбәлеп торды-торды да кыюсыз күз карашын улы Ризван белән килене Тәзкиягә тидереп алды. Картның кыяфәте үтә нәүмиз, хәтта мескен диярлек иде. Менә ул янәшәдәге буш урынга ым кагып (Сабир әле һаман мастерскойдан кайтып кермәгән иде), бик тә тирән һәм мәгънәле иттереп сулап куйды:

— Сабир әнәтерә миңа иярмәгә риза. Айдаш та тегендә: «Рәхим генә итсен, барыбер ремонтта ич», диде... «Татарстан»ның Кенәҗ авылына бармага, дим...

Улының коңгырт кашлары капыл маңгаена менде, кулындагы чынаягы өстәлгә кунды:

— Шулхәтле дә үҗәтләнерсең икән! Үз хәлеңне хәл димиенчә...

— Кордыйлар бит без, бу гасырга атлап кергәннең иң тәүге җылында туган бәндәләр, мин җәтти буранында, ә ул җәйге челләдә, печән өстендә дөнҗага килгән. Өч чирек гасыр әүвәл!... Менә син үзең җәшьти дип үлеп торасың бит. Авылда сез икәү генә иегез: Хәнәфи кияү дә син. Инде килеп, җаңа директор Акбашев өстәлде. Калган хәтлегезнең сөякләре тегендә, җыракта... Исемнәре генә клуб җанындагы һәйкәлдә уелып тора. Минем җанга да җәшьти-кордыйлар кадерле түгелмени? Кемнәр генә калды да кемнәр генә исән инде? Барын да бит җырак җыллар суырып алды, бик күбесен вакытыннан иртәләй... Кузьмичтан бүтән кордыйны белмим дә инде мин...— Туры картның тавышы кисәк чатнап куйды, хәтта сытылып-изелеп киткәндәй булды.— Бер сәхрага чыгып, сәфәр йөреп кайтулары ни? Бәлкем, азаккысыдадыр...

Килене Тәзкия усал иттереп, яндырып ире Ризванга күз ташлады:

— Ни дип олы кешенең җөрер жулларына киртә торгызасың әле син?.. Бар, әткәй, бар, аңа карама, ичмаса, бер сафланып кайтырсың!

Ниһаять, Ризванның да күңеле йомшый төште кебек, әтисенә күтәрелеп карамыйча гына:

— Җиңел машинада җилдерт кенә озатып куйыйммы соң? — дигән булды.

Туры картның авыз тирәсе, сытылырга торган сабый баланыкы сыман, мимелт-мимелт итеп торды:

— Кирәкмәс... үз ирегем, үз җаем белән генә чыгып китәсем килә сәфәргә...

18

Хикмәтле серне Рәсүләгә аягоч күршесе Фәгыйлә түти ачып салды.

Беркөнне кичке уңайда Рәсүлә, яңа бәрәңге казып алырга дип, арт бакчасына чыккан иде. Бәрәңге әле бик яшь, сусыл, ныгып, крахмалланып өлгермәгән, ләкин ул, кайтуларына, ичмаса, үзгә бер ризык булыр, тансыклаганнардыр инде, дип уйлады.

Бәрәңге төпләрен чыра пычагы белән казып-актарып, бәләкәй чиләген инде тутырып килә язганда, ул якында гына тамак кыргалаган тавыш ишетте, һәм шуның арты ук аңа:

— Әй, күршегенәкәем, исән-имин хәлләрдә генә җәшәп җатасызмы? — дип эндәштеләр.

Баш күтәреп, күз салса, Фәгыйләттәй икән. Озын итәкле чуар күлмәгенең җиңнәре сызганулы, кулында исә тирән генә табак: яшь бәрәңгене ул да тансыклаган, күрәмсең. Үзенең тирән җыерчыклар бизәгән җыйнак кына, түгәрәк йөзендә батуга таба юл тоткан кояш нурлары балкый...

— Шөкерләр диярлек... Үзең соң?

Байтак көннәр инде күрешкәннәре юк иде, ике арадагы шомырт куагы төбенәрәк, буразна читенә җылы һәм йомшак җиргә утырыштылар. Шуннан инде, иплемөлаем төстә хәл-әхвәл белешкәләп алгач, әкренләп, үз җайлары һәм таныш сукмаклары белән кереп киттеләр көн күрешнең куе әрәмәләре арасына...

Фәгыйлә түтинең балкып торган мөлаем йөз-кыяфәтеннән дә, көр тавыш белән гөлдер-гөлдер сөйләшергә тотынуыннан да кәефенең үтә күтәренке икәнлеген бик әйбәт чамаларга була иде.

Аны аңлавы кыен түгел иде: шушы җәй башыннан Фәгыйлә түтигә җан юлдашы булып, аның өендә бертуган сеңелесенең кызы да яши башлады. Зәйтүнә исемле, сөлектәй төз, зифа сынлы, чем кара кыйгач кашлы, мөлаем-моңсу карашлы ул кызый, Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлагач, монда килеп эшкә урнашкан иде. Хәер, ул кызый аңарчы да кышкы каникул вакытларында Әҗер урамнарында күренгәләр, ә өченче елның җә-

ендә хезмәт практикасын да боларда үткән иде. Ул чакларда тал чыбыгыдай нәзек кенә, сыгылмалы гына бер җан кыйпылчыгы иде, ә хәзер... сөбханаллалар, димиенчә сиңа! Рәсүләнең ишеткәне булган иде инде: Зәйтүнәнең үз әнисе моннан биш-ун ел әүвәл ниндидер чирдән капыл гына үлеп киткән, шуннан соң әтисе яман салуга ябышкан, бер өйләнеп караган, ике... Үги ана кулы астында Зәйтүнә игелек күрмәгән, Мөслимдәге үз туган йорты тәмуг оясына әверелгән, имеш. Менә шул сәбәпләр аркасында Фәгыйлә түти ярым-ятимәне үз кызыннан да болайрак якын күрә, аны җан аямый карый-тәрбияли һәм урамда берәрсе белән очрашып гәп корып җибәрүенә үк, «минем Зәйтүнәкәем шулай бит әле, болай бит әле» дип, авыз суларын корытып, кызыйны мактарга тотына иде...

Менә хәзер дә ике бакча арасындагы шомырт куагы төбенәрәк йомшак, җылы җиргә җәелеп утырышкач та, Фәгыйлә түти, тегесен-монысын ипле генә әвәләштергәч, әлбәттә, Зәйтүнәкәе хәлләренә күчеп, кызыйның совхоз яшелчәлеге дип, җанын фида кылырдай дәрәҗәләрдә янып-көеп йөрүләрен сөйләүгә күчте һәм, сүзен кисәк кенә өзеп, Рәсүләнең иңбашына орынып алды да капыл кеткелдәп җибәрде:

— Синең Рәмзи төпчегең дә төннәрен җәшелчәлекне каравылларга чыккалый димсең инде, ә? Һе-һе... бер-мәлне чалбарын да җыртып кайттымы? Икенче мәлендә күлмәк-пинжәкләрен буяпмы? Буявы куе-җәшелме?

Рәсүлә аягоч күршесенә үтә сәерсенү аша күз атып алды:

— Кайтты... чалбарын да җыртып..., буявы да куе-җәшел ие... Ә син каян беләсең?

— Белмәскә... һе-һе, савхуз җәшелчәлегендә, имеш... Минем ихатамда булгандыр ул хәлкәйләр! Чалбарын да үзем җурамалый суккан очлы кадакка җырттыргандыр, буяуны да сөяләсе төшләренә үзем кичтән үк буяп куйган ием. Һе-һе... Ичмаса, истәлеккә бер тамгасы калыр дип... Арт койма аша селтәнеп кенә керә шул күршегенәкәе! Анда инде болдыр төбендә гөлдер-гөлдер... Кайчагында өй эченнән тамак кыргалап өркеткәлим дә үзләрен... Их, җәшь чаклар, их, тансык заманнар!

— Соң, соң...

Бу сүз, бу яңалык Рәсүлә өчен бөтенләй көтелмәгән иде, ул, өстенә берьюлы бер ләгән әллә сап-салкын, әллә кап-кайнар су сипкәндәге шикелле, бөрешеп калды, муенын эчкә батырды.

— Заманасында минем Зәйнулламмы?! Сезнең Әжер белән безнең Игенче арасын күпмедер димсең? Барыбер ара жырак дип тормады, киң-төннәрен безнең жулларны таптауда булды... Кая анда чалбар жыртулар гына! Эттән талаттырдылар, жегетләр дөмбәсләп озаткалады... Һай, гаярь дә ие соң мескенкәем, жегетләрнең, чын әгәр, асылларыннан да асылы ие!.. Синең Рәмзи төпчегең дә болай жарыйсы... Тик аңа әллә кайларга жөрисе жук шул: бакча артында гына... Инде, дим, бу хәлләрдә өемә жаучы жибәрүләрегез... жук, үзегезнең мендәрле кунак булып килеп утыруыгыз бик тә ихтимал. Хәнәфиең белән парлашып, озакламыенча, дим.

— Соң... соң бит... Зәйтүнәңнең армиядә жегете бар, шуны көтеп, шуңа күрә синең канатың астында томаланып-бикләнеп жата диләр түгелме соң, Фәгыйләттәй? Кичләрен жүнләп клубта да күренмиенчә, ә?

Бу сүзгә Фәгыйлә түти, утырган жирендә гәүдәсен әле алга таба бөгелдереп, әле артка таба каерылдырып, тагын да кәефлерәк рәвештә кеткелдәргә тотынды:

— Жук сүз, чүп сүз бит ул, Рәсүләкәйгенәм! Жүри тараттык бит без ул сүзне! Бал-майга жыен чебен-черки тиккә жабырылмасын әле, дип, һе-һе... Төтен жибәрү инде, төтен! Армияләрдә бернинди дә жегете жук аның, ходага шөкер... Инде менә синең Рәмзи төпчегең бөтерелә башлагач кына... ием, аңа гына ачылырга иттек, үзем дә ризалаштым инде... Әллә ышанмыйсыңмы? Әллә тагын чалбарын жырттырып жәисә күлмәк-пинжәген буяуга буяп кайтсынмы? Аннары гына ышанырсыңмы?

— Нишләп инде? Алай кыландырмасаң да, ышанмаганнар кая!

— Әллә минем Зәйтүнәкәемне ошатмыйсыңмы, күнеләңә чит күрәсеңме? — Фәгыйлә түти, кызның бәһасын бик әйбәт белгәнгә күрә, бу минутта түшен үк кабартып алды.— Айса, армияләрдә бернинди дә жегете жук дип таратам да жибәрәм сүзне... Асыл жегетләр дөнжа тутырук бүгенгесе көнне! Анда инде синең төпчегеңә...

Рәсүлә курку-шөбһәдән куырылып төшә язды:

— Нишләп инде чит күрием, ди... андыен уңган кызны?

— Вәт-вәт, шулай диебрәк ач авызыңны, сеңелкәем... Айсам, мендәрле кунак булып килүләрегез, дим... ие, үзегез чамаларсыз тагы. Шунда ипләп-жайлап кына сүләшербез бар жәһәтеннән дә... Их, гөлдер-гөлдер итешүләре, бер тыңлап карасаң икән, Рәсүлә бәгырькәем, билләһи, үз жәшлегемә әйләнеп кайткандай инде!

— Бардыр инде, бардыр...

— Ә минем Зәйнуллаем — тулган аем безнекеләрне кундермәгә калым башы итеп дүрт аяклы мал тоттырган ие заманасында. Ни җарлы булса да... Аннары бу яшьләрнең дә никах туйларын үзебезчә, әүвәлдәгечәрәк иттереп кыландырыйк, дим.

Рәсүлә Фәгыйлә түтинең соңгы бер-ике елда авылдагы җыен диндар, тәкъва корткалар белән тыгыз мөнәсәбәткә кереп, әвеш-түеш килеп йөргәнлеген, дәшсәләр, коръән чыгартулы аш-су мәҗлесләрен калдырмаганлыгын бик әйбәт белә иде. Ни хәл итәсең, гомер көзенә кергән адәмнәр, бигрәк тә Фәгыйләттәй кебек бу фани дөньяның әчесен-зәһәрен кирәгеннән артык татыган керсез саф күңелләр, теге дөньяның биниһая рәхәт оҗмахына җан атып өметләнә торгандыр. Анысы аның үз иркендә. Мәгәр менә хәзер, шомырт агачы төбендә утырган мәлләрендә, Рәсүлә аягоч күршесенең ерганакны кайсылайга таба ерып җибәрергә ниятләвен абайлап, курку катыш шөбһә белән әйтә куйды:

— Соң, комсомоллар бит алар, Фәгыйләттәй!

— Булса соң! Син комсомол булмадыңмы, мин булмадыммы? Хәер, мин үзем комсомол түгел ием түгеллеккә, әмма заманасында җалкынлануларым аларныкыннан ким иеме? Никахның бүгенге заман кушканын кем дә эшли инде анысы, әмма тегесен дә читкә сукмыенча, урталарга куеп кына, дим... Җәмленең дә җәмлесе итмиенчә монда... Җарый, әле сүләшербез. Әнә капкамда кемдер бар... Зәйтүнә гөлиемдер әле. Чәйләр эчеп, сусын басарга кайткандыр, мөгаен.

Фәгыйлә түти, җәелеп утырган җиреннән җәһәт кенә кубып, бер кулы белән чуар чәчәкле күлмәгенең озын итәген күтәргән шәйгә, бәрәңге сабакларын ера-ера ихатасына таба юнәлде. Буш табагы буш килеш калды, аңа яшь бәрәңге казып тутырмады. Менә инде Фәгыйлә түти арт капкасыннан кереп ихатасында күздән дә югалды. Бакчасына да ул яшь бәрәңге казып алудан битәр эчендәге матур һәм изге хисләрен түгелдерергә дип чыккандыр да әле...

Рәсүлә исә, утырган җиреннән калкынды да, тирәнтирән сулыш алып, беркавым зиһенен җыеп торды.

Әлбәттә, иң әүвәл улы Рәмзине уйлады. Менә бит, ристан, менә бит рәхмәт яугыры, тормыш сукмагын ничек һәм кайсылайга ярырга иткән икән? Ә монда әнисе ут йота... Соңгы вакытларда улының элек йөргән кызы Язилә күренгәләр — тәмам ясанган, бизәнгән, әмма күз

төпләрендәге күгәренкелегән, ягъни бетешкәнлегән яшерә алмаган кыяфәт — Рәмзинең кич-төннәрен батып йөрүләрен шул бичурага юрап, бөтенләй пошаманга чумган иде Рәсүлә, ә бактың исә...

Күз алдына агроном кыз Зәйтүнә килеп басты. Зифа буй-сын, чем-кара кыйгач кашлар астыннан караган моңлы-нурлы караш... Совхозның яшелчәлегендә бөгелә-сыгыла җил-җил йөреп йатулары...

Рәсүләнең куанычы төптән дулкын-дулкын булып күтәрелә, кулының әле берсе, әле икенчесе муены төбенә менә. Кулы белән ул әлеге дулкынны сыйпагандай-иркәләгәндәй иттерә...

19

Төн шактый ук караңгы. Һава аз гына салкынча һәм дымсу. Өч-дүрт көн элегрәк әйбәт кенә явымлап алган, шуның бәрәкәтле сулышы үзен әле һаман сиздерә иде.

Күк гөмбәзен тоташтан калын болытлар басып киткән, шул сәбәпле йолдызларның әсәре дә күренми иде.

— Әллә тагын явымларга ниятли микән?

— Яуса соң... Аның каравы безгә җиңелрәккә килә, ичмаса: кимрәк сиптерәсе була,— диде Рәмзи, башын каера төшеп, дөм караңгы күк гөмбәзеннән күз йөртеп алгач.— Тик менә синең җыясы яшелчәләрең генә...

Зәйтүнә, йөзен егеткә таба борып, коры гына тавыш белән әйтә куйды:

— Минем? Минеке генәмени ул?

— Җә инде, җә,— диде егет, җиңелчә кеткелдәп, һәм кызның иңбашларын үзенә таба кысыбрак тарта төште.— Барыбызныкы да... Явымлый китсә, җыюлары үтә авыр булуыннан әйтәм.

Кыз җавап кайтармады, башын егетнең иңенә салды.

Алар шулай төн караңгысында урам кырыйлатып Түбән очның аргы башына таба үз җайларына әкрен генә, кәлдин-сәлдин генә атлауларында булдылар.

Бүген шимбә. Әҗер клубы бүген бөтенләй шауга-гөргә күмелде: авылга КамАЗ һәм Яңа кала салучы яшь дуамалбашлар өере белән кайтып төшкән иде. Рәмзи белән Зәйтүнә әллә ни озак болганмадылар, дус-ишләре искәрмәгәндә, урамга саф һавага шылдылар.

Шулай инде, бер-берсенә тыелгысыз рәвештә ымсынып һәм тартылып торган ике күңелгә, бүтәннәрнең гел дә очкыннар яудырган күз карашларыннан коты-

лып, үз ирегендә, аулакта йөрүләре бик күпкә рәхәтрәк ләбаса!

Урамның чокыр-чакырлы төшләрендә күлдәвекләр әле һаман сакланып торса да, өй-кура тирәләреннән үткән, койма-читән буйларыннан сузылган сукмаклар инде кибеп өлгергән. Ләкин бөтенләй үк катып такырланып китмәгән әле. Атлаулары йомшак — тавышсыз диярлек...

Соңгы берничә көнне рәхәт иде бу ике җанга: үз ирекләре белән төннәр гизеп нихәтле йөрсәләр дә, киртә кую түгел, орынып сүз әйтүче дә юк. Яшьлегеңнең чын тәмен белеп кенә туйганчы кинән авылыңның иркен кочагында!

Әнә бер кичне Зәйтүнә урам йөреп керергә җыенган чагында аның «алмапае» Фәгыйләттәй булып Фәгыйләттәй әйткән аңа:

— Син, күргәрченкәем, алай бик нитмә инде... Җәйнең җомшак төн кочагында минем бәп-бәләкәч өем белән ихатам төбен саклап җатулардан инде туеп беткәнсездер дип әйтеп әйтүләрем. Тик, кызым, гөликәем, җәшьлегең ирегендә кинәнгәндә җон-каурыйлар койдырмаенча, чын инсафланып кына берүкләр өчен,— дигән.

Зәйтүнә, «йон койдырмый, каурый-канат сындырмыйча» йөрүләрнең, чын, нәфис сафлыкны саклый белүнең кадерен, аның асыл бәһасен аңламыймы соң?! Ләкин аны «алмапае»ның соңгы араларда үтә йомшарып, үтә нәзакәтләнеп китүләре генә азрак сәерсендерә иде.

Шушы арада гына «буласы ике кодагыйның» бәрәңге бакчасындагы шомырт төбендә аулакта тәмләп сөйләшкәннәре, ул сөйләшүнең дулкынландыргыч тирән һәм татлы мәгънәсе аларга, әлбәттә, билгеле түгел, шулай да нидер булганлыгын азрак сизенәләр иде.

Төн караңгысында бер-берсенә сеңәрдәй булып сыенышкан хәлдә атлый бирделәр.

Әнә инде авылның Түбән очы да, караңгыда томаланып, әллә кайда артта калды; пленка япмалы, тигез корылмалы, әмма төнен тоташтан кара-кучкыл шәүләләнеп, куркыныч кыя-яр сыман тоелган теплица яныннан да уздылар.

Дөнья тып-тын.

Шилнә яры буеннан сузылган сукмак беленми дә диярлек. Аяк асларында йомшак үлән кыштырдый.

Бу тирәләрдә инеш суы ярларына тула язып тора. Әмма су өсте бик тонык шәйләнә. Аръякның яр буйларында зирек агачлары һәм тал куаклары тирән йокыга талганнар—аларның кара шәүләләре генә абайлана иде.

Йөзләренә орына язып һәм сискәндергәләп, әледән-әле төнге һава хуҗалары — җитез ярканатлар очып үткәли.

Шомлы, хәтта куркыныч та кебек...

Алгы тарафтан тонык кына булып су шавы ишетелде. Анда инеш буасы. Аңа якынайган саен, шарлавык тавышы көчәйгәннән-көчәя барды.

Атлый торгач, иң әүвәл яр читендәге насос карачкысына җитеп тәртелделәр. Насос төннәрен тып-тын тора, ял итә. Аның каравы, көндезләрен буыла-буыла дурылдаулардан бушана алмый. Соңгы араларда әйбәт кенә явымлап алса да, культуралы болыннар белән яшелчәлекнең беркадәр өлешләрендә — кәбестә һәм чөгендер плантацияләрендә — барыбер су сиптерүләрне өзелдермиләр иде.

Кыз бу тирәләрдә, әлбәттә, бик сирәк була, ә егетнең исә — үз биләмәләре...

Буа өстендә шактый озак басып тордылар.

Түбәнге буа иде монысы. Инеш буйлап бер-ике чакрым югарыда Яңа поселокка бара торган асфальт юлның күпере төбендә тагын берәү бар. Буаларның икесе дә, билгеле, хәтсез басуларда ясалма яңгырлар яудыру өчен бөялә иде.

Бөянең өскерәк өлешендә, алай-болай ташу була икән, артык суны агыздырырга дип, юан гына торба сузып салынган. Әлегә ул кысыр диярлек: инеш суы аңардан саркылып кына ага. Торбаның икенчесе исә, шулай ук ярыйсы гына юаны, су эчендә өстән берәр метр тирәнлектә урнаштырылган. Су нәкъ шунысына бөтереләчолгана килеп керә дә, торба аша үтеп, буаның теге ягында шаулый-гөжли түбәнгә ургылып төшә.

Төн караңгысында шарлавык үзе күренми, әмма аның кодрәтле шавы колакны түгел, күңелнең үзен тондыра сыман...

Ләкин иң сәере, җанны өшеткәне бу түгел иде әле. Анысы, җанны өшеткәне, өске якта суның нәкъ шул бөтерелеп-чоңгылланып торба эченә ургылып кергән төщендә иде: әллә су берьюлы сыя алмыйча тыгылып-тоткарланып кала, әллә торба эченә һава кереп кысылган була, мәгәр чоңгыл бөтермәсендә нидер вакыт-вакыт шомлы һәм дәһшәтле тавыш белән яман ыңгырашып-уфылдап куйгалый иде.

— Сулый... Буаның да җаны бар кебек.

— Җан сиңа! Анда берәр коточкыч аждаһа күмелеп

ятадыр әле! Адәмнәрне йотарга гына торадыр. Әйдә, Рәмзи, җәтрәк китик моннан!

— Шулай, дөп-дөрес: аждаһа!.. Кичке эңгердә бер-мәлне үземнең күзгә чалынганы бар: чынлап та, бер күрсәң, котларың калмас! Көндезләрен тими ул, әмма төннәрен... менә шушылай дөм караңгы да булса...

— Һай, өркетмәсәң дә әле... Әйдә, дим!

— Аның каравы... әнә тегендәрәк... югары төштә,— диде егет, шомлы-серле пышылдавын дәвам иттереп.— Тымызык су борылмасында... төннәрен тал куагы төбенә... су анасы чыгып утыргалый. Алтын тарагы белән чәч тарамага!

— Ипи диген!

— Ипекәйне рәнҗетәсем килми... әмма тап шулай! Әллә ниме... Тукайның теге шук малае кебек, без дә синең белән нитәбезме... алтын тарагын, дим... Артыбыздан куа китсәме? Ә нигә куркырга? Без бит икәү... Тик менә ай яктысының булмавы гына...

— Бу кадәр дә чут... чутыл...

Егет сылукаена әйтеп бетерергә бирмәде, аны нечкә биленнән кочып күтәреп алды да һавада әйләндергәләр-гә тотынды. Бераздан төшерде. Төшергәч, кызның йөзенә таба ымсынып ипелде — иреннәр капыл кушылдылар... Дөньяда иң кайнарның татлысы, иң татлының кайнары...

Чоңгыл авыр ыңгырашып уфылдавын белде, шарлавык туктаусыз шаулый торды, ә ике сөйгәннең өзелмәс-киселмәс үбешүдән сулышлары буыла язды...

Аннары алар караңгылык пәрдәсен ерта-ерта аръякның йомшак чирәмле тугае белән инеш буйлап өскәрәк күтәрелделәр. Шулай инде: гыйшык утында янучылар табигатьнең гүзәл һәм тын өлешләрен, аның аулак һәм сихри бер кочагын эзләүчән. Мәхәббәт дигән төшенчәнең үзендә дә, уртада ук нурланмаса да, бу хәл бик әйбәт төсмерләнә ич. Тик шунысы бар: кыз халкыннан кайберәүләр шул сихри-гүзәл табигать кочагында йомшак-нәфис үлән белән бергә яшьлекләренең иң кадерле чәчкәсен дә издертәләр, алай гынамы, кайчакларда хәтта адәм мәсхәрәсенә калалар һәм, җаннарына оялаган мәңгелек үкенечнең зәһәр әчесен гомер буйларына тоеп, ачуташ суырып яшиләр. Икенче берәүләр, намус һәм вөҗданнарына кер кундырмаганнар исә, киресенчә, ул ямьле-тылсымлы кич-төннәрен гомерләре буена аллы-гөлле төсләрдә күрәләр, исләренә төшергәндә, кабаттан яшәреп-балкып китәләр, төшләренә керсә, янәдән чик-

сез рәхәтлекләр кичерәләр һәм, әнә шулай нурлы куанычның мыскалын да киметмичә, аны һич шиңдермичә, гомер азагына тикле алып баралар...

Хәер, кыз халкының төрлесе төрле хәләтләр кичерүендә бөек һәм изге табигатьнең ни катнашы, ни гаебе яисә гөнаһы бар? Әллә бармы?

Караңгы тугайның йомшак үләнен кыштырдатып барган чакларында, бермәлне йөзләрен гаҗәпләнү-соклану аша күк йөзенә төбәгән хәлдә, тукталып калдылар. Моннан, Шилнә үзәнлегеннән офык читләрен басып алган тоташ ут дингезе күренми, әмма аның яктылык шәүләсе көнбатыш тарафларда күктәге болытларга бик мул булып төшкән иде. Мендәр-мендәр болытлар да нәкъ әнә шул яктылык шәүләсе аша үтеп талгын гына болай таба агылып килә һәм боларның баш өсләрендә инде шактый ук таркалган, сирәгәйгән рәвешләрдә күренә иде. Әнә болыт ертыклары арасында йолдыз энҗеләре дә, серле-сихерле, әмма бик тә ягымлы һәм күңелле җетеелтырап, җемелдәшергә тотынган инде...

— Сәер дә, хикмәтле дә: Чаллының дуамал яктысы күктәге болытларны да киптереп, таратып җибәрә сыман... Тылсым көче бар диярсең, иеме, Зәйтүнә?

— Ие...

Әсәрләнеп торган җирләреннән теләр-теләмәс кенә куптылар һәм бераздан, шомландыргыч карачкылар булып күренгән тал куакларын әйләнә үтеп, янә инеш ярына килеп чыктылар.

Бик аулак һәм тыныч төш иде бу. Ян-якларда бәләкәй генә тал куаклары абайлана, ачыклыкның үләне дә куе һәм йомшак. Егет пиджагын үләнгә җәеп салды.

— Әзрәк тын алыйк... Әйбәт бит монда, иеме?

— Ие...

Аяк сузып утырыштылар. Сыеныштылар.

Чоңгыл уфылдавы һәм шарлавык шавы монда бөтенләй тонык ишетелә иде. Буа суы тымызык. Күктә генә түгел, тып-тыныч су йөзендә дә йолдызлар җемелдәшә. Һава тын.

Ләкин егет белән кызның бу минутларда бернидә дә гамьнәре юк иде. Чиксез киң һәм олы җиһанда алар нибары икәү генә иделәр. Икәү!

Кызның башы егет иңендә. Шома, нәфис муены һәм ияк асларына тикле кайнарланып тора. Ә йөрәге? Тыгыз күкрәге төбендә ул ашкынып-ашкынып тибә дә кинәт туктап, сагаеп калгандай була. Егет моны кайнар кулы

белән генә түгел, бар җаны белән тоя. Мөгаен, аның үз йөрәге дә шул ук ритмда тибәдер әле. Иярәдер...

Егет шашкын хисләр өермәсендә бөтерелеп, сөйгәнен үбә-үбә дә кайнарланып пышылдавын белә:

— Яратасыңмы? Яратасыңмы, дим, Зәйтүнә?

— Ие... ие, дим бит.

— Юк, син тутырып әйт, «яратам» дип... Минем кебек иттереп...

Җиңел түгел, күрәмсең, кыз кешегә «яратам» дип тутырып әйтүләре... Егетнең үзенә соң? Берничә көн әүвәл генә? Бик бөек һәм изге, татлы һәм ялкынлы сүзне әйтүенә бар җан, бар гәүдәсе белән әллә нишләп киткән иде лә... Ә кыз кешегә ничегрәк? Үзебезнең татар кызына, авылда үскән нәфис җанга?..

Кызның иңбашларына сибелеп төшкән чәчләре гаҗәп йомшак. Алардан, юк, чибәркәйнең бар гәүдәсеннән башын әйләндерерлек хуш ис бөркелә... Әйс, кырлар чәчкәсе лә ул аның! Егет туган авылы басуларында сулар сиптереп, бихисап су тамчыларында салават күперләре уйната-балкыта үз куллары белән үстергәндәй булды ла аны!.. Бит алмалары ут булып яна. Ә иреннәре... Иреннәрендә ян бакчаларында сусылланып пешкән кура җиләге, юк, Калмаш яисә Әҗер урманы аланнарында балланып өлгергән каен җиләге тәмнәре бар. Элегрәк ник белмәде икән бу сылуны? Бигрәк тә солдатта чагында? Ә хәзер... хәзер инде ычкындырмаячак ул үзенең бәхет кошын! Һичкемгә дә, беркайчан да!

— Юк, син тутырып әйт!..

— Ие, дим бит инде... Ие!

Ниһаять, кызның күңелендәге хисләр бөясе агылырга, йөрәгендә тыгызланып өлгергән ут йомрысына ярылырга вакыт җиткән, ары түзәр чамасы калмаган иде ахры, ялкын өреп пышылдады:

— Җаратам!.. Бик-бик җаратам, бәгърем!

Һәм кинәт егетне шашынып кочып алды да суырып-суырып үбәргә кереште, егет хәтта артка таба калканып, йомшак үләнгә чалкан килеп төште.

Бу тып-тыныч төн, төн генәме, иксез-чиксез киң җиһан тулаем аларныкы иде.

20

Көн бик аяз, бик матур иде. Чиксез сәхра зәңгәр күк тирәнлегеннән мул булып иңгән җылы, йомшак нурларда рәхәтләнеп коена иде.

Туган авыллары Әҗернең сөзәк үр артында югалып калуына инде әллә кайчан. Инде әнә тирән ерганаклы тәбәнәк ҭау уркәченә сыеныбрак сибелгән Гәрдәле дә, куе яшеллек эчендә йомылып-яшеренеп утырган Чуар да артта калды. Юллары, ниһаять, Ләпәй урманына житеп, әмма аның ешлыгына кермичә генә, басу кырыйлатып ачык ызан буйлата сузылды. Туры алаша, үзе дә киң сәхрага, иреккә һәм иркенгә чыгып йөрүләрне тансыклаган, ахры, дилбегә какканны да көтмәстән, әле җиңел генә юыртып китә, әле тыенкылана төшә дә тибеш-тибеш атлауга күчә иде.

Соңгы араларда явып узган бәрәкәтле яңгырлардан соң япа-яланда басу юллары җилләп өлгерсә дә, урман кырыенда, ышыклыкта күлдәвекләр берән-сәрән очрап куя иде.

Туры карт Әҗердән чыгып китүләренә үк дилбегә тотуны оныгы Сабирга тапшырган иде. Ләкин ул, арбада ике аягын да селкеп барган җирендә, әледән-әле дилбегәгә үрелеп:

— Ашыктырма әле, улым. Чак кына сабыр итик әле!— дип, атны туктаттыра һәм әйләнә-тирәсенә күз йөртә һәм:— Хәйран да вәйран шул дөнҗалар! — дип баш селеккәләп алгалый иде.

Басу юлы белән менгән чакларында әллә ничә тапкыр шулай иттерде, инде менә урман кырыйлатып ипле генә атлаткан шәйгә, сокланулы рәвештә тел шәпелдәтеп, янә дилбегәгә үрелде:

— Күрче, дим, тыңлачы, дим, улым!

Туры карт няге белән урман эченә ым какты. Анда, янәшәдә генә диярлек, матур гына, җыйнак кына алан пәйда булган инде. Уртадарак вак яфраклы зелпе куаклары күренә, аланның әйләнә-тирәсе миләш, юкә һәм каен агачлары белән каймаланып алынган иде. Галәмәт купшыдыр үзләре... Аланның печәне инде әллә кайчан чабып алынган, тик ни уртада, ни эчкәредә кибән янсә чүмәлә-мазар күренми, соңгы җылы яңгырлар бәрәкәте белән аланда куе-яшел хәтфәләнеп, яшь кәлшә шактый ук күтәрелеп өлгергән иде инде. Яшел хәтфә өсләрендә анда-санда чуар күбәләкләр бөтерелгәли; һавада исә бихисап умарта кортлары, төклетуралар безелдәшә; ул да түгел, купшы агачлар ешлыгында, инде җәй азагы булса да, ярыйсы ук гайрәт белән сайрар кошлар аваз сала иде. Ләкин барыннан да бигрәк күзнең явын алганы бер өер сыерчыклар булды. Алар, юк, сайрамый, әмма, чиксез куаныч-юаныч белгертеп, чиркылдый-чиелдый

аланның бер ягында утырган купшы ябалдашлардан дәррәү күтәрелешеп икенче тарафка очып чыгалар, аннары янә әйләнә-бөтерелә куе-яшел кәлшә юрганына төшеп куналар иде.

— Җырак сәфәрләренә китәрләре алдыннан канат чыныктыра, бәхырьләр... Исәнлеккә-иминлеккә була күрсен, диик, улым!

Туры картның тавышы үтә көр һәм җылы иде. Гомумән, аның тавышы гына түгел, бар төс-кыяфәте гаҗәп җанлы, гаҗәп көләч иде. Аңарда кичәге чиктән ашкан мескенлек белән нәүмизлекнең эзе дә калмаган иде. Сәхра иркенлеге һәм хозурлыгы үзгәртсә дә үзгәртер икән картыңны!

Ләкин ул матур аландагы күркәм җанлылыкка нурлы күзләрен төбәгән килеш, кинәт авыр иттереп көрсенеп алды:

— Әүвәлтендә шушы Ләпәй урманы тагын да баерак, тагын да җәмлерәк ие, эмма безнеке иемени ул? Баяры ни, кенәҗе-графлары ни, урманына кереп җукә каезласаң, ул синең арка тиреңне каезлар ие... Бар ие шул без җәшь чакларда каһәрләнгән тәртипләр!

Бабасына ияреп, Сабир да авыр сулап куйды. Егет, әлбәттә, моңа кадәр әүвәлге хәлләр турында бабасыннан аз ишетмәгән, аның өчен моның бернинди тансыклыгы юк иде, һәм ул, бабасы тирәнгә чумып, янә күңелсез, ямьсез нәрсәләрне селкетергә тотынмагае, шуның аркасында шушындый матур һәм көләч көнгә, күңелле сәфәрләренә тиктомалдан күләгә төшермәгәе дип ахры, сүзне капыл гына икенче юнәлешкә борып җибәрде:

— Күрәсеңме: арада мунча пиннегенә тунарга каеннарның ай-һай шәпләре бар, бабай, ә!

— Бар күк шул...— Әмма Туры карт шуның арты ук чал кашларын җыерды.— Җук, әллә ни түгелләр... И улым, мунча пиннегенә дип, урманга үземә ияреп ничә тапкырлар менгәнең булды, инде оныттың дамыни? Мунча пиннегенә, улым, каенның иң читтә кояшта баштанаяк коенып утырганы да, куе җышлыкта җәфа чиккәне дә әллә ни димәс, һәйбәтнең дә һәйбәте кояш тарафыннан, җәгъни иң кырыйдан өч-дүрт рәт эчкәрегә таба утырганы булыр. Урта җәшьләрдәге каенны гына сайлап аласың да, аның урта тирә ботакларын гына кисәсең. Әлбитте, бериш таза миңгерәүләр күк агачны төбеннән әрәм итмиенчә генә...

— Онытмадым ла... нишләп инде...

— Ә болай Ләпәй урманы каенның теләсә ниндиенә бай анысы, хаклыдыр сүзең. Тик, улым, һәйбәт пиннекнең вакыты үткән шул инде: августның икенче җартысына түндек ләбаса. Инде хәзер зифа каеннарның җафрак-ботаклары тиешенчә җомшак та, сыгылма да түгелдер, артыгын катыланып киткәндер. Пиннек әзерләүнең иң шәп чагы өч-дүрт атна арасы — июль аенда, нәкъ инде печән өсләрендә... Пиннекнең иң берәгәйлесе шул булыр!

Бабай әзерләгән мунча себеркеләре йортларында печәплек түбәсе астында киштәләргә эленгән хәлдә байтак саклана иде әле: былтыргылар гына түгел, өченче елгылар, хәтта аннан элегрәк бәйләгәннәре дә бар иде. Һәммәсе елныкы елы белән аерым киштәләрдә бүлем-бүлем, әмма аларны берсен икенчесеннән һич аерырлык түгел иде: арада ник бер себеркегә сары иңеп, кипшенеп һәм тузгып торса икән. Мунча керүчеләр, пиннек парлаганда, аның купшылыгына һәм хуш ислелегенә хәйран булыр иде, аннары инде тыела алмыйча, сулышларны куырган эсседә ах-вах итә-итә тотыныр иде тән вә һәм җан җебетергә... Ахырда, тәмам изрәп, камырга әверелгән адәм баласы йортның карт хуҗасына мунча хөрмәте өчен буыла-мышный мең рәхмәтләр аударганда, бусы: «Исәнлеккә-көрлеккә, байлыкка-саулыкка булсын!» — дип, йөзендәге бар җыерчыклары белән балкып, ияген сыпыргалар иде. Данлыклы иде шул Түбән очта Туры картның ак мунчасы да, үзе бәйләгән каен себеркеләре дә!

— Күрче, бабай, күрче: бу аланның кырый-кырыйларында, эчкәредә печәннең чабылмаганы да күренә бит. Арбага салмага әллә әзрәк кыркыштырабызмы?

Туры карт, бик күптәннән гадәтенә сеңгәнчә, җәйләрен ат җигеп ераграк җиргә сәфәр чыкканда, арбасына үткен чалгы кыстырмыйча калмас иде. Бүген дә ул аны, әлбәттә, онытмады. Арбаларына түшәлгән печән дә бик юка, такы-токы гына иде. Ләкин бабай, купшы аланга төбәлгән килеш, баш селеккәләде:

— Печәннең һәйбәте алда да очрамый калмас әле... Монда без сыерчыклар өерен өркетмик инде. Аларның сәфәре безнекеише генәме; бик җырак шул очасылары, һай, җырак — туйганчы кинәнсеннәр инде бер рәхәттә!

Чыннан да, кузгалып аз гына киткәннәр иде, аларның бик бәләкәе, вак куаклар басып алганы очрады — монысына һич чалгы кермәгән, житмәсә, күләгәлектә

үскән печәне дә ярыйсы гына куе һәм сусыл күренә иде.

Янә тукталып, арбадан чалгыны суырып алдылар.

Туры карт, билгеле, эшкә тотынмады, башын кыңгыр салган көйгә, оныгына тегеләй дип, болай дип акыл биреп торды. Үзе ул ара-тирә мыек астыннан гына көлемсерәп тә куйгалый иде. Оныгы Сабир инде, шөкер, буй җиткезеп, егет булырга чамалый, борын астында бәбкә йоны да, төс иңдереп, куера килә, буйлы ак күлмәк астында күкрәк һәм кулбаш мускулларының да җегәрле уйнавы аермачык беленеп тора, әмма, юк, ни таза буйсын үстерсә дә, печән чабуның һич җай-чамасын белми: гәүдәсен уклау йоткандай туры катырып селтәнә, селтәнгәндә тырт та пырт иттерә. Бик тә авыр һәм шыксыз кыландыра. Тәҗрибә юк, шомару җитми. Хәер, печән чабуда гынамы, дилбегә тотып юл барганда да, туры алашаны әледән-әле сискәндереп, һаман да тырт-пырт тарткалый... Сабир кебекләргә мотоцикл, машина руле генә булсын — анысында инде махирлыкның аръягында алар. Дөрес, үзләре теләп тотынган эшләрендә, комбайнда ашлык суктырганда яисә культуралы болынлык белән яшелчәлектә хикмәтле нәрсәләрдән яңгыр яудырганда, утлар уйната беләләр үзе. Шулай инде, Сабирга хәзер чалгы ни дә ат дилбегәсе ни... Замана кыйпылчыгы!

Чабылган хуш исле урман печәнен арбага үз асларына тигезләп түшәп куйдылар, калган хәтлесен арткы өлештә тыгыз өем иттерделәр.

— Булды гына бу! Рәхмәт, улым! Үзебезгә утырып бармага да галәмәт йомшак, тегендә Кузьмич кордаш җортында кунып җатканда алашага да кинәнгәнче булыр!

Арбага менеп, җәйрәп, инде бусында аяк сузып утыргач, Туры карт кинәт бөтен урманны яңгыратып көлеп җибәрде:

— Хе-хе, улым, этиеңне әйтәм әле: үзеңеҗ җәшел пәриендә выжылдатып кына илтеп куймакчы не, тилебаш! Соң, машинада җилдерткәндә күзгә шушындый җәмь, борынга шушындый хуш исләр тияр идемени!

Моның соңында ул тирән иттереп сулап куйды:

— Адәм баласы үтә дә ашыга бүгенгесе көнне. Машина, ди, самолет, ди, инде әнәтерә ракета, ди, жиде кат күккә менеп йолдыз аулыйм, ди. Әллә ул заманны, әллә замана аны куалый. Гомеркәйләре дә выжылдатып кына үтә дә тора! Әмма ләкин адәм баласы тора торгач,

галәмәт тә сагынып әле ашыкмыйча гына ат җигеп йөрүләрне, җир җөзенең җәмен дә, тәмен дә сеңдерә-сеңдерә менә шушылай ипле генә сәхра гизүләрне...

— Син нәрсә, бабай, атка мода киредән әйләнеп кайтыр дисеңмени?

— Кайтмыйча!.. Хәер, ат муда әйберемени ул? Хатын-кызның кыска итәкле күлмәге җәйсә менә синең ише исәрләрнең башындагы чәч пумаласымыни? Ат менеп җәйсә ат җигеп җөрүләр, улым, гомер-гомерләрдән адәм баласының канына сеңгән — һай тансыклар әле бер дә бер көнне! Тансыклар да җәнәдән әйләнеп кайтыр! Минем гомергә эләкмәс инде ул хәл, ә менә синең җәшиселәрең алда әле, синең гомердә үк әйләнеп басар әле андый көн. Туры бабай әйткән ие, дип әйтерсең әле бер заманны!

Урман кырыйлатып атлатып барган мәлләрендә шактый озын итәкле, әмма ярыйсы ук калку булган үргә якынлаштылар. Алаша, йөгән тимерләрен чыңлата-чыңлата баш селеккәләп, бу үрне ничегрәк алдырганда уңайрак булыр дип чамалаган арада, Туры карт арбадагы печән күбәсеннән яшьләрчә җәһәтлек белән шуып та төште:

— Тау менгәндә җөгеннән төшә белгән адәмне атмалкай гынасы җанына үтә җакын күрер, ди...

Үр юлында Сабир арба читенә сыңар кулын салган көенчә атлаштырды, бабасы исә, ике кулын да артка салып төйнәгән килеш, үз җаена адым санавын белде.

Өскә менеп җиткәч, туры алаша, үз белдеге белән тукталып һәм башын чак кына бора төшеп, өлкән юлчыны көтеп алды. Әмма сәфәрчеләрнең ни өлкәне, ни яше киредән арбага менеп утырып юлны дәвам иттерергә ашыгычлык күрсәтмәде.

Үр кашыннан, югарыдан, каршыларында хәйран күренеш ачылып киткән: әйләнә-тирә, ерак-еракларны иңләп һәм җәй азагының бар ямьнәренә бизәнеп, җәйрәп ята иде.

Куе-яшел төстәге чөгендер, кукуруз басуларына тоташып һәм алтынсу нурларда күңелле балкып, хәтсез җирләргә иген кырлары сузылып киткән, игеннәрнең байтак өлеше инде урып-сугылган, шулай да әле комбайн керергә өлгермәгәне дә шактый абайлана иде. Әлегә кара-кучкылланып яткан уҗым кырлары, салам өемнәреннән тазартылып, эскертләре ызан читләренә чыгарылган менә-менә туңга сөреләсе мәйданнар, тар,

әмма нәфис тасмадай яшел урман полосалары — бары, бары да уч төбендәге кебек иде. Киңлек, хозурлык!

Юлчыларның сулыш алулары ук киңәеп китте шикелле.

— Шулай инде, улым, басу-кырларга адәм баласының вакытында кулы тиеп, вакытында маңгай тире тама белсә, җәмленең дә җәмлесе шулдыр инде дөнҗада!

Әмма хәйранның да хәйраны беркадәр арырак, офыкка табарак иде: сул кулда, дөньяны мул иттереп алтын нурларга коендырган кояш ягында, җирдән күккә таба хәтәр биек ике морҗа — ТЭЦ торбалары күтәрелгән, аларның берсеннән беленер-беленмәс кенә булып сорызәңгәр төтен дә бөркелә, каршыларында, туп-турыда исә ерак басу түрләренә сыенышкан КамАЗ корпуслары, тимер-бетон һәм пыяла киемнәргә киенә-бизәнә, тәмам тернәкләнеп китәргә җыенып ята, ә уң кулда, күгелҗемләнеп торган урманлы-таулы Кама-дәрья тарафында, зәңгәр рәшәле офык сызыгында Ак кала үзе... Әле генә дәрья суында юынып, сафланып чыккандай, актыр, пакьтер һәм гаҗәп җиңелдер ерак кыр күкрәгеннән калкынган биек йортлар!

Зәңгәр күктә анда-санда инде мамык болытлар пәйда булган һәм иң биек, иң чибәр йортлар ул болытларны үзләренең түбәләренә купшы чалмалар итеп урап алганнар шикелле. Рәшә әллә ни куе түгел, зәңгәрсу-сыек, әмма ул киң сәхра өсләрендә җиңел генә дулкынланып тора шикелле һәм аның белән бергә ерак офык каршындагы ак чалмалы ак йортлар да талгын-талгын тирбәлеп-җилпенеп куйгалыйлар кебек...

Туры алаша бая купшы алан янында тукталган мәлләрендә дә башын борып, үзенчә соклану-гаҗәпләнү аша байтак кына төбәлеп торган иде, инде менә хәзер, үр өстендә, юлчы хуҗалары шикелле үк, акыллы күзләрен сирпештергәләп, иркен сәхрадагы чиксез хозурлыкка — бу сихри манзарага хәйран булган рәвештә, тын алырга да онытып калган сыман иде. Хайван булып хайван...

— Тап инде әкиятләрдәге тылсым көче җәисә диюләр кодрәте белән диярсең... Ә бит шушы фани дөнҗада күз алдында... Адәм баласы үзе...

Арба тәгәрмәчләре әкрен генә алга таба тәгәрәде. Үр кашында юл ярыйсы ук тигез һәм такыр иде, әмма туры алаша юыртып китәргә һич ымсыну сиздермәде, хәтта адымнарын тибеш-тибеш салудан да тыенкыланып, салмак кына, ыспай гына атлап китте: гүя инде,

бу хәйран манзарага бер туйганчы карагыз инде алай-са, диде акыллы мал...

— Таптым, бабай, таптым! Әнә Айдаш абай яшәгән ундүрт катлы йорт: болай таба кырыйдарак... урта тирәне кара, күрәсеңме?

Сабир сыңар кулы белән сәхрага таба ишарә ясап, арбадагы печән күбәсендә кымшангалап алды. Моның белән ул, әлбәттә, сихри хозурлыкны тын кысып күзәтүдән көндәлек тормыш дулкынына күчеп, чайпалып китүен дә аермачык сиздерде.

— Әйтерең жук: каргалар жапына, ундүрт катка ук менеп ояламаса соң, мәнсез,— диде Туры карт, тамагын кыргалап.— Аның лифтәләре дә кайчагында жүнләп эшләми, ди, житмәсә, су белән дә жыш кына иза чигәләр, ди.

— Аның каравы, бабай, балконга чыгып бассаң, бар дөнья уч төбендәге кебек! Айдаш абай әйтә: «Үзебезнең туган авыл басуларында кайда ни эшләгәннәрен — чәчәләрме, уралармы яисә культуралы болында печән чабалармы — барын да күреп, белеп торам», ди... Бинокльдән карап, билгеле.

— Бинокльдән? Нинди бинокльдән? — дип муенын сузды Туры карт.

— Нинди булсын, шәп бинокльдән. Илле алты сумга сатып алган. Кибеттә иң берәгәйлесе, ди.

— Илле алты сумга! Кит аннан! Ай-һай ла кесәдәге акчаң котыра башласа! Авылда кайберәүләр тир түгеп тапкан айлык хезмәт хакы диярлек ләбаса!.. Күр иблисне, каргалар жанына менеп оялавы тиккә генә түгел икән, күзәтеп жатмага икән!

— Заманында үзең эшләп йөргән басу-кырларны күреп торасың килсә, менәрсең дә.

— Сагынулары шул тиклемгә житсен әле бәхырның!.. Их, Айдаш абаең тизрәкләр генә әйләнеп кайтса ла икән. Бөтенләйгә үк!

— Нишләп? — дип текәлде Сабир, коңгырт кашларын жыерып.

— Соң, шуны да аңламаска... Теге жылны, олы төзелешкә төптән кубып китеп барганчы синең ул Айдаш абаең, һай, атаулы ие, исеме бөтен Чаллы районында шау итәр ие, ни данлыклы этисе Хәнәфинекеннән бер дә ким түгел ие, билләһидер. Инде менә хәзер Айдаш киредән бөтенләйгә әйләнеп кайтырга исәп итсәме?! Ипидер, байтак адәмнең күңеленә жәнәдән корт керер ие: «Тикмәгә түгелдер, Айдаш булып Айдаш төптән

уйламыйча җөрмәс»,— дип... И кубарылып кайтырлар ие бөтен механизаторларың. Их, житенкерәми шул бүгенгесе көнне авыл җирендә тракторчысы да, бүтәне дә!

— Ә бәлкем, Айдаш абай ҚамАЗның беренче чиратын җибәргәнче көтмәс тә әле, әйләнеп тә кайтыр... Йөргән кызы ни дияр бит,— диде Сабир һәм, теш арасына чәчәк сабагын кыстырган хәлдә, башын кыңгыр салып, бабасына күз төшерде: янәсе, бу сүз аңа ничегрәк тәэсир итәр икән?

Ә бабасы чынлап та кинәт сискәнеп куйгандай булды һәм, онычына таба бөтенләй янтаеп, ымсынулы пышылдау белән:

— Кызы, диденме? Кем кызы, кайсы җакныкы? — дип сорады.

— Кайсы, кайсы... Ык буеның Тау асты Байлар авылыннан, ди. Бездән утыз чакрымнарда гына бугай. Ә хәзер ул кызый җәйге каникулда икән. Айдаш абай мотоциклда әллә ничә әйләнеп кайтты инде аннан. Берсендә төн уртасында, яңгырда манма булып... Син ул авылны беләсеңме әллә, бабай?

— Белмәскә... Элгәреге җылларда без ул тирәгә малтуар алмага баргалар иек. Ык тугайларының җиләкҗимешен суырып үскәнгә күрә микән, һай, җилледер ул авылның хатын-кызы! Хе-хе,— дип күңелле генә кеткелдәп җибәрде Туры карт.— Үзе ничегрәк икән соң? Эшлиме, укыймы, дигәндәй?

— Укый, ди. Кайдамы? Соң, Чаллыда инде. Кулинария училищесында, ди. Әле тагын бер ел укыйсы, ди. Кемнәрнеме? Соң, җыен сатучы, җыен аш-су остасын әзерләп чыгаралар инде анда. Яшькәме? Безнең Рәмилә апа чамасындарак бугай...

— Җәшьлеккә әзрәк җәшьрәк икән, ә җук, таманча гына! Безнең Айдашка суйган да каплаган инде, хехе! Җитмәсә, авыл кызы да булгач...

Сәфәрләре болай да гаҗәп матур, гаҗәп хуш иде, инде бу хәлдә Туры картның күңеле тәмам түгәрәкләнеп китте. Моңарчы ул өлкән оныгы өчен пошынып, алай гынамы, җаны тәмам кыйналып йөргән иде, ә хәзер исә... Әйе, шушылай юл гизәргә чыкмыйча, өендә томаланып утыра бирсә, оныгы Сабир-Чуерташ аңа инде дә татлы сүз әйтеп, егетләр серен ансат кына тишеп салыр идеме соң?

Ул арада туры алаша иңкү төшне берне түгел, инде берничәне җилле генә алдырган, инде менә юлның чал-

кыйрак җиренә янә менгергән һәм... янә адымын акрынайта төшкән иде.

Исләренә килеп, әйләнә-тирәләренә күз салдылар.

Уң тарафта, киң басу-кырлар ягында, юк, ни КамАЗ ТЭЦы, ни завод корпуслары күренми — үр сырты артында, галәмәт дәү шырпылар сыман, ике морҗа гына күк гөмбәзенә кадалып тора, әмма, аның каравы, чак кына арттарак, зәңгәрсуланып торган Кама-дәрья тарафында Ак кала үзе бик ачык булып шәйләнә иде. Анда офык өстендә йөзгән баягы мамык-мамык болытлар, инде хәзер куера-тыгызлана китеп, биек йортларны ак чалмаларыннан мәхрүм иткән, инде хәзер таш кала тоташтан аклы-зәңгәрле шәльяулыгын бөркәнгән сыман, әмма йөзе барыбер һич үзгәрмәгән: йомшак кояш нурларында ул баягыча ук гаҗәп ак, гаҗәп көләч һәм матур чырай белән балкый иде...

— Мәскәүлеләрне әйтерең җук: Чаллы җиренә килеп, җорт-сарайларның нинди чибәрләрен, нинди берәгәйлеләрен салып җата, ә! Рәхмәт инде — әҗәтле булып калмаганнар!

— Ник алай дисең әле, бабай?

— Соң, үзеңә сөйләгәнем бер генә булдымы? Унтугызынчы җылның җазлыгын әйтәм, Урал җакларыннан Колчак җавы җабырылып килгән мәлләрне... Әчтәхи бай элеваторында берәр бөртек ашлык калдырдыкмы ул кара җавызларга? Җук! Барчасын җөзәрләгән обозларга төяп, ачка интеккән Мәскәү пырлитариатына булсын әле дип, Вәтски Пүлән станцасына ташып бетердек ләбаса! Инде күр, ничәмә җыллар үткәч, мәскәүлеләр әйләнә кайтып, Чаллы җирләрендә әкиятләрдә генә макталган ак калада таш пулатлар торгызып җөри ич. Шулай инде: илең-көнең белән бергә-бергә җәшәп җатканда, бәйрәм ашы кара-каршыдыр...

Бабай бер тынара сулышын көйләгәндәй булып торды, аның соңында көр тавышына бер тамчы сагыш тамызып җибәргән шикелле иттерде:

— Ул чакларда без җәшь иек әле, һай, җәшь иек әле, менә синеке күк борын астында бәбкә җоннары төс индерергә җабышкан гына ие әле. Олауларның берсенә Кенәҗ авылыннан Кузьмич җәшьти баш ие, үзебезнең авылныкына мин ием, ә мылтык дигәнебез, бик тә хәтерлим, нибары Кузьмич иңендә генә ие...

Туры картның җаны бүген күбәләктер, ә хәтерендә сакланганнар яшел сәхраларны бизәгән аллы-гөлле чә-

чәкләрдер. Күбәләк чәчкәдән-чәчкәгә кунмый түзә алыр димени?

— Гражданнар сугышы беткәч, мин үзем җыракта Себердә бүленеп калдым, ә Кузьмич кордаш туган авылы Кенәжгә әйләнеп кайткан. Аларга җакында гына алпавыт утары бар ие, галәмәт ие. Әмма револютсә купкан көннәрдә тамырдан туздырып, җандырган булганнар. Алай да әйләнә-тирәсе шәп сад-бакчадыр, сакланган хәтле каралты-кура да әкәмәттер әле, шул заманның үзенә күрә вак-төяк машинасы-мазары тагы... Менә шунда иң әүвәлтен «агроүзәк» дип тотынганнар, аның соңында, урысы-татары бергә укмашып, эртил-коммун корабыз дип җабышкан, монысын бераз торгач, совхозга әверелдергәннәр. Безнекеләр колхоз корырга җабышканчы ук бит! Үзләренең «Татарстан» совхозлары белән бөтен Татарстан җөмһүриятендә, һай, шаулаганнар ие лә заманасында! Беренче тракторны да иң әүвәл шулар кайтартты бу тирәләрдә. Көпчәкле ие, бәләкәй генә ие үзе. Шуна таң калулармы! Бик тә хәтеремдә: шушы Ләпәй урманы буйлата дуамаллар кубып барган иек без анда шул «атсыз җир сөрүче җен арбасын» бакмага. Хәйран тамашалар инде! Соңыннан да баргаладык без аларга тегесен-бусын күрергә — өйрәнмәгә...

Уң тарафта юлчыларны озата килгән үр сырты калыная бара, арырак, артка табарак уентылыкта күренгән Ак кала да бер калкулык мендәре артына таба әкрен генә шуыша-шуыша күздән йомыла бара иде. Туры карт сыңар кулын маңгай җыерчыклары өстенә менгереп, шул якка төбәлде. Ерак офыкта зәңгәрсуланып торган Кама-дәрья таулары да, күз карашларыннан югала барган Ак кала да аның уй-хатирәсен янә моңсагыш дулкынында тибрәндереп җибәрә, ахры:

— Безнең обозда Җумай-башкорт та бар ие. Герман сугышында җөреп җараланып кайтканнардан ие. Һай, оста да ие җырга-көйгә димсең, үткер сүзгә димсең! Безнең Әҗердә җыен бәеттер, җыен такмактыр-җырдыр анардан чыгар ие.

— Шилнә буендагы сабантуй тугаена пар тупыл утыртып калдырган Юмай-башкорт бабаймы?

— Ие, улым: пар тупыл — аның җәдкәре... Их, җыллар, җыллар, зәһәр дә җил булып зиһенне җилләтүләре генә менәтерә! Җырлаган ие обозда барганда Җумай берәгәйле бер җыру, хәтәр моң белән дә, җаман гайрәт белән дә!.. Их, төшмәй генә бит исләремә! Җыллар, җыллар, зиһенне кырау гына сукмаган булса соң!

Туры карт күзләрен йомды. Бераздан арбада селкенеп барган җирендә аның кысык иреннәре арасыннан моң агылырга тотынды. Ләкин ул тоташтан диярлек көй генә иде, сүзләре бик аз иде:

Каласың лай, Чаллым, бәхил бул!..

Сабирга бик моңсу булып китте.

Барыр юллары озынрак булса, бабасы юка иреннәре арасыннан көй белән бергә сүзләр дә чыгара башлар идеме, әллә хәтер сәхрасыннан оныгын кызыктырырдай чәчәкләрне янә нурландырырга керешер идеме, әмма рәхәт сәфәрләре инде азагына якынлашып килә — каршыларында киң сәхра-урманнарны кистереп үткән Минзәлә юлы ята, димәк «Татарстан» совхозына барып җитәргә әллә ни күп калмаган иде инде.

Асфальт юлдан выж да выж машиналар чаба — тузаннар гына уйный.

Шау-шулы, ыгы-зыгылы көндәлек дөньялары иде бу...

Ат әлеге шау-шулы, ыгы-зыгылы дөньяны бик үк өнәми иде, ахры, ул, сагая калып, адымын ярыйсы ук салынкыландыра төшкән иде.

Туры карт та, күзләрен ярым йомып, арбада җай гына селкенгәләп, моңлы көен сузуында булды. Ул бөтен уй-хисләре белән ерак-еракларда калган еллар кочагында йөзә сыман иде. Ә юк, бабай бүгенге дөньяны да бөтенләй үк онытмаган икән, менә сәер генә кеткелдәп алды:

— Ундүртенче каттан, димсең... кулларына бинокльләр тотып, димсең... Сагындырыр шул туган басу-кырларың!.. Хәлләр диген! — Аннары, өненә килеп, терсәге белән оныгының янтыгына төртеп куйды.— Әйдә, кызула атыңны! Тик торганны бер генә дә җаратмый ул замана!..

21

Кем генә, кайсы гына авылда малай-шалай чагында, хәтта яшүсмер булып исәпләнгән мәлләрендә, бакча басып йөрмәде икән? Көндезләрен дә, төннәрен дә? Урланган яшелчәнең тәме үзенчә булган, күрәмсең... Ә кызыгы, романтикасы? Ул каравылчыны алдаулар, аның сине куулары, качу-посулар! Өйдәгеләр ишетеп, белеп алса, колакны каерып борулары яки, ай-яй, ай-яй, ыштаныңны салдырып, кычыткан белән чәпәләүләре... Билләһи, кайчагында сагынып искә төшермәле!

Ә хәзер? Әҗердә? Бу җәһәттән рәт бетте малай-шалайга. Дөрес, баштарак, совхозларында яшелчәлек алай бик җәелеп өлгермәгән чакларда, кергәләрләр, баскаларлар иде, көндезләрен дә, төннәрен дә... Каравылчысы да бар иде, җиренә җиткерергә тырышып, акырып-бакырып, куарга тотынып иде... Инде хәзер яшелчәлек хәтсез җирләрне биләп алгач? Плантацияләрен аркылыдан-буйга рәхәтләнеп гизә бир, сүз әйтүче булмас. Шартлаганчы ашадың ни дә, ашамадың ни, кесәләреңә яисә күлмәк асларыңа корсагыңны кабартып тутырдың ни дә тутырмадың ни — кая анда өстеңә таяк тотып яман сүгенеп килүләр яисә тоз белән мылтыктан атып, йомшак төшләрне әчеттерүләр, йодрык йомарлап янаганына тикле сирәк булгалый. Шулай икән шул: авылыңда яшелчә аз булганда гына рәхәтнең дә рәхәте, тәмленең дә тәмлесе икән лә! Инде менә кызыгы бетте, романтикасы югалды...

Ләкин рус әйтә: «Изге урын буш тормас»,— ди. Малай-шалай тормышында да шулай күрәмсең...

Хәзер алар кызыкның, ямьнең бүтән төрлесен тапты. Шилнә инешендә бөялгән бер буадан икенчесенә чабалар, су коена-коена күгелҗемләнеп бетәләр, буаларга куелган насос тирәләрендә тыкшынып, машинист-операторларны йөдәтеп бетерәләр. Шулай да иң әкәмәте, әлбәттә, басу кукрәкләрендә! Шул ук яшелчәлектә үсентеләрне утырту, рәт араларын эшкәртү яисә өлгергән яшелчәне җыеп алу өчен машина-механизмнарның ниндиләре генә зыр-зыр эш кыйратып йөрми! Ә культуралы болынлыкларда печән чапкан мәлләрдә туган хәйран-тамашалар! Әмма хикмәтнең дә хикмәте, әлбәттә, ясалма яңгыр яудыруларда иде. Монда инде дөньяңны да, көнеңне дә берочтан онытасың!

Ә өлкәннәр тормышында, аларның гадәт-холкында?

Басуда эштән бушагач, күчтәнәчкә-фәләнгә дип, кем генә чиләк яисә букча төпләрендә өенә яшелчә алып кайтмыйча түзәр, ди? Сеңерләргә сеңгән гадәт. Һәм андыйны эш кешесе урлауга, языклы нәрсәгә санамый. «Үз хәләл көчемне салган, үз тиремне түккән җимеш ләсә... азрактан колхоз яисә совхозга ни зыян?» — ди. Шулаен шулай да... менә бер заман болар совхозында яшелчәлектә аерым-аерым звеноларга укмашып эшләүчеләр колак артын кашырга тотына, колак артын кашып кына да калмый, бер-берсенә күз сала, сүз ката башлый: «Син алып кайт, мин алып кайтыйм, бүтәне тагы... Яшелчәбез хәттиннәрдән ашып уңган, иге-чиге

җук дисәк тә... нишләп чутсыз-исәпсез булсын! Килолардан центнерлар, центерлардан тонналар җыела ич»,— ди. Бар хикмәт шунда: соңыннан көзнең тымызык бер көнендә һәркемгә дә җәен җәй буена тир түгеп алган бакча җимешләренең исәп-хисабыннан чыгарылып өлешенә күрә — акчасы да, бүләге-хөрмәте дә! Иң югары уңышка ирешә аласың икән, бигрәк тә хуп! Андыйлар, әлбәттә, түбәсе белән күктә, күкрәге белән диңгездә йөзә! Шулай булгач, һәммәкиенә дә күз-колак булмыйча, ис-өн җуеп йөрерсеңмени яшелчәлектә?

Көндезләрен, ярый, күз-колак була алалар, көндезләрен тәмле, сусыл яшелчәгә күз кыздырганнар күрәләтә басып керергә алай бик кыюлык та итми. Ә кичләрен, күз бәйләнгәч, бигрәк тә дөм караңгы төннәрдә? Йөзәрләгән гектар җирләрне каравылларга нинди адәм алынсын, ди? Табылмый андый кеше!

Ә тегеләр килә. Төн караңгысында ауга чыккан җумба балыклары сыман, посып-шыпыртынлап килә. Җәяүлеседер, велосипедка атланганыдыр. Мотоциклда яисә мотороллерда булсалар, фаралары кабындырылмый... Чаллы төбәгендәге меңәрләгән халыкның йөздән бере, хәтта меңнән бере генә килсә дә, көн саенга китсә азмыни? Беришләре, мөгаен, үзләренчә кызык табыптыр, икенчеләре, әлбәттә, котырган нәфсен тыя алмыйча, ач күзләнеп, ертлачланып... Арыш капчыклары кыстырып!

Куйган җәтмәләренә, әзерләгән тозакларына эләкмичә калмыйлар. Ләкин җәтмәгә бер-ике җумба балыгы эләгүдән генә, бүтәннәре төн караңгысында ауга чыгудан тукталып торыр димени?

Әлбәттә, совхоз дирекциясе колак артын кашу белән генә чикләнми: һич югы авыл кырыйлата һәм асфальт юл буйлата койма тотар өчен тимер челтәргә заявканы әллә кайчан ук биреп куйган инде. Әмма кайчан кайта әле ул?

Бүген исә дежур торырга график корыла. Каравылга совхоз активистлары һәм дружиначылар тартыла. Шулай инде: көндез эшлә, төнлә көндез эшләгәнеңне сакла! Корган ауларына, әзерләгән тозакларына балыкның эресе дә эләгә, вагы да каба. Хәер, котылганы да хәтсез...

Ләкин төнге дежурга кызык эзләп түгел, ачуташ йотып чыгалар!..

Бу киеренкелек, билгеле, Бариевлар гаиләсенә дә орынмый калмады. Рабочком Хәнәфи күрше Илбакты авылыннан, төнге дежурга чыкканда харап та шәп булышчы булыр бу дип, бер карт кына эт алып кайтты.

Сарбайның инде өздереп кабардай тешләре дә калмаган, юньләп өрә дә алмый, әмма йолкышлыгы — хәтәр! Совхоз эшчесе исәпләнмәсә дә, төпчек уллары Рәмзи дә бүтәннәрдән калышырга теләми: төнге ауга ул да, коңгырт күзләрендә очкыннар кабындырып, чыгып киткәли.

— Төн караңгысында җумба аулап йөрүләре үзе бер тамаша! — ди.

— Таптың тамаша, тфү! — дип зәһәр төкселәнеп куя моңа әтисе Хәнәфи.— Җыен ыбыр-чыбыр, җыен ертлач диген!.. Их, адәмнәрнең нәфсе корысын, ертлачлыгы корысын! Басуда, әнәтерә, чүп үләннәре баса башласа, тирәнрәк сөрәсең, тырмалыйсың-нитәсең, инде тәмамлай котырып китсә, чүбенә карап гербицид сиптерәсең... Ә монда? Их, кеше җанындагы чүп-чарларны да берәр гербицид сиптереп кенә корытып булса ла икән!

Хәнәфи Бариев игенче-механизатор башы белән шулай ди. Хатыны Рәсүлә дә асылы-тамыры һәм яшәеше белән таза игенче токымыннан, әмма ул, үз тәҗрибәсеннән чыгып, ире әйткәнгә төзәтмә кертергә кирәк таба:

— Адәм дигәннең ниндиен генә чирләре җук, күбесенә дәвасын да табалар, сихәтләндерәләр. Ә күңел, җан дигәненә? Анысын да шулай ук таблетка-мазар җоттырып җәисә уколлар кадаттырып кына тазарындыра белсәләр лә! Җук инде, җук, булмастай нәрсәләр белән баш әйләндерәбез, карт кынаем. Әнә бит заманасында әле Тукай бабай ук әйтеп калдырган бит: «Тәнгә мунча, җанга җук», дип... Электә дә шулай булган, бүген дә шулай...

Әҗер авылының тыкрык чатындагы өендә тын кичләрне адәмнәрнең җанын сафландыру һәм пакьләндерү хакында баш сөремләндереп утыргалыйлар инде шулай. Уфтана-сыкрана җир йөзенә яктылык, җылылык һәм матурлыкның күбрәк иңүен теләүләре.

22

Башта гаҗәп ямьле, гаҗәп күңелле булган иде: ниһаять, Вәсим өр-яңа «Жигули» алып җибәргән, автомобиле куе-кызарып пешкән чия төсләрендә, елык та ялык... Егетнең авызы ерылудан бушый алмый, бер кулы белән күпереп торган чәч пумаласын тузгыткаласа, икенчесе белән елтыр-ялтыр иткән автомобилен сыйпаштыргалый иде...

Шул көнне үк өр-яңа җиңел машинаның руль артына утырып, туган авыллары Әҗер урамнарын Рәмзи әйләнеп кайтты, аның соңында әтисе... Үтереп мактадылар.

— Ак бәхеткә, зур куанычларга булсын инде,— диделәр.

Аннары кичке уңайда Вәсим, үз янәшәсенә әнисен утыртып, сәхра гизәргә алып чыгып китте. Асфальт юл белән Яңа поселокка барып чыктылар, аның тирәсендәге Калмаш һәм Әҗер урманнары буеннан уздылар, аннары, кире кайткан чакларында, бормалы-сырмалы юлларга кереп, культуралы болынлык белән яшелчәлек җирләрен әйләнеп үттеләр. Рәсүләнең моңа тикле шушылай йомшак утыргычта рәхәт тирбәлә-тирбәлә туган авылы басу-кырларын гизеп йөргәне юк иде әле, күңеле галәмәт хушланды.

Аның тагын шунысы да бар бит әле: төпчек улы Рәмзи белән аягоч күршесендә яшәп ятучы агроном кыз Зәйтүнәнең озакламый ярәшеп куюлары бик тә ихтимал, димәк, зур бәйрәм — түгәрәк туй көтелә. Дөрес, бу хакта ни уллары Айдаш белән Вәсим, ни кызлары Рәмилә берни дә белми әлегә. Ләкин туасы көн тумый калмас — озакламый бары да ачылыр һәм тиешенчә нурланыр, менә шулчакны инде кешегә ялынып тормаслар, туган авыллары урамнарын балкытып йөрмәгә елтыр-ялтыр иткән «Жигули» үзләрендә булыр...

Аннан соң, теләгенә ирешеп, машиналы булгач, Вәсим дә үзенә оя кору хакында, мөгаен, төплерәк уйлый башлар?

Әнә шулай нигез өендәгеләрне ямьгә һәм нурга күмелдереп китеп барды Вәсим үзенең Чаллы каласына.

Китеп баруы белән батып та калды. Менә инде атнаун көнләп кайтып кергәне юк. Ә бит җилләр генә уйнатып кайтып төшмәгә елтыр-ялтыр машинасы да гел үзенеке...

Тикмәгә түгел икән...

Ул арада шуыша кайтып, үтә күңелсез һәм ямьсез хәбәре ирешелде: Вәсим, элек яшәгән квартира шартларына риза булмыйча, «Жигули»ен күршедәге яшь кенә бер тол хатынның ишегалдысына кертеп куйган, ди. Элегрәк тә аның күршедәге бер яшь хатын белән әвештүеш килеп йөргәнлеген җиткергәннәр иде, әмма ул чагында, егет кешенең тегеләй-болай кыланулары, шаяртулары гынадыр, дип уйлаганнар, шул сәбәпле, бу хакта

сүз кузгатырга да ничектер уңайсызланып килгәннәр иде.

Ә бит чынлыкта Чуар кызы Фәүзия әнә кем аркасында егеттән йөз чөергән ләбаса! Васимнәре ни яшерергә тырышмасын, андый кырын эш беленмичә каламы соң? Их, вакытында араларына кысылып, ул яшь хатыннан биздерә белмәделәр егетне... Ә хәзер Васимнәре өр-яңа машинасын аның ихатасына кертеп урнаштыру гына түгел, үзе дә шунда күчеп оялап алган, ди... Ул яшь, чибәр хатын әнисе карчык белән генә үз йортында яшәп ята икән, инде берме, икеме тапкыр кияүгә чыгарга да өлгергән, тик моңа кадәр ул ирләреннән тәм таба алмаган, аларны куа-очырта торган, ди. Инде менә хәзер үзенең мәхәббәт күлендә колач салдыра-салдыра боларның Васимнәрен йөздерергә тотынган, ди, ах алла гынасы...

Бу ямьсез хәбәрнең ялган түгеллеген, чытырдап торган чын сүз икәнлеген тәмам кара көйгән кыяфәтләрдә Рәмилә дә кайтып раслап китте.

— Эшеңне уен ит! Кызлар — уен, семья кору — уен... бөтен дөнья — уен! Тик нәфсең туенсын да рәхәт булсын! Бар җүнсезлекләре симез калҗалардан намусын май басып киткәнгә күрә аның! — дип хәтәр дулап алды әтиләре Хәнәфи, бу алама хәбәрне ишетүгә. Аннары, зәһәр усал тавыш белән хатынына кадалды: — Чуарлар сихереннән котларың калмаган иде, ә бактың исә, әнә кем сихерләгән булып чыкты тәти малаеңны!

Ире төрттермәсә дә, мондый хәлләрдә Рәсүлә, билгеле, кигән күлмәгенә сыя алмыйча, зиһене ачылы-сөремле хисләрдән бөтенләй чуалып:

— Тфү, нәселебездә булмаганны! Саф, керсез күңеле, тап-таза җегет башы белән берәр җүнлерәк кыз-чәчләкәен тапмаска! Муеныңа уралдырып, газиз каннарыңны имдереп җатмага бетмәс дөнҗада өянәк җухалар! Барып пыран-заран туздырып кайтыем әле адәм мәсхәрәләрен! — дип, ачыну-өзгәләнүләрнең чигенә җитте.

Аннары, күңелендә купкан ачы буран кинәт тынабасыла язып, зиһене ачылып киткәндәй булды. «Тукта, сабыр, сабыр... Васим акылын бөтенләй җуйган, тәмам зәвыксызга әверелгән өметсез бәндәләрдән түгел ләсә. Саф кыз дигәч тә, аларның да әллә ниткәннәре бар ич. Ирдә булган булса соң... Азмыни җүнсез ирләргә җулыккан бәхетсез хатыннар бүгенгесе көнне? Күңеле-җаны ничектер бит. Бәлкем, бөтенләй бал-май чүлмәгедер ул җәшь, чибәр хатын... Җук-җук, дуамаллар кубып, ила-

һы-уптым туздырулар һич кенә дә җарамас. Иң әүвәл ипләбрәк, нечкәртебрәк хәлләрен белешеп кайту дөрес булыр. Тиктән җаман дип җамау салмыек...»

Ләкин Рәсүләгә, бар ачу-ярсуларын бер төенгә төйнәп яки, киресенчә, күңелен җебеткән һәм йомшарткан хәлдә, Чаллыга барып йөрергә язмаган булып чыкты.

Бер иртәне Хәнәфи совхоз конторасына барган җиреннән бөтенләй бөрешкән, яньчелгән кыяфәттә кайтып керде дә, башын ике куллап кыскан көенчә тупсага утырып, яман сыкрану аша:

— Тотканнар! — дип ухылдап җибәрде.

Рәсүләнең йөрәге шундук жу итеп куйды: авыл җирендә моңардан да яман сүз бармыни?!

— Кемне?

— Кемне булсын... Вәсимне инде... Үзебезнең нәгъләтне!

Бу хәбәр аяз көндә яшен суккандай яңгырады, һәм Рәсүлә баскан җирендә чайкалып китте, үз тавышын үзе дә ишетмәде кебек:

— Кайда? Кем белән, ни белән?

— Кайда, кайда... төнлә, яшелчәлектә... яртышар капчык кыяр, суган, помидор, ди... Теге албасты чибәрен утыртып, «Жигули»енда килгән булган...

Авыр-авыр уфтанып куйгалагач, Хәнәфи сыкрануын теш аралый сыгып кына ары аңлатып китте: боларның өстенә узган төнне дежурга чыккан ике дружиначы, ике шофер — Гегель белән Мирсәет баскан. Әлбәттә, машинасы-нисе белән алып калмакчы булганнар, ызгыш-тартыш купкан. Вәсимнәре: «Без бит юри генә, шаяртып кына... сезнең уяулыкны сынар өчен генә!» — дип акланып азапланган. Менә шул чагында, Вәсимнең бәхетенә, өлкән дежурчы Гәрдәле управляющие Хәкимҗан килеп чыккан. Таныган, белгеле, һәм машинасына тимәскә, дигән. Ә Вәсим исә бу хәлләрдә чамасын онытып, капчыкларын да алып шыларга итенгән. Анда инде ни сабыр, ни ипле Хәкимҗан шартларга җитеп: «Убырланма! Исән чагыңда ычкын җәтрәк!» — дип җикергән.

— Капчыкларындагы нәмәрсәләре нибары биш тәңкәлек бит, алай булса әле... Көнлек хезмәт хакының өчтән бере!.. Тфү, череп баеган башы белән шуңа хиресләнмәсә соң! Хурлыгы ни!

— Шул иблис өшкергән нәмәрсәсе котыртып кынадыр! Парлашып килгәннәр, димсең бит... Нибары шул гына иләсләндергәндер! — диде Рәсүлә, аңгы-миңге хәлендә ничектер аклану җаен эзләүдән генә.

— Үз акылы, үз намусы кайда? Чүп үләннәре ничек тамырлана, нидән котыра, дибез... Ә монда үз канатыбыз астында... Үзебездән төшкән орлык лабаса, нинди туфракка эләгеп, нинди тиресләр белән ашланып шундыйга әверелде соң ул? Сугышта чагымда, алама җанлылар кайда туа, каян килә, дип аптырар идем, ә бактың исә...

— Җә инде, җә, алай бик тирәнгә җибәрмиенчә генә... Ул Гегель белән Мирсәет дигәнең совхозга читтән килгән бәндәләр ич, бәлкем, җүнләп абайламый да калганнардыр әле. Ә Гәрдәле Хәкимҗаны... аны телен әйбәтләп тешли белүчеләрдән димсең түгелме соң? Бәлкем, исе-төтене чыкмыйча да калыр әле авылга...

— Чыкса, чыкмаса... Хикмәт андамыни? Бүтәннәрне тикшергәндә, һай, оста соң үзебез, таблеткалар йоттырып, уколлар кадаттырып, һич югы, эссе мунчада пиннек белән җәрләндереп адәмнәрне җан чиреннән тазартулар хакында баш ваткан булабыз... Ә монда, үзебезгә кагылса... Их!

Шулай инде, бүтәннәргә югарыдан торып акыл өйрәтүе җиңел, әмма үзең бәла-казага тарысаң, мурдага эләккән балык сыман, чыгар тишегеңне табалмый йөдисең.

Ана кешенең җаны әле һаман вакыйганы ничектер йомшарту, ыспайландыру җайларын эзли иде:

— Алган җәшелчәләре нибары җартышар капчык кына димсең бит. Ул тиклемгә генә... Касса басмаган, кеше таламаган ласа.

— Ул чагында, бәлкем, җиңелрәк тә булыр иде: угрыбандит дияр идек, бөтен авыл белән йөзенә төкерер идек. Ә монда? Астыртынлап, яшерен мәкер белән... Димәгән ки, җанына корт оялаган. Кайчан, ничек? Хыянәтнең олысы ни, кечесе ни... Туган туфрагына бит! Нәсел-токымны пычратулары, йөрәккә хәнҗәр тыгып болгатулары... Таш түбәсенә орып, сазга батырасы бәндә, их!

Ниһаять, Рәсүләнең дә сөремләнеп томаланган зиһене кисәк чатнап китте, күңеленең бер почмагы убылып төште сыман:

— Күр җүнсезне! Теге көнне җылык-җылык машинасында басу-кырларыбызны гизеп җөргәндә, бер күзе белән, мәлгун, матурлыкка соклангандай иттерсә, икенчесе белән урлашырга җуллар чамалаган икән лә! Җәнәшәсенә үз әнәсен утырткан шәйгә... Ах аллам, җаманлыкның да мондые...

Без капчыкта ятар, яман эшнең сасысы таралмый торыр димени! Җитмәсә, гөнаһ иясе — рабочкомның үз малае лабаса!

Кеше күзенә күренергә оялып, башын кая куярга белмичә, үз эшенә совхоз конторына барган чагында, чат башында Хәнәфигә Гарапша очрады. Юри сагалап, көтеп торган, диярсең. Хәл-әхвәл сорашу юк, ни юк, симез нягеп сыпыргалап, турыдан сукты:

— Асыл кош аягыннан эләгә димс әле, Хәнәфи? Малаең Вәсимне әйтәм.

Хәнәфи кинәт каушап-югалып калды, тамагы төбенә ачы төер кунды һәм, тотлыга китеп, үзе дә абайламастан аклана башлады:

— Уя бит юри шаяртып кына... дежурга чыкканнарның уяулыгын сынар өчен генә...

— Хе-хе, сынар өчен... Бер капкан, ә капмыйча калганнарыгыз күпмедер — кем санаган?

— Син үзеңне бел!

— Безнекенә тыкшынма син — безнеке ал да гөл булыр! Ә сез менә... астыртын имеп ятуларыгыз җитмәгән, инде күрәләтә таларга керешкәнсез икән совхозны! Әмма ләкин чуан бер тишелми калмый ул, хе-хе! — дип, каһкаһәләп көлеп калды Гарапша...

Менә ул иске Чаллы. Әүвәлге больница артындагы өрәңгеле-юкәле тар гына урам.

Август аеның караңгысы монда аерата тиз иңгән. Урам тып-тын, ул йокымсырый кебек.

Хәнәфи элгәредә улы Вәсим яшәгән йортка сугылып та тормады. Аны узып, ары атлады.

Менә бусыдыр... Чын: капкадан эчкә үтүенә — ишегалдында караңгыда да елык-ялык иткән таныш машина. Абзаңның үзеннән-үзе тешләре шыгырдады...

Өй ишекләрен әллә шакыды, әллә шакымады, каерып ачып, эчкә атлады. Яндагы мич аралыгыннан ыңгыраша-уфылдый бәләкәй генә бер кортка килеп чыкты. Теге юхасы өйдә юк, ахры. Ә Вәсим түрдә, ярым-яктыда кәнәфигә тез чәнчеп утырган да телевизорга төбәлгән. Бүлмәләре матур гына җиһазлы, зиннәтле пәрдәләр... Байгураларча кереп оялаган ла бу!

Ялт иттереп якты ут кабынды.

— Эти! Ничек болай?.. Әйдә, түрдән узып җибәр, димме...

Тураеп баскан Вәсим биш бармагын да чәч пумаласына батырды, йөзе кызарып кына түгел, бүртеп үк чыкты бугай.

Әтисе Хәнәфинең тавышы авыр дөмбертке белән субай суккандагы шикелле, кырыс һәм каты гөрселдәп яңгырады:

— Мондагы түрләр безнеке булмас! Сөйләшер сүзнең дә урыны бу түгел! Әйдәле, чыгабыз!

— Соң нәрсә инде син... бигрәк...

— Әйдә, дим!

Вәсим ак күлмәге өстеннән пиджак эләргә дә онытты. Чыктылар.

— Ач капкаңны! Утыр машинаңа... кабыз!

— Нишләп инде... соң монда гына...

— Ач дим, кабыз дим!

Егетнең буйсынмый чарасы калмады.

Муса Җәлил проспекты тоташтан якты утларга күмелгән. Әрле-бирле машиналар чабыша. Кичке сәрендә халык та кинәнеп урам йөрүдә. Һәркемнең үз гаме... Ә мондагылар? Әтисе каш-күз җимереп, карашын бер ноктага төбәгән, улы исә, ак күлмәге эчендә бөтенләй бөрешкән хәлдә, руленә сыланган...

Урамның аргы башындагы развилкадан әйләнә төшеп, беренче юл дип аталган олы магистраль белән элдерткәндә, ГАИ постын үткәч, әтисе кырыс төстә тамагын кыргалап алды:

— Туктат!.. Рульгә үзем утырам!

Урын алмаштырган чакларында, Вәсим машина алып бару җайларын өйрәтмәкче булып, төчеләнә башлаган гына иде, әтисе янә кырт кисте:

— Үзем белермен... Өйрәтмә, ичмасам!

Ары элдерттеләр. Рульгә ябышкан куллар йөнтәс, бармакларына мәңге юылмас булып майлар сеңгән...

ҚамАЗ корпуслары буйдан-буйларга якты утларда җемелди. Утлар артка таба йөгерешә. Менә инде РИЗ да артта калды. Тигез, туры асфальт юл тик фара яктысында гына тирбәлә...

Уңга каерылдылар. Менә инде Шилнә күпере дә артка таба шуышып калды...

Шуны узгач, машина туган авылы Әҗергә борылып керер дип көткән иде Вәсим: утырган җирендә авыр гына кымшангалап алды. Ләкин юк, «Жигули» борылмады, асфальт белән турыга — Яңа поселокка таба юл тотты. Егет янә бөрешеп калды. Ул әтисенә күтәрелеп карый да алмый иде. Буйсынган, бетешкән кыяфәт...

Ләкин машина Яңа поселокка да барып җитмәде. Шактый озынга сузылган сөзәк үр белән выжлатып менеп барган мәлендә кинәт сулга каерылып, юлдан төшеп

китте. Фаралар яктысында купшы каен посадкасы балкып алды. Монда инде басу юлы белән әллә ни ерак кермәделәр. Машина капыл тукталды, фаралары капыл сүнде.

— Чык!!

Яшелчә җирләренең басу түрендәге иң аргы очы иде бу. Уң тарафта исә хәтсез киңлекләргә культуралы болынлык җәелеп китә иде.

Каршыларында офык читләре тоташ утлар балкышына күмелгән — КамАЗ да, Яңа кала да бөтенләе белән ут диңгезендә йөзә кебек. Якындарак, сөзәк үр астында куе караңгыда сирәк утлары белән күз чепиләндереп һәм сулышын кысып, туган авыллары Әҗер тынып калган. Баш өсләрендә август аеның дөм караңгы гөмбәзендә бихисап йолдызлар җемелдәшә...

— Туган авылың басуы бу... Заманасында син аңарда кайнар тирләреңне түккән идең, хәләл көчләреңне... Ә хәзер? Яман да пычраттың син аны, хыянәт иттең... Нәсел-токымыңа кара тап төшердең... Атаң белән анаңның калҗасына үткен хәнҗәр тыгып болгатуларың... Сугышта без ике уйламас идек, андыйларны үз кулыбыз белән...— Бу минутта ата кешенең тавышы кисәк чатнап, сынып куйды, әмма ул авыр-авыр сулап, аны янә үз җегәренә кертә алды тагы.— Әнәтерә каршы ягың тоташтан ут диңгезе, тоташтан балкыш. Ә артыңда? Дөм караңгы урман ягы... Ни уйларсың, ни сайларсың, туган нигезеңә кайтып аңлатырсың.

Машина ишеге шап иттереп ябылды. Хәтта басу-кырлар сискәнеп куйгандай булды... Ләкин дөнья тып-тын иде. Әнә югарыда, дөм караңгы күк гөмбәзен кыеклата ярып, йолдыз атылды...

— Әт-тей-й!!

«Жигули» җавап кайтармады. Ыспай гына кузгалып борылды да, артындагы кызыл утларын челт-мелт йомгалап, килгән юлы белән кире китеп барды...

23

Сабир икенче көнне үк кайтып төште. Дөресе, аны Кузьмич картның исәпсез оныкларының берсе, Сабир шикелле үк нык буынлы, күбә чәчле яшүсмер егет Андрюша әрҗәле мотоциклда китереп куйды.

Көн уртасы иде. Сабирның әтисе белән әнисе, төшкелектә тәгам җыйгач, эшләренә чыгып китәргә әле өлгермәгән иде, ах иттеләр:

— Нишләп япа ялгызың гына? Бабаң кайда?

Сабир, авызын ерып, ак тешләрен генә елтыратты:

— Бабайның кәефләре ал да гөл аның, «сәфәр җөрү җан газизе» дип калды.

Әтисе Ризванның шундук кашы-күзе җимерелде:

— Нәрсә, Кузьмич кордые белән тагын «кәгеп», тагын мөгез чыгарырга тотындымы?

— И әти,— дип җавап кайтарды улы, йөзенә капыл гына төксе һәм үпкәчел чалым кертеп,— син бабай турында һич җүнлене уйлый белмисең... Нишләп «кәгеп»? Тамчы да йотмады. Кузьмич бабай ни кыстаса да... «Мин болай да әле исерекләр күк исәр» диде. Кузьмич бабай үзе генә очрашу хөрмәтенә аз-маз кыландырды шунда. Әмма ул да хәмерне бөтенләйгә ташларга ниятләп ята икән.

— Нишләп калды соң ул анда?

— Сәхра җене кагылган аңа! Миннән туры алашаны җигеп калды. Бер купкачтын урман кырыйларыннан гына китеп, Җугары Суыксу белән Мәләкәсләргә дә сугылып, Бикләннең үзеннән үк әйләнеп кайтыем әле, ичмаса, дип... Бүтән төшләрдә дөнҗа хәлләре ничекләйрәк икән, дип... Ә Бикләндә аның туганнан туган апасы бар икән. Бу җылларда сабантуйларга да кайтып җөрмәс булды, картаюларның арҗагында ниләр җимерттереп җата микән, хәлләрен белешим әле бер алмапайның, диде.

— Ие шул, ни җыллар күренгәне җук,— дип ияк какты Сабирның әнисе Тәзкия.— Әле һаман да текер-текер микән? Инде хәзер исән-сау булса, сиксәннәрне уздырып туксанны куа торгандыр инде ул әкәмәт карчык.

Әтисе әле һаман кушылып торган кашларын язып җибәрә алмыйча:

— Үз хәлен үзе белмичә, иреккә ычкынган тай кебек кыланмаса соң! Бик зарыккан булса, машинада гына илтеп куя белмәс идеммени? — дип сукранды.

Әтисе белән әнисе, йортның карт хуҗасы кыланмышларына хәйран булып баш селеккәләгән хәлдә, үз эшләренә, икесе ике тарафка китеп барды.

Аулакта калгач, Сабир өр-яңа дусты Андрюшаның бик әйбәтләп, гөрли-көйли тамагын туйдырды, аннары аны, зур рәхмәтләр әйтеп, озатып җибәрде. Моның соңында ялт-йолт кына өс киемен алыштырды да ятьрәк мастерской утарына Айдаш абыйсы янына чыгып чапты. Урак өсте, егет кешегә тәнгә ит-май кундырып ятар чакмыни?

Бабасы Туры карт исә...

Аны бер көн көттеләр, ике көн, өч көн көттеләр, тик киткәненең дүртенче көнендә генә иртәнге якта боларның капка төпләренә куе-яшел төстәге «Волга» килеп туктады.

Картның өлкән улы Ризван агроном да, оныгы — «нәсел ботагы» Сабир да, әлбәттә, күптән инде иген басуында иде, өйдә тегесен-бусын караштырып-җыештырып тик килене Тәзкия генә тоткарланып калган иде. Ул, кайсы икән тагы, дип, йорт капкасы төбенә чыгып басса, йөрәге жу итеп куйды: ике адәм — берсе егет, икенчесе йомры гына, яшь кенә хатын кеше — Туры картны ике як култыгыннан җитәкләп, яшел «Волга»дан болайга, капкага таба, алып килә иде.

Тәзкия, алар белән исәнләшергә дә онытып:

— Һай, алла гынам, ниләр булды сиңа, әткәй? — дип аларга таба атлады.

Туры картның эчкә батып торган күз төпләре күпкүгелҗем, болай да ак йөзен, ияк-яңакларын көмеш төкләр бөтенләй басып киткән — менә ул кулларын ычкындырырга итенде, ычкындырды, аннары баш түбәсендәге көрән эшләпәсенә үрелде, шул мәлдә, авыртудан бигрәк, уңайсызланудан ахры, бик тә ямьсез төстә чыраен чытты (әллә көлемсерәве шулай булды):

— Ни... Әллә нишләп киттем шул әле, килен... Үзегез исән-саулар гынамы соң? Җарар, син нитмә инде бик...

Аны иплән кенә ихатага алып керделәр, ләкин Туры карт шундук болдырдан менеп китәргә теләмәде, баскычка утырды. Утырды да кул аркасы белән маңгай җыерчыкларын сыпырып узды, елмаерга итте, әмма йөзе янә ямьсез чытылып кына куйды:

— Шул җөрәк тамырлары инде... Хәзер җарыйсылана төште кебек... Үз өемә дә кайткач... Уф, шөкерләр инде...

Яшь, йомры хатын Бикләннең фельдшеры икән, ул хәлне аңлатып та бирде: бабайның йөрәк чире һич уйламаганда, алар авылында әле өченче көнне үк яңа мәктәп ачу тантанасы вакытында, дөресе, тантана инде бетеп килгәндә, кузгалган икән. Аны шундук колхоз председателе йөргән «Волга»да медпунктка алып киткәннәр, анда инде, билгеле, беренче ярдәм...

— Тиз генә Чаллыдан «Ашыгыч ярдәм» дә чакырттык. Врач бик иплән карады. Бульниска үк алып китмәкче иде дә, менә бабай үзе аягы-кулы белән карышты шул.

— Карышмыенча... Анда, таш капчыкка кереп, әҗәл кочагына җатаргамы? Гомеремдә үзем белеп, үз чирем белән духтырларга багылып җөргәнем булмасын да, монда тик торганнан гына...

Хаклы сүз иде бу: теге заманда, әле яшь чагында, капчык киертеп, кансыз рәвештә кыйналып ташлангач та, аннары, инде герман җирендә, бомба шартлап яман контузиядән тетелгәч тә, озак вакытлар больница-госпитальләрдә, әҗәл белән якалашып ятулары, әлбәттә, үз чире аркасында түгел иде. Билгеле, ул чир-сырхау дигәнне бөтенләй белми яшәмәде, булгалады андый хәлләр, әмма моңа кадәр, кая анда Чаллы тикле Чаллыга барып йөрүләр, үз авыллары Әҗердә дә медпункт сукмагын таптауны уена да китерми гомер сөргән иде.

— Нишләп үзебезгә хәбәр итмәдегез соң? Көне-сәгате белән барып та җиткән булыр идек,— дип үпкә белдерде Тәзкия.

Фельдшер хатын, шома муеның йомры җилкәләре эченә батырып, кулы белән Туры картка ишарә ясады, ә тегесе, очлы ияген учлаган килеш, баш селеккәләде:

— И гөлием, нишләп инде сезне борчырга, ди?

Ниһаять, Туры картны өенә алып кереп, йомшак диванга утырттылар, килене Тәзкия диван почмагына ястык-мендәр өеп куйды, бабай шуңа гәүдәсен кырын салды.

Ул да түгел, Тәзкия алгы өйдә әле кайчан гына кагып, каплап куйган самоварын тергезергә кереште, әмма озата килүчеләр чәйләп утырырга теләмәде. Йомры фельдшер хатын:

— Инфаркт түгел микән дип котларыбыз калмаган иде. Стенокардия пристубы икән... йөрәк бумасы,— дип пышылдады, аннары Тәзкиягә авыруны ничегрәк карау хакында тегеләй дип, болай дип киңәш бирергә тотынды: — Медпунктыгыз алай ерак түгел икән, фельдшерыгыз да бик әйбәтләрдән, зинһар инде, врач кушкан уколларны оныттыра күрмәгез!

— Җарый-җарый... Игелегегез өчен үзегезгә бик рәхмәтләр инде! — диде Тәзкия, дымланган күзләре белән елмаеп.

Аларны озатып җибәргәч, Тәзкия каенатасының хәлен әледән-әле белешкәли торып, алгы өйдә табын өстәленә ризык-нигъмәтнең иң татлысын һәм үзенчә иң шифалысын әзерләргә тотынды: балдыр-майдыр, сөттер-каймактыр, вареньедыр-кактыр... Аның иртәнге савымнан соң сыерларны көтүлеккә тараткачы, җәйге лагерьга барып

житәсе бар иде, әмма бу хәлләрдә нишләсен, күрше кызына кереп һәм аңа тоткарлануының сәбәбен дә әйтеп, моны ферма мөдиренә җиткерүен үтенде.

Өйлә якынлашып килгәндә, басудан Ризван кайтып төште. Алгы өйдә хатыны белән пышан-пышан сөйләшеп алгач, Ризван түр өйгә үтте, диванда гәүдәсен кырын салып яткан әтисе белән ике куллап җылы гына күреште дә аның янына утырды. Утыргач, әтисенә күзләрен тутырып карап торды, шул чагында аның яңак тирәсе тартышкалап та алды, аннары бик тә авыр иттереп сулап куйды, әмма тавышына тамчы да катылык кертмәде:

— Тыңламадың шул сүземне, әти...

— Җарый инде, җарый, рәнҗемиенчә генә, улым! Аның каравы, сәфәрләрем бик тә матур булды — инде күңелем тәмам түгәрәк. Тик күргәннәрем генә бәгырь кисәгенә күбрәк өелде, ахры, тамырлары, дим, какшабрак китте. Ә туры алашаны миннән җигеп калдылар, китереп куярлар.

— Хикмәт туры алашадамыни соң? — Ризван янә күзләрен тутырып әтисенә карап алды.— Үзеңне сакалмыек та тәмам басып алган икән. Кая, хәлең булса, хәзер ялт иттерәм.

— Анлык кына нишләп булмасын, ди...

Бер-ике минуттан түр өйләрен электр кыргычның күңелле гөжләве тутырды.

Кичен Туры карт янына туган-тумачасының иң якыннары, иң газизләре җыелды. Бабайның инде хәле «ходага шөкер» диярлек иде, ул тегесе-бусы турында гәп кузгалганда, үз авызыннан шук-шаян чаткылар да очырткаларга тырыша иде: янәсе, хәлебез хәл булса да, алай бирешергә бик ниятләп ятмыйбыз әле... Ниһаять, диван почмагындагы ястык-мендәрләрне йомшак куллы килене Тәзкиядән төзәттереп-кабарттырып алгач, ул, көчәнү аша булса да, көр тавыш чыгарырга тырышып, «әҗәл-мәлгуннең кай мәлне ничекләй җакага җабышуын» сөйләргә тотынды:

— Шул мәктәп ачу бәйрәмендә инде... Ә мәктәпләре хәйран! Искесе белән җәнәшәдә генә, почмакка почмак орынып утыра диярлек. Аның искесе дә ике катлы, болай олы гына, әмма бүрәнәләре каралып, таушалып беткән инде... чырае да шул сәбәпле караңгы. Җаңасы исә җалт та җолт! Ә бәйрәмне шунда ук чияле-алмагачлы бакчада корып җиб-бәрделәр. Түрдәге кызыл постаулы өстәл артына, әлбиттә, зур дәрәҗәле кешеләр кереп урнашты. И тотындылар сөйләргә!.. Аның соңында кәнсирт ишесе.

Җырдыр-шигырьдер, музыкадыр-биюдер. Баянчылары да әллә ничәү...

— Безнең үзебездә дә җаңа мәктәпне ачып җибәргәндә хәйран тамаша кыланганнар ие! — диң сүз кыстырды килене Тәзкия.

— Үзебезнең Әҗердә, дисеңме? Белмәем, үзем күрә алмадым, жәл, кайдадыр читтә калдым ул чакны... Комиссияләренең койрыгына тагылып, үз күзләрем белән карап җөрдем, иренмәдем, ике катын да әйләндем, һич арттырмыйм: барчасы энәдән-җептән чыккан, җалтыр да җылтыр. Ул уку бүлмәләре, ул олы заллары! Ашханәләрендәге җиһазларына тиклем көмештән коелгандай! Ә мастерской дигәннәре? Агач эшкәртмәгә җәки анда тимер кырмага станок-верстакларына, төрледән-төрле коралларына тиклем инде әзер, рәхим генә ит... Хи-химе, улым Сабир? Әмма ләкин кызыкның да иң кызыгын азакка табарак калдырганнар икән: менә бер заман бакча уртасына әйләнә-бөтерелә нәниләр өере килеп керде. Тап җитез күбәләкләр инде! Бикләннең балалар бакчасыннан икән, бу җылны өр-җаңа мәктәп ишекләрен ачып керергә тиешле гөлиләр икән! И такмаклыйлар, мин сиңа әйтим, и биләр, и бөтереләләр, баян өздерә, болар өздерә — ару җук, талу җук, дөнҗа бөтенләе белән аларныкы!.. Шул чакны... шул чакны... күкрәгемә куаныч күбрәк керде, ахры... Җарый әле, җанымда алмапай утыра ие, җарый әле председательләре.., кем, үзебезнең Җамалый малае вакытында абайлап алган, бәхеткә аның «Вулга»сы да әллә ни җыракта түгел икән...

Өйдәгеләр, авыру тирәсенә җыелышып алганнар, азы сөйләшә, күбрәге бер-берсенә күз төшергәләп, тирән-тирән сулап куйгалый, сөйләшкән тәкъдирдә дә пышын-пышын гына сүз алышкалый иде.

— Дөнҗада хикмәтле үзгәрешләр әллә ни хәтле шул инде, ул Суыксуда дисеңме, җәки Мәләкәстәме...

Туры карт бу минутта ачык күзләре белән түшәмгә карап ята иде, менә ул күкрәгенә салган сөякчел кулларын кузгаткалап алды да бик киң иттереп сулап җибәрде:

— Ием, гаҗәеп бүгенге дөнҗалар! Хайраннар инде! — Аз гына тын алып торгач, аның авыз тирәсе кинәт кыйшаеп китте.— Ә теге җырак заманда, миңа капчык киертеп, кансызланып, селеккән мәлләрендә, җөрәгем белән абайлап калган ием: арадан берәвесе тап Җамалый-әзмәвир ие... Мөртәт!.. Әмма ләкин аңардан туган бала... малае...

Өйдә утырганнар бер-берсенә капыл гына күз төшергәләп алды: алар өчен зур яңалык иде бу, Туры бабайның моңа кадәр шушындый сүзне һичкайчан да ычкындырганы юк иде әле...

— Ием, малае бөтенләй бүтән... Абруйлыдыр үзе... аннан да бигрәк инсафлыдыр, итагатьледер кыланмышлары... Үземә миһырбанлык кылганы өчен дә, бикләннәрне әнә шулай матур дәрәҗәгә җиткергәннәре өчен мәңге бәхил мин аңа... мәңге!

24

Туры картның хәлен белешергә баргач, Хәнәфи үзен бик авыр хәлдә тоеп утырды. Аның күңеле һич тә тыныч түгел иде. Уллары Вәсим тудырган каза өстенә бу тирән хафа... Дөрес, хатыны Рәсүлә белән ул Вәсим вакыйгасын Туры картка сиздермәү чарасын алдан ук кайгыртып куйган иде. Болай да сырхау кешене нигә инде тагы авыр борчуга салырга, ди?

Гәп корып утырганда, азактанрак, Туры картның куанып, әмма тирән уфтану аша әйткән сүзләре исә Хәнәфине бөтенләй әллә нишләтеп җибәрде.

Җамалый-әзмәвир... Каракайның уң кулы... Җамалыйдан туган малай — Чаллы төбәгендә аталмыш председательләрдән...

Егерменче елларда бу тирәләрне дер селкетеп торган, соңрак авылдашлары күңеленә уелмаслык булып кергән батыр йөрәкле, үткен һәм хәйләкәр акыллы, әмма чамасыз ертлач холыклы адәм турында Хәнәфинең күп мәртәбәләр ишеткәне бар иде. Әллә кемнәрдән әллә нинди хәлләрдә... Аның турында сөйләүләр дә алар авылында бер тыныбрак тора, бер көчәеп китә иде. Нидән бу? Тынычлыкларын җуеп, болганыбрак торган чакларга туры киләме? Әнә Яхъя Таипыч та, директорлыгыннан киткәч, Каракайны, дөресе, «каракайлык»ны телгә алып, сөйләгән иде бит. Ул да аны бүгенге көнгә, атап әйткәндә, управляющий Гарапша кыланмышларына бәйләбрәк каһәрләгән иде. Каракай... каракайлык...

Инде хәзер Хәнәфи үз улы Вәсим кылган гөнаһ турында уйлап, күңеленнән аның асыл сәбәпләрен ачыкларга керешсә, күптән шаулап узган бик тә аянычлы һәм гыйбрәтле хәлләргә ирекле-ирексездән керә дә китә, аларны аңларга тырышып, һәммәсен нечкәли, һәммәсен күз алдына китерергә тырыша иде. Ә нечкәләү өчен аңа бик очраклы төстә, әмма бик уңай бер җай да туган

иде: ул Каракайга бәйле вакыйгаларны бер дә әллә кемнән түгел, үз бабасы Туры карт авызыннан кабат ишеткән иде.

Бу хәл карт казалы сәяхәтенә чыгып киткәнче, әле бик күптән түгел культуралы болынлыкта сугаручылар янында булды...

Су сиптерүчеләр, һәйбәтләп тамак туйдырганнан соң кайсы гәүдәсен кырын салган шәйгә, кайсы аяк бөкләп утырган көенчә, йомшак үләнгә урнашып алган иде инде. Берәүләрнең йөзендә иронияле көлемсерәү, икенчеләренең зур кызыксыну чалымнары... Хәнәфи, бу ни хикмәт икән бу дип, каш җыерса, сүз Каракай турында купкан икән. Кайсы һәм ни сәбәптән кузгаткандыр...

Хәнәфи үзе дә йомшак үләнгә аяк бөкләп утырмыйча булдыра алмады.

Болынлыкта бабайның ике оныгы — Рәмзи белән Сабир — һәм һәрчак уйчан, җитди карашлы Мөбәрәй генә түгел, бүтәннәр, читтән килгән адәмнәр дә бар иде.

Туры карт үзе дә үләнгә җәйрәп утырган җирендә, сыңар аягын тарта төшеп, тез калкытты һәм нигәдер уфтанып куйды. Әле анда да авызыннан сүз чыкмады, тик салам эшләпәсен баш түбәсеннән маңгай өстендәге тирән буразналарга таба шудырып төшергәч кенә, иреннәрен хәрәкәткә китерде:

— Авылның иң кырыенда ие Каракайның өе. Мунча хәтле генә. Җарлының да җарлысы! Нәселләре белән җалчылар ие...

Бабай янә тынып калды. Чал кашларын уйчанланып җыерган хәлдә, карашы белән Илбакты һәм Калмаш тарафларындагы басу түрләрен иңләп алды, гүя ул сөйлисе хикәятен үзенең хәтер әрҗәсеннән түгел, бәлки нәкъ менә ерактагы зәңгәр рәшәле офык артларыннан эзләп алырга җыена иде. Тагын бик тә тирән иттереп сулап куйды, аннары инде бу фани дөньядан күптән китеп барган берәүнең авыр һәм гыйбрәтле язмышын кабаттан үрергә керешә...

Теге дәһшәтле елны Әҗер белән Гәрдәледә фетнә кубып, аларны «абжур команда»сы басып алгач, Каракайның атасын да, бер аягы белән гүргә кергән бабасын да җәлләп тормаганнар: һәйбәтләп тунаганнар аркаларын камчы белән... Яман рәнҗү, үч-ярсу дигәнең, шулай иттереп, Каракайга сабый чагыннан ук сеңеп калган. Үзе инде дә гаярь булып үскән. Дөнья таный башлавыннан ук Калмаш боярында, тагын бүтән авыл-

ларында ялчылыкта йөрсә, әллә кемең дә каешланыр шул!.. Каракай егет булып җиткәч кенә, герман сугышы башланып китә. Анда инде, билгеле, моны да читтә калдырмыйлар — бу да китә ут эченә... Бер заман моның хәбәре туган авылы Әҗергә кайтып ирешә, бөтен авыл белән авыз тутырып моны сөйләргә тотыналар: «Вәйт, диләр, Каракай тегендә ут эчендә дә сынатмый икән, хәтәр дә сугышып җөри икән, күкрәгенә патша хәзрәтләре тоттырган тәрене берне түгел, икене тагып куйган, ди, инде...» Берәүләрне аның гайрәте шаккатырса, икенчеләрне хәйран иткәне шул була: «Мөселман башы белән ул тәреләрне алладан курыкмыйнча ничеклэй асып җөри икән? Менә күрерсез, шул тәреләре аркасында бер дә бер заман җәһәннәмгә китәр әле!» — диләр... Ә ул, Каракай батыр, һаман да исән, һаман да гаярь икән. Менә бер вакыт Февраль, аның соңында Октябрь революциясе була — Каракай, билгеле инде, ул данлы-шанлы вакыйгаларның уртасында кайнаша. Ә туган авылы Әҗергә кайтып төшүе, авылдашлары белән күрешүе исә бик тә әкәмәт хәлләрдә була...

— Унсигезенче җыл бетеп, унтугызынчы җылның кышында булды ул хикмәт. Самый кырлач аенда, зыкы суыкларда. Миңа унсигез тулып киткән генә ие әле. Җарар, бервакыт Илбактыга чакырталар. Волуст шунда бит, Илбактыда... Ни икән дисәк, комиссар килгән икән. Кызыл Армиягә җазылу хакында, җәгъни мәсәлән, димләве. Байтак халык җыйналды. Өй шыплап тутыргандай. Төрле авылдан, төрле халык. Шунда мин сорау бирдем комиссарга, исәр. Җәнәсе, без дә төшеп калганнардан түгел, җәнәсе, замана шомартканнардан. Җугыйсә, үзем инде Минзәләдән каралып та кайткан ием, кулымда кәгазь дә бар, чакырткан көнпәрендә килеп җитәргә дип...

— Ә соравың ни иде соң? — дип төбәлде шул мәлне Мөбәрәй, Туры картның читкәрәк тайпылуын чамалап.

— Соравыммы? Беркем котыртмый-нитмичә, үз җенем котырганга гына, тоттым да сорадым комиссардан урысчасын, татарчасын бергә бутап: «Җарар, берәүләр җазылды, ди. Ә җазылмаганнарны нишләтәсез инде? Андыйлар да жук түгел кебек бит, тувариш комиссар?» — дип әйтеп... Шулай дип әйтүем белән дары мичкәсенә очкын төшердеммени! Комиссар авызын ачып җавап бирергә өлгермәде, и купты тавыш, и башланды мәхшәр! Урысы кычкыра, татары акыра: «Туйган инде сугыштан! Иген игеп, икмәк ашыйсыбыз килә, армия

никчаму безгә!» — дип... Җыен кулак аламасы да килгәнен каян беләсең? Комиссар кул изәп карады, кычкырып карады, җук, тынмыйлар, кайсыдыр дөбердәтеп тәрәзәне ватты, кайсыдыр эскәмия күтәреп ишеккә орды. Ахырда комиссар наганын чыгарып шарт та шорт түшәмгә атып җибәрде, ул да түгел, монда да кемдер ишек төбендә мылтык шартлатты... Теге, нишләсен, чыгып кошовкасына утырды да элдертте җәтрәк. Кайткач, әлбиттә, әйткән инде: «Фетнә куптардылар анда»,— дип... Ә безме? Таралыштык. Кайсылары әшәке сүгенеп, кайсылары, минем кебек, җөрәгендә ут җандырып, инде ни булыр икән, дип... Җарар, шушы хәлдән соң икеме-өчме көн үткәч, безнең Әҗергә әтрәт килеп төште. Фетнә бастырмага инде. Илбактыда ничек булгандыр, белмим. Ә безнең авылның бар чыгар җулларына сакчылар тезгәннәр. Игәч башында пулеметка тикле куелган, ди. Җарар, бервакыт чакырталар каравыл өенә. Бардым. Барсам, минем ишләр байтак җыелган. Ә килгән командирны кем дисәк... хәйран тамаша, бусында үзебезнең авылдаш Каракай лабаса! Кыяфәте хәтәр! Ак тун өсләтә аркылы-торкылы каешлар, билендә нагандыр, кылычтыр! Күкрәгендә кызыл тасма. Ә чем-кара мыегы менә болай! Тавышы гөбердәп чыга! «Фетнәне син куз-гатып җибәрдеңмени әле, контра?!» — ди миңа. Минем тез асларга тикле дерелди, авызымнан җүнләп сүз чыга алмый. Сорау гына биргәнием, дип аңлатырга тырышып карыйм, булмый гына бит! Ахырда теге чакырту кәгазен тоттырдым, Минзәләдә биргәнне. Мин үзем, дим, бүген дисәгез, бүген, иртәгә дисәгез, иртәгә Кызыл Армиягә китәргә әзермен, дим. Ышанмый бу. Азакта бүтән авылдашлар да минем җакны каергач, авызын җәеп, мыек чолгыйларын бөтергәләде: «Алайсам алай икән, бик шәп, ди. Җугыйсә, фетнә дип уйлаган иек, пүчтәк кенә икән!» — ди. Шулай да барыбызны да утлы күзләре белән бер айкап алгач, бик хәтәр иттереп бармак селеккәләде: «Үз авылым дип тормам, чамалагыз, туганнар, контра җагына авышсагыз!» — ди. Аннарымы? Бар кызыл гвардиннарын җыеп, берәүләрдә бик әйбәтләп кунак булдылар болар: үз авылына беренче кайтып төшүе бит. Шуннан соң, чаналарына төялешеп, төнгә каршы җырлый-гөрли кайтып киттеләр... Авылда тагын сүз купты: «Менә кем булган безнең Каракай, исләрең китмәле!» — дип. Әле ул гынамы: «Имештер, Казанны ак чехлардан алган чагында, разведка җасап, ике җегет кергән, ди, шуларның берсе үзебезнең Каракай булган

икән»,— дигәне дә таралды. Ә нигә? Ышанмаслык түгел... Аннан соң, озак та үтми, Каракай белән җәнә очраштым мин...

Тыңлаучылар арасында күзләрендә иң хәтәр очкыннарны уйнатучы, әлбәттә, Туры картның оныгы Сабир иде. Ул бүтәннәргә әледән-әле ялкынлы караш ташлап ала иде: «Әнә Каракай нинди булган да безнең бабай нинди!..» Ә бабасы тукталмыйча сипләвен белде:

— Көтеп җатам шулай, кайчан инде Кызыл Армиягә чакыртырлар икән, дип. Ул арада җазга табан хәлләр, һай, хөртиләнеп китте — хәбәр таралды: «Урал таулары тарафыннан Колчак җавы сәвитне җалмап килә, ди, дәһшәтнең дә дәһшәте», ди. Март азагында ләҗбердек бер көнне чакырталар мине. Җук, Минзәләгә түгел, Чаллыга... Бардым. Эзләп таптым револүсионный штабларын. Тапсам, очраткан кешем тагын үзебезнең Каракай! Шул ук кыяфәт: кылыч та револьверт, кызыл тасма да хәтәр мыек. Тик бусында өстендә күн тужурка. «Вәт, маладис, авылдаш, ди, җегет икәнсең, ди. Әйдәле, керик әле, комиссар җанына!» — ди. Кердек. Кергәч, аңлаталар икәүләшеп: «Син, энекәш, бүгеннән башлап үзеңне Кызыл Армиядә исәплә! Әмма ләкин кулыңа мылтык тоттырмабыз, анысы Колчак җавын каршыларга монда кирәгер, диләр. Сиңа баевуй бурыч шул, диләр: монда Әстәхи бай элеваторында ике миллион потлап ашлык бар, тегендә Мәскәү пырлитариаты ачка интегә, шул ашлыкның бөртеген дә Колчакка калдырырга җарамый, аңлыйсыңмы?» — диләр. Аңламыйча, дим. «Алайса, бик шәп! Менә хәзер шул ашлыкны Кама бозы кузгалганчы Вәтски Пүлән стансасына ташып бетерергә кирәк. Авылларда атлы олаулар мобилизацияләнә, син, энекәш, үз авылыңда оешкан иң беренче олауга ук баш булып китәрсең»,— диләр. Ни әйтим? Җарар, дим, тик мылтык бирмәвегез генә җәл, дим. Шулай дигәч, Каракай үз күкрәгендәге кызыл тасманы алып, минем бишмәткә беркетеп куймасынмы! Үз кулы белән... Танауны шактый текә тоткан шәйгә кайтып киттем авылга, күкрәгемдә кызыл тасманы балкытып, чабатам белән карлы суны лычтырдатып...

— Әстәхи бай элеваторында ашлык ике миллион пот ук булды микәнни? — дип күзләрен тасрайтты читтән килгән егетләрнең берсе.— Хәер, булыр да: ул бит безнең Чистай тирәсендә дә җыйдырган икмәкне. Хакын бүтәннәргә карый кыйбатрак түләп булса да...

Туры бабай тамагын кыргалап алды һәм, үз сукмагыннан тайпылырга теләмичә, төп фикерне элеп, күтәреп киткәндәй, сүзен дәвам иттерде:

— Ә безнең Чаллыда аның истәлеге хәйран: бөтен Кама буйларында бер дигән элеватор! Җыйган икмәге дә сәвиткә бик җарап куйды, кәнкрит әйтсәк, Мәскәү пырлитариатына... Мин, шулай иттереп, җәгъни мәсәлән, мыек та чыкмаган көйгә, үзебезнең авылда тупланган олауга баш булып киттем инде. Мылтыксыз-нисез генә... Җазның сазламыгы, җөкләр саллы, атлар ухылдый, үзебез уфылдыйбыз... Дистәләгән, җөзәрләгән олау! Соңгы олау үтүгә Вәтке белән Кама бозы да кузгалган, диделәр. Алтындай кадерле икмәкнең бөртеге дә калмады дошманга... Үзем мин Вәтски Пүләндә Азин гаскәренә кушылмакчы ием дә, алмадылар. Малмыж каласына җибәрделәр. Мылтыкны, ахыр килеп, шунда тоттырдылар миңа...

Туры карт, башын чак кына бора төшеп, күз карашын кояш баешы ягына төбәде: «Малмыж» дигәне, мөгаен, шул тарафлардадыр...

— Гражданнар сугышында утлар-сулар кичеп, дошман җавын туздырып җөргән мәлләрдә нишләптер күңелемдә гел Каракай булды. «Их, туган авылга Каракай батырга тиң булып кайтсаң икән!» — дип хыялланган чакларым аз булмады. Ә бактың исә... Их, дөнҗа куләсә дибез дә бит, кайчагында ул тискәрегә таба да әйләнеп киткәли икән шул, кадалгыры!

— Нишләп алай дисең әле, бабай? — дип, үтә дә сәерсенеп, сорады Чистай егете.

Бабай җавап бирергә ашыкмады. Аның чал кашлары астындагы коңгырт күзләрен дым элпәсе каплаган иде.

— Бер заман, колхоз төзеләсен ишеткәч, семьям белән авылга кайтып төштем. Ул вакытта Ризван улым белән Рәсүлә кызым бар ие инде. Чит-җат җирләрдә җөргәндә, туган туфрак үлеп сагындыра шул. Аннан килеп, тормышның җаңасы корыла, диләр — бусы да әкәмәт кызыктырды... Җарар, җырак Себердән кайтып төштек тә алай-болай урнаштык. Хикмәт анда түгел, хикмәт шунда: Каракай да авылда бит! Әмма ләкин исләрең китәрдәй хәл: бөтенләй беткән бу, тәмамлай түбән тәгәрәгән. Ничекме? Үзебезнең Әҗердә бертөсле шайка оештырган, хәтта, әйтер ием, банда! Җыен башкисәр ир-җегетләрдән. Әүвәлтендә дә безнең авыл усаллыгы белән дан тотар ие, инде хәзер бөтенләй җаман атын

сатканнар. Каракай бер-ике ахирие белән күпмедер вакыт читтә жөреп кайткан икән, шунда бозылган, ахрысы. Ни сиңа җүнләп иген игү җук, булган хәтле җирен алабута-әрем басып киткән, ни бүтәне җук. Бар булган кәсепләре: кеше талау, кибет басу. Болай Әҗер кешесенә, якынрак авылларда җәшәүчеләргә зыян итмиләр үзе. Әллә кайларга китеп җөриләр икән. Астыртын гына... Ул Әлмәт белән Зәй тирәләре дә калмаган, Кама арҗагына чыгып, Алабуга белән Бондюгларны да капшаштыргалаганнар. Үзләре бар тапкан малларын типтереп олактыралар. Бермәлне болар таңнар атканчы, әйтер ием, хәтта мулла өендә дә ду китереп җатканнар. Болай да коты алынган хәзрәтне үләр чикләргә җиткезеп: «Дөнҗа — безгә, ахирәт — сезгә, мулла абзый!..» — диләр икән. Җитмәсә, авыл Советы да җомшак. Тәмамлай постырганнар авылны... Нидән бу? Җарар, әүвәле безнең ата-бабалар кайчагында шулай җөргәннәр инде, җыен байларны, түрәләрне талап. Заманасы кушкан, золым-нужасы кушкан. Ием, дөнҗа чигеннән чыккан-га... Ә бит хәзер хөррият, бары да син крестиан өчен! Җиңеңне сызган да көчеңне җәлләмә! Әллә, дим, ата-бабаларның җулбасарлык каны күчкәнме? Шул аздырамы бәндәне? Алай дисәң, кайсыбызда җук ул кан безнең авылда. Ни уйласаң да, башлар җитми... Җарар, НЭП заманында бериш җаңарган байларның кызган майларын сыгып җөргәнлегенә әллә ни аптырамас та иең, ә бит болар, бер азгынлыкка чумгач, кооператив кибетләрен дә читләтеп үтмиләр, кайсыдыр бер авылда почтаны басып чыкканнар. Төрле складларның чуты да җуктыр... Ә без монда җыен җарлы-җабага әртил кормага җөрибез, «Искене тамырыннан җолкып атабыз!» — дибез. Атарсың бик! Милиция дә нишләптер әллә ни җимертә алмый... Шулай җәшәп җатканда, җегермебишмеңле Гайнуллин дигән берәү килеп төште. Әртилгә җан кертеп, җәшьнәтеп җибәртү өчен инде. Болай сабыр холыклы, таза акыллы адәмнәрдән. Авыл Советы нығып киткәндәй булды, үзебез дә җиңел сулап куйдык. Инде Каракай өере белән нишләргә? Иң әүвәл өшкереп карарга булдык, аннан соң инде ныгытып койрыгына басарга ният. Ә Каракай күзен дә җоммый: «Сәвит ул минем үземнеке, мин газиз канымны койдым аның хакына, ди. Колхоз да тап минем өчен генә — бик шәп накунис!» — дип кенә җиб-бәрә... Әмма озак тормый каптылар болар. Ничекме? Күрше Буравай авылының чиркәвен басканнар бер төнне. Ниенә кызыкканнардыр

инде? Хәмер сөреме белән миңгерәүләнгән башларына җиз суы җөгертелгән нәмәрсәләр алтын булып тоелды микәнни? Үзебезнең зират чокырына китереп җәшергәннәр, җүнләп күмә дә белмәгәннәр мескенкәйләр. Шул уңайдан: «Урыс алласының кулы катырак икән: маладис, тиз эләктерде җакаларыннан!» — дип, мәзәгрәк иттереп сөйләүчеләр дә булды авылда... Менә шул көннәрдә селектеләр дә инде мине Шилнә буенда, төнлә өстемә капчык киертеп... Әмма ләкин дапрус алганда да, хөкем иткәндә дә, Каракай, бар гөнаһларын сөйләп бирсә дә, бусыннан җөз чөергән: «Анысы безнең эш түгел... Мин Әүхәди энекәшнең күкрәгенә кызыл тасманы үзем тактым, андыен асыл бәндәне тиккә әрәм итәләрмени?» — дигән... Өерләре белән китеп җугалдылар шулай иттереп. Тап инде дәржә суларына салгандай...

Бермәлгә тынлык урнашты. Тик кайдадыр үлән арасында чикерткә генә өзек-төтек иттереп сайраштыра иде: янгырга түгел микән?

— Соң аларның семьялары, әйтик, яшь хатыннары, бала-чагалары да калгандыр бит. Алары белән ничегрәк булды икән? — дип сорады Чистай егете, сулышын кыскан көйгә.

— Җук, әрәм булмадылар. Сәвит какмады, барыбер үз итте. Гаеп аларның хатыннарында җәисә балаларындамыни? Арт урамда Җамалый-әзмәвир бар ие, Каракайның уң кулы... Шуңардан туган малай, мисал өчен генә әйтәмен, кая анда кеше рәтеннән төшеп калулар, үсен, чын кеше, зур кеше булды хәтта ки... Моңардан армиядә чагында, партиягә алырга җыенгач, сораганнар ди: «Әтиең кем?» — дип. Бу яшереп тормаган: «Бандит!» — дигән. Җыелыштагылар хәйран аптыраштa калган. Алай да ишеккә күрсәтмәгәннәр, алганнар...

— Алмыйча... чын кеше булып җитлексен дә...— дип җүпләп куйды Мөбәрәй.

— Ә хәзер ул адәм актыгыннан туган ир заты күрше колхозларның берсен өстери. Шәп җитәкли, диләр! Күчмә кызыл әләмне әледән-әле шул ала. Ә Каракай... каракайлар... Искә төшкән саен әллә нишләп китә күңел... Аның җыруы да бар, җаман да ачы җыру:

Каракай ла батыр, карчыга,
Сызгырып лай җибәрсә, җил чыга.
Кылыч айкап, «ирек» дигәндә,
Җан сатмаган ие акчага...
Их, дөнҗа,
Җан сатмаган ие акчага-ау...

Бабасы Туры картка ияреп, Сабир да кипкән иреннәрен тибрәндерергә тотынды. Аның артыннан җырга карлыкканрак тавыш чыгарып, моңсу кыяфәтле Мөбәрәй белән Мәттин агай да кушылды:

Каракай ла батыр, бичара,
Күзләр сөрем, шөһрәт ни чама?
Бозылса лай каннар тамырында,
Төзәтергә-әй җуктыр бер чара...
Их, дөнҗа,
Төзәтергә-әй җуктыр бер чара-ау...
Каракай ла батыр, Каракай,
Күкрәгендә инде ни улай?
Бер иленә кулың күтәрсәң,
Эзләрең дә-әү калмай җул буйлай...
И шулай,
Калмады ла-ай эзе җул буйла-ай...

— Гомерем буена уйлыйм инде шулай: нилектән, дим? Кырлар эндәшми, авыллар җазмышы җавапсыз... Ә бит кем чыгар ие аңардан, кем чыгар ие! Барган җулында әллә бик җаман иттереп тибәрделәрме үзен? Шуннан җарсыган да, җарсуы җавызлыкка әйләнгәнме?

— Бар хикмәт җирдән аерылуында, хезмәттән... Җиргә тир түкмичә, җиңел кәсеп эзләүләрдән! Шуннан килә инде ул дөнҗага төкереп караулар! — диде Мөбәрәй, каш-күз җимереп.

— Әллә, бәхетсезлегенә, үз вакытында комиссарның җүнлерәгенә җулыга алмады микән, дим, ахыры килеп?

— Ие, кешенең үз күңелендә булмаса...— диде Рәмзи, бик тә хәсрәтле төстә ияген каккалап.

— Шулай: үз күңелендә булсын... үз комиссарың булсын күкрәгеңдә! Аерата кыен чакларда киңәш-табыш итешергә...

— Күктәге алла кебегрәк,— дип куйды Мәттин агай, гадирәк итеп аңлатмакчы булып.

— Күктәге алла? Җук, күктәге алла боера гына белә, әмер генә бирә. Аның белән бәхәсләшү түгел, киңәшеп тә булмый. Боерган икән — үтә генә!.. Ә үз күңелендәге комиссар исә... анысы бөтенләй бүтән... Һай, бүтән!

Бу минутта һәммәкиенең дә күз карашы рәшәле офыкларда, һәммәкиенең дә күз алдында Каракай батыр... Ерак еллар пәрдәсен ертып, килеп баскан да бар кыяфәте белән чалымлана: аркылы-торкылы каешларда кылычтыр, нагандыр, күкрәгендә кызыл тасма, йөзендә хәтәр мыек, чем-кара күзләреннән очкыннар сибелә...

Ә бактың исә... чынлыкта... Иң кирәклесен булдыра алмаган Каракай. Булган хәтлесен дә җуйган...

Туры карт боларның ни турында уйланганын сизенде ахры: менә утырган җирендә салмак кына кымшангалап, тирән иттереп сулыш алгач, ниһаять, ярым пышылдап, әмма каяндыр күкрәк төбеннән менгән тавыш белән әйтә куйды:

— Коры гайрәт кенә ни әле ул? Чытырманны җалмаган ут кына. Хәтта ки, күмере дә калмый, нибары көл генә... Җук, оланнар, адәм баласына җан арулыгы, чын инсафлык белән чын миһербанлык барыннан битәр хәҗәт шул!..

Ул чакны Хәнәфи гәпкә катышмады. Нибары тыңлап кына утырды.

Ә хәзер, ул вакыйгадан соң байтак көннәр үткәч, барын да күңеленнән кабат кичерә, нечкәли, болында купкан бәхәсле гәпне үзалдына дәвам иттерә.

Берәүдән, явыз юлбасардан, туган малай тора-торгач, чын адәмгә, хәтта ата коммунистка әверелә; ә икенче берәүдән — аның үзеннән, бер гөнаһсыз җаннан туган малай исә... дөрес, әлегә арадан берәвесе... инде чын адәм булды дип торганда гына, аның «каракайлык» юлына басканлыгы ачыла. Югыйсә, аның үзенекеләр бары бер шартларда яшәп һәм укып, бер үк дәрәҗәдә тәрбияләнгәннәр иде ләбаса! Аеру юк, бүлү юк... Нидән килә бу яманлык? Туры карт әйтмешли, юлбасарлык-ертлачлык сыйфатлары, ата-бабалардан күчеп, канда сакланамы әллә? Саклана да, тамыр җибәреп, үсентеләнер өчен, дөньяның чуалыбрак, болганыбрак китүен генә көтеп ятамы?

«Үз күкрәгеңдә булсын комиссар!» — диюләре тагы... Әйтүе җиңел. Ләкин чынлыкта ни ул? Капшап булмый, күз алдында төсмерләнми... Бу сыйфат та, кан аша күчеп, бала белән бергә дөньяга киләме? Әллә аңа соңрак кереп оялыймы? Ояласа, кайчан, ни рәвешле?

Хәнәфи үзалдына сорауларны куя куюын, ләкин, ни үрсәләнсә дә, аларга анык һәм төгәл җаваплар гына таба алмый иде...

25

Көттеләр.

Бер көн үтте, ике көн... атна үтте!

Егет туган нигезенә кайтып егылырга уйламады да.

Әнисе Рәсүлә көндезләрен авыл урамыннан күзен алмый; эшенә, басу-кырларда тир түккән эшчәннәрне туендырмага барса, анда каерыла-каерыла ерак юлларга караш ташлый. Ә кичләрен тоташ яктылык шәүләләрендә балкыган Чаллы тарафларына төбәлә. Вәсим дә арада макталмышлардан иде: үрнәк алырдайлардан дип, аз чөелдермәделәр исемен, гәҗиткә дә аз басмадылар һавалы сурәтен... Җыен корыч шул ут эчендә чыныга кебек. Ә бит, бер уйласаң, Иблис тә ут-ялкыннан туган шикелле, ул да үзенекеләрне ут белән суда чыныктыра, күрәмсең...

— Әтисе, дөм караңгы басу күкрәгендә җапа-җалгызын калдыргансың ич. Андый хәлдә кешенең әллә ни кылуы бар. Шул тиклем катыланмаган булсаң соң!

— Йомшакны эзләп йөрмәгән бит үзе дә.

Хәнәфи иртән башын игән көенчә чыгып китә, кичен башын игән көенчә кайтып керә. Ул үз карашын мәңге җирдән аерып алалмастыр кебек. Аңа, әлбәттә, аерата кыен. Ни дисәң дә, рабочком, кеше арасында эшлисе... Хәер, Рәсүләгә дә бу ачы көннәрдә басу күкрәгендә пешергән ашы аш булып пешмәгәндер кебек тоела, үз йортында, мал-туар, кош-кортны караган чагында да ардым да бәрдем кыландыра...

Ә болай яман хәлнең төтене-исе авылга таралып китмәде шикелле. Рәхмәт, Гәрдәле Хәкимҗаны чыннан да телен тешли белүче адәмнәрдән икән, тегеләре, ике дружиначы — Гегель белән Мирсәет тә — серне эчләренә сеңдерә белгәннәр кебек... Ләкин рәхәтме соң? Азакка таба Хәнәфи бу хакта бөтенләй бүтәнчә уйлый башлады:

— Исе-төтене таралмавы җүнлегәдер дисеңме? Киресенчә: таралган булсачы! Шундый да алама бәндәне канатың астында тәрбияләп чыгаргансың дип, бер туйганчы тетмәмне теткән булырлар иде, ичмаса! Бәлкем, рабочкомлыктан ук очыртырлар иде... Шушылай кеше күзенә туры карарга оялып йөргәнче...

Рәсүлә аны тынычландырмый, иреннәрен генә чәйни.

Төпчек уллары Рәмзи өйләрендәге галәмәт хәлгә — бигрәк тә лапас астына кертеп ябылган «арестованный» «Жигули»га — үтә гаҗәпсенеп һәм сәерсенеп калган иде. Аңа яман серне тишмичә булдыра алмадылар. Соңгы вакытларда егет бик тә дәртсенеп һәм очынып йөрүдә иде, сөмсере капыл коелды. Ә бит, югыйсә, аны һич коелдырасы түгел иде...

Аягоч күршеләре Фәгыйлә түти исә ут йоткандай һаман тыз да быз йөрүдә. Әле беркөнне кичен Шилнә

буена каз эзләргә төшкән җирләрендә, Рәсүләгә зур куанычын әйтте: Волгоградтагы автомеханик улы сентябрь уртасында отпуск алып, гаиләсе белән туган авылына кайтып төшмәкче икән. «Җәрәшүнең бар нәмәрсәләрен шул тирәгә чамаларга кирәк булыр»,— ди. Фәгыйләттәй хәзер инде «мәһәредер... калымбашыдыр» дип сүз кузгатып вакланмый, ярәшү-кавышу йоласының зуррагын, эрерәген күз алдында тотыбрак тукый: «Берчәсен әвәлтенчәрәк иткәндә үтә дә җәмле булачак, билләһидер»,— ди. Аның үз мәнфәгате, үз хәсрәте — матуры, күңеллесе...

Бариевларның Чаллыдагы ике таза кыйпылчыгы, Айдаш белән Рәмилә, туган нигезләрендәге зур яңалыкның ни яманын, ни матурын әлегә белми иде. Озаклап саклардай сер түгел, көне суккач, белми калмаслар... Ә туйны, Фәгыйләттәй әйткәнчә, сентябрьнең икенче яртысына чамалаганда кулайрак булыр. Әйе, монысын, җир җимерелсә дә, өзәргә ярамас! Анда инде урып-җыю эшләре төгәлләнеп, хәлләр бераз җиңеләйгән булыр. Дөрес, яшелчәчелектә эшләрнең әле һаман иң кызган чагына туры килер килүен, әмма ике-өч көндә генә яшь агрономсыз да үлмәсләр әле...

Тик аңарчы ничектер чүп-чардан арынасы, җанны-рухны ничектер тазартасы иде!

Ниһаять, Вәсимнәрнең хәбәрләрен ишеттеләр: адәм актыгы, Чаллыдагы эшеннән чыгып, каядыр читкә шылган, ди. СССРда ударный төзелешләр азмыни? Әллә БАМга, әллә Атоммашка, ди. Чаллы төзелешендә аталмыш-макталмышларның берсе иде, урыннарда утырган эшнәләре дә аз түгел иде, мөгаен, путевкасын-мазарын да кирәгенчә юнәткәндер.

— Ә бәлкем, читкә китеп барулары хәерлегә генәдер, әтисе? Туры бабасы әйткәнчә, тормыш җилпучында кибәге кибәккә очып, җармага җүнлесе төшәр...

— Орлыгы таза булсын... Их, барын да онытасы, онытыласы иде!

Ләкин дөнья ансат кына оныттырамы соң? Чүп өстенә чүмәлә өю яисә ярага тоз сибүләрне исеннән чыгарамы соң ул! Тормышның холкы шулайрак лабаса.

Беркөнне кичен көтү кайтып, урамнар тынып калгач, боларга һич уйламаганда Чаллыдан теге «юха» килеп төште. Рәсүлә, билгеле, аны бусагасыннан атлатып, өенә кертмәде, болдырга утырыштылар.

Чыннан да үтә чибәр һәм елдам икән. Кулларында бармак саен диярлек балдак-йөзектер, колак яфрак-

ларындагы алкалары да әллә чын алтыннан, әллә алтын суы йөгертелгән. Муены шома ак мәрмәрдәй, кашлары тигездер, нәзектер, йөзе түгәрәк матурдыр. Чын әгәр, ир-атның теләсә кайсын суырып кына алырдай! Теле дә йомшактыр, шомадыр, май тамызмый майлаучандыр... Иплəп кенә хәл-әхвәл белеште, тормыш җайларын сорашкандай иттерде, аннары үзенең Вәсим белән бик тату, нурлы яши башлаулары хакында тәмләп сайрарга керешге һәм сүз арасында:

— Без бит апрель аеннан бирле, аңардан өч айлык көмәнем бар инде, малай булыр, ахрысы, гел балык сорый,— дип тә ычкындырды.

Рәсүлә, түземен җыеп, сабыр гына, ияген каккалап кына тыңлап утыра иде, ул дуамал кубарга әле иртәрәк дип, җай-чама көтә иде. Чибәр хатынның азаккы сүзләренә, ниһаять, үз бәясен бирмичә булдыра алмады:

— Урам себеркесе... Ыстырам!

— Нишләп инде? Без бит яшертен булса да, әдәп белән...— дип, хуҗа хатын әйткәнне колак читеннән генә уздырырга итте чибәркәй һәм гөлдер-гөлдер ары тезеп китте.

Шулай үз тормышын, үз хәлләрен мактап утырганда, ул әледән-әле лапас астында карасу-кызыл чия төсләрендә елтыр-елтыр иткән матур автомобильгә дә ымсынулы карашын ташлап алгалый иде. Ә хуҗа хатын исә мыштым гына тыңлый бирә, оятсызлыкны, ертлачлыкны әкрен генә сеңдерә бара, дөресе, сеңдергән хәтлесен озакламый барын берьюлы, әлбәттә, җыелган зәһәр нәфрәтен дә кушып, чибәр хатынның үз өстенә капыл аударыр өчен, вакыты җиткәнен көтә иде... Хуҗа хатынның мыштымлыгын һәм юашлыгын үзенчә юрап, ахры, чибәр хатын, лапас астында сихерле елкылдап торган затлы һәм кыйммәтле нәрсәгә караган шәйгә, ниһаять, җете-кызартылган дымлы иреннәре арасыннан кысып чыгарды:

— Бу машинаның торыр җире, апакай гынам, монда түгел, тегендә, тиешле урынында... Китеп барган чагында Вәсим җанашым нәкъ шулай дип әйтеп әйткән ие...

Менә шунда инде Рәсүлә: «Кая язылышканлыгыгызга паспортың? Кайда әйткән сүзләрең теркәгән кәгазең? Үтәдән чыккан җуашлар, күндәмнәр дигәч тә, терелә тунарга килдеңме, эт җан?! Минутында эзеңне суыт!» — дип эчендәге бар ачысын, бар ярсу-нәфрәтен бергә төенләп, ябырылмакчы гына иде, өлгермичә калды: болдырга, өйалды ишеген җәһәт кенә каерып ачып, ире

Хәнәфи атылып килеп чыкты. Анда ул, бераз тын алмага дип сыртын ян сәкегә сузып салган жирендә, боларның сүзенә колак шәбәртеп яткан, күрәмсең. Атылып чыккан шаенә үк:

— Шул ертлачның ысылдавын тыңлап, ни дип колак сасытып утырасың?! — дип жикерде ул хатыны Рәсүләгә.— Әйдә, жебеп утырма! Бар, капканы бикләп ал, ә мин этне жибәрәм. Асыл кош аягыннан эләгер, ди!

Чибәр хатынның аксыл, түгәрәк йөзе капыл гына сыек-яшел кофтасы төсенә керде, аягүрә калкынды.

— Нишләп әле син, абзый кеше... тик торганда... тиктомалдан гына...

Хәнәфи аңа түгел, янә хатынына жикерде:

— Бар, дим, бикләп тизрәк капканы!.. Ә мин жәт кенә участковый белән пүнәтәйләрне чакырып апкиләм! Ул төнне йомшаклык кылганнар үзләренә... Бер буры Чаллыдан качып котылса, икенчесе үз аягы белән килеп керде бит. Жебеп калмыйк: жавапка тартканда, астына салмага бер документ булыр, ичмаса!.. Жәтрәк кыймылда, дим!

Рәсүлә, иренең хәйләсен аңлап, капыл гына утырган жиреннән купты. Ә чибәр хатын исә, бәбәкләрен зәңгәрләтеп, чак кына өнен-зиһенен жыеп торды да кинәт:

— Кара-вы-ыл!.. Суя-ла-ар! — дип яман чинап жибәрде һәм, Рәсүләне бер кырыйга этеп, бәрелә-сугыла капкадан урамга атылып чыгып китте. Анда аны мотоциклы бер адәм көтеп тора икән. Шуның янына барып баскач та, чибәр хатын, чинавыннан тукталмыйча, һавада матур йодрыгын болгавын белде:

— Әле каннар косарсыз! Күрәләтә талап ятарга монда... законнан өстен булалмассыз!

Әнә шулай яман каһәрли-яный авыл урамыннан тырылдаттырып китеп бардылар. Шул китүеннән соң чибәр хатын бүтән күренмәде, өнен-исен сиздермәде. Көмәне-нисе булса идеме? Андыйлар ис сиздерми йөреп ятыр, ди! Йөрәгеңә төшәр!.. Хәер, бер-ике ай үткәч, Бариевлар аның хакында Вәсим яшәгән квартир хужасыннан ишетер: имеш, ул үтәдән чыккан чибәр, чая хатын инде икенче берәүнең муенына сарылып алган, ди... Бу хәтлесе соңыннан беленер, ә хәзер исә...

Ирле-хатынлы моңа тикле күпне ишеткән, күпне сеңдергән болдырга килеп утырыштылар. Икесе тиң башларын куллары белән кочып алды. Авыз ачып сүз әйтерлек хәлләре калмаган иде. Ниһаять, Рәсүлә ике ку-

лын да тез капкачлары өстенә күчереп, тирән уфтану аша әйтә куйды:

— Ә Вәсимнең читкә шылулары, бәлкем, уңайгадыр әле? Берочтан, дим, шушы имгәгеннән... тагын да зуррак казадан котылуы булырдыр, ә?

Ире җавап сүз әйтмәде — аның куе төкләр баскан какча яңаклары гына тартышкалап алды...

26

Арпа кырына комбайннар төште.

Ике звенога бүленеп, басу иңендә сузылып яткан теземнәрне җыеп суктыралар. Арпа галәмәт уңган — теземнәр тап инде арыш кырындагы шикелле калынаеп, күбә-күбәләнеп ята. Комбайннарга шактый көчәнергә туры килә.

Басу бөтенләе белән күңелле хезмәт гөрелтесенә күмелгән.

Уң тарафтагы төркемдә бәләкәй кызыл әләм өр-яңа «Нива» комбайны өстендә җилферди — аңарда Әҗернең ата комбайнчысы Шакирҗан улы Мәхмүт җимерттерә. Бу елны рәхәт Мәхмүткә: маңгаена күзлек тә киеп тормастан, пыяла кабина эчендә штурвалга таба чак кына иелә төшкән дә, умырттыруын белә. Комбайнның күкрәгендә инде тугыз йолдыз балкый, димәк ки, шартлыга куеп, ягъни игеннәрне теземнәргә егуын да кертеп йсәпләгәндә, инде тугыз мең центнер суктырып алган. Ә бу чикмени әле аңа? Ничәмә еллар буена совхозда барган кайнар алыш-ярышта беренчелекне бирәүгә дә бирмәгән абзаң менә бу җәйне шушылай игеннәр дуамал уңган чакны гына сынатып ятар димени?

Сул канаттагы төркемдә дә кызыл әләмчек «Нива» комбайнында. Анысында штурвалга ике куллап Матвей Ворончихин ябышкан. Сары чәчле, ябык кызгылт йөзле бу елгыр адәм Әҗер кешесе дә, гомумән совхоз эшчесе дә түгел: КамАЗның двигательләр заводында эшләүче слесарь. Элек-электән үк канына сеңгән, күрәмсең: җәй уртасында урак башлануга түзә алмый, җаны иген кырына ашкына, ди. Андыйларның атлар юлына киртә торгызып буламы соң? Әле өченче елны ук Матвей болар совхозында байтак кына эш майтарып киткән иде, ә былтыр Чаллы районының кайсыдыр колхозында иген кыркышкан, әмма анда әйткән, ди: «Юк инде, эшләрне оештыру «Йолдыз» совхозындагыга җитәме соң? Аларда, ичмаса, комбайныңны теләгән кадәренчә «йолдыз»-

лар белән бизәргә була» дигән, ди... Хәзер аның «Нива» күкрәгендә сигез бөртек ак йолдыз балкый, ягъни абзаң ата комбайнчы Мәхмүтнең үкчәсенә басып бара диярлек. Тегесенә, атаклы остага да, ярсу йөрәкле көндәш барында, әлбәттә, һич ансатка килми. Ләкин нихәл итәсең, көрәш мәйданына тик батырлар чыга, тик асыл йөрәклеләр генә җиңүгә ирешә ләбаса!

«Йолдызчык»ларның иң азы Айдаш Бариев комбайнында — нибары дүртәү.

— Ә син, Әүхәди абай, аңа тамчы да пошынма... Комбайн иемени аларда? Җыенысы кул селтәгән кылтыр-келтер көлтә арбасы ие бит! Инде шуңардан да тик торганда совхозга дүрт меңне суктырып бирсен дә сиңа — уен эшмени? Ие, әйтерең җук, синең Айдашың җукны бар итеп җөрүчеләр токымыннан, валлаһи газимнәр! Аның җанына тагын оныгың Сабирны да кушып куйсаң...

— Шулай димсең инде...

— Шулай... Ә җолдызларны әле тагын да кабындырырлар. Бу басу азаккысы инде, моны иртәгәләргә очлап та куярлар. Аннарымы, җалап-түгәрәкләп куйгачмы? Әлбитте, инде звено-звенолап күрше совхозларга чаптыралар. «Татарстан» белән «Илбакты»да урасы да, суктырасы да шактый, ди, әле...

— Күршеңә булышмыйча җарамый инде, Мәттин, дөрес, үзең бакыр булсаң да, сүзең алтын синең. Тик тоташтан җавымга китмәгәе, дим, көзгелеккә кереп баруыбыз ич.

— Китмәс... Әле бирер...

Ике карт — Туры бабай белән Мәттин агай — билләрен ат арбасына терәгән хәлдә, әнә шулай үз көйләренә ипле генә сөйләшеп тора иде. Арбага төрле ризык: икмәктер-сөттер, кыярдыр-помидордыр төялгән. Артларында текә һәм биек стена булып кукуруз басуы тоташып китә, ә чак кына читтәрәк, ызан буенда, Рәсүләнең походный кухнясыннан сыек зәңгәр төтен бөркелә, ул тарафтан, тамак төпләрен кытыклап, итле аш исе килә.

Ике картның да нурлы карашы шау-гөр иткән алтынсу иген кырында. Телләренә дә сүзнең татлысы, рәхәте килеп тора. Ә каршыларында басу күкрәгендә гөрләгән комбайннар төркеме бер-берсеннән торган саен ераклаша бара. Кыр корабларының әле берсендә, әле икенчесендә, өскә калкынып, һавада җәһәт-җәһәт береткепка янсә кызыл әләмчек болгарга тотыналар. Ләкин бу хәл озакка сузылмый, тегендә дә, монда да сибелешеп,

тукталып торган автомашиналарның берсе, капыл кубып, ятьрәк шул тарафка элдертә, димәк ки, тегеләрнең бункеры тулган, ә вакытның сәгате түгел, минуты кадерле.

Мәттин агай әрҗәсенә брезент япмалы зур гына машинаның камыллы басудан бик авырлык белән генә такыр юлга чыгуын күзәтеп торды да, аны күз карашы белән озатып куйгач, Туры картның янтыгына орынып алды:

— Тегендә ындыр табагындагы көшелләрне күрсәң син, Әүхәди абай! Прәме дә әкәмәтләр инде! Җарый, кайтканда, анда да сугылырбыз әле... Ә бу арпа кырыннан кантрульгә суктырганда, күпме чыккандыр дип уйлыйсың? Төп-төгәл утыз да тугыз центнер!

— Хәйран шул, хәйран... Кырыкка бер генә тулмаган икән. Андыйны моңарчы безнең күз күргәнме, колак ишеткәнме, Мәттин, ә?

— Ие: әйтерең җук... Ә бәлкем, бу арпа басуыннан тулаемны кырыкка да тутыра алырлар әле. Аның бу кантрульгә суктырганда, иң шәп, иң куе төшен электермәделәр, тәк сибәрәген генә...

— Инде болай да хәттин шәп, рәхмәтләр инде! Җылның шушылай җаман да уңай килүләре генә менә сирәгрәк...

Туры карт сокланулы күз карашы белән басуны кармалаудан тукталмый, Айдаш белән Сабир оныкларының комбайнын күз кырыннан ычкындырасы килми иде аның: «Алай-болай җәнә уалып калмагайлары, берүк ходай үзләренә рәхимлек кыла күрсен инде!» — дип изге теләк теләүдә иде ул.

— Җылы җыл инде аның, әмма ләкин...

Мәттин агай сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Туры карт кинәт күзләрен чепиләндереп аңа төбәлде:

— Син нәрсә, Мәттин? Син дәме «Һава хәлләренең ифрат катлаулы» җәисә «Табигатьнең җаман килелекләренә карамастан» дип, авызыңда суган әвәләргә тотынмакчымысың? Көн туды исә, теген нән Казан радиосы да шулай сөйләнә, гәҗитләр дә әледән-әле шуны ташка бастырып чыгара. Бер иш адәмнәр җахшыны җаманнан аера белмәс булган инде тәмам. Шушылай һәйбәт килгән җылны бит!

Мәттин агай, сискәнеп китеп, өлкән иптәшенә җәлт кенә күз төшереп алды. Шушылай матур гына, көйле генә сөйләшеп торган мәлләрдә, аның һич кенә дә ямьсезләнәсе килми иде. Ни дисәң дә, олы кеше, абруйлы

кеше, житмәсә: авыр сырхаудан савыгып килгән генә чагы: аннары ул аны үзе үк авыл очында юл башында очраткач: «Әйдә генә, Әүхәди абай, гөрләп торган басуларыңны бер әйләнеп, хозурланып кайтсаң, тәнеңә дә, жаныңа да сихәтлек тиз иңәр, ичмаса!» — дип, арбасына утыртып алып килгән иде ич...

— Хе-хе, нишләп инде, жылны жаманлап торыйм ди? Мин дә бит, әйбәт, дим, шөкрана, дим... Әйтик, менә син эшләрне оештыру жәһәтенә генә күз сал!

Туры карт дың тоӊаналардан түгел, ул, әлбәттә, барын да күреп-белеп яши, әмма кайчан әле хак һәм татлы сүзнең, кабат-кабат әйтелсә дә, жанны жәрәхәтләгәне бар ди? Туры бабай няген селкә-селкә тамак төбеннән чыккан тавыш белән:

— Ыхтымат инде! — дип жүпләп, бер сүз белән генә мөһерен бастырып та куйды.

Ә Мәттин агай туктауны белмәде, бер алган кызуын тамчы да киметмичә, ары тезеп китте:

— Инде агротехника дигәнемнән... Арыш жәки «Мироновский» көзге бодайларга кагылмаем да — аларыннан да уңыш хәттин генә, жазгылыкны әйтәм... Сабанга чыккач, чәчү чәчкәндә, бодайдыр, солыдыр, жәки әйтик, шушы «Мәскәуски» сортлы арпа жирләрендә чәчкечләр генә дә басулар буйлата ничәмә тапкырлар үтмәгән, димсең? Буйга берме, аркылыга берме? Аннары кайтып, кәтүкләп узганнан соң, инде шытымнар калкынгач...

— Кһем-һе, сине, Мәттин туган, минем малай Ризван-агроном урынына гына куясылары бар инде! Беклегеңне әйтәм.

— Жә инде, жә, син алай бик үк...

Ул арада авылга таба сузылган такыр юлда мотоцикл гөрелтесе ишетелде: картлар, икесе бердән башларын борып, шул тарафка күз ташлады. Озын гомерле булыр, ахры: юл белән жилдертеп килүче бер дә әллә кем түгел, Туры картның кияве рабочком Хәнәфи Бариев иде. Ызан буенда, походный кухняга якында гына, жигүле ат арбасына сыртларын терәп торган ике адәмнең кемлеген шәйләгән булса, ул, әлбәттә, каенатасы Туры карт белән килеп күрешмичә, аңардан хәл-әхвәл белешмичә калмас иде калуын, әмма, күрәмсең, шәйләмәгән: суктырылган теземнәр турысына килеп житкәч, тәбәнәк кыркылган камылларны ердыртып, салам күбәләре арасына кереп китте.

— Мөгаен, Гәрдәленең бодай басуыннан килешедер. Тегеләр белән боларны жарыштырып жөрүчеләрдән бит.

Тегендәрәк, басу уртасындарак, комбайннарның эшенә күзәтчелек иткәләп, ягъни сыйфат ягын кайгыртып, Әҗер управляющие Мөхлис йөренә иде; Хәнәфи, мотоциклыннан төшмиенчә генә, аның белән нидер сөйләшеп алды да салам өемнәре арасыннан җәһәт кенә уң канатка таба элдертте. Анда ул, барган шәпкә үк, комбайннарның берсенә кул изәп, тукталырга кушты. Сыйфатны кайгыртуы икән: әнә инде Хәнәфи комбайнчы белән икәүләшеп әлерәк кенә төшеп калган салам чүмәләсен актарып атты да аның кибәген җилгәрергә кереште. Әмма суктыруда гаеп-мазар чыкмады, ахры, чөнки комбайнны торган җирендә полный ходка дыңгыр-даңгыр суктыртып азапланмадылар да. Аның каравы... Хәнәфи кинәт ул комбайнчының күзлеген салдыртып, үзе киеп алды һәм, егетләрчә җитезлек белән өскә менеп, штурвал артына утырды. Утыруы булды, комбайнны яман үкерттереп һәм подборщигы белән теземне җәт-җәт йоттыра биреп, суктыра да башлады. Күр үзен, елгырны!

Бу хәлне күзләрен тутырып карап торган Туры картның күңеле бөтенләй хушланып китте. Монда, якында гына, походный кухня морҗасыннан һавага зәңгәр төтеннәр бөрки-бөрки кыр эшчәннәренә тәмле тәгам әзерләп, кызы Рәсүлә пешә-яна эш кыйландыра; тегендә, иген суктыруда исә ике оныгы белән кияве утлар-җилләр уйнаттыра... Тик үз улы баш агроном Ризван гына нишләп күренми соң әле, кая югалды икән? Ындыр табагында орлык салдырудамы әллә яшелчәлектә кирәккә-кирәкмәскә акыл чәчеп йөрүдә микән? Бу хакта янәшәдә басып торган Мәттиннән белешергә дә булыр иде, әмма сорашырга итмәде, тик аның әйткән сүзенә генә колак салды:

— Хе-хе, шулай инде ул синең кияваң: комбайнда гынамы, чәчү чәчкәндә дә, җәки әйтик, сөрү сөргән чакта да, үзе утырып бер-ике әйләнмәсә, җөрәге тынмый аның...

Ләкин тегендә Хәнәфи киявенә алай озаклап кинәнергә язмаган икән: монда аның хатыны ләгән төбен дыңгырдатып-кыйнап алды, аллы-гөлле яулык бәйләнгән озын колганы һавада болгап җибәрде, ул да түгел, яулык болгаган шәпкә:

— Әй-дәгү-үз! А-шар-га-ау! — дип каты зыңлатып аваз салырга тотынды.

Мондый хәлдә, Мәттин агайның да сын катырып тору вакыты чигеннән чыгып киткән, уртак табынга аш-ризык

әзерләгәндә, Рәсүләгә булышмыйча һич ярамый иде, әмма ул, баскан җиреннән куба алмыйча, күз тасрайтып торуында булды.

Рәсүләнең яман чәрелдәп кычкырган тавышы басу түрендә җир селкетүчеләрнең колагына барып ирешкәндерме-юктырмы, әмма аның һавада яулык болгавы үзенә бертөсле сигнал булды шикелле: сул тарафта ипле генә тезем җыеп-суктырып барган бер комбайн, ни күрсеннәр, капыл гына читкә борылды да, хедерын күтәрә төшеп, салам чүмәләләре арасыннан җил-җил урталыкка таба юл тотты. Урта турыга килеп җитүенә, янә капыл борылып, загон ярганнан бүленеп калган куш теземне өздереп алды һәм аны умыра-умыра «яларга» да керешге. Ләкин бераз алдыруына төртелеп калды, шул секундта ук комбайн канатыннан берәү җәһәт кенә җиргә сикереп төшеп, теземнәрне куллары белән тараткаларга, юкаландырырга тотынды. Бәй, Сабир лабаса бу, Айдашның «Сибирягы»! Менә сиңа калтыр-кылтыр комбайн! Бу хәлне күреп, абайлап алган бүтәннәр дә өлешсез калырга теләмәде, күрәсең: иң әүвәл уң тарафтан Айдашның этисе Хәнәфи комбайнын урталыкка таба борып җибәрде, аңа ияреп, аргы очта КамАЗ слесаре Матвей Ворончихин, ә бире баштарак үзенең «Нива»сында Шакирҗан улы Мәхмүт кузгалды. Басу күкрәгендә буйдан-буйга хәтәр гүелде купты, и тотындылар, мин сиңа әйтим, моңарчы тыныч кына яткан куш теземнең тетмәсен тетәргә!

— Әбәткә тукталганда дип, алдан ук сүз куештылар микәнни?

— Үзем дә белмәем, Әүхәди абай...

Куш тезем галәмәт калын, аны алдыруы үтә дә авыр иде.

«Нива» комбайнының хедеры да, подборщигы да шактый ук киң, җегәре дә шәп, әмма ул булып ул әледән-әле төртелеп кала иде. Югарыда ике куллап штурвалына ябышкан комбайнчыга ничектер, әмма түбәндә җирдәге калын теземне селкә-юкарта барган ярдәмчесенә ай-һай ла!.. Шулай да, төртелеп куйгаласалар да, тукталып калмыйлар, чамасын белеп кенә умырттыра бирәләр. Башаклардан бөртек төшеме галәмәттер: бункерларын әле кайчан гына бушатканнар иде, әнә инде арырак Сабир майда-тузанда кара-кучкылланган кепкасын һавада селеккәләп алды, монда да, якынракта да, «Нива» комбайны өстенә чөелгән таза яшь кулда кызыл әләмчек җилфер-җилфер бөтерелгәләргә тотынды.

Бер кырыйдарак шуны гына көтеп торган ике автомашина, капыл кузгалып, чакырган тарафка юл алды. Һавага сәләмәләнеп әчкелтем-татлы тузан сибелә, һавада колакларны тондырырлык дуамал тыгыз гөрелте тирбәлә — кыр күкрәгендә мәхшәр!..

Нык сеңерле, чыдам тамырлы Мәттин агай булып Мәттин агай авыз ачып сүз әйтә алмый: аның гәүдәсендә сәер дерелдәү кузгалган, тамак төбенә исә әкәмәт дулкын килеп тыгылган иде... Менә ул иңбашына сөякчел каты кулның орынганлыгын тоеп, башын борып карады, караса, Туры картның йөзеннән кан киткән, күгелҗемләнеп калган иреннәре сизелер-сизелмәс кенә кыймылдый:

— Мәт... тин... зин... һар... су...

Бу да түгел, картның гәүдәсе кинәт авыраеп-сыгылып агайга таба түнә дә башлады...

Мәттин агай, сөякчел гәүдәне кочып чүгәләгән шәйгә, башын читкә таба борып, ачы тавыш белән аваз салды:

— Рәсүлә! Рәсүлә, дим!.. Әтиең... зинһар, су дим, су! Җәтрәк!

Кулына ак чүмеч тотып, Рәсүлә килеп тә җитте, һәм, сулышы куырылып, әтисе өстенә иелде:

— Әтәй...ниләр генә булды, ни?.. И алла гынаем!

Тегендә мул игенне дөбер-шатыр суктыра бирәләр, бункерлар тулганнан-тула килә, тере алтын бөртекләр агыла тора — машина әрҗәләрендә көшел түбәләре калыкканнан-калка бара, ә монда...

— Гө... гө... лием... бә... хил...

— И әтәем, и җаныкаем ла!..

Ниһаять, тегендәгеләр дә ызан буендагы яман хәлне абайлап алды, ахры, бер-ике комбайн кинәт тынып калды, бер-икесе, киресенчә, ачы гүелдәп читкә ыргылды, салам чүмәләләре артында болай таба әпен-төпен йөгерүчеләр күренде, алар арасында, билгеле, Туры картның кияве белән ике оныгы да бар иде...

Ләкин карт игенчегә инде беркем дә берничек тә ярдәм итә алмый иде...

Сүнде...

Икенче көнне төштән соң Туры картны җирләделәр. Бөтен Әҗер купты.

«Нәсел ботагы» Сабирга мәрхүмнең: «Тиккә кысып тормасын, ләхетемне иркенрәк итә күрсеннәр»,— дип әйткәне булган икән, әмерен үтәделәр...

Матәм маршы да уйналмады, зират өянкеләрендәге карга-чәүкәләрне өркетеп, мылтыклар да шартламады.

Аның каравы, моңа кадәр Әҗер тарихы белмәгәне булды: мул уңыш биргән арпа басуыннан күршедәге совхоз кырларына күчеп баручы комбайннар, асфальт юлдан тайпылып, зират тирәсенә тупланып алган иде. Мәрхүмнең гәүдәсен гүргә иңдергән мәлдә, алар, бары бердән, моңлы-ачы тавыш белән берара гүелдәп тордылар. Аннары тындылар.

Бу гасырга атлап кергәннең җәтти бураннарында туып һәм ничәмә еллар буена фани дөньяның җиңеллекләрен билбау иттереп, авырлыкларын шыңгырдамый гына иңнәрендә өстери белгән гап-гади игенче-крестьян җәй азагының тымызык бер көнендә шул рәвешчә туган туфрагы кочагына кереп сыенды...

Кешелек тарихында иң зур җиңүләрне яулаган буыннан берәү...

Ләкин ул төп йортына мәңгегә китеп барасы алдыннан үзен алай тиз арада гына онытырлык итмәгән иде...

27

«Өчесен» уздырдылар, «җидесен»...

Алда әле «кырыгы» бар, «еллары» бар...

Өйләрендә юксыну-сагыш, бушлык, нәүмизлек. Боларда гынамы, Әҗернең бөтен түбән очында...

Ризван-агрономның киң маңгаенда буразналар ишәеп һәм тирәнәеп китте шикелле, чигәләрендә көмеш укалар да куера төште сыман, ул әледән-әле:

— Үземә ныграк торасы калган икән лә...— дип әрнүле-үкенүле рәвештә әйтеп куйгалый иде.— Әмма ни хәл итәсең инде? «Кузьмич кордый дип, бердәнбер җәшьтием, дип, сәфәремнең бәлкем азаккысы булыр», дип, тәмам җелегемә тиде бит. Әҗәл эзләп йөрүләре булган икән шул...

Тегендә, үз өендә Рәсүлә дә ачы үкенүдән бушый алмый иде:

— Арпа басуына утыртып апчыгасылар гына калмаган ла, бәгырь кыллары шунда гына өзелде лә, жугыйсә үз көйләренә җорт тирәсендә ипле генә җөреп җатар ие лә... Арбага утыртмый чарабыз да жук ие шул: «Басу-кырларыбыз дәшә, шуларны бер әйләнеп кайтсам, җаным тынар ие ичмаса», дип өзгәләнеп үтенде бит. Андый чакта үз атаңа буйсынмый, ни кыласың инде?

Әмма хәсрәт-сагышның иң зурысы һәм иң авыры бабайның оныгы Сабир иңнәренә ауды шикелле. Юксыну, моң-сагыш йөге астында бөтенләй басынкыланып, хәтта нәүмизләнеп калды егет. Аның да күкрәген усал мачы тырнап-тырнап алгалый, һәм ул моны өйдәгеләрдән һич яшермичә:

— «Татарстан»нан икенче көнне үк әйләнеп кайтмыйча; Бикләннәргә хәтле ияреп барган булсаммы? Анда яңа мәктәп ачу бәйрәмендә бабай янында үзем утырган булсаммы? Бабай тик торганда алай җебеп төшмәс тә иде әле! — дип ачыргаланып куйгалый иде.

Гомер иткәндә шулай инде: югалтуларның, кайгыхәсрәтнең юлдашы сүрелмәс әрнү-үкенүләр, ди...

Мәктәптә укулар башланды инде. Сабир унынчыга йөри — азаккы елы.

Дәрес вакытларында биргән гыйлемнәрен сеңдерә аладырмы-юкмы, өенә кайткач, китап-дәфтәрләрен аннан-моннан гына караштыра яисә бөтенләй кагылмый да — басуга элдертә.

Яшелчәлектә халык мәш килә: җыялар, төйиләр, озаталар... Әмма яшелчәлектә инде күптәннән су сиптерелми, биредә ул эшләр инде күптән түгәрәкләнгән.

Сабир ары атлый. Күңеле арыдарак...

Әле һаман хәтфәләнеп җәелеп яткан культуралы болынлыкларда да хәзер нибары ике «Фрегат» кына сиптерә. Калганнары инде сүндерелгән, инде озын кышны каршылауга табан борылганнар. Бу икене дә җиргә артык дым сеңдерүдән битәр, боларга киләсе бертөсле халыкның күз явын алдырыр өчен сүндерми көчәндерәләр: озакламый алар совхозында зур семинар үткәреләчәк, ди, аңа әллә ни хәтле хуҗалыклардан, хәтта күрше районнардан, әллә кемнәр җыелачак, ди. Шул сәбәпле, оператор Мөбәрәйнең мәшәкатьләре әле һаман муеннан. Ләкин Сабирның аңарда эше юк. Ул соңгы көннәрдә «ясалма яңгыр алла»сының кул арасына керергә ашыкмый, аның янына барып та тормый, хәтта күзенә дә күренми...

Хәтфә болынның йомшак үләне арасына кереп утыра. Ирен арасына үлән сабагы кыстыра.

Каршысында хәтсез озынлыкка сузылып, «Фрегат» — яңгыр иясе кыймылдый. Автоматлар туктаусыз кылт та шылт, челт тә пелт иттерә. Кызыл путалы ак тәгәрмәчләр куе үлән арасына үзләре үк салган һәм инде каралып, тирәнәеп торган эз белән бик тә акрын, теләр-теләмәс рәвештә генә, алга таба тәгәри килә, аның саен

«Фрегат», болынлыкта иләмсез дәү божралар ясап, әйләнә бара.

Агрегат буйдан-буйга, яңа сауган сөт күбекләре сыман, тоташ яңгыр болытлары эченә күмелгән. «Фрегат» дип аңа исемне бик белеп куйганнар: галәмәт озын һәм җиңел кораб шикелле ул, ә яңгыр болытлары исә ак җилкәннәр сыман...

Хәтфә үләннәр өстенә сибелеп торган яңгырның шавы да чиксез матур һәм йомшак...

Көн кояшлы булганда, аерата кояш инде баеп барганда, яңгыр «җилкәннәрендә» бихисап вак «кояшлар» җемелдәшә, исәпсез салават күперләре уйный. Чын әгәр: тылсым үзедер кебек!

Сабир тирән-тирән сулап куйгалый.

Тылсымга төбәлеп, оеп-онытылып утырган мәлләрендә, күңелендәге сагыш та йомшарып, таралып киткәндәй була. Егетне моңлы көй басып ала...

Өенә кайткач, баянына тотына.

Аулак өй тынлыгында әле сузылып, әле өзелә-теленә моң агыла...

Юк, Сабир алай бик остарганнардан түгел иде, авылларында классташы Вәкил кебек, баянда үзәкләрне өздереп уйный белүчеләр әллә нихәтле хәзер. Алар янында Сабир бөтенләй мескен. Шул сәбәпле, ул, күңеле сүрелә китеп, соңгы вакытларда баянын онытканда бер генә кулына алгалар иде.

Ә бер кичне Туры бабасы, әле түшәктә сырхаулап яткан чагында: «Улым, баяның тиктомалга тузан җыеп җата, уйначы бер көйгенәләрнең иң тансыккайларын!» — дип үтенде аңардан.

Сабир, әлбәттә, карышмады. Уйнады. Үзе туйганчы уйнады. Әмма бабасының күңеле туларлык булдымы икән? Инде менә үкенечкә калды... Клубка ашыккан булды шул егет кисәге. Их, качмас иде әле кызларга кызыгып, аларны аулакта кытыкларга ымсынып йөрүләре!..

Тагын бер-ике көннән соң, басуда игеннәрне яңгыр чылатып, өйгә иртәрәк кайткан кичендә, аулак сәгатьтә бабасы үзе аңа өр-яңа бер көй өйрәтте. Тавышы тамак төбеннән карлыгыбрак чыкса да, моңын җиренә җиткереп, өздереп көйләде...

Теге чакны, «Татарстан» совхозына сәфәр тотып, юллары азагына җитеп килгәндә өзелеп калган көй иде ул. Соңыннан, җигүле атта инде япа-ялгызы гына сәфә-

рен дәвам иттергәндә, бабасы ничектер ахырына тикле исенә төшерә алган икән аны...

«Бикләннәргә үзем дә ияреп барган булсам, бабай тик торганда җебеп төшмәс иде әле»,— дип Сабир менә хәзер бик яман үкенә дә үкенүен... янында оныгы утырып барган булса, бабасы ул гаҗәеп көйне исенә төшерә алган булыр иде микән әле?

Тик кайсы урман кырыйларыннан, кайсы басу буйларыннан узган чагында хәтер төпләреннән сөзеп-сөзеп ала алды икән?

Нурлы күз карашын ак чалмадай ак болытлар каплаган Ак калага, аның артында зәңгәрсуланып торган Кама тауларына төбәгән килеш микән? Мөгаен, шулайдыр... Төбәгәндер дә, туры алаша тибеш-тибеш атлаган шәйгә, уй-хисләре белән бик еракларда, зәңгәр офыклар артында югалып калган авыр көннәренә, газаплы юлларына кабаттан китеп баргандыр...

Шәфәкъ микән, ялкын микән? —
Болытларга кан сеңгән...
Каласың ла, Чаллым, бәхил бул!
Аклар явы ак түгел шул:
Канга сусап ат менгән...
Каласың ла, Чаллым, бәхил бул!..

Юмай-башкорт бабай да, Туры бабасы да ул канлы елларда кайларда гына сугышып йөрмәгән. Урал таулары белән Себер юллары да, Дон һәм Кырым далалары да калмаган. Әлбәттә инде, бу җыр да аларга ияреп йөргәндер, аны бүтән кызыл сугышчылар да сагышланып һәм ярсынып җырлагандыр. Әйе, җырда тирән моң-сагыш, ачы хәсрәт кенә түгел, ялкынлы өмет һәм шиңмәс дәрт тә бөркелеп тора ич. Тап инде яңгыр «җилкәннәрендә» җемелдәгән бихисап «кояшлар» һәм салават күперләре кебек! Аларның бөртеген дә җуймаска иде. Шифалы яңгыр бәрәкәтле җиргә сеңгән шикелле, бу көй дә, авылдашларының күңелләренә үтеп керсен, сеңсен иде. Бабайларның мәңге сүрелмәс ядкәре һәм төсе булып!..

Ал байрак кулларда,
Җилферди җилләрдә...
Ут булып кайтырбыз... их,
Туган-үскән илләргә!

Әллә сабакташы Вәкилгә өйрәтергәме? Менә кем бу җырны бар бизәкләре белән сыздырттыра белер иде! Ә юк, Сабир үзе тырышырга тиеш! Шартласа да, чәнчел-

сә дә, тик үзе!.. Ә җырларга дигәндә, тамак төпләренә былбыл кунганнар мәктәптә җитәрлек, үз классларында ук әллә ничәү. Өйрәтер. Әмма иң башта үзе... Октябрь бәйрәменә инде ерак түгел, әлбәттә, шул көнне клубта!

Ургыл-ургыл, Чулман-судыр,
Ургылганда чаларыр.
Сагышланма, Чаллым, көтеп кал!
Кызыл яулар ирек даулар,
Киң дөньялар нурланыр...
Сагышланма, Чаллым, көтеп кал!..

Кыр-сахралар сары-соры һәм кара-кучкыл төсләрендә инде тәмам чуарланып беткән.

Зират агачларыннан җилпер-җилпер яфраклар коела. Яшел үлән өсләренә сары һәм алсу-кызгылт төсләр иңгән.

Арада өр-яңа кабер. Янында бәләкәй генә иске күбә — карчыгыныкы...

Ике кабер дә менә инде тоташтан тимер чардуган белән әйләндереп алынды. Аны куе зәңгәр төскә буяп җибәрделәр. Чардуганны мәрхүмнең яраткан кияве — молдаван «мыеккае» КамАЗның РИЗ цехында үз куллары белән эшләгән.

Эчтә кабер ташы — оныкларының сөекле бабаларына соңгы бүләге. Аның өстендә яшел ай кыйпылчыгы, югары өлешенә исә кызыл йолдыз уелган. Шулай итәргә бер дә бер көнне үзенең «нәсел ботагына» әйткән булган мәрхүм...

Ләкин Туры карт каберлекнең басынкы, авыр ямен тагы да бизәүдән битәр, зиратның тынлыгын һәм туган авылының иминлеген саклау өчен җир куенына кереп ятты шикелле.

Туган туфрагы сагына...

Калдырып киткән өендә исә, тыныч, аулак сәгатьләрдә, талгын-талгын яисә дәртле-ашкынулы рәвештә, салават күпередәй матур төс-бизәкләргә манчылган моң дулкыннары тирбәлергә тотына.

Җыр инде егетнең иреннәрендә, җыр инде баян телләрендә:

Ай байрак кулларда,
Җилферди җилләрдә...
Таң булып атарбыз... их,
Туган-үскән илләрдә!..

Әлегә Әҗер ишетми, дөнья белми...

Данлы елларның онытылмаслык чыраен һәм рухын үзенчә нурландырган бу җырның, ни гомерләрдән соң яңадан терелеп, яңгырар көне алда әле. Аңа инде күп калмады.

ИКЕНЧЕ ӨЛЕШ

1

Авыллар, авыллар...

Игелекле җир...

Салмак җилләрдә тәгәрәшкән иген дулкыннары. Хәтфә болыннар өстендә балкыган салават күперләре...

Туфрак җылысы...

Яшел тугайларга сибелешкән чуар көтүләр...

Икмәк исе...

Адәмнәр куанычы...

Бары, бары да рабочком Хәнәфинең күңеле түрендә...

Күргән һәм кичергәннәре еш кына, бигрәк тә кичтөннәрен, тын алырга, йокларга яткач, кино яисә телеэкраннарда сурәтләнгән кадрлар шикелле, күз алдына килеп баса. Ул кадрларның беришесе күз ачып йомган арада йөгереп үтә, икенче төрлесе акрын һәм салмак хәрәкәтләнеп, әмма бик ачык вакыйгалар, җанлы күренешләр рәвешендә гәүдәләнә иде. Алар һәммәсе дә, әлбәттә, аның көндәлек эшләренә, тынгысыз хезмәтенә турыдан-туры бәйле иде.

Элегрәк елларда, «коп-коры» механизатор чагында, аның күз алдыннан кайтарылып ташланган һәм көн яктысында сызылып яткан буразна сыртлары, зәңгәрсу-яшел борчак яисә кукуруз басулары, комбайн шнегыннан буыла-ургыла агылган гәрәбәдәй бөртекләр, алтын ашлык көшелләре китмәс иде. Ә хәзер исә, рабочком булгач... Юк, андыйлары да күз алдына әледән-әле калкынгалый аның. Кайчакларны ул үзен басу юлы белән майлы, җегәрле кулларын селти-селти кайтып килгән рәвешләрдә күрә. Адымнары нык, саллы — җиргә ышанып һәм сөеп баса.

Ә шулай да соңгы елларда аның күз алдында күбрәк вакытта кешеләр гәүдәләнә иде.

Кешеләр...

Аз төшәме аларның йомышы рабочкомга? Хәлләренә керә бел, һәркайсы белән аңлаш-бүлеш, һәрдаим һәркемгә ярдәм кулы сузарга әзер тор!

Ә совхозның үз эшләрендә, аерата уртак хезмәттә кайнар ярышлар оештырганда? Бит монысы төбе-асылы белән аның җилкәсендә.

Ярыш... Аның тирән мәгънәсен, уртак хезмәттә һавадай кирәклеген аңламыйммы, ярышта җиңү яулауның

татлы тәмен һәм рәхәтен белмиме соң Хәнәфи? Миенә һәм канына сеңгән әйбер.

Инде менә ничә еллар рәттән ул аны үзе оештыра, ярышта җиңүчеләргә бүләкне дә, совхозның иң төп хуҗаларының берсе сыйфатында, өләшә. Җиңүчеләргә кызыгып һәм сокланып кына калмый, кайчагында алардан хәтта көнләшеп тә куйгалый. Механизатор булып эшләгән чакларын сагына, кыр-басулар иркенлегенә кабаттан кайтасы, янәдән мәңге кадерле һәм хөрмәтле игенче хезмәтенә баштанаяк чумасы килә...

Инде арылды. Йокысыз төннәре ишәйгәннән-ишәя бара.

Күз алдына һаман да кешеләр килеп баса. Үз авылдашлары, совхозларына читтән килеп төшкән халык... Һәммәсен ипләсиплә, җайла-майла, тынычландыр-урнаштыр. Эш-хезмәтләрендә дисеңме, тормыш-көнкүрешләрендә дисеңме.

Ә киеренкелек кимеми, елның елында арта гына бара кебек.

Заманасында колхоз председателе булып эшләгән, ягъни кешеләр белән эш итүдә зур тәҗрибә туплап өлгергән Ризван-агроном, шушы уңайдан гәп куертып җибәргән чакларында:

— Инде хәзер, шөкер, каршыбызда социаль-сыйнфый дошман да ысылдап тормый, күкрәгебезгә мылтык та төбәмиләр, шулай ук аулактан чыгып, баш түбәләребезгә күсәк белән дә ормыйлар... Әмма ләкин көрәшнең тукталганы юк. Тик ул хәзер тирәнгәрәк, эчкәрегәрәк күчкән: адәмнәр җаны, адәмнәрнең вөҗданы белән намусы тирәсендәрәк бара,— дип ычкындыргалый.

Аның сеңелесе Рәсүлә дә шуңа охшашлы рәвештә, әмма фикерен чагыштырулар чалмасына уратыбрак, әйтеп куйгалый:

— Шундыерак, триер-сортировка ише нәмәрсә уйлап табылса икән: аңарда, ашлыкны тазарткан сыман кешеләрне дә тиз генә җилгәртеп, тазартып булса ла икән! Кибәген кибәккә очыртып, орлыгын орлыкка бүлеп, сортын сортка! Ул чагында кемнең нигә җаравын бик әйбәт белеп булыр не,— ди, хыялый...

Кызганычка каршы, Олы төзелеш һәйбәтләп «җилгәргәндә», болар тарафына күбрәге кибәк очырта, орлыкның тазасы, берәгәйлесе тегендә, завод белән шәһәр җирендә утырып, шытым бирергә кала. Өч-дүрт ел дәверендә төзелештә эш кыйраткан булып йөреп тә, ни

хезмәтендә, ни тормыш-көнкүрешендә юнь чыгара алмаган бәндәгә ни өмет тотып була инде?

Якын тирәдәге районнардан, хәтта шактый еракларидан да, болар совхозына күченеп, урнашып алырга ниятләүчеләр килеп чыккалый. Арада, билгеле, чын адәмнәр, бик төпле, бик әйбәтләре дә булмый калмый. Әмма мондагылар хәтта андыйларга да шикләнебрәк карарга мәҗбүр иде: үз колхозында яисә совхозында хезмәттә абруй казанган, нык тамырлы, таза тормышлы адәм ансат кына туган авылыннан кубарга җыеныр һәм андыйларны хуҗалык җитәкчеләре дә җиңел генә җибәрергә теләр димени?

Мондагылар читтән килгәннәрне, әлбәттә, үзләренчә сынау аша үткәрергә тырыша. Асылда сынау җайлары бер: әхлакый саф һәм нык булып, игелекле җиргә түгә белеп түккән маңгай тирең.

Совхозда өч-дүрт ай эчендә — гадәттә ул җәен иң киеренке дәвер була — үзенең чын адәм икәнлеген тир түгеп раслый алганнарга гына Яңа поселоктагы шәп квартирага ордер тоттыралар. Күбесе шыңгырдамыйсынатмый атлап үтә әлеге киртәне. Шулай да, сирәк булса да, атлап үткәннәр арасыннан да алама җанлылар килеп чыккалый: үз теләгәннәренә ирешеп, Яңа поселокта тормыш корып җибәрүләренә, ягъни иркенәйгәч, туарыла китеп, әле тегенди, әле мондый «матур» сыйфатларын калкындырырга, шуның белән канга тоз сибәргә керешәләр. Нишлисең, андыйларны тәрбияләү ягын уйламыйча булдыра алмыйсың. Ә кайберәүләр боларның хезмәт сынавын да үтә алмый, беренче адымнарында ук абынып, авыз-борынын каната...

Бер вакыйга Хәнәфи күңеленә аерата нык уелып керде.

Рабочком сыйфатында әле беренче җәен уздыруы, кешеләр белән эш итүдә әле «пешеп өлгермәгән» чагы иде. Болар совхозына Олы төзелештән килеп, ике адәм эшкә урнашты. Хәнәфи хәзер аларның исемнәрен дә хәтерләми, хәтерләсә дә, телгә алып әйтергә теләмәс иде. Берсе колгадай озын буйлы, нәзек гәүдәле, икенчесе тап шуның киресе: тәбәнәктер, юандыр. Бу ике бәндә Олы төзелештә тегесен ошатмаганнар, бусын килештермәгәннәр икән, ә монда, болар совхозында «чын-чынлап тамыр җибәрергә бар шарты да килгән, өстәвенә, алар иген-игүне бик тә яраталар, җирнең үзенә дә зур хөрмәт белән карыйлар», имеш.

Боларны сугару эшенә билгеләделәр. Авыр һәм чете-

рекле хезмәт. Ул чакта әле «Волжанка»лар да өч бөртек кенә, «Фрегат»лар исә, кайтарылган булса да, монтажланмаган иде. Суны, торбалар сузып сиптерәсе, ягъни шактый изалар чигәсе. Бу ике адәм, шыңгырдамый-нитми, әйбәт кенә керешкән, әйбәт кенә эш җәелдергән кебек күренде әүвәл.

Ә беркөнне Хәнәфи алар эшләгән төшкә барып чыкса, исләре-акыллары китте!.. Тегеләр, нибары трусиктан гына калып, өсләреннән салып атканнар да, юан гына торбага кара-каршы атланып алган шәйгә, кәрт сугып утыралар. Байтак утырганнар, ахры: суган кишәрлекләрен тәмам су каплаган, җете карасуланып бөтерелгән ташкын эчендә исә айкала-чайкала хәтсез генә суган башлары агып ята... Тегеләрнең гамьнәрендә дә юк!

Хәнәфи, алар янына барып басуына, йөрәгенә чыдый алмыйча: — Ни кыландыруыгыз бу, адәм актыклары! — дип җикерде.— Башыгызга орып, үзегезне җиргә сендерәм бит!

Тегеләр, исләренә килеп, капыл аягүрә басты. Әмма шул мәлне колгадай гәүдәлесе, әллә аяклары оеп киткәнгә, әллә Хәнәфинең кул хәрәкәтеннән, артка таба чигенеп һәм җирдәге торбага сөрлегеп, лып иттереп юеш туфракка аркан килеп төште. Сикереп торуына, күзләрен акайтып, үзе үк Хәнәфигә җикерде:

— Әле син рабочком башың белән кул сузасыңмы? Эш өстендәме, эш кешесенәме?.. Менә синең үзеңне фәлән дә төгән...

Шул минутта гына Хәнәфи үзенең инде кем икәнлеген исенә төшерде һәм тотлыгып калды. Ярый әле, юантык бәндә, әйләнә-тирәсенә күз салгалап, үз ялгышларын аңлап алган һәм, эшне тирәнгә җибәрмәс өчен, аны йомшарту ягына таба каерырга керешкән иде:

— Юк ла инде, нишләп кул сузсын, ди, син үзең бит... Сез инде, абзый кеше... не, хата үзебездә...

Хәнәфи, беравык тотлыгып торса да, ярсуын һич киметергә теләмәде:

— Соң, аңгыра башлар, бу тиклем симез, һәйбәт туфракны булдыру өчен, ничәмә гасырлар кирәктер дип беләсез? Нормаларны бозып, шушылай коендырып ятсагыз, аны тәмамлый юып, совхозыбызны такыр әрләнбалчыкка утыртып калдырачаксыз бит! Өстегездән акт язып, җавапка тарттырам, билләһи!

— Ярар инде, абзый кеше, тирәнгә җибәрмичә генә... гаеп үзебездә, ничектер онытылып киткәнбез... Без хәзер, айн маминт рәтлибез аны!

Кызуланып әпен-төпен тотындылар: колгадае аргы башка чапты, бүрәнәдәе монда калды. Тиешле винтильләрне боргалагач, су арыдарак сузылган торбалардан сиптерә башлады. Аннары бу ике хәсрәт, кул асларында җыярдай савыт булмаганлыктан, аунап яткан күлмәкләренең җиң-изүләрен бәйләп, ташкында аккан суганны ашык-пошык җыярга керeште...

Әлеге «казалы» кишәрлектә, суганны кабаттан утыртып, аны ярыйсы гына төс-кыяфәткә кертә алдылар үзе. Аннан соң да берничә көннәр әллә ни сынатмадылар. Ләкин тора-бара каннарына сеңгән гадәт-холыклары барыбер үзенекен итте: эшкә салмыш баштан чыккаладылар, кичләрен авыл урамында да сәрхүш хәлдә күренгәләделәр... Ахырда, бер-бер артлы каты кисәтүшелтәләр алгалагач һәм монда да әллә ни эш майтара алмаячакларына бик әйбәт төшенгәч, гариза тотып конторага килделәр. Аларның кыяфәте үтә мескен һәм нәүмиз иде. Әмма болардан җәфасыз-нисез, шома гына котылгач исә:

— Дөньяда бер Чаллы гынамыни? Ысысысырда ударный төзелешләр бетмәгән и бетмәс тә! — дип, мыскыллы көлемсерәп һәм кикрик шәбәртеп, китеп бардылар. Иң әүвәл Чабаксар төбендәге трактор заводы төзелешенә, ахрысы...

Берәүләрнең бөтен ил буйлата әнә шулай җан көеге булып, сөрсенеп йөрүләре күңелгә авыр һәм кызганыч иде...

2

Зәйтүнә үзенең бәбиен кышка кергәч чатнама суыкта китерде. Аларны Чаллыдан бик кадерләп, бик саклап кына алып кайттылар.

Әтисе Рәмзи чикләрдән ашып куанды.

Бабасы Хәнәфи белән әбисе Рәсүлә дә...

Нәнечкә Вилдан дип исем куштылар.

Йомры гына, сөйкемле генә малай. Галәмәт тере. Күзләре коңгырт. Чәчләре дә, инде куера төшеп, коңгыртланып килә. Әтисе әйтә: «Сиңа охшаган»,— ди, әнисе әйтә: «Сиңа...» — ди.

Өйләре тоташтан нурга күмелде. Дөнья яме менә нидә шул!

Ике кодагый — аягоч күршеләр Рәсүлә белән Фәгыйлә карчык мондый хәлләрдә ни кылганнарын да белмәде. Кышын ике арадагы бакчаларында тирән карда сук-

мак салынды. Мунчаны әле берсе, әле икенчесе ягып җибәрә. Эсседә юындыралар, шәпәли-әвәли йомшарталар: «Ныгысын, таза-сау булып тизрәк үссен!» — диләр, бәбине әнисе Зәйтүнәгә юньләп тоттырмыйлар да...

Җәен дә бәрәңге бакчаларында сукмак өзелмәстер...

Ә яшь килен, тынмас җан, декрет ялы да бетмәс борын ук, совхоз яшелчәлегендә, атап әйткәндә, полиэтилен пленка ябмалы теплицада, җиңнәр сызганып, үзенең язгы эшләренә керәште. Яшь сабыйны, әлбәттә, ана сөтеннән өзелдерергә ярамый, Зәйтүнә, тиешле вакытында җәт кенә кайтып, имезеп китә.

Алдагы җәйне Рәсүлә совхоз эшенә чыгып йөри алмастыр да әле. Үзенең дә нияте шулайрак: «Арылды, бәби карау сылтавы белән бераз тын алырмын, ичмаса»,— ди. Аны тегендә алыштырырдай, үз кулы астында эшләп, аш-суга остарып беткән яшьрәк хатыннар берәү генә түгел, әллә ничәү инде. Алаен алай да, Рәсүлә үзе өйдә бикләнеп ятулардан гарык булмасмы, кырсәхра дәшүләренә, механизаторларны туендырып йөрүләрнең җан рәхәтен һәм хозурлыгын сагынуларга йөрәге түзәрме? Мөгаен, түзә алмастыр...

Аны үз өендә дә алмаштырырдай җай-юнь бөтенләй үк юк түгел бит: аягоч күршесе Фәгыйлә карчык бәби карарга үлепләр тора. «Җил дә тидертмәм!» — ди.

Бу да түгел, үз кызлары Рәмиләнең дә хәле хәлләнеп килә: ул инде икенчесенә узарга өлгергән — көмәне әллә кайлардан ук беленеп тора. Карасу йөзенең сизелер-сизелмәс сипкелләрдә чәчәкләнүе дә, янә бер затның дөньяга килергә ниятләп, җан җитлектереп ятуын күрсәтә. Ире Женя Мында — молдаван «мыеккае» аңа әледән-әле:

— Квартирда япа-ялгызым калсам соң... Курыкма, үлмәм дә, югалмам да... Ә монда авыл һавасы, авыл тынычлыгы синең үзеңә дә, «туачагыбызга» дә әкәмәт килешер! — ди.

Алар инде хәзер «малосемейка»да интегеп ятмый: ике бүлмәле квартиралары Яңа каланың үзендә. Ишегалларында ук өр-яңа, хәйран шәп балалар бакчасы — ясле. Үз эшләренә китеп барган мәлләрендә Динәне шунда гына кертеп калдыралар.

Динәнең исә галәмәт күңелле чагы — теле ачылып, туктаусыз чутылдап йөргән ай-көннәре. Әбисе Рәсүлә аңа:

— Син үрдәк теле ашагансыңдыр ла, кызым,— ди.

Монда, авылга кайттылар исә, Динә Вилдан яныннан китми: бишектә йоклаган чагы булса, кирәксә дә, кирәкмәсә дә, бишек тирбәтергә тотына, коляскага китереп салсалар, монысына ике куллап ябыша. Аннары әнисе Рәмиләне йөдәтергә тотына: «Әнием, үзебезгә дә бәбәй кирәк. Тизләк апкайт инде! Тик ул кыз булмасын, Вилдан булсын!» — ди, өзми дә куймый да. Әнисе, әлбәттә, озакламас, алып кайтыр, әмма җиңел машинада җилдерттереп «апкайтканы» кыз булырмы, малай булырмы, әллә ике бәхет бергә килерме — анысын Динә-чәчнәби әлегә белми.

Шулай инде, карау-тәрбияләүләре ни кыен, ни мәшәкатьле булмасын, өеңдә бала-нарасый авазлары яңгырап, алар итәк-чабуларыңа чытырдап ябышкан шәйгә шыңшый-чиный йөреп ятсалар, дөньяларың бөтенләй бүтәнчә нурлана шул!

Көтә торгач, ниһаять, ике җәһәттән дә бабай булып алган рабочком Хәнәфи дә, совхоз эшләрен кайгыртып йөргән җирләреннән ни кырысланып, ни зәһәрләнеп кайтмасын, алгы өйдә чишенеп, түр якка үтүенә, какча яңакларын җәелдереп, минутында балавызга әверелә дә куя.

Бишек янына килә дә, авызын бөрештереп, үзе уйлап чыгарган такмакны әйтергә тотына:

— Кояш чыкмый, көн тумас, елмаймыйча, нур булмас... неме, бәпкәчем? Тү-тү-түт! — ди.

Ләкин күркәмнең дә күркәме, мөгаен, аягоч күршеләре Фәгыйлә түти кичергәннәре булгандыр.

Соңгы вакытларда ул бөтенләй яшәреп киткән, кайсыбер елларда көз бик җылы, бик матур килгәндә чияалмагачлар кабаттан чәчәк аткандагы шикелле, күңелен-җанын шау чәчәккә күмелдереп, яшьләрчә җилкенеп һәм нурлар сибеп йөрүен белә иде.

Барысы да, әлбәттә, өченче елның җәй азагында ике яшь күңелне ярәштерү һәм кавыштыру көннәрендә купты. Шуннан соң инде Фәгыйлә түтинең галәмәт нурларда балкышы сүнү түгел, киресенчә, көчәйгәннән-көчәя генә барды кебек...

Ә Бариевлар үзләре? Бигрәк тә Рәсүлә белән Хәнәфи? Онытырлыкмы соң!

Күркәм вакыйгалар инде хәзер тәмам тыгызланып йомрыланган, укмашкан, һәм алар аны гүзәл бер хатирә-хикәят төсендә күңел түрләрендә бик кадерләп саклыйлар иде.

3

Ул көзне, көне-сәгате суккач, Хәнәфи белән Рәсүлә парлашып аягоч күршеләре Фәгыйлә түтигә «мендәрле кунак» булып килде. Аңарчы инде сернең яшерерлеге калмаган, егет белән кызның үзара вәгъдәләшүе хакында сүз-хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән, алай гынамы, кыз үзенең «туганым алмапасыннан», егет үз әти-әнисеннән кавышу-өйләнешүләре хакында сүз кузгатып, фатихаларын да алып куйган иде. Ягъни әүвәлгенең димче корткасына гына түгел, хәтта яучы-башкода булып мәшәкатьләнеп йөрүләргә дә урын калмаган — төп вазифалар, бары бергә төенләнеп, яшьләрнең ата-анасы һәм туганнары җилкәсенә аударылган иде.

Аңа тикле ни Хәнәфинең, ни Рәсүләнең беркемгә дә, беркайчан да «мендәрле кунак» булып барганы юк иде. Алар үзләренең кавышу, өйләнешүләрен алай бик бизәп, чуклы-чаклы иттереп үткәрә алмаган — сугыш арты елларының бу җәһәттән дә талканы үтә коры иде, «туй» дигәнен ничектер җиңел кулдан, ашык-пошык кына әвәләштергәннәр иде. Туйларның бизәкле-чәчәклесе, ягъни чын асыл балкышлысы, сугыш аркасында еракта, теге еллар кочагында бүленеп калган иде шул... Соңгы вакытларда исә кавышу-өйләнешүләр шәһәр җирендә генә түгел, авылда да бөтенләй бүтән төс, бүтән рәвешләрдә үткәрелә башлады. Кем ничек булдыра, кем ничек уңай һәм кулай таба. Әнә үз кызлары Рәмиләне дә бирделәр бирүен, әмма аларның никахланып язылышуы да бик еракта читтә булды, зур туйлары да кала җирендә якты кафе залында төрле төсләрдә елтырап һәм зур-зур бүләкләргә күмелдерелеп, бик тә шаулы-гөрле үтте. Тап инде замана кушканча һәм кыздырганча!.. Ләкин йола-гадәт бизәкләре дигәннән, телгә алып сөйләрдәй берәр нәрсә күңелләргә сеңеп калган булсачы!..

Ә монда исә Фәгыйләттәй өзмәстән-куймастан: «Әүвәлтенгеләрне дә тергезебрәк»,— дип, алдан ук чатнап-чытырдап торды ич. Аның кемлеген, таләбенең нык һәм какшамас икәнлеген, шулай ук кызның — өйләренә, ниһаять, бер заман кайтып төшәсе тансык җанның — кадерен һәм бәһасын бик әйбәт белгәнгә күрә, Хәнәфи белән Рәсүлә, күңелләре зәһәр кытыкланган хәлдә, уйисәп чоңгылына чуммыйча да булдыра алмады: андый чакта сынатырга ярыймыни, ил-көн алдында абруй җую килешерменни?

Ләкин алар туй йоласы җәһәтеннән, әлбәттә, бик күп

нәрсәне белми, тик чамалый гына иде. Ирле-хатынлы икәүләшеп балачакларында, ягъни сугыш алды елларында, күңелләрен үтә иләсләндергән нәрсәләрне исләренә төшереп, бик әйбәтләп хәтер янчыкларын селкештерде, аннары Рәсүлә, исләренә төшкән, абайлаган хәтлесен тагын да тирәнәйтү һәм ныгыту нияте белән, күршекүләндәге җанына якынрак булган корткалардан шактый гына нечкәлекләрне иплəп-җайлап кына төпченеп тә чыкты.

Шул сәбәпле, аягоч күршеләре Фәгыйлә түтигә «мендәрле кунак» сыйфатында барып кергән кичләрендә, алай бик югалып калырлык хәлдә түгел иделәр, хәтта, әйтергә кирәк, күңелләре саф булуы өстенә, ярыйсы ук көр һәм күтәренке иде.

Анда инде, билгеле, ян сәкегә сузып салынган йомшак киезне тойган хәлдә, шанлы көен сузып гүләгән самовар каршысында хуҗабикәнең алмадай пешеп, нурланып киткән йөзенә күз төшергәли-төшергәли ыспай-йомшаклап кына сүз җефәгеннән гәп чигәргә керешү: дөнья һәм авыл хәлләре, адәм әхвәлләре...

Һәм менә шунда, минуты җиткәнне чамалап һәм көен көенчә иттереп, гәрчә кыз белән егет арасындагы мөнәсәбәтләр төсмерләнү генә түгел, инде ап-ачык рәвештә хәл ителеп куелган булса да, әүвәлгенең шартына һәм рухына китерергә чамалый-тырыша, ягъни кинаяле төстә әйләндерә-чәбәләндерә, буласы кодагый алдында җаннары тезгән мәрҗәнне елкылдатып җибәрү...

Имештер:

— Ошбу җыйнак та, чибәр дә җортта алтын канатлы, көмеш гәүдәле бәхет кошы үсеп, житлегеп куйган, ди, әмма ул асыл кош үз бәхете өчен дә аннан да битәр бүтән берәүнең бәхетенә шулай матур, шулай бәһасыз булып үскән, ди. Ә боларда шул бәхет кошы турында хыялланып, тилмереп җөргән арысландай җегет бар, бу икене бергә кушканда гына аларның бәхетләре тәмам түгәрәкләнәчәк, ансыз бересенең асыл канатлары шәлберәеп, бөтенләй коелып калуы ихтимал, икенчесенең арысланныкыдай җөрәге сүнеп куюы ихтимал икән... Инде без, акыл иясе адәмнәр, андый җәмсезлеккә, андый хәвефкә җул куймыек, алдагыда ил-көннең бар гүзәллеге менә шул ике асыл затны тиз арада кавыштырып, мәңгегә бергә кушылдырып җибәрүдәдер — үзебез өчен дә иң изге, иң саваплы эшләрдән булыр бу...

Болай ук купшы чәчкәләндерүне карт хуҗабикә көткән идеме-юкмы, мәгәр аның йөзендәге бар җыерчык-

лары алсу ялкынга күмелде, куллары исә кабаланып чәй яңартырга үрелде... Ул, билгеле, шартына китереп, моңсуланып һәм нәүмизләнеп калырга тиеш иде, Фәгыйлә түти шулай итәргә тырышты да кебек, әмма аның җаны тәмам эреп, җиде кат күкләргә ашканлыгын тавышы аермачык сиздерде:

— Анысы хак инде: өй-җортыбызда бәхет кошкае житә җитлегеп килә инде. Тагы шунысы да хак: канатлары, чын билләһи, алтындыр, гәүдәсе көмештер, күзкәйләре гәүһәрдер... Тик җитлегеп кенә киләдер шул, үземә дә күз нурым бердәнбер генә, ансыз, һай, күңелсез, һай, томанлы булып калыр ла тормышкайларыбыз, шул сәбәпле алай бик кызулап очыртырга ниятләребез җук ие әле бөтенләй үк... Әмма ләкин ни хәл итмәк кирәк инде, чын билләһи, ата-бабаларыбыздан калган мәслихәт эшләрдәндер, җазмышларында чәчләре чәчкә бәйләнәсе дип җазылган икән, көне җиткәч, ходага шөкрана кылып, бәйләнер инде. Тик менә үзегезнең безләрне чамасыз ашыктыруларыгыз гына...

Үзе сөйли, үзенең авыз тирәсе бер җыела, ике җәелә. Күз төпләрендә саф чыктай ике бөртек яшь җемелди — әлбәттә, куанычыннан, хисләре ташып түгелүдәндер...

Ә болар соң?

Рәсүлә җаны-күңеле белән генә түгел, бар гәүдәсе, бар булганы белән үзен шулай ук әллә кайда болытлар өстендә йөзгәндәй тоя, аның купшы, чуклы-чаклы сүзләре дә нәкъ менә күкләрдә йөзгәнгә күрә генә тугандыр кебек. Ире Хәнәфи, ни җитди, ни сабыр булырга тырышмасын, барыбер ул да йомшартып киткән, ул хәтта җамаяк тәлинкәсен авызына китергән мәлендә дә, көлемсерәвен тыя алмыйча, әледән-әле:

— Ие, шулай инде... дөрестән дә...— диебрәк, ярым пышылдау аша буласы ике кодагыйның сүзен үзенчә тизрәк җупләп куярга тырыша иде.

Әйе, «башланмыш»ның бар шартын бик әйбәт китерә белделәр шикелле!

Аның соңында инде, җитдиләнә төшеп, әмма шулай ук елмаюларын сүрелдермиенчә һәм капыл куырттырмыенча, хәтфә үләнне ыспай, йомшак җил сыйпаштыргалаган рәвештәрәк иттереп кенә, әмма берүк вакытта кабат-кабат кузгатып, сөйләшеп йөрүләргә чик куярга тырышып, ягъни килешү-вәгъдәләшүне тамырыннан ябалдашына кадәр хәл итәргә ниятләп, «кавыштыру-кушылдыру» җайларын ачыклауга күчтеләр: туй мәшәкатьләредер, дәшәсе кунак-төшемдер, бүтәнедер. Әлбәт-

тә, матур йолага хилаф кылмыйча, яшәгән йортлары ни кысан булмасын, туйны кыз ягында үткәрәчәкләр, ә туй чыгымнарын исә бөтенләе белән диярлек кияү ягы күтәрәчәк — монысы бүгенге заманда алай бик аптырарлык нәрсәмени?

Ләкин бу азаккысына Фәгыйлә түти алай бик тиз эреп китәргә ашыкмады, иреннәрен капыл җыя төште:

— Син алай ук димәсәңә, кем... Хәнәфи энем. Туй казанына салырлык кына. Ием, һәр кемдин хөлендин хәленчә, дигәндәй...

— Юк, җиңгәчәй, юк,— дип кашларын биеткәләп алды Хәнәфи шул мәлне.— Аның кына көч-кодрәтләр булмасмыни безнең?

Фәгыйлә түти бу хакта кабат сүз катмады, күнә язды шикелле.

Болары бик хуп, бик мәслихәт диярлек иде. Ләкин гәп-килешүне тәмләп һәм нәфисләп вәзенләгән мәлләрендә, Фәгыйлә түти «мәһер, калым» хакында авызын ачып ник бер сүз кузгатсын! Ул «мендәрле кунакларын» зур хөрмәт белән сыйлый-көйли, бер үк вакытта үзен дә онытмыйча, ак самоварны сыгып утырганда, әле уйга тарып, әле көләчләнә китеп, үзенең бик еракларда калган яшьлек еллары дулкыннарында тирбәнүләргә күчеп куйгалый иде: имеш, «алар асыл җегетләрнең дә асылы Зәйнуллае-тулган ае белән тегеләй иттергәләгәннәр, болай кыландыргалаганнар — әкәмәтләр инде...» Әмма элегрәк көннәрдә Фәгыйлә түти, бәрәңге бакчасында очрашкач та, кичен Шилнә буена каз-үрдәк эзләргә төшкән җирләрендә тап булгач та: «Заманасында безләргә калымбаш иттереп дүрт аяклы мал тоттырган не лә»,— дип, бик ачык рәвештә төрттергәләп алган иде ич. Үз өендә табын артында исә, нәкъ менә иң кирәкле сәгатьтә, бу турыда ләм-мим. Әдәп сакларга ниятләп, артык итагатьле булырга, абруй-дәрәҗә төшермәскә теләвеннәнме? Рәсүлә сүзне үзе кузгатырга булды.

— Соң, ни бит әле, җиңгәчәй... элгәрерәк «калымбаш» диюләреңнән... дүрт аяклы мал диюләреңнән... без инде ни...— диде ул тотлыгыбрак кына.

Фәгыйлә түти челт-мелт күз йомгалады, башын кыегайта төшеп, исәпсез җыерчыклы кулы белән авыз тирәсен каплады, аннары кисәк чытыр-чатыр кеткелдәп җибәрде:

— И Рәсүлә җаныкаем, соң бит мин үз җәшьлегемне искә төшерепләр генә... Бүгенгесе көннең кешесе ни дияр? Бер рәхәтләнеп көлмәсме? Аннары килеп, ул дүрт

аяклы малны җапа-җалгызыма асрап җатулары тагы... аның авырлыгы...

Бу хикмәтнең шунысы да бар икән әле: калымбашка китерелгән малны ни сатарга, ни суярга ярамый, һич шиксез асрарга тиешлесең икән... Әмма сүз кузгатылган, шушындый тантаналы, матур әхвәлне тиешле эзенә салып утырганда, беркемнең дә күңел тарайтасы килмәс — монысында инде Хәнәфи үзе күкрәк тавышы белән ныгытыбрак мөһер басарга итте:

— Син, Фәгыйләттәй, һич кенә дә пошынма! Замანасында әртилдә уртак эшкә иң зур өлеш кerткәннәрдәнме? Инде хәзер пенсионермы? Асрарсың әле бик әйбәтләп кенә! Совхоз андыйларга булышмый калмый. Монда бит әле без үзебез дә бар... кызың, киявең тагы...

Һәм Хәнәфи, егетнең атасы да, үзе үк «башкода» да буларак, шушы күркәм һәм түгәрәк килешү-вәгъдәләшүнең азагы иттереп, дөресе, аның төпле һәм ныклы икәнлеген раслау нияте белән, икенче көннең кичендә үк кыш туып, инде яз-җәйләрне уздырган тана бозавының көтүдән кайтуын гына көтте дә, аны үз ихатасында соң мәртәбә туйганчы ашаткач-эчерткәч, әле көн яктысында, кояш баеганчы ук муенчаклап, тыкрык сукмагы белән аягоч күршесенә илтеп куйды. Бозау шактый гәүдәле иде, җитмәсә, төсе белән дә көрән-чуар иде.— Фәгыйләттәйнең элекке елларда үзе асраган сыеры төсле.

Ихатасында андый малны күрүгә, Фәгыйлә түти тәмам хәйран калып торды, ахырда, хәлне төшенеп алгач, авызы колагына җитеп:

— Сез бигрәкләр инде... Һай, бу хәтлем дә... Җарый, мең саваплар җаусын инде үзегезгә! — дия-дия, әле чырык-чарык кеткелдәде, әле тана бозауны ике куллап сыйпаштыра-сыйпаштыра «әгузе-бисмилласын» әйтеп, пышын-пышын үзе белгән догаларны укырга тотынды.

— Булгач, булгач, малның затлысы булсын, дидек инде. Игелеген күр, җиңгәчәй! — диде Хәнәфи бик тә көр тавыш белән.

Шул көннән соң ничәмә еллар дәверендә сыер малын белү түгел, аның исен дә оныткан ихата белән җылы абзарда иртә-кичләрен мөгерәү авазлары ишетелгәли башлады.

«Калымбаш»ка әверелгән көрән-чуар тана үзе, әлбәттә, берни белми, аңламый, әмма ул, берәүләрнең күңел киңлеген һәм юмартлыгын гәүдәләндергән билге төсендә, Түбән очта гына түгел, бөтен Әҗердә мактальп адәмнәр теленә керде...

4

Ә туй үзе?

Башта ук Фәгыйлә түти:

— Бүгенгенең кызыгы ни? Кала җирендә дә шул, авыл җирендә дә шул: әфтәмәбилгә тасмалар бәйләп, маңгаена курчаклар утыртып бик хәтәр җилдертеп җөргән булалар да җөрүен... Күркәмлеге безнең җәшлектәгегә, әүвәлтенгегә җитәме соң? — дип тел чатнаткан иде.

Елгыр түтәй коры сүзләр белән генә чикләнмәгән, төп эше җәһәтеннән совхозда ат караучы булып исәпләнгән Мәттин агайның күңелен җайлый-майлый үз ягына аударып, аны бик җилле төстә эшкә дә керештергән иде. Совхозда, шөкер, атлар бөтенләй үк бетерелмәгән, арада бик шәпләре, күз явын алырдай елдамнары да бар иде, күңел салып, чынлап торып тотынсаң, тузыптаушалып бетә язган тарантасларны да рәтләп була, инде жете карага буяп та җибәрсәң, бөтенләй өр-яңа диярлек кыяфәтләргә кертергә мөмкин икән. Ә инде дуга-камыт, сбруй-мазарын да төзәтәсен төзәттереп, майлап һәм ялтыратып куйсаң, экәмәтләр була икән.

— Моңарга атны түгел, үзең җигелеп чабарлык булган ласа! Чир-сырхауларны белмиенчә, меңнәр җәшә, Мәттин гөликәем! — дип, Фәгыйләттәй останы һаваларга чөеп мактап та алды хәтта.— Туйның да түрендә булырсың, алла боерса.

— Тырышканым хөр җәшьлек хакына инде. Туйлары туйча, тап байларча булсын дигәннәрдән инде! — диде тегесе, бик тә кәефле төстә булмаган мыек чолгыйларын бөтерә-бөтерә.

Яшьләр билгеләнгән көннең тиешле сәгатендә, Мәттин агай зур тырышлык белән хәстәрләгән зур бүләккә, ягъни жете-кара төстә елтырап торган ике тарантаска, болар артына тагы өченчесенә — тимер ходлы җыйнак кына арбага — утырышып, шаулый-гөрли авыл Советына киттеләр. Атларның сбруйлары чуклы-чәчәкле, ялларына төрле төсләрдәге тасмалар үрелгән, ә кызыл башлы ак сөлгеләр ураулы текә дугаларда исә көмеш авазлар белән җиз кыңгыраулар чыңлый, оста куллардагы баян, гармуннардан сызылып-дәртсенеп һәм дулкын-дулкын тирбәлеп җанга татлы көйләр тарала. Бер арада Әҗер урамнары әллә нишләп китте, әллә нишләп торды.

Тегендә, авыл Советында, акыллы сүзләрне, матур киңәш һәм үгет-нәсихәтләрне тыңлый-тыңлый, закон

кушканны тиешенчә җиренә җиткереп түгәрәкләп куйгач, яшьләр уйный-шаулый, җырлый-гөрли Әҗер урамнарыннан янә әйләнделәр. Аннары, моның белән генә дә канәгатьләнмичә, авыл кысанлыгыннан киң яран-сәхраларга ургылып чыктылар.

Ел тәүлеге сентябрьнең икенче яртысына авышкан чагы булса да, көн аяз, һава тын, дөнья нурлы иде.

Туган авылы басуларында — яшелчәлектә — дистәләгән автомашина һәм трактор, йөзәрләгән халык: үз хезмәттәшләре, ярдәмгә килгән камазчылар, төзелеш училищесы һәм автомобиль техникумы студентлары, мәктәп укучылары — адәмнәрдән төрле төсләрдә балкыган җанлы чәчәкләр.

Чуклы-бизәкле туй атлары элдерткән уңайда җиз кыңгырауларның көмеш чыңы, сыздырып уйнаган гармун моңнары, җыр-көйләр, чикләрне белмичә, басу-кырлар буйлап әллә кайларга тарала.

Басудагы «җанлы чәчәкләр» баш калкыта. Читтән килгән ят адәмнәр бермәл гаҗәпләнеп тора, аннары, хәлне төшенеп алгач, һавага сокланулы авазларын сибелдерә:

— Туйлар чаба ла... туйлар!

— Күрегезче бизәкле атларын!

— Ә кыңгырау чыңнары! Уйнау-җырлаулары... һай гыналар!

Үз кешеләре, бүген авылда ни кубасын бик әйбәт белсәләр дә, эсәрләнүләрен һич тыенкылатмыйча, башларыннан сыпырып алып, яулык болгарга, куллар изәргә тотына:

— Хәерле сәгатьләрдә-әү! Ак бәхетләр җаусын!

— Тигезлек белән тиң-тиңнәрчә җәшәргә җазган булсын!

Ничәмә дистә еллар дәверендә мондый күркәм тамашаны күрмәгән, ишетмәгән сәхралар, җәйран вә вәйран булып, тын кысып калган сыман иде.

Алай гынамы, күк булып күк, яшьләргә олы куанычлар китерергә, аларга ак бәхетләр теләргә ниятләп, шушындый көннең туасын сабырланып көткән һәм, шул сәбәпле, менә ниһаять көне җиткәч, чалт аязланып, зәңгәр тирәнлегеннән алтын кояш нурларын мул иттереп сиптерергә тотынган иде.

Дөнья йөзе, чын әгәр, чиксез сөйкемле һәм куанычлы иде...

Соңыннан, кичен дә, төнен дә, җиз кыңгырауларның көмеш чыңы Әҗер урамнарында тынып тормады.

Бөтен авыл купты сыман...

Әлбәттә, Фәгыйлә түтинең бәләкәй өе җыелган кунак-төшемне сыйдырырлык түгел иде. Туй мәҗлесен, шул сәбәпле, аның ихатасында, йомшак чирәмле ишегалдында корып җибәрделәр. Өй һәм келәт кыекларына, колга башларына эленгән электр лампалары, караңгылык элпәсен ертып, нур сибеп торды. Ул да түгел, беркавым вакыт үткәч, соңга калдым ахрысы, тизрәк өлгерергә кирәк, дигән шикелле, офык артыннан ашыгып һәм куе-кызарынып тулган ай калкынып чыкты. Аннары, бераз күтәрелгәч, тәмам тынычланып һәм йөзенә дә көмеш төс иңдереп, күк гөмбәзендә хәрәкәтсез диярлек эленеп торды. Бу исә болай да күркәм кич-төнгә бертөсле серле һәм сихерле рәвеш бирде...

Туй мәҗлесе, дөнья тутырып, шаулавын, гөрләвен белде.

Аның баллы-татлы, әчеле-төчеле мул сыен авыз итеп, кәефләнмәгән кеше, бөтен Әҗер ук димик, мәгәр Түбән очта һич калмаган дадыр.

Мәҗлес күрке, әлбәттә, кияү белән кәләш иде — пар күгәрченнәр... Алар үзләрен бик иркен, әмма шул ук вакытта гаҗәп тыйнак һәм итагатьле тота иде. Алларында кояш үзе өлгерткән бихисап байлык, ләкин бу ике җан нибары татлы җимеш суыннан гына авыз иткәләде. Йөзбитләре ялкынланып яна, аз гына дым элпәсе каплаган коңгырт күзләреннән исә чиксез куаныч һәм бәхет нурлары балкый иде...

Ике кодагый, аягоч күршеләр Рәсүлә белән Фәгыйләттәйнең нурланышы да аларныкыннан әллә ни ким булмагандыр. Бу ике ут йомрысының куя арасына кереп булышырга теләүчеләр дә исәпсез иде: туган-тумачадыр, кардәш-ырудыр, күрше-күләннән җиңел сөякле киленнәрдер. Мәш килделәр. Бакчалары тоташып, арт күршеләр булып торган йортның берсендә бер нигъмәт пешсә, икенчесендә икенче төрлесе өлгерә. Шөкер, ризыклар мул, күңелләр киң — кинәнеп сыйлануыңны бел, рәхәтләнеп күңел ачуыңны бел!

Алай да төп булышчылар арасында җан биреп иң күп чапканы, иң күп тир түккәне, мөгаен, Фәгыйлә түтинең Идел яры Волгоград төбеннән туган авылына ялга кайткан улы Мөнир белән килене Гөлгенә булгандыр. Аерата бу соңгысы — Казан арты, Дөбъяз кызы...

Нәкъ менә шул уңган-булган киленнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, Фәгыйлә түтинең, бәләкәй генә өе белән ихатасы ни арада ялт иттерелгән, нәкъ шул көр, күңел-

ле, елгыр килен җитәкчелегендә, әлбәттә, кайнанасының өйрәтүе һәм күзәтчелеге астында: яшь кәләшнең дус кызлары дүрт куллап ак келәтне юып, җыештырып алган, аны бирнә әйберләре белән зиннәтләп бизәгән, анда пар урындык, бер өстәл куеп, ике яшь күңелгә аулакта куана-сөенә, тыела-ымсына чәй эчәргә, көмеш самоварлы табын хәстәреп күргән иде. Ул да түгел, инде монысында Гөлгенә килен җылы, йомшак куллары белән нәфис чаршау-чыбылдыклар эленмәле, киң караватка катлам-катлам ястык-юрганнар җәеп, мендәрләр өеп, «рәхәткә» ятак урыны әзерләп куйган, бу да җитмәсә, күршедән бер йомры, тупырдык малай-нәнечне табып, аны әлеге йомшак ятакта бер туйганчы елмайта-кинәндерә аунатып алган иде.

Монысы аерата күңелле һәм кызык булды. Гөлгенә малай-нәнечне көлдерә-чиелдата аунатуын белә, үзе баллы авызыннан, йомшак көйләп, такмак сибелдерә:

Тупыр-тупыр, әл-лием,
Депер-депер, гөл-лием.
Ике тиңнең баласы-у,
Ак бәхетләр алмасы-у...
    Теф, теф, күзләр тия күрмәсен!
Тупыр-тупыр, әллүр бу,
Депер-депер, бәллүр бу.
Яшәү нуры күзләрдә-ү,
Дөнья яме безләрдә-ү...
    Иеме, нәнечкәем?
    Теф, теф...

Ак келәттә Гөлгенәнең кул арасына кереп йөргән кыпшы күкрәкле, сылу гына бер кызый да бар иде — кәләшнең «дустымы». Әлбәттә, ул биредә бу төнне ни буласын бик әйбәт белә, аның бар нечкәлекләрен бөтен күңеле белән үзенчә кичереп тора иде. Инде күп кәтәсе калмагандыр, аның үзенең дә шушындый серле һәм татлы киче-төне килердер. Әлбәттә, килер!.. Җаны артык кытыкланып китәнгәме, кызый дымлы алсу иреннәрен бик матур иттереп кыймылдатып алды:

— Әкәмәтләр инде, әйгеләрем!

Шул минутта, артык нечкәргән уй-хисләрнең оялтуыннан ахры, үзенең бит урталары янып та чыкты... Һәм ул яшьлек дусты хөрмәтенә матур кабартып хәстәрләнгән ястыкның зәңгәрсу япмасына иплап кенә ап-ал төстәге ике чәчәк куйды...

Алда иң олысы һәм хикмәтлесе көтелә — зөфаф төне...

Иртән баш калкытуларына исә «кияү мунчасы»...

Аягоч күршесенең ак келәтенә атна-ун көнләп «кияүләп» йөрде шулай бәхете дәрья булып ташыган адәмнәрдән берәү...

Ләкин матур йоланың ахыргы чиге түгел иде бу. Ибен-көен китереп килен төшерәселәре бар әле. Кызыл башлы ак сөлгеләр, төрле төстәге тасмаларга бизәлгән, җиз кыңгыраулы, көмеш чыңлы туй атлары кабаттан кирәк булды.

Монысында һаман да шул Фәгыйлә түтинең сабыр, нәзакәтле өйрәтүләре, җылы үгет-нәсихәтләре һәм барыннан да бигрәк: «Хәерле сәгатьләрдә! Зур куанычлар белән сау-сәламәт җәшәп, зур бәхетләр җаварга җазган булсын үзегезгә!» — дип әйтелгән изге теләкләре астында, туй атлары ишегалдыннан ыргылып кына урамга чыктылар да, капыл уңга каерылып, гөлдери-чыңлый Югары очка таба элдерттеләр.

Авыл урамнары янәдән гармун моңнарына, җырга, күңелле-шат авазларга күмелде.

Әнә шулай шаулый-гөрли Әҗер урамнарын ике-өч әйләнгәч кенә, кояшка таба борыла килеп, төп нигезләре Бариевлар йортына якынлаштылар.

Менә шулчагында инде капка төпләрендә, туй атларын яман өркетеп, шарт та шорт мылтык аткан тавышлар яңгырады. Моны, әлбәттә, туйның иң хөрмәтле, иң атаулы кешеләреннән берсе Мәттин агай оештырган иде. Мылтык шартлаулары тынуга, аның тамак төбеннән гайрәт белән чыккан үз тавышы да һаваны дерелдәтеп алды:

— Шулай ул! Килен ни чибәр, ни затлы булмасын, аңа ияреп иблис өшкергән кара рухлар йортка үтә күрмәсен, җыен җен-пәриләр тышта бүленеп калсын! Иеме, дим, җәмәгать!

Шаулатып-гөрләтеп бер көлешеп алдылар. Ләкин мылтыкчылардан бер-ике егет, могтәбәр агай сүзе белән генә канәгатьләнмичә, ашыга-кабалана янә мылтык корырга тотынды:

— Ә бусылары туасы нәниләре хакына!

Янә шарт та шорт, шарт та шорт!.. Ничәне тудырырга тиешләр соң болар? Санаган кеше булмады.

Аннары капыл гына тынып калдылар.

Туй атлары инде Бариевларның киң ихатасына кереп тулган, анда тантананың иң күркәме һәм нәфисе көтелә иде.

Сулышлар кысылды. Дистәләгән пар күз ымсынып шул тарафка төбәлде.

Ил-көн арасында Рәсүлә, әлбәттә, йөзенә кызыллык китерергә теләмәде. Ул бик күп нәрсәне белеп һәм үзләштереп алырга өлгергән иде инде. Улы Рәмзи белән килене Зәйтүнә утырган баш ат, тарантасың уң ягы белән болдыр турысына китереп тукталгач, йортның өлкән хуҗабикәсе, килен иң әүвәл аяк басасы төшкә миндәр куеп, аңа җиргә төшәргә булышты, аннары болдыр баскычына сузып салынган кызыл каймалы яшел паласка бастыра-бастыра өскә ияртеп алып менгәч, күптән тансыклаган җанның өй бусагасыннан уң аягы белән атлап керүенә нурланып күз салды.

— Әйдә, изге сәгатьләрдә, төкле аякларың белән, гөлием,— диде.

Улы-килене әле тарантаста чакта ук алар белән шулай ук ике куллап, бик тә җылы иттереп күрешеп алган Хәнәфи исә, бу соңгысына бик катышмыйча, ягъни килен каршылау җайларын хатын ирегенә куеп, өйгә иң азактан атлап кергән иде, әмма ул да какча яңакларын хәтәр җәйгән көенчә, җылы-йомшак тавыш белән:

— Матурга, ак бәхетләргә булсын! — дип өстәп куйды.

Моның соңында Рәсүлә үзе махсус пешергән түгәрәк ак күмәчнең кибән башын гына кисеп алып, аңа мул иттереп бал-май якты да аны килененең уң кулына тоттырды, сулына исә куе иттереп, сөтләп-каймаклап ясалган чәй тустаганын сузды. Бит алмалары кызарып пешеп чыккан килен шулай алгы өйләрендә аяк өсли генә тигез кара кашларын уйната-биетә, елмая-көлә ашарга, эчәргә керешге.

Ләкин ул «кибән башының» яртысына җиткәч, кинәт ашавыннан тукталды да:

— Шундый да тәмле... Мә, син дә! Бергә-бергә булсын! — дип баллы-майлы ипекәйнең дә, сөтле-каймаклы чәйнең дә калган хәтлесен авызын ерып торган ире кулына тоттырды.

Матур йоланы бозу ук булмаса да, аңа җитди генә төзәтмә иде бу. Әмма Рәсүлә бу хәлгә ачулану яисә үпкәләү түгел, киресенчә, күңеле хушланып китүен генә тойды:

— Ием, бергәнеке берәгәйле... Зур игелекләргә!

Килен кеше бу йортта иң беренче изге вазифасын шул рәвешле йомрылап куйгач, хуҗаларга татлы-баллы ризык өчен дә, җылы-мөлаем мөгамәләләре өчен дә, баш иеп, нәфис-йомшак тавыш белән зур рәхмәтен әйтте. Тик шуннан соң гына киленне алга уздырып (һәм ул, әл-

бəттə, янəдəн уң аягы белəн җиңел атлап!) түр өйгə керделəр.

Яшь килен көннең-сəгатьнең кадерен бик белүчелəр токымыннан иде, ул вакытны һич əрəм итəргə телəмичə, үзлəре белəн бергə туй атларында китерелгəн бирнə əйберлəрен һəм туйга салынган бүлəк нəрсəлəрен кертəбушата, түр өйлəрен бизəргə тотынды. Бизəгəндə биеме Рəсүлəнең дə, ире Рəмзинең дə əйткəн киңəшлəренə колак салгандай иттерде, əмма чынлыкта күп нəрсəне барыбер үзенчə кыландырды. Кай арада түр өйлəре бөтенлəй бүтəн рəвеш алып, аңа ямь-нурның бөтенлəй бүтəн төрлесе сеңеп куйды!

Кичен, əлбəттə, мəҗлес яңадан тергезелде — килен төшерү тантанасы, зур һəм күркəм йоланың ахыргы аккорды!

Атналар артыннан атналар үтə, айлар артыннан айлар, еллар...

Кеше күңелендə керлəр кунмый тормый, юшкыннар утырмый калмый. Лəкин адəм гомерендə һичнинди керлəр һəм тузаннар кундырмый торган гүзəл бер вакыйга була, һəм ул, мəңге шиңмəс, матур төслəрен мəңге җуймас чəчəклəр букеты сыман, яшəгəн саен ныграк нурлана гына бара.

Кеше күңеле аны кадерлəп саклый, аны мəңге сагына...

Югыйсə дөнья бик ямьсез булыр, хəтта кысырланып калыр иде... Ə Бариевлар нигезендə бүген ул зур яңарышның, ул матур чəчəклəр букетының беренче татлы җимеше булып, бишектə нəни тирбəлə. Ана сөтен даулап, шыңгырдый-еламсырый, максатына ирешеп, бер туйганчы рəхəтлəнгəч, кинəнеп тибенə, елмая, балкый.

Тышта исə кыш, юк, менə инде яз котыра. Тəрəзə өлгелəрен зеңгелдəтеп кырыс, дымлы җил бəрелə. Түбə бозларыннан тамчылар тама...

Юк, алар да əллə ни ачулы һəм ярсулы түгел шикелле, бишектə тирбəлгəн бəбине:

— Əйдə, җəтрəк бул инде: ел үсəреңне ай үс, ай үсəреңне атна үс! Синсез дөньялар дөнья булмас! — дип ашыктыралар, үрсəлəндерəлəр генə кебек.

5

Əмма күркəм яңарыш һəм үзгəреш бер Бариевлар нигезенə генə кагылдымы соң?

Чал чəчле, йомры гəүдəле карчык куптарган бəрə-

кәтле җил Бариевлар йортын, хәтта Түбән очны гына түгел, бөтен Әҗер авылын селкетеп-тирбәлдереп алды ла!

Киң колач белән җиренә җиткереп, матурлап үткәрелгән туй йоласы хикмәтләре авылда озаклап һәм тәмләп сөйләр өчен әкәмәт шәп азык булды.

Әле алай гынамы!

Совхозның ат караучысы Мәттйн агай авылда иң кадерле, иң абруйлы кешегә әверелде. Атларны бик әйбәтләп карап-тәрбияләп, аларны гелән дә елкылдатып торуларын әйткән дә юк, ул әүвәлге, тузган тарантасларны төзәткәләп, адәм карар кыяфәткә керту белән генә чикләнмәде: каяндыр, Ык буенда утырган авылларның берсеннән, ахры, зифа тал чыбыкларыннан менә дигән иттереп үрелгән өр-яңа тарантас кәрзиннәре алып кайтты. Аларны чем-карага буяттырды, ныгытып һәм матурлап урнаштырды. Ә кыш өчен? Бусын да онытмады: кошовкалар ясаттырды, берсен — кияү белән кәләшкә дип аталганын — хәтта кимәле иттерде.

Мактамый чараң да юк: нибары бер-ике ел эчендә, җәен-көзен дә, кышын-язын да, инде әллә ничә яшь пар олы һәм күркәм йоланы үзләренчә киң колачлап, килештеребрәк үткәрергә җыенган чакларында:

— Рәмзи белән Зәйтүнә туе кебек булсын! — диләр.

— Җиз кыңгыраулар чыңласын! — диләр.

Матур бизәлгән, җиз кыңгыраулы туй атлары ничәмә тапкыр инде Әҗер урамнарына ямьле нурлар сибеп, аларны көмеш чыңнарга коендырып йөрде...

Инде Айдашныкы да әллә ни озакламастыр. Ык буеның Тау асты Байлар авылында туып үскән, ярыйсы гына чибәр, әмма аз гына нәзберегрәк, үҗәтрәк холыклы «мәхәббәт алмасы», тамырына шифалы сулар сибә, күнел сабакларына җылы һавалар өрдерә торгач, ниһаять, чәчәккә бөреләнгән, инде бөресеннән чәчәк аттырырга да җыена шикелле. Аларның туен да, әлбәттә, шулай иттерерләр!

Ә Фәгыйлә түтинең үз нигезендәге хәлләр?

Улы Мөнир тәвәккәл йөрәкле адәмнәрдән икән. Ул элегрәк кайткан чакларында да туган авылын сагынуларын аз сөйләмәгән, мондагы яңарыш-үзгәрешкә дә күз нурландырмый калмаган иде шикелле. Кадерле әтисеннән калган тәп йортта һич уйламаганда туй ялкыны дөрләве исә аның канын ахыргача кыздырып җибәргән, күрәмсең, ул хәтта кем беләндер бәхәскә дә кергән бугай... Һәм ел азагында, ике уйлап тормастан һәм кышка

кергән чак та димиенчә, гаиләсе белән өелешеп, туган авылына кайтып төште. Бәтенләйгә! Тегендә, Волгоград каласы төбендәге уңайлы квартирасын, әйбәт кенә эшен калдырып...

Былтыр җәй ул иске, бәләкәй өйнең сипләтердәй төшләрен сипләтеп, түбәсен яңарткач, аның ян кырыена бүрәнәләрдән җылы бүлемте — веранда сыман нәрсә әмәлләп куйды (Әҗердә әле һаман өр-яңа бура бурап йорт салырга рөхсәт ителмәгән иде). Аннары каралтыкурасына ябышты. Ябышмаска, кош-корт шактый ишле, сарыклар да әллә ничәү, аннан да бигрәк «калымбаш» тана бар — бу көрән-чуар малкай инде буаз булырга да өлгергән иде.

Ил азатлыгы хакына шәһит киткән әтисенең җылысын ничәмә дистә еллар буе сибелдерми-чәчелдерми саклап килгән төп йортының бәрәкәтле туфрагында — әнисе Фәгыйлә түтинең чиксез куанычына һәм бәхетенә — тормыш шул рәвешле яңа тамырлар җибәрде, яңа туйралар тибендерергә әзерләнде...

Совхозга да оста куллы автомеханик бик тә ярап куйды.

Ә йомшак җанлы, көр күңелле хатыны Гөлгенә исә... Ул тегендә тәрбияче булып эшләгән икән, ә монда Яңа поселокта өр-яңа балалар бакчасы ачып җибәргән айкөннәр иде. Бусы инде совхоз өчен кисеп куелган әзер ипи телеменә атлан май ягып җибәргән шикелле булды да куйды!

Әмма хикмәтнең тагын да әкәмәтлерәк, нечкәрәк һәм яшертенрәк ягы да бар булып чыкты — монысы әле бик күптән түгел, шушы язга кергәч беленде.

Мөнир белән Гөлгенәнең гаиләсе инде тәмам түгәрәкләнгән сыман иде, ике балалары бар — кызлары бу елны җиденчедә, малайлары дүртенчедә укый. Тегендә чагында Гөлгенә бүтән үрчемәскә, ишәймәскә дип, кырт кисеп тә куйган булган. Ләкин монда исә... авылның шифалы һавасы килеште микән, торган нигез туфраклары җилкендерде микән, мәгәр бу ир белән хатынның Әҗер авылын тагын да баетып җибәрү юнәлешендә күңелләре бер заман кымырҗылап алганлыгы хак.

— Болай иртә картаерга ярамас, тагын бер «кояшланмыйча» булмас! — дигән ди, имеш, Гөлгенә-баллы тел...

Көмәне инде Рәмиләнеке чамасындарак, котылулары да, мөгаен, бер тирәдәрәк, җәй урталарындарак булырдыр...

Гомер сөрмешнең җылы учагы да, якты өметләр һәм ак бәхетләр йомрысы да булган гаилә тормышында әллә нинди кызыклы һәм серле хәлләр туып торгалый инде шулай...

6

Әтисе дә, әнисе дә төпчек уллары Рәмзинең холкын бик әйбәт белә иде: күп сөйләшмәс, берәр эшкә керешәсе булса, җиде кат уйлар, бер кат кисәр, инде кисеп куйса, җиренә җиткерергә тырышыр. Кешеләр белән мөгамәләдә дә кубып бәрелмәс, итагатьледер, йомшактыр күңеле.

Өйләнеп, башлы-күзле булгач, Рәмзинең холык-фигылендәге итагатьлек һәм йомшаклык сыйфатлары тагын да нечкәребрәк китте сыман: хатыны Зәйтүнә янында һаман да гөлдер-гөлдер генә, күзләрендә дә мөлаем, сөйкемле караш һич тоныкланмый иде. Ә инде хәләл җефете аңа тупырдап торган тансык җанны да бүләк итеп тоттыргач, бөтенләй исәргә әверелә язды адәм дигәнең. Әмма яшь ир заты бер үк вакытта әтисе белән әнисенә мөнәсәбәттә дә элгәреге җылысын, уллык хисләрен киметмәде һәм сүлпәнләндермәде шикелле: әйткән сүзләренә инсафланып колак сала, йомышларын карусыз диярлек тыңлый, тиккә сырт кабартмый.

Ләкин аның кирәк чагында, ярыйсы ук кырыс һәм каты була алуын да өйдәгеләре бик яхшы белә иде.

Шулай, аның холкы ныклыгын кабат сынап карарга теләгәндәй, бер дә бер көнне аталмыш БАМ төзелешеннән хат килеп төште. Абыйсы Вәсимнән...

Вәсим, Вәсим... Алдагы августта аның Чаллыны ташлап, читкә шылуына ике ел тула. Баштарак өн-хәбәр сиздермәгән иде. Үзенчә ныклабрак төпләнергә, җан тынычлыгын табарга эзләнеп йөрүе булган икән. Иң әүвәл Нурек ГЭСы корылышына барып чыккан, әмма анда әллә ни эш майтара алмаган, күрәмсең: ниендер ошатмыенча, яңарак кына җәелеп киткән Атоммашка, Дон даласына сыпырткан, аннан ерак Себергә, БАМ төзелешенә... Бу азаккысында менә инде елдан артык эшли икән. Җанына кыенлык эзләведер, ахры: БАМда төпләнебрәк, утырыбрак эш җимерттерергә ниятләгән шикелле... Соңгы вакытларда хатларыннан өзелдерми үзе. Әмма язганы һаман да сеңелесе Рәмилә белән энесе Рәмзи исеменә. Дөрес, әтисе белән әнисенә күп-күп сәламнәр ирештерә, хәл-әхвәлләрен сорашкандай иттерә,

шулай да... Туган туфрагында кылган теге «олы гөнаһы» хакында әлегә ләм-мим. Ни үкенү, ни ачыну-көенү, хәтта ки пошаманлык әсәре дә сиздерми. Сер бирергә теләмәвеме, әллә тәкәбберләнүеме? Ә бит туган авылы утырган Чаллы төбәген әнә шулай әллә кайлардан урап, чит-ят якларда газиз хәлләрдә әйләнгәләп йөрер-йөрер дә бер заман барыбер туган нигезенә кайтып егылыр. Егылмаса да... Юк, Вәсимне искә төшерәселәре дә килми. Теге чактагы галәмәттән купкан ачу-ярсу тузаннары кире кунып, юшкыны инде күңел төбенә утырган, алай да егетне исләренә төшерүгә үк, йөрәкләренең чәнчемәгән төше кисәк чәнчергә тотына иде. Әтисенең дә, әнисенең дә шулай...

Бу хатында ул, шактый ук киңәеп, үз әхвәлләрен, ягъни «ни зәһәр салкыннар, ни ямап бураннар, ни сазурман димиенчә, Ерак Көнчыгышта океанга таба тимердән юллар салганда, җиде кат тир түгеп тән-гәүдә чыныктыруларын язган да хатларында әле аңарчы һич телгә алмаган автомобиле язмышына күчкән: «Анда минем «Жигули» тиккә тузан җыеп, сөяк черетеп, җитмәсә, күзегезгә арпа кылчыгыдай кадалып ята торгандыр инде. Ятмасын! Мин аны сиңа, энекәш, бүләк итәм. Бер рәхәтен күреп калырсың, ичмаса! Ә минем мондагы төшемнәр бер анлык кынамы соң! Әмма хикмәт анда түгел...» — дигән. Ләкин «хикмәт нидә» икәнлеген ары аңлатмаган, өзгән. Бүләк итүенең рәсми дөреслеген раслап, түгәрәк мөһерле кагәзен дә җибәргән.

Моңа өй тутырып куанышмасалар да, өлкән Баривларның авыз тирәсе җәелә төште. Вәсимнең: «...хикмәт анда түгел» дип әйтүләре бер үзе ни тора бит!

Рәмзи исә каш җыерып, кырыс-уйчан кыяфәттә бер ноктага төбәлеп торды да теш аралый:

— Һе,—дип кенә куйды.

Ни «шәп» димәде, ни «яман» димәде.

Югыйсә мондый хәлдә бүтән берәү булсамы, куанычыннанмы?

Тәгаен ахырын көттеләр.

Бер төн кундылар, ике төн, ә Рәмзи елтыр-ялтыр иткән «Жигули» хакында әлегә ләм-мим. Зур бүләк «тоттырган» хат аңа бөтенләй килеп төшмәгән дә күк...

Ә чибәр автомобиль лапас астында шәпләп томаланган хәлендә ятуын белә: «арестованный»... Аңа килеп орыну түгел, хәлен белешкән кеше дә юк.

Искә төшерсәң, бер заман аның язмышы кыл өстендә генә калган, ул бер төнне тәмам пыран-заран туздыры-

лып ташланасы нәрсә иде, югыйсә. Һәм аны бер дә әллә кем түгел, йорт хуҗасы Хәнәфи үзе челпәрәмә ватып-җимереп ыргытырга дуамалланып купкан иде.

Бу хәл теге җәй азагында Чаллыдан алтын балдаклы-алкалы үтә чибәр «юха» килеп төшкән кичне булды. Хәнәфи, тиле баш, йөрәгенә чыдый алмыйча, караңгы төшүгә әллә кая китеп югалып торды да шул китүеннән шактый ук «шәбәреп» кайтып керде. Аның әллә ни гомерләрдән бирле шушылай ни бәйрәм, ни туй чакта «төшереп» йөргәннәре юк иде. Салган баштан төн караңгысында ишегалдында тегесен кузгатып, бусын ишелдереп ду килергә тотынды. Ахырда шәп кенә кысәк табып алды...

«Жигули» бәхетенә ярый әле:

— Шаштыңмы әллә? Машинаның ни гаебе бар? — дип, хатыны Рәсүлә аның иңнәренә асылынып өлгерде.

Ярый әле ул кичне ничектер бәйгә утыртылмыйча иректә калган карт Сарыбай, шашкан хуҗасының күкрәгенә атылып, теле белән битен яларга итенде, гүя бу акыллы җанвар да: «Җенләнмә — исеңә кил!» — дип йорт хуҗасын җәт кенә өненә китермәкче иде.

Капыл гына сүрелде тагы...

Икенче көнне тәмам тынычланган йорт башлыгының крестьян акылы һәм холкы үзенекен итте: «Жигули»ны, көпчәкләрендәге һаваны бушаткач, тумран өсләренә утыртты да аның өстен брезент япма һәм җыен иске плащ-пальтолар белән томалап куйды. Соңрак, кош-корт пычраклары үтә күрмәсен тагы дип, Рәсүлә дә «Жигули» гәүдәсенә иске-москыны өстәп ыргытты. Ни дисәң дә, мал бит, зиннәтле һәм кыйммәтле нәрсә бит!

Менә шуннан соң «арестантлары» шәпләп томаланган хәлендә лапас астының ярым-караңгысыннан көн яктысына күз чекрәйтеп тора да инде.

Аны иреккә кем иң беренче алып чыгарга итәр дә, кем руле артына иң беренче булып утырыр?

Ниһаять, Рәмзи бер көн, ике көн уйчанланып-дәшмәкиләнеп йөри торгач, өченче көнендә кичен басуда «Фрегат» монтажлап-көйләп яткан җиреннән майларга буялып, алҗып кайтып керде дә, абыйсының хатын кабат кулына алды, янә теш аралый гына: «Һе», — дип куйды, аннары:

— Андый машинада элдертеп йөрүләрнең әллә ни рәхәте булмас. Миңа аның машинасы түгел, үзе кирәк! — дип кистерде.

Ул да түгел, абыйсы тегеннән түгәрәк мөһер басты-

рып җибәргән рәсми кәгазьне ерткалап учак утына илтеп ташлады.

Әтисе белән әнисе моңа ни дип тә җавап кайтармады, тирән иттереп сулап кына куйдылар...

Ә хатыны Зәйтүнә? Үтә сәерсенгән-аптыраган хәлдә коңгырт күзләрен челт-мелт йомгалап, дымлы алсу иреннәрен турсайтты. Ихатаңда өр-яңа «Жигули» тиккә муртаеп ятканда, кемнең генә күңелен авыл урамнарыннан, кыр-сәхралардан җил-җил элдертеп йөрүләр иләсләндермәс икән? Әмма Рәмзи, хәләл җефетен нәфис хиреслектән аерып алып, минутында реаль җирлеккә бастырып куярга исәп итте:

— Безнең монда мотоцикл да җилләр уйнатырга бик шәп әле, шулай бит, Зәйтүнә? Инде тегендиенә, елыкялык килгәненә бик кызыксак, үз кодрәтебезгә таянып үрелербез, иеме?

Зәйтүнә, ни әйтсен, баш каккалап, елмайгандай иттерде...

Ул, әлбәттә, иренең хаклы икәнлеген бик абайлый иде. Мондый ир белән гомер сөрмешнең бормалы-сырмалы, чокырлы-чакырлы сукмакларыннан атлап барганда, аның нык һәм чыдам иңнәренә ышанып таяначагын бик белә иде. Шулай булгач, ничек ризалашмыйсың, ничек инде күңелең кымырҗылануын минутында бастырыклап куймыйсың ди?

Зәйтүнәнең үз холкы-фигыле исә... Әйе, бер генә дә тигез, бер генә дә шома түгел кебек. Үз атасыннан аз гына да җылы тоймыйча, үги ана кулы астында кагылыпҗәберләнеп үскәнгә күрәдер ахры, яшь киленнең холыкфигыльләре шактый ук сикәлтәле иде.

Юк, аны һич кенә дә үзсүзле, иренчәк яисә нәзберек җанлы буш куык дип әйтеп булмый. Тырышлыгы һәм кул арасына керүчәнлегенә дә тел-теш тидерә алмассың.

Рәсүлә аны күзәтү-сынаулардан туя алмый.

Бианалар шулай инде: йортларына төшкән киленне энә күзе аша үткәрүчән. Бер түбә астында ике хуҗабикә яшәгәндә, савыт-саба шалтырамый гына торыр димени? Ләкин Рәсүлә аны һич кенә дә шалтыратырга теләми, аның җыен вак-төяк ыбыр-чыбырлардан бик өстен, бик югары торасы, яшь киленне үз кызыдай күреп, тыныч һәм ипле яшисе килә. Шул сәбәпле, ул ямьсезлеккә таба үзе башлап ерганак ерып җибәрүләрне һич уена да китерми, ул үзе иң әүвәл авызына май кабарга әзер.

Аның шунысы да бар бит әле: бүгенге яшьләр, чәчләрен чәчкә бәйләүгә, озак уйлап тормый, башка чыгу

җайларын карый, ни кыен булмасын, бүтән түбә астында яшәүне кулайрак күрә. Бу җәһәттән алар совхозында форсаты да майлап куйгандай: әнә Яңа поселокта аерым яшим дисәң, квартирларны өлгертеп кенә торалар. Дөрес, әлегә анда тормыш итәр өчен кыенлыклар да шактый гына, әмма квартирлардагы бүлмәләр яктыдыр, җылыдыр, суы белән газы да кул астында гына... Читтән килгән халык кынамы, аларның Әҗереннән дә берничәләп яшь белгеч, шунда күченеп, оя корырга кереште инде. Тормышларының яшертенрәк яклары ничектер, мәгәр тыштан караганда, бик тә килештереп, бик тә һавалы кыяфәтләрдә йөриләр...

Юк, Рәсүләнең улы белән киленен анда һич кенә дә җибәрәсе килми. Аның гына түгел, ире Хәнәфинең дә... Өйләре, ниһаять, шушылай матурланып, нурланып китсен дә, кабаттан төмсә йомылуга ничек иттереп юл куясың ди? Бер нигездә, бер түбә астында, дус һәм тату булып, җырлый-гөрли яшәүләргә ни җитә!

Хәер, киленнәре Зәйтүнә дә моны бик аңлый, татулыкның, гаилә җылысының кадерен бик белә. Тик менә гомер сөрмештә кешенең тормышы нибары гаилә белән генә чикләнәмени? Аны чолгап алган мохит бар, дөнья ыгы-зыгысы бар, һәм барыннан да бигрәк хезмәте, ил күзендә йөрәк майларын суырттырып эшлисе эшләре дә бар ич әле! Зәйтүнә исә агроном-бакчачы, житмәсә, бик яшь әле, тәҗрибәсе бик тә чамалы...

7

Тырышмыйлар-тырмашмыйлар түгел. Иртә яздан башлап көзнең дөм сукыр көненә тикле ялан кырда-басуда. Кояшта-җилдә йөзләре көеп-каралып, чуар «киндерләнеп» бетә, бармаклары-куллары чебили, кытыршылана, кич-төннәрен билләре сызлап йөдәтә, алай да чыдыйлар, сер бирмиләр. Һәр звенода шулай. «Мул булып үссен-өлгерсен, КамАЗ төзүчеләренең дә, завод халкының да табынына менеп, тамакларына тәмле ризык булып үтсен!» — диләр.

Куандырган көннәре аз булмый. Иске Чаллы белән КамГЭС поселогыннан да, Яңа каладан да матур хәбәрләр кайчакларны дулкын-дулкын тәгәрәп кайткалый. Бариевлар йортына андыйны гадәттә кияүләре Женя Мында белән кызлары Рәмилә, өлкән уллары Айдаш ташый.

— Үзебезнең совхозныкы икәнен әллә каян таный-

быз. Танымаска, үз җирләребездә үзебезнең кешеләр үстергән ләсә! Кыяры да, помидоры да шундый тәмле, шундый әйбәт! — диләр.

— Анда инде кибет эчләрендә яисә палаткаларда гынамы, хәтта урамнарда, чат башларында да саталар яшелчәне. Җинәнә, ичмаса, Чаллы халкы! — диләр.

Күңелле сүз, матур хәбәр... Мондые кыяр белән помидор, шулай ук кыяклы яки башлы суган хакында әйтелә. Болары үтемле: халык ябырылып ала. Тик яшелчәнең бүтән төрлесе дә бар бит әле: чөгендер белән кишердер, кәбестәдер... Һай, болары белән күргәннәре!

Ә бит югыйсә яшелчәнең андые да ел тәүлегендә кирәк, андые да кибетләрдә өзлексез булып торырга тиеш ләбаса!

Былтыр кишерне җыеп тапшыргандагы хәлне генә исеңә төшер. Галәмәт уңган — үзе юандыр, беләк буедыр, әкәмәт сусыл һәм тәмле иде кишерләре.

Башта бик куанганнар иде. Аны Чаллыдагы сәүдә оешмасына атна буе ташыдылар. Мондый хәлнең аңарчы булганы юк иде әле: кып-кызыл кишер төягән машиналар бер-бер артлы китә торды, китә торды... Аннары: «Булды, таулар өелде инде, җитте!» — дип капыл туктаттылар. Тагын берәр атна чамасы вакыт узгач, Чаллыдан ике иякле, түгәрәк йөзле бер адәм килеп төште. Кызарынып, бүртенеп... Койрыгына басканнар, күрәмсең. Анда ачык һавага тау-тау өелгән кишерне ни сәүдә челтәренә сатуга таратмаганнар, ни саклауга куймаганнар икән. Төннәрен салкынча, көндезләрен исә кояш кыздыра, кишерләре тәмам бозылып, пәлҗерәп беткән. Җишергә күп кирәкмени? Мондагылар ах итте.

Ә ул бәндә, аптыраган үрдәк арты белән суга чума дигәндәй, үзен аклар өчен, гаеп эзләп килгән икән: янәсе, болар басуыннан шундый бозык кишер җибәрелеп торган...

Кишер плантациясендә, төп яшелчәчеләрдән тыш, мәктәп укучылары белән техникум студентлары да шактый гына иде, совхоз директоры Акбашев менә шулар алдында әлеге адәмне җиде бабасына җитеп әрләп ташлады:

— Каян килсен безгә пәлҗерәгән нәмәрсәләр! Казыган, җыйган хәтлесен озата барабыз лабаса! Мә, кулларыңа тотып кара, тешләрең белән киртләп кара: мондыен кишер белән башыңа орсам, җиргә сеңәсен бит, җан көеге! Йөрмә, ичмаса, басуыбызны пычратып, менә боларның күңелен җәрәхәтләп!

Халык контроле кишердәй кып-кызыл йөзле, ике ияге астына хәтәр зур галстук элгән ул «җаваплы адәмне» нишләткәндер, белмәделәр. Мәгәр ул болар совхозына бүтән килеп йөрмәде. Алай бик хәсрәтләнерлек тә түгел иде кебек: совхоз зыян күрмәгән, тапшырылган ризык өчен күчереләсе акча һичшиксез күчереләчәк иде. Шулай да ул көннәрдә директор Акбашев та, баш агроном Ризван да, бүтәннәр дә кара көеп йөрде. Ләкин яшелчәчеләр арасында иң авыр кичергәне, иң үрсәләнгәне, мөгаен, яшь агроном, Бариевлар килене Зәйтүнә булгандыр. Шул кичне ул, төп хуҗаларның аңарчы да күпне күргән болдырларына утырып, инде беленә башлаган көмәнен кочкан шәйгә, үксеп-үксеп күз яшьләрен койды, бахыр:

— Шул тиклем бит, шул тиклем! Ничәмә дистә машина, ничәмә гектар җирләрдән җыеп алган уңыш бит! Берәүнең дә тамагына кермәсен әле! Ә без монда, көн дими, төн дими, чиләнеп...

Шулай инде: берәүләрнең гамьсезлеге һәм булдыксызлыгы икенче җирләрдә икенче берәүләрнең йөрәгенә ук булып кадала...

Шушы ел, ярый ичмаса, җиңел сулыш китерде, дересе, вәгъдә итте. Партиянең шәһәр комитеты проблеманы куптара-кымтырыклый торгач, ниһаять, үз максатына ирешкән: бу елдан Чаллыда әллә ничә мең тонналарга исәпләнгән җиләк-җимеш һәм яшелчә комбинаты салырга тотыначаклар, ди. Бу хакта — агропромышленность берләшмәсенең һавадай хаҗәт булуы хакында — сүзләр күптәннән йөри, хәтта Украинага барып тәҗрибә дә җыеп кайтканнары булган иде. Ниһаять, төбе-тамыры белән кузгатылган икән! Ул, билгеле, хуҗалыкара кооперация нигезләренә корылып, ышанычлы арадашчы буласы, ди, анда инде яшелчәнең тоннасы түгел, хәтта килосы да әрәмгә китмәячәк, ди.

— Менә, ичмаса... куанасыларыбыз бар икән әле,— диде Зәйтүнә, бу хәбәрне ишеткәч, авызын бер җәеп, бер җыеп, аннары йөзенә янә күләгә йөгертте.— Тик кайчан корылып бетә бит әле ул? Аңарчы тагымы?

— Җә, җә, өметсез шайтан булмыйк! Йолдызның кабынып, балкый башлавы әйбәт,— диде аңа Рәмзи.

Ул күңелгә күләгә йөгертүләрне һич өнәми иде.

Моңа охшашлы сөйләшүләр, көндезләрен эш арасында да, кичләрен тын алган чакларында да эледән-эле кубып торгалый иде. Хәтта кайчакларны төннәрен, баш-

ларын йомшак мендәргә салгач та, дөнья хикмәтләре хакында телләренә сүз килми калмас иде.

Хәер, төннәрен бишектә яткан Вилдан уяныл киткәли. Әнисе аны күтәреп ала да үзләре янына уртага сала. Сала да кайнар күкрәген чыгарып нәнечено төртә. Бәби чмөк-чмөк иттереп имәргә тотына.

Асыл куанычлары да, юанычлары да...

Яшь ана белән ата тынып кала — дөнья хәлләре, тормыш мәшәкатьләре каядыр артка чигенә, таралып югалгандай була...

Шулай да Рәмзи, бер кулы белән хатынының нәфис чәчен сыйпаштырып, икенчесе белән улы-нәнечнең йомшак, җылы гәүдәсен иркәләгән шәйгә, куанычлы пышылдау аша:

— Әйдә, улым, бер тотынгач, соңгы тамчысына тикле сыгып бетер инде! Замана белән ярыша-ярыша дөньялар куганда, синең тизрәк үсеп, кул араларга керүләрең бик кирәк шул... бик тә кирәк! — дип куйгалый. Кайчакларда исә шулай ук пышылдап, әмма тавышына серле-шаяртулы төсмер биреп, сорау белән төбәлә: — Үскәч, этиең кебек җирдә яңгыр яудыру «алласы» булырга ниятләрең юкмы соң, улым, ә? — ди.

Бәби үтә тырышып, үтә тәмләп ими имгән җирендә, капыл тукталып, колак сагайта. Әллә, бермәл тын алып, хәл җыюы, әллә дөнья хәлләрен аңларга тырышуы нарасыйның...

8

Совхозларында эшче куллар җитмәүдән әле һаман зур кыенлыклар кичерә иде. Өстәвенә, данлы Чаллы тарафларыннан әледән-әле: «Төзелештә күрәп-күрәп акча каерырга җайлар туып торганда, моңа кушып, хәйран да шәп фатирлар өләшкән мәлләрдә, ни пычагыма дип авылда черешеп ятарга?» — дигән, боларның яман да ачуын китереп, тәмам ярсыткан коткы сүзләрне дә ишеткәләрләр иде. Әле ул гынамы, бөтенләй чыгырдан чыгарырдае да колакларына эленгәләр иде: имештер, әлеге яман коткыны, дусларча киңәш-табыш чапанына төрелдереп, бер дә әллә кем түгел, Яхъя Таипыч үзе таратып ята, ди... Совхозның элеккеге директоры Таиповны якыннан белгән кешеләр, әлбәттә, моңа ышанмады: шундый абруйлы, шундый дәрәҗәле кеше андый түбәнлеккә төшәр димени? Ярый әле андый хыянәтне Яхъя Таипыч үзе ишетми, белми яткан....

Тора торгач, әлеге коткының җеп очы кемдә икәнлеген аермачык белделәр: Әҗернең элгәреге управляющие, «таш бәгырь» Гарапша икән лә!.. Ни җитми кешегә?

Югыйсә, җаны алгысып торганга ирешкән бит инде: Камснаб тикле Камснабка барып оялаган, машиналар алып, гаражлар салдырган, квартирасында хәйран, диләр — үз күлендә үзе теләгәнчә йөзә бирә... Каракайлыкның шушындый төсендәгесе, үз туган авылыңнан үч алу, аңа яманлык кылу рәвешендәгесе дә, була микәнни?

Үч алу, яманлык кылу дигәннән, аның тагы һич уйгаискә китермәстәе дә туа икән: Гарапша кала җирендә тамырларны тирән җибәргән, киң җәелдергән, ә әйләнә-тирәдә исә «коры закон» — хәмер яратучылар тилмерә... Авылдашларыннан җеннәре котырганраклар моңа сукмакны тиз таба, ә Гарапша, бик кирәк дисәләр, хәмерне әрҗәсе-әрҗәсе белән җибәртергә дә җайларны әмәлли белә. Ягъни, ялварып килгән авылдашларына яхшылык итә, изгелек кыла, рәхәтләндерә. Ә чынлыкта? Ул кылган «изгелекләр» аркасында авылдашларыннан — бигрәк тә Чаллыга яшелчә илтә барганнардан — ничәвесе бәла-казага юлыкмаган да ничәмә машина-механизмнар уалмаган... Эш иң кызган, иң киеренке чакларда бит!

Хәнәфи менә боларның барын бергә җыеп, барын берьюлы Гарапша өстенә түгәргә, аның йөзенә төкерергә җыена, моның өчен җай көтеп йөри иде. Гарапша туган авылына, төп йортларында инде япа-ялгызы гына яшәп яткан әнисе янына кайтмый тормый бит. Урамга ул бик тә ыспай киенеп, күкрәкләр киереп чыга, йомрыланып киткән йөзе дә шома елтырый. Ләкин ул Хәнәфигә һаман да аулаграк төшләрдә очрый, ә Хәнәфинең аны кеше җыелганрак җирдә — кибет янсә клуб тирәсендә — туры китерәсе, аның кара йөзен нәкъ менә халык алдында яктыртып, җаны теләгәнчә «камчылыйсы» килә иде...

Ләкин алай итәргә язмаган икән. Беркөнне өйлә вакытында Хәнәфиләргә участковый милиционер Фәйзрахман килеп керде. Тегендә кыландыра торгач, Гарапша үзенең ике-өч әшнәсе белән бик шәпләп тозакка эләккән, шул сәбәпле, прокурор биргән ордерны тотып, монда төп йортларына тентү белән килгәннәр. Фәйзрахман Хәнәфине менә шунда пүнәтәй сыйфатында чакырырга дип кергән икән. Хәнәфи участковыйга бер тынара күзләрен шакмакландырып карап торды да, баш селкеп, кырт кисте:

— Өен дә, үзен дә күрәсем килми! Бар әнә, әбәт

бетүгә, конторадан бер-икесен иярт яисә Гарапшаның үз күршеләрен дәшеп ал!

Төп йортларындагы тентүдән ис җибәрерлек берни дә чыкмаган. Гарапша бар булдырганын, бар тапканын үзе һәм хатыны, җиткән кызы белән малае исеменә ачтырган саклык кенәгәләренә җыеп барган, аны алтынга-мазарга әйләндерергә өлгермичә калган икән, диделәр.

Шулай инде, болганчык суда балык тотарга ятырсың да ятуын, әмма бер заман үзең дә кабарсың шул! Ни эре булма, ни оста боргаланма, җәтмәнең сиңа ярардае да табыла... таза һәм чыдамлысы, рәшәткәлесе!

Ул да жәл. Ир уртасы, дәрте-гайрәте ташыган чагы иде югыйсә...

Шушы вакыйгага кадәр Хәнәфи үз улы Вәсимгә кылган катылыгы өчен вакыт-вакыт үкенү һәм әрнү хисләре кичергәләр иде, ә хәзер исә үзендә ул бимазалы хисләрне читкә кагардай көч тапкан кебек булды. Каракайлык нидән башлана? Бик бәләкәй, күзгә күренмәстәй, кулга тотылмастай нәрсәдәнме? Хәер, бик теләсәң, күреп тә, тотып та була икән...

«Вәсимне туган авылы басуында дөм караңгыда япа-ялгызын калдырып бик тә дөрес иткәнмен... Лапаста өр-яңа «Жигулие» дә үз көенә череп ята бирсен... Бер дә зыянга булмас...»

9

Инде чынлап та арылды. Йөрәк ял сорый... Ә күңел олыгаю-картаюларны белмәстән, киң иген кырларына, чиксез басу хозурлыкларына ашкына...

Ләкин, юк, Хәнәфи күңелендә әле һаман иң әүвәл адәмнәр әхвәле, авыллар язмышы, тирән буразналар булып, сырлана бара һәм... сырланачак та әле!

Узган кышны профсоюз отчет-сайлау җыелышында Хәнәфи, үзенчә сәбәпләр һәм дәлилләр табып, җилкәсендәге авыр һәм мең мәшәкатьле вазифасын икенче берәүгә, аңардан шактый яшь, белемлерәк, телгә-сүзгә остарак булган дипломлы белгеч иңнәренә аударырга тырышып караган иде. Барып чыкмады. Әйттеләр аңа:

— Ә диплом ни пычагыма безгә? Йөрәгең җылы, сүзең үтемле — иң әһәмиятлесе шул! Совхозда синнән дә кулайракны табуы кыен булыр,— диделәр.

Халык шулай дигәч, ни кыласың инде: иңнәреңдә, дөресе, күкрәгеңдә һаман бер рабочком вазыйфаларын тамырландыра бирәсең...

Хәнәфи бүгенгә белми әле: алдагы отчет-сайлау җыелышында да аңа шул рәвештәрәк, ягъни «синнән дә кулайрагы әлегә юк» диебрәк әйтәчәкләр...

Дөньяда: «Кирәк! Син генә тиешлесең!» дигән хикмәтле сүзләр бар шул. Җанында инде сүнә барган очкыннарны кабаттан дөрләтми чараң калмый.

Аның яшьтиләре директор Акбашев белән баш агроном Ризван да шулайрак сөйләнә.

Ризван-агроном дигәннән, аны былтыр партком секретаре итеп сайлап куйдылар. Совхозларына директор булып Акбашев килгәч, Нурулла Садыйков та болай ярыйсылана төшкән иде. Әмма аның эшчәнлеге дулкын-дулкын сыман иде: бер үтә активлашып җенләнеп йөри, бер сүрелеп-сүлпәнәеп кала. Яңа поселокта өр-яңа типовой урта мәктәп бинасы салынып беткән көннәрдә аның сүлпәнлеге аерата көчәеп китеп, үз эшеннән туктаусыз зарлануга әйләнә язды. Ахырда коммунистлар:

— Ярый инде алайса, тәмам сырхауга әверелеп, бөтенләй көеп бетүең бар. Китсәң китәрсең. Тик мәктәбеңдә балаларны шәһәр ягына таба түгел, үзебезнең авыл ягына каратыбрак укыта күр — инде хәзер төп вазифаң шул булсын! — дип, эшеннән азат иттеләр.

Партиянең шәһәр комитеты аларга, әлбәттә, дәртлерәк-ялкынлырак берәр кемсәне тәкъдим итә алган булыр иде. Хәер, анда да иң кулай адәмнәр тәгәрәп кенә йөрмидер, әле эзләп табасы бардыр. Ләкин ул кеше, иң әйбәт дигәне дә, кайчан әле боларның бар хәлләрен дә беткәнче аңлап, аларның дөньясына тәмамлый чумып китә ала? Күпме вакыт кирәк моңа? Ә совхозда исә иң киеренке чаклар... Директор Акбашев, менә боларны истә тотып һәм шулай ук тормыш тәҗрибәсенең бай, үзенең белемле, сабыр холыклы, принципиаль булуын исәпкә алып, секретарьлыкка Ризван Әүхәдиевны тәкъдим итте.— Саулыгы әлегә шөкер... Нибары бер-ике елга, совхоз иң киеренке чорны кичергән вакытка гына... Бу эштә үз кешебезнең булуы кирәк, ә мин Ризван иптәштән дә кулайракны күрмим бүгенгә...— диде.

Коммунистлар аның тәкъдименә баштарак бик сәерсенсәләр дә, эшне аңлап алгач, берсүзсез ризалаштылар тагы. Әлбәттә, Ризванның эшен җиңеләйтү чарасын да күрделәр: ул директор урынбасары вазифасыннан азат ителде. Ә инде төп хезмәтенә килгәндә исә, шулай ук бик пошынырлык түгел: хәзер инде аның кул астында икәү кырчылык, берәү яшелчәлек агрономы булып эшли иде. Һәммәсе дә нык белемлеләр, җиллеләр...

Шул рәвешле Ризван Әүхәдиев баш агроном булуы өстенә партком секретаре эшләрен дә үтәргә кереште һәм, әйтергә кирәк, бу эшенә дә бар күңелен салды. Һаман да шул дөньяның: «Кирәк! Син генә тиешлесең!» дигән бер хикмәте инде...

Анысы аның алаен алай да... Хәнәфи Бариевны уйламаганда каушатып җибәргәне шул булды: бер дә бер көнне «яшьтие» Ризван аны партиягә керергә димли башлады. Аңарчы Нурулла Садыйковның да бу хакта сүз кузгаткалаганы булган иде, әмма Хәнәфи аларында ничектер ансат кына котыла белгән иде. Бу юлы исә ул, ык-мык итеп төртелеп тору яисә, киресенчә, күңелле кеткелдәү белән генә котылып булмаячагын аңлап, житди рәвештә әйтте аңа:

— Соң, мин инде иллеләң теге ягына атлап чыктым лабаса. Алай бик хәҗәт булгач, яшьрәкләрне эзләштер син!

— Әйттең сүз... Партия, яшькә карап, чик куямыни?

— Анысы, бәлкем, алайдыр да... Юк, миннән булмастыр! Тик торганда әллә ничегрәк...

— Бер дә әллә ничек түгел. Самый раз дигәндәй, кияү...

Совхозның ындыр табагында булды бу сөйләшү. Алар алтын бодай көшелләреннән, шул көшелләр тирәсендә мәш килгән хатын-кыздан читкәрәк китеп, амбар ышыгына сәренгә килеп утырганнар иде.

Каршыларында хәтәр дәү киптерү-сортировка агрегаты, аның түбәсендә уңа төшкән кызгылт әләм җилферди, бик югарыда зәңгәр күк гөмбәзендә исә ак болытлар йөзә иде.

Ризван алтын көшелдән ярты уч бодай чүмерттереп алган иде, ул гәрәбәдәй бөртекләрне бер учынн'ан икенчесенә төшергәләп, җилгәрткәндәй иттереп утыра иде. Аның тавышы басынкы, әмма гаҗәп җылы һәм үз иде.

Хәнәфи менә шулчакны, бик тә тирән сулап куйгач, эчендәгене, күптәннән уйланып җыелганны, ниһаять, якты чыгарып салырга исәп итте:

— Син, яшьти, хәтер янчыгыңны селкетеп ал әле бер: сез сайлау кампаниясе җиткәч, әйтик, Верховный Советкамы яисә бүтән берәр төрлесенәме сайлаганда, халык алдында нинди сүз белән чыгасыз әле? «Коммунистлар белән партиясезләр блогы яшәсен!» дипме?

— Шулай дип... Төп асылы белән партия политикасы...

— Ә ул тимер-бетон блок сайлау кампаниясе вакы-

тында гынамы соң? Ул бүтән чакны да таркалмый, гелән дә яши түгелме? Дөрес сукалыйммы?

— Бик дөрес.

— Анысы дөрес булса, мин үз акылым белән хәлне болайрак дим: коммунистлар ул блокта тимер булса... Бетонны җимерелмәслек, таркалмаслык иттереп ни ныгыта, ни укмаштыра, ә? Цементмы? Менә мин... минем күк беспартийный большевиклар әнә шул цемент буладыр инде.

— Цемент?

— Әйе, цемент! Димәк, тимә син миңа! Минсез кыен булыр. Каберемә кереп ятканчы үз җаема шулай ипле генә яшәвемне белим инде мин, яшьти!

Ризван башын кыйшайтып аңа сынаулы, үткен карашын тидереп алды, аннары, ике бармагы белән кылыч борынын сыйпаштырып куйгач, бик тә тирән сулый җибәреп әйтә салды:

— Белмичә йөргәнмен... Әнә нинди икәнсең лә син, кияү-яшьти! Ярый алайса, цемент икән цемент!

Шул сөйләшүдән соң Ризванның аңа бу хакта сүз катканы булмады...

Хәнәфи әнә шулай шактый кәпрәеп, ягъни сүзне сырттан гына чыгарып, үзен «цемент» дип бәяләп маташты. Әмма тормышта ни ныгырга, ни укмаштырырга тырышма, гелән дә син теләгәнчә генә булмый шул. Тормыш бөтерелмәсе кай вакытларда тузанга да куймый синең сүзеңне дә, кыланмышларыңны да! Кайчакларда, катыга орынып, тимер булып тимер бөгелә, хәтта ки сынып та куйгалый...

Үтәдем авылы белән ничекләр килеп чыкты?

Нык авыл, җиргә шәпләп береккән авыл кебек иде. Йөз утызлап хуҗалык исәпләнә иде. Шуның өчтән бере соңгы вакытларга кадәр кендеге белән совхозга чынчынлап тоташып тора шикелле иде әле. Өмет боларда иде. Калган хәтлесе төзелешкә, КамАЗ зил-зиләсенә баштанаяк чумып, бөтерелүдә иде инде. Үтәдемдә җыелыш уздырырга ничәмә тапкырлар гына бармаганнардыр, күпме үгет-нәсихәт түгелмәгәндер, күңелләренә никадәр коткы салынмагандыр. Рабочком Хәнәфине әйтәсе дә юк, Үтәдем халкын үгетләргә совхоздан директор белән парторг та, авыл Советы председателе, хәтта Чаллының үзеннән райбашкарма вәкилләре дә, КамАЗ кешеләре дә катнашты.

Иң әүвәл андагы дуңгыз фермасы бетерелде, аның соңында торак йортларга чират җитте.

Ахыры ни?

Үтәдемнең бар халкы диярлек — боларның совхозына кендекләре белән тоташып, төп ышанычлылларына тикле — «оҗмах» дип аталган Яңа поселокка күченә түгел, ул тарафларга күз атып карарга да теләмичә, беравыздан: «ҚамАЗны без чакырып китердекмени? Учында кыссаң, майлар чыгардай җиребезгә килеп утырмасын ие! Күчендерәсе иткәч, фатирның берәгәйлесен бирсеннәр и ниприминнәй «Думның үзеннән булсын!» — дип аяк терәп үҗәтләнде. Нихәл итәсең, закон алар ягында...

«Йолдыз» совхозына ябышып калырга теләүчеләр исә... алтау гына булып чыкты. Йөз дә утыз хуҗалыктан — алты! Шуларның да әле тик өчәве генә Яңа поселокка күченеп урнашты, калган өчесе — болары өлкәнрәк яшьтәге механизаторлар иде — күкрәк киереп һәм беләк шәбәртеп: «Үз пуҗымыңда үз йортың, үз каралты-кураң белән бакча тотып, мал асрап яшәүләргә ни җитә безнең ише крестьян кешесенә!» — дип Әҗергә төшеп утырды.

Андыйларга, Әҗердә ни кысан булмасын, иске йортлы, таушалган каралты-куралы пуҗымнар табылды, әлбәттә. Мондыйларның гаиләсе дә ярыйсы ук ишле иде — совхоз аларга сәгате-көне белән ярдәмгә килде.

Шул рәвешле Үтәдем авылын бар булганы белән, керәшеннәрнең үз телләрендәгечә иттереп әйтсәк, «Дум» дип аталган Яңа кала үз эчләренә суырды да алды...

Хәер, суырып алды дигәч тә... ишеткәлиләр: анда капыл гына шәһәр кешесенә әверелгәч, үтәдемнәрдән берничеләр шәп йортның хәйран квартираларындагы төрле уңайлыкларга — кайнар суы белән зәңгәрләнеп янган газ утына да, ванные белән йомыш йомышларга дисәң, кафель плитәле кухнядан нибары ике-өч адымда гына булган хаҗәтханәсенә дә — әллә ни ис-өн җибәрмичә: «Их, туган авылкайларның матур таңнары, тын кичләре! Чишмә суларының тәме, басу иркенлекләре!» — дип уфтаныша ди инде әнәтерә. Мөкетә карт, Мәтрүнә түти кебек ил картлары, ил корткалары гына түгел, алардан шактый яшь булган адәмнәр дә әнә шулай уфтанасыкрана язмыш кәүсәләрен кимерергә тотынган, ди, инде...

10

Ә бүтән авыллар? Утырган җирләрендә әлегә утырып калганнар?

Әҗер белән Чуар соңгы ике-өч ел арасында галәмәт

үзгәреш кичерде. Авыл язмышына балта кизәнгәнлеген, ягъни тиздәнме, озактанмы барыбер күченәселәрен, шул сәбәпле яңа йорт бурасы түгел, мунча бурасы да рөхсәт ителмәгәнлекләрен халык бик белә, бик абайлый иде, шулай да...

Бу ике авыл ашкынып бизәнергә керешге. Аның материалы — тактасы-нисе дә кул астында гына һәм бөтенләй бушка диярлек бит: КамАЗ җиһазлары такта тышчаларыннан чишенә бара, боларда исә өйләр өр-яңа тышчаларга матурланып киенә бирә, абзар-куралар яңартыла, урамнар буйлата тигез койма-текмәләр тезелә бара. Каян әмәлләгәннәрдер, күпләр инде капка баганаларына тикле юан тимер торбаларга алмаштырып, торба өсләренә исә тактадан агач «түбәтәй»ләргә кияртеп куйды... Гигант төзелешкә, әлбәттә, буяуның да төрлесе хәтсез кайтып тора — рәхәтлән!.. Урамнарның кырый-кырыйларына әллә ни хәтле агач: юкә-өрәңгедер, шомырт-миләштер утыртып чыктылар. Әле бу да түгел, совхоз дирекциясенең тырышлыгы белән һәм, әлбәттә, шефлары КамАЗ кодрәтенә таянып, Әҗернең үзәк урамын буйдан-буйга актарып, тыгызлап һәм вак таш өсләтә бетон түшәп, аңа тип-тигез асфальт җәеп җибәрделәр, чын кала җирендәгечә — гомерлек! Янәсе, ансыз һич булмый, янәсе, яшелчә үзәгенә юлның менә дигәне — иң югары сорты хаҗәт! Соңгы бер-ике елда әүвәлге Әҗернең танырлык кыяфәте калмады да...

Ә Чуар?.. Болай да курорттай урында утырган бу авыл инде хәзер җәйләрен купшы яшеллек эчләреннән калай һәм шифер түбәләре, зәңгәрле-яшелле капка-коймалары белән дөнья йөзенә үтә көязләнеп карый. Йорт-кура тирәсен әйткән дә юк, алар инде кыр капкасына тикле төзәттергән — кабаттан машина-мазарны авыл урамына кертмиләр дә... КамАЗ төзүчеләр яшәгән елларда авыр яраланган бердәнбер урамнары инде әнә җәрәхәтләрен бөтенләй төзәтә язып, тоташтан хәтфә чирәмлеккә бөркәнгән. Сабантуйны, телисең икән бирге очта, телисең икән аргы башта, инде бик уңай дип тапсаң, таш кибет каршындагы киң мәйданда гөрләт тә җибәр! Бүгенге көндә Чуар — кая анда картаюлар! — алгысып туйга әзерләнгән яшь кәләш кебегрәк: «Менә без нинди чибәр дә, җилле дә! Кочагыңа суырып алам димсең дә... мәһәренә ни бирерсең икән, батыр егет?» — дип, тулы йөзен нурландырып, КамАЗ тарафларына каш астыннан гына күз сирпеп куйгалый сыман. Ә юк, ул үз кадерен белеп, теләгенә ирешкән горур килен шикелле, кулларын

купшы күкрәкләре өстенә куйган да: «Сезнең үз рәхәтегез үзегезгә рәхәт анда, безнең үз рәхәтебез үзебезгә рәхәт монда! Әйдә, кунак булып рәхимнәр ит: барын бер очтан күреп тә, татып та китәрсең, абзыкай!» — дип көлемсери кебек.

Гәрдәле исә... өлгермичә калды. Иркенләп бизәнергә керешкән җирендә, капыл киселде. Киселмәскә, тап авылың өстенә китереп, яңабаштан дәү бер завод салырга тотынсыннар да сиңа! Юк, монысы КамАЗ түгел инде, бүтәне... Транспорт-электр җиһазлары заводы, ди. Шулай ук ярыйсы гына эреләрдән, замана тоткаларыннан буласы, ди... Бик тә хаҗәт, күрәмсең: монысын да галәмәт кызу тотмакчылар, каты җилдертеп, утлар уйнатмакчылар шикелле! Дөрес, әлегә җирне читтәрәк, басу күкрәгендә каезлап-умырттырып ташый бирәләр, тирән чокырларда казыналар. Әмма озакламый ул завод Гәрдәленең сыер фермасын да, авылның урта тирәдәге чокырга тиклем бөтен Түбән очын да алмап алачак бит...

Моның өстенә тагы ике йөз гектарга якын һәйбәт туфраклы менә дигән тигез җирләр...

Бу хәлгә бер гәрдәлеләр генә түгел, күршеләре Әҗер халкы да ах итеп, егылып китә язды. Хәнәфинең хатыны Рәсүлә, алар җирендә бик якында гына янә бер завод салыну хәбәрен ишетүгә, сулышы кабудан, кулларын муены төбенә менгерде дә:

— Мин пешереп бүләк иткән ак күмәчләрне тегендә, Министрлар Советында ашап карамадылар микәнни? Яратмадылар микәнни? Һайгыналарым, үзебезнең совхоз җирләрендә үстерелгән икмәк ие ләбаса! — дип ухылдап җибәрде.

Совхоз дирекциясе борчулы уйга тарып, хафага чумды: болар да Үтәдемне үрнәк итмәсме? Яңа каланың магниты һай куәтле ич, Гәрдәлене, тулаем ук булмаса да, совхоз өчен һич югы яртысын саклап каласы иде лә!

Җиргә хөрмәтләре зур үзләренең. Кадерен бик беләләр. Шулай булмаска, кайнар тирләре генә түгел, ерак елларның кызыл шәфәгында ата-бабаларның газиз каннары да тамган бит ул туфракка!

Ышанычлы адәмнәр, чын вәгъдәлеләр болай хәтсез кебек үзе: механизаторлардан, терлекчеләрдән, яшелчә үстерүчеләрдән...

Алаен алай да... әнә авыл читендә дөбер-шатыр мәхшәр купкан, күченер сәгатьләре борын төбендә, әмма, шуңа да карамастан, арадан ник берсе, алдагы көндә яшәр өчен торак-квартира сорап, совхоз дирекциясенә

гариза тотып килсен икән! Юк андыйлар! Мондый хәл шөбһәләндермимени?

Гәрдәле ике юл чатында: берсе читкә, сихри нурларда балкыган данлы калага табан илтә, икенчесе туган туфрак өсләреннән газиз совхозларына таба каерыла...

Инде күп көтәсе калмады...

Иртәгә, берсекөнгә ни дияр, ни кыландырыр Гәрдәле?...

11

Хәнәфинең күңелендә тирән уелып, хәтер түреннән әледән-әле калкынып сурәтләнүче «кинокадрлар»ның берсе, иң кызыклысы һәм җитдие сугарулы болында «төшерелде».

Июль аена кергәннәр иде инде. Көн аяз һәм җылы иде.

Печәнчеләр, төшкелектә тамак туйдырып алгач, кыр станыннан читкәрәк тайпылып, җыелмаган хуш исле печән күбәләре өстенә килеп ятканнар иде. Бер өер. Бөтенесе диярлек механизаторлар белән шоферлар иде. Арада сенаж ташуда булышучы яшь җилкенчәк тә бар иде.

Печән чапкычлар, теземнәрне җыеп сенажга тураучы агрегатлар һәм биек әрҗәле автомашиналар белән дәү-дәү арбалар таккан «Беларусь»лар болын буйлап әллә кайларга сибелешкән — алар да тынып калган, алар да хәл җыя сыман иде.

Бер кырыйдарак йомшак печән өемендә Хәнәфи дә, оеп һәм мулла күк мөкиббән китеп, утырган иде. Аның әллә ни сөйләр сүзе юк, тик колак салып тыңлап кына утыра, исәбе эшкә кузгалуларына берәрсенең агрегатында — йә чапкычта, йә җыеп тураyда — азрак «кан кыздырып, буыннар яздырып» алырга иде. Гадәтенә сеңгән нәрсә...

Тамак тук, өс бөтен, эшләр дә үз җаена тәгәрәп кенә бара, димәк, кәеф тә күтәренке... Андый чакта авызга сүзнең тәмсезе киләмени?

Авызга тәмле сүз генә килүнең җитди бер сәбәбе дә бар бит әле: әнә анда галәмәт киңлекләрдә җәйрәп яткан болынның Әҗергә таба хәтсез генә өлешендә теземнәрдәге кипкән печәнне подборщик-копнительләр җыеп, чүмәләгә өя-утырта баралар. Ә ул матур-матур кабарып тезелешкән бихисап чүмәләләр бер дә әллә кая китәсе түгел, нәкъ менә боларга, совхоз эшчеләренә өлә-

шенәсе бит! Хәер, кичә-бүгеннәрдән машиналарга төяп авыл тарафларына ташый да башладылар инде. Менә дигән хуш исле һәм туклыклы печән ләбаса!

Печәнчеләрнең кайсы кайда һәм кайсы ничек урнашып алган хәлдә тел чәбәләндереп азапланганы да нәкъ менә сугару һәм аның файдасы тирәсендәрәк иде. Әйе, шушылай галәмәт коры килгән елда әйтерлеге юк: әнә бит болынлыкларда печәннең куелыгы ни дә, тез тиңентен, хәтта урыны белән бил тиңентен үсүләре ни!..

— Карале, матур сипкелле энекәш, анда комплекс катында ничәнче манараны тутырмага керештеләр инде зрә дә шәп корылы-чиле туракланган печән белән, ә? Дүртне түбәләмә иттергәч, бишенчесенә керештеләрме?

«Матур сипкелле энекәш» көттермәде, теш аралый чулт иттереп төкереп куйды да:

— Ие, инде бишенчесенә тотындылар,— дип җавап кайтарды.

— Әһе... Әнә бит...

Бу минутта һәммәсе дә башларын борып, Яңа поселок ягына күз ташлады. Юк, ул тарафта поселок үзе күренми, әмма үз сырты артыннан комплексның биек манара башлары — көмешсу йомры «түбәтәйләр» — кояш нурларында бик матур булып балкып тора иде.

— Җәмгысы сигезәү... Һәркайсына тугызар җөз тонна сенаж сыешлы. Хәтсез бит, җегетләр, ә? Барын да тутырып куйсаң, дим. Җәнә дә бетон траншейларны кушып җибәрсәң, ә?..

— Сыерның сөте телендә дигәндәй, җүнгә ирешәселәребез алда әле, Сәетҗан абай! Тик менә быелгысы елны иген хәлкәйләре генә хөртиерәк шул тегендә. Бу тикле зәһәрләнеп корытса да корытыр икән!

— Их, иген кырларына да сугаруны җәелдереп җибәрсәң икән менәтерә! Ә бәлкем, алдагы елларны...

— Сугару сезгә, сугару... алдагы елларда да җәелүләр, төштә күрмәгәнне өндә күрәләр... Өстебезгә янә берике завод китереп салсалар, совхоз дигәнебез, йөзтүбән капланып, мәңгелек мәрткә китмәгәе! Җеннәр генә орсын үзләрен, тфү, әйттем исә кайттым!

Моны печән күбәсенә сыртын кырын салып яткан гәрдәле Хафизы әйтте, һәм ул, әйткән кызулыгы белән йөз чыткан килеш, торып ук утырды да, майга каткан көрән кепкасын маңгай өстенә батырып төшергәч, кинәт зәһәр тавыш белән кеткелдәп җибәрде:

— Җеназасына ясин укымага Уфадан мөфти хәзрәтләрен чакырырга туры килмәгәе, хе-хе! Яки, әйтик, берәр җаваплырак министрны!

Зәңгәр күктәге алтын кояшны кисәк кара болыт каплап алгандай булды. Әле генә шундый күңелле, шундый тәмле иттереп сөйләшеп утыралар иде, ә хәзер кинәт кенә... Йөзләргә күләгә йөгерде, һәммәсенең дә кашкүзләре капыл җимерелде.

— Син нәрсә, тагын безнең өсләргәме? Авызыңнан җилләр алсын! Җитмәгән ди инде!

— Җиткәнме-җитмәгәнме, әнә югарыда байтак кына министрлыклар безнең Чаллы төпләренә үзләренә берәр завод салмага үтә теш кайраштырып тора ди. Нигәме? Соң, бердән, географик шартларының уңайлыгыннан чыгып, аннан килеп, төзү-кору эшләрен җәелдермәгә мондагыдай иләмсез куәтләр тагын кайда бар Советлар илендә? Синең җирең шәплегенә бик исләре китте ди, синнән-миннән сорап тордылар, ди...

— Их, нишләп әнәтерә Кама аръякларында җәелдермиләр икән ул төзелешләрне? Анда бит җыен басу-кырлар комдыр, көлсудыр. Ерганак-мазарларны күп дисәләр, хәзерге техникага чүп ич алары, югыйсә...

Бу минутта карашлар еракта күгелҗемләнеп торган калкулыклар — урманлы Кама ярларына таба күчте.

— ГЭС корылып бетсә, аннары тагы тимер юл да сузып үтсәләр, бәлкем, ул якларга да чыгарлар әле.

— Җирең түгел, үз күкрәгең кысылгандай инде, билләһи! — Хафиз утырган җирендә авыр гына селкенгәләп алды, кара-кучкыл төкләр баскан иягеи учлады һәм яман сызлану аша уфылдап җибәрде.— Туган авылымнан эшкә чыгып киткән мәлләрдә йөрәк телгәләнергә тотына, шушында хәтфә болынлыкка килеп, эшкә чумгач кына, онытылам бер арага... Тегендә умырттырып каезлыйлар гына бит туфрак кынайны, каезлыйлар да өя баралар... Җир түгел, бәгырьләр каезлана! Ул да җитмәсә, йортың-кураң белән җимерелеп, тамырдан кубып китәр көннәр дә борын төбендә инде. Сезгә анда Әҗердә әлегә тыныч, ичмаса, әлегә җиңел, ә безләргә?

— Соң йортың-кураң белән Әҗергә төш тә утыр. Синлек кенә безнең авылда пуҗым табылыр әле!

— И әйттең сүз, Шәйхелислам! Бер генә белешмәдем, бер генә төртелмәдем инде мин. Авыл Советы аяк терәп каршы. «Булмый, ярамый, киңәергә рөхсәт юк. Әҗер үзе дә, ае-көне җитсә, күченеп китүе ихтимал», ди.

— Ихтимал сиңа... Әнә КамАЗ тирәсендә азмы ва-

кытлы поселоклар? Кубарга, бетәргә җыеналармы? Әле исләрендә дә юк. Алар булып алар... Шулай булгач безнең Әҗер...

— Сез бәхетле!

Гәп мондый юнәлеш алгач, аңарчы дәшми-тынмый утырган Хәнәфи:

— Совхозда менә дигән Яңа поселок корылып ятканда, син бигрәкләр инде, Хафиз,— дип куйды теш аралый гына.

Болай кысылуы белән ул ары таба теләсә дә, теләмәсә дә, гәпкә суырылды да керде...

Хафизның күз агы елтырап алды, авызы кырыенда исә җиңелчә көлемсерәү чалымы хасил булды:

— И Хәнәфи абай, бүгенге заманда рабочком булып йөрсәң дә, син бит төп асылың белән безнең кебек үк механизатор лабаса, җиргә җаның-тамырың белән береккән адәм. Аңларга тиешсең...

Хафиз гәүдәгә чандыр гына булса да, нык, таза ирләрдән, буыннарда җен егәрләре бар: кем әйтмешли, типсә тимер өзәр, сукса чуен изәрдәйләрдән. Эшендә дә һич ал бирергә теләмәс. Тормыш итүләре белән дә Гәрдәледә нык, чыдам тамырлардан исәпләнә. Авыл җирендә андыйларның әйткән сүзенә колак салмый, кылган эшләрен күзәтми тормыйлар. Ул үзе дә боларны бик белә иде.

— Юк, Хәнәфи абай, Яңа поселоктан мин тиктән генә һич гаеп эзләргә җыенмыйм. Күркәм яклар күп анда. Комплекс үзе генә ни! Дөньяда бер буласы! Ә хәйран иркен, әкәмәт мастерскойлар, гаражлар, машина-механизмнар утары! Өч катлы таш мәктәп! Класслары, заллары — безнең төшләргә дә кермәгән ләбаса андыйлар! Ярый, ичмаса, хет үзебезнең балалар рәхәтләнер... Ә клуб, ягъни культура сарае? Аның спорт залы да берүзе ташпулат буласы ич. Озакламас инде, очлап та куярлардыр.

Хафиз ачык көлмәк изүеннән күренгән йөнтәс күкрәген кашыштырган шәйгә һәммәсенә дә берәм-берәм елтыр күзләрен йөртеп чыкты, аннары бер тынара баш селеккәләп торды:

— Ие, җан асрап ятмага әкәмәт уңай сыман үзе. Квартиралары тап инде кала җирендәгечә: яктыдыр, җылыдыр, суы, ванные, бүтән хаҗәтләре — бар нәмәсе үзендә... Әмма...— Кинәт ул, каш-күз җимереп, бик тә тирән сулап куйды:— ...тормыш итәр, көн күрер өчен бернинди дә җүн юк анда!

— Йә, йә, әйтәсеңне әйтеп бетер,— диде Хәнәфи, күзләрен сак кына йомгалап.

Теге исә ашыкмады. Янә печәнчеләргә күз йөртеп чыкты, моның соңында буынтыкларына мәңге юылмас майлар сеңгән юантык бармакларын берәм-берәм бөгәргә тотынды. Ул бөгә бара, әйләнә-тирәдәгеләр ул бөгеп әйткәннәргә куәт өсти тора иде:

— Каладагыча иттерәбез дигәч тә, ни пычагыма кирәк булгандыр икешәр, хәтта дүртәр катлы йортларны берсе өстенә икенчесен тыгызландырып өяргә? Ә яннарында бакча җимеше үстермәгә аз гына да рәт бармы соң?

— Кая анда бакча сиңа! Матурлык өчен ни яшел газон, ни чәчәклеккә юньләп урын калдырмаганнар. Бала-чагага иркенләп уйнар өчен дә җайлар юк. План сызганда ни уйлаганнардыр, тавык миләр.

Гәп оеткысын куертучы буларак, Хафиз сыңар кулын күтәреп, бүтәннәрне тыярга чамалады, чүмәләне үзенчә өяргә тырышты:

— Анда мал-туар асрамага урман кырыйлатып абзарлар салырга җыеналар, имеш. Торган торагыңнан ярты чакрымнарда. Сыерын, сарыгын, бүтәнен тотам дисәң, ничек карап өлгермәк кирәк? Бозаулаган, бәрәнләгән чакларында бигрәк тә... Ә бакча дигәне... Ярый, бәрәңге утыртырга җир бүләләр үзе, әмма җәһәннәм читендә ләбаса ул! Яшелчәне, җиләк-җимешне кайда үстерергә? Бер учма яшел суган кыягы, бер табак кыяр яисә яшь бәрәңге алмага ике чакрымнарга чабаргамы? Безнең күк бер кылны кырыкка ярырга җиткән кешеләргә, ә? Авылда үз өең белән яшәгәндә бары да кул астында гына, барына да эш арасында өлгерәсең.

— Ичмаса, кала җирендәге кебек коллективный садбакча тотарга яраса икән. Бәләкәй йортлары, су сиптерүләре белән...

— Соң, райбашкарма рөхсәт итми бит. Имеш, авыл җирендә килешми, ямьсезли, «поселок городского типа» диләр бит,— дип аз гына ачыклык кертергә тиеш тапты Хәнәфи, әмма моның белән ул утта кызган табага май чыжлаттыргандай гына иттерде.

— Һе, ямьсезли, имеш. Зуррак калаларны ямьсезлимә? Килеп кергән чакларында зрә дә матур. Рәхәтләнә, ичмаса, анда халык!

— Төкерәм мин аларның «городского типа» дигәннәренә! Бүгенге заманда аның «поселок» дигәнендә үк

кала чалымнары бар ич. «Деревенского типа» дисеннәр алайса! И шулай эшләсеннәр дә!

Яңа поселокның тетмәсен тетеп, тезәләр генә бит шулай.

Ниһаять, коттеджларга, ягъни «мансардлы йорт» дип аталганнарына да чират җитте.

Болай бик тә чибәр, бик тә уңай йортлар инде югыйсә. Тап курчак өйләр сыман. Аларның кайберләренә совхоз хезмәткәрләреннән берничәләп гаилә кереп оялап та алган иде инде. Ошатмыйлар түгел кебек үзе, алай бик зарланганнарын әлегә ишеткәннәре юк... Ә берсе, Үзәк урамда урта тирәдәрәк утырганы, аерата матур бизәп эшләнгән иде. Монысында әле беркем дә яшәми, монысын үзенә күрә күргәзмә йорт сыман итеп тоталар иде. Өйләнәсе чуен рәшәткә белән коймалап алынган, керер юлына асфальт җәелгән, басар сукмакларына бетон плитәләр коелган, ихатаның түр почмагында кирпечтән салынган гараж, өй артында бер читтә таштан-агачтан җыйнак кына беседка әмәлләп куелган — таянырга бәләкәй генә өстәл, утырмага шомартып, стильләп эшләнгән юан тумраннар. Янәшәдә генә, җимешләре пешеп өлгергәч, үрелеп кенә өзәр өчен, алмагачтыр, чия куагыдыр утыртылган. Идиллия үзе, оҗмах үзе! Тик, ни хикмәттер, оҗмахтан аермалы буларак, ул җимеш агачлары утыртылган язларында ук корып та өлгергән иде. Ярый, монысына күз йомыйк, өй эче? Бихисап бүлмәләре, иркен өйалдысы, киң верандысы? Һәммәсе әйбәт, матур буяулы, елтыр да ялтыр...

Совхозга эш-йомыш белән дә төрле семинар-киңәшмә ишесенә дә кеше аз килми. Кызык эзләп, дөнья танырга теләп йөрүчеләре дә, әйтик, хәтта журналист-язучы кебекләре дә, сирәк-мирәк булса да килеп чыккалый иде. Хәнәфинең үз күзләре белән күзәтеп, үз колаклары белән тыңлап торганы бар — килгән халыкның һәммәсе диярлек, әлеге чибәр йорт белән танышып чыккач, хәйран рәвештә баш чайкаштыргалап: «Заманалар диген: авыл җирендә шушындый әкәмәтләр салдырыр көннәргә дә ирешербез икән, ә? Менә ичмасам, ә! — дип сокланулы тел шәпелдәтүләрдән туя алмый иде.

Үзләре соң, авыл халкы? Анда яшәү җайлары бөтенләй белмәгән шәйгә, баштук: «Менә кайда җәшәп җатмага оҗмахлар буласы!» — дип, күз нурландырган, ә Хәнәфинең үз хатыны Рәсүлә аңа «Ватан» дип бик матур, бик килешле исем дә табып куйган иде ич.

Бактың исә, тормыш итә башлагач... Хәзер инде Чаллы җитәкчеләре дә Яңа поселокка экскурсияләр оештырмас, анда төрле семинар-киңәшмәләр үткәрмәс булды.

Ә монда киң болын күкрәгендә йомшак печән күбәләрендә яткан җирләрендә механизаторлар исә, ул матур йорттан әле генә чыккан рәвештә, аның һәр ягын да күз алларына китереп, мактардаен мактап һәм хуплап алды, әмма шул ук чакны һәммәсе үз уе һәм үз мәеленчә каккалап-суккалап, «чибәрне» чишендереп ташларга да күп сорап тормады:

— Кала кешесенең бар нәфсен җиренә җиткереп үтәгәннәр, ичмаса: дача димәсәң дача!.. Премиясен дә хәтсез генә эләктергәннәрдер әле Казанның уйлап табучылары!

— Аста өч бүлмә, өстә түбә астында янә ике! Ә тәрәзәсез-нисезләре тагы нихәтле! Үземнең юри санап чыкканып булды: төп-төгәл унөч ишек, билләһидер! Вәт кала җирендә булса, хәтсез генә студент халкын асрап ятмага җүн, ә! Тиктән акчалар сугып кына...

— Хезмәтемдә һәйбәт эшләгәннәр өчен алай-болай орден-мазар биреп, аны юарга кунак дәшәргә язган булса, яки, әйтик, кызны кияүгә биргәндә туй итәр көннәр җитсә, ни кылмак кирәк инде? Өч-дүрт парны гына сыйдырышлы бүлмәдә ни җимерттерә аласың? Кала җирендәге кебке кафе-мазар эзләп чабаргамы? Юк инде, миңа шул шәп «мансардныйны» тоттырырга итсәләр, астагы ике бүлмәсен ике уйламый бер иттерәчәкмен. Ягъни, кермәс борын, өр-яңа баштан ремонт!..

— Аның каравы ишегалды иркен, асфальтлы-бетонлы. Таш беседкасы үзе генә ни! Кулыңа гәҗит тотып, шома тумранга аяк бөкләп кенә утырасың да дөнья яңалыкларын укып туйганчы кинәнәсең! Укыган шәйгә корыган алмагачның шәрә ботагыннан алма өзеп алгандай иттерәсең дә аны керт-керт кимергәндәй буласың.

— Гәҗит-журнал дигәннән, үземнең укыганым булды: әнә тегендә, Белоруссия белән Балтик буе республикаларында инде дә хәтәр иттереп салып яталар ди, бүгенгесе көнне поселокларын! Өйләрнең уңайларын, төрледән-төрлесен! Кала җайлыклары да исәпкә алына ди, авыл кешесенең бар булган ихтыяҗлары да... Менә ичмасам! Югыйсә чит илдә түгел, чат үзебездә ич!

— Һи, аны барып өйрәнәсе-нитәсе, өйрәнгәч күчерәсе бит. Ә моның өчен генә дан-шөһрәт киләмени, премия тәтимени? Аңгыра булма, Заһидулла абай!

Хафиз исә кояшлар-җилләр ашаган маңгаен сырландырып, майлы, юантык бармакларын янә бөгәргә тотынды:

— Ару гына ян бакча тиешме? Тиеш. Мал асрамага абзар-кура. Гараж белән келәт ишесе, ак мунча тагы... Ие, мунча да! Минем гаилә өчен иң әүвәлгесе! Соң, Яңа поселокта казна мунчасы салганнар да салуын, суы да ташып кына тора, җылысы да бар сыман ди, әмма чабынырга җәре? Тиккәмени андагылар сыртлары кычыта башласа, Чуар яисә Әҗер мунчаларына табан җәр эзләп тырыйк-тырыйк йөгерә! Ә мин үз йортымда үз мунчама хәләл җәфетем янына, әлбәттә, ул балаларны берәм-берәм юындырып чыгаруга күкрәкләр киереп кенә китәм дә анда инде икәүләшеп-парлашып туйганчы чабынасың-кинәнәсең... аннары ни...

Бу минутта яшь-җилкенчәк, авызын ачып, күз тасрайтырга өлгергән иде инде, Хафиз, моны сизеп, ак мунчада «аннары ни...» буласын төшендереп тормады, сүзен капыл гына икенчегә борды:

— Минем Әлфинур, ягъни сез бик әйбәт белгән, бер кылны кырыкка ярырга өлгерүчән, совхозның атаклы сыер савучысы ни ди миңа? Өч бөртек кыз бар безнең. Аларны берәм-берәм кияүгә бирер көннәр җиткәч, бирнәләренә, һәйбәт мамыктан түшәк-ястык, мендәр ишесе кирәкме? Үл дә кит — ансыз һич ярамый. Димәк, казүрдәк тотмый нишлисең! Сөте-мае, күкәе-ите тагы? Шушылай галәмәт кысырланган заманны тел өстенә салып, теш арасына кыстырмага нидер тиешле ләбаса! Совхоз боларны булдыра аламы, көченнән киләме? Кибеткә кайтамы? «Һи-һиләр» шул! Авыл җирендә яшәп, менә шулардан мәхрүм ителсәм, миңа ни кылырга кала инде, ә? Шәп поселокның шәп йортында «пролетариат» булып ятканчы, Үтәдемнәр артыннан койрыкны сыртка салып, Яңа кала тарафына шыларгамы? Алар анда, беришесе авылны сагынабыз дип ни шыгырдамасын, күпчелеге гөрләр гөрләттереп яшәп ята ич! Кала шартында балалар хезмәткә юньләп өйрәнмичә, тырай тибеп йөрсә йөрер, әмма, аның каравы, анда культурасы-нисе, төрле чаралары муеннан күмелерлек ләбаса!

— И шулай: бетте-китте — вәссәлам! — дип, калын күкрәк тавышы белән җуплап куйды моны арадан берәү.

Совхоз өчен хәтәр сүзләр иде бу. Соңгы вакытларда кыюлана китте, хәтта усаллана төште игенче халкы. Җир кадерен, аннан да бигрәк, үз кадерен бик әйбәт аңлаганга күрә микән?

Яңа поселокта тормыш итү шартларының җайсызлыклары хакында Хәнәфи аз ишетмәгән, әмма аның моңа кадәр бу чаклы ук почмакка кысрыкланганы юк иде әле. Әйләнә-тирәсенә күз йөртеп чыкты. Йөзләр чытык яисә, киресенчә, чалымнарында ачы көлемсерәү... Ә бит алар — Яруллалар, Сәетҗаннар, бүтәннәр — һәммәсе дә совхозның төп терәге, аның бүгенгесе, иртәгәге көне! Җавапка ни дә булса әйтмичә калырга һич ярамый иде. Ләкин ни дияргә?.. Хәнәфинең какча яңагы тартышып алды, һәм ул, моны сиздермәс өчен, учын яңагына китерде, сыйпаштыргалагандай иттерде, көчәнеп булса да, тамак кыргалап куйды:

— Булдырам, шәп сөйли беләм дигәч тә, бу тикле үк яман өркетеп селтәнмәскәдер, бәлкем? Яңа поселокта тормышның башы гына бит әле, барын берьюлы ничек хәл итеп бетерәсең ди?.. Аннары төрле кыерсыту-кысуларга сылтауларыбыз да сәеррәк. Соң, поселок әле кәгазьдә вакытта кайсыгыз килде аны тикшермәгә, кайсыгыз төпле фикер әйтте иң тиешле, иң кирәкле чагында? Эһе, юкмы андыйлар? Ә ник килмәдегез? Инде менә, көне җитеп, яшәү җайларына төртелгәч кенә...

— Шулайрак килеп чыкты шул, чәнчелгере: гаеп атта да, тәртәдә дә... и татар акылы тауга менгәчтенрәк шул,— дип озын муенын сузды Әҗер Шәйхелисламы.— Җарар, җегетләр, сырт салындырып, май җыеп җатар чакларыбыз түгел. Тегендә машина-тракторларыбыз, безне зарыгып, күгәреп китмәгәйләре.

Ләкин кузгалырга теләүче булмады. Йомшак печән күбәләренә кайсы ничек сеңгән булса, шул көенчә кымшанмыйча кала бирде.

Хафиз үз сүзен кеше бастырыгы астында калдырырдай адәммени?

— Юк, җылы су йоттырып кына сызлаган күңелләрне басарга итенмәгез әле, зинһар. Без кем? Авыл кешесеме? Җир хуҗасы, диләрме? Хезмәт иясеме? Ияce! Иярчене түгел...и вәссәлам! — Шулай дип, ул, зәһәр бер кырыслык белән тез капкачындагы күк ямауга шапылдатып алды, аннары, күзләрен кыса төшеп, Хәнәфигә төбәлде:

— Мелә син Хәнәфи абай, иң хөрмәтле кешеләребездән. Үзең, безнең күк, ата механизатор... профсоюзыбызга баш... Ие, «баш» булып та әйт әле: менә син минем хәлгә төшсәң, ягъни яшәгән-торган нигезеңнән төбеңтамырың белән кубарга дисәләр, ни кылыр иең, ә?

— Соң... ни...— Хәнәфи бермәл тотлыгып торды, ияк-яңагын сыйпаштырды.— Соң, ни инде... Диңгездә батасы корабның капитаны ахыр чиктә ни кыла ди? Корабы белән диңгез төбенә чума яисә аны иң азактан калдырып китә бугай... Менә шулай!

Дәррәү көлеш яңгырады. Хафиз, ни кырыс, ни җитди күренергә тырышмасын, барыбер түзә алмады, шаркылдарга тотынды:

— Капитан?! Әҗернең батасы кораб капитаны! Әнә бит ничек!

Бераздан ачыкланды: бактың исә печәнчеләрнең бөтенесе диярлек үз авылларында ахыр чиктә «капитан» булырга бүгеннән үк әзер икән...

12

Совхоз хәлләре хакында уй-исәпләргә баткан чакларында, Хәнәфинең уй очы еш кына директор Мөслим Акбашевка барып тоташа иде.

Байтак кына кызыклы һәм әһәмиятле вакыйгалар уртасында да нәкъ менә яңа директор калкынгалар иде.

Баштарак Хәнәфи аны аңлап бетермәгән, дөресе, бер яклырак аңлаган иде. Авыл хуҗалыгында ничәмә еллар буена җитәкче урынында эшләве белән тәмам остарган, теләсә нине мөгезеннән эләктереп алып, җай гына егып сала белүчеләрдән дип исәпләгән иде. Әйе, йомшак сыйпап, катыга да утырта ала, кирәксә, каты орып, юешең чыкканчы йомшарта да ала!.. Ә бит тормышта бүтән юнь-җәһәтләр дә бар әле, нечкәрәк, нәфисрәк дигәндәе. Бу тарафларда исә Хәнәфи аның хакында: «Талканы корыданрак, күңеле такырданрак, ахрысы»,— дип уйлаштыргалый иде.

Хаталанган икән. Терсәкне терсәккә орып эшләп йөргәндә, сулышны сулышка кушып гомерләр сөргәндә, тора-бара күп нәрсәләр ачыкланып куя шул. Кайчакларны кешенең һич уйламаган, һич көтелмәгән яклары да ачылып киткәли...

Хәнәфинең Акбашев белән бергә әллә ничә тапкыр кунак мәҗлесендә булганы бар. Мәҗлес өчен ул үтергән дә куйган адәмнәрдән икән: төрле кызыклар, хикмәтле хәлләр сөйләп көлдерү дисеңме, матур тост әйтүләр, күңелле җыр башлап җибәрүләр дисеңме — барына да оста, хатын-кыз карашлары гел аңарда! Егет чакларында әкәмәтләр булгандыр ла ул!..

Анысы алай, әмма боларга Мөслим Акбашевның бүтән бер сыйфаты башта ук ошап куйган иде: вак җанлы түгел икән, аннан да бигрәк, тормыштагы күркәм күренешләрне, кешеләрдәге матур сыйфатларны күрә белүчән икән. Гадәттә урын алышынганда бериш җитәкчеләр ничек кылана? Аңа тикле ирешелгән казанышларны, уңай якларны күрмәмешкә салыша, күз йомып йөри, кайберәүләре хәтта башта ук кара күзлек киеп килә: ямьсез, җитешсез якларның барын да, югын да чамасыз күпертеп һәм каралтып җибәрә. Шуның белән ул, янәсе, нибары «нульдән», хәтта тик яманнан гына тотына, янәсе, нибары аңардан, алланың бу кашка тәкъсеннән генә, үсеш һәм яңарыш башлана... Мөслим Акбашев исә алай кыланмады. Аңарчы болар хуҗалыгында, бигрәк тә сортлы игенчелек белән мал асраучылыкта, ярыйсы гына казанышлар булган, һәрхәлдә, болар Чаллы төбәгендә алдынгылар рәтендә исәпләнә иде. Мөслим Акбашев, дөрес, төрле кимчелекләргә дә күз йомып карамый, бу җәһәттән турысын һәм гаделен әйтә, әмма ул элгәреге казанышларны аңлый белә, шуларны үстереп җибәрергә тырыша иде. Иң әүвәл матур сыйфатларны! Шул сәбәпледер, ахры, ул хуҗалык ветераннары Хәнәфи Бариев, Ризван Әүхәдиев кебекләрне бик тиз арада үзенә якынайта алды, аларда үзенә ышанычлы таяныч таба белде. Бу хәл хәтта элеккеге директор Яхъя Таипычка да кагылмыйча калмады. Яхъя Таипыч: «Их, мин киткәндә елы каһәрле килмәгән булса соң, җегәрләр булып, һич югы шуны атлап үтә алган булсам соң!» — дип ачы үкенеп йөргән иде кебек. Ул, Чаллыга — кала җиренә күченгәч, анда олы төзелешнең кулайрак бер өлешендә прораб булып эшләп караган, аннары, «авыл хуҗалыгына бераз якынрак булырмын, ичмаса» дип, берара «Сельхозтехника»да эш кыйландырып йөргән иде. Ахырда, сәламәтлеге шактый ук какшагач, пенсиягә чыгып һәм шәһәрдәге шәп квартирасын кияве белән врач кызына калдырып:

— Кала җире безнең өчен түгел икән. Төкерим уңайлыкларына! Дөбер-шатырлы таш капчыкта ятып, вакытыннан иртә гүргә керәсе килми әле,— дип, карчыгы Мәрзия белән, бөтенләйгә туган авылына, үз өенә кайтып төште.

Яхъя Таипыч кул кушырып утырырга яратучан адәмнәрдәнмени? Җаны тынычланып, бераз җегәр кайтканын тоюга ук, эш сорап, аның да нәкъ менә игенчелеккә, ашлыкка якынрак булганын үтенеп, совхоз дирек-

циясенә килде. Урып-җыюның кызып киткән чагы, җитмәсә, ашлык та мул кайта, аңа Әҗернең ындыр табагында мөдир урынын тәкъдим иттеләр. Абзаң моңа куанып ризалык бирде, ул хәтта күз алларында яшәреп киткәндәй булды. Аңардан да битәр Акбашев үзе сөенде ул хәлгә! Алдагы көннәреңне, яулыйсы үрләреңне уйласаң, хуҗалык итүләрдә, бигрәк тә сортлы игеннәр үстерүләрдә бай тәҗрибә туплаган адәмнең кулга-кул тотынып эшләргә керешүе үзе бик зур сөенеч ләбаса!

Бу кышка керер алдыннан Акбашев та Яңа каладагы квартирасын калдырып, гаиләсе, ягъни хатыны һәм җитеп килгән төпчек улы белән, поселокка күчеп урнашты. Аның Рәхиләсе, юкарак гәүдәле, болай мөлаем гына хатын — бай тәҗрибәле фельдшер, Яңа поселокта медпункт өчен дә, шулай ук балалар бакчасы белән мәктәпне ышанычлы канат астына алуда да бик ярап куйды. Ә директорның үзенә? Кичләрен арыган-ватылган гәүдә белән руль артына утырып ерак өенә элдертәсе, анда таң тишеге белән торып, кабаттан машина кабызып азапланасылар юк. Биредә барысы да янда, бөтенесе дә кул астында диярлек... Әмма иң әһәмиятлесе: ул совхоз коллективы эченә, күктән төшкән шифалы яңгыр сыман, тирәнгә сеңде дә куйды. Җитәкче адәм өчен бу — иң хаҗәте түгелмени?

Менә шунда, Яңа поселокта урнашып яши башлауларына Акбашевның тагын бер кызыклы сыйфаты, дөресрәге, холкы-фигыле ачыкланып китте.

Нинди шарт, нинди кыен хәлдә булмасын, ул һәр көн иртән ятагыннан баш калкытуына... гантельләр, герләр уйната-чөя бик шәпләп, тир бәреп чыкканчы физзарядка ясап ала, соңыннан бил тиңентен юынып җибәрә икән. Көннекен көнендә калдырмыйча! Моңа ул, Ватан сугышыннан әйләнеп кайткач ук, бик нык какшаган сәламәтлеген тизрәк рәтләү өчен керешкән. Инде утыз елдан да артык, инде шактый олыгаеп барса да, әле һаман кыландыра!

Менә каян килә икән аңардагы җегәр-куәт, менә нидән икән аның чир-сырхауларны белмәве, сүнмәс дәрте-дәрманы!

Ә ул үзе исә, бу хакта сүз куптарсалар:

— Хәрәкәттә — бәрәкәт! Режим белән тәртип — иң әүвәле! Аның ачкычы һәркемнең үзендә ләбаса,— дип кеткелдәп кенә җибәрә.

Ләкин ул шаяртып әйткән әлеге сүзләренә чынлыкта тирәнрәк һәм киңрәк мәгънә сала иде кебек. Аның

«бәрәкәтле хәрәкәтенә» ансат кына иярел кара, бар! Акбашев арбасына утырып, җан-фәрманга элдерткәндә, ныклап тотынмасаң, мәтәлеп төшеп калуыңны көт тә тор!

Совхоз эшчәннәре, аерата турыдан-туры директор кулы астында эшләүче төрле белгечләр, мондый хикмәтне абайламый торыр димени? Теләсәң дә, теләмәсәң дә, итәк-чабуларыңны җыеп, билбауларыңны кыса төшебрәк бәйләргә мәҗбүрсең!.. Иртән иртүк торып «зарядка» алып өлгергән директорың, әйтик, фермага сыер савучылар белән бергә атлап кереп, эш майтарып йөргән мәлдә, анда ферма мөдире белән зоотехник күренмәсә, соңыннан күңеллеме булыр үзләренә?

Яисә, әйтик, басуда печән-салам җыюда, яшелчә алуларда оештырылган өмәләрдә — ә андыйлар сирәк үткәрелмәс иде — директор үзе олы башы белән иренү белми тирләр түгеп йөрсә, ә син җегәрең ташып торган агроном яисә инженер, плановик яисә бухгалтер, дип исәпләнгән зат булып та уртак эшкә чыкмый калсаң яки чыгып та юньләп эш кыйрата белмәсәң, соңыннан директорның үзенә түгел, халык күзенә күренүләре әйбәт булырмы?

Ә бит директор җилкәсендә шушындый эшләрне оештырып, башлап җибәрүләр генә утырамыни соң? Совхозның бүгенгесен, алдагы көнен кайгыртып, тегендә-монда чапканда, аңа төрле киртәләрне аз аударырга туры киләдерме, аударганда аз җегәр һәм сәләт түгеләдерме? Чаллы җирендәге хуҗалыкара кооперация оешмалары, «Сельхозтехника», мелиорация колоннасы, сәүдә оешмалары, бүтәннәре белән алыш-биреш итүләр, эшләрне җайга салулар... боларның кырыкмаса кырык төрле мәшәкате, бетмәс җәфасы иң әүвәл кем җилкәсенә ава? Аның нечкәлекләрен, җелекне суырырдай якларын күпләр, әлбәттә, белми дә бит!..

Ә шефлары? Чаллы төбәгендә җәелгән гигант төзелештә галәмәт көч-куәткә ия булган шефлар бар. Һәркайсы да үз канаты астындагы хуҗалыкларда, хәтсез җегәрләр салып, әллә никадәр эшләр башкарып ята. Шулай да арада иң куәтлесе, елның елында җегәр-сәләтләре иләмсез үсә барып, инде тәмам әкиятләр пәһлеванына әверелеп киткәне КамАЗ иде. Әмма ул чиксез кодрәтле Пәһлеван белән уртак тел табасы, аның күңелен күреп, ышанычлы таянычка әверелдерәсе бар иде әле. Акбашев исә тапты, булдырды, әверелдерде, ул, аерата, автогигантның парткомы белән дуслаша белде. Әгәренки андый чын дусың, ышанычлы ярдәмчең булмаса, алга

таба шушылай текә һәм кыю сикереш ясый алыр идеңме? Уйлыйсы да юк!..

Кайчакларны кайберәүләр тыштан мөлаем кыланып, асылда көнләшеп һәм астыртын гына авырттырып чеметү нияте белән, Акбашевка:

— Маладцы димиенчә: КамАЗны имә белеп имәсез, ичмаса, Мөслим Гайнаныч, ә! — дип төрттереп тә куйгалый иде.

Ә бу ни әйтсен?

Җитдиләнә китеп, бер тынара ияк каккалаган рәвештә уйчанланып тора, аннары киң, таза иңбашларын яза җибәреп:

— Ялгышасын, туган: без ими имүләрдән күптән узган инде! КамАЗ өчен кем без? Аның аерылгысыз бер өлеше түгелме? Монда сүз Урак белән Чүкечнең чынчынлап дуслаша белүе хакында гына булуы мөмкин! Ватмыйча-җимермичә берсен икенчесеннән кубарып алмау хакында гына! Тап инде Советлар иленең Байрагында яисә Гербында береккән Урак белән Чүкеч шикелле! Менә нидә хикмәт! — дип күңелле кеткелди-кеткелди тегенең авызын җәт кенә ямап куя иде...

13

Хәнәфи бик хәтерли: өченче елны, юк, аңардан да элгәрерәк әле, алар совхозының сугарулы басуларына бер төркем олы җитәкчеләр килеп чыккан иде. Арада Казаннан партиянең өлкә комитеты секретаре да, төрле министрлар һәм җаваплы вәкилләр-дә, шулай ук Мәскәүнең үзеннән сугару министры да бар иде. Яшелчәлек плантацияләрен әйләнеп үттеләр — яшелчә, аерата кыяр-кишер һәм кәбестә-помидор, галәмәт уңган, күзләрнең явын алырлык иде, җитәкче агайлар соклану-лы тел шәпелдәтүләреннән һич бушый алмадылар. Ә менә культуралы болынлыкка җитеп, хәтфә үлән арасына кереп баскач исә...

Ул чакта сугарулы болыннары нибары ике йөз илле-өч йөз гектарлар чамасында гына иде әле. Әмма ике «Фрегат» кайтартылган һәм басуда көйләнеп, инде ходка җибәрелгән иде. Келт тә челт иттерә иде автомат җайланмалары.

Август башлары иде кебек, культуралы болынлыкта печәнен бер кат чабып алганнан соң, үләннәр әйбәт кенә куеланып һәм сусылланып, кабаттан тездән дә югары күтәрелеп өлгергән иде инде. Көн кояшлы һәм ярыйсы

ук жилле иде, «Фрегат»ның сөттәй ак яңгыр болытында салават күперләре балкый, ә хәтфә үләннәр өсләтә аксыл-сорыланып көмеш дулкыннар тәгәрәшә иде...

Җитәкче агайлар хәйран кыяфәттә ис-өннәрен җыеп, байтак вакыт дәшми-тынмый күзәтеп тордылар. Менә шул мәлне партия өлкә комитетының беренче секретаре, олы гәүдәсе белән чак кына борыла-кыйшая төшеп һәм бер кулын башындагы сыек-көрән төстәге чүпрәк кепкасына тидереп, икенчесен Мәскәү министрының иңбашына орындырып, иләсләнгән бер тавыш белән әйтә салды да инде:

— Сез анда, Федор Евдокимович, сугару җиһазларын бик тә жәлләп кенә җибәргәлисез. Бик тә жәлләп!.. Ә монда? Күрәсезме, үләннәр өстеннән дулкыннар ничек матур тәгәрәшә! Нәкъ инде яңа сауган сөт дулкыннары! Ә, юк, каймак, сөт өсте шулай күз явында салмак-салмак дулкыннар булып, ыспай гына тәгәрәшә! Хәйранның да хәйраны түгелме соң, ә?

Шулчакны Мөслим Акбашев, уч төбенә йөткергәләп алды да, күз карашын министрга төбәгән хәлдә, кыюланып үз сүзен кыстырды:

— Җитәрлек күләмдә җиһазлар кайтса, тагын да хәйранрак булыр иде әле!.. Сез, Федор Евдокимович, сөт өстен, әлбәттә, ярата торгансыздыр инде... әллә бик үк яратып бетермисезме?

Министр, бер тын ара күзләрен челт-мелт иттереп йомгалап торгач, кинәт рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Сөт өстен яратмыйлармы соң? Табыннарыбыздан өзелә генә күрмәсен! — Аннары ул, дустанә бер хәрәкәт ясап, уң кулын Акбашевның иңенә салды.— Турысын әйтим, моңа кадәр мине шушы тикле оста һәм матур иттереп бер почмакка кысрыклаганнары юк иде әле!.. Ә сездә чынлап та әкәмәтләр икән шул! Ярый, хөрмәтле Мөслим Гайнаныч, сез дигәндә, юкны да бар итәргә тырышырбыз инде!

Әнә шул җәйдән текә борылыш ясалып, биек үрләрне яуларга юл җайлары капыл ачылды да куйды. Ни дисәң дә, КамАЗның шәһәр тирәли зонасы, ә бу зонада алар совхозы күз өстендәге каш кебек шул.

Инде әнә узган җәйдә ул соры-аксыл дулкыннар «сөтләнеп-каймакланып» дигәндәй, куе һәм сусыл үләннәр өсләтә меңләрчә ике йөз гектарлар чамасына җиткән киңлекләрдә тәгәрәште. Кай араларда диген!

Ә бит моңа өстәлеп, яшелчәлек плантацияләре бар, кукуруз һәм мал чөгендере басулары, берьеллык үлән-

жирләре бар! Барын бергә кушсаң, бүген үк искитмәле бит инде!!

Юк, моның белән генә тукталмаячаклар — сугарулы җирләрен тагын да җәелдерәчәкләр әле. Шушы алдагы язда һәм җәйдә өр-яңа «Волжанка»лар, «Фрегат»лар кайтачак, болары янына «Днепр» дип аталганы тагы. Бу азаккысы хакында әлегә ишетеп кенә беләләр иде, аныسы нидер?

Үрләр, үрләр... Яуланган хәтлесе, яуланасылары... Зур сикереш, яңарыш!

Акбашев, саф һәм иркен суда йөзгән балык шикелле, һәр чакны да үзе яраткан һәм белгән стихиясендә сыман иде... Ул текә һәм авыр үрләр яулаган мәлләрдә дә, кайберәүләр кебек, тиккә шапырынмый, хәтта үзендә артык дулкынлану, әсәрләнү чалымнары да сиздерми иде...

Ә юк, ихтыяры никадәр нык булмасын, ул да бит адәм баласы, аның да бит күкрәгендә лепелдәп торган йөрәге бар. Хәнәфи моны бермәлне, совхозларында өр-яңа, хәтәр дәү комплексны эшкә җигәргә әзерләнгән хәлләрдә аерата нык сизде...

Ул көзне совхоз терлекчелегендә гаять киеренке хәл туган иде. Юк, азык җитмәүдән түгел, анысы, киресенчә, җитәрлек, хәтта артыгы белән күп хәстәрләнгән иде. Бар хикмәт терлек биналарының кысанлыгында иде. Иске абзар-куралар инде шактый таушалган, аларны рәтләп-төзәтеп бетерерлек түгел иде. Бар өметләре яңа комплекста иде. Аны исә төзүчеләр, ай-һай, озакка суздылар. Җәен үк андагы бар эшләрне төгәлләп тапшырасылар иде, булмады, сентябрьгә калдырдылар, аннары октябрьгә күчерделәр...

Борын төбендә зәһәр кыш. Меңәрләгән хайванны кая куеп, кайларга сыйдырып бетермәк кирәк?

Комплекс экспериментал, республикада иң заманчасы... Аның бер төшен төзеп бетерсәләр, икенче төшен сүтеп, кабаттан рәтләргә тотыналар иде. Аерата төрле механизмнар һәм автоматлар белән иза чиктеләр: монтажлыйлар-көйлиләр, өсте-өстенә үзгәрешләр кертәләр — һич бетәсе, һич очына чыгасылары юк кебек.

Ул арада, октябрьнең икенче яртысында, зәһәр суыклары белән иртә кыш килде. Килде генәме соң, яман яу сыман көтмәгәндә басып алды. Менә сиңа мә!..

КамАЗ төзүчеләре белән завод халкына синең мал исәбең кирәкмени? Аларның табынында сөте-мае, каймагы-эремчеге, бөтәне өзелмәсен. Ә монда исә... Шушын-

дый кыен хәлләрдә чамасыз кысанлыкта савым кимемиме соң?!

Акбашев көннәр буе бар кыяфәте белән ачуташ чәйнәп йөрде. Бүтәннәр дә шулай...

Тегендә төзүчеләр белән монтажчылар да, хәлнең чынлап та яман икәнлеген аңлап алды, ниһаять: алар көнне төнгә ялгап эшләүгә күчте. Совхоз да аларның кул арасына кереп булышмага үз осталарыннан махсус бригада төзеде. Арада улы Рәмзи белән Хәнәфи Бариев та байтак көннәр комплекста батып ятты.

Ниһаять, көне җитте, вакыты сукты!

Ноябрь башында, Октябрь бәйрәме алдыннан булды ул хәл...

Комплексны кабул итеп алуда дәүләт комиссиясен республиканың авыл хуҗалыгы министры урынбасары җитәкләгән иде. Комиссиядә төрле белгечләр — кыяфәтләре эредер, чамасыз җитдидер. Ни дисәң дә, республиканың терлекчелек тармагында иң дәү, иң яңа объект ләбаса!.. Күпләрнең үз гомерендә мондыйны кабул итеп йөрү түгел, моңа кадәр күргәне дә юк иде әле...

Комплекста гаҗәпләнеп һәм сокланып карардай нәрсәләр чыннан да аз түгел иде. Бүтәнен әйтәсе дә юк, аерым блокларда буаз сыерларга профилакторий, ә яңа туган нәни бозауларга исә үзенә күрә «ясли-балалар бакчасына» тикле бар иде...

Комиссия койрыгына тагылып Хәнәфи дә йөргән булды, ул, үтә эшлекле кыяфәттә эре сыманланып кыланган әгъзалардан әле берсенең, әле икенчесенең, балавыздай эри язып:

— Без моңарчы күргән-белгән фермамыни бу? Чын әгәр, фабрика дисәң, фабрика!

— Мал-туар яшәр дә димәссең. Культура сарае үзе! — диебрәк ычкындырган чуклы-чаклы сүзләрен колагы белән элеп алгалады.

Азактан тиешле документларга кул куяр алдыннан шактый гына киеренкелек туып, төзәтеп һәм көйләп бетерәсе эшләр хакында озын гына исемлек төзелсә дә, комиссия төзүчеләр һәм монтажчылар хезмәтенә шартлатып «яхшы» билгесе куйды.

Совхоз эшчәннәре, ниһаять, җиңел сулап җибәрде... Ләкин иң кызыклысы соңрак туды.

Нәселле кара-чуар таналарны икенче көнне үк алып килделәр. Аларны Чуар белән Гәрдәле фермасында асрарга мөмкинлек калмаган иде инде. Юл арасы байтак иде, бу чибәрләр шактый алҗыган иде, якты һәм иркен

«бокс»ларда ныгытып, тәмләп тамак туйдыргач, алар төркем-төркем үз урыннарында — агач идәнгә корсак җәеп яттылар. Тәртип! Әдәп!.. Гүя аларның һәркайсын шушы ялт иткән «хан сараенда» үзеңне ничек тотарга кирәклеген алдан ук өйрәтеп куйганнар иде. Һәм аларның дымлы зур күзләре бик җылы, бик мөлаем карый, шул ук вакытта чибәр таналарның күз карашында: «Монда шундый иркен, шундый рәхәт, ә сез безне шайтан да яшәмәс алама хәлләрдә асраган идегез. Ник алай иттердегез соң, и адәмнәр?» — дигән үпкәле төсмер дә бар иде сыман...

Бераз хәл җыеп алгач, һәммәсе бердәм диярлек яткан җирләреннән купты. Алар инде яңа шартка ияләшеп бетә язганнар иде, ахры, торуларына бер-беренә ышкынырга, төрткәләшергә, уйнакларга тотындылар. Тамак тук, урнашкан йортлары иркен, якты һәм җылы — нишләмәк кирәк тагы?

Тагын бер көн үтүгә, савым сыерларны куалап китерделәр. Бер көтү. Бу кара-чуарлар моңа кадәр Әҗер фермасында, инде ташланырга тиешле булып та ташланмыйча тотылган тәмам таушалган биналарда асралганнар иде. Боларның үткән юллары тагын да ерактанрак, туңга сөрелгән басулар, уҗым кырлары аша иде. Бәхетләренә, кыр-басуларга кар бик юка яткан иде әле.

Комплексның үзләренә тиешле блогында дәү ишекләрдән эчкә керергә теләми интектерделәр. Азаплы, озын юлның каткан кәсләреннән тояк авырттырып килә-килә сөтбикәләрнең карыны бик нык ачкан иде, әлбәттә. Ә тегендә, якты һәм киң блок эчендәге озын транспортерга туклыклы, сусыл сенаж инде салынган иде, аның хуш исе, ниһаять, сыерларны суырып кына алды эчкәрегә!.. Тамак тәмугка да кертер, диләр шул!

Ашагач, кара-чуар сөтбикәләр, ни кылырга белмәстән, бик тә шөбһәле кыяфәттә, байтак кына вакыт кымшанырга да өркеп, басып тордылар. Ахырда, арыганлыклары үзенекен итте: кайсы кайда басып торган булса, шунда — агач сайгакларга, тирән траншея өстен каплаган чуен рәшәткәләргә — бик тәртипсез рәвештә, бөтенләй буталып сузылышып ятты. Корсаклар тулы иде, йоткан азыкны кабаттан эшкәртергә тиешләр иде кебек, әмма күшәү юк, ни юк... Муеннарын сак кына боргалап, шар ачкан зур күзләре белән тегендә карыйлар, монда төбәләләр. Авыр-авыр сулап куйгалыйлар. «Бу ни хикмәт икән бу? Шушындый зиннәтле сарайда асрарга җыеналармы? Әллә газиз башкайларыбызның

бетүләре шушында булыр микән?» — дип, чиксез шикшөбһәдә тәмам каушап калганнар иде, ахры...

Кая монда хайван, кеше булып кеше, искәрмәстән килеп керсә, хәйран аптырашта калыр иде: түшәменнән йомшак көн яктысы сибелеп торган, галәмәт иркен завод цехы дияр идең, станоклар гүләве ишетелми, кешеләр күренми, тик буйдан-буйга сузылган транспортер, автоэчергеч линияләре һәм хикмәтле чәбәләндереп тотылган тимер киртәләр арасындагы киң бүлемтеләрдә ала-кола сыерлар гына мышнап ята... Әкият булмый сиңа!

Сөтбикәләрнең беришесе күзләренә мөлдерәмә яшь тә чыгарган шикелле — андыйлары, дәү капкалар ачылып китсә, минуты белән дөнья иркененә чыгып шылырлар иде бугай...

Ләкин хикмәтнең дә хикмәте кичке савым вакыты җиткәч туды. Яткан җирләреннән авыр булса да куптылар кубуын, ачып җибәрелгән тимер киртә араталарыннан да ипле генә үттеләр, әмма саву бүлемтесенә кермиләр генә бит! Дүрт аякларын терәп кенә түгел, сыннарын катырып каршылар! Ялгызлап та, укмашып та әле болайга төртеләләр, әле тегеләйгә чайпалалар...

Монда инде терлек караучылар, зоотехниклар мәш килә: чуарбикәләрнең сыртларыннан сыйпаштыралар, төртәләр, чәбәклиләр, мөлаем-йомшак тавыш белән дә эндәшәләр, зәһәр сүгенеп тә җибәргәлиләр:

— Җә инде, җә, сөтлекәч... Саумыйча гына ничек инде?

— Их, анаңнан саташып туган нәмәрсә! Бу хәтле акаймасаң соң!..

Директор Мөслим Акбашев белән Хәнәфи Бариев та шунда иде. Бер арада директорны ишек төбендә бүлемте почмагына кысрыкладылар, тегенең һич борылыр җае-әмәле калмады, көчкә котылды, ә Хәнәфине исә бер чуары мөгезләре белән бетон диварга китереп терәде, тагын чак кына көч салса, рабочкомыңны бөтенләйгә сытып-изеп ташлыйсы иде...

Саву бүлемтесендәге «елочка»ның ялтыравык никель уентысындагы тәмле комбикормага танауларын төрткәч, сыерлар тына-тынычлана язды, әмма барыбер гәүдәләрендәге калтырау басылып бетмәде әле. Монда инде ак халатлы савучы-операторлар ыгы-зыгы хәрәкәткә килә, аларның үпкәле-шуклы авазлары яңгырап куйгалый иде:

— Күрче, монысы да имчәгенә тикле дерелди. Бу хәтлем дә... Һәйт дим, сиңа әйтәм!

— Җә инде, җә, чуар гына аккынай! Алай саранланма сана! Үзеңә зыянга гына булуы ихтимал бит!

Сөтбикәләр сөт бирергә һич теләми иде. Аларга һушларына килү ансат түгел иде, күрәмсең...

Мөслим Акбашев, әле сыерларның сыртларыннан сыпыргалап, әле учын-учка шапылдаткалап, шырык-шарык көлүен белә иде:

— Кешеләр, дибез... Менә бит малкайлар да өр-яңаны тиз генә кабул итәргә теләми... Аларда да психология! Ничава, ничава, өч-дүрт көннән тәмам ияләшеп бетәрләр әле... Адәмнәр белән кыенрак...

Беренче көннең кичке савымында өч-дүрт сәгатьләп иза чиктеләр шулай...

Кич тып-тын иде. Дөм-караңгы күк гөмбәзеннән сирәк-мирәк кенә кар бөртекләре төшкәли.

Акбашев үзенең «уазиг»ын инде әллә кайчан ук кайтарып җибәргән иде. Шул сәбәпле асфальт юл беләм Яңа поселокка таба җәяүләп кенә киттеләр. Бераз юл алгач, тукталдылар.

Каршыларында офык буйдан-буйга бихисап утларда балкый. Карашлары шул тарафларда...

Анда, әнә шул бихисап утлар артында, бик-бик еракларда, башкаланың үзендә бу көннәрдә аларның байтагына тиешле документлар хәстәрләнә. Озакламас, хөкүмәтнең дан бүләкләре кайтып та җитәр.

Ләкин шушы сәгатьтә алар — ни Хәнәфи Бариев, ни Мөслим Акбашев — бу хакта берни белми, аны хәтта уйларына да китерми иде әле.

Аларның уй-хисләре бөтенләй бүтәндә иде.

Әнә якында гына, Әҗер урманы башындагы киң уенты аланлыкта, көлтә-көлтә яктылык нурларына күмелеп, аларның иң Олы куанычы балкып утыра. Кем әйтмешли, үзе бер фабрика! Республиканың сөт җитештерү тармагындагы флагманы менә инде сафта!

Өсләреннән тау төшкәндәй, җаннарында гына түгел, гәүдәләренең һәр буынында илаһи бер җиңеллек...

Иркенәеп сулыш алып куйсалар, күкрәк читлекләренә дөньяның бар саф һавасы кереп тула шикелле...

Ә офык буйлата җәелгән ут дәрьясының балкышы көчәйгәннән-көчәя бара сыман. Аның бер өлешендә автомобильләр җыю заводы. Анда баш конвейердан бу минут, бу сәгатьләрдә дә сынау-көйләү режимында шанлы КамАЗлар бер-бер артлы җыелып төшә тора...

КамАЗлар... Монда да бит шуңа тартым хәл, монда, комплекста да сынау-көйләү режимы лабаса! Хәер, аермалары да бәләкәйдән түгел: тегендә тоташтан җансыз нәрсәләр белән эш итәләр, монда исә тумыштан ук җанлы... Хәтта үз психологияләренә тикле бар!

Акбашев нык, таза кулын Хәнәфинең иңбашына салды.

— Булды!

Мөслим Акбашев нибары бер сүз генә әйтте, әмма аның тавышында чын ирләрчә куануның тыйнак һәм салмак тибрәнеше аермачык беленде.

14

Шулай, зур куанычлар булмый тормый. Ләкин ул куаныч-шатлыклар чиксез кыенлыклар, чамасыз киеренкелек аша, йөрәк майлары тәмам суырылып беткәч кенә, кадерле һәм тансык җимеш рәвешендә өлгереп килә. Бу — уртак хезмәтләрендә шулай.

Ә кешеләр белән, адәмнәр язмышы белән ничегрәк?

Мөслим Акбашев: «Кешеләр белән күп кыенрак»,— дип хаклы сүз әйтте, ахрысы...

Бер вакыйга Хәнәфинең күңеленә тирән уелып керде...

Җәй азагы иде. Көн җылы, тымызык иде. Хәнәфи кичке уңайда яңа поселоктан әйләнеп кайтырга исәп итте. Анда берничә гаилә яңа квартирага күченгән, менә шуларның яңа шартлардагы тормышы белән танышып, хәл-әхвәлләрен белешеп кайтасы килде Хәнәфинең. Ә кайтышлый исә хайванчылык комплексына сугылып, анда кичке сменада бетон башняларга сенаж тутыручы һәм траншеяларга силос салучыларның хезмәтен үз күзләре белән күреп чыгарга ниятләде. Көннәр әйбәт торганда, әлеге эшләр тегендә төн урталары җиткәнче диярлек дәвам итә иде.

Әнә шундый уй-ниятләр белән әрҗәле мотоциклда асфальт юлдан җил-җил менеп барган чагында, инде Яңа поселокка җитәрәк соңгы үрне алдырганда, Хәнәфи ни күрсен: тегеннән аңа каршы таба, шулай ук әрҗәле мотоциклда, берәү җан-фәрманга төшеп килә. Соры кепкасын маңгаена батырып ук кигән, яшел плащ чабуларын җилбәгәй җибәргән... Бәй, Әртәми Вәсилич ләбаса! Әүвәлге Үтәдем кешесе, инде артта калган елларда киң басу күкрәкләрендә җәелгән ярышларда Хәнәфинең

алышташы-көрәштәше дә, дусты да... Ни эшләр бетереп йөри, ни йомышы төште икән?

Әртәми Вәсилич та аны, әлбәттә, ерактан ук танып алды һәм, аралары якынайгач, мотоциклының газын кимәтә төшеп, тукталырга ишарә ясады.

Тукталмыйлармы соң! Күрешмәгәннәренә ни гомерләр бит инде!

Ике таза ир, асфальт юл уртасына баскан көйгә, кочаклашып ук булмаса да, бер-берсенә каккалый-суккалый бик тә җылы һәм дустанә рәвештә күрештеләр. Аннары Әртәми Вәсилич Хәнәфине кырыйга, үзенең мотоциклы янына алып килде. Менә шунда юл читенә, күтәртелгән дамба каршына утырыштылар да бик тәмләп үзара хәл-әхвәл белешергә керештеләр. Әртәми Вәсилич үзе һаман шул бер хезмәттә — Яңа кала урамнарына, автогигант корпуслары тирәсендәге юлларга асфальт җәюдә икән, ә хатыны Мария исә, калага күченеп киткән Үтәдем хатыннарының бик күбесе кебек үк, ашханәдә эшли икән. Аларның бердәнбер уллары Володя инде өйләнеп җибәргән, инде нәни кызлары да бар икән. Бары бергә өч бүлмәле иркен генә квартирада шау-гөр килеп, күңелле генә яшәп яталар икән. Әртәми Вәсиличның әнисе Мәтрүнә карчык исә... аның исемен телгә алуга, Әртәми Вәсилич кисәк ык-мык итеп калды, йөзенә капыл караңгылык инде. Хәнәфи бу хәлгә үтә сәерсенсә дә, аны-моны әйтмәде, кабаттан сорашмады.

Әртәми Вәсилич чырайга шактый ук олыгайган. Чигә чәчләренә мәңге эреми торган кырау кунган, маңгай җыерчыклары шулай ук нык ишәйгән һәм тирәнәйгән, эчкә батып торган зәңгәрсу күзләре дә, бик нык алҗыган кешенеке сыман, үтә моңсу карыйлар иде.

Хәнәфинең сәерсенеп куюын ул, әлбәттә, сизми калмады, ләкин ул, уң кулын Хәнәфинең иңенә салган көенчә, тавышына ярыйсы ук көр төсмер биреп, әйтә салды:

— Ә сезнең монда хәл-әхвәлләр, Хәнәфи туган, бер генә дә начардан түгел, ә! Ишетеп тә торам, күреп тә йөрим: алга табан шәп кенә тәгәрисез! Бигрәк тә иген уңышлары җәһәтеннән, ә!

— Әйе, алай сынаткан юк,— дип көлемсерәде Хәнәфи, иягең сыпыргалап.— Сикәлтәле юллардан, җаен-чамасын белеп кенә, әкертенләп шулай тәгәрәштерәбез инде текә үрләргә табан...

— Чын, валлаһи, җәйләрен басулардан бер әйләнсәм, күңел әллә нишләп китә... Ә бит мин, Хәнәфи дус, җәйгә чыктым исә, бер генә әйләнмим... их! — Әртәми

Вәсилич, тирә-юнене күз йөрткәләп, бик тә тирән иттереп сулап җибәрде һәм шапылдатып тез капкачына сугып куйды.— Тик басу-кырларны иңләп йөргән чакларымда нишләптер сине туры китерә алмауларым гына... Бу елны да менә...

Хәнәфи аның туган як басу-кырларын айкап йөрүләре турында аны күргән-белгән кешеләрдән ишеткәләгән иде, һәм ул андый хәлгә алай бик ис-өн җибәрмәгән иде. Хәзер дә ул әүвәлге дустына җиңелчә кеткелдәп җавап кайтарды:

— Югыйсә минем басулардан кайтып кергән дә юк диярлек. Һаман да яландагы халык арасында!.. Сукмакларыбыз кисешергә язмаган, күрәмсең. Аймылыбрак йөргәнбез.

— Шулайдыр, язмаган булгандыр...

— Соң, син Әҗер юлын таптамаган кеше түгел бит. Өемнең дә кайдалыгын, шәт, онытмагансыңдыр әле. Ә безнең капка исә, үзең дә бик әйбәт беләсең, гел дә уңай якка гына ачылып тора — рәхимнәр генә ит!

— Анысы алай да... Ничектер уңайсыз барып керергә бу хәлләрдә... мескенләнәсе килми...— Әртәми Вәсилич, авыр сулап, тез капкачына янә сугып куйды.— Ә бүген менә, шушылай басуда яисә юлда очратмасам, өеңә барып кермәкче идем. Чын, валлаһи, җир тишегеннән дә эзләп табасы идем. Никме? Их, дускай, киңәш-табышсыз гына яшәп буламыни бу дөньяда? Ә син миңа үлеп кирәк бүгенгесе көнне! Акыллы киңәшең, җылы сүзең кирәк!

— Ни икән? Тыңлап карыйк алайса,— диде Хәнәфи, сагая төшеп.— Тик киңәш дигәнең генә... Юньлесен, син теләгәнен биреп булырмы икән?

— Син дә бирмәгәч, кем тагы?

Хәнәфи, башын бора төшеп, элекке дустына текәлебрәк карады. Әртәми Вәсиличның шома кырылган, әмма кояшта-җилдә тәмам кучкылланып беткән какча йөзенә аптырау катыш йөдәү дә, ялвару-инәлү дә — бары бергә иңгән сыман иде. Менә ул соргылт кашларын куша язып, маңгай җыерчыкларын ишәйткән хәлдә — үгезне мөгезеннән эләктереп алырга бик вакыт икәнлеген шәйләп ахры — киң бер сулыш белән кинәт кенә ярып салды:

— Син турысын гына әйт әле, Хәнәфи дускай, мин киредән совхозга әйләнеп кайтсам, ни дияр идегез? Алыр идегезме?

— Алмаганнар кая! Бик рәхәтләнеп! — диде Хәнәфи, авызын киң җәеп.

— Юк, син ихлас күңелдән әйтәсеңме моны?
— Ихластан булмыйча... Минем кайчан рияланганым бар?
Әртәми Василичның туган совхозы кырларын айкап йөрүләре тиктән генә булмаганлыгын, җитди сәбәбе барлыгын Хәнәфи элгәре үк бик әйбәт шәйләгән иде. Алай тынамы, Әртәми Василич үз ниятләрен кайберәүләргә чишкән дә иде. Инде, ниһаять, көне җиткән, сәгате суккан, күрәмсең...
— Соң сез инде хәзер совхозга яшьрәкләрне җыясыз түгелме? Минем кебекләр ярап бетәрме? Инде бит пенсиягә дә бер генә адым калып бара лабаса.
— Шактый әле. Бирешергә җыенма! Әле җирләр җимертәселәрең бар! Аннары, синең кебек, минем кебекләр пенсиягә чыккач та тик ятар димени?
— Шулай анысы, корсакка май җыеп ятучылар токымыннан түгел үзе... Эш табылыр, димсең, алайса?
— Синең кебек ата механизаторгамы? Табылмаганнар кая! Көне-сәгате белән!
— Рәхмәт, дускай, җылы сүзләреңә! Болай булгач... тукта, мин миңгерәү керәшен тәресе, онытып та җибәргәнмен: коры кашык авыз ерта диләр лабаса! Без мондыен сөйләшүне...— Әртәми Васил‌ич, яшел плащын кыштырдатып, утырган җиреннән җәт кенә купты да янәшәдә торган мотоциклы янына барды һәм аның әрҗәсеннән күн букча алып кире килде.— Үз өеңдә утырырбызмы әллә дигән идем, ярый инде, сәхра иркенендә тагын да шәбрәк...
Күн букча эчендә «ак башлы» күренә, шунда ук кәгазьгә төргән нәрсәләр дә бар иде.
— Тамакны, дим, азрак чылатып алыек әле шушындый да важный хәлләрдә. Кабарга улсы-бусы да бар...
— Менә бусы бер дә ярардай эш түгел инде, Әртәми дус,— диде Хәнәфи, йөз чытып.
— Нәрсә, үткән-сүткән кешедән шүрлисеңме? Әйдә, алайса, әнә анда каеннар арасына кереп утырыйк... Аулакка! — диде Әртәми Васил‌ич, каршыларында шау яшеллеккә төренеп утырган каен посадкасына ишарәләп.
— Хикмәт үткән-сүткәннәрдә генәмени? Яңа поселокка кеше арасына менеп барам. Килешмәс, дим... Әле бер иркенләп утырырбыз, язган булса... Аннары бит син дә рульдә, мин дә рульдә...
— Әй, руль дигәнеңә төкерер идем лә бүгенгесе көнне! Безнең гәүдәгә ни бу? Сеңә дә бетә! Җәл, кеше ара-

сына менәм дисең шул... Ярый алайса, бу шайтан суыннан башка гына...— Әртәми Вәсилич авыр көрсенү аша күн букчаны читкәрәк этеп куйды һәм шуның арты ук көр тавыш белән бүленеп калган гәпне тергезеп җибәрде:— Алайса, эш табылыр, димсең?

— Әйттем ич: көне-сәгате белән!

— Кабаттан рәхмәт җылы сүзеңә!.. Их, Хәнәфи туган, дускаем, аңласаң ла икән хәлләремне: туган басулар төшләремә кереп йөдәтә ләбаса! Ул җир сөреп йөрүләрем, актарып ташланган, ялтырап яткан буразна сыртлары, шаулап тәгәрәшкән иген дулкыннары, алтын бодай көшелләре...

— Ә мин гагы, кала җиренә китеп, көрәп-көрәп акча алган кешенең төшенә бөтенләй бүтән нәрсәләр керә торгандыр дип уйлый идем, тилебаш.

— Көлмәсәнә!.. Менә иснәп кара әле бу киемнәрне! Нинди ис килә? Ачы асфальт исе, сумала, төтен исеме? Ә бит бу яман ис киемгә генәме, тәнгә дә сеңгән, хәтта ки җанга да!.. Ә минем кабаттан сафланасым килә, тәнгә дә, җанга да кабаттан басулар исен, ашлык исләрен сеңдерәсем килә!

— Тәнгә дә, җанга да, димсең? Ипекәй исен, димсең? — Моны әйткәндә Хәнәфинең дә тавышында исәрләнү кебегрәк нәрсә чагылды.

— Шулай дим! Мин генәме соң? Әнә минем Мария ашханәдә эшли, җыен ризык-ниГъмәт эчендә... Әмма ул да авылдагы тормышын үлеп сагына. Ул бит үтә дә малтуар җанлы минем.

— Беләм инде.

— Белгәч соң...— Үгезне мөгезеннән нығытып эләктереп алганлыгын Әртәми Вәсилич бик шәйли, әмма аны аударасы да бар ич әле, һәм ул, сүз сөрешендәге кызулыкны һич киметмичә, рабочком дустына төбәлгән килеш, күңелендәге шикне чыгарып салды:— Ә тору җәһәтләреннән ничек булыр? Фатир мәсьәләсе, дим...

— Курыкма, ялан кырда калдырмабыз,— дип көлемсерәде Хәнәфи.— Палаткада яшәмәссең, булыр сиңа фатир.

— Соң... соң... сез фатир тоттырганчы, адәмнәрне өчдүрт ай буена сынап карыйсыз түгелме?

Бусына Хәнәфи кеткелдәп үк куйды:

— Сиңа нинди сынаулар булсын ди! Утыз ел буена туган басуларыңа маңгай тирләрен түгеп бик шәп сыналганнардан түгелмени син!

Әртәми Василич үзе дә хихылдап куймыйча булдыра алмады. Җаны эреп, йомшарып...

— Ә кайчанрак булыр, димсең?

— Алай бик сузмабыздыр. Әле шушы арада берничәләп гаилә яңа фатирга күченгән иде. Озакламый янә унлап фатирны өлгертәчәкләр. Син үзеңне әнә шул исемлектә, сыналганнар исемлегендә дип исәплә, дускай!

Әртәми Василич, брезент плащын кыштырдатып, кымшангалап алды, аның зәңгәр күзләрендә исә житез, әмма бик тә ягымлы очкыннар биешеп куйды.

— Мең рәхмәтләр инде, Хәнәфи туган! Андый игелекләр кылып торганда, мин үзем сынатаммы соң! — Бу сүзләрне шактый ук күтәренке рухта әйткәч, Әртәми Василичның тавышына янә шөбһәле төсмер керде.— Син шулай дисең дә бит, директорыгыз бар, бүтәннәр бар, алар ни дияр икән?

— Моңарчы андый нәрсәне хәл иткәндә, рабочком сүзенә колак салмый тормаслар иде, хәтта уртага куярлар иде.

— «Иң әүвәл рабочком Хәнәфине күреп сөйләш» диюләре тиккә түгелдер шул. Әйләнә-тирәдә мең абруйлы ла син, Хәнәфи туган.

Бусы инде күрәләтә салпы якка салам кыстыру иде, әмма Хәнәфи эреп китәргә ашыкмады, ирен читенә көлемсерәү галәмәте чыгарган килеш, коры гына әйтә куйды:

— Шөкер, куктәге болытка атланып йөзмибез, җирдә йөрибез. Кешеләр белән эшлисе дә, яшисе дә...

Инде сөйләшәсе сүз сөйләшенгән, хәл итәсе нәрсә хәл ителгән, ике ир — ике дус инде хәзер, урыннарыннан кубып, аерылышсалар да булыр иде. Ләкин, алай итсәләр, бу очрашу, бу гәп Хәнәфинең күңелендә тирән эз калдырыр иде микән әле? Шушыңа тартым очрашусөйләшүләр аз булып торамыни аның көндәлек тормышында, аз төшәмени аңа төрле кешеләрнең йомышы?

Бүген исә аны уйга да китерә алмастае көтә икән...

Бермәл тын гына утырдылар. Әртәми Василич авыравыр сулап куйгалады... Хәнәфи соңыннан гына аңлады: моңа хәтле сөйләшкән-килешкәннәре дусты мәелендә үзенә күрә кереш кенә булган, иң житдие һәм авыры ахырга калдырылган икән...

Ә хәзер исә ул авыр-авыр сулап куйгалаган Әртәми Василичкә сәерсенебрәк күз атмыйча булдыра алмады: әле генә бик тә җанлы, бик тә көр күңелле күренгән абзаның кара-кучкыл какча йөзенә янә күләгә, хәтта бер

төсле нәүмизлек иңеп өлгергән, аның авызыннан сүзләре дә сыктану-уфтану аша изелеп-яньчелеп чыга башлады:

— Куандырдың, рәхмәт, дускай! Әмма... әмма минем өчен ярты куаныч кына шул әле бу! Никме? Бер таш капчыктан икенчесенә күчү генә була бит әле бу! Үзеңә аерым йорт белән, үз ишегалларың, янәшәдә үз бакчаларың, һич югы, кош-кортлар асрап яшәсәң икән менә!

— Тукта, сабыр, тора-бара без сине мансардный дип аталганына ирештерербез әле, бәлкем. Өметеңне өзмә! Анда шартлар бүтәнчәрәк...

— Анысы да таш йорт шул... Минем үземә дә, Мариягә дә бик ярар иде ул, бик шәп булыр иде. Иркенләп яшәүнең җайларын таба белер идек. Тик менә минем әнинең хәлләре... син әйбәт белгән Мәтрүнә түтиеңнең...

— Ни булды аңа? — дип текәлде Хәнәфи, сулышын кысып.

— Каты сырхау ул... Бер терелә, бер үлә, дигәндәй... Ахыр чикләргә җитеп йөдәде инде. «Их, ди, ахыргы көннәремдә әүвәлгечә агач җортларда, кош-корт, мал-туар арасында, аларның тавышын ишетеп, үз өемдә җанган учак җылыларын тоеп, җалкын җактыларын күреп, аз гына җәшәп калсам ла икән», ди...

— Ә нинди чир соң аңарда?

— Яман чир. Моңа хәтле без ишеткән-белгән чир дә түгел...

Бераздан керәшен дустының уфылдап-сулкылдап сөйләвеннән Хәнәфи аңлап алды: боларның авылы бетерелеп, яңа калага күченүләренә, куркыныч хәл үзен алай нык сиздермәгән икән, Мәтрүнә түти, шыңгырдап кына булса да, үз җегәрендә йөрүен белгән, әмма соңгы берике елда бик нык какшап киткән: ни иркен, ни уңайлы квартираларында һава җиткерә алмый йөди, ди, буыла башлый, күбенеп-шешенеп йөри, ди... Врачларга каралып-тикшертеп йөри торгач, ахырда белгәннәр: «аллергия» дигән, моңарчы гомер ишетмәгән чир икән. Таш йортта яшәү килешми, ди...

— Безнең Мәләкәс белән Бордыбаш авылларында кардәш-ыру бар. Керәшен туганнар... Шунда китеп, икеөч атна торуына кабаттан сафланып, җегәрен тутырып кайта. Берни булмагандай! Әмма кайтып ике-өч көн торуына, кабаттан күбенә башлый, кабаттан тереле-үлеле хәл... Кайчакларны балкон ишеген яртылаш ачып, төн ката саф һава сулап үткәрә...

Инде хәзер Хәнәфи үзе дә сыкрану-уфтану аша тирән сулап куймыйча булдыра алмады. Алар әледән-әле ишеткәләп торгалыйлар иде тегендә, кала җиренә күченеп яши башлаган Үтәдем кешеләре, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр: «Их, туган авылымның алсу таңнары, челтер-челтер чишмәләре, тирәкләр шавы, чирәменең җомшаклыгы» дип, фәләне-төгәне дип, зар түгүләрдән, үлеп сагынулардан бушана алмыйлар, ди. Ә бит монда, Мәтрүнә түти язмышына килгәндә исә, бөтенләй әллә ниткән, әйтсәң, кеше ышанмастай хәл... Хәнәфинең йөрәге авырттырып чәнчеп-чәнчеп куйгалады...

— «Ни гөнаһларым өчен Кристос аллабыз мине бу тикле җәзалый икән?» ди... Ә болай йөрәге таза әле аның. Былтыр ике тапкыр, бу елны, җәйгә кергәч, бер тапкыр Минзәләгә келәүгә дә барып кайтты. Өч көн бара, өч көн кайта, өч көнен чиркәүдә догалар укып, ходага ялварып үткәрә... Юлда автобуска-мазарга утырмый да. Аркасына биштәрен аса да, кулына таяк тотып, җәяүләп китә. Шулай иткәндә, ходайга якынрак була, күрәсең... Инде менә иртәгә таң белән тагын китмәкче. Җыенып тора. Тик бусында Алабуга районының Қастеней авылындагы чиркәүгә... Тагын кулына таяк тотып, биштәр асып... Тик инде хәзер сихәтләнү-яшәү хакында уйламый да, әҗәлнең тизрәк килүен теләп ялвара. «Шул изге җулларда әҗәл бирсә икән лә Кристос аллабыз», ди...

Бу күңел әрнеткеч авыр күренеш бөтен кырыслыгы, бөтен чынлыгы белән күз алдына килеп басты Хәнәфинең. Әмма шуның арты ук, әллә каян, артта калган еллар түреннән калкынып, бүтән төрле күренеш тә пәйда булды: Мәтрүнә түтинең пөхтә җыештырылган өе, өй почмагындагы иконада янып торган шәмнәр, чал чәчле түтинең, Кристос алладан алар язмышына катылык кылмаска, миһербанлы булырга ялварып, саф татар телендә пышын-пышын укыган догалары... Хәнәфинең йөрәген кабат яман эссе көйдереп алды: «Тиккә булмаган икән, карт ана күңеле алдан ук сизенгән икән...»

— Агач йортта учак тергезеп яшәү килешә димсең алайса?

— Килешмәгәннәр кая! Бордыбашта да, Мәләкостә дә белешкәләгән идем инде, йорт сатучылар бар үзе, әмма тоткарланып калдым. Күңел тартмый: туган як түгел. Әни дә: «Үзебезнең Шилнә буйларыннан булмасмы?» ди... Их, картаймыш көнендә туган нигезеннән аермасыннар икән кешене! Күрәләтә үз анамны вакытын-

нан иртә гүргә кертергәме инде миңа? Тап-таза ир башым белән, ә? Аннары бу дөньяда яшәүнең ни кызыгы кала миңа?

— Әйе, мәңге үкенечкә каласы...

— Шулай, гомерең буе җан көйдереп яшисе... Әле менә Чуардан кайтып килешем. Ишеткән идек: анда изге Вәлихан карт вафат булган да аның буш калган йортын агай-энесе сатарга җыена икән дип... Безнең басулар тоташып киткән иде бит, үз авылыбыз инде булмаса да, аның исән калган карт тирәкләре алардан уч төбендәге кебек күренеп тора бит — күңелгә якын җир. Шул рухландырган иде... Әмма барып белешсәм, киредән уйлап, сатмаска булганнар тагы. Дөрестерме-юкмы, имеш, читтәге кызы белән кияве кайтып төпләнергә ниятли, ди. Күңелгә шик тә керде: без керәшенне андый изге карт нигезенә кертәләр диме соң!

— Менә бусында хаталанасың, туган,— диде Хәнәфи, баш селеккәләп.— Хикмәт синең керәшен, ә аның «мөселман изгесе» булуында түгел. Үземнең белешкәнем булды: картның читтәге кызы белән кияве чынлап та монда кайтырга җыена...

Бу минутларда Хәнәфинең күңелендә, әлеге хикмәтле һәм аянычлы хәлне чишү юлын эзләп, өермә бөтерелә, зиһене чатнап-чатнап китә иде, менә ул, уйлана-эзләнә торгач, керәшен дустына таба ава төште дә аның янтыгына орынып:

— Тукта, сиңа күк капусы ачылырга чамалый бит, туган! — дип кычкырып ук куйды.— Син безнең Әҗердән яшь агроном Инсафны беләсеңме? Өченче елны институт бетереп кайтты, кырчылыкта эшли, ә хатыны зоотехник...

— Белүен белмим... Соң?

— Үткән язда аларның да әниләре вафат булды. Үзләре генә утырып калды нәни кызлары белән... Өйләре шыгырдап тора әле, каралты — курасы да ярыйсы гына. Әмма мал-туарны бетерде болар. Карарга вакытлары да җитми, теләкләре дә юк. Хәзер алар бездән яңа поселокка күчәргә квартир даулый. Гаризалары минем өстәлдә ята. Әмма без аларны: «Баш өстегезгә түбә ишелеп төшәргә җыенмый, азрак сабыр итегез», дип тынкылатып торабыз. Алар үҗәтләнеп өйләрен сатып җибәрергә дә ниятләгән иде — анысын да әлегә тыйдык: сүтеп читкә алып китсәләр, Әҗердә менә дигән торак йортны киметүдән ни мәгънә?

— Шуннан ни?

— Аңламыйсыңмы? Шуннан шул, туган, син безгә гариза тотып киләсең дә, без сине исемлеккә кертәбез, әмма яңа поселоктан фатирны сиңа түгел, аңа тоттырабыз, ә син бик әйбәтләп кенә Инсаф өенә кереп утырасың... Дөрес, гәрдәлеләрдән дә ул шәп йортка теш кайраучылар булмый калмас, әмма араларында синеке күк аянычлы хәллесе юк әле бүгенгесе көндә...

— Ә син Инсафны күнәр дисеңме? Их, акчасыннан да тормас идем, сораганыннан артыгы белән тоттырыр идем мин аңа сәгате белән үк!

— Акчага хирыс кеше түгел ул. Соң, аның өчен дә майлаган күк була ич. Үзе дә түбәсе белән түшәмгә тияр әле!

— Һай, шәп булыр иде! Әни дә Әҗерне әллә ничә телгә алгалаган иде. Үзебезнең Шилнә буйлары бит, аның анда таныш-белеше дә хәтсез генә... Тик менә Әҗер халкы үзе... без керәшенне...

— Таптың бер сүз: керәшен дә керәшен!.. Соң, безнең авылда торып, яңа поселокка кемнәр генә күчмәде инде? Урысны әйтмим дә, арада чуваш белән мари да, удмурт та, хәтта ки Урал ягыннан килгән немецка тикле бар! Кайгырма, гел үз кешеләребез булып бетәрсез әле!

Ни вакытлар ачы хәсрәт йотып һәм район бетереп диярлек үзенең сырхау аналы гаиләсе өчен төпләнеп алырга урын табалмый йөдәгән һәм бу нәрсә аның өчен инде ерып чыга алмаслык проблемага әверелүенә инана язган адәм менә хәзер аны икенче берәүнең капыл гына, ансат кына чишеп куюына әле һаман ышанып җитә алмый иде, ул күзләрен челт-челт йомгалап Хәнәфигә текәлде:

— Син чынлап та булдырып булыр дисеңме?

— Шуны да булдырмаска, ни пычагыма рабочком бу дөньяда?

Сизелерлек вәкарь аша ярыйсы ук кырыс әйтелгән бу сүзләргә Әртәми Вәсилич әллә ни ис-өн җибәрмәде. Аның күкрәге куаныч болыты белән тулган, ул кабаланып, утырган җиреннән купты да, кулына күн букчасын тотып, мотоциклы янына барып басты, үзе ашкынып сөйләнүендә булды:

— Җәт кенә кайтып әнине куандырыйм әле! Аны келәүгә барырга җыенган җирендә туктатып булмас инде. Таң белән изге сәфәренә чыгып киткәндә, ходадан әҗәл ялварып түгел, яшәү хакына догалар укып чыксын, ичмаса. Тегеннән тәне дә, җаны да бөтенләй сихәтләнеп кайтыр, бәлкем...

Менә инде ул, мотоциклын кабызып, аңа атланып алды. Атланып алды да, авызын киң җәйгән килеш, баш кагып куанычлы сәламен калдырды һәм фырылдатып китеп тә барды.

Хәнәфи юл читенә басып калды һәм, кызып киткән күкрәгенә күбрәк һава тисенгә, сырмасының изүен киңрәк ачып җибәрде.

Бу тымызык кичне тап-таза ир уртасы ике адәмнең кайсы күбрәк дулкынланды икән?

Ә кызарып барган кояш тегендә, нәкъ менә үр кашын асфальт юл кискән төштә, җиргә орынган иде. Ашкынып, плащ чабуларын кош канатыдай кагып-җилфердәтеп барган адәм әнә инде үр кашына менде дә туп-туры кояш эченә кереп югалды...

15

Көзен Минзәлә питомнигыннан байтак кына алмагач, чия, карлыган үсентеләре алып кайтканнар иде. Аларны совхоз эшчеләренә өләштеләр. Җитмәде. Бу язны да, соңгармыйча, тагын кайтартырга кирәк булыр. Рәхәтләнсеннәр! Күңелләре бераз басыла төшәр, ичмаса.

Яңа поселокта яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасын икешәр-дүртәр катлы йортлар яныннан гына, асфальт юлның теге ягындагы киң бушлыктан бүлеп бирделәр. Ул төшләр поселокның генераль планында совхозның үз җиләк-җимеш бакчасы, ягъни «яшел зона» дип билгеләнгән иде. Ә нигә, барыбер түгелмени? Әллә кемнәргә өләшенми, совхозның үз кешеләре рәхәтенә бирелә ич!

Ярый, монысы хуп диярлек иде. Ә менә мал-туар, кош-корт асрарга теләүчеләр белән ни хәлләр итәсе инде? Әнә «мансардлы йорт»ларда яшәүчеләрдән кайберәүләр ихаталарына шәп ак кирпечтән салынган «гараж» дигән матур нәмәрсәләрне тавык кетәгенә яисә каз-үрдәк оясына әверелдерүдә үтә өлгерлек тә күрсәткән иде. Каз-үрдәк тотам дисәң, анысына мач, ичмаса: якында гына урман буйлата шәп-шәп буалар корылды, совхоз елның елында комбикормнан, һич югы фураждан ярыйсы гына өлеш тә чыгаргалый иде. Ә эрерәк малны, сарыгын, дуңгызын, сыерын асрамага теләүчеләргә нишләргә? Асрарга юньле урының булмаса, совхоз өләшеп тоттырган печән-саламнар ни әле ул?

Яңа поселоктан читтә Әҗер урманы буйлата корырга тотынып та сүлпәнләнеп калган таш абзарлар салуны

кызуларга булдылар. Планда рөхсәт ителгәнен, бердәнбер «законлысын»...

Ләкин гәрдәлеләр андыйга гына риза буламы соң? Алар ил законнарын бик аңлый, күпләр бүгенге яшәү җайларыннан аерыласы килмичә: «Йорт-куралар белән мал-туар асрарлык булсын! Өең янында иркен бакчасы булсын!» — дия-дия, яман үҗәтләнеп үз чөен сугуны белә иде.

Акбашевның киң маңгаендагы сырлар соңгы араларда тагын да ишәйде сыман. Ул колак артын кашудан һич котыла алмый иде:

— Әкияттәге кебек, әфсен өреп кенә хәл итеп булса икән, ялт та йолт, ә!.. Поселокны проектлап раслаганда ук, безнең башка бәла итеп, шулхәтле проблемалар кысгырып куймаган булсалар соң! Хәзер менә чиләп инде бер туйганчы!

«Чиләнмәслек» тә түгел шул Гәрдәленең башта уйланылган яртысын ук булмаса да, совхоз өчен, һич югы, өчтән бер өлешен саклап каласы иде. Моның хакына көрәшмәслек түгел иде. Андагылардан — Хафиз, Сәетҗан, Ярулла кебекләрне, эшкә тотынса, ут өермәләре уйната белүчеләрне, гигант төзелешнең үзендә дисеңме яисә район хуҗалыкларының берәрсендә дисеңме, көне-сәгате белән суырып кына алачаклар бит.

— Аның крестьянын әйтер идем инде: охмажка эләксә дә, малым-туарым, бакчам-мунчам кайларда, дип җенләнеп, андагыларның теңкәсен корытып бетерер иде бугай.

Болай дип Акбашев, әлбәттә, бик аптыраганнан гына әйтте.

— Авыл кешесенең утырган төшендә ныгытып тамырланасы килә шул, Мөслим Гайнаныч,— диде аңа Хәнәфи.

— Үзебезгә дә, алма пеш, авызыма төш, дип тик ятулар килешмәс. Хәрәкәттә — бәрәкәт дип яшибез түгелме соң?

Уйлый-эзләнә торгач, үзләренчә әмәлен таптылар шикелле.

Яңа поселокның урта тирәсендә — икешәр һәм дүртәр катлы йортлар, шулай ук коттеджлар арасында киңәергә һич җай-чама калдырылмаган, болары болай да тыгыз укмашып утырган иде. Ләкин бит поселокның кырый урамнары бар. Бүгенгә алар буп-буш әле, тик шәйләнәләр генә. Дөрес, аларга да инженерлык коммуникацияләре инде үткәрелгән, буласы кайбер йортлар-

ның нигезе дә таштан-бетоннан коеп куелган, тик өйләр үзләре генә юк иде әле. Менә шундыйларда җәелеп тамырланам дисәң, каралты-кураларың, арт бакчаларың белән ачык басуга таба рәхимнәр генә ит ләбаса! Бу хакта Гәрдәле халкының байтагына: «Анда сезгә күк капусы ачылырга чамалана бит әле. Өметләрегезне өзмәгез!» — дип, шыпыртлап кына колакларына кирттереп тә өлгерделәр.

Әйе, моны совхоз җитәкчеләре әлегә сер итеп сакларга тели, бу турыда бик шауламаска куша иде. Ни дисәң дә, алар исәп иткәнчә кыландыру «Генераль план»ның чит-читләрен кимереп, аларга үз ямауларын салган шикелле килеп чыга ич. Совхозның алдагы көнен, кешеләр язмышын чын-чынлап кайгыртып эш иткәндә, бүтәнчә ни кыла аласың тагы?

Ләкин «серне» алай озаклап саклауның хаҗәте дә калмаган иде инде.

Озакламый, алдагы җәй уртасында, Мәскәүдә Үзәк Комитетның махсус Пленумы булачак. Анда инде бүгенгә көндә авыл хуҗалыгында хәл ителәсе гаять әһәмиятле һәм кызыклы мәсьәләләр белән рәттән авыл җирендә ярдәмче хуҗалыкның асыл мәгънәсенә дә шактый киң һәм төпле тукталачаклар — аны дәүләт күләмендә бик кирәкле, бик әһәмиятле өлеш дип билгеләячәкләр...

Пленум үтүгә, «Йолдыз» совхозындагылар җилкәләреннән бик авыр йөкнең капыл тәгәрәп төшкәнлеген тоярлар һәм киң сулыш белән, инде хәзер кыюланып һәм ачыктан-ачык җиңнәр сызганып, башлаган эшләрен дәвам иттерергә тотынырлар.

Халык куаныр...

Ләкин аңарчы, эчке пружиналарын кысып торырга мәҗбүрләр шул әле...

16

Шилнә суы ага тора, ярларын кимерә бирә, урыны белән чонгыллана-бөтерелә, урыны белән тына-тынычлана төшеп, түбенә ком-ләм утыра бара...

Вакыт та шулайрак: айлар-еллар булып, җир кыяфәтенә җуелмас эзләр сала-сала, туктауны белми агыла тора...

Менә инде янә яз.

Түбә читләреннән тамчылар тама...

Юк, эрисе карлар күптән эрегән инде, чат яңгыр тамчылары бу. Шифалы, җылы ләйсән тамчылары да түгел. Бүтәне...

Галәмәт иртә килде бу елны яз. Март азакларында шәпләп җылытып, хәтта куыра язып, җир өстен салкын кар юрганыннан капыл гына ачып җибәрде. Апрельнең беренче атнасы үтүенә үк Камада боз кузгалды — бик тә сирәк була торган хәл...

Ул да түгел, дөньяны сафландырып, җир өсләрен, бигрәк тә басу-кырларны юындырып, ләйсән яңгырлары да явып үтте. Гаҗәп матур һәм күңелле булган сыман иде...

Әмма шуның арты ук, инде җирләр өлгереп, чәчүгә чыгарга вакыт төенләнде дигәндә генә, һавалар әллә нишләп китте: өсләренә дулкып-дулкын булып салкыннар ишелде, төннәрен карасу-көрән җир җыерчыкларын чираткаладь, хәтта катырып ук алгалады, җебеп-йомшап киткән чакларында исә күк гөмбәзендә әле бу тарафтан, әле теге тарафтан агылган кургаштай авыр, соры болытлар шыксыз, чиркандыргыч яңгырлары белән җирне камчыларга тотынды.

Әмма игенче җаны моңа баштарак һич сыкрамаган, киресенчә, чамасыз сөенүдән хушланган гына иде.

Былтыр ел янәдән үтә коры килгән, шул сәбәпле, җәен, хәтта көзлектә дә, басу-кырлар дымга чамадан ашып тилмергән иде. Тик туңдырыр алдыннан гына әйбәт кенә явымлап, җиргә сеңдерергә тырышып караган иде. Ләкин ни әле ул? Өстәвенә, кышын да кар юка төште...

Дым, дым...

Ярый әле, совхозда чәчү әйләнешендәге кырларның яртысын диярлек сугаруга көйләп өлгерделәр. Ул хәтлесендә дымны көздән үк шәпләп сеңдерә белделәр үзе. Әмма бүтән басулар бар бит, бүтән хуҗалыклар бар, республика бар, ил бар. Һәркайда да, болардагы шикелле, ясалма яңгырлар ул тиклем үк киңлекләрдә җәелдерелмәгән ич әле...

Кышын басу-кырларда, бигрәк тә чалкыерак, түбәлерәк төшләрдә, кар тоту чараларын күрделәр, язның дуамал кыздырган көннәрендә кар суларын тотарга тырышып карадылар. Ләкин җиргә барыбер дым хаҗәт. Ничәмә ел рәттән сусынын җүнләп баса алмаганның, җүнләп туенмаганның ничектер үчен кайтарырга кирәктер ич!

Ләкин яңгырлар тоташтан китсә дә, бер генә дә

әйбәт түгел шул: салкындыр, әрсездер, җирне түгел, җанның үзен кыйныйдыр!

Тәҗрибәле игенче язның иртә килүен һич өнәми! Барыбер үзенекен итәр — суытыр, сузылыр, хәтта әле кирәкмәгән чакта карлар явып, җәфалавы да ихтимал, ди. Дымы булып та, җылысы иңмәсә, иртә чәчүләреңнән ни файда?

Көне килерме, һавалар ачылып, аязырмы, яз кояшы рәхәтләнеп елмаерга тотынырмы?

Әлегә исә көннәр тоташтан нурсыз һәм төмсә. Юеш. Басу-кырлар күкрәгенә машина һәм агрегатлар белән түгел, аяк атлап керәсең юк.

Һай, тартылды, һай, сузылды ла!

Ярый әле ачылыбрак, тыныбрак торган мәлләрдә самолеттан хәтсез җирләрне — уҗым кырларын, арыш белән көзге бодай «Мироновская»ны, шулай ук инде мең гектардан да ашып киткән культуралы болыннарны — тиешенчә ашлый алдылар. Файдасы тими калмас — шәп булыр! Әле алай гынамы, көздән туңга сөреп калдырылган һәм менә, хәзер тиешенчә эшкәртелеп, чәчеләсе басуларга да һавадан байтак кына ашлама сиптерелде. Тик мондыеның файдасы гына менә... Юылып, кара туфрак астындагы әрләнә балчыкка сеңгән ашламадан ни мәгънә?

Өсләреннән кургаш болытлар агыла тора, җирне юеш камчылар авырттырып камчылый бирә!

Көндезләрен, ачылмасмы, азрак ирек бирмәсме дип, күккә күз сала-сала, анда сугылып, монда орынып үткәрәсең.

Ә төннәрен?

Дөп-дөп тамчылар тама. Өйгә, тәрәзә өлгеләрен зеңгелдәтеп, каты һәм кырыс җил бәрә. Йокыны качыра. Күңел пошаманлы уйларга чума...

Әлбәттә, чәчәргә тиешлесен чәчми калмаслар, бәрәкәтле җиргә төшәсе орлык барыбер төшәр. Ләкин кайчан, ни рәвешле?

Игенче җилкәсенә сыналуның тагын нинди иңүе икән бу?

Төннәрен урамнан җыр җырлап үткәлиләр. Җил димиләр, яңгыр сибәли димиләр.

Армиягә бу язны Әҗердән ике егет китә. Берсе — Сабир-Чуерташ. Хәер, аның хәзер «чуерташ» диярлеге юк инде: үсте, ныгыды һәм, бабасы Туры карт, әтисе Ризван шикелле, калын җилкәле, чыдам сеңерле сабыр

гына бер егеткә әверелде дә куйды. Борыны астында инде ярыйсы ук коңгыртланып мыек та үсентеләнеп килә.

Солдат хезмәтенә китүчеләрнең икенчесе — Ас урамнан Хәлим, гәүдәгә чандыр гына, чаграк кына нәрсә, әмма яшь шоферлар арасында иң елгыры...

Төннәрен күбрәк чакта Сабир япа-ялгызы гына узгалый. Кызын озатып кайтышлары. Авызыннан җыр өзелми, тегесен көйли, бусын суза, еш кына, хәтта ачы җил исеп, яңгыр сибәләгәндә дә, кулындагы баянын тартып-сыздырып җибәргәли... Ә кызы аның Игәчтән, Сәимә Юмаева. Ягъни тамыры белән Шилнә буендагы тугайга пар тупыл утыртып калдырган аталмыш Юмай — башкорт бабайга барып тоташа. Яшь тал туйрасыдай зифа һәм сыгылмалы җаныен өзелеп сагынасын белгәнгә күрә, алдан ук моңланадыр, мөгаен, егет күңеле...

Сабирның тавышы калынча, шома-йомшак бәрхеттәй... Теге елны, Туры бабасы гүр иясе булган көздә, егет һич уйламаганда җырга, баянда уйнарга әвәсләнде дә китте. Сөекле бабасын артык юксынганнандыр инде... Ул көзне Октябрь бәйрәмендә Сабир бабасыннан отып алган җырны сәхнәдән башкарды. Үзе уйнады, үзе җырлады. Дөрес, җырның кушымта өлешен иптәшләре — егетләр хоры күтәреп, гөрләтеп торды. Клубтагы халыкның исе-өне китте ул өр-яңа «иске» җырга, күңелләре бердәм хушланды, аннары инде, әлбәттә, Әҗернең уртак хәзинәсенә әверелде... Менә хәзер дә Сабир ул шанлы җырны әледән-әле җырлап үткәли. Туры бабасы, Юмай башкорт бабалары ядкәре итеп кенә түгел, туган авылы төсе итеп тә... Әйе, егет җырга үзенчә чак кына үзгәреш төсмере дә керткән сыман булды:

Ургыл-ургыл Чулман-судыр,
Ургылганда чаларыр...
Сагышланма, авылым, көтеп кал!..

Шулай инде: җырның әллә кайчан онытылып, югалып калганы да кире әйләнеп кайта һәм терелеп, өр-яңадан тугандай була, әле алай гынамы, әүвәлдән үк авызларыннан өзелмиенчә, күңелләрне гелән дә хушландырып килгән җырларга да замана үз нурларын, үз рухын һәм моңын кушып җибәрә ләбаса!

Аларның күршесендә генә бер укытучы яшь. Читтән килгән адәм. Әле икенче елын гына укыта. Әле өйләнмәгән дә... Менә шул егет беркөнне Хәнәфигә:

— Төн уртасында баяннар сыздыртып, тамак ертып

йөрмәсәләр соң! Уятып, йокыны качыралар...— дип ачы зарын белдергән иде.

Хәнәфи аңа җавапка:

— Ә миңа дисәң... ягъни минем кебекләргә, киресенчә: рәхәт кенә — үз яшьлегеңә әйләнеп кайткандай буласың! Күңелне чүп-чарлардан тазартып, җилкендереп җибәргәндәй итә, билләһи,— дип көлемсерәде генә.— Ансыз авылның яме ямь булыр иде микән? Үз хәлең хәл, әмма бүтән адәмнәр җанын да аңлый белергә кирәктер сиңа, энекәш!

Төнге тамчылар дөп-дөп... Тәрәзәләргә зәһәрләнеп җил бәрелгәли. Болай да пошаманлы күңелне әллә кайларга алып китә... Ә җыр-көй, чын әгәр, җанга бөтенләй бүтән төсләр, бүтән нурлар иңдерә...

Ә җырлар яңара. Әүвәлгеләренең заманча төсләр, заманча рух белән бизәлүе генә түгел, өр-яңалары туа тора... Әнә гәрдәлеләр дә, син күр дә мин күр, үз җырларын чыгарган. Үз хәлләрен аңлатып, язмышларын кайгыртып... Аны бик күптән түгел, 8 март бәйрәмендә, клуб сәхнәсеннән укучы яшь кызлар — гәрдәлеләр башкарды. Бик тә дәртсенеп, аерым төшләрен хәтта ничектер тилпендереп, киң дөньяларга очырткандай иттереп башкардылар аны ул чибәрләр... Яшьләр күңеленә бик хуш килде, ахрысы: шул арада совхоз буйлата әнә инде таралып та өлгерде... Бу җырны, гәрчә үз авылы Әҗер турында булмаса да, Сабир да үз иткән иде. Әлбәттә, тикмәгә түгелдер... Язның җилле-яңгырлы, төмсә кич-төннәрендә егет аны әледән-әле җырлап үткәли иде:

Җир, диләр, әйләнә, җир, диләр. бәйләнгән
Күктәге кояшның үзенә.
Авылым, Гәрдәлем, язмышың-күрмешең
Бүгенге дөньяның күзендә...

Ә кушымтасын Сабир тагын да дәртсенебрәк, күкрәгендәге бар куәтен моңга салган рәвештә, тибрәндереп җибәрә:

Гәрдәлем, Гәрдәлем,
Аязып атсыннар
Туачак таңнарың!..

Үз авылы җыры түгел, күрше авылныкы. Әмма тегеләрнең язмышы боларга да якын, боларга да үз ич...

Сабир сагыныр, барын да сагыныр әле. Сөлектәй зифа буйлы, алма йөзле Юмай чәчлекәен генә түгел, менә шушылай төннәрен туган авылы урамнарыннан

җырлап үтүләрен дә сагыныр. Тир түккән хезмәтен аерата сагыныр.

Былтыр унынчыны тәмамлавына Сабир өлгергәнлек аттестаты белән бергә кулына шофер һәм тракторчы-механизатор правасын да алган иде. Ягъни, совхоздагы өр-яңа техниканың шактыен егетләрчә елдамлык белән авызлыкларга ибе дә, җае да бар иде. Әмма ул шәп, елгыр техникага утырырга итмәде, басулар буйлата аяк өсли чабып, манма тирләргә батып йөрүләрне кулайрак күрде: электән үк күңеленә сеңгән хезмәтенә, ягъни кыр-басуларга яңгырлар сиптерү эшенә җенләнеп ябышты. Аның хыялы Рәмзи абыйсы кебек булу, аның эзеннән китү иде. Рәмзи былтыр җәй башында Яңа поселокта инженерлык коммуникацияләрен корып бетерүләренә, тулае белән совхозга зыкә күчте һәм, билгеле инде, сугару-мелиорация эшенә кереште. Аны үзенә күрә мастер иттеләр. Ә бу елга кергәч, әле бик күптән түгел, Казаннан кышкы сессиясеннән әйләнеп кайтуына, аны, институтны тәмамларга төгәл ике елы алда булган студент-заочникны, тоттылар да, «инженер-мелиоратор» дигән исем биреп, үзенә аерым штатка утырттылар. Шул рәвешле дипломы булмаган шәйгә, сугаруда иң җаваплы кеше, иң төп белгеч сыйфатында совхозның баш инженеры Исламовның уң кулына әверелде дә куйды.

Рәмзи абыйсының, армиядән кайтып, нибары дүрт-биш ел эчендә иләмсез авыр хезмәттә дә шыңгырдамый-нитми кылган эшләре, Сабир кебек инде хәзер үк үз адымнары, үз язмышы хакында төптән уйлый башлаган егеткә өлгедәй күренә иде, ахрысы.

Мөгаен, шуңадыр, узган җәйдә Сабир үзе дә сугаруда алны-ялны танымый җенләнеп эшли алуын да, ярыйсы ук катлаулы автоматларны җигү-көйләүләрдә әвәслеген, осталыгын да чын-чынлап күрсәтә белде. Аңа да, бүтән оператор-машинистларга биргән кебек үк, ике «Фрегат» тапшырылган иде. Ике дигәч тә, аның сиптерер позицияләре икәү түгел, дүртәү бит! Вакытында кара, тикшереп йөре, автоматларың челт тә пелт эшли белсен, хәтсезләргә сузылган «яңгыр корабың», миллиардлаган су тамчыларында салават күперләре уйната-балкыта, үз күчәре тирәсендә әйләнә биреп, җир-басуны бу төшләрендә тиеш кадәренчә дымландыргач, аны күрше позициягә күчерү җайларын чамала! Әҗернең беренче «яңгыр алласы» Мөбәрәй дәрәҗәсендә үк ыхтыматлыкка һәм төгәллеккә ирешә

алмаса да, Сабир беренче җәендә үк аңардан әллә ни күпкә калышмады шикелле...

Совхозда яңгыр осталары, машинист-операторлар җитешми. Ә Сабир инде ярыйсы ук шомарган һәм остарганнардан исәпләнә иде. Менә шул хәлне истә тотып, совхозның баш инженеры Исламов сүз кузгаткан: янәсе, Сабир, үзе риза булса, аны военкоматтан сорап бер-ике елга бронь белән калдырып торырга да булыр иде, дигән. Моны Исламовның уң кулы исәпләнгән Рәмзи дә, хәтта директор Акбашев та бик хуплаган. Сабирның, әлбәттә, авызы ерылган, әмма ул шуның арты ук аптыраудан колак артын кашырга тотынган һәм берничә көннәр буена бу хәләтеннән котыла да алмаган. Военкоматның ризалашуы бик тә ихтимал шул. Ихтималын ихтимал да...

Егет, колак артын кашый-кашый уйланып йөри торгач, өлкән абыйларын сискәндереп:

— Юк, үз яшьтиләремнән каласым килми, иң әүвәл солдат хезмәтен тутырып кайтам. Соңыннан кыенга килүе генә ихтимал,— дип кистергән.

Молодец егет, иң әүвәл Ватаның алдындагы изге бурычыңны үтә — намусыңны һәм вөҗданыңны кояшландыр! Тормышы алда — әле бик күп нәрсәләргә өлгерер!

Тик таза-сау йөреп, исән-имин хәлләрдә кайтырга гына насыйплар булсын!

Инде күр, кич-төннәрен җилле-яңгырлы, караңгы урамнарны буйлаган чакларында егетнең үтә хушланып җырлаган җырында да, гәрчә ул җыр бөтенләй бүтән авылга атап чыгарылган булса да, үз туган авылы, тулаем үз төбәге, хәтта үз хәл-әхвәлләре дә шактый тулы һәм ачык шәйләнә кебек ич! Еракта авыр солдат хезмәтендә аерата сагынган минутларында ул шушы җырны җырлый-көйли туган ягындагы бик күп нәрсәләрне, якты һәм матур төсләрдә нурландырып, күз алдына китереп бастырырдыр:

Айга да менгәннәр, менгәннәр-күргәннәр:
Авылым кырлары балкуын;
КамАЗның утлары, йөрәкләр ялкынын,
Илемнең нурлана баруын...
Гәрдәлем, Гәрдәлем,
Бәхетләр китерсен
Алдагы көннәрең!..

Гәрдәле шулай, үз җыры, үз көе-моңы белән гомергомерләр буе утырган туфрагыннан кубып китәргә җые-

на. Төенчекләрен шыплатып төенләргә инде күп калмаган.

Яшьләргә, әлбәттә, күп җиңелрәктер. Ә өлкәннәргә, туган туфракларына тамырларын тирән җибәргәннәргә ничегрәк?

Язның төнге җиле котырына. Тәрәзә өлгеләре шыбырдап-зыңгылдап алгалый...

Урамда, болардан чак кына арыдарак, тагын җыр авазы яңгырап куйды шикелле. Әйе, шулай: инде якынлашып килә...

Сабирның тавышы алай куәтле яңгырамый, әмма күкрәк төбеннән үк күтәрелеп менә, һәм җыр-көе белән вак яңгырлы ни котырма җилне дә басып, җиңеп бара сыман...

Рәмилә, нурлы йөз, әйтә: имеш, бу җырны гәрдәлеләр чыгармагандыр, аны Чаллы шагыйрьләреннән берәрсе иҗат итеп тоттыргандыр, ди. Ихтималы бар. Ләкин авыл җире дә алай бик үк коргаксымаган ич, монда да җыр-көй чыгарырдай гына сәләтләр бетәр димени?

Күчәсең, авылым, искедән Яңага,
Калдырып бабалар нигезен.
Гөр килә, шау итә заводлар батыры,
Яшьлек бит яшәртә ил йөзен...
Шиңмәсен, Гәрдәлем,
Чәчәккә күмелеп,
Балкысын гөлләрең!

Әнә инде җыр төн бөтермәсендә эреп юкка да чыкты...

Хәнәфи бу җырның кушымтасындагы азаккы юлларны нишләптер аерата үз иткән иде. Исенә төшсә, көндезләрен дә җанын тибрәндереп җибәрә, һәм менә төн төмсәсендә җил улавын тыңлап яткан мәлендә дә:

— Шиңмәсен... балкысын гөлләрең! Гөлләрең-дөньяларың! — дип пышылдый күңеленнән...

17

Шактый уйландырган һәм байтак ыгы-зыгылар тудырган «Гәрдәле проблемасы»ның көтмәгәндә тагын бер хикмәтле ягы ачылып китте. Җилкендергәне, исләрне җибәргәне...

Нәрсәме?

Гәрдәле янында, дөресе, аның өстенә үк китереп салынасы яңа завод нигезләрендә җир эшләре башлану-

га, андагы симез кара туфракны тиешенчә каезлап, бер читкә өя барганнар иде. Янә бер «ипекәй» калкулыгы!

Ләкин көз азакларында совхоз кырлары бушап калуга әлеге калкулыкны да, аңардан әллә ни еракта утырмаган, ҚамАЗ тудырган әүвәлге кара тауны да экскаваторлар белән актарып, шулай ук җирнең бульдозерлар каезлый барган хәтлесен дә кушып, өстәге чалкый басуга ташырга тотынмасыннармы! Янә бер мәхшәр!

Көтелмәгәндә дисәк тә, «кара тауларда» тиккә томаланып яткан үтә һәйбәт кара туфракны җегәрсез, зәгыйфь басу-кырларга тарату хакында сүзләр бер генә купмады, төрле җыелышларда, хәтта партия-хуҗалык активларында да аны кискен рәвештә тырпайтып алгалаулар булган иде. Заманасында Туры карт та:

— Их, никадәр байлык әрәмгә җата, шуны җәтрәк җүнгә китерә белсәләр соң! — дип яман ачынып, эч пошуларын әледән-әле сиздергәләр иде. Ә хәзер ул, җир куенына мәңгегә сыенган хәлендә, туган як кырларында купкан әкәмәт дөбер-шатырны колак сагайтып тыңлап ята торгандыр инде, мәрхүм...

Әйе, бу хәл үзеннән-үзе генә тумады, җиңел генә бирелмәде. Теге чакны автогигант зилзиләсе купкан дәвердә авыл җитәкчеләре ничектер оеп китеп, йомшаклык күрсәткән: ҚамАЗ хәтсез күләмнәрдә каезланган җир-басулар өчен акча түләү белән генә котылган иде. Хәзер инде хуҗалык җитәкчеләре тәҗрибәнең ачысын да, төчесен дә шактый туплап өлгерде, хәтта ки кыюлана һәм усаллана төште. Директор Акбашев монысында:

— Қабаттан акча түләү белән генә котылыргамы, дәүләтнең бер кесәсеннән икенчесенә салып куяргамы? Ә бәрәкәтле кара туфрак кабаттан басу читләрендә таутау өелеп калсынмы? Юк, безнең авызлар бер тапкыр бик яман пеште инде! Җиребездә янә завод салырга җыенгансыз икән, рәхим итеп, аның астына китәсе бәрәкәтле туфрак тиешле басуларга тиешенчә күчерелеп куелсын! Алай түгел, менә болай булсын! — дигән кырыс таләп куеп, үз сүзендә нык торган иде.

Партиянең шәһәр комитеты да, боргалану-сыргалануларга урын калдырмыйча, аны яклау ягына авышты.

Шул рәвешле, ниһаять, көне җитеп, сәгате сукты! Ерганак ерылды!..

Басу кучә, басу! Ярлы җирләр «баерга» җыена!

Җәен дә түгел, кышын бит! Кар шактый тирән яткач та туктауны белмәделәр. Шыр ялангач язга тикле!

Көндезләрен күзәтүләре үк галәмәт күңелле иде. Тырыш кырмыскалар — әллә никадәр бульдозер, автоскрепер, дәү-дәү үзбушаткычлар — актарыналар, яман гүелдәп, астан өскә таба үрмәлиләр, кадерле йөкләрен бушаткач, янә түбән таба чабалар... Ә кич-төннәрен? Басу күкрәкләрендә, яман зур утлы күзләрен акайтышып, әллә нинди аждаһалар-җеннәр котырынып туй итә сыман, хәтта куркыныч ук булып китә!..

Әкәмәт хәлнең Бариевлар гаиләсе өчен үтә дә кызыклы һәм күркәм ягы да бар иде: анда үзенең галәмәт җегәрле бульдозеры белән өлкән уллары Айдаш та җир актарышкан, туфрак тигезләштергән иде. Кай көннәрдә ул туган нигезенә кайтып кунгалаган, кай вакытларда кире Яңа каладагы тулай торагына юл тоткалаган иде — үзенең «чәүкә оясына»... Авызы ерылган иде егетнең:

— Төзелештә шушылай кара туфрак каезлаудан башлаган идем, инде менә эшне йомрылавым да шул ук нәрсәкәйдә... Тик монысында басу үтерергә түгел, терелтергә! — ди.

Ул инде Яңа поселокка кайтып төпләнергә үзенә «оя» да чамалаган шикелле. Әлбәттә, назлы кәләше — Тау асты Байлар кызы белән... Тик КамАЗның кайсыдыр корпус тирәләрендә, азаккысы иттереп, беркадәр җир мәйданнарын гына рәткә-җүнгә китерәсе бар, ди.

Ә гәрдәлеләргә ничегрәк? Яңа поселок тарафына үзләреннән дә алда туфрагына кара тирләре, хәтта бабаларының газиз каннары тамган туган басулары күченергә кирәште түгелме соң? Мондый хәлләрдә күңел төбен әллә ниләр кымырҗытып тормас димени?

Язга кадәр өч йөз алтмыш гектар җирне ыспай гына әтмәлләп тә куйдылар. Үзе бер басу лабаса! Матур өметләргә ышанычлы нигез!

Шушы уңайдан боларның телендә өр-яңа төшенчә дә туды: әлеге яңартылган басуны, чикылдап торган тавтология икәнлеген исләренә дә алмыйча, иң әүвәл русчалатыбрак: «землевать ителгән җир» дип атап йөрттеләр. Тора-бара үзебезнең телгә килешкәнрәге дә тумый калмады: берәүләр аны «хәлләнгән кыр» дип йөртә башлады, икенчеләре исә, элгәредә ала-кола, шыксыз-шадра булып торган җир өсләрендә менә инде кара туфрак күпереп торгангамы, әллә алдагы көннәргә өметләре көчле һәм матур булгангадырмы, аңа «кү-

мәчле басу» дигән бик тә кадерле исем кушып җибәрде. Боларның кайсы ныгып калыр һәм таралып китәр икән? Хәер, монысы — киләчәк эше, тел үз җайларын үзе белми калмастыр...

18

Әлеге басуга кышын-кыш буе эз суындыра белмәгән баш агроном Ризван Әүхәдиевнең йөзе-бите җилләп, бөтенләй каралып бетте, аның хәтта яңаклары чокыраеп, коңгырт күзләре тагын да эчкәрерәк батып калды шикелле. Хәер, бер ул гынамы шулай? Директор Мөслим Акбашев та, Хәнәфи Бариев белән аның улы Рәмзи, бүтән кайбер белгечләр һәм механизаторлар да элеп киптергәндәй кыяфәттә иделәр. Башларыннан салдылар исә, маңгайларының югарыгы өлеше ап-ак булып ялтырап тора — кышын-язын ялан кырда җилләр кочагында зур эшләр башкарып йөргән игенче икәнлекләре әллә каян беленә.

Ләкин шулай да, ни алҗысалар, ни ватылсалар да, алар һәркайсы да үтә җанлы, үтә көр күңелле күренә, һәрхәлдә, басу «яңартып» йөрүләреннән һәммәсе дә бик риза, бик канәгать иде кебек. Дөрес, Ризван Әүхәдиев кайчакларда чал бизәге суга башлаган кашларын кырыс җыерып:

— Их, җирләр җитмәве, яман кысрыкланулар! Чәчү әйләнеше белән басу тәртипләренең дә һич очына чыгып бетәсең юк,— дип ачыргаланып ала.

Хәнәфи исә, бу зарның баштагы өлеше белән күңеленнән килешсә дә, азаккысы белән риза түгеллеген ачык сиздереп, аңа төрттереп куйгалый:

— Үзең басуларның тәртибе юк дисең, ә үзең... гектарның җегәрен торган саен үстерә барып, инде «программалы» уңышка ирешә язып киләбез дип, авыз чайкыйсың...

— Чайкамыйм, дөресе шул: инде ирештек дисәң дә була. Безнең өчен андый уңыш әллә кайдагы көн түгел, без аңа, чынлап карасаң, бүгеннән үк керештек дип исәплә, яшьти!

— Шулайрак сайра! Югыйсә әллә ничек килеп чыга...

Шундыйрак сөйләшү, сүз көрәштерүләр гадәттә баш агрономның үз бүлмәсендә булгалый. Хәнәфи, вакыты тигәндә, бу хикмәтле бүлмәгә кермичә китми. Монда, иренмичә караштырыйм дисәң, пыяласыз шкаф шүрлек-

ләрендә һәм почмактагы өстәлдә төрле китап-журналлар хәтсез генә тупланган. Әмма иң кадерлесе: бүлмә шәп уңыш биргән ашлык һәм үлән көлтәчекләре, ашелчә һәм кукуруз үрнәкләре белән тутырылган, шул сәбәпле монда чак кына бурсыган, шулай да һәрвакыт җанга тансык булган ис күңелне җылытып тора.

Алай бик еш булмаса да, баш агроном бүлмәсенә директор Мөслим Акбашев та сугылмый тормый һәм, керсә, бик теләп боларның гәбенә кушылып китәли. Аның да җанын, тәмләп һәм иркенләп сөйләшү ихтыяҗыннан тыш, бүлмәдәге бай уңыш үрнәкләрен кабаттан күрү һәм исләрен иснәү мөмкинлеге тарта иде, ахры. Гәп кору җәһәтеннән дә, биредә ул ничектер иплерәк, шомарак һәм йомшаграк бара сыман. Һәрхәлдә, Хәнәфигә шулай тоела иде.

Сүзләре күбрәк вакытта һаман шул бер җир хакында, аңардан тагын да мулрак уңыш алу — шуның перспективалары турында төенләнә.

— Шөкер диик: сугаруда ярты җирләребезгә җитеп киләбез бит инде. Ике мең ярым гектар җир, уйнама, бер дә аз түгел инде. Безнең бу тирәләрдә тагын кайда бар икән андый совхоз яисә колхоз? — дип күзләрен уйнатып ала Хәнәфи, төкле ияген сыпыргалап.

— Алай бик шапырынырга ашыкма әле! — дип тыенкылата төшә аны Ризван.— Син әйт: сугаруны җирләребезнең өчтән ике өлешенә тикле җиткереп җәелдерсәң иде менә, диген! Ул чагында сөйләшергә булыр иде. «Чирәм җир» дигәнебезне дә елның-елында үстерә барырга җайлар туар иде, ичмаса!

Әйе, әйе, «чирәм җирләр»! — моны Ризван хаталанып әйтмәде: болар культуралы болыннарны яңарту нияте белән ел саен аларның шактый өлешен сөреп, иген культуралары астына калдыра барырга исәп тота иде. Хәер, үткән көздән моңа керешкәннәр иде инде. Әйбәт тиресләнгән-ашланган андый басуларда югары сортлы игеннәрнең нинди уңыш бирәсен чамалавы бер дә кыен түгел иде: үзе «чирәм җир», үзе, җитмәсә, сугарулы...

— Шулай, ансыз кая инде үргә табан текә сикерешләр! — дип, башын селки биреп, Ризван сүзен җупләп куя Мөслим Акбашев.— Тегендә әнә Кама аша ГЭС бөясен бетереп киләләр дә инде. Киләсе җәйдән никадәр болын-тугайларыбыз, алар янында нихәтле сөрелгән җир су астына китәчәк ләбаса. Ә бит, хәтсез җирлә-

регездән мәхрүм калдыгыз дип, безгә җиңеллек бирмәячәкләр.

— Бер без генә түгел бит андыйлар.

— Бусы да куандырмый, Хәнәфи туган. Ие, мал-туар санын киметергә безгә беркем дә юл куймаячак. Киресенчә, арттыра барырга тиешбез. Шулай булгач, гектар җегәрен бермә-бер күтәрмичә, каян җиткерергә, ди, азык? Тик менә ары таба сугару җайлары гына... Их, бу Үтәдем басуы белән дә тәмам аптыраш! Үтәдем, Үтәдем... Үтәдемнең матур ядкаре.

Бу минутта өчесенең дә күз карашы стенадагы карта-схемага төбәлә. Әнә ул бәрәкәтле җир... Үтәдем авылы күптән юк инде, дөресе, тормышта юк — анда нибары карт тирәкләр генә моңаеп шаулап утыра — ә картада исә авыл урыны күрсәтелгән, ләкин монда да ул автогигант чиге эченә кертелгән, ягъни заводныкы булып исәпләнә. Ә басу — заманасында үтәдемнәрнең куанычы да, мактанычы да — исән... әлегә исән. Картада ул иң читтә, почмактарак, нык кына уентыланыпбүселеп җәелгән. Үзе нибары дүрт йөз гектарлап кына, әмма аңардан совхоз амбарларына агылган ашлык исә... Әнә Чуарның чалкый төшләрдәге мең гектарлык басулары бер кырыйда торсын! Чын әгәр, кем әйтмешли, туфрагын ипи телеменә ягып ашарлык! Сугару өчен дә уңай: тип-тигез, иңгә-буйга да таман гына... Уңаен уңай да... сугарулы басуда һаман да терлек азыгы үстерәләр, әмма ишелеп уңачак ул азыкны бу тикле ерактан Яңа поселок янындагы комплекска ничек ташып бетерергә, моның өчен каян транспорт җиткерергә кирәк? Шул сәбәпле, «иген уңышын болай да хәйран бирә, шул хәлендә яшәвен белсен» диебрәк, аны сугарудан тоткарланып, тыелып калдылар.

Әле бер-ике ел әүвәл генә боларга җан өшеткеч хәбәр ирешелде: тегендә кою заводы тагын да зураерга җыена, ди, зурайганда канатларын әлеге Үтәдем басуына таба җәелдерергә чамалый, ди. Боларның, әлбәттә, котлары алынды. Ләкин, тегеләр янына барып, төпченеп белешсәләр, алай ук куркыныч булып чыкмады: заводларын зурайткан тәкъдирдә дә, болар җиренә орынмаячаклар, автогигантның үз эчендәге бушлыкларга табан киңәячәкләр икән. Мондагылар тынычлана төште. Ләкин күңелләрендәге шик-шөбһә бөтенләй үк эреп юкка чыкмады. Шулай булмаска, Чаллы төбәгенә әле теге министрлыктан, әле бу ведомстводан төрле дәрәҗәдәге вәкилләр килеп, үзләренә завод яисә бүтән

берәр зуррак цәмәрсә кору өчен җайлар иснәштереп йөри, ди. Әле бик күптән түгел, җирләр кардан ачылу белән үк, зур вәкаләтле бер төркем янә килеп төшкән, ди. Байтак җирләрне айкап йөргәннәр, имеш. Боларның күзенә чалынмасалар да, «Йолдыз» совхозы җирләрен дә читтә калдырмаганнар, урап чыкканнар. Үтәдемнәрдән калган әлеге басу янында байтак вакытка тукталыш ясаганнар. Анысына сүз әйтерлегең юк: зур бер завод корырга тотынам дисәң, бу басу — суйган да куйган инде! Андагы туфракның ипигә ягып ашарлык дәрәҗәдә әйбәт булуы, аның биргән һәм бирәсе уңышлары җәһәтенә килгәндә исә... яңа завод салу уе белән җенләнгәннәр монысына алай бик ис-өн җибәрер ди синә! Гәрдәле белән бер авызың пешкәч, сискәнмәс җиреңнән сискәнерсең шул!

— «Аллаһе әкбәр» дип тагын аяк сыпырып калырга туры килер микәнни? Тагын кара тауга әвереләдерерләр яисә Чуарның сөзәк үр битләренә ташый башларбыз микәнни ул хәйран басуны? — дип куйды Хәнәфи, моңсу уйчанлыкка бирелеп.

— Шулай инде, Гәрдәленең әнә чем-кара тавыннан өр-яңа басу әвәләштереп, аны әкәмәт җегәрле иттердек дип сөенешеп йөргән булабыз да... асылда аның куанырлыгы ни? — дип кушылды аңа Ризван да, шулай ук авыр көрсенеп.— Җәйрәп яткан басуларың, хәл-җегәр туплап, үз урыннарында ята бирсен — иң хәерлесе шул лабаса! Ә сугарулы дигәнебез... үзе индустрияләшкән җир. Зур уңышларга нигез булуы өстенә, күз майландырганнар каршысында чын барьер, чын баррикада — аңа инде этем дә борын төртә алмый!

Хәнәфи, күңелендә өмет чаткылары кабындырып, күз карашы белән Акбашевка орынып алды.

— Бәлкем, бу юлысында да тимәсләр? Каза, безне читләтеп, бәлкем, ыспай гына узып китәр әле?

Мөслим Акбашевның да кашы-күзе жимерек иде:

— Белмим инде, белмим... Үзебезне җир хуҗалары дип йөртсәләр дә, җир язмышын хәл иткәндә, бездән бик сорап тормыйлар шул, каһәре. Анда инде хет башыңны ташка ор — файдасы булмас. Алай да бер-бер әмәлен эзләштермичә дә ярамый безгә...

Ләкин «әмәл» дигәнендә дә болар алдында зур кыенлыклар туган иде. Дөресе, үзләренең үк зур тырышлыгы һәм тынгысызлыгы аркасында торгызылган иде ул киртә. Хәзер әнә министрлыкта да: «Сугаруда сез инде хәтсез үрләрне яулап, әллә кайларга ыргылды-

гыз. Инде артыгын хирысланмасагыз да була. Дөньяда бер сез генәмени? Бүтән хуҗалыкларны да сезнең арттан аз-маз тарта төшәргә кирәк бит әле» дип, боларның алга таба атлавына чик куеп, төрле җиһазлар җибәрүне кырт кистеләр. Ул гынамы, болар җирләрендә майтарган зур эшләре белән моңарчы горурланып һәм мактанып килгән проект оешмасына тикле «Йолдыз» совхозына кинәт кенә арт белән борылып, аның заказын үтәүдән баш тарткан иде. Өстәвенә, «Җирләрегездә хәйраннар кыландырып күрсәттегез шул!» — дип сокланучылар булган шикелле, «Тәмам алланың кашка тәкәсенә әйләндегез инде!» — дип, зәһәр көнчелектә янучылар да аз түгел иде. Әмма чынлыкта алай бик көнләшерлекме соң хәлләре?

Мөслим Акбашев — ни әйтсәң дә, директор кеше — йөзендәге кырыслыкны иң әүвәл язып җибәрде һәм, тавышына көррәк төсмер бирергә тырышып, әйтә салды:

— Ярар, өметсез шайтан булмыйк. «Ятып калганчы, атып кал» дигән сүз дә бар бит әле дөньяда...

Әнә шулай үз-үзләрен тынычландырырга нихәтле генә тырышмасыннар, көннәр озаеп, җәйгә табан атлаган саен, күңелләрендәге пошаман көчәя генә барды: нинди уңышлар бирер дә җирләренә нинди язмышлар китерер икән бу җәй?

Баш ватып йөри торгач, Ризван Әүхәдиев Үтәдем басуын саклап калу җәһәтеннән үзенчә ниндидер әмәл тапкан шикелле. Ләкин ул аны уртага чыгарып салырга ашыкмый, күңелендә һәм зиһенендә аның тәмам пешеп-өлгереп җитүен көтә, шул сәбәпле әлегә зур сер итеп саклап йөртә икән...

19

Бу юлы алар икәү генә иделәр. Тышта, яз караңгысында, җил уйный, тәрәзә өлгеләрен, вак ядрәләр булып, яңгыр тамчылары четердәтә иде.

Ризван Әүхәдиев эш өстәле артында уйчан-җитди кыяфәт белән ниндидер кәгазьләргә чумган. Хәнәфи, аңа комачау итмим дип, шкафтан бер журнал эзләп алды да мыштым гына урындыкка утырды һәм, тыштагы җил улавына, тәрәзә челтерәвенә колак салган көенчә, журнал актарырга кереште.

Берзаман башын күтәреп караса, Ризван, күзләрен кыса төшеп, аңа төбәлгән. Карандашы колак өстендә, терсәге белән өстәлгә таянган да бөгелгән бармакларын

иягенә тидергән. Иреннәрендә җиңелчә көлемсерәү чалымы... Ни икән дисә, теге атнада болар совхозында уздырылган семинарны исенә төшергән икән.

— Беләсеңме, анда кем дә килгән иде?

— Кем?

— Синең кодаң... буласы кодаң! Тау асты Байлар авылыннан... Йортыңа киләсе киленнең әтисе ягъни...

— Туктале, тукта! Ничек алай? — Хәнәфи журналны җәт кенә шкаф шүрлегенә куйды да, урындыгына кире утыргач, гәүдәсен алга таба авыштыра төште.— Нишләп шулчакны ук әйтмәдең?

— Әйтергә... үзе кушмады. «Уңайсыз... ярамый да, килешми дә», диде. Ни дисәң дә, кыз атасы бит... Ә миңа тишелде...

— Вәт сиңа, ә!

Ул семинарга, көн шыксыз, юлларны беткәнче изрәткән дип тормыйча, шушы төбәктәге, хәтта күрше районнардагы хуҗалыклардан да байтак халык — агрономнар һәм мелиораторлар — җыйналган иде. Шуларны укмаштырып-оештырып һәм үзләренә сый-хөрмәт күрсәтеп, уртада Хәнәфи белән Рәсүлә дә кайнашкан иде ләбаса. Бактың исә, арада әнә кем дә булган икән! Читтән генә күзәтеп йөргән, күрәсең...

— Уеңа да китермәгән идеңме? Ә ул синең хакта бик әйбәтләп сорашты.

— Ни дидең соң?

— Болай ярыйсы гына мужик... игә килгән чаклары да булгалый, дидем.

— Ишкәнсең икән!

— Хе-хе, йөрәк кылларың азрак зыңлап куйдымы? Җүләр син: үз сеңелемнең ирен, аның семьясын хурлыймыни соң мин!

Хәнәфи өстендәге сырмасының азаккы төймәсенә тикле ычкындырып җибәрде, бер аягын тез өсләтә куйды да аны җәт-җәт селкеткәләп алды. Айдаш белән теге кызый арасы узган көзгә бик нык суынып киткән, шул сәбәпле аларның, Рәсүлә белән икесенең, эчләренә салкын болыт кереп оялаган иде. Соңрак беленде: егет белән кыз арасына Вәсимнән калган теге өянәк, алтын алкалы чибәр юха, кысылып, аларны бозыштырырга тырышып караган икән. Этлекнең чиге бармыни? Бәхетләренә, кышка кергәч, егет белән кыз үзләренең әйбәт мөнәсәбәтен кабат тергезә алган, җылытып җибәргән, язга чykканда инде Айдашлары бөтенләй тиле-милегә әверелә язган иде... Инде әнә боларга семинарга килгән

җирендә, кызның атасы үзенчә разведка ясап кыландырган. Арада кайсы булды икән, кыяфәте нинди́рәк иде икән? Хәнәфи белгән булсамы соң! Их, бу татарның иң кирәкмәгән чакта да артык тыйнак булып йөрүләре! Ярар, алай итүләре, бәлкем, хәерлегә генәдер әле... Урамда язгы шаян җил уйнаклый, тәрәзәгә килеп бәрелгәли, йорт стенасына сырпалана, ә юк, ул инде хәзер тыштан кереп, Хәнәфинең үз эчендә бөтерелә: күңеленең әллә нинди почмакларына орынып, кытыклап куя иде...

— Үзе ничегрәк соң? Ни яшьләрдә? Хезмәте ни?

— Бездән бераз яшьрәктер... Эшләвеме? Нигә, Айдашның әйткәне булмадымыни? Кукуруз игүдә икән. Ә хәзер исә, безнеке кебек, күкрәгенә җен оялаганга охшый: «Инде менә мелиораторга әверелеп барам, бүтәнчә булмый», ди.

— Билен безнеңчәрәк иттереп буарга ниятләгән алайса...— Бу секундта Хәнәфинең йөрәге янә җылы кытыкланудан бермәлгә тукталып ук торды сыман...

— Миннән сорашмаган нәрсәсе калмагандыр да... Беләсеңме, нәрсә ди? — Ризванның тавышында шаярту төсмере инде сизелми дә диярлек, абзаң күзгә күренеп җитдиләнә төшкән иде.— «Шулай инде ул, Ризван туган, дөньяда иң матур күренешләрнең төп асылында мул уңыш ята, аңардан игенченең күңеле түрендә чәчәк ата, уңыш арткан саен аның җиргә тамырлануы да тирәнәя бара», ди.

— Тап минем авыздан суырып алып әйтә икән!

— Бик тә хак сүзләр шул... Үзебезнең башларны өзлексез катырып килгән, миләрне черетеп бетергән әлеге дә баягы социаль укмашу, социаль ныгу дигәнебезнең дә чын асылы әнә шул шәп уңышларда ич — игенченең күңелендә чәчәк аттыруларда...

Хәнәфи, иреннәрен киң җәйгән килеш, ашыгып ияк каккалады. Ә Ризванның күзләрендә шул арада янә шаян чаткылар кабынды шикелле.

— Айдаш, дибез инде, Айдаш... Кайчанга чамалый әле ул? Язгы эшләр түгәрәкләнүгәме? Мәттин агайга әйтеп куясы булыр: атларын шәбәртә торсын, тарантасын-мазарын караштырып, майлап-ялтыратып куйсын... Димәген ки, юллар бераз кибә төшү белән үк...— Ризванның колак өстендәге карандашы хәзер инде кулына күчеп, бармак араларында бөтерелә иде. Тавышына да шук төсмер кабат әйләнеп кайтты.— Юк, бу юлысында баш кода булып үзем китәм! Безнең Сабир армиядән

кайчан өйләнеп кайта да кайчан андый бәхеткә ирештерә әле? Хатынны тарантаска янәшә утыртам да, дугада җиз кыңгырауларны чыңлатып, җилдерт кенә! Ык буеның Тау асты Байларына тикле ничәмә авылны үтәсе бугай — әйдә, авызларын ачып, сокланып калсыннар әле бер!

— Һе-һе, ашыкма — пешүең бар! Егетнең үз әтисе исән чагында монда...

— Ә син «мендәрле кунак» булуның рәхәтен бер татып карадың бит инде. Җиткәндер!.. Ярый алайса, Рәсүлә белән тимер худ арбага утырып иярсәгез ияреpсез — мин каршы түгел, кияү!

— Тимер худ арбага? Уйнама! Туй тарантаслары инде өчәү хәзер — рабочкомга караганы да бар. Юлда, шөлдерләр зыңлатып, узышып барганда... тәгәрәп төшмәгәең!

— Карап карарбыз...

Икесе тиң рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аның соңында, сулышларын да, уй-хисләрен дә бер җайга салырга теләгән рәвештә, бермәл тынып тордылар.

— Ярый, монысын булдырдык ди... Инде хәзер төпчек малаең Рәмзи хакында...

— Нәрсә, аны да... кабаттан өйләндерергә булдыңмы әллә?

— Өйләндерәм... Үтәдем басуына!

— Үтәдем басуына?

Ризванның авыз тирәсендә көлү чалымы сакланса да, маңгай җыерчыклары тирәнәеп-ишәеп киткән, күзләре исә серле үткенләнеп карый иде. Хәнәфи аның, әнә шулай шаяртып-шукланып сөйләшү белән күңелне иләсләндереп куйгач, искәрмәстән генә үтә җитди нәрсәгә күчә торган гадәтен белә иде — сагая калды.

— Дүртенче курсны аударып куйды бит әле ул, эһеме? Димәген ки, диплом проектына тотынырга елдан артыграк әле... Шулай да, институттагыларны күндерә алырбыз дип уйлыйм. Алар өчен дә үтә кызык булыр бу. Бәлкем, институтлары тарихында беренче тапкырдыр әле.

— Аларны ни нәрсәгә күндермәкче булдың тагы?

— Егетнең диплом проектын әйтәм. Ул аңа хәзердән үк тотынсамы? Ул чагында... ул чагында Үтәдем басуы... Ие, диплом проектына беркем дә каршы тора алмый, киресенчә, рәхәтләнеп булышачаклар, бик теләп кулларын куячаклар. Рәмзинең тәҗрибәсе җитәрлек, белеме дә сайдан түгел, үткенлеге дә хәттин ашкан —

без теләгәнне озакка сузмыйча җиренә җиткереп башкарып чыгар дип уйлыйм. Тегеләр өчен нибары диплом эше, ә безнең өчен, туганкай, шундук гамәлгә ашырыласы эш проекты...

Хәнәфи бер тын ара зиһенен җыеп утырды.

— «Хәйләсез — дөнья файдасыз» дисең инде син?

— Була бирсен... Сугару тресты әлегә читтәрәк торып торыр. Хәзер без, шөкер, үз көчебезгә дә ныклап таяна алабыз. Тик күп нәрсә Рәмзинең өлгерлегенә бәйле.

— Ә җиһазлар, ә бүтәне?

— Анысы да табылыр... Акбашевның әнә нефтьчеләр белән әшнәлеге әйбәт кенә. Ә шефыбыз ҚамАЗ? Бар басуны сугаруда бик шәпләп булыштылар бит, оныттың дамыни? Өстәвенә, аларның Қою заводы янында Шилнәдә бөяләре инде өлгереп тә килә. Димәк, шактый арзанга төшәчәк әле безнең бу эшләр...

Тышта җил йомшабрак киткән шикелле: тәрәзә өлгеләре хәзер инде алай ук нык челтерәми иде.

Хәнәфи янә бермәлгә тынып калды, аннары, сулышын кыскан көенчә башын күтәреп, Ризванның ут булып янган күзләренә төбәлде.

— Соң бу... сугару трестын гына түгел, министрлыкның үзен дә кәкре каенга терәтү була түгелме соң?

— Нишләп? «Әйләнечтән — юл туры» дигәнне ишеткәнең юкмыни? Нибары шул гына...

— Тукта, боларны син баш агроном буларак кына кыландырырга җыенасың, моның өстенә син бит әле партком җитәкчесе дә, ягъни ике башлы адәм... Тегендә, шәһәр комитетында, бу кыланышың өчен җилкә тамырыңа дөмбертке белән кундырмагайлары!

— Алай булуы да ихтимал, булмавы да мөмкин. Аңларлар дип уйлыйм. Һәрхәлдә, Низамов үзе... Шушылай тәвәккәлләгәнне ярата бугай ул. Аннары, башын бөгеп караса, аның да бит тамырлары әллә кайларга киткән. Үтәдем басуы кебек һәйбәт җирләр өчен аның да йөрәге янмыйдыр дисеңме? — Ризван, кияве Хәнәфигә, сораулы караш ташлады, әмма аның йөз чалымында үз-үзенә инану аермачык беленә иде.— Тик син Рәмзиенә болар хакында тишелмичәрәк тор. Акбашевны да дәшеп, без аны шушында бөгәргә тырышачакбыз.

— Нәрсә, күнмәс дип куркасыңмы? Рәмзиме? Һеһе, соң бит ул, минем кебек үк, әйбәт чүпрәдә изелеп, шәп күтәрелгән камырдан ласа. Аңардан, телисең икән, түгәрәк ипи яисә күмәч, телисең икән, булка-мазар пешереп чыгарырга була. Тик, артыгын көеп китмәсен-

гә мичәннең кызуы гына таманча булсын! — Беләм мин сезнең нинди камырдан ясалганны — үзеңнең дә, улыңның да! — Ризван ихтыярсыздан үзе дә көлеп куйды.— Ярар, мичнең кызуын таманча гына иттерербез — анысы өчен пошынма, яшьти!

20

Тышта җил чынлап та басыла төшкән икән. Яңгыр сибәләве дә инде сизелми диярлек.

Хәнәфи үз өенә җитәрәк, адымын акрынайта төште, ә капка төбендә исә бөтенләй тукталып калды, ихатага атлап керергә ашыкмады. Монда бер тын ара гына уйланып торды да, якты тәрәзәле өен артта калдырып, тыкрыкка чыкты, әмма караңгыда сукмак белән әллә ни еракка китмәде, тукталып, бакча киртәсенә сөялде.

Күзләрен йомды...

Аңа яшьтие Ризван әйткәннәрне, кабат уйлап һәм кичереп, үз күңеленә тирәнгәрәк сеңдерергә кирәк иде.

Дөнья дөм-караңгы булмаса, ул, мөгаен, тукталып калмас, тыкрыктан авыл читенә чыгып һәм басу юллары белән шактый еракларга китеп, әллә кайлардан әйләнеп кайтыр иде...

Ләкин барыбер чыгып китте... гәүдәсе бакча киртәсенә сөялеп калды, ә җаны белән туган авылының кырбасу түрләренә юнәлде.

Күз кабаклары йомык, дөнья дөм-караңгы, әмма аның күз алдында туган кыр-басулары бар булган төскыяфәтләрендә бик әйбәт шәйләнә иде. Шулай булмаска, күңел күзенең үткенләнгән, җанның илаһи бер яктырып, нур сипкән, ягъни абзыйның туган авылы басукырлары белән ихластан аз булса да сөйләшеп аласы, серләшәсе һәм киңәшәсе килгән сәгате иде бу...

Ел тәүлегендә ничә тапкыр туа микән мондый ихтыяҗ? Әйтүе кыен. Ләкин тумый тормый. Төрле чакларда, төрле халәтләрдә ничектер искәрмәстән, үзеннән-үзе туа да куя.

Машинасыз-нисез җәяүләп кенә чыгып китәсең. Япаялгызың. Бүтәнчә ярамый... Басу юллары, ызан сукмаклары белән ашыкмый-кабаланмый гына атлый бирәсең. Кырлар синеке, син аларныкы. Рухлар кушыла, сүзләр бер тирәдә урала... Шулай туйганчы серләшкәч-киңәшкәч, хәсрәт-пошаманнарың таралып, җаның тынычлана төшә, рухың баеп кайта...

«Басуларны әйләндем әле» дигән тәкъбиргә Хәнәфи

энә шундый мәгънә сала. Бер ул гынамы икән шулай? «Басу әйләнеп кайтулар»ны аның яшьтиләре Ризван-агроном белән директор Мөслим Акбашев та бик ярата шикелле, тик ярып әйтмиләр генә. Хәер, бөтен ил күкрәгендә исәпсез-сансыз чын игенчеләр нәкъ шулай итәдер кебек тоела иде Хәнәфигә...

Җәй башларында хәтфә уҗымнар һәм сабан ашлыклары дәррәү күтәрелеп килгән мәлләрдә кырлар эндәшә аңа:

— Күзләрең нурланып, күңелләрең тулдымы инде, кеше? Маңгай тирләрен җәлләми тамызып, җан аямый эшли белгәннәргә безнең әҗер менә нинди ен!

— Мең рәхмәтләр сезгә, кырларым-туганнарым, дөнья күрке игеннәр!

Соңга табарак, игеннәр өлгереп, тук башаклар өсләтә җитез дулкыннар йөгерешкәндә, басу-кырларның горур өненә беркадәр пошаман төсмере дә кушылып куя:

— Инде тәмам канәгатьме, куанычың күкләрдәме, дускай? Тик син үзең сынатмассыңмы? Бу юлысында да әрәм-шәрәм итмиенчә, бетереп җыя белерсеңме безләрне?

— Җыймаганнар кая! Алтын бөртекләрегезнең берсе дә әрәмгә китмәс, үзегез күрерсез, җаныкайларым!

Көзен игеннәр җыелып, ашлык амбарларга кергәч һәм кырлар бушап калгач, дөресе, тиешенчә сөрелеп, салам эскертләре рәт-рәт тезелешеп утыргач, туган җире үзе башлап җылы сүзләр әйтә аңа:

— Ихластан рәхмәт сиңа, хуҗа! Эшләреңне ыхтымат тота белдең, бу юлысында да сынатмадың!

— Тырышсаң, күңел сала белсәң, шулай булмый ни! Минем карчык әйтә әнә: «Җанынның бер өлешен сала белмәсәң, кая анда ипекәйне һәйбәт иттереп пешерүләр, хәтта ки бәрәңгене дә җүнләп кыздырып булмый», ди!

— Шушы акылны бүтәннәргә сеңдерә белсәгез иде сез, хуҗалар! Инде тормышыгыз матур булсын, алдагы көннәрегез-айларыгыз рәхәттә үтсен!

Бу язны кырлар кардан арынуга Хәнәфи «яңартылган» басуга барып чыккан иде. Чем-кара туфраклы, әле тигезле-тигезсез яткан «күмәчле басу»ның өнендә шикпошаман аермачык беленде:

— Ничәмә еллар тау рәвешендә өелеп, томаланып яткан идем, Кояш нурларын сеңдерә алмадым, җегәрсезләндем... Тиз арада җегәрем кире кайтып, тәмам хәлләнеп, сез адәмнәрне куандыра алырмынмы — бу хакта әлегә әйтә дә алмыйм ын, хуҗам...

Хәнәфи аны тынычландырырга ашыкты:

— Хәсрәтләнмә, пошынма юкка, туганкай! Кояш нурларында туйганчы коенгач, бик тиз хәлгә килерсең син! Инде тәмам ныгып китүең өчен, без сиңа иң әүвәл берьеллык үлән — солы катыш вика чәчәрбез, аның соңында күпьеллык үлән тугаена әверелерсең.

— Шулай димсеңме?

— Шулай!.. Дымга да туенып яшәрсең: без сиңа сугару үткәрәчәкбез. Һәйбәтләп, җиренә җиткереп!

— Алайса, мин сезнең үзегезне дә чын-чынлап куандырачакмын әле, хуҗа! Тик мин шушы яңа җиремнән кабаттан кузгатылмаммы, шушында мәңгегә ятып калырмынмы икән?

— Мәңгегә! — дип ышандырды Хәнәфи «күмәчле басуны»...

Ул сәгатьтә Хәнәфи, колагын сагайтып, күз карашын шактый еракта яткан Үтәдем басуына таба төбәмәгән иде. Әмма ул андагы үтә җегәрле басуның, алдагы язмышы өчен хәсрәтләнеп, авыр-авыр сулап куйгалаганын күңеле белән бик ачык тоя иде...

Кыр-басуларның моң-зарын, шик-пошаманын һәм куанычын-шатлыгын тик өшегән җанлы туң колаклар гына ишетми һәм аңламый. Хәнәфи исә андыйлар рәтендә йөрми, дөньяга килгәненнән бирле, шөкер, туган җире белән уртак җан, уртак рух тоеп яши...

Менә хәзер дә, караңгы тыкрыкта бакча киртәсенә сөялеп торган җирендә дә, ул туган басу-кырлары белән ихластан сөйләшеп-серләшеп алды. Гәүдәсе монда, зиһене монда, ә кайнарланып типкән йөрәге исә бинихая басуларны әйләнеп йөри... Һәм ул күңеле белән Үтәдем басуының өметле өнен аермачык ишетте:

— Язмышымны кайгыртып яшәвегез өчен, меңрәхмәтләр сезгә! Мин барын да ишетеп, тоеп торам. Бәлкем, алдагы көнемнең һаман да матур булырын җайлауда чынлап та бер-бер әмәлен табарсыз?

Кешеләрнең уй-исәпләрен, бәхәс-гәпләрен кырлар ишетми, белми ята дип хаталанма, алар барын да тоеп һәм кичереп яши. Һәм Хәнәфи көр тавыш белән сөзәк үрләр артында еракта яткан Үтәдем басуын тынычландырырга тырышты:

— Табарбыз, тапмый калмабыз, туган! Синдәй җегәрле басу хакына җан фида кылырга әзер торабыз бүгенгесе көнне!..

Аның соңында, вәгъдәсен тагын да ныгытып куяр өчен, яшьтие Ризван һәм әлегә таныш булмаган кодасы авызыннан чыккан сүзләр белән дә раслап алды:

— Ник дигәндә, мул игеннәр үстергән саен, игенченең үз күңеле дә нурланып чәчәккә күмелә. Ә бу исә бик күп нәрсәгә нигез: матур тормышка да, шул тормыш хакына булган кыюлык белән тәвәккәллеккә дә, туган!

Баскан җирендә кымшанмыйча, дөм-караңгы тыкрыкта Хәнәфи, тирән уй-хисләргә чумган хәлендә, әнә шулай туган кыр-басулары белән җылы гына серләшеп торды. Кузгалып, өенә китәргә ашыкмады.

Әлеге тирән уй-хисләренә ялганган рәвештә, янә бер хәл һәм вакыйга аның хәтеренә килде.

Анысы да үтә дулкынландыргыч иде, һәм ул хәлвакыйга кыш урталарында булып үткән иде.

Ул онытылмас гәп-әңгәмә дә, билгеле, яшьтие Ризванның бер үк вакытта партком кабинеты да, агроном бүлмәсе дә булып исәпләнгән, шәп уңыш төсе — ашлык һәм үлән көлтәчекләре, кукуруз һәм яшелчә үрнәкләре белән тутырылган хикмәтле куышында башланып киткән иде.

Ризван алдагы көндә генә Чаллыда партия-хуҗалык активында катнашып кайткан иде, һәм ул, аннан алган тәэсирләрен сөземтә рәвешендәрәк иттереп, ярыйсы ук дулкынланган кыяфәттә, Хәнәфи алдында тезәргә дә кереште:

— Партияле булмагач, син анда катнаша алмадың... Низамов үзе сөйләде, аннары аңа КамАЗның партком секретаре да, бүтәннәр дә куәт өстәде. Шул инде, шефлык мәсьәләсе... Безнең үзебезгә моннан ары тулаем КамАЗ булмаячак, аның бер заводы гына калачак. Нигәме? Соң, шефлык итүләрне әйләнә-тирәгә шактый җәелдерергә ниятләре... КамАЗ күрше районнар чиген атлап үтәчәк. «КамГЭС»ның эрерәк подразделениеләре дә шулай... Хәтта без үзебез дә совхозыбыз белән шефка әверелергә тиешбез. Бөтен районыбыз белән хәтта ки! Соң, шулай булмый ни, бөек Тукай исемен йөрт тә синә!..

— Шулай, бөек шагыйрь исемен йөртү уен эш түгел ул,— дип куәт өстәде шулчакны Хәнәфи үзе дә.

Әйе, алар Тукай районына әверелделәр дә куйдылар берзаман. Ничектер искәрмәстән генә...

Инде менә тәмам күнегеп бетә яздылар. Ә баштарак сәеррәк тоелган иде. Төрле сүзләр дә булып алгаладылар: «Тукай шушы төбәктә туганмыни? Кама аръякларын гизеп йөргән булса икән... Арча яклары үпкәләгәндер инде...» Әлбәттә, болай диюләр бик сай йөзү иде.

Тирәнрәген, Яңа каладан кайтып, кызлары Рәмилә аңлатырга тырышып карады:

— Гизеп йөрмәсә соң... Бүгенге көндә яңарыш кайда, шигърият кайда? Чаллы төбәгендә түгелмени? Бик тә белеп биргәннәр!

Тагын да төплерәген, нәкъ асылына туры килгәнен Хәнәфигә һаман да шул бер яшьтие Ризван-агроном төшендереп бирде:

— Тукай кем ул? Куәтле өермә булып халык язмышына, халык күңеленә үтеп кергән олы бер хикмәтме? Аның бүгенгесен генә түгел, алдагы көнен дә яктыртып торучы сүнмәс йолдызмы? Йолдыз!.. Синең, Хәнәфи, шәһәр комитеты бинасына кереп, аның вестибюлендәге түр стенага мозаика белән язылган шигъри сүзләрне укыганың бармы? Эһе, юк... Йортны салдырганда Низамовның үз башына килде микән, әллә бүтән берәрсе әйтеп микән, белмим... Әмма тап инде бүгенге көннең энҗесе!

Чак кына тынын җыеп торгач, Ризван калган хәтлесен шактый ук пафос белән һәйбәт чарландырып дәвам итте:

— Чаллының гигант төзелешендә лозунг-девизларның төрлесе балкыды инде. Әмма барыннан да көчлерәге, һәммәсеннән дә мәгънәлерәге, мөгаен, Тукай-шагыйрьнекедер... Мин аны, көчемнән килсә, Чаллының күгенә үк ут-ялкын белән яздыртып куяр идем: «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!..»

Шул мәлне Хәнәфинең күңелендә таш диварга сырлап язылган ул шанлы сүзләрне үз күзләре белән күрү теләге уянды да куйды.

Озакламый ана моның өчен үзеннә-үзе җай да туды.

Февраль урталарында Чаллының «Энергетик» культура сараенда «Йолдыз» совхозына узган елдагы уңышлары өчен партия Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Күчмә Кызыл Байрагын тапшыру тантанасы булды. Байракны, бик олылап һәм матурлап, өлкә комитеты секретаре үзе тапшырды. Аңарчы да алар совхозы елныңелында байракларның төрлесе белән шактый еш бүләкләнеп килгәләгән иде. Әмма бу юлы иң Олысы, Союз күләмендәгесе ләбаса! Өстәвенә, бу данлы төбәктә беренчеләрдән булып бит!

Менә шул зур һәм матур тантана тәмамлангач, кайтып китәргә автобус тирәсенә бүтәннәр җыелган арада, Хәнәфи түзә алмады, партия шәһәр комитеты бинасына таба атлады.

Таш баскычка салмак-салмак баскалап, өскә күтәрелде. Пыяла ишекне ачып, эчкәре үтте.

Вестибюль уртасында тукталды. Уң кулда газета-журнал киоскысы, сулда исә бәләкәй генә өстәл артында дежурный утыра. Үтә сәерсенде, ахры. Ярар, сәерсенсә сәерсенер — аның үз эше...

Каршыда, Хәнәфинең нурлы күз карашы алдында, мозаик бизәкле түр диварның өске өлешендә... чын, билләһи, бөек шагыйрьнең сүзләре сырландырылган иде...

Хәнәфи әллә нишләп китте. Бая «Энергетик» культура сараеның сәхнәсендә Олы Байракны алып, аны кулдан-кулга күчереп сөенгән мәлдәге шикелле үк, аның бар гәүдәсе кинәт эсселәп чыкты, сәер дулкын тамагы төбенә килеп тыгылды... Ни тырышмасын, җәт кенә баса алмады...

Шагыйрь сүзләренең татарчасы гына түгел, шунда янәшәдә үк, русчага тәрҗемәсе дә укаландырылган иде:

«Жизнь люби, люби народ и мир его стремлений!..»

21

Рәмзинең кулында улы Вилдан. Көннәр тотрыксыз, җилле һәм яңгырлы булганга күрәдер ахры, соңгы вакытларда, бигрәк тә кичке уңайларда, бәби нык көйсезләнә. Рәмзи аны, һавага чөеп, үчтеки дә иттерә, куллары белән ян-якларга әйләндергәләп, селкеткәләп тә карый, юк, нәни бала еламсыраулы шыңгырдаудан туктамый. Әнисе Зәйтүнә ян бүлмәдә үзләренә ятарга урын-җир хәстәрли, бала чүпрәкләрен караштыра, бишеген төзәтә.

Вакыт инде шактый соң. Телевизорлары тынып калган. Алгы өйдәге репродуктордан, ишетелер-ишетелмәс кенә булып, ниндидер көй агыла.

Рәсүлә бүлмә читендәге кәнәфидә, торшер яндырып, нидер ямаштырып утыра. Аның күзлегендә яктылык нуры уйнап куйгалый.

Хәнәфи гадәтенә сеңгәнчә диван почмагына сыенган. Аның күз кабаклары авырайган, гәүдәсендә исә йомшак оеганлык. Ул, кулына бәбәй тоткан килеш, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренгән улы Рәмзигә күз төшергәләп ала. «Син бүгенгә берни дә белмисең әле, улым,— дип эндәшә ул аңа күңеленнән.— Әмма озакламый сиңа өстәмә камыт кияргә туры киләчәк. Камытның да ниндиен әле! Ие, Үтәдем басуын саклап калмыйча һич яра-

мый безгә... Саклап калу гынамы, бер үк чакны аннан аласы уңышларны да икеләтә-өчләтә үстереп җибәрергә тиешлебез... Син инде бу җәйне, кырыкка ярылсаң ярылырсың, әмма ләкин без йөкләгәнне чын егетләрчә иттереп башкарып чыгарсың — бүтәнчә һич булмый, улым...»

Менә инде Рәмзи ян бүлмәгә кереп китте. Шуның арты ук тегеннән бәбинең, чөмек-чөмек иттереп, ими имгән авазы ишетелә башлады. Яшь ата белән ана ни хакындадыр пышылдашып алдылар. Ул да түгел, әнә инде бишек тә шыгырдарга тотынды. Ләкин шулчакны Рәмзи нигәдер кире бу якка чыкты. Үзе нибары майкадан. Бите, муен тирәләре ябык, әмма кулбашлары, күкрәге нык һәм таза аның.

Рәсүлә, кәнәфиеннән кубып, үзләренә урын-җир хәстәрен күрергә нишләптер ашыкмый. Хәнәфи исә аның кузгалуын көтә.

Өйләрендә тынлык урнашты. Ул менә-менә тулаем оеп китәчәк... Әмма, шулай да, өй һавасында әлегә ниндидер серле киеренкелек саклана сыман...

Соңгы араларда Айдашлары сирәк кайта, кайтса да, куна калмый, тизрәк тегендә, Яңа каладагы үз «оя»сына ашыга: төзелештә егетнең азаккы атналарын эшләп йөрүе...

Хәнәфинең авырайган күз кабаклары үзлекләреннән йомыла, ләкин аның җаны йокымсырап китәргә җыенмый әле. Ул, «яшьтие» Ризван җиткергәннәрне исенә төшереп, татлы хисләрдә йөзә, күз алдында иләсләндергеч күренешләр пәйда була, йөрәген кытыклап, матур уйлар йөгерешә... Пар ат җигелгән тарантаска җәйрәп утырып, басу юлы белән җилдертәләр. Атлар чигүле сөлгеләр белән бизәлгән, дугаларда җиз кыңгыраулар чыңлый... Иң башта, әлбәттә, «мендәрле кунак» булып барачаклар. Соңыннан инде туй үзе... Тегеләре — Рәмилә белән Рәмзи — булдыра алмады. Ә менә иң өлкән улы Айдаш булдырды, ирештерде, аны кодага — Хәнәфи өчен бик тә тансык, бик тә кадерле ул җанга... мең рәхмәт үзенә! Ие, хәзер инде шулай дисәң дә ярый торгандыр... Кода, кода... Ризван сүзләренә караганда, чын адәми җанлы, ипле кеше булырга тиеш. Аралары нибары утыз-кырык чакрымлап... Бүгенге көн өчен ни ул?..

— Әти, дим...

— Нәрсә, улым? — Хәнәфи күз кабакларын авырлык белән генә ачты, әмма иреннәре татлы хисләрдә җәелгән килеш кала бирде.

— Вәсим абыйдан хат бар.

— Шулаймы? Ниләр язган соң?

— Иң әүвәл сәламнәрен тезгән... Ә сиңа аерым атап язган.

— Һе... Вәгаләйкемәссәлам! — диде Хәнәфи киң бер сулыш белән, әмма тавышы ничектер карлыгыбрак чыкты.

Бу минутта Хәнәфи ана белән улның үзара күз атышып алганлыгын бөтенләй абайламады: моңа кадәр Вәсимнән сәлам ирештергәндә, ата кешенең мондый матур сүзне авыз тутырып әйткәне юк иде, ул нибары «һе» дип кую белән генә чикләнгәләр иде.

— Аның соңында ни сайраган тагы?

— Әни исеменә акча салдым әле, шушы хат артыннан ук барып җитәрдер, дигән... Мең тәңкә!

— Мең тәңкә?! Тагын берәр мөгез чыгарырга җыенды микәнни?

— Мөгез сиңа, мөгез! Уртанчың хакында җүнлене уйлый да белмисең! — Рәсүләнең күзлеге маңгаеннан кулына күчте, кыяфәте белән ул күзләреннән дә, авызыннан очкыннар чәчрәтергә әзер кебек иде. — Соң, абыйсының туе чамалана ласа, шуңа әйбәтрәк бүләк алырга кушып! Әнә хатын үзең укып кара!.. Үзе кайта алса икән.

Моңа хәтле улыннан килгән хатны Хәнәфинең үз кулына алып, укыганы булмады, бу юлы да хатка үрелергә ашыкмады.

— Аңа мин гаеплемени? Үз хикмәтләре... Ул тикле еракка китеп олагырга кем кушкан аңа?

— Күр, гаебе юк, имеш!

Шулчакны, чын ирләрчә гап-гади ныклык күрсәтеп, араларына Рәмзи кереп өлгерде:

— Ярар, четердәмичә генә... Вәсим абый аныcын да язган әнә: «Алай-болай авылга кайтырга исәп итсәм, ни әйтерсез, анда миңа кулайрак эш табылырмы икән?» — дигән...

— Шулай дигәнме? «Ни әйтерсез?» дигәнме? — Хәнәфинең күкрәк читлеге эчендә капыл гына нидер убылып төшкәндәй булды, һәм ул «нидер», бугазы төбенә менеп, сулыш юлларын томалап алгандай иттерде. Ие, ата кеше җәһәннәм тишегенә китеп олаккан уртанчы улыннан нәкъ менә шушындый сүзләрнең килүен көтә, бик көтә иде. Улының бөгелүе түгел, сынуы хаҗәт иде аңа...— Соң ни... мин каршымыни? Кайта бирсен... Ул инде анда үзенә тиешле юлның саласын салгандыр,

шәт... Аннан килеп, үз туган туфрагында маңгай тирләре түгеп тапкан тиеннәр тегендәге алтын тәңкәләрдән мең өлеш кадерлерәк тә әле ул...— Хәнәфигә үз тавышы ничектер артык басынкы, хәтта мескен һәм нәүмиз рәвештә чыккан кебек тоелды, юк, ачы кырыслык ук булмаса да, азрак ныклык һәм катгыйлык чаткысы да кирәктер, ахрысы... Тамагын кыргалап алды.— Тик ни... өйдәгеләре җебеп төшкәннәр дә җәелеп киткәннәр дип уйламасын тагы... Ие, улым, җавап хаты язган чагында, кистереп әйт: монда аңа техниканың өр-яңасын тоттырырлар дип, өметләрен зурдан кабындырып куймасын... Тракторның искесенә, иң аламасына утырыр!

22

Күк гөмбәзеннән салмак кына соры болытлар агыла. Юк, алар әллә ни авыр түгелләр инде. Кичә-бүген җир өстен яман камчылаудан бизеп агалар иде.

Чем-кара басу читендә өчәү басып тора.

Өч «яшьти», өч фронтовик-ветеран...

Өчәү... Алар әледән-әле, җиргә таба иелә төшеп, учларына туфрак алалар, кысып карыйлар. Дымлы. Укмаша. Таралып китәргә уйламый да...

Күз карашлары әле күккә төбәлә, әле басу иңнәренә сибелә...

Кояш томаланган. Иң кирәк чагында аның җиле дә, чәнчелгере, катырак исә белми, ичмаса...

Көтәләр...

Гәүдәгә тазалар, ныклар. Өсләрендә күн тужурка, кыска пальто, сырмадыр. Аякларында резин итекләр. Йөзләре хафалы.

Май бәйрәме арасында, күк йөзе ачылып, әйбәт кенә ирек биргән иде. Байтак җирләрне эшкәртеп һәм чәчеп чыгарга өлгерделәр. Аннары янә юеш камчысы белән тотынды шыбыр-шабыр чыбыкларга!

Һай, сузылды ла!.. Ә бит эшләнәсе эшләр биниһая әле: эшкәртәсе, чәчәсе, утыртасы!

Иртәгә Җиңү бәйрәме...

Бүген кич аны, әлбәттә, билгеләп үтәрләр. Бәлкем, Яңа поселокка Мөслим Акбашевның каладагыча бай һәм матур җиһазлы квартирасына җыелырлар, ә бәлкем, үзләренең Әҗерләрендә генә калып, авылда күнегелгәнчә уздырырлар. Утыз өч ел буена өзми-нитми бәйрәм итеп килсеннәр дә, яз яман юньсез һәм усал килде дип, ничек инде аны мыштым гына уздырып җибәрәсең ди?

Иртәгәсен, Җиңү көнендә, әлбәттә, кабаттан басу иңнәрен буйлауда булырлар...

Алардан чак кына арттарак межа читендә чәчү агрегаты, ашлык төягеч машина... Бер кырыйдарак чәчүчеләр — нык һәм таза гәүдәле өч-дүрт адәм — көлә-шаяра учак ягып җибәргән. Коры-сарыны якындагы куаклыктан ташыйлар. Янәсе, файдасы тиеп, күк йөзе «кибеп» китмәсме...

Мондагылар исә сабырсызланып туфрак изәләр, әледән-әле җиргә таба иеләләр...

Чытыр-чатыр янган учакның файдасы «тиде», ахры: әнә инде күк йөзендәге болытлар арасында зур-зур ертыклар да күренгәли башлады.

Сабыр, сабыр...

Ә чәчкечләргә гәрәбәдәй орлыклар инде тутырылган. Сортлы бодай. Ашлама тартмаларында исә җир сыеның һәйбәте...

Инде менә шушы елны нишләр? Нишләтер?

Күз карашлары, үзеннән-үзе соры болытларга ияреп, еракларга китә — алдагы көн һәм айларга төбәлә сыман...

Ә чем-кара туфраклы басу һәйбәт эшкәртелгән — ул күпертеп куелган хәтсез киң ястык сыман...

Күзләр күктә... Менә бу араларда тоташтан аязып торсын иде дә, җәйгә кергәч, иң кирәк чакларда, явып-явып киткәләсен иде лә!

Дым, дым... Игенченең мәңгелек зары һәм теләге!

Бу өчәү белми әле, беркем дә белми: күк аларның теләген өлешчә кабул итәр. Кабул итәр дә... аны унлата тапкырлар арттырып үтәргә тотыныр!

Җәен дә, көзен дә көннәр-төннәр тоташтан диярлек яңгырларга китәр. Күк гөмбәзе җүнләп ертыла да белмәс, елмаеп балкуларны онытыр...

Салкыннар торыр...

Игеннәр өч атнага соңлап өлгерер... Кукуруз уңмас, әмма, аның каравы, болын үләннәре билдән булыр. Җыеп алмага бары бергә төртелер...

Ифрат кыенга килер. Чиксез көчәнәсе булыр...

Мондыйны ил картлары да яденә китерә алмас...

Фронттагыча чын көрәш җәелүе, фидакарь хезмәте белән бу ел гасыр хәтеренә тирән сеңеп калыр!

Бу хәл Илнең бөтен Европа өлешендә булыр...

Мондагыларга исә ҚамАЗ халкы һәм төзүчеләр ярдәмгә ашыгыр. «Йолдыз» совхозына Айдаш Бариев кайтып төшәр. Инде бөтенләйгә! Аңа бүтәннәр ияреп...

Югалтулар да аз булмас. Урып-җыю эшләре кар төшкәнчегә кадәр сузылыр...

Алай да җиңәрләр!

«Йолдыз» совхозы меңләгән мал-туарына ныклык азык базасы булдыру өстенә, үз йөкләмәсен икеләтә, Ватан амбарларына үзенә аерым «алтын эшелон» озатып куяр.

Ә шушы сабан бодае — атаклы «Мәскәүский сорт»? Ишелеп уңар! Күкрәкләргә җитеп үссә дә, һич сөрлекмәс, тук башаклары күпереп-тырпаеп торырлар!

Аңа комбайнны турыдан-туры кертеп җибәрерләр. Соңыннан, җыеп, суктырып алгач, үзләре дә хәйран калыр: тулаем биш йөз гектардан уртача алтмыш ике ярым центнер чыгар! Ә Үтәдем басуы? Анысы, сугарулы мәйданга әверелгәнче, азаккы тапкырында, «дымга кирәгенчә туена белсәм, менә мин нинди!» дип, алга таба киң ишарә ясаган сыман, уртача алтмыш дүртәрне бирер! Төшләргә дә кермәгән уңыш лабаса! Әлбәттә, Казан радиосы бер шаулап алыр, республика газеталары да читтә калмас...

Ләкин аңа кадәр шактый вакытлар бар шул әле. Аңарчы чиксез көчәнәселәре бар!

Хәзер исә карашлары күк гөмбәзендә һәм басу иңнәрендә. Күңелләрендә бүгенге көн, бүгенге хәлләр... Хәер, Хәнәфинең күңелендә бөтенләй бүтән төрлесе дә чыңлана иде...

Бүген иртән, шушы басуга юл тотканчы, теплица янында ишетте ул аны: вахта автобусыннан төшкән шәпкә, яшелчәче хатын-кызлар җырлады ул таныш җырны. Башта Хәнәфинең колагында аның кушымтасы, инде күп тапкырлар яңгыраганы чыңлап торды:

Гәрдәлем, Гәрдәлем,
Калырсың мәңгегә
Күңелем түрендә...
Күңелләр түрендә!..

Әмма шуның арты ук тагын да куәтлерәк төстә, дәррәү күтәреп, Хәнәфи моңа кадәр ишетмәгәнне, күрәмсең, җырның өр-яңа өстәмәсен гөрләтеп җибәрделәр.

Җир, диләр, әйләнә, җирнең дә бар, диләр,
Ялкыннар дөрләгән үзәге...
Авылым кырлары кызулый заманны,
Җирнең лә күчәре түзәрме?..

Жыр әле сүнә төшә, әле кабаттан чиксез бер дәрт белән дөрли Хәнәфи күңелендә...

Шулай да жырда күпкә ансат... Ә чынлыкта, тормышның үзендә?

Заманaны кызулый-кызулый, дөньяны ямьгә-нурга күмелдермәкче булып, язмышлар яңартырга тотынсаң, һай, бер генә дә жиңел түгел шул, жиңел түгел! Һәммәкие дә жанны айкап ала, кайчакларда хәтта ки бәгырьләрне телем-телем кискәләп үтә лә...

Чын әгәр, чыдамлык белән ныклыгын дисеңме, кыюлык белән тәвәккәллеген дисеңме — һәммәсен дә һәр жәһәттә, һәрдаим belә-белеп үткенлә, очкынландыр... Әмма төп асылда вөжданың белән намусыңа йокымсырарга бирмә. Алдагысы көнеңне көн итәм дисәң...

Яшьтие Ризван орынуга, Хәнәфи айнып киткәндәй булды.

— Әллә, дим, тотынабызмы әкренләп, ә?

Баш агрономның кулында бер уч кара туфрак иде. Әмма ул, туфрактан бигрәк, алга таба ым какты: арыдарак басу читләренә тимгел-тимгел кояш яктысы төшкән иде. Менә ул матур һәм тансык яктының озын бер көлтәсе еракта Яңа кала белән ҚамАЗ корпусларын да сыйпагандай иттереп узды...

Хәнәфи, аңа ияреп Мөслим Акбашев та жирдән берәр уч туфрак алдылар, аны кыскалап тордылар.

— Керешсәк тә ярар,— дип жүпләп куйды Хәнәфи.— Менә жир үзе дә әйтеп тора: «Инде өлгереп житеп киләм... Иләп кенә изге эшегезне башлап жибәрсәгез дә була», ди... Әллә тоймыйсызмы?

Хәнәфинең бу сүзләреннән Мөслим Акбашевның да, Ризван-агрономның да какча йөзләренә капыл якты нур йөгерде, жылы гына елмаешып куйдылар.

— Әйе, жир үзе дәшә,— дип пышылдады Мөслим Акбашев һәм, чәчү агрегатына таба борылды да, һавада соры эшләпәсен болгый-болгый, көр тавыш белән чәчүче механизаторларга кычкырды:

— Әйдәгез, егетләр, кузгалыйк булмаса! Хәрәкәттә — бәрәкәт, диләр кебек!

Аз гына вакыт үтүгә куәтле гөрелте авазы купты, һәм чәчү агрегаты йомшак туфраклы киң басу түренә юлланды...

1974—1984
Чаллы-Брежнев

ЭЧТӘЛЕК

Беренче китап
ДУЛКЫН

Беренче өлеш 4
Икенче өлеш 131

Икенче китап
ШИҢМӘСЕН ГӨЛЛӘРЕҢ

Беренче өлеш 242
Икенче өлеш 379

Эдуард Салихзянович Касимов

ПУСТЬ НЕ ЗАВЯНУТ ЦВЕТЫ

Роман

(на татарском языке)

Редакторы *К. Миңлебаев*
Рецензенты *Н. Юзиев*
Художнигы *И. Воробьев*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Л. Тилк*
Корректорлары *Р. Хәмидуллина, М. Хәйруллина*

ИБ № 4247

Наборга бирелде 28.01.86. Басарга кул куелды 6.06.86. ПФ 01071. Формат 84×108$^1/_{32}$. Типография кәгазе № 3. Гарнитура литературная. Печать высокая. Якынча басма табагы 25,2. Усл. кр. отт. 25,5. Учетн.-изд. табагы 27,1. Тираж 13 300. Заказ Т-78. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан китап нәшрияты.
420084. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420084. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты.
420084. Казан, Бауман ур., 19.

1 сум 80 тийн